ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11. 1994



# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1995 ЕЛДА

**«Казан утлары» журналы укучыларыбызны татар әдәбиятының кызыклы, күренекле яңа әсәрләре белән таныштыруны дәвам итә. Редакциябез хәзинәсендә әдипләрнең күләмле проза әсәрләре дә байтак. Без аларны укыйбыз, өйрәнәбез һәм, әлбәттә, сезгә тәкъдим итәргә ниятлибез. Җөмләдән, кайберләре:**

**Хисам Камал.** «Түләнмәгән күз яше». *Роман.*
**Гомәр Бәширов.** «Гыйбрәт». *Роман.*
**Ринат Мөхәммәдиев.** «Утлы таба өстендә». *Роман.*
**Ризван Хәмид, Рөстәм Мингалимов.** «Идегәй». *Киносценарий.*
**Фәрит Яхин.** «Август ае». *Роман.*
**Гариф Ахунов, Мәгъсум Гәрәев.** «Арча ягының ачык китабы». *Документаль повесть.*
**Аяз Гыйләҗев.** «Камыш бармак, көмеш тырнак». *Повесть.*
**Шәүкәт Галиев.** «Истәлекләр». *Биографик әсәр.*
**Атилла Расих.** «Тыныч еллар күләгәсендә». *Автобиографик әсәрнең өченче китабы.*

Шагыйрьләребез яңа әсәрләрен тәкъдим итәләр: **Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Харрас Әюпов, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Роберт Әхмәтҗанов, Рәдиф Гаташ, Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьҗан, Рәшит Әхмәтҗанов, Илдус Гыйләҗев, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рашат Низамиев һ. б.**

Фәнни, тарихи, публицистик мәкаләләрдән:
**Габделбари Баттал-Таймас.** «Казан төркиләре».
**Александр Беннигсен.** «СССРда мөселманнар».
**Габдрахман Авторханов.** «Рәсәй язмышында Ленин».
**Садри Максуди.** «Англиягә сәяхәт».

Журнал сәхифәләре Сезгә алдагы елда да яктылык, күңел бәйрәме, көтелмәгән очрашулар алып килер, дип ышандырабыз.

РЕДАКЦИЯ.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**(865)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Р. ХАРИС. Мәхәббәт шигырьләре ........ 3
Я. ЗӘНКИЕВ. Иртеш таңнары. *Роман* . 10
М. НӘЗИРОВ. Язганым савап булырмы? *Шигырьләр* ........ 77
Н. МӘДИЯРОВ. Елларымны бизи шигърият. *Шигырьләр* ........ 82
С. МУЛЛА-ГАЛИ. Нигә өшим? *Шигырьләр* ........ 87
Ф. ӘМӘК. Чытырманда кош оясы. *Повесть* ........ 91

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ӘХМӘТҖАН. Мәгърифәт нуры чәчәр ........ 135

МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВКА 60 ЯШЬ

А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Командор ........ 147

ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Шамил Усманов көндәлеге ........ 154
Б. СОЛТАНБӘК. Ул елларда... *(Шамил Усманов көндәлеге турында галим фикере)* ........ 170

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ч. ЗАРИПОВА. Сәгыйть Рәмиев һәм Нәсими ........ 173
Г. ФӘЙЗЕРАХМАНОВ. Берәгәйле булсын иде. *(Булачак «Татар энциклопедиясе»нә бер караш)* ........ 180

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

А.-Г. РҮРЛИХ. Алтын Урданың бүгенге варислары ........ 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнен адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: Продолжение романа Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша»; повесть Ф. АМАК «Птичье гнездо в дебрях»; стихи Р. ХАРИСА, М. НАЗИРОВА, Н. МАДЬЯРОВА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА.
«Публицистика»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА посвящена проблемам воспитания молодого поколения на основе национальных традиций.
«К 60-летию М. Салимзянова»: статья А. ГИЛЯЗОВА «Командор».
«Эхо прошлых лет»: дневник Ш. Усманова; статья Б. СУЛТАНБЕКОВА «В те годы».
«Литературная критика»: статья Ч. ЗАРИПОВОЙ «С. Рамиев и Насими»; статья Г. ФАЙЗРАХМАНОВА «Пусть будет полноценным» посвящена «Татарской энциклопедии», которая скоро выйдет в свет.
«К истории народа»: статья А.-Г. РУРЛИХ «Современные наследники Золотой Орды».
Хроника культурной жизни.
«На наших обложках»: «Лето» — картина художника Р. Гусмана; известный писатель А. Гаффар.

## IN OUR ISSUE.

«Prose and Poetry»: Ya. Zankiev's novel «Irtish's Daybreaks»; Ph. Amak's novel «Bird's Nest in the Dense Forest»; the verses of R. Kharis, M. Nazirov, N. Madyarov, S. Mullagaliev.
«Publicism»: M. Akhmetzyanov's article devoted to the education of the younger generation on the basis of national traditions.
«To the 60 Anniversary of M. Salimzyanov»: A. Gilyazov's article «The Knight Commander»
«Echo of the Past Years»: Sh. Usmanov's diary, B. Sultanbekov's article «In Those Years»
«Literary Critique»: Ch. Zaripova's article «S. Ramiev and Nasimi»; G. Phayzrakhmanov's article «Let It Be Valuable». This article is devoted to the «Tatar Encyclopaedia» which will published soon.
«To the History of Nation» A. G. Rurlikh's article «Contemporary Heirs of the Golden Horde»
«The Chronicle of the Cultural Life»
In our corvers: R. Gusman's picture «Summer»; well-known writer A. Gaphar.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 29.09.94 ел. Басарга кул куелды 3.11.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 819. Заказ А-454. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# ШИГЪРИЯТ

**Ренат**

**Харис**



## МӘХӘББӘТ ШИГЫРЬЛӘРЕ

### Кочак иясе

Минем сагыну сиңа күчә бугай —
түзем тәмам дулый дигәндә
пәйда буласың да әллә кайдан
һәм аласың мине йөгәнләп.

Һәм биклисең мине кысан, кайнар
кочагыңа... Шундый сөясең —
мин ул чакта адәм түгел инде,
мин ул чакта — Кочак Иясе!

Ләкин синең кочакныкы гына!
Башкаларга инде сыялмыйм,
йөрәгемә чөнки сине керткән,
сине йөрткән ике дөнья мин!

* * *

Гаҗәпкә калып торасың,
җиталмыйсың төшенеп —
язмышымны тоттырырлык
ние бар бу кешенең?!

Йөрәгемә шырпы сыза,
җанымда су кайната,

Ренат ХАРИС (1941) — *шагыйрь, күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил премиясе лауреаты. Казанда яши.*

каннарыма таш тоз сала
әйләнеп кайта-кайта.

Сүзе белән телеп ала,
күзе белән бораулый...
Елына бер елмайса да
эрим, каршы торалмыйм...

Ничек аны Җир күтәрә,
ничек өреп төшерми?!.
Синең, әйе, күргәнең юк
миндәй авыр кешене...

Ә шулай да бардыр миндә
бер яшерен матурлык,
Җир дә, син дә, кешеләр дә
тартылырлык, татырлык...

* * *

Тынычлыгың киметсәм дә,
бәхетсезлегең түгел мин...
Яшь булып тулганмын икән,
йом күзеңне, мин түгелим.

Үкенечләр ташы булып
күкрәгеңне кысам икән,
турай, тетрән — мин китәрмен,
һәм кагылмам сиңа бүтән.

Бугазыңда утырсам мин
уфтану төере булып
ятлар үбүен су итеп
ул төерне йот та, оныт...

Үтенечнең барысын да
үтә әле, үти алсаң,
ләкин уйла: мин нишләрмен
син барында синсез калсам?..

* * *

Кеше арасына поса-поса,
кулны түгел, керфек кенә изәп,
калган чакның кыска минутлары
йөрәгемдә гомер булып үсә...

Ул гомердә күпме вакыйгалар:
ачу, көнләү, елау, аһлар-зарлар
күңелемнең ак, пакь китабына
үкенечләр булып язылалар.

Һәрбер хәреф — кызган келәймәдәй...
Нигә әле миңа мондый язмыш?!
Бу дөньяда әллә яшермичә
сөеп була торган кеше азмы?!.

Син китәсең... Мин каламын ялгыз...
Кем дә белми шулчак, әй, хәлемне —
халык уртасында басып торам,
«Яшерен сөю» дигән һәйкәл мени!..

* * *

Битемдәге ерганаклар буйлап
йөрде синең кайсы бармагың?
Күзем сүнде... Җаныма син салган
эзләрне мин кабат барладым.

Тәүге тапкыр кулың кагылган эз...
Күз яшеңнең утлы тамчысы...
Иренеңнән сеңгән дәртле тетрәү...
Сүзләреңнең салкын кайчысы...
Күңел күзем йөрде эзләр буйлап.
Ачылары күпме?! Татлысы!
Кайберләре өтеп алсалар да,
кагыласы килде, саклыйсы...

Битемдәге упкыннарга төште
дерелдәгән җылы бармагың...
Күзем йомып, күңелемне бикләп,
мин үземдә сине барладым.

* * *

Мин кайчакта,
кирәкмәгән сорау биреп,
үз башыма гөрзи белән орам.
Чаткы чәчри... Йөрәгемә янгын каба —
әй сызланам! Тешем кысып чыдап торам.

Күзләремнән эчкә таба, күкрәгемә,
ташып ага үкенечнең сыек бозы.
Ялкын сүнә.
Күтәрелә булы төтен —
үзе салкын,
үзе ачы,
үзе тозлы...

Югыйсә бит җавабы да кирәк булмый...
Килә шунда дөньясына кул селтәсем...
Катып калам...
Һәм кычкырам тавыш-тынсыз:
«Ник, йөрәгем, акылымны кимсетәсең?..»

* * *

Йокысызлык төнгә әйләндерде
мине тәмам... һәм мин йокламыйм —
йокы даруының төймәсе дип,
ахрысы, мин кояш йотканмын.

Күз эчләрем көннән яктырактыр...
Алка-алка төсләр уены...
Ә уйларым инде алҗып бетте
куе яктылыкта коенып.

«Минем уйлар аны туйдыргандыр...
Арыткандыр аны назларым...»
Нишлисең бит — кышның башларына
туры килгәч йөрәк язлары!..

Бөтен хисләр икегә һәм өчкә
тапкырлана икән ул чакта...
Учларына бармак кагылса да
хис итәсең: «Мин бит кочакта».

Йә булмаса: «Бәлки, минем назым
ул көткәнчә түгел, үшәндер?..»
Мин күкләргә диеп уйлап чөям,
ә ул аңа бары түшәмдер!..

Ә мин аңа куанычлы гомер
вәгъдә иткән идем кайчандыр...
Якты вәгъдәләрем минем, бәлки,
күзләремә кереп качкандыр —

күз эчләрем көннән яктырактыр...
чәрдәкләнгән төсләр бәйләме...
Йокысызлык мине тәмам изде,
һәм мин инде төнгә әйләндем...

* * *

Нигә авыз иттем бу чишмәдән?
Нигә суладым бу һаваны?
Алар бары озайттылар гына
сусавымның авыр дәвамын.

Нигә авыз иттем бу чишмәдән,
эчеп бетермәгәч бар суын? —
дулкыннары кереп авырайтты
йөрәгемнең татлы ярсуын.

Нигә суладым мин бу һаваны,
күрә торып куе болытын?..
Моңа кадәр минем йөрәгемдә
нинди туйлар булган — оныттым.

Нигә авыз иттем бу чишмәдән,
нигә суладым бу һаваны,
дарулардан шифа табалмагач,
агулардан эзләп дәваны?..

## Сәрләүхәсез

*Лилиягә*

I

«Мин сине сөйгәндә
син кемне яраттың?..»
Бу сорау өстенә
ничәмә кар ятты,
ничәмә эреде,
әйләнде ул парга...
Без һаман элекке —
һаман да без ярлар.

II

Безнең өй, мин беләм,
һич җәннәт түгелдер —
бөрешкән мендәргә
күпме яшь түгелде,
кандагы кайнарлык
назларны киптерде.
Нишлисең? Тормыш бу!
Син — тере. Мин — тере.

III

Үпкәләр, үпкәләр!
Кемнәрне өтмәгән!
Чүмечләп эчтек без,
чамалыйм — бетмәгән,
бетәчәк тә түгел,
бетмәсен, үтмәсен —
җансызлар гына тик
булалар үпкәсез.

IV

Син хаклы. Мин хаклы.
Икебез дә хаксыз.
Була ул еш кына:
җөп уйлар, ә так сүз.
Шуңадыр, мөгаен,
җаннарны аралап,
ярыкка чөй сугып,
шик-шөбһә ярала.

## V

Йөрәкләр авырта...
Сәбәпләр төрледер.
Кайчакта гади сүз
куркыныч серледер.
Кайчакта гайбәтнең
агулы энәсе
хисләргә яман чир
чигәдер, күрәсең...

## VI

Кешедә иң бөек
хис нәрсә дигәндә,
«Көнләшү!» дип әйтә
курыкмый бу бәндә.
Мин аны татыймын...
Син аны татыйсың...
Күнеккән чәчәкнең
тату ул ят исен...

## VII

Ә бәхет дигәнең
һәркемдә үзенчә.
Ә безнең — безнеңчә! —
дип әйттем мин ничә.
«Ә безнең — безнеңчә»
нәрсә ул дисеңме?
Ул — синең җисемең
һәм минем исемем...

## VIII

Артта юл озынрак...
Алда юл — кыскарак.
Җан, шуны күрептер,
яшәүдә остара.
Ә яшәү ул — сөю!
Мәңгелек формула!
Һәм моны оныткан
соң чиктә хур була.

## IX

Син мине сөйгәндә
мин кемне яраттым?
Мин җанны бүлгәләп
галәмгә тараттым.
Иң матур кисәген
кем алган? Бу сорау
канымны кайната,
җелекне суыра...

* * *

Мине чиргә сабыштырдың
сагыну беләп сынап...
Күз йомып алган чакта да
мин сызланып юксынам,
котым очып күзем ачам
тизрәк күрергә теләп —
син бит миңа бу дөньяда
бирелгән сихри бүләк!
Күрәмен дә — онытамын
гомер чорын, сәгатьне...
Син бит минем яшьлегемнең
үлемсезлек сәләте...

* * *

Мин төн кичтем...
Өйдә түгел...
Җирдә дә түгел хәтта...
Сөюнең гарше көрсие[1]
урнашкан бөек катта.

Ләкин берни хәтерләмим,
чөнки берни күрмәдем,
беркем белән сөйләшмәдем,
чыкмадым һәм кермәдем.

Мин эредем һәм таралдым
галәм чиксезлегенә —
җирдәшләрем гаҗиз булып
беткәндер мине эзләп.

Ләкин үзем яши бирдем
бөтен бер аң, җан булып,
дөньяның барлык ләззәте
бер миңа гына тулды...

Тамырларым, һәр күзәнәк
бәлзәмләнде ләззәттә...
Көнләшмә, тәңре, бит мин дә
әйләндем үлмәс затка!

[1] Алла тәхете урнашкан иң бөек, югары кат.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Якуб Зәнкиев**

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАН

Сания бу конарсыз бәндәнең дөньяда барлыгын күптән оныткан иде инде. Әллә шушы адәм актыгы белән очраштырыр өчен генә ачтымы Гитлер-иблис бу сугышны? Ялан авылыннан ничаклы ата балалары сугыш кырларында таралып беттеләр, ичмасам ник шуларның берәрсе очрасын! Ире Мөхәммәт тә өйдә генә ята алмагандыр, ул да шушы, дөнья халыкларының язмышы хәл ителә торган канлы мәйданнарның берәрсендәдер... Исәнме ул? Хат-хәбәрләр элегрәк тә саркып кына килеп җитә ала иде. Хәзер исә, дошман кулына әсир булып төшкәч, туган илдән бер хәбәр килеп ирешсә дә дөнья могҗизасы булыр иде.

Ай ярым элек дошман кулына төшеп, хатын-кыз әсирләр арасына катнашып байтак лагерьлар узган, җәбер-җәфа ашаган, киеме теткәләнгән, йөзе алмашынган Сания шушы иләмсез алама адәм белән очрашырмын дип уйлый алмаган иде, оныткан иде ул бу мөртәтне!

Теге әшәке бәндә аны Форштад шәһәре тирәсендәге концлагерьга олактырды. Шул явыз гына ашады аның башын. Сания белән бер тирәдәрәк дошман кулына төшкән хатын-кызларның байтагысы немец алпавытларына эшкә таралды, бер ишләрен фабрик-заводларга урнаштырдылар. Сания өлешенә төшкән юл иң авыры, иң өметсезе, иң катлаулысы булып чыкты.

Чираттагы зонага аларны төнлә китереп ташладылар. Бу зонаның исеме, кайдалыгы белән дә кызыксынмады Сания. Сырхап тора, ике көн инде тәне кызышып, башы авыртып йөри. Сынык күңелдә бер аяусыз сорау гына тере калды: «Бер-бер чиге булырмы моның, Ходаем!»

Зона белән танышып өч көн узды. Яңа урын, яңа иптәшләр, ә тормыш шартлары, режим һәркайда да бертөсле диярлек. Таңнан уяталар,

Дәвамы. Башы журналыбызның 10 нчы санында.

мәйданга чыгарып тезәләр, санап бетергәч тә таратмыйлар, кемнедер көтәләр. Менә төш җитә, төштән соң зонага хушбуй исләре таратып көттә киенгән немец марҗалары кереп тула. Базар башлана, немец марҗалары әсир хатын-кызлар тезелгән рәтләр буйлап әкрен генә баралар, үзара бер-ике сүз алмашалар, җете күзләре белән Рәсәй хатыннарын тишеп-тишеп тикшерәләр — мал сайлыйлар. Кол кирәк аларга кара эшләрне башкарырга, мал-туар багарга, өй, ишегалды, бәдрәфләрне чистартырга кол кирәк. Шушы кол базарына Санияне дә китереп керттеләр. Беренче көнне аңа игътибар иткән кеше булмады, икенче көнне калку буйлы, нечкә озын аякле фрау тукталып, аның илдә кем булып эшләвен сорады. Саниянең врач икәнен белгәч, тиз үк аның янынан үтеп китте. Әлегә дошман иленнән килгән врач аларга кирәкми иде. Ник шикләнгәннәрдер, Сания аңламады, атна буе коллар рәтендә басып торып берәү дә аны ияртеп китмәде.

Зона зур, шактый киң мәйданга җәелгән, бер ягы белән ир-атлар зонасына барып тоташкан иде. Ир-ат әсирләр ишле булу өстенә, аларда хәрәкәт шактый көчле иде. Этап килә, этап китә, каяндыр китерәләр, каядыр ташыйлар. Бер төнне Сания йокысыннан куркып уянды, ничектер аның Мөхәммәтен дә шушы әсирләр зонасына китереп кертkәннәрдер кебек тоелды. Әсирлектә күнелгә килгән курку тиз генә китми, куркып уянганнан бирле соңгы тынычлыгын югалтты. Хәзер ирләр зонасында ыгы-зыгы сизелсә, этләр өрә башласа, ул башын-күзен онытып ирләр зонасы ягына ташлана. Бүген дә шулай булды. Карлы яңгыр төшкәләп торган төксе бер көн иде. Тегеннән дә, моннан да хатын-кызлар йөгерешергә тотынды, алар бар да ирләр зонасы ягына таба чабалар иде. Барасы да килә Саниянең, күңеле дә тартмый, аягына гер элгәннәрмени! Барса, бүген, нәкъ бүген ул тирәдә аны ниндидер күңелсезлек көтәдер кебек. Үз-үзе белән тарткалашып, атларга мәҗбүр итеп чәнечкеле тимер чыбыктан үрелгән киртә буена тезелеп баскан хатын-кызлар арасына барып керде Сания. Әсирләр! Урыс армиясе солдатлары. Таныш шинельләр, колакчыннары өзелгән таныш бүрекләр. Шәүлә-күләгәләр, кичәге солдатлар... И Аллам! Никадәр солдатлар, бәхетсез ана балалары! Кысыла торгач Сания алгарак чыкты, әсир-солдатларны ачыграк күрә башлады. Танышлар, якташлар юкмы? Шунда кемдер аның исемен әйтеп эндәшкәндәй булды. Сания, аякларын кузгатмыйча алгарак иелеп, бер-бер артлы үтеп торучы солдатларга текәлде. Әллә ялгыш ишетелде инде? Кем аны бу хәлдә танысын? Аның үзен танытасы килде, үзе дә сизмәстән яулыгын чишеп җибәрде. Бусы түгел, бу да түгел... Солдатларны берәмберәм санап уздыралар, немецлар аларны ашыктыра, куалый, ара-тирә этләр тавыш бирә. Ләкин шушы тоташ шау-шу арасында кемдер ап-ачык итеп аның исемен атады. «Сания! Бу мин!»

Әсирләр сафын күзәтеп, Сания аларны урап атлаган немецларны онытып җибәргән икән, карамаган да, күрмәгән дә. Немецларның берсе барган җиреннән туктап, тимерчыбык киртәгә таба бер-ике атлагач кына Сания үзенә атап эндәшкән немецка күтәрелеп карады. «Булмас, юктыр! Ул түгелдер! Ачлы-туклы яшәп миңа тавык күзе булгандыр!» — дип уйлады ул. Әмма аңа эндәшүче ул иде...

Яланга укытырга килгәч, авылны бер дә яратмыйча, тешен кысып кына сөйләшеп, язмышын каһәрләп йөргән Айсетдин иде бу! «Шушы төбәккә туры килүемнең бердәнбер бүләге Сания, сез!» — дип ачыктан-ачык аңа төрле төстәге тәкъдимнәр ясаган кеше! Мең хәйлә, мәкерле гамәлләр табып аны Мөхәммәтеннән аерып алырга җыенган, Санияне эзәрлекләп Омскига барып җиткән әрсез алабай! Нигә немец киемнәре киеп йөри ул? Ничек алар арасына барып кергән? Хыянәтчеме, әллә сугышчан бурычын үтәп йөрүеме?

Әсирләрне ерактагы иң кырый баракка алып киттеләр, Айсетдин дә бүтән эндәшеп тормады, көязләнеп, иңбашларын күтәреп атлап аларны

озата китте. Ир-атларны каршыларга чыккан хатын-кыз таралды. Өметсез уйлар җәтмәсенә килеп капкан Саниянең болай да башы исәрләнгән иде. Айсетдинне күргәч, ул бер мәлгә уйлау сәләтен дә югалтты. Кичкырын надзирательдән берәү, юантык, алтын тешле немец марҗасы аны сакчылар урнашкан бинага чакырып кергәч, мунча кертеп, юындырып таза киемнәр кияргә боергач, ни дияргә дә белмәде. Белгәнешеп өлгергән әз-мәз хатыннар аңа көнләшеп карадылар. Сания үзен күмеп ташлаган сорауларның берсенә дә җавап бирә алмады. Киенгәндә хатын-кызның иң кирәкле эчке киемнәре булмау гына аны шикләндерде. Тел белмәсә дә, ул үзенә тиешле киемнәрнең кайда булырга тиешлеген кулы белән төртеп күрсәтеп надзирательгә карады. Алтын тешле марҗа көлгәндәй итте, кулы белән күкрәкчәнең һәм ыштанның кирәк түгеллеген аңлатырга тырышты. Сания тугры мөселман хатыны, шушы җанга тия торган шакшы тормышта да мөмкин кадәр үзен карап, өс-башларын пөхтә тотарга тырыша иде. Марҗа каршы торырга маташса да, салган иске ыштанын киде, тупырдап торган имиләрен күкрәкчә астына яшерде...

Көтә дә, көтми дә. Айсетдин хакындагы шикле уйларын бүтәнчәрәк фикерләр алыштырды. Мөгаен, Санияне шушы хәлдә күреп бик нык җәлләгәндер якташы. Үткәндә, тегендә, Себердә чакта кылган ямьсезлекләре өчен үкенәдер. Хәзер шуларны исендә тотып Санияне бу җәһәннәмнән йолып алырга уйлыйдыр. Немец киемен киеп йөрүе бер-бер хәйләдер әле. Бүтәнчә булмас. Совет кешесе, татар, совет власте укытып чыгарган мөгаллим туган иленә хыянәт итә аламы? Язмаганны!

«Айсетдин мөгаллим мине дошман тырнагыннан аяп иреккә чыгарачак!» — дип үз-үзен ышандырырга тырышты Сания. «Тел белмәгән килеш монда чит җирләрдә, чит халыклар арасында нишләрмен?» — дип кыйналды һәм аның тәшвишле, әмма җылы уйлары тагын Айсетдингә барып җитеп тукталды. «Бер-бер әмәлен табар әле!» — дип өметләнде.

Аны каравылчылар йортына күз бәйләнгәндә алып киттеләр.

Айсетдин яшьтән үк чебен тимәс чер итәр диярлек иркә бала иде. Бала чагында аны чир-чорлар сагалап кына торды диярсең, танау асты кипмәде, җәйге чилләләрдә дә өзмәс ютәлләп йөрде. Кызамык чыкты аңа, салган чәчәге чыпчык башы кебек кабарып, шешеп йөрде. Тамагына өч тапкыр балык кылчыгы кадалды, җиде яшенә кадәр астына сиде. Үзен бик бәхетсез санап, үсә төшкәч, әти-әнисен каргады: «Тәрбия итә алмагач, ник алып кайттыгыз мине?» — дип, җир тибә-тибә җылады. Качышлы уйный башлыйлар — тәкә булып Айсетдин кала. Лапталы уйнаганда чүрәкәй ике тапкыр аның кашын җимерде, хәзер дә эзләре бар. Берәр әйбер бүлешсәләр, аңа гел калдык-постык, яисә өлешенә иң бәләкәе эләгә. Тигез бүленсә дә, Айсетдинга үз өлеше иң кечкенәсе булып күренә. Берзаман класста диктант язганда маңкасы танавыннан чыгып дәфтәренә тия дигәндә укытучысы: «Айсетдин, кунагыңны җый!» — дип эндәшеп аны көлкегә калдырды. Шул кичне үк кире беткән малай укытучысының тәрәзә пыяласын бәреп ватты.

Шулай кимсенеп үсте Айсетдин, кыдрач, кире беткән һәм үчегергә әзер кеше булып җитеште.

Инде диплом алып, мөгаллим булып эшкә кайткач та аның бу холкы үзгәрмәде. Борын биектә иде егетнең! «Укытучы Айсетдин!» Бу инде вак-төяк түгел, бигрәк тә авыл җирендә укытучыларның абруе гаять югары йөргән чак! Җаны теләгәнен ашап, күңеле сайлаган киемнәрне киеп, күзе төшкән һәр чибәрне кочып яшәргә иде Айсетдиннең исәбе. Язмыш аның каршысына Санияне чыгарып бастырды. Егет аңа үлеп гашыйк булды дияргә ашыкмыйк, Айсетдин ярата да белми иде. Алай да ул Саниягә — аның уңганлыгына, чибәрлегенә тартылды, тиз үк кызның тулы хуҗасы булырга теләде. Ә Сания аңа әйләнеп тә карамады, үзеннән шактый өлкән яшьтәге Мөхәммәт Уразаевны яр итте. Укытучы Айсетдин тиз генә бирелмәде, ул яшь киленнәрне җиңү, кочакка алу ансатрак

булыр дип куанды. Аның тиз генә өйләнергә исәбе юк иде әле. Егетлекне озаккарак сузып, өстенә «ир» бурычларын өймичә генә «сылу кызларның каймагын ашап», чирттереп яшәргә иде аның чиксез зур планнары. Сания аны кочагына кертмәде, куенына да алмады. Айсетдин турыга бәреп әйткән сүзне түгел, кырын карашны да яратмый башлаган иде. Теле белән әйтмәсә дә, ул Саниягә ачу йодрыгын йомарлап куйды, эченнән генә: «Дөнья куласа ул! Ике әйләнә дә бер баса!» — дип кабатлады...

Советлар илендә, беркемнән, бер чакта да яхшылык күрмәдем дип санаган, дөньясыннан, җирдән, күктән үч алырга ашкынган өтек ир кисәге армиягә алынып, сугыш кырына килеп җиткән беренче көндә үк үз иркеннән дошман ягына качып чыкты. Немецлар андыйларны көтәләр иде, аны биш куллап каршы алдылар. Немец армиясе формасын киеп алгач егетнең шәбәюенең чиге юк иде. Хәзер аңа әсирләр арасыннан мөселман легионына яраклы кадрларны сайлап алу, аларны әзерләү бурычы йөкләтелгән иде. Бу эшне Айсетдин яратып башкара һәм немецлар алдында абруе арта тора иде.

Санияне күргәч, аның күңелендә җил-давыллар уйнады. Бердән, үзенә баш бирмәгән сылу хатынның алам-салам киемнәргә төренеп, нурсыз күзләрен нәүмизләндереп текәлеп торуы ошады. Икенчедән, Айсетдин җиңүчеләр арасында! Ул — җиңүчеләр затыннан!..

Зоналарны үткән хатын-кызга чучка исе сеңгәнен дә, аларның түбәнләгән дә, байтагысының ә дигәнче мә дип, ыштан салырга торуларын да белә Айсетдин. Хатын-кызга мохтаҗлык юк иде югын. Тамак тәмугка да кертә! Күңелендә ямьсез бер төен булып килгән Сания дә хәзер йөгереп аның янына килеп җитәчәк, аның итек башларын ялый-ялый ярдәм сораячак. Бер кыерчык икмәк бәрабәренә тәнен үзе тәкъдим итәчәк.

Итекләрен ялтыратты Айсетдин, иртән бер кырынган булса да тагын бер мәртәбә чистарынып алды, әзерләнде. Муенына, чәчләренә хушбуй сипте. Үзенә-үзе чиксез сокланып, тар, җитлекмәгән чебеш күкрәген алга бүлтәйтеп йөреп маташканда ишек ачылды һәм аннан юаш кына атлап Сания килеп керде. Әле генә корган матур планнар әллә кая очып таралды, Сания Айсетдин көткәнчә җебеп төшкәнгә бер дә ошамаган иде. Дөрес, ябыккан, беләкләре юкарып калган, күз төпләренә күгелҗем пәрәвезләр сарган. Алай да күзләре элеккедәй матур, эчке бер нур белән яктырып яналар. Идәнгә дә ташланмады Сания, елтыр итек башларын да яламады, ишек катына басып, озынча, туры муенын күрсәтеп башын чак кына артка ташлады. Бу кыяфәт, бу караш Айсетдингә ошамады, ул үзенең шушы хатын алдында түбәнсенүләрен аермачык хәтеренә төшерде, Саниянең каршысына килеп басты. Юк, Сания анда да чигенмәде, нидер көтепме, аңа багып катты. Айсетдин иелде, бармак очлары белән Саниянең күлмәк итәген күтәрде һәм тоныкк тавыш белән: «Нигә ыштан киеп кердең минем янга?» — дип кычкырып җибәрде. Менә шунда инде Сания каушады, бер мәлгә эреп, югалып калды. Ләкин бу мизгел озакка бармады. Күңеле каткан иде аның. Айсетдиннән ярдәм өмет иткәне өчен аның горурлыгы үртәлде һәм ул салмак, җитди сабыр тавыш белән, нәфрәтен һәм җирәнүен ап-ачык белдерде: «Байтактан үз телебездә сөйләшкәнне ишеткәнем юк иде, татар теле сагындырды. Әмма ләкин сагынылган телдә беренче итеп шундый оятсыз, шулкадәр ямьсез сүзләр ишетермен дип уйламаган идем», — диде.

Бу сүзләр әкерен яңгырасалар да шундый эчке көчкә, чиксез кодрәткә манылып чыкты ки, явызланган Айсетдиннең ирлеге шундук сүнде, гомере буе баллыны ашаган, конфит суырган Айсетдин элеккеге мәми авыз, маңка малай булды да калды...

Кара-каршы очрашып, язмышы хәл ителгәндә дошман киеменә төренгән мөртәтне каушата алса да, дөнья явызы Айсетдиннең арттан чагуына каршы тора алмады шул рыясыз татар хатыны! Мәкер остасы Айсетдин арттан килеп тез астына китереп бәрде, төзәлмәслек агу белән

чагып, хатынны упкынга ыргытты. Санияне башы-аягы белән гестапога илтеп яптырды. Иртәнчәк китергәннәр иде, әбәд алдыннан шоп-шома, мыеклары майлап таралган, базда үскән бәрәңге сабагы сыман озын, юка бер офицер каршына бастырдылар. Атна буе җәфалады аны офицер, үзе яңаклады, куллары арыгач мал суючыга охшаган, куллары йөнтәс, бүселеп торган итләч берәүне чакыртып алып аңардан тукматты. Күкрәген төйде немец Саниянең, ботын аерып тимер үкчәсе белән типте, чәченнән тотып уңлы-суллы болгады. Аны «хатын-кыз әсирләр арасында империя интересларына каршы коткы таратуда» гаепләделәр. Янәсе ул: «Эш урыннарыгызда Германиянең көчен какшатырлык гамәлләр үткәрергә кирәк, империяне эчтән җимерү безнең бурыч»,— дигән сүзләр сөйләгән.

Гаепләү адәм ышанмаслык ялган булса да, Айсетдин кемне ничек аяктан егарга мөмкин икәнлеген өйрәнеп өлгергән әшәке җан иде.

Гестаподан аны үзе шикелле үк нахакка хөкем ителгән урыс, украин хатын-кызлары белән этаптан этапка куа-куа Бухенвальд лагерена китереп җиткерделәр.

Нечкә күңелле, моңлы, тәнен вә җанын моңарчы явызлыктан, хыянәттән саклаган, урлашмаган, кеше ризыгына өметләнмәгән, ялагайланмаган, әләк-чәләктән ерак йөргән, шушы сыйфатларына таянып түбәнлеккә төшмәгән хатын Бухенвальдка килеп атна уздыруга, өметсезлек коесына төште. Ул монда илләр, халыклар кичергән чиксез газапларга бик сирәк кеше генә түзә алачагына ышанды. Фашизмның үлем тегермәнендә яшәүчеләр йә үләргә, йә акылдан шашарга тиешләр иде. Барыбер моннан котылмак юк, әҗәл көтеп тора, нигә газапларны озайтырга, дип уйлады ул шушы бер атнада. Монда язмышларга соңгы ноктаны Әҗәл куя, крематорий торбаларыннан кара дегет-сөрем Германиянең төссез күгенә көне-төне күтәрелеп тора. Адәм җаннары кара яулыкларын болгап дөнья белән саубуллашалар.

Санияне бер нәрсә — лагерьда бала-чагаларның ишле булуы гаҗәпләндерде. Балалар барагы бераз читтәрәк аерым мәйданда булса да, ике арада сакчылар юк, теләгәндә кереп-чыгып йөрергә дә була икән. Бу арык, бичара ятимнәрне күргәч, Саниянең күңеленә кызы Фаягөл тып итеп килеп куна. Ире дә сугышка киткәндер, Фаягөл әти-әнисен вакытлыча җуйган ятимә, шундый ук бәхетсездер, дип уйлый. Сания бик тырышса, илдә-дә кала ала иде бит! Ире белән алар кат-кат мәслихәтләштеләр, икесе дә сукраер дәрәҗәдә ватанпәрвәр зат иделәр. «Дошман туган илгә басып керде! Аны тиз арада үз җирендә тукмап, җәһәннәмгә озатырга!» — дип ашкындылар...

Фаягөле өйдә өйдәсен, сөйкемле әбисе янында, ул нәбәрәсен кыерсытырга ирек бирмәс, дөнья нужаларын җиңеп яшәр яшәвен... Тик, сугыш шушы кадәр озакка сузылыр да дошман Урал тауларына барып җитәр дип кем уйлаган?.. Чын хәбәрләрне белмәгән Сания немецлар инде Урал тирәсенә барып җиттеләр дип белә иде.

Бухенвальдта адәмнәрне өметсезлек кимерә, туймас албасты булып тоткыннарның иңбашыннан төшми. Әнә шул тоткын балалар белән очрашу Саниянең боз белән капланган өметсез җанын чак кына җылытып җибәрде. Тоткын балаларның төпсез күзләрен күреп, ул кызы Фаягөле турындагы сагышлы уйларын өметле алгы көннәргә дә ялгый алды. «Бирешмәскә, әҗәлгә баш бирмәскә!» — дип үз-үзен юатты ул.

Балалар янына кергәләргә тырышты, керсә сорашты: «Ничек һәм кайлардан бу зонага эләктегез?» дип кызыксынды. Башта читенсенеп куркып, ятсынып кына караган балалар арасыннан аңа тартылганнар да барлыкка килде.

Тугыз яшьлек Валентин Нестеровны Сания аерата нык яратты. Урыс булса да, татарга бик нык охшаган иде бу Николаев шәһәрендә туып

үскән бала. Шәһәрдән алар әнисе белән бергә качып чыгып китәләр. Юлда аларны дошман самолетлары бомбага тота. Малай әнисен югалта һәм ике көн бер чокырда качып ята. Тамагы бик ачкач эзләнә башлый, бәрәңге басуына юлыга һәм шунда бәрәңге төпләрен актарганда аны немец солдатлары тотып алалар. Ни сәбәптәндер баладан шикләнәләр, әйткән сүзләренә ышанмыйлар. Валентинны партизан отряды развед-чигы санап, концлагерьга илтеп тыгалар.

Павелны исә Германиягә алып китәргә җыенганда урманда качып ятканы өчен китереп япканнар. Аңлы рәвештә дошманга каршы көрәш башлаган яшь партизанны облава вакытында эләктереп алганнар. Әле җаннары ныгымаган, тәннәре көчәеп тә җитмәгән, ата-ана җылысында канат кагарга тиешле балалар, шушы, почмакларына куе бәс сарган, тынчу агач баракларга килеп эләгеп, явыз эт өргән тавышларны һәм явыз каравылчыларның акыру-бакыруларын гына ишетә алган яшь җаннар ниләр уйлый ала икән? Крематорий авызы алдына арбаларга төяп китерелгән, әрдәнәләп өеп куелган мәетләргә карап ничек йөрәкләре ярылмый аларның?..

Сания бу балаларның эчке тормышына үтеп кереп, аларның исем-фамилияләрен берчакта да белә алачак түгел иде: балалар барагына һәм балаларның йөрәгенә Санияне Нина Павловна Тарасюк ияртеп кермәсә... Нина Павловна белән алар бер баракта, бер үк секциядә яшиләр булып чыкты. Баракта, адәм куелыгында танышмаганнар иде, очраклы гына, бер кичне, күк читендә ярымай уянып маташканда Нина Павловна бер хатынның тилмереп, өзелеп-өзелеп балалар барагына карап торуын абайлады һәм туктап эндәште:

— Туган илне сагынасызмы?

— Сагынмый була мыни?— диде Сания моңсу гына.

— Сез кай яклардан?

Шушы гап-гади сорауны ишетүгә Саниянең күңеле тулды, ул ике-өч сүз белән үзенең Себер ягы татары булуын, илдә шәфкать туташы, врач булып эшләвен, өйдә кызчыгы калуын сөйләп бирде. Нина Павловна үзе белән таныштырды, укытучы булып эшләгән икән, иренең сугышта икәнлеген, балалары юклыгын, табарга өлгермәүләрен аңлатты.

Алдагы көннәрдә дә очраштылар алар, бер-берсенә сыендылар һәм Сания Нина Павловна авызыннан яңа, сөенечле бер хәбәр ишетте. Шушында, балалар барагында, мәктәп эшләп килә икән!.. Чын мәктәп, сыйныф бүлмәләре, күргәзмә әсбаплар, китап-дәфтәрләр булмаса да, балаларның чын укытучылары бар икән һәм алар мөмкин булган кадәр даими дәресләр алып баралар, нәни тоткыннарга аң-белем бирергә тырышалар икән. Ике-өч көннән соң Сания дә Нина Павловнага ияреп мәктәпкә барды һәм тоткын мәктәпнең бердәнбер ир укытучысы Николай Васильевич Федосенконы күрде.

Николай Васильевич кай ягы беләндер аның Мөхәммәтенә охшаган иде. Шундый ук озын гәүдә, киң, килешле җилкәләр, сүз арасын яктыртып елмаеп куюлары да, әз генә иелебрәк йөрүе дә, нәкъ Мөхәммәтнеке инде менә.

Нинди нигезләрдә, нинди фәннәр укыта икән, дип кызыксынып керсә, Николай Васильевичның дәресен тыңлагач Сания мөгаллимнең тапкырлыгына таң калды.

Бу суык дөньяга куып кертелгән ярым сынган күңелләрне нинди сүзләр, нинди уйлар белән генә җылытып була икән? Мөгаллим әле бер бала, әле икенчесе янына барып баса да, җылы куллары белән аларның баш түбәләреннән сыйпап сораулар бирә: «Син үзеңнең кайда туып, кайда үсүеңне онытмадыңмы? Хәтерлисеңме туган җиреңне? Син яшәгән урамның исеме ничек иде? Туган авылыңда чишмәләр бар идеме? Тыкырыклар? Сезнең урманнарда нинди чәчәкләр үсә? Сөйләп бирче!» Сания мөгаллимнең зирәклегенә сокланды, аның шушы үтә гади сораулары, балаларга туган илләрен онытмаска ярдәм итү чаралары да ич!

һәм буй-буй төрмә киеме кигән, тоташ игезәкләргә әйләндерелгән балалар кинәт кенә үзгәрәләр, алар мөгаллим сызган сукмаклар буйлап хыялда туган якларына йөгерешеп кайталар, аларның сүрән йөзләре аклана, күңеленнән татлы балачак истәлекләре агарга тотына.

Федосенконың дәресләре Саниянең күңелен дә яхшы якка кузгатты, ул да уймакланып аккан Иртеш елгасын, Ялан авылының таралып утырган йортларын, шул йортларда яшәгән күңел бизәкләре — авылдашларын һәрдаим уе аша үткәрә башлады. Авыл хакында ниләр генә уйласа да аның зарыгып сагынуы көчәя, дәрте арта, яшәүгә омтылышы һәм ышанычы ныгый иде.

Николаев шәһәре үсмере Валентин Нестеров, күрер-күзгә йомыкый һәм нык өшәнгән күренсә дә, асылда, шактый елгыр, ачык зиһенле малай булып чыкты. Йөрәкле дә икән үзе, лагерь карачкылары — надзирательләрдән дә куркып тормый, балалар барагының аръягында гына булган ирләр зонасына да барып керә, ниндидер юллар белән бирәр кыерчык кына булса да икмәк тә юнәтә, табышын Сания апасы белән уртак итәргә дә тырыша иде. Әлбәттә, малай авызыннан ризыкны алмый Сания, рәхмәт әйтеп ягымлы карашы белән малайны иркәли. Ир-атлар, яшьме алар, өлкәнме, гомерләре буена хатын-кыз назына мохтаҗ булалар.

Беркөнне Валентин аны аерата дулкынланып каршылады, «Тетя Соня, тетя Соня! Кара сакаллы бер мужик, «а у вас, среди женщин, нет ли татарочки?» дип сорый», — диде. Саниянең колакларына кадәр кызыша башлады:

— Ә син ни дидең?

— Әйтмәдем! — диде үсмер, гаҗәпләнеп. — Сезнең белән киңәшмичә ни әйтим.

Сания иреннәрен бөрештереп тешләп уйга калды, аннары Валентинның арык җилкәсен кагып:

— Ә син аның кемлеген сораш. «Татарочка нигә кирәк?» дип белеш.

Малай кайнарланып белешергә вәгъдә бирде һәм икенче көнне нәни генә кәгазь кисәген Сания апасының кулына тапшырды. Кәгазьдә татарча болай дип язылган иде. «Мин үзем Себер ягыннан, Вагай районыннан. Исемем Сабирҗан». Шушы саран сүзләр дә Саниягә җитә калды. Якташ та икән үзе, татар да икән, мөгаен, Мөхәммәт Уразаев хакында бер-бер нәрсә беләдер, күрмәсә дә ишеткәне бардыр, дип төрлечә уйлады.

Икенче көнне кич кырын алар әзгә генә очрашып алдылар. Сабирҗан инде олыгаеп килгән базык кына юаш бер абзыкай икән. Юк, Уразаевны очратмаган да, ишеткәне дә булмаган. Алай да бик гозерләнеп, иякләрен күкрәгенә бәрә-бәрә ялынды: «Монда татарлар бар-барын, ләкин якташлар, Себер кешеләре юк. Син минем якташым икәнсең, димәк, туганым булып чыгасың. Ходай безне очраштырды, форсаттан файдаланыйк. Минем кемлегемне белеп кал, онытма, илгә кайта калсаң безнекеләргә хәбәр җиткерерсең. Өйдә хатыным Хәмдия, анам һәм алты балабыз калды. «Мин күргәндә исән-сау иде», диярсең. Хәзер үзеңне белдер, мин исән кайта алсам, сезнекеләргә барып кайтырмын. Онытмам! Вәгъдә — иман!» — диде.

Алар бер-берләренең исемнәрен, адресларын бикләргә тырышып, икеәч тапкыр кабатладылар, кул бирешеп, Ходайдан шәфкать теләп аерылыштылар. Шул очрашудан соң озак та үтмәде, Сания Валентинны ияртеп ирләр зонасына карый-карый йөреп торганда, малай кинәт кенә апасының җитәкләгән кулын ычкындырып кычкырып җибәрде:

«Әти, Әти! Анда минем әтием!»

Малай зоналарны аерган чәнечкеле тимер чыбык киртәсенә таба томырылып чаба да башлады. «Ярамый! Тукта!» — дип кычкырды Сания аңа, каушаудан көчен җуйган зәгыйфь тавышы белән. Уңдагы зона белән хатын-кыз бараклары арасындагы араны кораллы солдатлар саклый иде. «Анда концлагерьлардан бер тапкыр качкан тоткыннар ята», дигәнне ишеткәне бар иде Саниянең.

Аллы-артлы чабалар, малай ач, арык булса да әтисен күрү теләге шулкадәр көчле ки, ул болан баласыдай сикерә-сикерә томыла һәм бертуктаусыз: «Папочка, папочка!» — дип сөрән сала. Теге яктагы ирнең Валентинның әтисе түгеллеген Сания инде аңлап та өлгерде, ир малайның үзенә кул болгый-болгый җан авазы белән эндәшеп йөгергәнен күрде, әмма урыныннан кымшанмады. Әзмени Бухенвальд зонасында акылларын җуйган малай-кызлар? Ир шулай дип уйлады, ахрысы. Менә тыелган зонага өч адым калды, ике... тыны бетеп мыш-мыш килгән малайны эләктереп алам дигәндә почмактагы вышкадан ату тавышы яңгырады, малай абынды, сөрлекте һәм чәнечкеле чыбыкларга егылды. Чалбар сәләмәсеннән бүселеп чыккан буй-буй ристан күлмәге канга манчылды. Сания малайның култык асларыннан эләктереп тартып алырга, усал чәнечкеләрдән араларга теләде. Ул арада аяусыз мылтык тагын бер мәртәбә гөрселдәде... Авыртуны сизмәде Сания, ничектер җиңеләеп калгандай булды. Ярасыннан сулык-сулык кан акканын да ишетте кебек. Күз алдында кайнаган яшькелт томан эчендә Фаягөлнең шәүләсе тирбәлде дә югалды. Сания: «Балам! Кызым!» — дип кычкырды, дөньяны яңгыраткандай булды. Тик беркем дә аның тавышын ишетмәде, бичара хатынның тавышы чыкмады, ирен араларыннан кысылып кына кан ага иде.

Ходаның хикмәтләрен, язмышның кодрәтләрен беркем дә бер чакта да аңлатып бетерә алмый. Әгәр шул минутларда сул яктагы ирләр зонасында Сабирҗан күренмәсә, ул Саниянең һәлакәтен күреп калмаса, Ялан авылы кызы, Фаягөлнең әнкәсе, Мөхәммәтнең бәхете булып туган татар хатынының дөньядан китүен берәү дә белми калыр иде. Ике иңендә яшәп аның гомер юлын гамәл дәфтәрләрендә теркәп барган фәрештәләр белде белүен, алар ефәк канатларын кага-кага очып күккә аштылар. Әмма алар гөнаһсызлар, языклы җиргә төшеп адәм балалары белән мөнәсәбәтләргә керә алмыйлар шул. Адәмнәргә атап эндәшсәләр, фәрештәләр күк гөмбәзеннән егылып төшеп һәлак булалар, югалалар.

## 11

Аяусыз, суык көннәр башланды. Башында тузынган бураннар атна азагына кадәр тынмады, улады да улады. Иртеш бозы өстенә яткан карларны куып елганың өстен ачты, яр чокырларын күмеп бетерде. Атналар буе торага ат җигеп тә бара алмадылар, почтага төгаенләнгән алаша да авылдан чыгып карады да, корсак астына кадәр тирән карга баткач, борылып кайтты. Җил-буран кайдадыр телефон чыбыгын өзеп бетердеме, тора белән элемтә өзелде. Шулай җир шарыннан, дөнья хәлләреннән аерылып Ялан авылы көн, сәгать исәбен югалтып байтак вакытлар тилмерде. Юлларны буып куйган бураннарга төрле кеше төрлечә карады, әлбәттә.

Чырык Абдрахман кара бураннар тавышын тыңлап ходасына рәхмәт укыды, өстенә язык җыйганын белсә дә, Колгасар Миша Сорокинга, аның тирәсендәге әтрәк әләмнәргә әҗәл теләде. «Кар каплап китеп бугазларын томаласын иде! — дип ялварды карт. — Урман-яланнар мөртәтләрдән тазарсын иде, илаһым!»

Чырыкның мылтык-дары таба алганы да юк. Сорокин явыз куеныңа салырлык хатыннар да күзенә күренми. Карчыгын җирләгәннән бирле һушына килә алмаган Абдрахман гел-гел болай яши алмаслыгын белә, әмма көндәлек тормышның кайсы якка борып җибәрергә кирәклеген таба алмыйча, җиде җил күзендә утырган авылның җиде юлы чатында адашып, каңгырап басып тора иде. Кай көннәрдә миченә ягарга, өенә җылы җибәрергә дә иренә, күпме көннәр Бүре Рәхмәтулла алачыгында, туңып-өшеп иләнгән арык тәне, салкынны да сизми иде.

Шулай бер көнне, буран-җил томалаган ишекне көч-хәл белән каерып ачып, аның җансыз йортына бишмәте өстенә калын шәл чукларын таратып ташлаган берәү килеп керде. Аралыкта ятып тәне язылмас булган Чырык эһем-эһем дип, бугазын чистартып, керүчегә күтәрелеп бакты. Кем дисәң, керүче Сәрвәр туташ икән. Чырык аны танымаганга салышты:

— Вакытсыз кем йөри икән анда?—диде.

Сәрвәр чишеп җибәреп шәлен иңенә, муенына төшерде, йөзен ачты, бияләен салып мич яңакларын сыйпады.

— Әллә мичеңә дә якмагансың инде, Абдрахман әкә,—диде.

Чырык торып утырды, сул кулы белән шытырдатып муенын кашыды, уң кул учы белән авызын каплап кат-кат иснәде. Сәрвәр исә эшлекле кыяфәт белән нык-нык басып оялдына чыкты, бер кочак каен утыны күтәреп керде, коры яфракларны җәһәт-җәһәт мич төбенә тезеп таратты һәм каен тузы кисәкләренә ут элдерде. Морҗада шашып уйнаган җил утны ашыктырды. Берзаман морҗа шашып гүләргә тотынды. Ул арада Чырык ямалган иске итеген сөйрәп мич авызы каршысына килеп утырды һәм күзләрен чет-чет йомып Сәрвәргә карады. Ник килгән? Нишләп йөри? Йомышы ни?..

Янган утка текәлеп бераз уйчанланып торган Сәрвәр йомшак тавышы белән картка эндәште.

— Мин, Абдрахман әкә, сезнең катка олы бер гозер белән килдем әле.

Шулай диде дә янган утка карап озак кына дәшми торды, озынча матур бармакларына шәл чукларын урады. Бер урады, ике, сүтте, шуннан соң гына, Чырыкның яшьләр тавышын күптән онытканы өй эчен сагышлы моң белән тутырып сөйли башлады:

— Үткәннәрне искә төшереп рәнҗеп йөрмим мин... Нишлисең, күрәчәкне күрмичә гүргә кереп булмый, ди иде минем әни. Әниләр белми сөйләмәгәндер. Аңлагыз, Абдрахман әкә, ата-анам гүрдә, бик якын туган-тумача калмады. Киңәшер кешеләрем юк диярлек... Син дөньяны күп күргән адәм... Минем Шамилнең кәләше булуымны да, аны армиягә озатып калуымны да, вәгъдәләр алышуыбызны да беләсеңдер инде.

Чырык үтә нык кызыксынып, күзләрен челт-челт йомгалап ияген какты. Кая таба сукалый бу кызыкай?

— Элек тә хатларны сирәк яза иде Шамил... Хәзер бөтенләй туктады. Исәнме ул, моны миңа кем әйтсен? Ә белергә кирәк, бик кирәк, Абдрахман әкә! Син бер-бер ырымын беләсеңме шуның, Шамилнең исәнлеген өзеп кенә әйтә алмассыңмы? Мин бары тик аңа таянып кына яшим, минем алдагы гомерем, бар өметләрем аңа бәйләнгән!

Белә Абдрахман төлке, чамалый, күңелгә кайгы кунса кул буш булмый, мөгаллимәдән шактый чирттереп булыр иде. Бик сайрыйсы килә Чырыкның, «Шамилең исән-сау, сугышның иң алгы сызыгында йөри, шул сәбәпле генә хәбәрләре килеп җитми!»—дип ышандырасы килә. Берүк вакытта җаны тартыша, иманы: «Алдама, ялганлама, син туры юлга басам, дип мәрхүмә карчыгың Гөлҗамалның кабере авызында ант эчтең!»—дип кыйнап, искәртеп тора. Чырык уйнап түгел, чынлап ук уйга чумды.

— Чын күңелеңнән сорыйсыңмы моны, Сәрвәр кызым?—дип сорады ул актыктан.

— Мин бүтәнчә сөйләшә дә белмим, Абдрахман әкә. Күргән төшләргә карап кына өметемне алдарга теләмим. Миңа дөреслекне белү кирәк. Сине әүлияләр белән аралаша ала, дип тә сөйлиләр, җен-шайтаннар белән танышлыгы бар, дип тә өстиләр. Фал ачасыңмы, китаплар актарасыңмы? Исән-саумы Шамил, юкмы? Турысын әйт...

Һәм үз гомерендә беренче тапкыр Чырык Абдрахман үзенең гап-гади бәндә булуын, Ходай белән дә арадашлыгы чамалы икәнен, җен-шайтаннарга юлы булмавын Сәрвәргә ачып салды.

Мич янып бетте, өйгә иренеп кенә җылы төште. Сәрвәр кесәсеннән ике унлык чыгарып Абдрахманга сузды:

— Әгәр исән икән, «ризыгы киселмәсен!» дип телә, Абдрахман әкә. Вафат икән «рухын якты кыл» дип дога укы,— диде ул саубуллашып...

Күздән ашык-пошык кына әзерләгән утын кыш уртасына да җитмәде, убыр мичләр аны йотып бетерде. Олы мичләргә ягуны күптән туктаттылар, калдык-постык ботак-сатакны бердәнбер тимер мичкә ягалар да, дәресләр башланыр алдыннан сыйныф бүлмәләренә әз генә җан кертеп алалар. Бүтән вакытларда мәктәп коридорларында усал җилләр уйный. Атна буе уйнаган тоташ бураннар мәктәп сараендагы соңгы запасны да ашап бетерделәр. Мәктәп утынсыз калды. Миңнурый, Сәрвәр, Мәүлияләр, Я̌ланның яшь укытучылары, буран басылганны зарыгып, дүрт күз белән көтеп алдылар. Бүген дәресләр булмады. Аклы-каралы ямаулар белән чуарланган, җиңнәре кыскарган бишмәтләрен юкә бау белән буып алган малайлар, билләренә балталар, култык асларына пычкылар кыстырып мәктәп янына җыелдылар. Кырык өчнең гыйнвары мәктәп өчен аяусыз айга әйләнде. Утын китерерлек ир-атлар юк, хатын-кызлар гәүдәләрен чак-чак күтәреп йөриләр. Мәктәп тирәсендә койма, читәннәр барысы да ягылып бетте.

Урман кисү кебек авыр эшкә тәвәккәлләсәләр дә, балалар шул әле алар, дөньяларын онытып шаярып та алалар, чәрелдергә әзер кызларны карга егып җылаталар. Укытучылар җитәкләгән балалар төркеме, каз бәбкәләре кебек тезелешеп, иң якын урманга таба юл алды. Әби-бабалардан, әти-әниләрдән алган дәү итек табаннары астында кар шыгырдый. Фаягөл белән Гөлнурның гына аяк тавышлары чыкмый. Гөлнурның кат-кат ямалган киез итеге табанына әнкәсе йөнтәс бозау тиресе тегеп куйган. Ә Фаягөлнең тишек үкчәсеннән чыккан чүпрәк олтырагы юлдагы карны себереп бара...

Урман авызындагы яшь каен чаукалыгына барып керделәр. Мәктәптә чакта шаяргалаган балалар урман тынлыгына килеп кергәч сөйләшүдән туктадылар. Миңнурый апалары агач егарга дигәндә иң җәһәт белгеч булып чыкты. Ул арадан бер үткер балтаны сайлап алды да тәртә юанлыгы каеннарга рәттән чабып чыкты. «Монау бу агачларны егарсыз, балалар,— диде,— торарга да җайлы, төяргә дә җиңел булыр».

Өшегән, туңга әйләнгән каен кәүсәләренә балталар теләр-теләмәс кенә керәләр, бармак буе йомычкалар чәчрәп карга чума, урманда эш кайный, һәркем монда әндрәшкә-брәшкә[1] уйнарга килмәвен белә. Кем чабып ега, кем ботак кисә. Сәрвәр, Мәүлия, Миңнурыйлар эрерәк каеннарны буе-буе белән чәнәшкә-тәртнәләргә төйиләр. Көчлерәк малайлар баулар белән утынны бастырыклый. Бу чаналар тартып барганда карның тирәнлеге сизмәделәр кебек, хәзер юл — газап булып чыкты. Чалбар балакларын итек тышына салындырган малайлар күкрәктән кар ерып алдан баралар, карга баткан чәнәшкәләрне көч-хәл белән тартып чыгаралар. Утын тураганда шактый җылынган кызлар туңа, калтырый башладылар. Иртеш өсләп килгән җил җәяүле буранны тарата, килгәндәге эзләрне күмә, җәфалый. Балалар калдырып киткән урман бик моңсу иде. Ботакларына ялтыравыклы бәс кунган каеннар, ылысларын кар баскан кедрлар моңланып баш иеп калдылар сыман. Иң арттагы чәнәшкәләр мәктәп ихатасына кайтып кергәндә морҗалар күксел төтен төтәтеп масаялар, җиңгән сыман текә генә күккә күтәреләләр иде. Җыештыручы Әсма апа беренче чанадагы утын белән мичне дөрләтеп ягып җибәргән икән. Мәктәп бинасы да иске-москы шул, почмаклардан бәсле мүк кисәкләре асылынып тора, күпме яксаң дә җылы сакланмый. Яңа мәктәпнең нигезен салдырган иде Мөхәммәт абыйлары, өлгертә алмадылар, сугыш чыкты. Мәктәп элеккеге Бүре

[1] Әндрәшкә-брәшкә — юк эш.

Рәхмәтулла йортында сыенып калды. Башлангыч класслар өчен янәшәдәге Гафур мулла йортын җайлаштырганнар иде, утын төткәзә алмагач, аны да ташладылар. Мулла колхозлашу елларында бөтен имаратын[1] ташлап каядыр качты...

Берзаман мәктәп коридорында шау-шу купты, чыр-чу, пыр тузып чабышу. Әйтерсең лә дөньяны сугыш сөреме капламаган, әйтерсең лә дөнья элеккечә матур! Сәрвәр апалары балаларга бераз кипшенергә кушып бияләйләрен, шәлләрен тимер мич тирәсенә таратып эләргә кушкан иде.

Дәресләр юклыгы яшь укытучыларның да күңелен бөтәйтеп җибәрде.

Элеккеге кысан чоланда хәзер «укытучылар бүлмәсе». Анда тимер мич юк, укытучылар «чолан»га кергән арада коридор ишеген кысып кына ачык калдыралар. Бу ике-өч адым киңлегендәге «чолан» өчен ишек ярыгыннан кергән җылы ярап куя, әз булса да җылыта. Әз дә җитә сугыш чоры кызларына. Алар азга да канәгать! Бик сирәк эләгә торган буш вакытларында алар шунда керәләр, шунда җыйналалар. Урындык вазифасын каен бүкәннәр үти. Мәүлия өеннән алып килгән ватык көзге кисәген диварга элеп куйган. Көзге — кызларның бердәнбер кадерле җиһазы. Күңелләре көр чагында шул көзге каршысына басып чәчләрен төрлечә кыландыралар, күпертеп куялар, икедән үреп төшләренә салалар, кашларын кыска калган карандаш белән каралталар, битләренә кершән сөртәләр. Имештер, егетләр сугыштан кайткан мәлгә шулай бизәнеп торачаклар алар! Чынында, көзгегә караган булып кызлар посып килеп чыккан күз яшьләрен киптереп тә алалар.

Мәүлия Йосыфның хатларын җыеп бара, берсен дә калдырмыйча үзе белән йөртә. Күңелләре сынык чакта хатларны кабат-кабат, туктыйтуктый, һәр ноктасына, өтеренә бармаклары белән төртә-төртә укыйлар, укыган саен яңа мәгънә табалар. Шамилдән хатлар башта ук сирәк килә иде, нишлисең, кулын төеп яздырып булмый. Миңнурый исә Мөхәммәт абыйсы язган хатларны алып килә, аның сүзләрен дә җыйнаулашып укыйлар, шатланалар.

Ана теле укытучысы Казан кызы Зилә генә Себер шартларына күнегә алмыйча озак интекте. Зиләнең тавышы сөйләшкәндә дә матур, ә инде җырлый башласа, иптәшләрен моң дәрьясына алып кереп китә. Борынгы көйләрне аерата ярата Зилә. Җырлый-җырлый да әнкәсен сагынып җылап җибәрә.

Балалар аның моңлы тавышын үтә нык яраталар, күзләре яшьләнгән Зиләне кызганалар да иде.

Укытучы кызлар, ишеткәннәрен, укыган китапларыннан алган гыйбрәтләрен кушып егетләр хакында гәпләшә башласалар, Сәрвәр бер читкәрәк тартыла. Ямьсез-бәхетсез булды моңарчы аның яшьлек гомере. Әткәсе Әссәтне атып үтерделәр, әнкәсе Иртеш суына батып вафат булды... Ә үзен, ә үзен... Үлмәс атлы әрсез пәри кызлыгын харап итте. Ниләр күрсәтмәде ул явыз! Сәрвәрнең сандугач оясына үтеп кергәндә читләр кызның кайгылы башын көлә-көлә тотып тордылар... Искә төшкән мәлләрдә тәне әле дә чымырдап китә, чигәләренә ут каба... Ә искә төшерми була мени?.. Әле Шамилдән хатлар килгәләгәндә, егетне үз янында, күкрәк турысында дип хис иткәндә йөрәге шушы кадәр янмый иде. Хатларның юлы киселде, өмет учагы сүнде. Сәрвәрнең күңеле үтә сизгер икән, чамалый, Шамил исән! Исән-аман аның сөйгән егете, хатлары гына туктады. Нихәл итәсең, Шамил олы егет булып килә, дөньяны таныйбелә башлагандыр, төрле авызлардан төрле гыйбрәтләр ишетеп бүтәнчә уйларга килгәндер! Томрап торган егеткә ни-нәрсәгә кеше калдыгы?!

Буранлы атна башындарак Сәрвәргә яман бер төш керде. Гөллечәчәкле май ае, имеш. Сәрвәр тар гына инеш ярында бер ялгызы басып тора. Елга уймакланып-җырлап ага да ага!.. Башында ап-ак яулык

[1] Имарат — хуҗалык, ихата.

Сәрвәрнең. Кинәт әллә каян җил чыкты, кызның ак яулыгын очыртып алып китте. Яулыкны алыйм дип үрелсә, тар инешнең теге ярында Шамиле баскан. Солдат киеменнән! Чибәрдер үзе, тазадыр, авызын ерган да Сәрвәргә карап тик басып тора. Ул арада яулык агып та китте, түбәндә, шактый еракта, шәүлә булып кына күренгән ят бер хатын Сәрвәрнең яулыгын тотып алды. Тотып алды да иңенә салды. Сәрвәр Шамилгә үпкәләп нидер әйтмәк була, ул арада инеш киңәя башлады. Киңәя, киңәя Шамиле бик тиз ераклашты, күздән гаеп булды.

Сәрвәр куркып уянды, өй стеналарына ятып җылаган җил тавышына кушылып озак кына үкседе.

Шул төш, шул төш иңгән төн аның сабырлыгын тузгытып ташлады һәм ул үтә кыен булса да Чырыкның ишеген какты. Бүтәнчә барыр җире юк иде. Чырык та аның хәсрәтен юарлык сүз әйтә алмады...

Кызлар егетләреннән килгән хатларын бергә укысалар да аерым-аерым укыйлар, аерым-аерым сагыналар. Сәрвәрнең Шамилгә әллә ниләр язасы килә, кулы бармый. Ни дип язсын ул аңа? Тиң кешеләр мени алар? Сәрвәр мәсхәрә ителгән бер бәндә! Ни кыз түгел, ни тол хатын түгел! Белми бит аның Шамиле барын да! Теге чакта вәхшиләрчә мәсхәрә итте бит аны Үлмәс! Вәхшилек чигеннән чыгып, эш Сәрвәр танымаган кешеләр алдында булды! Оялмады җир бит. Караган врач аның инде бервакытта да бәби тапмаслыгын әйтте. Әйтеп ялгышты, хата кылды! Шамил исә балаларны өзелеп ярата!

Боларын да кушып уйлагач Сәрвәрнең йөрәге жу итеп китә. Булмый, Шамилкәем, синең белән кавышулар насыйп түгел безгә! «Бер-беребезне онытырга тырышыйк!» — дип язасы килә Сәрвәрнең. Кая язсын, ничек эзләп тапсын? Кайчаннан бирле хат-хәбәре юк. Фронт тик тормый, фронт күчә, күпме җаннарны күчереп йөртә!

Менә Йосыф яза ичмасам Мәүлиягә хатларны! Һәр хаты җыр белән тәмамлана.

Хатка карап Зилә җыр җырлый башлый, Мәүлия белән Миңнурый күтәреп алалар. Борлыгып, күз яшьләренә юынып Сәрвәр читтә басып кала. Миңнурыйга рәхәт, әле аның мәхәббәт елгасының татлы да агулы да суын эчкәне юк. Сөймәгән дә ул, сөелмәгән дә!.. Кыш уртасындагы Себер бураннарының Ялан авылына күпме мәшәкать өстәвен күреп, белеп торса да Миңнурый шушы юлсызлыкка, чит төбәкләр белән арадашлык өзелгәнгә эчтән генә куана. Тик ул моны берәүгә дә әйтми, белдерми дә! Тамагы ач булса да, колагы бу көннәргә кадәр тыныч иде аның. Тубылдан убыр булып теге кулсыз килеп чыкмады. Миңнурый чамалый, ул шөкәтсез, чибәр кызларны болай гына калдыра торган түгел, хатын-кыз буа буарлык булса да, Миңнурый чибәр шул, затлы кыз. «Берәрсенә ияләнеп мине онытса ярар иде лә!» — дип ялвара Чиләбе кызы таңнарда. Ялвара да усалланып та куя. Сәрвәрнең тарихын, аның яшьли күргән газапларын, мыскыллануын ишеттергәннәр иде инде аңа. Сәрвәр мисалы аның күз алдыннан китми... Беркөн чормага, Мөхәммәт абыйсының иске китапларын караштырырга менгәч, өрлеккә сузып салган, чүпрәк-чапракка уралган ау мылтыгын күргәч, мылтыкны да, патроннарын да аска алып төшеп, чолан почмагына яшереп куйды. Әгәр теге явыз килеп чыгып аның сафлыгына кулын суза икән... баш биреп торачак түгел Миңнурый. Мәэзин бабасы үз иманын саклап милиционерлар өеренә каршы чыга алган! Миңнурый шул мәэзиннең тугры баласы, нәбәрәсе түгелмени?!

Сугыш елларында бер генә көн дә тыныч кына, ипле генә үтмәде. Мәктәпне бикләп, таралырга торганда, җылый-җылый шешенеп беткән Гөлнур килеп керде. Ниһаять, көч-хәл белән пар ат куып Тубылдан почтаны алып кайтканнар икән. Хатлар да булган... һәм хатлар арасында Гөлнурларга кара кайгылы хәбәр дә килеп ирешкән.

Укытучылар, кайтып китәргә өлгермәгән балалар кызны уртага алып як-ягына түгәрәкләнеп бастылар.

— Әтиемне фашистлар үтергән,— диде кыз яшькә буылып. Зилә апасы, нечкә күңелле Казан кызы аны кочып алды. Бүтәннәр тын гына аларга карап катып калдылар. Бүгенге көн дә корбансыз, бәхетсезлек китермичә үтә алмады. Әле алда ниләр булыр, әлегә сугышның очы да, кырые да күренми...

## 12

Ана күңеле чиксез дәрья, бала — ана җанының яртысы. Саниясенең мәрхәмәтсез дошман кулыннан үтүен Мөхлисә карчык көне-сәгате белән белде. Төшләр дә күрмәде, юрап интекмәде дә, Саниясе үлгән көнне аның ярты ягы тораташ булып катты да калды. Кулы белән агач кашыгын авызына җиткерә алмады, уң аягын сөйрәп кенә йөртә башлады, уң як кашы мелт-мелт итеп чиртә торган булды. Хәтта уң ягындагы чәчләре тоташ агарган иде. Бер тапкыр да үз авылыннан чыгып чит җирләргә барып йөрмәгән, дөньяда германнар барлыгын да сугыш афәте чыккач кына белә алган татар карчыгы ни кодрәт белән уй җепләре артыннан Бухенвальдка барып җиткән дә кызның үлеме хәбәрен аңа кем җиткергән?.. Моны Мөхлисә әби белә дә, аңлата да алмый иде. Йокысыннан уянды, калкынып намазын укырга җыенды һәм ярты гәүдәсенең тынып калганын аңлагач: «Сания балакаемны харап иткәннәр»,— диде. Гаҗәп, җыламады да Мөхлисә карчык.

Миңнурый Яланга күчеп килмәсә, карчыкның эше харап иде. Әле Фаягөл үсеп-ныгып китмәгән, көч маясын туплап калкынып кына килгән чагы. Ә әбинең күрер күзгә курач гәүдәсе шактый авыр булып чыкты. Хәзер аны багарга, ничә мәртәбә тәһарәт алдырып, бөгелми торган аягын салындырып чиста бүкәнгә утыртырга, аның эчке бер тантана белән намаз укуын караштырып торырга кирәк иде. Беренче көннәрдә үз хәленә күнегә алмаган карчык, бүкәннән егылып китеп сул күз тирәсен нык ук канатты.

Миңнурый Фаягөлне җитәкләп мәктәпкә китә, юлда барганда иелеп өч-дүрт мәртәбә аны үбә, иркәли. Әбисе алдында сорашырга базмаган кызчык юлда, икәүдән-икәү генә барганда еш-еш: «Миңнурый апам, нигә әнием хат язмый?» — дип сорый. «Ник? Нигә?» Боларын каян белсен Миңнурый? Ул һәркөн җавапны яңачарак бирергә тырыша, төрле сәбәпләр эзли. Ләкин кызны бер җавап та сөендерми, аңа сүз түгел, әнисе кирәк. Фаягөл белә, әгәр әнкәсе өйдә булса, әбисе дә чирләп китмәс иде. Әбисе нидер белә, аңа фәрештәләр хәбәр иңдергән булырга тиеш, мәгәр Мөхлисә карчык та нәбәрәсенә ачылып китми. «Нигә сабый җанын тинтерәтергә?»

Юллар өзек, беркем беркая чыга алмый, кибетнең айлар буе ачылганы юк, кыска гына ачылып торган арада исәннәр кибеткә кереп тула тулуын, алар буш киштәләргә карап бер офтаналар да кибеттә икәнлекләрен онытып үзара гәпләшә башлыйлар. Сүз һаман бер тирәдә бара. Сугыш, кемнәр үлгән дә, кемнәр хәбәрсез югалган. Сугыш хәлләреннән соң монда, авылга борылып кайталар... Имеш, төн уртасында авыл аша чаңгыга баскан өч кеше үтеп киткән. Фәлән авылның колхоз фермасыннан соңгы дүрт сарыкларын алып чыкканнар. Тегән авыл кибетенең тәрәзәсен ватып, бурлар кергән дә бар булган вак-төякне кырып-себереп алып чыкканнар...

Кем йөри, кибетләрне кем баса, мал-туарны кем урлый — моны беркем белми... Сугыш шушы аулак авылга да яңадан-яңа афәт өстәп тора. Менә Мөхлисә әби йортында да шырпы, ипи-тоз бетте. Утлы күмерләрне калын итеп көл белән каплап саклаштыралар, күмер сүнеп киткәндә

балчык чүлмәк тотып күрше-тирәгә ут эзләргә чыгып чабалар. Ә тозны күршедән сорап ала алмыйсың, алтын бәясенә дә таба торган түгел тозны. Бер көн тозсыз аш пешерделәр. Фаягөл чыраен сытып, зарлана-зарлана гына сыек өйрәне шопырды да, кашыгын куеп читкә барып ятты. «Әллә, тәмсез!» диде. Мөхлисә әби гадәттәгечә йомшак тавыш белән Миңнурыйга эндәште.

— Кызым, әллә Шәгъбикәләргә барып карыйсыңмы? Анда тоз да, шырпы да булырга тиеш.

Миңнурый карышып тормады, дәрес әзерләп утырган җиреннән тиз-тиз калкынып авылның аргы очындагы Шәгъбикәләр өен эзләп китте.

«Сугыш чыкса, илдә кемдер симерә, кемдер буш улак башы кимерә», диләр. Хак сүз. Кырык беренче елның кара көзендә, сугыш башланган елны бик соң гына Шәгъбикәнең тәрәзәсен кактылар. Авыл читендә яшәгәч мондый хәлләр элек тә булгалый, соңарып йөрүче юлчылар фатир сорап аларга кергәлиләр иде. Шәгъбикә ертлач һәм батыр хатын, кисәү агачын сул кулына тотып, уңы белән өйалды ишеге келәсен күтәрде.

— Кем йөри анда? Ни кирәк? — дип сорады.

Юлаучылар икән. Каяндыр кайтып киләләр дә атлары арган, үзләре ачыккан, иртәдән бирле карлы-бозлы яңгыр ява, юллар җебегән, кыскасы, «Син, чибәр апасы, безне кундырып чыгар инде. Без икәү. Ашарга да юнәтә алсаң, буш итмәбез!» Шәгъбикәнең өе иркен, түре киң, нигә кертмәскә? Шәт буш итмәсләр әле, ат аунаган җирдә төк кала.

Атны лапас астына кертеп, алдына печән катыш салам салгач, юлаучылар балчык ябышып батман-батманга әйләнгән кирза итекләрен оялдында калдырып өйгә керделәр, ишек катындагы агач чөйгә юеш кием-салымнарын элделәр һәм пар күтәрелеп торган кыска чәчләрен сыпыра-сыпыра өстәл янына кыю гына килеп утырдылар.

Алар сөйләргә ашыкмады, Шәгъбикә ашыктырмады, чыра телеп самавырына су тутырды. Ипи кыерчыгы чыгарды, иртәннән калган салкын бәрәңгесе һәм бер-ике кисәк балыгы бар иде, шуларны такта өстәлгә чыгарып тезде.

Салкын бәрәңгене, кайнар чәйне тамаша итеп утырган юлчыларның өлкәне, Шәгъбикәнең калын, түгәрәк артына күз сала-сала күзләрен уйнатып болай диде:

— Рәхмәт, чибәр апасы. Түреңне бирдең, чирканмадың, чәең тәмле булырга охшый. Анысы өчен дә рәхмәт. Тик безгә болар гына җитми. Син безгә бер ярты чыгар! Актан булса да ярый, самогоннан да баш тартмыйбыз, булсын гына. Ә без сиңа... — Юлаучылар бер-берсенә карашып алдылар. — Шырпы, тоз калдырабыз.

Шәгъбикәнең ерылган нәни бүрәнкә авызы тиз үк җыелды:

— Шырпы, тоз? Кинәндерәсез икән! Ни пычагыма ул миңа шырпы-тоз?

— Ялгышма, апасы... Бүген булмаса, иртәгә аларны алтынга тиңләп йөртә башларлар!

«Алтын» дигәнне ишеткәч, Шәгъбикәнең калак сөяге астында нидер кыймылдап куйгандай булды һәм Гобәйбә буйдактан алып кайтып куйган сасы самогонын чыгарды. Юлаучылар аны чынаяк чәшкеләренә бүлеп салдылар да йотып та куйдылар. Табындагы ризыклар бик тиз юк булды. Юлаучыларның өлкәне — телгә беткән Казан ягы кешесе икән, рәхмәтне кат-кат итеп мул яудырды. Инде төн урталары узып, Шәгъбикә дә изрәп йокыга китеп азапланганда теленә шайтан төкергән татар, яткан җиреннән идәннән шуып-тәгәрәп кенә килде дә «ә» дигәнчә каравatка менеп җитте, таза тәнле хатынны аерып-чаерып бәхет диңгезенә кереп тә чумды. Шәгъбикә «эх» итәргә дә өлгермәде. Алар төнне бергә уздырдылар...

Иртәнчәк Шәгъбикә әтәчен суеп, кайнар шулпа пешерде, йөгереп кенә Гобәйбә буйдак капкасын кагарга өлгерде. Тышта кара яңгыр ява, кар

төшә, таң байтактан атса да өй караңгы диярлек. Юлчылар ул көнне әле чыгып китә алмадылар. Шул ук тоз, шырпы вәгъдә итеп, сыйланып тагын бер төнне үткәрделәр. Бу төндә Шәгъбикә конарсыз юлаучыларның яшьрәгеи куенына алды. Тагын бер, өченче төннәрен кунгач, һавалар әз-мәз утырып киткәч, шома Казан татары Шәгъбикәгә болай диде: «Чибәр апасы, кайтып керүгә без сугышка чыгып китәсе... Әллә кайтып була аннан, әллә юк. Безне кабул иттең, рәхәтләндердең. Сиңа яхшылык бездән булсын: без сиңа дүрт капчык тоз, дүрт зур тартма шырпы калдырабыз. Киңәшемне тот: бүгеннән чыгарып салма син аларны, бирәүгә дә белдермә! Ходай бәхетеңне бирсен, бәрәкәтен таты бездән калган малларның!»

Ошатты юмарт юлаучыларны хәйләкәр төлке Шәгъбикә, сүзләрен дә, биргән бүләкләрен дә ошатты. Иң мөһиме, юлаучыларның кунып ятуы да, калдырган маллары да авыл арасында сүз булып таралмады.

Сугыш заманы бик тиз үзен сиздерде, ярты ел дигәндә Яланда тоз да, шырпы, керосин да калмаган иде инде. Йорт хуҗалары вак-төяк затлы әйберләрен йомарлап Тубылга чаптылар, пароходларны көтеп алдылар, онытылып беткән кардәш-ыруларына Салехардка хат яздылар: «Коткарыгыз, булышыгыз!» Шәгъбикә шырпының, тозның исен чыгармады. «Әйдә бераз бәяләр күтәрелсен!» дип һаман өметләнеп көтте, көткән саен комсызлыгы котырды.

Кырык өченең гыйнварына кергәч, Шәгъбикәгә тагын бер акыл иңде. «Әгәр бар булган малны алыштырмасам, Ялан авылында алтын-көмеш тә, йөзек-беләзекләр дә, акча да калмаячак!» — дип уйлады ул һәм тоз, шырпыны бик чамалап кына, саранланып, бәхәсләшеп, килгәннәрнең бугазларыннан алып шыпырт кына шудыра башлады. Хәбәр киртәләрне санламый, тоз-шырпы теләнеп күрше авыллардан килә башладылар. Аракыга да алыштырды Шәгъбикә хәзинәсен, балдаклар да җыйды, очы-очы белән кызыл мал да алды, йортын, чоланын, идән асларын мал белән тутырды. Пар ат җигеп аңа утынны да китереп ташладылар, он, ярмасы да әллә кайчанга кадәр җитәрлек булды Шәгъбикәнең.

Шул чакта, кырык өченчедә, Яңа елны каршылаган мәлләрдә авылга Тимерҗан исемле егет кайтып төште. Яраланган, сул кулын кара тасма белән муенына асып йөри, нужа шулпасын шактый ашаган егет икән, кайтып керүгә авылда күпме тол хатын барлыгын, кияүгә китмәгән кызлар ничә икәнен белешкәч, исәпләп чыгарган, исемлек төзегән. Хатын-кызларның тормыш мөмкинлекләрен чамалагач, Шәгъбикә исеменә төртеп күрсәткән дә: «Өйләнәм!» — дигән...

Миңнурый гозерләнеп Шәгъбикәләргә барып кергәндә Тимерҗан селәгәйнең кияүләп яткан ширбәтле көннәре иде. Ит югында җылы шулпа, тол Шәгъбикәгә Тимерҗан да ярап тора. Җитмәсә аны кичәге җыелышта колхоз рәисе итеп сайлап та куйдылар. Дәүләтшә әкә бик өшәнгән, тазалыкка туймый башлаган иде. Тимерҗанның сөяге сыек, күзенең комсыз икәнен дә беләләр, «әйдә ярар, ир-ат әле!» диештеләр Тимерҗанга кул күтәреп ризалашкан Ялан хатыннары. Колхозның черек кулга барып кергәнен күреп торган Дәүләтшә әкә, төнлә карчыгын уятып: «Язгы чәчү якынлаша! Күтәрә алмам мин ул авыр эшне!» — дип, үзен-үзе акларга азапланды.

Миңнурый барып кергәндә Тимерҗан күлмәкчән генә түргә утырган да сары майга мана-мана, ясканып төче коймак ашый иде. Ишектән суыкта янып кызарып пешкән, заманына күрә һәйбәт кенә киенгән сылу кызны күргәч, коймак Тимерҗанның тамагына торды, ул чәчәде. Иренең чит хатын-кызга тасыраеп карап торуын күреп, көнче күбәләк Шәгъбикәнең җене котырды. Мөгаллимәнең тоз, шырпы сорап килгәнен ишеткәч, Миңнурыйга булдыра алган кадәр мыскыллап карады.

— Кулың буш, — диде ул тәртмә тавыш белән. — Мин бит тоз-шырпыны акчага сатмыйм.

Кәләшенең сүзе Тимерҗанга ошамады, ул бүртенеп:

— Нигә сатмыйсың? Акчадан туйдыңмы әллә?— дип кычкырып куйды.

Шәгъбикә Миңнурыйның акчасын алып, күзгә кырып салырлык кына тоз, ике кап шырпы тоттырып озатып калды. Миңнурый артыннан капка ябылуга, ул уклау тотып Тимерҗанга ташланды.

— Минем эшемә катнашма, ачбет! Тыгын, аша, ирлек вазифаңны стахановчыларча үтә, мәгәр телеңне тый! Мин сине алып кайттым, куып чыгарырга да күп сорамам!..— дип кабатлый-кабатлый иренең җилкәсен төйде Шәгъбикә.

Табан астына сүнмәс ут кабынган Шәгъбикәнең селәгәй Тимерҗанны йортка кертүе авыл арасында бер мәзәк булып, атналар буена авыз чайкарга яраса, икенче бер хатынның күрсәткән кыланмышлары Ялан авылын тетерәтте.

Иреннән озак вакытлар хәбәр-хәтер килми торгач, шактый хафага төшкән Мәүлихага Омск шәһәреннән, госпитальдән хат килеп төште. Чакыру хаты. Хатта кем дә аңларлык итеп ачыктан-ачык менә болай дип язылган иде: «Хөрмәтле Мәүлиха! Ирең батырларча сугышып бик күп яралар алды. Хәзерендә дә аның хәле җиңелдән түгел. Ул сезне, гаиләсен бик нык сагына. Теләсәгез, сез аны үз яныгызга алып китә аласыз».

Мәүлиха хатны өй борынча күрсәтеп йөрде, ни-нәрсәгә булыр бу чакыру, дип тирән аптырашта калды. Ике көн тоташтан баш ватканнан соң, баласын әбисе янында калдырып, ире Шәүкәт янына китте.

Мең бәла белән Омскига барып җитеп, көч-хәл белән гаскәри госпитальне эзләп табып, ире янына кергәч аптырап китте, чак кына авып китмичә калды. Иренең аяк-кулларын төптән үк кисканнәр, ул түгәрәк, ямьсез бүкәнгә охшап калган иде. Яралылар үзара мондый бичараларны «самавыр» дип атап йөртәләр икән. Бер палатага җыелган өч самавырның чарасыз калган күзләренә карарга курыкты Мәүлиха. Андый солдатларны махсус беркетелгән шәфкать туташлары бага икән, шулар ашата, йомышларын үтәтә, урын-җирләрен карый. Шәүкәт бахырның җыларга да хәле калмаган, алай да ике күзеннән дә елга булып яше ага. Мәүлиха ире янына якын бара алмады, чирканып та, гарьләнеп тә ишек катында шактый вакыт басып торды. Аны озата кергән врач: «Таныйсызмы, бу сезнең ирегез!»— дигәч, җене чыгып, үртәлеп: «Юк, бу минем ирем түгел, минем бу кешегә кияүгә чыкканым юк!»— дип кычкырып җибәрде. Хатынының күрәләтә үзеннән ваз кичүен күреп, иң актыккы өметенең дә юкка чыгуын күреп торган Шәүкәт: «И җаным, Мәүлиха! Бу мин, синең Шәүкәтең. Менә нинди хәлләрдә калдым!»— дип үрсәләнде. Мәүлиха ул арада уйларын йомгаклап, акылын йодырыгына җыеп өлгерде: «Юк, юк! Бу адәм саташа гына, аның һичкайчан минем ирем булганы юк!»— дип кабатлады. Ул, мондый хәлләрне сирәк булса да очраткалаган врачны ышандырырга тырышты. Үзе өзмәс: «Бу бүкән белән ничек яшәмәк кирәк? Болай да читен тормыш арасына бу имгәкне дә алып кайтсаң...»— дип уй йөртте.

Шәүкәт исә Мәүлихасын бик яхшы таныды, өзелеп көткән хатынының үзен күргәч җимерелгән чыраена туры карарга тырышты: «Мәүлиха, Мәүлиха!»— дип йөз кабат тәкърарлады. Хатынының каты бәгырьле булуына исе китеп, врачка дәшеп карады: «Әйтегез аңа, зинһар аңлатыгыз. Мин аның ире, исемем Шәүкәт!»— дип ялварды. Мәүлиханың якын килү түгел, арты белән һаман ишеккә таба чигенүен күргәч, Шәүкәт соңгы сүзләрен әйтеп калырга ашыкты:

— Бик кыенсынсаң, балам белән генә күрештер. Өйгә алып кайтып бер-ике кич балам янында кундыр. Улымны чиксез сагындым. Минем каным ич анда! Үз балам!

Бу сүзләр йөрәкне умырып- яралап күкрәктән чыкса да, хатын чарәшеп каткан иде, һаман үз сүзен тукылдады: «Юк, син минем ирем түгел!»

Бу сүзләрне тыңлап яткан, бердәй әче язмышка дучар ителгән ике солдат башта тыела алмыйча үкседеләр, аннары чыдамнары бетеп, атыюлы белән сүгенергә, Мәүлиханы каргарга тотындылар. «Эчең әйләнеп чыксын, мөртәт!» — диде аларның берсе. «Бәлки үзара уртак фикергә килерләр, уртак сүз табарлар», дип, шәфкать туташлары, врачлар, күз яшенә тончыгып коридорга чыгып киттеләр. Аларга ияреп ишек бавына тотынган Мәүлиха, Шәүкәтнең соңгы үтенечен кире кага алмыйча, тукталырга мәҗбүр булды.

— Күрәм, танымыйсың. Нишлим, дөнья үзгәртте шул безне, танымаслык итте. Инде соңгы бер үтенечем генә калды. Балабыз хакына ялварып сорыйм, Мәүлиха. Соңгы үтенечемне кире какма! Яшьлегемне озатканда бер үбим үзеңне. Мәңгелек хатирәң булып шул калсын! Кил яныма!

Шәүкәт үлем авазы белән ялваргач, янындагы гарип иптәшләре дә куәтләгәч, Мәүлиха чыгар җиреннән тукталды, борылып кире килде, күзләрен йомып, җирәнеп, укшуын тыеп тере «самавыр» өстенә иелде һәм шул арада Шәүкәт Мәүлиханың танавына эт булып ырылдап ябышты һәм күз ачып йомган арада акыртып хатынының борын очын өзеп тә алды. Кан чәчрәде.

— Ай-вай! — дип акырган тавышка шәфкать туташлары, врачлар йөгерешеп керделәр һәм канга буялган хатынны хирургка алып кереп киттеләр.

Шәүкәт ачыргаланып:

— Син дә гарип булып яшә, аннары аңларсың! — дип кычкырып калды, һәм авызындагы канлы ит кисәген түкереп атты.

Гаиләсе баш тартканнан соң мәңгелек гарип, сугыш батыры Шәүкәтне инвалидлар йортына илтеп тапшырдылар.

Берничә көн дәвалангач, иреннән ваз кичүе турында кәгазь язып, өзек борын очын Омскида калдырып, томшыгын кап-кара чүпрәк белән бәйләп Мәүлиха авылына кайтып җитте.

Шыксыз хәбәр аның артыннан ук колактан колакка сикереп, авыздан авызга күчеп Яланга барып та җитте. Мәүлиха: «Хата чакырганнар, бөтенләй танымаган, чит ирне күрсәттеләр!» — дип ышандырырга тырышып азапланса да, аның китек танавына карап сүзенә ышанмадылар. Шәүкәтне, заманасында авылның иң чибәр, иң ягымлы егетен җәлләмәгән кеше калмады. Яшь, таза, куе бөдрә чәчле Шәүкәт өчен, җәйге таңнар сызылып атканда, Иртеш өстенә ак буран булып ак корт яуганда күпме житкән кызлар кайнар яшьләрен түкмәгәндер? Андый егетне үзенә карата алган Мәүлихадан көнләшеп йөрделәр. Авылның бердәнберен кулына төшергәч, Мәүлиха аны боргычлап тотты, кичке уеннарга чыгармады, шашып-шашып иркәләде, юмалады, юхалады, үпте, кочты. Кемнең кем икәнен — әүлияме, албастымы булуын — авыр хәлгә дучар булгач кына беләсең икән!

— Намусың кайда синең? Бала атасыннан ана кеше баш тарта аламы?.. Намусы юкның иманы да булмый икән шул,— дип беравыкка кадәр уфтанды Ялан кешеләре. Бу сүзләр Мәүлиханың бер колагына керде, берсеннән чыкты. Ул томшыгының китеген кара чүпрәк белән бәйләсә дә очраган бер чит ирга өзелеп күз салды...

## 13

Улы Ташкәй хакында сөйләшергә яратмый Йомабикә абыстай. Ташкәй төрмә бусагасын атлап кергәннән бирле аның чыраен дөньяга ачып рәтләп сөйләшкәне дә юк. Кызы Мәүлиягә дә ачык чырай бирми диярлек, аяк атлау рәвеше дә үзгәрде, кемнәндер качкан сыман чайкала-чайкала бара. Авыз ачып сүз әйтә икән, тыңкышлана, җөмләсенә

борын авазларын күбрәк кушып җибәрә. Мөхәммәт Уразаев армиягә киткәннән бирле аның табигате тагын да ныграк үзгәрде. Сандык төбеннән күптән онытылган намазлыгын эзләп алып, тәһарәтләнеп Аллаһе Тәгаләгә мөрәҗәгать итте. Бүтән эндәшер кешесе дә, сердәше дә калмаган иде аның. Ырсытдин вафат, кадерле улы Ташкәй рәшәткәле йортта. Кызы Мәүлия белән аларның берчакта да борчаклары пешмәде. Ата кешенең мөгаллим Мөхәммәт абыйсы икәнен белгәннән соң, Мәүлия Йомабикәдән читенсенде. Алар бер йортта, бер түбә астында яшәсәләр дә һәр каюсы үз читлегендә, үз тормышы белән яши иде. Мәүлия мандолинада уйнарга өйрәнде, ялгызлык чиреннән мандолина чиртеп котылырга гадәтләнде. Ара-тирә аларга Зилә дә кереп утыра, бергәләп җырлап та алалар. Яңа укытучы Миңнурыйның гына алар йортына аяк басканы юк. Йомабикәне күргәч шушы билсез юантык хатынның Мөхәммәт абыйсының мәгъшукасы булуын ул һич күз алдына китерә алмый иде. Эчке, тирән нәфрәт белән яратмый иде Миңнурый Мәүлиянең әнкәсен.

Ходага шөкер, Ырсытдин хәлле чагында йортны иркен итеп салган, икесенә ике башта ике өй, ике ишек, атналар буена күрешмичә яшәргә була. Йомабикә дә, Мәүлия дә ялгызлыкны ярата башлаган вакыт иде.

Кышның сирәк очрый торган тын, аяз кичләренең берсендә Ырсытдин ихатасында әрсезләнеп кар шыгырдады. Кар шыгырдавы бераз тынып торды да Йомабикә бичә яши торган якның иске чүпрәкләр белән ышыкланган авыр ишеге шыгырдап ачылды. Йомабикә сискәнеп китте. Чал бөртекләр күренгәли башлаган чәчен ашык-пошык иске яулык астына бөтереп тыкты — керүче ир затыннан иде. Якасыз иске бишмәт, йоны тырпаеп тузган бүрек кигән тәбәнәк, курач бу кеше Чырык Абдрахман иде. Көннәрнең язга борылып яктыра башлавын тойган карт, Колга Миша Сорокинның кат-кат колагына киртләгән боерыгын исенә төшерде. Мылтык белән дары табарга кушкан иде бит ул. Аның һәр боерыгын үтәмәсәң, эшнең яман якка борылып китәсен хәтереннән чыгармаган Абдрахман, Йомабикәдән ничек тә булса мылтык, дары юнәтергә кергән иде. Корулы мылтык Абдрахманның үзеннән дә артмас иде артуын...

Кучкарда куыксыз җиделе лампа гына янса да Абдрахманның челтчелт күзләре шактый ачык күрә икән әле! Йомабикәнең ситса күлмәгенең алдан да, арттан да шактый нык кабарып торуын да, Ырсытдин хатынының әле бик үк тузмаганын да абайлап күңеленә салып куйды.

Йомабикә Чырыкны ул көткәнгә караганда ачыграк чырай белән каршылады.

— Әйдүк, әйдүк, Абдрахман әкә! Әле бер башым гына булгач чәй куярга да иренә идем, кунак булгач самавырны да җырлатырбыз, чәй чәшкеләрен дә биетербез,— дип урын күрсәтте, тунын, бүреген салырга булышып чәйгә элеп куйды. Тол дүдәк Чырыкның күңеле йомшарып китте. Ул нинди йомыш белән кергәнен дә онытты.

— Нихәлләрең бар соң, килен? Ничек яшәп ятасың?— дип моңлы тавыш белән тезеп китте. Йомабикәнең күңелен нечкәртергә, балавыз сыктырып йомшартырга, шуннан соң гына йомышын әйтергә дип әзерләнгән иде кунак.

— Ни хәлләр дип, Абдрахман әкә!.. Хәзер кемдә дә бердер инде ул. Әле көндез Мөхлисә корткага хәл белергә кергән идем. Ярты ягын паралич суккан диме, ипсез чакта җен-пәриләр кагылып киткәнме, ята мескен бүкән булып!

Сөйли Йомабикә, теле дә, үзе дә тик тора алмый, ялт итеп, симез артын як-якка чайкалдырып Чырыкка терәлеп диярлек үтеп китә, тагын борылып әйләнә. Җегерли башлаган йон кабасын бер кирәкмәскә урыныннан күчерә, лампаның корымы чыкмаса да филтәсен бер күтәрә, бер төшерә.

Белə Йомабикə: Чырык таушалган, коры сөяккə калган бер өрəк кенə. Əмма табигать бу хатынга шулкадəр мул дəрт, мəхəббəт чире биргəн ки, ир-ат күренсə, ул яхшы бия кебек кешни һəм коерыгын чайкый башлый. Чырык та моны сизə, ирлек тəҗрибəсе юк түгел, яшьрəк чакта, ярминкəлəрдə йөргəндə, Өркет каласына чаклы барып җиткəне бар, ярминкəдə нилəр генə булмый? Тəтəйлəр янына да кергəли иде, шайтан алгыры...

— Мөхлисə карчыкны əйтəм... Инде дөньяда бер өмете калмаган. Нəбəрəсе нəрсə, Фаягөл атлы анын нəбəрəсе, бала тек бала, сабый. Фатирына мөгаллимə төшергəн икəн. Каян андый хəтəр кызны табып алып кайтканнардыр. Хак булса, Мөхəммəт эзлəп тапкан, дилəр.

Ниһаять, Йомабикəнең сере ачылды! Мөхəммəттəн көнлəшеп, шуның сөяклəрен Иртештə чайкап утыра икəн. Ə Чырык, яктыга очып кергəн ябалак төсле, күзен бер ача, бер йома. Гөнаһына каршы, Йомабикə артын биетə-биетə үтеп киткəндə, аның мыймылдап торган йомырыларын тотып карыйсы килə. Бəрəкəт, Колгасар Сорокинга мылтык эзлəп килеп, куенына алырлык бичə тапты түгелме Чырык?!

Ул арада самавыр гөлдердəп кайнап чыкты. Йомабикə əллə нинди хикмəтле үлəннəр салынган чəйнеккə чырылдатып су агызды, бүлмəгə татлы урман исе таралды. Хуҗа зурлап кунакны чəйгə өндəгəч, Чырык пешенə-пешенə ике-өч тапкыр чəй йотты да, бугаз төерен калкытып башын арткарак чөйде һəм Йомабикəнең майлы күзлəренə текəлеп:

— Йомабикə бичə, сиңа йомышым төште бит əле,— диде.

Йомабикə юри көлгəндəй итте, күңеленə шик төште.

— Син, ил агасы, йомышсыз йөрмəссең, гуй.

— Хəтерем алдамаса, Ырсытдин замандашның бик шəп бер берданы булырга тиеш иде. Кедр очына менеп качкан тиеннең сул күзенə туп-туры бəрə торган бердан иде!

Йомабикə дə берданның барлыгын бик белə, ире ерак сəфəргə киткəндə үзе белəн алган иде аны, ияртеп алып та кайтты, майлап, чистартып, карап тотты. Бу арык төлке каян белə əле чоландагы агач сандык төбендə бердан барын? Чырык Йомабикəнең җавабын ашыктырмаска телəп шапыр-шопыр чəй чөмерергə кереште.

— Син аны, ничек, сатып алырга кердеңме?

— И Йомабикə чибəркəй!—шулай диде корышкан Чырык, телен җəллəмəде,— ниемə сатып алыйм ди мин аны? Чаңгыларымны барладым, əле көчем җитəрлек, күзем нык. Ауга чыгып кайтыйм дим, берданыңны кире китерермен анысы.

«Күзем нык» дигəндə Чырык Йомабикəнең сəдəфе ялгыш кына ычкынып киткəн күлмəк ерыгына карады. Бер төймəле, бер ычкындыра зəңгəр сəдəфне Йомабикə... Тəки җавабын уйлап тапты:

— Габдрахман əкə, синең сүзне җиргə саласым килми. Тик шунысы бар гуй, исəн микəн əле ул мылтык дигəнең? Бу арада күзгə-башка күренгəне юк. Менə, боерган булса, иртəгəге көнгə мин аны караштырып, эзлəп куярмын. Əгəр бар икəн, нигə биреп тормаска?.. Авың уң булып куяннарны күбрəк ата алсаң, мылтык хакына бирəрсен миңа да бирерсең...

Сүз кай тирəлəргə барып җитəр иде, əңгəмə шунда өзелде, авыр ишек шыгырдады, аннан шəлгə төренгəн, ак биялəй кигəн Сəрвəр килеп керде. Бу һич көтелмəгəн кунакның болай килеп керүе өйдəгелəрне соң дəрəҗəдə гаҗəплəндерде. Чырыкның авызы ачык калды, Йомабикə зəңгəр сəдəфен тоткан килеш керүчегə карады. Сəрвəр дə уңайсызланды, авызыннан чыккан сүзе аңлашылмады. Ул һич тə Чырыкны монда очратырмын дип уйламаган иде. Чын дөресен əйткəндə, кызның илəс-милəс чагы иде. Шамилнең хаты Мөхлисə тəтəйгə килгəн, ул əткəсенең адресын сораган. «Хəбəре бармы? Сания апа язамы?» — дип тə кызыксынган. Боларын Сəрвəргə Миңнурый килеп сөйлəде. Шамилнең элеккеге хатларында Сəрвəр хакында сүз булмый калмый иде, сəламнəрнең дə иң кайнары аның исеменə килə иде. Бу юлы лəм-мим. Икенче хат килде. Бусында да Сəрвəр хакында сүз юк иде.

Сәрвәр пошаманга төште, рухы җимерелде. Ни уйларга белмәде. Кыз күңеле кая борылырга белми икән, ул сары сагышка салыша...

Үзен яклап, җирбит Үлмәсне теге дөньяга җибәреп, сигез елга төрмәгә хөкем ителгән Ташкәй хакында Сәрвәр бик сирәк кенә уйлаштыра иде. Башта чире көчле булды, ул вакыйганы, ул вакыйгага катнашкан кешеләр хакында уйлыйсы, искә төшереп газапларын арттырасы килмәде кызның...

Инде менә, гаиләсендә япа-ялгыз калып, назлы өмете Шамиленнән дә хатлар өзелгәч, кызның рәнҗетелгән сизгер күңеле төрле якларга чәчелә башлады. Һәм шул чәчелгән очкыннарның берсе Ташкәйгә барып төште. Сәрвәр өчен үч алды бит ул егет! Аның намуслы исемен саклап Үлмәсне теге дөньяга озатты!.. Сәрвәр өчен генә чордашлары белән сугышка чыгып китә алмады. Ташкәй фронтта булса, кызны Шамил кебек хат-хәбәрсез интектермәс иде ул. Әзрәк җилпәк, әзрәк тупас булды Ташкәй, матур сүзләр сөйли белмәде, мәгәр ярата иде ич ул Сәрвәрне! Һәр егет үзенчә ярата, мәхәббәтен үзенә хас сүзләр белән аңлата. Күз карашы да бердәй булмый егетләрнең, Ташкәйнең теле тупасрак булса да, күз карашы нинди ягымлы иде бит! Кыз намусын яклап зур гөнаһ кыла алган кешене ничекләр онытып җибәрде соң әле Сәрвәр?..

Мәүлиядән: «Абыеңның хәбәре бармы? Ниләр яза?» — дип сорарга базмады, аулак чакны сайлап Ташкәйнең әнкәсе янына кагылырга булды. Кызның иләс-миләс чагы иде, күңеленә бер уй килсә, аның очына чыгарга талпынган ярсулы мәле иде. Йомабикә түтәй янына кыенсынып, соңгы көчен җыеп килеп керде. Ишек катында тыелып тукталса да Сәрвәрнең нияте нык, теләгәне кичектергесез иде. Чырыкның монда булуы, бәлки, файдагадыр әле? Йомабикә вак-төяк сораулар, шикләнүләре белән кызның җанын кыйнаганчы Сәрвәр үз сүзен әйтер дә... Һәм ул, Йомабикәнең кунак кызны түргә өндәвен ишетмәгән дә төсле, тынын эчкә алды да:

— Йомабикә апа, миңа Ташкәйнең адресы кирәк иде. Хатлар яза торгандыр бит? — дип сорады. Чырык нигәдер җиңел сулап куйды, Йомабикә сикереп торды, ипи табаклары тезелгән киштәдә эзләнә башлады.

— Ай аллам, хаты килмәгәнгә дә байтак булды инде. Бала өчен җаннарыңны бирәсең дә алар өй турында уйламый шул. Кыен ашый инде, балакаем, «Урман кисәбез, тимер юл салабыз»,— дип язган иде. Менә!

— Мин бу хатны алып торыймчы, Йомабикә апа,— диде Сәрвәр, аны-моны аңлатып тормыйча гына.— Иртәгә үк кертеп бирермен.

Сәрвәрнең Чырык алдында Ташкәйнең хатын укыйсы килми иде. Аралары матур түгел ич аларның, матур түгел! Болай да авыл арасында әллә нинди сүзләр таратыр. Шикле кеше, озак вакытлар югалып торган бәндә!

Сәрвәр хуҗаның ризалыгын көтеп тә тормады, таушалган өчпочмакка бөкләнгән кәгазьне ап-ак бияләе эченә тыкты да, ак шәлен тартыбрак бәйләп ишеккә ябышты. Саубуллашмады, борылмады...

Кыз чыгып киткәч, Йомабикә Чырыкка күтәрелеп карамады, аның баягы шуклыгын, Чырыкның килеп керүен уен итәргә теләп маташуын Сәрвәр алып киткән иде. Чырык исә әз генә аңгыраеп утырды да күтәрелеп карады, исе китте. Йомабикә ап-ак имиен күрсәтеп зәңгәр сәдәфләрнең бөтенесен ычкындырып бетергән иде. Шулчак нидер булды, күптән хатын-кыз назын татымаган картның тәне буйлап астан өскә яшьлек дулкыны йөгереп узды, ул өреп утны сүндерде һәм арттан килеп Йомабикәнең култык асларына кулларын тыкты. Йомабикә каушап телсез калды: «Үзем, үзем!» — дип пышылдады. Тиреләр җәйгән агач карават киң һәм иркен иде. Барыннан да бигрәк җып-җылы! Җылы гынамы соң — кайнар, ут!..

Йомабикә, Абдрахман инде коры сөяккә генә калган мәхлук, дип уйлап ялгышты, хәле-җегәре бар икән әле явызның. Мыймылдап торган бичәнең түшләренә яткан Чырык Абдрахман оҗмах капкасын ачып керде һәм тук мәче кебек мырлады. Үбешмәделәр, Чырыкның коргаксыган иреннәре тиеп киткәндә дә Йомабикә бичә җирәнеп йөзен борды...

* * *

Мөхлисә карчыкны чиргә сабыштырган, Сәрвәр сылуның җанын кырыкка ярган, Фаягөл сабыйның тынычлыгын алган Шамил солдат, Шамил егет исән-сау иде. Ничәмә-ничә сугышларда катнашып, чигенеп, әз-мәз алга кузгалгалап, исәнлегенә куанып, моңарчы бер яра да алмавына гаҗәпләнеп яшәп ята иде. Төрле хәлләрне күрде Шамил, үзе белән хезмәт иткән бик күп сугышчан дусларын югалтты, аерата якын дусларын җирләгәч яшертен генә җылаган чаклары да булды. Солдат күңеле катыланса да, Шамилнең күңелендә җылы бер почмак үзгәрешсез кала бирде. Бу җылы почмакта егетнең туган-үскән авылы Ялан, кадерле әткәсе, Мөхлисә әби, сеңлесе Фаягөлдәй якыннары саклана иде. Дөресен әйткәндә, күңеленең иң зур урынын Сәрвәр били иде. Хат язарга артык әвәс түгел иде Шамил солдат, башта ул фронт хәлләрен, күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен әткәсенә язылган хатларга терки, шик-шөбһәләрен дә яшерми, «ник гел чигенәбез соң без?» дип язган чаклары да булды.

«Особый отдел»га чакырып алып пешекләделәр егетне! «Паникер!» дип атадылар. «Бәхетең, командирларың ярата үзеңне, кыю-батыр солдат дип атыйлар, югыйсә, әллә кайчан чыгарып ата идек!» — дип куркытып озаттылар. Солдатлар арасыннан да кемнәрнедер чакырып-чакырып алуларын, киткәннәрнең эзсез югалуын Шамил ишеткәләп тора иде. Димәк, аның бәхете бар икән әле, атмадылар, шуның өстенә яшереп тә тормадылар: «Сак бул, телеңне тый, кирәкмәгәнне күрмә, ишетмә дә!» — дип тә аңлатып куйдылар.

Артык курыкмады да Шамил, солдат әҗәл сүзенә ияләнә, үлемнән курыкмый башлый. Алай да авызын җыйды Шамил, күп сораулар бирергә яраткан иптәшләренә сагаеп һәм төпченеп карый башлады, кемнең кем булуын танырга өйрәнде. Һәм хат язуларын киметте, язганнары да ике-өч җөмләдән артып китми иде.

Көтелмәгән бер хәл егетнең тормышын бөтән бер якка борып җибәрде һәм бу вакыйга аның тормышында үтә җитди урын алды...

Шамил хезмәт иткән полк, каты сугышлардан соң оборона алды. Полк таланган, йончыган һәм өстәмә көчләргә сусаган иде. Бөтәннәр әл-хәл ала, юына, кырына, өс-башны карый. Шамил беркетелгән разведка ротасында исә «кызу» эш бара. Бүген разведкага барырга кузгалганда Шамилләр тукталган авылны дошман бомбага тотты. Кара тәре таккан самолетлар, ике тапкыр ябырылып, авылның астын-өскә китерделәр.

Украин авылларын үткән чакта солдатлар төрледән-төрле хәлләргә шаһит булдылар, әмма бер нәрсә үзгәрешсез иде: сугыш хәлләрен бер генә кичермәгән украин хатын-кызлары хуҗабикәләр саранлыкны белмиләр иде диярлек. Бар булган ризыкларын җәлләмиләр, солдатны кадерлиләр, арсаң җылы урыннарын бирәләр, таләпчәнрәк, әрсезрәк булсаң куеннарына да алалар. Бу юлы Шамилләр гаҗәп саран бер хатынга юлыктылар. Ипи кыерчыгы түгел, кабыклы бәрәңгесен дә күрсәтми солдатларга! Ә хуҗалыгы нык кына! Немец авылны бомбага тотып тар-мар итеп киткәч, хуҗабикә артык дәрәҗәдә юмартланды. Казан тутырып бәрәңге пешерде, аны төеп, мул итеп көнбагыш мае сипте. Солдатлар лыкынганчы ашадылар. Хатынның биш капчык бодае өй базында саклана икән, күрше-каршы йортларның коры саламдай

шытырдап янып бетүен күргән хуҗабикә капчыкларны нык өсле тышкы базга күчерергә ниятләгән икән. Авыр, буаз капчыкларны хатын-кыз күтәрерлек кенә түгел. Егетләр «ә» дигәнче капчыкларны ташып куйдылар, лачинка белән балчык ташып баз өстен тагын да ныгыттылар. «Бомба түгел самолет үзе егылып төшсә дә баз түбәсен тишә алачак түгел»,— дип җорлангач, хуҗа хатын һәрвакыт тамакка таза солдатларны эремчек пилмәне — вареник белән сыйлады. Пилмәннең бер башын тешләп өзеп, эченә тутырып ашар өчен куе каймак та чыгарды. Хуҗабикәнең юмартлыгы бер көнгә генә җитте, егетләр бер-берсенә күз кысышып: «Немец мәлгунь авыл читенәрәк кенә булса да бер дәүрәк бомбаны ташлап китеп, безнең түтәйнең котын алмый ичмасам!» — дип шаярттылар...

Ниһаять, планнарны өр-яңадан тикшереп, картадан карап юлларны билгеләп разведкага чыгып киттеләр. Авылдан ерак та түгел җимеш агачлары арасында умарталык булган икән. Бомбалар ул тирәгә дә төшкән, кай якка карасаң да тирән-тирән чокырлар тәтәп ята. Шамилләр үтеп барганда чокырларның берсеннән ике аяк чыгып торганын күрделәр. Адәм аягы! Кинәт аяклар селкенеп куйгандай булды! Димәк, балчыкка күмелгән гәүдәнең җаны бар! Взвод капыл гына туктап казынырга, бәлагә тарыган кешене коткарырга кереште. Кеше! Гәүдә! Җитмәсә, хатын-кыз! Гәүдәне тартып чыгарып, чирәме сау калган аулакка яткырдылар, күзен-битен юып мәшәләнгән арада кызның чыраена сүрән генә кызыллык кайтты, сулышы тигезләнде. Бераздан кыз күзләрен дә ачты. Шамил йөгереп барып палаткалардан носилка алып килде. Алар туфрак астыннан чыккан яшь-яшь кызыкайны госпитальгә тапшырып калдырдылар.

Разведгруппа үз юлында булды, алар хәвеф-хәтәрсез генә дошман ягына үтеп чыктылар, кирәкле белешмәләрне дә тупладылар. Чуалып таралган кәкре-бөкре траншеялар арасыннан үтеп чыгып кайтабыз, котылабыз дигәндә дошман котырынып ут ачты, әгәр взводның үз ягыбызда — тылда калган яртысы уяулык күрсәтмәсә, белмим, Шамилләр исән-имин кала алыр идеме икән?..

Шамил разведкадан җиңелчә яраланып кайтты. Язмыш аны медсанбатта әлеге Зося белән очраштырды. Алар күрше палаткаларда булып чыктылар. Җиңел контузия алып, кулбаш тиресе сыдырылган, уң кулы каймыккан яшь, сәламәт кыз озакламый аягына басты  йөри дә башлады. Шәфкать туташлары аны җитәкләп Шамил янына алып керделәр һәм: «Менә сине теге дөньядан коткарып алып кайткан егет шушы, рәхим итеп, ал үзен!» — дип шаярттылар. Шул чакта Шамил тәмам югалып калды, юньле сүз дә әйтә алмады бугай. Беренчедән, кызның чибәрлеге аны коралсызландырды, икенчедән, коткаручы бер ул гына түгел ләбаса!

Зося ни уйлагандыр, дәшмәде, җәһәт атларга тырышып Шамил янына ук килде дә чүп иттереп уң битеннән үбеп тә алды.

Икенче көнне ул Шамил яткан палатага ике кып-кызыл алма алып керде. Ни хикмәттер, Шамилнең кул сызлавы бүген басыла төшкән иде, ул үткән төнен рәхәт итеп, изелеп йоклады, күңеле көр, кәефе әйбәт чак иде. Егет кызыл алмаларга карады. Әйтерсең лә аның моңарчы андыен да сихри нигъмәтләрне күргәне юк иде. Алмалар чын түгелдер, алар ниндидер сихри ым иярәредер дип тә уйлап алды егет. Шуннан соң гына күзе Зосяга төште. Зосяның битләре дә шул алмалар төсле янып тора иде, алмаларның берсенә энҗедәй ак тешләрен батыргач кына Шамил алмаларның чын булуына ышанды. Алмадан чәчрәгән татлы су егетнең битенә кунды, ирененә сирпелде. Зося исә һич тартынмады, алма сулы иренне үбеп тә алды. «Рәхмәт сиңа, егет!» — диде көлә-көлә Зося.

Тыйнак татар кызларын гына күреп, сөйләшеп белгән егетнең исе китте, бер үк вакытта ул үтә дә бәхетле иде, ни әйтергә дә белмәде.

Ялгышып кына килеп кергән асыл күбәләкне куркытырмын дип, ни кылырга, ни сөйләргә дә кыймады. Зося Шамил яткан караваттагы җәймәнең читен ачып аның гәүдәсенә терәлеп утырды, бит очларын, түшен сыйпады, «Авыртмыймы?» — дип сорады һәм исемен, кай яклардан сугышка алынуын белеште. Шамилнең Себер якларыннан килгән татар угылы икәнен белгәч, Зосяның кыйгач кашлары дугаланып югарыга сикерде. «Син татармыни? «Без укыган дәреслекләрдә, китапларда татарлар алар мөгезле шайтаннар, алар мәгарәләрдә яшиләр, чи ит ашыйлар»,— дип язылган була иде. Татар түгелсеңдер син, мондый сылу, чибәр егет татар буламыни?» — дип шаяртты. Шамилнең җитдилеген, дөрес сөйләвен күреп, аны иркәләргә, йомшак бармаклары белән чәчен араларга кереште.

Зося үзе ашый башлаган алманы Шамилгә дә каптырды, аның иреннәре тигән урынны кат-кат үпте, күзеннән якты нурлар, теленнән йомшак сүзләр түкте. Әле хатын-кыз назын татымаган, егетлеген бозмаган саф, тәҗрибәсез егет ни кылырга да белмәде, аның ирлеге уянды... Моны сизеп шук кыз күзен кысты, бармагын селкеде: «Ашыкма, ашыкма! Бар да булыр!» — дип вәгъдәләр бирде.

Зося терелеп кулбашлары сызлавы, колак шаулаулары кимегәч, бер көнне палатага әнисе белән килеп керде. Алар «коткаручы батыр егеткә» слива, чия кебек татлы җимешләр, сөт, каймак алып килгәннәр иде. Зосяның әнкәсе дә ачык йөзле, әле чибәрлеге йөзеннән китмәгән мөлаем апа икән. Ул егетне үзләренә кунакка чакырды. Алар шул җимерелгән чүнник янында гына яшиләр икән. «Бабабыз да бар әле безнең, аның да сине күрәсе килә. Әчетергә куйган балы да бар!» — диде Зосяның әнкәсе...

Бу көннәрдә Шамилләр дивизиясе икенче эшелонга күчеп шушы авылда байтак тордылар. Разведкачы егетләрнең байтагысы авыл кызлары белән танышып өлгерделәр, кичке уенга чыктылар.

Ләкин Зося белән Шамилнең дуслыгы тирәнрәк, кадерлерәк иде. Кыз, коткаручыларның берсе, иң тырышканы Шамил дип белгәнгә, җаны-тәне белән аңа тартыла иде. Күрешүләр, очрашулар никадәр татлы булса да, Зося аерылышу сәгатьләре якынаюын белә һәм шуны уйлап төннәр буе борчылып, бәргәләнеп ята иде. Бер кичне ул «татар егете»н бабасына күрсәтергә ниятләп өйләренә алып кайтты. Бабасы җимерек өйне такта кисәкләре белән ямаштырып, аннан каккалап, моннан суккалап җәй көннәрендә яшәрлек хәлгә китергән икән. Кызлы йорт таләп иткәнчә, шушы өй әләмәсен дә икегә бүлгәннәр. Ишектән кергәч тә уңда аш өстәле урнашкан, өстәлгә ишле-сыңарлы чәй чынаяклары, балчык чүлмәкләр тезеп куелган. Зося бер минуттан үз ягыннан әйләнеп чыкты. Хәзер аның өстендә юка күлмәк, күлмәк кызның нечкә билен, матур гәүдәсенең һәр ноктасын сызыклап кысып тора. Чәчен бердән үреп күкрәгенә салган, яланаяк, җитез атлап ары-бире йөргәндә тулы балтырлары Шамилнең күзен кисә, үзенә ияртеп китә. Кыз бөтен күңелен салып кунагына чәй әзерли. Бабай егеттән өзмәс сораштырып утыра, теле сүзгә зарыккан диярсең. Ара-тирә гәпкә Зося да катнашып ала.

— Сезнең Себердә аш-суны бүтәнчәрәк әзерли торганнардыр?

Кыз сораган сорау егетне җилкендерә, ул кыюланып:

— Сылу кызлар әзерләсә, сый кайда да тәмле була торгандыр ул! — дип җавап бирә. Җавап бабайга да, Зосяның әнкәсенә дә ошады ахрысы, бабай иелеп, өстәл астыннан чиреклe шешә тартып чыгарды. Дәү шешәнең бөкесен ачты, эчтәге сыеклыкны болгатып алды. Борынга ачы бал исе килеп бөркелде. Хатын-кызлар аны-моны китергәләгән арада Шамил белән бабай берәр тустаганны түнтәреп тә куйдылар.

Сугыш мәйданнарында, кан-яшь арасында йөзгән солдатның күңелле мизгелләре! Әче бал, тыныч өй, табындагы сый-хөрмәт Шамилнең күңелен шулкадәр нечкәртте ки, бабайдан, кызның әнкәсеннән читенсенсә дә ул күзләрен бәхете тулып ашкан Зосядан ала алмады. Нинди рәхәт!

Кызның әле унсигезе дә тулып җитмәгән икән. Бабасы да сокланып карый аңа, әнкәсе йомшак, иркә сүзләрен өзмәс әйткәләп табынны, очрашуны бизи. Кызның уңганлыгы күренеп тора, җитез, шәфкатьле. Әтиләре үлгән икән, Зося өч яшьтән бирле бабасы кул астында үскән. Ата да ул аңа, кадерле бабай да.

Ашап-эчеп алгач хуҗалар Шамилне кунарга калырга кыстадылар. Башта бик уңайсызланса да, як-ягына каранып башын кашыса да, яхшы кешеләрнең күңел җылылыгы үзенекен итте. Сугыш газапларыннан арынып тору, моңарчы татымаган рәхәтлек аны җиңде. Ул взводына Зосяны ияртеп барып килде, ике атна аларда фатирда торырга рөхсәт алды...

Взводташлары: «Новоиспеченный жених! Фәлән-төгән»,— дип, аннан көлеп, чеметкәләсәләр дә Шамилнең күңеле төшмәде, сүрелмәде.

Алар әйләнеп кайтканда йорт буш калган, бабай да, кызның әнкәсе дә каядыр чыгып киткәннәр иде. Кыз Шамилне җитәкләп үз бүлмәсенә алып керде. Бераз тын тартырга да базмыйча бер-берсенең учларын кысып, иркәләшеп утырып тордылар. Аннары Зося егетне кочып алды, иреннәре иреннәрне тапты. «Әнкәң кайтып керсә?» — дип сорады куркынып Шамил. Чая Зося бүлмәсен яңгыратып көлеп җибәрде. «Алар безне икәүдән-икәү генә калдырырга теләп чыгып киттеләр ич! Бу бит безнең кавышу төне!» — диде.

Куштан, әз генә чытлык, шук, наян Зосяны очратканчы ул гел Сәрвәр хатирәсе белән яшәде. Ятса-торса күз алдында гел Сәрвәр гәүдәләнде. Кайсыдыр спектакльдән отып калган җырын адым саен кабатлый иде: «Сәрвәрем, Сәрвәрем, мин сине сөям, һәр сәхәр вакытында төшемдә күрәм!»

Эх, Зося, Зося! Нишләттең син татар баласын? Танымаслык үзгәрде егет! Хәзер ул Сәрвәре исенә төшсә күзләрен каршысында балкып утырган кыздан алып читкә төбәлә. Монда Зося, читтәрәк Сәрвәре... Утыра торгач ике кыз бер шәүләгә әйләнә, бер кеше булып кына кала. Әйтерсең лә, алар берсен берсеннән аерып ала алмаслык игезәкләр! Ләкин мондый хәлдә озакка калып буламыни? Зося егетне чынбарлыкка тартып кайтара, елмаеп егетнең икеләнгән җанын эретә. Шулкадәр охшашлык, мөлаемлык булыр икән! Уяулы-йокылы төшеннән арыныр өчен Шамил чигәләрен уа... Ничә айлар сугышның кыргый кануннарына буйсынып, атып, үтереп, төннәрне көннәрдән аера алмаслык дәрәҗәгә җитеп миңгерәүләнгән егет, ниһаять, бәхетле оҗмах ишеген ачты. Рәхәт тә аңа, газаплы да. Уйлары кызларның берсеннән икенчесенә күчеп интектергәндә, аның эчендә нинди утлар дөрләгәнен сизгәндәй, Зося егетнең тезенә менеп утыра, муенына сарыла. Бабасы өйдә, әнкәсе керә-чыга йөри, һич читенсенми, шайтан кыз. Шамил югалып кала, кыенсына, йөзе чөгендердәй кызара.

Кызның һич читенсенмичә яшь егет белән аралашуына әнисе дә сүз әйтми, киресенчә, аларның дуслыгына куана гына бугай! Егет муенына сарылу да бу якларда гаепкә саналмый, күрәсең.

Ах, ул көннәр, ул көннәр! Төштәгедәй үттеләр дә киттеләр! Сугышның бар явызлыкларын оныттырып бәхет дәрьясында йөздергән кызга ничек рәхмәт укымыйсың да, аны ничекләр яратмыйсың? Бәхетле иде Шамил, шул ук вакытта нидер аның йөрәген сызлата, талый иде.

Шамил бүген взводы белән бергә кунды. Солдатлар походка әзерләнәләр, полк алгы сызыкка, дошманга якынгарак күчә. Һәр кеше юлга әзерләнә, оекбашлар, аякчулар юып киптерелә, гимнастерка якаларына ак тасмалар тегелә. Һәркем эч пошуын сиздермәс өчен шукланган була, кылана, алда торган сугышлардан куркуын эченә яшерергә тырыша.

Таң яралгач кына ул Зосяларга китте. Барса, бабай тәмле йокыда, ә Зосяның ишеге тартып ябылган. Зося янына үтим дисәң, бабайны уятырга кирәк. Ул баскыч тактасында бөкшәеп утырганда Зосяның кайнар

пышылдавын ишетте: «Поручик, кер бирегә!» Баксаң, ул йокысыз төн үткәреп егетен көтә икән. Йокы керәмени андый чакта?!

— Зосенька,— диде теле урыслаша башлаган татар егете Шамил,— мин китәм. Саубуллашырга кердем.

Егет кызның маңгаена сак кына кагылды.

— Шамильчик! — диде егетнең исемен ике телгә дә җайлап куштан кыз.— Ашыкма, чак кына сабыр ит, зинһар.

Кыз карават янында иелеп торган егетнең муенын кочып үзенә тартып алды. Гәүдәсе белән май булып сыланды. Ничә көннәр, ничә төннәр кыз назына сусаган таза, сәламәт егет, башын җуеп кыз кочагына — упкынга ташланды. Аның колагы төбендә кыз сандугач булып сайрады, былбыл булып талпынды.

— Шамилем! Мой Шамиль! Мин сине яратам. Зинһар, мине башсыз бер азгын кыз дип уйлама. Минем әле үз гомеремдә бер генә егет белән дә үбешкәнем юк иде. Син минем беренче мәхәббәтем. Синең белән мине Езус Мария кавыштырды. Югыйсә мин беткән идем, балчык астында калып үләсе идем. Мин синең өчен өр-яңадан тудым, синең хакка гына терелдем. Мин сине әллә кайчаннан белә идем ич, син төшләремә керә торган идең. Мин сине гомерем буе көттем, Шамилем. Менә син килдең, кабул итеп ал, мин — синеке.

Шамил сиздерер-сиздермәс кенә читкә тартылды.

— Зосенька, туган илемдә минем сөйгәнем бар, вәгъдәләшкән кызым бар!

— Булсын, булсын! Хәзер син минеке. Мин синеке, Шамил. Алла билгеләгән язмышыма мең ризамын. Мин сине сугыш беткәнче, алай гына түгел, гомерем буе көтәрмен. Коч мине, ал, үзеңнеке ит! Монда булмаса, теге дөньяда, һичшиксез, кавышырбыз. Балам булса, синең төсең итеп, иркәләп, назлап үстерермен.

Сафлыгын бүләк итте Зося, сөеклесен мәңге бергә яшәргә үз төбәгенә чакырды. «Тормышны бергә корырбыз, умарталар үрчетербез, кып-кызыл алмалар үстерербез»,— дип өзмәс тәкърарлады.

Алда ниләр көткәнен төптән уйлап бетермәсә дә Шамил бу мизгелләрдә аныңча уйлап, аныңча яши башлаган иде инде... Полк авылдан кузгалган чакта ап-ак күлмәк кигән, кызыл комач яулык бәйләгән Зося юл читенә чыгып баскан иде. Сафка баскан Шамиле яныннан үткәндә, тигез басарга тырышып, кыз да аңар иярде, бара-бара муеныннан көмеш чылбыр алып, аны Шамилнең муенына бәйләде. «Аллага тапшырдык!» — дип, егетнең битеннән үбеп алды. Элегрәк кыз янына барып сеңгән егеттән көлеп-шаяртып йөргән иптәшләре дә, яшьләр арасының уеннан узып, тирән бер эзгә керүенә ышандылар.

Кызның озын керфекләр каймалаган коңгыр күзләре егетне бик озакка кадәр озата барды, борылып карый-карый егетнең муены авыртып бетте. Кызыл комачы кызыл түшле кош булып талпынды. Егетнең йөрәге урталай ярылып бәргәләнде. Үзе йөзләгән иптәшләре белән сафта бара, үзе ялгыз калып Ялан якларына, Иртеш буйларына, кедр урманнары — косоклыкка кайтып килә. Газиз илкәе шунда ич аның! Мең газап белән үзен аякка бастырган әтисе, сөйкемле Сания апасы, нәзек куллары белән аның муенына сарылып озатып калган чыркылдык Фаягөл, күзләрен тутырып өмет белән аңа баккан, язмыш ничә кат рәнҗеткән Сәрвәр... Бу кадерле истәлекләрне берара кансыз офицер Кандалыев каплап китә... Уйлар күчә, уйлар аны өстери, ниһаять, бу тамаша күренешләр эреп югала, күз күременә сыйган офыкта яктырып, нурланып сөйкемле Зося гына кала...

Волхов фронтында ул монафыйк Айсетдинне күреп калды.

Һич уйламаганда очраштылар. Айсетдин полковник киеменнән иде. Шамилне очратуына сөенмәде, күзен як-якка йөгертеп, ике-өч сүз белән хәл-әхвәл белеште дә, маңгаен бәрә язып машинага кереп утырды һәм

китеп тә барды. Әгәр Шамил Айсетдиннең немецларга хезмәт итеп, Сания апасының үлемен якынайткан хыянәтче икәнен белсә... Очрашкан көнне немец разведкасының заданиесе белән безнең якка чыгып, совет гаскәрләре хакында белешмәләр җыеп йөрүен аңласа...

Юк шул, белми иде егет, белә дә алмый иде.

Зося белән оҗмахта яшәп ятканда ул Сәрвәрне генә түгел, өй эчендәгеләрне дә онытып торды, авылына хат язмады. Дөнья бүгенгә сылу Зося белән чикләнгән иде.

## 14

Гыйнвар азакларында, зәмһәрир салкын кичләрнең берсендә, урамтыкрыклар чекерәеп торган йолдызларның сыек-сүрән яктысы астында йокымсыраган Ялан авылын сискәндереп, урман ягыннан өч чаңгылы килеп керде. Берзаман алар бүленделәр, икесе Чырык Абдрахманның авыш капкасын ачып кереп күздән югалды, берсе, арадагы иң озыны таяклары белән этенә-этенә чаңгысын чыжлатып Ырсытдиннар турына барып җитеп туктады. Урамның ике ягында утырган агачлардан сыкы коеп җил исте. Озын кеше чыраен томалаган башлыкны ачты, колагын якасыннан чыгарып, тыңланып торды, алдына-артына караштырып иплә кенә капка келәсен күтәрде. Сәер юлаучыны сизепме кайдадыр эт һаулады, ләкин еракта иде эт тавышы, килүче бер мәлгә икеләнеп торды да, чаңгыларын кочаклап ишегалдына үтте. Ишегалды сукмаклары аңа шактый таныш иде ахрысы, кеше җәһәт атлап түр өйгә якынлашты, тәрәзәгә чиртте. Тын төндә мылтык аткан тавыш булып нәни чиртү тавышы бөтен өйне кузгатты.

Ишек ачылды, чаңгылыны көтәләр иде ахрысы, өйдә тавыш-гауга ишетелмәде.

Мәүлия бүген бик соң кайтып яткан иде. «Мөхлисә әби нык ук сырхап тора»,— дигәч, ул Миңнурыйга ияреп китте дә алар мунча ягып, житештереп, икесе ике яктан әбине кочып мунчага алып бардылар. Каен миннек белән аяк-кулларын кат-кат чабып, әбинең җаеннан гына торып кат-кат юындырдылар. Мөхлисә карчык: «И бәбкәләрем, нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр... Тик юкка тырышасыз, миңа озын гомер кирәкми инде. Яшәсе яшәлгән, биргәненә шөкер. Мин кар-бозлар китеп, җир ачылганын, җир җылынганын көтеп ятам... Дөньяда чакта да суыкны күп ашадым, инде анда да туң арасына кереп ятасым килми», дип яшь аралаш, әле инәлеп, әле шаяртккан булып күңелен бушатты. Әбине алып кайтып, кайнар чәй эчертеп, чиста җәймә түшәлгән урында йокларга яткыргач, Мәүлия белән Миңнурый үзләре мунчага киттеләр. Әби барында рәхәтләнеп сөйләшә алмаганнар иде, аулак калгач бер-берсенең зифа, бозылмаган нык гәүдәләренә карап сокландылар. Бер-берсенә мактау сүзләре яудырдылар. Миңнурыйның шалкан кебек ап-ак гәүдәсе сукыр лампа яктысында да аермачык күренгәч, Мәүлия соклануын яшереп тә тормады. «Күз тимәсен сиңа, багалмам,— диде ул.— Кем бәхетенә сине болай үстергәннәр икән?!» Миңнурый мунчаны тутырып кычкырып көлеп җибәрде дә моңсуланды. «Әй, җаным, безгә багышланган асыл егетләр сугыш кырыннан әйләнеп кайта аламы, юкмы... Тол кызлар булып утырып калмабызмы... Синең ичмасам Йосыфың бар!» — диде.

Озын чәчләрен юып, аруланып, кояш исе килеп торган эчке киемнәрен кигәч тә ашыкмадылар, мунча сәкесенә утырып әлләниләр сөйләшеп бетерделәр.

Мәүлия кайтып капкадан кергәч әнисе ягына күз ташлады, аның тәрәзәләре караңгы иде. Суык өйнең җылысын алган, Мәүлия юрган астына чумды да, агач куышындагы тиен баласы сыман йомарланып ятты. Мунча тән арганнарын алган, изрәткән иде, алай да тиз генә

йокыга китә алмады кыз. Миңнурыйның «Синең Йосыфың бар!» дигән сүзләре колагында яңгырап торды. Әйе, бар. Мәүлия аны ярата. Аны гына! Хәзер дә кыз йокысын куып егетнең якты шәүләсе якында гына тирбәлә. Менә ул Мәүлияне үзенә таба тарта, иелеп колагына иң кадерле, иң газиз сүзләрен әйтә... Мондый суык, дәһшәтле төннәрдә кайларда куып йөртәләр икән аның солдатын?

Урыны җылынса да, җаны җылынмады тупырдап торган сәламәт кызның. Шулай бәргәләнеп ятканда әнисе ягыннан пышылдап кына сөйләшкән өзек-өзек тавышлар ишетелде. Ике йорт арасында элегрәк ишек бар иде, нинди дер сәбәп белән хәзер аны такта белән кадаклаганнар. Йомабикә дә, Мәүлия дә ишекнең барлыгын да оныткан нар, такталарны каерып ыргытмаганнар иде.

Нинди тавыш булыр икән? Кем булыр? Кунак-мазар килеп төшкән дисәң... Мәүлия сикереп урыныннан купты: әллә Ташкәй кайтып төшкәнме? Качып кайтканмы? Урманнарда төрмәдән качып чыккан, армиядән качып йөрүче адәмнәр күп дип сөйлиләр ич! Кыз кубарылып, ябынган юрганын идәннән сөйрәп ике арадагы ябык ишеккә килде, барлык ишету сәләтен туплап колагын торгызды. Урысча сөйләшәләр икән, Ташкәй түгел бу, ят кеше.

— Тотсалармы... күз дә йоммыйлар: бөтенебезне тезеп аталар.

Карлыккан тамаклы ир тавышы.

Бусы әнисе...

— Тоттырма, дию ансат ла ул!.. Синнән ярдәм кирәк.

— Ни эшли алам ди мин?

— Кума суыкка, ике-өч көн яшереп тот.

— Ә кыз?.. Аның барлыгын онытма. Аннан бүтәннәр дә... Авыл ич бу! Һәркемнең капкасына тукталган эзләрне күреп, белеп торалар.

— Әгәр куасың икән... куасың икән! — дип кабатлады карлыккан тавыш.— Әгәр телең кычытып безнең хакта берәр сүз ычкындырасың икән... үзең дә беттең! Кызың да бетте.

— Кызыма кагылмагыз... Әйт анда, үзеңнекеләргә дим, кагылмасыннар! Ул минем карап торган бердәнбер юанычым. Бердәнбер! Соңгысы! Ә мине... Теләсәң нишләт! Үтмәс пычак белән тиремне тунап бетерсәң дә дәшмим...

Мәүлиянең йөрәге котырып типте, тыны кысылды, иңе белән ара ишекне каерып ташлап әнисе янына керәсе килде. Керергә дә әүвәл башлап теге явызның бугазына пычак салырга... Әткәсеннән калган сугым пычагы кайда ята соң әле?.. Мылтыгы чормада шикелле! Патроннары да бар! Хәтерли Мәүлия, хәзер шыпырт кына алып төшәргә дә күкрәгенә терәп...

Ай-яй, атарсың, үтерерсең, мәетен кая куярсың? Ни дип аңлатырсың? Әнисе хакында ни әйтмәсләр? Нинди сүзләр йөрмәс?.. Болай да яман телләр, кыз яшьрәк чакта, Йомабикә турында тозлы-борычлы сүзләрне ычкындыралар иде. Аллам сакласын! Әнисе хакында гайбәтләрне һич чыгарырга ярамый. Мәүлия — мөгаллимә! Укытучы әнкәсе гайбәтләрдән ерак торырга тиеш лабаса!.. Димәк, әнисе янындагы явызны килмәслек кенә итәргә кирәк!.. Каян килеп кергән!.. Ә-ә, беркөн Сәрвәр: «Чырык күзен тозландырып сездә утыра», — дигән иде, мөгаен, шул сасы күзән ияртеп килгәндер әле монысын...

Тавышлар сүнде. Мәүлия туңып бозга әйләнгән аякларын җылыта алмыйча озак кына иза чикте. Өй эчендәге һәм күңеле тирәнлегендәге бозлар белән сугыша-сугыша таңны аттырды. Таң алдыннан капка шыгырдаган тавыш ишетелде...

Төне буе керфек какмаган кыз түшәктән тәмам миңгерәүләнеп торды, бакса, шул чатнама суыкта күлмәкчән генә мәктәбенә китеп бара икән. Борылып кереп бишмәтен киде, шешенгән күз кабакларын көзгедә күреп туктап калды. Әнкәсе янына керергәме, юкмы?.. Хәзер шул кискен сорау

боргычлый иде кызны. Кермәскә булды, мәктәпкә барып әзрәк тынычлансын, уйласын, ни әйтсәң дә Мәүлиянең кадерле әнкәсе ич ул!Мәктәп ыгы-зыгылары да төнге вакыйганы оныттыра алмады, утырып та тормады Мәүлия, ары чапты, бире йөгерде.

Мәктәп әлләни ерак булмаса да, Мәүлия өенә бик озак кайтты, ботактан ботакка тын гына сикерешкән ач чыпчыкларны тамаша итеп торды, кесә төбеннән бер-ике бөртек валчык ипи табып алып аны җиргә сипте. Ниһаять, кайтып җитеп әнисе ягының ишеген ачты. Әнисе кер уып маташа иде.

— Әнкәй, бәгырем, төнлә бездә кем булды? — дип сорады кыз калтыранган ят тавыш белән. Йомабикә агарынып китеп, каушады, лып итеп, сыгып куйган керләре өстенә утырды.

— Кызым, кызым! Син сорама, мин әйтмим,— диде ул көч-хәл белән.

Кызы авызыннан сүз түгел, ә бөтен тәнне ялмап ала торган ут өермәсе ургылып чыккандай булып тоелды Йомабикәгә. Аның бөтен тәнен очлы авызлы кырмыскалар сырып алды. Ире Ырсытдиннең теге чакта кырмыска түмгәгенә утыртудан да хәтәррәк булды бу юлы. Оят та, куркыныч та иде аңа. Әллә йөгереп чыгып кое авызына ташланыргамы? Ул хәлсезләнгән куллары белән кызын күкрәгенә кысты. Аналы-кызлы озак елашты алар, тәмам эчләре бушаганчы үкседеләр. Йомабикә кызының күпереп торган йомшак сары чәчләреннән сыйпады. Ниһаять, актык көчен җыеп кызының сорау тулган күзләренә карады.

— Кызым, йөрәк маем, кичер... Туры гына яши алмадым мин. Бер бәла-казадан котылдым дисәм, икенчесенә барып төштем. Белгәнеңне беркемгә дә әйтә күрмә! Бутадылар минем башымны, кайгыга батырдылар. Аннан ансат кына котылмак юк! Үзем өчен түгел, миңа ни... Кар яуса ни дә, боз яуса ни! Һичбер яклаучыбыз юк бит! Ташкәем өйдә булса, әллә шул явызларны куып таратмас идеме?! Йөрәгем сизә, моның азагы яхшылык белән бетмәстер. Әткәң мәрхүмнән мең кат усалрак ул бәндә! Мин аннан котылу юлын һич тапмыйм. Мине куркыта «алай-болай кылансаң, кызың бетте!» дип кенә тора. «Үтерәбез», дип яный...

Моңарчы Мәүлиянең башы бүрек эчендә булган икән. Нинди куркыныч бәла сагалый икән аны! Кызы язмышы өчен куркып әнкәсе кара кайгыга кереп баткан. Дошманнардан берәвесе әнисенең тәнен, җанын пычрата: «Чебен агуы эчертеп әллә җанын алыйммы?» дип тә карадым, йөрәгем җитмәде! дип кабатлады әнкәсе. «Үтерерсең, ә урманда аның иптәшләре! Хәзер эзеңә басып килерләр...»

Бу фани дөнья белән иң соңгы бәйләнешы булган Мәүлия өчен Йомабикә тау-таш җимерергә, дөньясының астын-өскә әйләндерергә әзер иде...

— Үтерәм мин аны, яшәтмим җир йөзендә,— диде ана, сүзенә ачык йомгак ясап. Мәүлиянең күзе алдыннан берсеннән-берсе куркынычрак күренешләр тезелеп узды.

— Юк, юк, әнкәем, алай ярамас. Алай булмый. Мин бер-бер чарасын үзем эзләп карармын!

— Берүк кызым, саклан. Төнгә калма, йөрәк маем! Кешегә авызың ачасы булма, кабып кына йотарлар,— дип кат-кат ялварды әнкәсе.

Мәктәпкә җыелган балалар төрле хәбәрләр алып килгәннәр иде. Колхоз фермасына бүреләр кергән, күсеәләр бер сыерның җиленен кимергән, чатан Хәйбулланың ике сарыгын алып чыгып киткәннәр. «Берсе буаз иде гүй, бәрәннәр чагы җиткән иде лә! Ел саен ике бәрән китерә торган ак сарыгым иде»,— дип, идәнне тырнап, ята-ята җылый ди. Хәйбулланың күзенә ак төшкән бичәсе: «Ишеттем, шикле тавышлар ишеттем... Нишлисе соң, ирем аксак-туксак, үзем сукыр-букыр, Ходаның каһәре суксын!» ди икән.

Мунча шифасы атнадан да артмады, Мөхлисә әби тәмам өзлекте. Кичтән аркасын мендәргә терәп утырган хәлдә бер-ике сәгать черем итеп

ала да төннәр буе йокламый. Кышкы суыктан бүрәнә шартлап ярылса да коты оча, песи мич башыннан сикереп төшеп Фаягөлнең куенына йөгереп кереп китсә дә йөрәге дерт итмичә калмый. Һәрбер кылт-шылтка йөрәге кубып, ят бер хәбәр, күңелсезлек көтеп ята. Ярты сынын сөйрәп тимер мич янына барып җитә, җылыны өзмәс өчен бер-ике чыбык ташлап куя. Әле ярый, шөкер, кияве Мөхәммәт утынны, вак-төяк булса да хәстәрләп киткән иде. Утын кимегәнне күреп хәвефләнә башлаган карчыкны юатыр өчен үткән якшәмбедә, ял көнне, Миңнурый белән Мәүлия урәчәле чәнәшкәгә җигелеп урманга барып, түбәләм итеп өеп каен ботаклары алып кайттылар. Мәүлиянең куян эзләрен кисеп-кисеп үткән чаңгы эзләренә ниндидер хәсрәт белән карап торганын күргәч, Миңнурый түзмәде, сорап алды:

— Ни булды сиңа, дустым, соңгы араларда нигәдер бик моңаеп йөрисең? — диде.

— Белмисез шул хәлләремне! — диде Мәүлия, кайгысын эченә йотып. Мул гына утын кайтканын күргәч Мөхлисә әби куангандай булды, елмайды. Тонык яктыда җәйрәп йоклап яткан Фаягөлнең юрганын кымтыды, хәзер нәбәрәсе аның күңел баглаган бердәнбер куанычы! Карчык тонык күзләре ачык чакта Фаягөл өйдә булса, гел аңа карап кына утыра. Керфекләре, чәче, бите — сылап куйган әнисенеке! Киң маңгай, йомыры борын, кысыграк күзләр — әтисенеке... Мәүлия белән Фаягөл арасында да охшашлыклар бар, аларын күрмәскә тырыша Мөхлисә әби.

Мөхлисә карчык үзенең соңгы көннәре җиткәнен чамалый, ул яз җитүен, җирнең җылынуын гына көтә. Фаягөлнең чит кеше кулында калуыннан курка, шуны уйлап Ходасына ялвара: «Ходаем, йөрәк маемны ятимә итмә, әткә-әнкәсе белән кавыштыр!» Киявен телгә алганда: «Сугышып йөрер чагы узган, Ходаның рәхмәте төшеп, кайтарып та җибәрерләр әле», — дип өметләнә.

Беркөн йокысыннан җиңеләеп, тән авыртуларын онытып уянды Мөхлисә карчык. Миңнурый белән Фаягөл торганчы бәрәңге пешереп өлгертте, урындыгында янтаеп кына иртәнге намазын укыды. Намазын тәмамлап, бүгенге тән җиңеллегеннән куанып, Миңнурый белән Фаягөлне уятырга дигәндә, иртәнчәк, таң алдыннан күргән төше исенә төшеп уйга калды. Әллә тау арасында йөри, ниндидер тарлавыкларда, әллә кызлар убасының өстенә үк менгән, кайдадыр, шул тирәдә генә кызы Сания дә бар икән, имеш. Бер югала Сания, бер күренә, күренгән саен кулын изи һәм: «Әнкәй, кил монда, кил. Монда рәхәт!» — дип кычкыра икән... Гадәттә, күргән төшләрен юраштыра торган иде Мөхлисә, бу төшен юрамады... Миңнурый белән Фаягөл уяндылар, бер-берсен шаярып үчекләп юындылар, иплә кенә бәрәңгене сыптырып куйдылар. Чыгарга җыенып киенделәр. Шулчак Мөхлисә әби утырган урыныннан калкынып аягын сөйрәп ишек катына килде һәм Фаягөл кызының, кадерле нәбәрәсенең, яулык бөркәнгән маңгаен ачып кат-кат үпте.

Алар китте, өй ашыгып яктырды, «Яз килә, яз җитә, җирләр җылынып!» — дип уйлады Мөхлисә карчык һәм түшәмгә карап уйсыз гына ятып торды. Төш алдыннан чәй җылытып алыйм дип көл таучыгын аударса, ни күрсен, учакта утлы күмер калмаган... Юк, утның очкыны да калмаган, алай гынамы, көле дә суына башлаган кечеучакның...

Чәй эчәсе килүе дә онытылды, иртәнге җиңеллек «ә» дигәндә юкка чыкты, иңнәрен нидер басты, күз аллары караңгыланды. Бер минутка гына, төшенә кергән Саниясенең шәүләсе күренгәндәй булды, ул баягы кебек итеп, кул изәп әнкәсен чакыра икән... «Саниям чыннан да дөнья куйган икән, үз янына мине дәшә!» — дип уйлады карчык. Ул тирәнгә, упкынга убылып төшеп китте...

Әнә шул көннән Фаягөл караучысыз ятим калды. Әгәр янында Миңнурый апасы да булмаса?..

Мәүлия моңарчы Фаягөлнең язмышыннан читтәрәк булды. Ул бу хакта баш ватып, уйлап та карамады, әткәләре бер, әнкәләре генә башка икәнен, Мөхлисә әби вафатыннан соң гына ныгытып уйлый башлады. Авылда ятимә кызның иң якын кешесе булып ул кала түгелме?

Ялан авылының сөекле бер кешесе Мөхлисә әбине җир куенына иңдерер өчен ике көн кабер казыдылар, ләхет алдылар. Мөселман йолаларын җиренә җиткерергә тырышып калдык-постык ир-ат, үсмер яшьләр җыелды, өтек гәүдәсенә тантаналы кыяфәт бирергә тырышып, ике сүзенең берендә тамак кырып, Чырык Абдрахман дога укыды...

Мәет чыккан моңсу өйдә Миңнурый белән Мәүлия, җылый-җылый күзләре кызарган Фаягөлне уртага алып, ни сөйләшергә, ни кылырга аптырабрак утырганда өйгә Гыйззәтбану түти килеп керде һәм кызны үзе белән алып китәргә нияте барлыгын әйтте...

— Тәкъдирдә шулай язгандыр, Уразай мөгаллимнән күргән изгелекләрне җепкә тезеп санап кына чыгарлык та түгел. Син, Миңнурый балам, уңган, житез бала күренәсең, мәгәр эшең муеннан. Таңнан торып чабасың бар, мәктәп мичләренә чиратлап ягасыз... Әйтер сүзем шул, ниятем нык, Фаягөлне үзебезгә алып китәм. Өйдә, янымда торсын. Күземә юаныч, күңелемә куаныч булыр.

Кызлар аяк терәп аңа каршы килделәр, Фаягөлнең үзен-үзе карарлык дәрәҗәдә зур булуын, кул арасына кирәрлек өлгер булуын әйттеләр. Һичкем уйламаганда, көтмәгәндә Мәүлия болай дип әйтеп салды.

— Миңнурый ахирәтем! Без әни белән икебез ике өйдә утын ягып, керосин әрәм итеп ятабыз. Синең миңа, минем сиңа килми калганыбыз юк. Дәресләрне бергә әзерлибез. Тотам да мин сезгә күчеп киләм! Минем әни ялгыз торып күнеккән, ахыр чиктә аны да ташламабыз,— диде.

Гыйззәтбану түти дә, Миңнурый да аптырап калдылар, мәсьәләнең кай якка борылганын төшенгән зирәк бала Фаягөл Мәүлия апасын кочаклап алды, сөенеп кычкырып җибәрде.

Мәүлия әнисе тирәсенә елышкан шикле бәндәләрне күргәннән бирле йорттан чыгып китү турында баш вата иде. Әллә Тубыл-Төмән якларына күчеп китим микән, сугыш заманы, кайда да эш бетмәгән дип уйлап куйган чаклары да бар иде. Хәзер мәсьәлә гади генә, җайлы гына хәл ителде, кичкә әйбер-караларын ул кул тәртнәсенә төяп Мөхәммәт Уразаевлар йортына күчеп тә килде. Миңнурый белән ул кичне сөйләшмәгән сүзләре калмады, озакка сузмаска, Миңнурыйның сыерын монда алып кайтырга дип тә килештеләр...

## 15

Яңа елга атна кала дигәндә, кызлар үзара сүз беркетеп куйганнар иде инде: Мәүлия белән Сәрвәр торага барып белешәләр дә Ташкәйне эзләп табалар, аннары Тубылга кадәр бергә барган Миңнурый Ростошка кадәр үзе генә бара да, сыерын ияртеп кайта. Кем алданрак кайтып элгәшсә дә, кызлар торада бер-берен көтеп алырга тиешләр. Ни булса да беркем дә Ялан юлына ялгыз чыкмый. Бигрәк тә сыерлы Миңнурыйның бер башын юлга чыгарып җибәрергә ярамый иде. Йозакларны ватып, нык-нык абзарлардан мал-туарны урлап чыгып алган угрылар, сыер җитәкләгән сылу кызны юлда, аулакта очратсалар ни кылмаслар. Мәүлия: «Безнең әткәйдән калган мылтык та булырга тиеш»,— дип әтәчләнеп Йомабикәнең өй түбәсенә, чормага менеп актарынса да мылтыкны да элек күзгә күренгәләгән дары, патроннарны да тапмады. Әнкәсеннән сорашмады, соңгы көннәрдә сирәк-сирәк кенә күрешкәләгән очракларда да Мәүлия әнкәсенә сораулар бирми, аны юк-бар белән аптыратмый иде...

Миңнурый Уразаевның чолан почмагына яшереп куйган мылтыгын алай да алырга булды. «Коралланган өч батыр кызга бер мылтык артык булмас!» — диде.

Фаягөлне мәрхәмәтле Гыйззәтбану түтигә тапшырып, тәгәрәткән бәрәңге белән хәстәрләнгән капчыкларын күкрәкләренә кысып, таяклар белән дә коралланып, дөм караңгыда, йолдызлар яктысына гына ышанып юлга чыктылар. Гәүдәләре шулай җиңел булгандыр инде, кар да шыгырдамады, суыктан куркып авыз ачып сөйләшмәделәр дә, этләр дә һаулап аларны озатмады, урамны тиз-тиз уздылар. Кырда җил әрсезрәк исә икән, алай да күк чалт аяз, ак ялларын болгап җәяүле буран гына алар артыннан чаба. «Җил арттан!» дип сөенештеләр кызлар. Тар юлдан өчәү рәттән сыймыйча әле берсе, әле икенчесе алга чыгып шактый ара бардылар. Ялкау таң, ниһаять, атты, уңда-сулда басу сакчылары — сыкылы ялгыз агачлар калды. Кар ныграк салган үзәннәрне кичеп, чокырларга төшеп батып бара-бара, кызларны бер атлы куып җитте. Кызлар юлның ике ягына тартылып, тездән карга батып, юлаучыны үткәреп җибәрәбез дигәндә, ат алар арасына килеп кергәч тукталды. Чуклы шлеялар, әле күненең каралыгы китмәгән дуга-ыңгырчаклар, тасма дилбегәсенә карап та, чанага чумып утырган, югары калкынган толып якасы эченнән борыны гына күренеп торган кешенең андый-мондый гына түгел, кәттә бер начальник икәнен аңлап була иде. Менә юлаучы толып якаларын ике якка кайтарып ташлады, эчтән шактый яшь, тукмак борынлы, нык иякле бер ир килеп чыкты.

— Чабасыз, чабасыз, артыгыздан җитеп булмый,— диде ир, кашаваеннан төшә-төшә.

— Барып җитәсе җирләребез ерак,— диде Миңнурый, кызларның иң чаясы.

— Кая кадәр инде алай, белергә яраса? — дип кызыксынды ир.

— Еракка,— диде Миңнурый һәм нидәндер шигәеп Мәүлия белән Сәрвәр ягына чыкты. Ул юлның уң ягында берүзе калган иде.

— Кай яктан киләсез? — дип сорады ир, кызларның шиген көчәйтеп.

— Ялан авылыннан без,— диде, һичбер вакыт алдашырга яратмаган Мәүлия.— Тубылга барып ятабыз.

Ир чөмгереп атын кузгатты да үзе кызлар янына басып чана артыннан җәяүләп атлады. Сөйләшмәделәр, ирнең кызларны танырга теләгәндәй, үткер карашын берсеннән икенчесенә күчерә-күчерә баруы гына аның юлчы кызлар белән кызыксынуын раслый иде. Менә ул дилбегәсен тартып атына эндәште, туктатты һәм барыр юлга артын куеп кузлага менеп утырды, бушап калган чанасына кызларга утырырга кушты.

— Утырыгыз, утыр. Байтак юл үткәнсез, барыр җирегез дә якын түгел. Өчәү сыясызмы?.. Сыясыз, сыясыз! Хәзер илдә юан адәмнәр калмады.

Мәүлия белән Сәрвәр читенсенеп торалар иде, чанага беренче булып Миңнурый менеп утырды, бүтәннәр дә аңа иярде. Бер-берсенә терәлеп утыруга ук рәхәт булып китте. Юлаучы дилбегәне Миңнурыйга тоттырды.

— Юлны сез карап барасыз, алай-болай салулап чәчелеп төшеп калмыйк,— диде ул. Баралар, кузлада утырган ир һаман кызларга карап ала, күзләр белән күзләр очрашканда да читенсенми, бара-бара сүз чыгып, танышып та беттеләр. Ир әлерәк кенә Тубыл НКВДсына эшкә билгеләнгән Казан татары Ишморза исемле капитан икән. Фамилиясен әйтмәде.

НКВД дигәндә колаклары үрә торучы кызлар, башта тартынып утырсалар да бара-бара Ишморза капитанны үз иттеләр, төрле яктан сораулар яудырдылар. Ишморза сорауларга туры, төгәл җавап бирергә тырышты. Чеметтереп-чеметтереп кенә булса да үзе дә сораулар биргәләде.

Ярты сәгать чамасы тигез юлда юртып, үр менгәннәрдә һич ашыкмыйча атлатып бардылар, ә сүз, әңгәмә гел бер тигезлектә акты. Ишморза ике кызның Ташкәйне эзләп баруларын да, Миңнурыйның «Җәмилә әбисенә кунакка кайтуын да» белеп бетерде. Баштарак аны Миңнурый кызыксындырган иде. Шактый ара җәяү килеп битләре бурлаттай кызарган, бу кызыллыкта кап-кара каш-керфекләренең аерата чибәрләнеп китүе, кызның җитдилеге, үз бәясен яхшы белүе, сүзләрне үлчәп кенә чыгаруы егеттә әле исеме ачыкланмаган кызыксыну уяткан иде инде. Әйтергә кирәк, Ишморза өйләнмәгән егет иде әле...

Сәрвәр белән Мәүлиянең моннан өч ел элек кеше үтереп төрмәгә кергән егетне эзләп баруларын ишеткәч, Ишморзаның бөтен игътибары аларга күчте. Мәүлия Ташкәйнең туганы икән, ә Сәрвәргә кем була ул егет?.. Сорашты Ишморза, Миңнурыйның очкын күзләрен онытып торып, шактый сораулар яудырды.

Кызлар «кичке караңгыга торага барып җитсәк» дип хыялланганнар иде, НКВДның тук аты аларны күз бәйләнгәнче үк китереп җиткерде. Кызлар бер танышларына кереп кунарга җыеналар иде. Ишморза Миңнурый белән кул биреп күрешкәндә дә, исем-фамилиясен сорашты: «Мин сезне эзләп табармын әле!» — дип, кызның кая, кемнәргә баруын куен дәфтәренә язып алды.

Аптырап юл читендә басып торган Сәрвәр белән Мәүлияне ашыктырып чана түренә утыртты да, атын юрттырып-каулап НКВДга алып китте.

Ишморза — биргән вәгъдәләрен үти торган сүзле, эшлекле вә ышанычлы татар иде. Ике еллык юридик мәктәпне тәмамлагач та фронтка алынды, шунда каты яраланып (дошман минасының ярчыгы аның үпкәсен чәрдәкләп үткән иде), алты ай чамасы госпитальдә ятканнан соң аны Төмән өлкәсенә эшкә җибәрделәр. «Себер урманнарында шактый күп санда дезертирлар, сугыштан качып ятучы хыянәтчеләр ята. Алар үз тирәләренә угрыларны, каракларны да туплыйлар. Авылларга налет оештыралар, милиция хезмәткәрләрен үтереп коралларын алалар. Кыш айларында алар ерак авылларга, сазлык эченә утырган йортларга сеңеп, яшеренеп яталар да, язын, кар китеп юллар төшкәч элеккеге өннәренә, урман ешлыкларына җыелып тагын явызлык арты явызлык кылырга тотыналар», — диделәр. Аны Тубыл районына беркеттеләр. Хәзер ул Н. авылыннан, яшерен агент хәбәр иткән «адрес»ларны тикшереп кайтып килә иде. Юл буе аны бер уй борчыды: карурманга тупланган явызлар арасына кемне дә булса җитез берәүне, совет властена аерата мөһим хезмәт күрсәтерлек кешене сеңдерергә кирәк иде. Шуннан башка иксезчиксез карурманнарга, сазлык-баткаклыклар, күлләр арасына качып яшәгән, тәҗрибә туплаган, хәйләкәр һәм явыз дошманнарны район НКВДсындагы җиде-сигез милиционер белән генә аулау да, тозакка төшерү дә мөмкин түгел иде.

Кызларның юлда очрауларын ул яхшыга юрады, арадан берсенең, Миңнурыйның сылулыгы аны таң калдырды, аның белән ялгыз калып сөйләшәсе, аңлашасы, дөньяның чуалчык хәлләрен онытып торасы килә иде. Әле кызлар белән мавыгырлык вакыт түгеллеген дә белә Ишморза. Җаваплы, авыр чор иде. Хәзер кыш, апрель-майларда ил талаучылар тагын урманнарда тупланачак. Быел, Ишморза дигән татар егете эшли башлаган язда, аларны әзерлекле, акыллы вә хәйләле план белән каршылыйсы иде. Ишморзаның моңарчы башлаган эшен азагынача җиткермичә туктаганы юк иде.

Әйткәнемчә, Сәрвәр белән Мәүлия кыйссасын тыңлагач, егет күңеле бөтен яккарак борылып китте, ул арыган, шактый йончыган булса да, кызларны иярттеп НКВДга кайтты. Ташкәйнең архивтагы эшен эзләтеп алды, егетнең сигез елга хөкем ителеп, Тубылдан утыз чакрым ераклыктагы биш йөз кешелек зонадаябылуда ятуын белеште.

Ташкәйнең утыз чакрымда булуын башта кызлар куркып тыңлаганнар иде, аннары, бер-берсен дәртләндерә торгач күңелләре күтәрелде: «Барабыз да кайтабыз, йөргән аякка ерак мени ул утыз чакрым!» — дип, таңнан кузгалырга булдылар.

Ишморзаның атын тугарып та тормаганнар иде, ул кызларны алдан килешенгән фатирга хәтле озата барды. Сәрвәр белән Мәүлияне өйгә кертеп куйгач, күз ымы белән генә Миңнурыйны оялдына дәшеп чыгарды һәм үзенең кыз белән алда да очрашырга теләге барлыгын белдерде һәм кыздан шуңа рөхсәт сорады. Миңнурый аптырап китте, нинди чая, кыю булса да бер мәлгә югалып калды, исенә килеп курка-курка гына Ишморзага, көндез очрашканнан бирле үзен борчып торган соравын бирде: «Сезнең белән Сидоренко дигән кеше эшләмиме?»

Ишморзаның коңгырт күзләре ныграк ачылды, кашлары югары күтәрелде: «Каян беләсез сез аны?»

— Белмәсәм яхшырак буласы иде дә...

— «Сыңар кул, сыңар булса да тимер кул!» дип йөрткәннәр икән аны,— диде Ишморза тынычланып.— Юк, ул мин килгәндә үк юк иде. Якын-тирәдә тагын бер лагерь-зона ачканнар да «тимер кул»ны шунда начальник итеп билгеләгәннәр.

— Рәхмәт,— диде кыз һәм Ишморзаның кулын учына алып кыскаьын сизми дә калды. Тагын очрашырга килешенеп саубуллаштылар.

Ишморзаның биргән сорауларын тезеп искә төшергәч, кызлар уртак бер фикергә килделәр: «Егет аларның язмышына битараф түгел, аерата ул Миңнурый белән кызыксынды»,— дигән нәтиҗә ясадылар. Мәүлия белән Сәрвәр кулларын чәбәкләп: «Сине ошатты ул, сине!» — дип ярым үчекләп, ярым сөенеп кызны йомшак кына үртәделәр. «Юк,— диде Миңнурый, ахирәтенә каршы төшеп,— НКВДда эшләмәсә бер хәл иде. КНВД дигәнне ишетүгә каным кайный минем... Күпме җәбер-җәфа китерделәр алар безнең нәселгә!»

Төнне әңгәмәләр, бәхәсләр белән кыскарттылар. Йокыларыннан торып, бит-кулларын юып, әз-мәз чәйләп кенә өлгергәннәр иде, ишектән айдай балкып Ишморза килеп керде. Миңнурый янына дип уйласалар, егетнең планнары бөтенләй бүтәнчә икән.

— Мин хуҗа белән сөйләштем, ул Ташкәй утырган лагерь начальнигына хат язды. Мин сезне зонага кадәр озатып та куям,— диде. Ат җигеп килгән егетне ничек елмаеп каршыламыйсың ди инде?

Миңнурый бер башы гына җәяүләп чыгып китте дә юл буе бер табышмакка җавап эзләде. Миңнурый белән очрашырга сүз куешкан Ишморза нигә дип әле Мәүлия белән Сәрвәргә ияреп китте!? Ни йомышы бар капитанның аларда? Әгәр күңеле Миңнурыйда икән, ул аны Җәмилә әбиләренә хәтле озатып куя ала иде ич?.. Бу җавапсыз калган табышмак, ахыр чиктә, аның ачуын чыгарды һәм ул: «Милициядән яхшы гамәл көтеп буламыни?.. Әгәр эзләп нитеп килсә, куам да чыгарам мин аны, тоз күзне!» — дип, кат-кат кабатлап уен беркетте.

Егетнең күзләре бер дә тозга охшамаган иде югыйсә, матур, акыллы иде милиция капитанының күзләре...

Кичәге ат, кичәге чана, аерма тик шунда гына — алар кашавай түренә кысылышып өчәү утырдылар. Ишморза сулда, уртада Мәүлия, аңа Сәрвәр терәлде. Ишморза кызларга бер толып тоттырды.

Кызларны гаҗәпләндергән капитан юл буе Ташкәй хакында сорашып барды, аның Ялан авылын ураган урманнарны, чокыр-чакырларны, аккөннәрен, сазлы күлләрне ничегрәк белүе хакында кайта-кайта сораулар бирде.

— Әллә сез дә Күчем ханның хәзинәсен эзләргә җыенасызмы? — дип сорады Сәрвәр...

— Тагын кем эзли хәзинәне? — дип шундук эләктереп алды Ишморза.

— Сөйлиләр бит...

— Кем сөйли? Кайда? Кемнәргә сөйли? — Ишморза сорауларны туп-туры куярга ярата иде, кызларны җайсыз хәлгә куюын чамалап, ул сүзне бүтән якларга борып җибәрде, юл урманны ерып үр төшә иде. Ике якта да иңнәренә авыр-авыр кар ястыклар аскан кедрлар озатып калды, шушы тынлыкта, агач араларындагы зәңгәрсу бушлыкта ниндидер серләр бар төсле тоела иде.

— Себер урманнарында шушы кадәр тантаналы матурлык бардыр дип бер чакта да уйлаганым юк иде, — диде Ишморза һәм тагын кызларны гаҗәпләндерде. Әле генә авыр-авыр сораулар биреп барган кеше матурлыкны күреп, аңа бәя биреп тә өлгерер икән...

НКВД капитанының сораулары бетмәгән икән әле, әңгәмә сиздермичә генә тагын Ташкәйгә әйләнеп кайтты. Кышларын чаңгыда йөргәнме егет, ауга чыкканмы, тәвәккәллиме, егәре күпме, Сабан туйларында көрәшә идеме, сугыш чукмары идеме? Мәүлиянең җаваплары кыска-кыска һәм өзек-өзек булса, бара-бара Сәрвәрнең теле ачылып китте. Беравык хәтта аңлашылмый да башлады: үзе өчен сөйлиме ул сүзләрен, әллә Ишморзага ниндидер яңалыклар табарга тырышып барамы, чөнки кыз Ташкәй башкисәрне тоташтан мактый иде.

Урман кисә икән Ялан авылының ачы язмышлы егете Ташкәй, Ырсытдин белән Йомабикәнең игелексез улы, кызларның моңарчы да тимер чыбык киртәләр белән тыгыз чолганган зоналарны күргәннәре бар иде, әллә мәгәр, ат куркыныч бер капка төбенә барып туктагач, зонага куркып, шикләнеп карадылар. Монда Ташкәй утыра.

Ник килде монда Сәрвәр? Бу адымы аның олыгаюы, җитдиләнүе идеме, әллә япа-ялгыз калып типкән кайнар йөрәгенең уянуы, бүтәннәрдән дә җылылык эзләве идеме?.. Менә очрашырлар, күрешерләр, ни әйтер ул Ташкәйгә, килүен ничек дип аңлатыр?..

Кар көртләре тәрәзәләрне сарып томалаган, тәбәнәк бараклар арасыннан салынган сукмакларда берән-сәрән кешеләр күренгәли, килүчеләрнең бәхетләре, бүген Ташкәйнең ял итү көне икән. Килүчеләр белән зекларны очраштыру кагыйдәгә сыймаса да, Ишморза сөйләшеп чыккач, егетне кызлар белән очраштырдылар. ППЧ начальнигы Крутиков күрешү өчен хәтта үз бүлмәсен биреп тә торды.

Мәүлия белән Сәрвәрне күргәч, Ташкәй нишләргә белмәде, сөйләргә теләде — сүзен таба алмады, сер бирмәскә, егетләнергә маташты — ике күзеннән дә яшь сытылып чыкты... Егет олыгайган, җилкәләре киңәйгән, куллары өрәңге тамыры, бармаклары — корыч, ә күзләрендә яшь.

Баштарак Ишморзадан тартынып утырганнар иде, ул Ташкәйгә карап, тын гына бераз утырды да Крутиков янына кереп китте, кызлар авылдашлары белән генә калдылар. Кызлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә авыл, йорт-җир хәлләрен сөйләп бирделәр. Сүз күбрәк авылдан киткәннәр, кайтканнар, югалганнар һәм үлү хәбәрләре килгәннәр турында бара иде. Әңгәмә уртасында Ташкәй ике тезенә кулы белән сукты да: «Ә Шамил? Хатлары киләме?» — дип сорап куйды. Мәүлия уңайсызланды, Сәрвәр кызарды. «Юк, — диде Сәрвәр, — байтактан хаты юк аның да... Язмый. Элегрәк килгәли иде, хәзер юк». Бу җавап тоташ билгесезлекләргә төренгән булса да Ташкәйнең йөзеннән ниндидер сәер яктылык йөгереп үткәндәй булды, ул сылу Сәрвәрнең күзләренә туп-туры карап алды. Мөхәммәт Уразаевның каты яраланып госпитальдә ятуын ишеткәч, егет моңсуланып та алды. Сүз арасында кызлар төенчекләрен чишеп, алып килгән күчтәнәчләрен суздылар, әз-мәз төче күмәч, сохариларны күргәч Ташкәй күмәч кисәкләрен алып шунда ук ашый да башлады, җилдә киселеп, имән кайрысына әйләнгән яңаклары туктала алмыйча селкенеп торды.

Димәк, Ташкәйнең күптәннән туя алганы юк!

Мәүлия: «Әллә кайчан килергә кирәк булган», дип уйлады, Сәрвәр дә үз алдына: «Үзгәргән Ташкәй, бөтенләй бүтән кеше булган», дип уйлады

да,— «Әллә үзем үзгәрдемме? Минем хакка ул монда ята ич! Минем исемемне даулап үтерде Үлмәсне!» Бу уйның элегрәк тә башына килмәвенә гаҗәпләнеп утырды-утырды да, аерылышканда ике кулы белән Ташкәйнең нык муенын кочып, күкрәгенә кысты һәм яңагыннан үбеп алды.

Зона хуҗалары яныннан Ишморза килеп чыкты, алар элеккечә кашавай түренә кысылышып утырдылар. Озын юл, урман-кырлар аларны моңсу гына каршылап, моңсу гына озатып барды.

Атна үтте, ун көн, һич уйламаганда-көтмәгәндә Ташкәйне Тубыл төрмәсенә күчерделәр. Егет бу хәлнең теге капитаннан килүенә бәйләп дөрес аңласа да, мәсьәләнең төбенә төшеп җитә алмады. Дөрес, зонага хәзер сугышларда катнашкан, хәлләрнең төрлесен күргән тоткыннар да килеп керә башлаган чак иде. Алар җинаять кылган тоткыннардан төзелгән штрафной батальоннар хакында сөйләп, егетнең канын кыздырганнар иде. Ташкәй элегрәк тә үзен сугышка җибәрүләрен сорап зона башлыкларына гаризалар биреп караган, үтенечен Мәскәүгә Калининга да язып салган иде. Әгәр Тубылга кайтуы шуларга җавап икән, ни өчен аны турыдан-туры армиягә алмадылар икән?..

Мәүлия белән Сәрвәр шул төнне үк торага кайтып җиттеләр.

## 16

Ялланлылар өчен быелгы кыш аерата авыр булды. Язга таба борылырга әле шактый вакыт бар, ә абзарларда салам-печән күзгә кырып салырлык кына калды, хуҗаларның базларында бәрәңге, чолан-келәтләрдә он-ярма җан сакларлык кына калып бара иде. Аерата колхоз маллары нужарды. Үз гәүдәләрен күтәреп тора алмаслык хәлгә җиткән, атласалар адым саен абына торган атлар, коры сөяккә калган сыерларга караган саен язгы чәчү искә төшә. Ни майтарырсың бу күтәрәмгә калган кешеләр белән дә, бу малкайлар белән ничек сөрерсең дә, ничек чәчәрсең?..

Ниһаять, авыр атлап «үләм, үләм!» дип чайкала-чайкала язлар-җәйләр, көзләр-кышлар бер-берсенә тагыла-тагыла үтә торды, сугыш бара дип тормыш тукталмады. Чираттагы яз якынлашты. Гыйззәтбану кебек гәүдәле апалар үзләре сукага җигелеп җир сөрергә чыктылар. Алты солдатка сука тарта, ә җиденчесе сука башына ябышып кыеш-мыеш буразнаны алып бара. Көнлек ун-унике сутый җир башына чыкканда иртән әле кыймылдый алган, кичкә көчсезләнгән, әлсерәгән хатын-кызлар әче тиргә, балчык, туфракка манчылып баскан урыннарында егылалар, аркалары, ботлары сызлауга зарланып, өметсез болытлар аккан күккә карап яталар. Бу бичара хатыннарны тик бер нәрсә яшәтә, тик бер нәрсә егылып үлүдән алып кала, бу — Өмет: менә-менә сугыш бетәр дә, кояш кебек әйләнеп ир-атлары кайтыр, кайтыр да бу авыр йөкне мәңгелеккә үз өсләренә алыр.

Сәлимә дә шул якты өметнең коерыгына ябышып яшәде. Маннуры белән кавышу истәлекләре, кыска гына арада бергә яшәп калган сихри көннәр, төннәр аның җанын һәр таңда җылытып күңел түрендә саклан-ды. Эш беткәндә ир-ат турында уйлый алмыйсың, гәүдәң чергән бәрәңгегә әйләнә. Бөгелсә дә, сынмады Сәлимә кебекләр. Менә алар алты хатын каткак җир өстен җырмачлап сука сөйриләр, алты солдатка, алтысы да чордашлар диярлек, алтыдан дүртесе ирләреннән хат-хәбәр дә алмый. Ә егылмыйлар, тарталар. Бара-бара арганлык та онытылып китә, алар сугышның бетүен теләп Аллаһе Тәгаләне искә алалар. Тәңредән бәрәкәт сорыйлар. Сүз арасында гына авылның ямен җибәргән зинахурлар — Шәгъбикә, Гобәйбә кебекләрне искә алып куялар. Каһәрләмиләр дә, сүкмиләр дә, чөнки Шәгъбикә сыңарлары Яланда әз, бик сирәк очрый.

Шәгъбикәдә кунып чыккан товаровед бүләкне мул яудырган икән, әле дә шырпы-тозы авыл арасында калкып чыга.

Ире Булат та исән ич әле аның! «Шәгъбикәм мине көтәдер»,— дип салкын окопларда җылынып ятканда, ул Булатның исемен аяк астына салып таптап, әлеге дә баягы Тимерҗан рәис белән яшәп ята. Ялан хатыннары: «Иреңне юньле хатын булып көтмәдең, кайта калса, күзенә ничек багарсың?—диделәр.

Шәгъбикә нәрсә, күзенә шайтан төкерсә дә «иртәнге чык!» дип ышандыра ала, кулларын бөеренә терәп хатыннар өстеннән тәкәббер күзләрен йөгертеп-йөртеп:

— Алдагысын берегез дә белми, йә кайтыр, йә кайтмас. Кайтса куаныч, кайтмаса? Кайтмый калса мин нишләрмен? Мин әлегә ир исен иснәп яшим ичмасам. Ирсез бер көн дә тора алмыйм мин, көмәйләр. Табигатем шундый. Так шту миндә сезнең эшегез булмасын!—дип кырт кисте.

Тыйнак, ипле, кешелекле Дәүләтшә әкәдән соң рәис булып алган Тимерҗаннан авыл халкы җык күрде. Ул баш булып алган көненнән алга таба һичбер үзгәрмәде, колхоз амбарының бер почмагында калган симәнәлек орлыкны да капчыклап Гобәйбәнең базына шудыра торды. Тимерҗан үзе иттән өзелмәде. Шәгъбикәнең тамагы тук, Гобәйбә урлап ташыган арыштан «май» сыга. Дөньяны су басса, үрдәккә ни кайгы? Шәгъбикә куштан Тимерҗан рәиснең, Тимерҗан сержантның аякларын һәр көн җылы су белән юа, элекке иренә бәрәңге дә пешереп ашата алмаган юбалгы хатын Тимерҗанга тәмле сыйлар әзерли. Үзе тазарып аркылыбуе бер булып китте, кабарынкы артын, дөя үркәчләре сыман атындырып кына йөри. Кайнарлыкка туймас хатын Тимерҗанны мәс булганчы эчерткәч өс-башын салып, Тимерҗанын үбә-коча чишендерә, башка солдаткалар җеннәре өзелгәнче кырда-басуда сука тартканда, алар, затсызлар, рәхәтләнеп җылы түшәктә аунадылар...

Тимерҗан, күргәнебезчә, сугышка кадәр байтак кешене чагып таш капчыкка озаткан, астырган-кистергән бәндә. Халык, ул җәрәхәтләнеп кайтып төшкәч, «дөнья авырлыкларын күреп, әллә Тимер җаны йомшадымы» дип уйлаган иде, ялгыштылар, өметләр акланмады, җаны тимер адәмнең күңеле кайда да җәлләү, шәфкать, мәрхәмәт дигән нәрсәләрне белми икән.

Печәнгә әнә шундый авыр көннәрдә төштеләр. Өйдән-өйгә шашып йөреп, ачлыктан тәмам өшәнгән, хәлсезләнгән хатыннарны Тимерҗан усал сүзләр белән коендырып, акырып-үкереп эшкә өерләп куып чыгарды. «Сез нәрсә, коерыксыз кәҗәләр, военный время икәнен оныттыгызмы? Арт симертеп ятмакчы буласызмы? Без кемнәр өчен анда кан койдык? Сез бе... ләр өченме?» Кергән бер өйдән аның шакшы лакан суы койганы яңгырап торды. Ялан халкын үз катылыгына өйрәтеп бетергәч, егәрен саклаган Алаяк исемле айгырына атланып ишегалдына керә дә хуҗаны баскычка чакырып чыгарып камчы белән каезлый. Чыгалар, камчы ашаганда да дәшмиләр, түзәләр.

Беркөнне Сәлимә аңа карышып нидер әйтмәк булган иде, Тимерҗан айгырны сикертеп аны аяктан екты. Ат тоягы астында коты чыгып аунап яткан хатынга Алаяк басмады, гәүдәсе аша сикереп үтте. Ат булып ат җәлләде бичараны, Тимерҗан борылып килеп, Сәлимәнең җилкәсенә тагын бер-икене тамызды. Тимерҗан ни котырынса да Сәлимә ул көнне эшкә чыкмады, әле өенә керде, әле нидер югалткан сыман, башын аска иеп ишегалдына чыкты, үзенең кадерсезгә калу гарьлегеннән өзгәләнеп җылады.

Алия исемле хатынның ире яраланып әзгә генә ялга кайтып киткән иде, орлыгы бәрәкәтле булган егетнең, хатын сөенеп-борчылып бәбәй көтте, корсагы, уенын-чынын кушып әйткәндә, борынына менеп житте. Шулай булса да ул бер көн дә эштән кала алмады, һаман чыгып ярдәм

итешеп йөрде. Беркөн Тимерҗан сугыштан өйрәнеп кайткан бөтен алама сүзләрен чәчеп Алияне эшкә куып чыгарган, шуның өстенә, болынга, печән кибәннәре куйган урынга килеп, комарланып эшне күзәтеп торган. Гомер-гомергә кибән очлаган, шул эшнең остасы саналган Алияне, таудай корсагын күтәртеп, кибән очларга менгергән. «Миңа су үтеп череп утырган кибән кирәкми! Мен дигәч мен!» Менгән бичара хатын, тыңлаучан җан, тешен кысып түзгән, аны-моны сиздермәгән. Кибән очланып килә дигәндә генә Алияне тулгак тота башламасынмы? Астан хатыннар кычкыра, төрлесе төрле тавыш белән ашыгыч киңәшләрен бирә. Моны тамаша иткән Тимерҗан атына менеп, мескен хайванны чарлый-чарлый авылга кача. Нигә чаба, моны бирәү дә белми кала, соңрак, эш узгач, Тимерҗан җирбит: «Мин кендек әбисе Сәгадәтбану артыннан чапкан идем»,— дип ялганлап котыла...

Алия балага зыян-зарар килер дип куркып кибән башыннан шуып төшәргә базмый, астагылар аның янына менәргә елгерми, бала туып, кибән очыннан дөньяга беренче авазын сала. Батыр хатын икән Алия, йөрәге ярылмаган, һушы китмәгән, итәгенә бәбәен салып аска шуып төшкән. Сабыйның кендеген чалгы белән кисеп, чистарак яулыкка төреп, «ата-анаңа игелек китер, озын гомерле бул» дип теләкләр теләгәннәр дә, печән түшәлгән арбага сабыйны кочкан әнкәсен утыртып авылга алып кайтканнар. Арбага биш хатын җигелгән, алар куанычларыннан юл буе җылаганнар.

Сугыш елларында күрелмәгән бик тансык малай иде бу. Барлык авыл Алиягә бала караштьы. Кем кәҗә сөте китерде, кем «имезлек салырсың», дип актык бер уч онын бәбигә багышлады, бишек тә табылды, юа, балтырган, кәҗә сакалы алып килеп тә бала әнкәсен сыйладылар.

Чөй өстенә тукмак дигәндәй, табигать тә усалланды, җәй буена нибары бер тапкыр аз-маз яңгыр сибәләп үткәндәй итте, җир саргаеп кипте. Дым җитешмәгәч начар эшкәртелгән басулар карун. Рәхмәтулладай бик саранланды. Гектардан ике-өч центнер уңыш алдылар яланлылар. Элекке елларда колхозчылар кибәк җилгәреп, качып-посып башак җыеп, шырчайлык арыш, бодай җыештырып калалар иде. Быел анысы да юк. Балаларның шәүләсе күренүгә, басуның теләсә кай төшенә Тимерҗан чабып барып җитә дә, сабыйларның җилкәләренә камчы эзләре сыза. Яшьрәк хатын-кызларны туры китерсә, туймас күз Тимерҗан аларны әрәмәгә өерләп кертә дә... Әгәр берәрсе ризасызлык белдереп сүз чыгара икән, андыйларны Тимерҗан сәвиткә чакыртып, «икмәк урлаганда тотылды», дип актлар язып башын тинтерәтә. Күпме хатын-кыз шул Тимерҗан мөртәттән корсакка узып, яшереп бала төшереп, саулыгын җуйды.

Ярый әле, бәхетләре бар икән, үгездәй симергән, күз кабаклары ачылмас булып шешенгән; мәңге исерек Тимерҗанны военкомат аша яңадан фронтка озаттылар. Җәфа чиккән, җык күргән Тимерҗанның канатлары салынган трантас әрҗәсенә кырын ятып авыл аша үтеп баруын тамаша иткән хатын-кызлар: «Йөргән җиреңдә муеның астына килсен, карайөз!»—дип каргадылар. Аларның каргышы төшкәндер, ихтимал, китеп ике ае да үтмәде, Тимерҗанның кара кәгазе килеп тә төште. Авыл сөенде, Шигъбикә белән Гобәйбә буйдак кына үкереп-үкереп, чәчләрен йолкып җыладылар да, эчеп-исереп алгач, авыл урамы аша кочаклашып җырлап үтеп киттеләр.

Тимерҗан киткән көн хатыннар өчен олы бәйрәмгә — явыздан котылу тантанасына әйләнде. Бөтенләй үк терелеп җитмәсә дә Дәүләтшә әкәгә барлык авыл хатыннары ялварып кергәч, ул пичәтне алырга ризалык бирде. Колхозчылар аны күтәреп йөртергә дә риза иделәр. «Җылы сүзеңне ишетү дә зур бәхет, Дәүләтшә әкә, җаныбызга шифа була, син өметне сүндермисең, ичмасам, озын гомерле бул, бергә яшик, булдыра алган хәтле бергә эшлик», диделәр җылап-куанып яланлылар.

Кыш авыр булды дидек. Сыерлылар аз-маз җан саклап яшәделәр, сыерсызлар тоташтан ачыкты. Сыер барда күк сөт эчеп булса да яшәргә җай кала икән! Чәмәкә, Аймыш, Илүкә әкәләр, бар булган ризыкларын кисеп, нәбәрәләренә ашатырга тырышып яши-яши үзләре ачлыктан шешенеп үлделәр...

## 17

Зурмы ул, кечкенәме, сугыш елларындагы һәр вакыйганы авыл уртак итә. Дөрес, һәр вакыйга көне-сәгате белән уртак булып бетә алмый әле, һәр авылның үз сере, яшертен тормышы, адәмнәрнең ашыгып дөньяга чыкмаган мөнәсәбәтләре була. Әйтик, Чырык Абдрахманның өенә төнлә-төнлә кемнәрдер кереп-чыгып йөрүен күргәннәр. Авылның күзен каплап булмаса да, телен тыеп була. Мәсәлән, Тубылдан кәттә бер капитан Чырыкның үзен күреп тә сөйләште, күрше-күләнне дә идарәгә чакыртты. Чырык сирәк керфекләр уртасыннан саеккан күл кебек кенә елтыраган күзләрен челт-челт йомып, сөякчел куллары белән тар күкрәгенә ябышып, капитанның сүзен кире какты. «Валлаһи, таллаһи, күргәнем юк, белгәнем дә юк, тавыклар белән бергә ятам!» — диде. «Әтәчләр белән бергә уянасыңмы?» — диде көлемсерәп Ишморза. Тубылдан килеп төнге сәфәрчеләрне эзәрлекләп йөрүче кеше ул иде. Күршекаршылар да бер сүздә булдылар. «Юк, чит-ятларның урамга кергәнен күргәнебез булмады. Абдрахман әкә бер башы яшәп ята».

«Юк, юк! Юкка мин үзем дә тук! Кайчан бетәр бу «юклык», дип, күңеленнән зарланып НКВДсына кайтып китте Ишморза Муллин. Ә хәбәрләр киресен сөйли: Т. авылында төнлә мәктәп тәрәзәсен ватып кереп, ике мелкашканы урлап чыкканнар. Мәктәп мелкокалиберный винтовкаларны тапшырырга тиеш булса да, коралларны тапшырмаганнар. Аларның сабыр гына мәктәп шкафында ятуын кемдер, каяндыр белгән. Лапиков директорны кулга алып утыртып куярга ашкынса да, Ишморза аңа каршы төште. «Уйлап бетерәсе планнарым бар. Әйдәгез, дошманны алдан ук өркетеп куймыйк», — диде.

Иң зур, бик күп сүзләр, юраулар тудырган яңалык шул булды: фронтта, авыр сугышларда кат-кат яраланып, контузиядән чукракланган һәм сөйләм сәләтен бөтенләй җуйган Булат авылга кайтып төште. Бөтен авылның колагы торды, һәммә кешенең, олысының, кечесенең игътибары шул якка борылды, ятып та, басып та тыңладылар: Булат кайтып төшкәч, бөтен пәрдәләре тыгызлап ябылган өй эченнән күк күкрәгән тавышлар ишетелмиме? Давыл чыкмаса да, иренең шулай «адәм актыгы булып» кайтып төшүе Шәгъбикәгә бер дә, бер дә ошамаган, имеш. Кайтып төшеп йорт-җире, капка-коймалары, келәте белән танышып йөргәндә, хатыны җыеп куйган байлыкны күреп, елга якын сүз әйтә алмаган Булат: «һм», дип кенә куйган икән, диделәр. Шуннан ары сүз әйтергә тырышмаган Булат, элек тә сүзен сатып кына бирә торган байгыш, үз эченә кереп бикләнгән. Авыл гадәте буенча аксакалларга, ил агаларына сәлам биреп, куанычын уртаклашып өй борынча йөреп тә чыкмаган, урам як тәрәзәсе каршысына утыра икән дә көннәр буе шуннан күзен алмый икән.

Ирем кайтты дип, Шәгъбикә үзе сайлаган сукмактан тайпылмаган, әле Тубылга барды чана тартып, әле Түмәнгә барып кайтты. Авылда тамыры корыган товарлар: аш тәлинкәләре, тоз, шырпы, борыч ише нәрсәләр аның шома кулы аша һаман үтә тордылар.

Ишле бала-чагаларын, җилкәләрендә калган картларны, карчыкларны ничек ашатырга, ничек үтермәскә дип баш ваткан толлар, солдатка апа-җиңгиләр түшәк-ястыкларын, самоварларын, кием-салымнарын, чиккән сөлгеләрен, хәтта туй алкаларын, йөзекләрен дә күтәреп киләләр

иде Шәгъбикә янына. Киләләр дә бер-ике чиләк бәрәңге, бер янчык онга, бер кап шырпы-тозга алыштырып китәләр. Чиккән сөлгеләрне, милли тастымалларны Төмән шәһәренә эвакуациягә агылган марҗалар, яһүдә апалар бик теләп алалар иде. Җыялар да җыялар, ник җыялар, кая алып барып тагын кемнәргә саталар — болары Шәгъбикәгә кирәк тә түгел. Аның үз көне көн! Кем дә кем аңа сүз куша калса — бетте, Шәгъбикә аны теле белән телем-телем турап ыргыта.

— Үз көчем белән тапкан хәләл малым. Кем тыя, бәрәңгесен дә үстерегез, бүтәнен дә юнәтегез. Чакыртып китермәдем, хаҗәтегез юк, алдыгыздан артыгыз матур! — дип кенә җибәрә.

Шәгъбикәнең мәрхүм әнкәсе болай дип әйтеп калдырган имеш: «Шушы балам белән авырлы чагымда талымладым да торна ите ашадым. Алагаем каты иде ите! Шуңа күрә кызым каты бәгырьле булды»,— дигән.

Күрер күзгә бик йомшак, ягымлы иде шикелле. Ятимнәрне күрсә җәлләр иде, капка каккан һәрбер хәерчене буш кул белән борып чыгармады. Мәүлияне карашты, төннәрен йокысыннан торып бакты, бер чакта да зарланмады. Өй эчендәге эшләрне бер үзе башкарып чыга иде.

Үсеп, кура җиләгедәй пешеп тулышкан кызны пәри алыштырды да куйды. Авылның иң затлы, мактаулы егете Шәүкәткә күңеле төште кызның. Аны җаны урынына күреп йөрде, эштән кайтканда сагалап торды, күрше апасы аркылы чиккән кулъяулыгы бүләк итте. Шәүкәт аңа әйләнеп тә карамады. Тубылга кунакка баргач бер егет белән танышты, егет төскә-биткә бер дә Шәүкәттән ким түгел иде. Авылына алып кайтып мактаныр өчен генә ул чибәр егеткә «хокукларны» артык күп биреп ташлады, нәтиҗәдә, егет кызны урды-урды да юмартлыкларын күргәч кача ук башлады. Шул көннән Шәгъбикәне кемдер кирегә аударып җибәргәндәй булды. Аңа бар кешеләр дә хәйләкәр, алдакчы, икейөзле, явыз булып күренә башлады. Үз бәхетен үзе яуларга ният итте Шәгъбикә. Һәр тармакта үзен алга чыгарырга, бүтәннәргә мәңге юл сапмаска ант итте. Тыныч, юаш һәм үтә эшчән, булдыклы Булатны сөймәсә дә үзенеке итәргә булды. Мең хәйлә, мәкер белән Булатның күзе төшкән кыз хакында гайбәт таратты, алдалады, юмалады, җылан булып унга бөгәрләнде, тәки теләгәнен эшләде: сөеп йөргән кызы Мәүлихадан тартып алып үзенеке итте. Энә-җептән тормышын җыя башлады.

Тир түкмичә генә бушка килгән байлык теләсә кемне боза. Шәгъбикә колхоз эшеннән тәмам читләште, бөтенләйгә бизде. Бар нәрсәсе житеш, тормышы түгәрәк булганда нигә аңа Сәлимәләр, Мәдинәләр рәтеннән бушка чиләнеп йөрергә? Бүтәннәрнең зар-моңына аның колагы чукракланды, кеше газабын күзләре күрмәс булды. Дөньяның бар рәхәтен, ләззәтен үзенә җыеп, бүтәннәрдән өстен булып, дәү кедр агачы кебек биеклектән карап кына яшисе килде Шәгъбикәнең. Төннәрендә ниндидер бер таза егетнең шыпырт кына аның янына, келәтләренә килеп йөрүе хакында хәбәрләр бер калкынса да, Шәгъбикә бу имеш-мимешләрнең дә юлын кисте. Гайбәт таратучы апа-җиңгиләрне тыйды, кайсын юмалады, кайберәүләрен өркетте. Явызлык та, хәйлә дә җитәрлек иде аңарда. Явыз хатынның хәйләсенә каршы торырлык ир бармы икән бу дөньяда?.. Кая ул, Шәгъбикә юаш Булатны чәйнәмичә дә кабып йотты.

Дөньяның һәр сулышыннан үзенә файда алырга өйрәнеп, остарып житкән Шәгъбикә телсез, өнсез ире кайтып төшкәч тә хафаланмады, хәтта сөенде дияргә дә ярый. Инвалид ирен дә карыйсы, тамагын кайгыртасы булгач, ул бәрәңге, тозга бәяләрне бермә-бер арттырды, мохтаҗлыктан зиһеннәре таралган, кулларыннан эш төшкән авылдашларының актыккы әйберләрен йолкып алганда да кулы калтырамады.

— Нишләп оялып торыйм? Берүземә генә түгел лә! Илебез өчен кайнар канын койган батыр өчен дә тырышам! — диде ул Гобәйбә буйдакка ачылып китеп.

Хатынның туң төсен күреп, авызыннан чыккан суык сүзләрне ишетеп Булат үзенең исән калуына үкенә дә иде бугай. Теле булмаса да кул-аягы бар, тормышта тулысынча рәхәт күрмәслеген белсә дә, тыныч тормыш өмет итеп кайткан иде ич егет! Күкрәгендәге медальләрнең чыңлавын ишетә алмаса да, аларның нурланып елтырауларын күзгедә күреп бер генә куанмады ләбаса Булат. Үз учагына талпынып, канатланып кайтып кергән иде. Учагы әнә нинди нурлар чәчеп дөрләп ята икән аның туган авылында, кайтып та керде Булат, канатлары көеп сәлперәеп тә төште. «һм» дигән аваз ургылып чыкканнан бирле аның мәңгегә дәшмәстәй күренгән бугазы чистарып киткәндәй булды. Атна-ун көн яшәп, туган ягына рәхәтләнеп, кинәнеп караганнан соң, колагы да әз-мәз ачылды шикелле. Ләкин ишетә башлавын да, бугазының сүзгә зарыгып, кымыржып торуын да ул әлегә беркемгә дә сиздермәде. Авызы ачылса, хатыны Шәгъбикә белән сөйләшергә туры киләчәк иде. Авылдашлары Шәгъбикә хакында тау-тау хәбәрләр җиткерәчәк иде. Булатның сөйләшәсе дә, хатыны хакында беләсе дә килми иде. Күзе сау, күрә, хатыны ул югында йорт-җирне байлык, хәзинә белән тутырган. Хатын-кызга, бигрәк тә табан астына ут капкан хатыннарга мал-мөлкәтнең нинди юллар аша үтеп кергәнен Булат әз-мәз чамалый иде. Сугыш юлларында ялгыз калган ирләр, хатыннар турында күп-күп вәгазьләр сөйләп юаш, күрер күзгә мокыт Булат солдатның да күзен ачып кайтарганнар иде.

Булатның көннән-көн йомыла, шиңә баруын Дәүләтшә әкәгә дә ирештерделәр. Ул бригадиры Сәлимәне ияртеп Шәгъбикәләргә килеп кергәндә, Булат иске шинеленә төренеп мич артындагы куышта йоклар-йокламас ята иде. Хәзер мич арасы — Булатның яраткан урыны, очлы күз Дәүләтшә әкә моны керүгә үк күреп алды. Солдатның баш очындагы урындыгында суык чәе тора, бер башы суда җебегән сохари телеме дә шунда. Шәгъбикә тимер мич өстенә таба утыртып май эреткән җиреннән туктап калды... Май эретә дә пәрәмәчләрне май дингезендә йөздерә. Янып пешкән йөзе, кызарган, авызындагы пәрәмәчен капыл-копыл йотты да авызын ерды.

— Кермисез, хәлләребезне белмисез дә, әнә авыру янвалид үпкәләп ята сезгә!

— Вакыт җиткерер хәл юк, Шәгъбикә кызым. Язгы чәчү җитә дип башымдагы соңгы чәч бөртекләрем коелып төште. Гафу итә күрегез! — диде Дәүләтшә әкә чын күңеленнән. Шәгъбикәне кыңгыр эшләре өчен әрләргә дип тә җыенган карт рәиснең күңеле җебеде дә төште. Шәгъбикәнең кызгандыра белә торган җырлы-моңлы тавышы Дәүләтшә әкәне дә сихерләде.

Кунакларның байтактан ишек катында басып торуларын күреп Шәгъбикә көлеп җибәрде.

— Әй ходаем, менә мине хәзәйкә диген инде, кадерле кунакларны ишек сакларга куйганмый гуй. И оят! Башымның әйләнгәне шул тиклем ки, Дәүләтшә әкә, әле дә ничек исән яшим. Шаклар катам. Авыру ир белән азаплану үземне тәмам тинтерәтте. Дәүләтшә абзыкаем, чиге, чамасы юк бу газапның! Кереп хәлемне дә белмисез ичмасам, — дип барысын бергә тезеп китте тасма тел Шәгъбикә. — Хуш килепсез, әйдә, түрдән узыгыз.

Ул аларны идәненә хәтфә палас җәелгән түр бүлмәгә алып керде. Кара лак белән күзгедәй ялтыратылган пианино корсагын ялтыратып түрдә утыра иде. Ялан тирәсендәге элекке мөхтәрәм байларда да булмаган мондый затлы малны каян кулына төшергән бу шайтан хатын? Кемгә, нигә кирәге бар бу әкәмәтнең? Булатны да тәмам котырткан, өеннән бизәргә, хатыныннан читләшергә мәҗбүр иткән төп сәбәп шушы кара тартма иде. Немец җирендә эшләнгән бу затлы әйбернең Ялан авылына ничек-ничек килеп җитә алуын Булат сорамаса да чамалый иде. Шактый акча киткән булырга тиеш бу

шайтан калтырчасына! Пианинодан уңдарак, эреле-ваклы ялтыравыклы шарлар тезелгән киң караваг тора. Кара бәрхет япмасы өстенә бихисап күп мендәрләр өелгән. Сандык, чемоданнар, талдан үрелгән кәрзиннәр нафталин исен чәчеп бер-берсен саклап уңда да, сулда да урын били-ләгәннәр. Уртадагы кызыл аяклы өстәл астында озын йонлы көрән аю тиресе җәеп салганнар иде. Сәлимәнең ул тирене элек Ырсытдин бүлмәсендә күргәне бар иде. «Ул да монда күчеп килеп яткан икән!» — дип уйлады Сәлимә. Сәлимә, кырык ямаулы оегын күрсәтергә теләмәгәнгә, паласка ялана́як басмакчы иде, Шәгъбикә аңа җылы эчле чүәкләр китереп бирде.

Берзаман, нафталин исен басып, йортка пәрәмәч исе таралды. Өстәл янына Булат та чыгып утырды. Ул кул бирмәде, кунаклар аның белән баш иеп кенә исәнләштеләр. Хуҗаның өстеннән фронттан киеп кайткан ямаулы гимнастерка төшмәгән иде әле. Түшен ике «Батырлык өчен» медале һәм гвардеец значогы бизәп тора. Шәгъбикә кече якта шактый озак кайнашты әле.

— Нихәл, солдат! — дип кычкырып исәнләште Дәүләтшә әкә. Булат күзләрен елкылдатып торды да, ике колагына ике бармагын юнәлтеп, иңбашларын сикертте. Берара тынлык булып алды. Дәүләтшә әкә баядан бирле күзен кырып утырган пианинога төртеп күрсәтте дә: «Син алып кайттыңмы моны?» — дигәнне аңлатып ишарә ясады. Булат кабаланып ике кулын да күкрәгенә куйды һәм башын тиз-тиз чайкады, «юк, юк!» янәсе.

Бераздан өстәлгә кайнар пәрәмәч чүмәләсе килеп утырды, уртада елтырык җиз самавыр пышылдады. Хуҗа хатын мул артын тирбәтеп өстәл тирәли йөрде һәм кунакларны өзмәс кыстады. Сәлимә белән Дәүләтшә әкәнең хуш исле бөртекле чәйне, тәмле ис таратып ашказанын котырткан пәрәмәчләрне кайчаннан күргәннәре юк иде инде. Бик тыйнак кылансалар да пәрәмәч тавын яртыладылар, өчәр чынаяк чәй чөмерделәр. Сәлимә янә табакка үрелгән иде, күзе яндагы көзгегә төште. Көзгене уратып алган чүпләмле Казан сөлгесе бик тә таныш иде аңа! Сөлгене Сәлимә үзе чигеп, бик якын кешеләренең туена бүләк иткән иде. Сөлге монда килеп җиткән икән! Хуҗалар, ашарларына беткәч сөлгене бәрәңгегә яки тозга алыштырып киткәннәрдер, мөгаен. Сәлимә ашыгып амин тотты һәм табын тирәсеннән кузгалып та китте. Дәүләтшә әкә дә чынаягын түңдәрде. Бригадиры аны моннан тизрәк китәргә өнди башлады. Ләкин Дәүләтшә әкәнең Булат белән бик нык аңлашасы килә иде. Сәлимә Булатның егет чагын, Мөхәммәт Уразаевта ликбезда укып йөргән чакларын исенә төшерде. Һәм бу хакта Дәүләтшә әкәгә дә әйтте:

— Язуын да онытты микән әллә бу бичара! — диде.

Шәгъбикәдән саргаеп беткән кәгазь сорап алдылар һәм Сәлимә латин хәрефләре белән бая Дәүләтшә әкә сораганнарны язып Булатка тоттырды. Булат кәгазьгә текәлеп карап торды да һәм кәкере-бөкере хәрефләр белән җавабын язды: «Хәлләр начар. Күрәсез хатын җилкәсен кимереп ятам».

Ике арада язма аңлашу китте. Дәүләтшә әкә әйтеп тора, Сәлимә яза: «Саф һавада кеше арасында булу сиңа яхшылыкка булмасмы?»

«Кеше арасына чыгып көлкегә генә калмаммы?» дип җавап бирде Булат. Шәгъбикә эшләрен ташлап, өстәлгә иелгән Сәлимәнең җилкәсе аша ире һәм бригадир язганнарны ашардай булып күзәтеп торды. Сак булырга кирәк; ире югындагы хәлләрне ишеттерә күрмәсеннәр.

«Йә, хуп, Дәүләтшә әкә, сүзеңне әйтеп бетер».

«Кулыңда егәр калгандыр ич?»

«Кул-аяклар ярыйсы». Менә бу,— Булат телен чыгарды, колакларына җәза биргәндәй аларны сугып күрсәтте. Аннан күзләре мөлдерәп китте, тиз-тиз йотына башлады. «Кхем, кхем» итеп алды. Әйтерсең, тамагын сугыш йоттырган төерне кырып атарга маташты, җылыйсы килгәндәй

ирен читләре калтыранды. Шәгъбикә исә, чыраен һич үзгәртмичә, бу язмышка катнашы һич юк шикелле, сүз әйтмәде, сагаеп урыннан урынга күчә-күчә нидер көтте. Бераздан үз көен көйләргә, үз сүзен өскә чыгарырга керешге.

— Гарип көенә эшләп йөрмәс инде. Тамагы тук, өсте бөтен. Дөрес аңламаслар, Шәгъбикә ирен эшкә куып чыгарган, дип гайбәт сөйләрләр. Бер ирне асрарлык кына көчем бар әле, шөкер. Сезнең көнегез шул янвәлидкә калдымы?

Дәүләтшә әкә бер дә яратмыйча Шәгъбикәгә усал карап алды да кыза башлады.

— Син, Шәгъбикә сеңлем, нишләп алай кыланасың, иреңне тере килеш күмәргә ниятлисеңме әллә? Үзе теләсә, эшкә чыксын. Яз җитә! Көч-хәл белән, күпме аяк итемне ашатып йөри торгач, әз-мәз симәнәлек бодай алып кайттык. Яртысы чүп-чар, аны җилгәрергә кирәк. Җилгәргечләребез дә, үзең әйткәндәй «янвалид». Төзәтергә кешебез юк, аны ашыгыч төзәтергә кирәк. Булат тимер-томыр эшен белә — ир кеше.

— Сәлимә, язып күрсәт Булатка. Барлык авыл эштә, картлар, карчыклар эшли-эшли аяктан егылалар. Син, Шәгъбикә, оялмыйча өйдә пәрәмәч ашап утырасың, җитмәс иреңне дә чыгармаска исәбең. Яз, Сәлимә! Ачык әйтеп яз!

— Таптың, Дәүләтшә әкә, оялтыр нәрсә. Мин әнә шул тере бүкәнне карыйм. Эшкә чыксам, аны кем бага? Син аш-су әзерлисеңме аңа, өс-башын арулыйсыңмы? Мине эшкә куарга не имеешь права! Мин янвалид бичәсе!

— Ирең өйдә юкта ниләр кыйратканыңны беләбез, дәшмә генә! Менә шул: иртәгедән эшкә чыкмасаң, колхоздан куачакбыз.

Шәгъбикәнең йодырыгы, тилгән булып, Дәүләтшәнең борыны төбендә тирбәлде.

— Андый праваң юк! Безне, сугыш кырларында кан койганнарның бичәләрен ничек әбиҗәйт иткәннәрен карап торырга кайтканмы ул? Кем өчен кан койган ул?

Сәлимәләр чыгып киткәч өйдә нинди давыл купкандыр, анысы билгесез. Тик шинелен җилбәгәй җибәргән Булат бер-ике сәгатьтән ындыр табагына килеп җитте. Моңаеп утырган җансыз җилгәргечне ике-өч тапкыр әйләнеп, карап чыкты. «Мескен, сагынып кайткан!» — диештеләр солдаткалар. Иелеп бер уч бодайны алып үпте, кашына, күзенә сөртте, озак итеп иснәп торды. Тагын «кхм, кхм!» дип, тамак төбенә сөлек булып ябышкан төерне кырып ташларга тырышып көчәнде. Шинелен салып келәт ишеге катындагы кадакка элде. Аннары иплэп кенә җилгәргеч тоткасына ябышты, әйләндерә башлады. Утыз биш яшьлек ирнең егәркуәте сизелеп тора. Биш солдатканы алыштырачак бу ир! Бер әйләндерде Булат, тукталып нидер уйланып торды, уңга чыкты, сулга иелде, турайды. Җилгәргеч тирәсендә аңа кадәр дә казынганнар иде, эшләре барып чыкмагач, вак-төяк коралларын шунда чәчеп калдырганнар иде. Җилгәргеч выж да выж әйләнә, эреле-ваклы иләкләр генә тик тора, җилгәрми. Берзаман Булат бөтен дөньясын онытып борырга, тартырга, чүкеч белән суккаларга тотынды. Ходаның хикмәте, Булат әйләндергән уңайга иләкләр дә дөрелди, калтырый башлады. Эшли!

Хатын-кызлар Булатны — ир кешене, солдатны урап алдылар, аның йөзенә елмаю йөгерде. Шул чакта гына ул борын очын ак чүпрәк белән каплап куйган Мәүлиханы абайлады. Мәүлиха очып китә алмаган җәрәхәтле канатлы кош кебек талпыныр-талпынмас аңа карап каткан, күзләреннән ургылып ут ага иде.

Яшь чагында шушы кыз артыннан җан атып йөргән иде ич Булат!

Өннә апа җилгәргечкә беренче чиләк чүпле бодайны китереп салды, Булат тотканы әйләндерергә тотынды. Кибәкләр тузгып бер якка очтылар, ә яп-якты эре бодай бөртекләре куанышып иләк өстендә бии-бии

мөшкә аша капчыкларга коелдылар. Өннә апа бодай ташый-ташый тиргә батты, менә аны Мәүлиха алыштырды. Шул чагында Булатның буыннары бушап калды, туктап тирләгән муенын җиңе белән сөртә башлады. Ул арада булмады, Мәүлиха алъяпкыч кесәсеннән ап-ак кулъяулыгы чыгарып Булатка сузарга уйлады да, ниятеннән кире кайтты, чиста, хуш исле яулык белән Булатның куе төк баскан ияк асларын, муенын сөртә, корыта башлады. Хатын-кыздан гына килә торган татлы ис аның башын әйләндерде, ул нафталин исе сеңгән Шәгъбикәсен күңеленә китереп борын җыерды. Мәүлиха аңа туры карады, борын очының юклыгын исеннән чыгармаса да, Булаттан күзен ала алмады. Булат та үзенең яшьлек мәхәббәтен, шашып сөеп тилергән мизгелләрен онытмаган, күрәсең... Күз карашлары очрашкач Мәүлиханы бер суык алды, бер ут ялмап йотты. Булат әйләндерә, бодай тулы чиләк Мәүлиха кулында очып кына йөри. Аларны урап алган хатыннар шаккатып күзәтеп тордылар да ындыр табагының бер читенәрәк тартылдылар. Җилгәргеч янында алар ничектер икәү генә калды.

Ике чордаш, ике кеше очраштылар. Булат Мәүлиханың иренә хыянәтен белми, Мәүлиха исә Булатның бүгенге хәлен, фаҗигасен аңлап бетерә алмый. Шулай да хатыннар Булатның үз күзләрен Мәүлихага уеп бирергә әзер икәнлеген дөрес аңладылар, төрле тарафларда төрле чошпошлар китте.

Өннә: «Тамак ялгап алабызмы әллә, көмәйләр?» — дигәч, көздән чәчелеп калган салам учмаларына таралышып утырдылар. Сәрвәр Мөхәммәт абыйның хатын үзе белән алып килгән икән.

Менә яза ичмасам Уразай мөгаллим хатларны! Саниясенең югалуына, Мөхлисә әбинең вафатына чиксез кайгыруын ишеткәч хатыннар кулъяулыкларына, күлмәк итәкләренә тотындылар. Мөгаллим ярты авылга сәлам әйтеп чыккан, үзенең госпитальдә дәвалануын бәйнә-бәйнә язган. «Үпкәм һаман савыгып бетми, йөткергәндә куе кан килә, мина ярчыклары чәрдәкләгән тезем ямалып килә диярлек» — дигән.

Хат азагына җыр даябыштырып куйган.

Туктәле, җил, исмәле, җил!<br>Өзмә гөлнең чәчәген;<br>Алга килми белеп булмый<br>Башның ни күрәчәген.

Телләре кычытып, тамак төпләре кымырҗыса да, хатын-кызлар бер мәлгә тынып калдылар.

Саниядән хәбәр юк, соңгы айларда Шамилдән дә хатлар килми.

Шамил исеме телгә кергәч, Сәрвәр капылт агарынып, үзгәреп китте. Ул җәһәт кенә сүзне тагын Мөхәммәт мөгаллим ягына борып җибәрде.

— Мөхәммәт абый кайтса, таяныр талыбыз булыр иде.

Сәрвәрнең җырлаганы күптәннән ишетелми иде, бу әңгәмә аның тынып торган яшьлек дулкыннарын да кузгатты, ахрысы. Ул ягымлы тавышы белән әкерен генә җырлап җибәрде, бүтәннәр уңнан-сулдан аңа кушылдылар:

Ямьле Иртеш буйларында<br>Тавышым калсын билгегә;<br>Уйларымда, җырларымда,<br>Йөрәгемдә син генә!

Хатыннарның гомер-гомергә җырлана торган авыл җырларына мөнәсәбәтләре үзенчә, әле генә бер йодырык булып ындыр табагын чистартучы, арулаучы, җыештыручы хатыннар җырлар җырлана башлауга таралдылар, һәркем үз якынын, сугыш кырларында әллә кайчаннан бирле йөри торган ир-атларын үзләренчә сагындылар, аларның җаннары

ерак-еракларга очып китте. Шушы өнсез Булат рәвешендә генә булса да... Кайтсын иде әле... Ир-атлары өйдә булса болай интегерләр идемени алар? Әйе, йөрәк маен өзеп ала торган авыл җырларын сугыш та оныттыра алмый.

Җырдан соң сүз килде, хатыннар рәхәтләнеп балавыз сыктылар, яшь чакларын искә төшерделәр, җиңеләеп калдылар.

Үз мәшәкатьләре белән булышып хатын-кыз Булатны онытып җибәрде. Ул тирләгән җилкәсенә шинелен салып үзеннән үзе тәмәке пыскытып утыра иде. Аны Сәрвәр шаярта-шаярта култыклап алып килде, кесәсеннән ярты уч чикләвек чыгарып солдатка бирде. Булат рәхмәт әйтеп баш какты һәм моңарчы йомык авызыннан «рәхмәт» дигәнгә охшаган бер сүз кысылып чыкты. Үз сүзен үзе дә ишетте кебек. Булат сәерсенеп як-ягына карады: көлмиләрме аннан?

Иртәштән ерак та түгел урнашкан ындыр табагы тирәсендә Булатны кузгатырлык хатирәләр дә җитәрлек иде. Эх, ул сихерле салам эскертләре, кояшта ялтырап яткан арыш көшелләре. Табалардан сикерешеп төшкән куырган борчаклар! Боларыннан да мең кадерле истәлекләре бар Булатның күкрәгендә... Күзен йомса әллә ниләр күренә башлый Булатның күңел күзенә. Мәүлиханың салам астыннан сары шәл бөркәнеп чыккандай кызарынып-бүртенеп килеп чыгулары, аның йөземнән татлы иреннәре.

Икенче көнне дә эшкә килде Булат, тик бүген кичә гөрләп торган ындыр табагы буп-буш иде. Кичә үзе очырып, әлләни еракка җибәрә алмаган кибәкләр канатланып талгын җилдә бөтереләләр, чүп-чарлар, салам кисәкләре керфек арасына кереп йөдәтте егетнең. Ул кичә тәмәке тартып утырган урынына чүмәшеп, күзенә кергән чүпне чыгара алмый шактый азапланды, чүптән арынып, күтәрелеп караса, аның каршысында Мәүлиха басып тора. Кичәгедән яхшырак киенгән, бер дә эшкә барырга җыенгандай түгел. Кыю, чая хатын шул Мәүлиха, ике кулы белән Булатның уң иңенә килеп кагылды, сөйдеме, бер-бер сүз әйтергә теләдеме? Булат сәерсенеп һәм сөзеп карады яшьлек дустына. Мәүлиханың тулышкан иреннәре кыймылдады. «Син минем хәлләрне беләсеңме?» — дип сорады ул. Булат тагын да җитдирәк итеп таныш иреннәргә текәлде. Хәзер Мәүлиха авызын ачар да, аннан Булатның саулыгын кайтара торган сихерле, татлы гыйбарәләр чыгардай тоелды. Һәм алар шунда буш ындыр табагында, үтәли йөгереп йөргән җил күзендә байтак утырдылар. Ходага шөкер, беркем аларга комачауламады, ым-ишарәләр дә катнашкан әңгәмәне өзмәде, чит күз карашлары аларны өркетмәде. Мәүлиха солдатның хәлен сорашмады, болай да кирәгеннән артыгын белә иде, Шәгъбикә тигез үзәнлектәге тау кебек, бөтен яктан ап-ачык күренә. Мәүлиханың үз хәлен яшьлек дустына үз авызыннан белдерәсе килде. «Син Шәүкәтне ташлап калдырган дип миңа үпкәләмә, Булат. Ни кылыйм? Мин көчле адәм түгел икән шул, зәгыйфь мин... Әле бер баламны багу да кыенга килә. Үзең күрәсең, хуҗалык таркалган. Колхоз әз генә дә көч бирми. Былтыр налогларга, заем түләр өчен сыерымны сатып җибәрдем. Суеп сатсаң, күбрәк алырга да булыр иде, эче-башы үзебезгә калыр иде дигәндәй, аның артыннан кем йөри? Бер яктан җаным тынды. Усаллар йөри, сыер-сарыкларны чүпләп кенә торалар. Курмы юнәтү дә үтә читен иде бит, Булат... Сыерың булмасын, сарыкларың бетсен, аяксыз-кулсыз ирне алып кайтып яткырып ни кылмак кирәк? Аның тилмереп карап ятуыннан йөрәгең ярылып үләрсең. Анда ичмасам үз тиңе арасында әлләни җайсыз да түгелдер: сыйдырмасалар да сыясың. Менә син кайттың! Рәхмәт! Син дә кайтмасаң... мин алдагы көннәремдә ничек яшәр идем?»

Ишетә дә, ишетми дә Булат. Аңлый да, аңламый да яралы солдат. Ләкин ул Мәүлиханың, яшьлек дустының үзе өчен бик кадерле, бүгенгә бик кирәкле сүзләр әйткәненә төшенә. Өйләнеп байтак гомер итсә дә ул

Шәгъбикәнe берчакта да яратмады, юаш, сабыр егет белән үзенең үткәннәрен, шунда кылган гөнаһларын каплап кына кияүгә чыгуын тора-бара аңлады. Окопларда телләр чишелә, Булат колагы сау чакта тормышның байтак гыйбрәтләрен ишетте, ишеткән саен ул үзенең хәйләкәр Шәгъбикә кулында уенчык кына булуын аңлады. Йортына, Шәгъбикә янына телсез, өнсез кайтып керсә дә, аның күкрәге тулы пошаманлы серләр иде...

Ярый, Шәгъбикә бозык җан, авыл арасында тагын яман сүзләр, әшәке хәбәрләр таратырга сәбәп тә булсын ди... Ә аның Мәүлихасы... Сөйгән кешеннең гаеп-кыегын күрми башлыйсың, ул яшьтән йөрәгендә урын алган Мәүлиханың китек борынын да күрмәс дәрәҗәдә иде... Әмма ләкин... Әгәр Булат Шәүкәт урынында булса? Аяксыз-кулсыз җанын саклап бүген дә Омск госпиталендә кара кайгыга батып ятса?.. Ниләр уйлый икән Мәүлиханың ире? Әллә төзек уйлары бетеп, аның йөрәгендә ачу суы гына калганмы? Ачы су тулган җан белән ничек яшәмәк кирәк? Күрә ич ул, ишетә, сабырсызланып илдән хәбәрләр көтә торгандыр. Ил хәбәрләрен солдаттан да яхшырак аңлаган кеше була микән?

Булат шул көннән колхоз эшенә өзмәс катнашып китте. Сыер җигеп ызанга төште, сөрде, чәчте. Һәм ни сәбәптәндер икәүнең сукмаклары гел кисешеп килде. Юк җирдән дә Мәүлиха килеп чыга, каршысына арттан килеп җитә. Теле туктамый Мәүлиханың, ул Булатны сөйләшергә өйрәтә. Үткер күзле карчыга сыман төнлә дә Булатны күзеннән ычкындырмаган Шәгъбикә Мәүлиханың әрсезләнеп ире артыннан сөйрәлүен ишетмәде түгел, ишетте, үз күзләре белән дә күрде. Баштарак ваемсыз гына йөргән иде, Мәүлиханың өзми-куймый ире артыннан ауга чыгуын чамалап, бу эшләргә чик куярга булды. Сүз авыл арасына нык ук таралгач, Шәгъбикәнең көнчелеге килде. Тагын җитди бер сәбәбе бар иде хатынның: башта мөгрәп кенә сөйләшкәли башлаган Булатның теле ачылды, колагы да ишетә башлады. Һәм Булатны военкоматка чакырып исәпкә алып та куйдылар. Сугышның әле беткәне юк, шундый авыр контузия алган гарипне дә исемлеккә теркәп куйгач... хәлләр әлләкем булмагандыр шул!

Шәгъбикә Мәүлиханы ишегалдына чакырып чыгарды, тешен кысып көтеп алды. Мәүлиха баскычтан төшеп тә өлгермәде ул аның якасыннан элдерде. «Син,— дип ысылдады ул кара җылан булып,— әлегә танаусыз гына калган иден. Башсыз да каласың киләме?» Шәгъбикә чая усал, Мәүлиха исә усал чая. Ир бирмәк — җан бирмәк! Бигрәк тә ир бүлешергә дигәндә хатын-кызлар Нил крокодилына, чүл бүресенә әйләнәләр. Булды, тарткалаштылар хатыннар, куллар чәчкә барып җитте. Эш шуннан арыга узмады.

Дөрес, карлар китеп, Иртештә бозлар аккач Шәгъбикәнең тузанлы, нафталинлы, йомшак булса да тәнгә кадала торган ятагыннан качып Булат та лапас түбәсендә йокларга гадәтләнде. Таң алларыннан каяндыр кайтканын да күргәннәр, имеш, дип сөйләделәр сөйләвен, сугыш елларында иртәрәк котылып кайткан ир-ат турында ни генә сөйләмәде ул чактагы солдаткалар...

## 18

Адәм балалары ничаклы ач, ялангач булсалар да, яз килгәнен алдан ук сизәләр, зарыгып көтеп алалар. Яз кыш буе туңып, калтырап йомшарган ятим йөрәкләргә дә кагылмый калмый, күкрәктә яшерен өметләр уята.

Әле рәислек белән чиләнгән, рәислектән төшеп торган аралáрда авыл язмышы, адәм балаларының хәсрәте белән йокысыз калган Дәүләтшә әкә беренчеләрнең беренчесе булып Иртеш буена төшеп җитә. Яз исен сизәргә җәһәт малайлар, урам тутырып:

— Боз кузгалды, боз китә! — дип кычкыра-кычкыра чатыр чабып узалар икән. Яланның ил агасы булып җиткән Дәүләтшә әкәнең дә дәрте кузгала, ул кырпулы иске бүреген өскәрәк чөеп җибәрә дә артыш таягы белән җирнең ныклыгын сыный-сыный Иртеш ярына барып баса. Иртешне ничә айлар богаулап тоткан калын бозлар шатыр-шотыр ватылалар. «Ничәнче язың инде?» дигән сыман, баш очына эленгән тургайлар да җыр түгәләр. Бер-ике үсмер ботак-сатаклардан «кораб» ясаштырып, төтене ургылып чыксын өчен черек саламнарга ут төртеп, яр буеннан өзлексез агып торган бозларның берәвесенә «утыртып» җибәрергә дип маташалар. Балаларның кыланышын күргәч, бабайның малай чаклары хәтеренә төшә...

Хатыннар исә тулаем ирләре хакындагы хатирәләргә йотылганнар. Җәйләрдә талгын гына агып яткан Иртешнең сугыш башланган елларда котырынуын искә төшереп: «Ходаның кодрәте!» — дип куя картлар. Сугыш ачылган елларны Иртеш тәмам дилбегәдән ычкынды, ургылып, үкереп ярларыннан чыкты, болыннарны гына түгел, иген кырларын, мал йөртә торган калкурак җәйләүләрне дә су басты. Бик күп авыллар, Тубыл шәһәренең түбән өлеше су астында калды. Йортлар арасында колач-колач дулкыннар уйнап йөрде.

Быел Иртеш алай ярсып акмый... Теге елда сугыш башланасын сизенеп котырган Иртеш яңадан усалланып уянмасын берүк! Ходавәндәм! Кешеләр чарлакларга күчеп яшәделәр, өйдән-өйгә көймәләрдә йөрделәр, бүрәнә-такталардан саллар бәйләделәр. Күпләр өйләрен ташлап күчеп яшәделәр. Каракларга, яман адәмнәргә көн килде! Хуҗалар читтә куныш өйләренә кайтсалар — бар ризыкларын, кием-салымнарын чистартып куйганнар.

Тубыл кешеләре «Страховой акчасы», дип йөреп караганнар иде, кая ул,— кайсы ишекне каксалар да, борып кына чыгардылар...

Шулай да гомер-гомергә килгән Боз озату бәйрәме күңелләрне кузгаткан, хәле барлар Иртеш бозлары белән саубуллашырга төшеп җиткәннәр. Агымсуларга карап егет булып килгән, бер кышта кыяфәтләре, рәвешләре танымаслык булып үзгәргән егет-җилән ярсый, Иртеш буенда җыр агыла. Яшьләр арасында Сәрвәрнең моңлы тавышы аерылып тора. Ул башлаган җырны Миңнурый белән Мәүлия дә күтәреп алалар.

Карлыгачым, килдең мени,
Канатларың кагынып?—
Сөйгән ярым кайтыр микән,
Синең кебек сагынып...

Иртеш буена җыелган халык бүген арурак, матуррак киенергә тырышкан. Сандык төпләреннән аллы-гөлле яулыклар чыккан, күлмәкләр ямалган, юылган. Алай да киемнәрнең искелеге, таланган, өтәләнгән булуы күзне кисә. Көз көне яфракларын койган каенлыкта күпереп утырган чыршыдай, бер Шәгъбикә генә аерылып тора. Өстендә бик пөхтә зәңгәр күлмәк. Нинди материядән тегелгәнен Ялан хатыннары әйтеп бирерлек тә түгел. Аларның мондыйны моңарчы күргәннәре юк иде. Кызыл бәрхет камзул өстенә муенына купшы коерыклы төлке тиресен салган, башында елтыравык мех бүрек, аякларында тупый башлы, кара лаклы туфлиләр. Таза, тулы гәүдәсенә киемнәре бик ятышлы, байларча. Кысынкырак кара шомырт күзләр өстендә карлыгач канатыдай сызылып киткән нечкә кашлар, кояш нурларын чагылдырып елык-елык килеп торган ахак кашлы алкалар... Ул күкрәкләрен өскә чөеп, тәкәббер төс белән хатын-кыз төркеменнән читтәрәк бер ялгызы басып тора. Мәүлиханың анның тирәсенә якынрак барасы, ялгышлык белән дигән булып зәңгәр күлмәгенә, бәрхет камзулына пычрак чәчрәтәсе килә, әмма кат-кат юылып төсен җуйган күлмәк итәгенә, кыршылып калган җакетына карый да авыр көрсенә.

Бер Шәгъбикә генә төркемнән читтә, аерылып тора дип без бераз ялгышканбыз, ахрысы. Яулыгын чишеп муенына салган, ике калын толымын плащы өстенә яткырган Миңнурый Шәгъбикә шикелле масаймаган, киресенчә, аның гадәттә шат чыраена борчылу галәмәтләре чыккан. Дөресен әйткәндә, ул Иртештә боз китүгә дә ул хәтле куанмаган төсле. Иптәш кызлары Сәрвәр белән Мәүлиягә дә ияреп кенә елмая кебек. Дәү боз кантарлары ярга бәрелеп, вак-төяк кисәкләрне изеп, сытып, урталайга яргаланганда тау кыясы хәтле бозларга да исе китми, ул үзенең авыл ягына карап торуын, ара-тирә Иртешкә алып төшә торган тыкрык тирәләрен уравын бүтәннәргә сиздермәскә тырыша...

Кызлар аның беркемгә дә чыкмаган һәм чыкмас серен дә беләләр: ул бүген Ишморза Муллинны, НКВД капитанын көтә. Белә Миңнурый, аңлый: әгәр аның әнә шул җәза отряды капитаны белән танышып-белешеп йөргәнен туганнары ишетсә, дөнья куйган бабасына җиткерсәләр, мөэзин бабасы ләхетендә әйләнеп ятып, аны төрле сүзләр белән каргар төсле. Ләкин, язмыштан узмыш юк, берәү дә ахыр чиктә язмышын авызлыклап тота алмый, моңарчы мәхәббәт күбәләге кунмаган кызның күкрәгенә Ишморза Муллин, Казан тумасы ут яккан икән, кыз ни кыла алсын?.. Мәхәббәт — дөньядагы иң зур җимергеч көч, ул хәйләкәр үрмәкүч, җәтмәсенә бер эләктеңме, беттең!.. Ишморза юлын туры китереп тә, уравыч ерак юлларны якын китереп тә Ялан авылына кагылгалый башлады. Килә, Дәүләтшә әкәләрдә туктый, «хәл белешергә» дип, кызлар яшәп яткан йортның — Мөхәммәт Уразаевның тәрәзәсен кага. Миңнурый сизгер җан, ул егетнең ник килеп йөргәнен дә, оялып-читенсенеп килеп керүенең сәбәбен күптән белә.

Яз җилләре Ишморзаның шактый кырыс холкын да үзгәртеп ташлады. «Чана ташлаганчы, әйдә, бер тапкыр булса да тораны күреп кайт!» — дип, егет Миңнурыйны үзе белән алып китте. Сәрвәр белән Мәүлияне дә дәшкән иде егет, Ишморзаның әдәп өчен генә чакыруын аңлап, кызлар баш тарттылар. Ялан белән Тубыл арасы гашыйк сәяхәте булды. Ишморза белән Миңнурый сүзне бик ераклардан, ата-бабаларыннан башласалар да, мәхәббәттә аңлашу белән тәмамладылар. Ишморза капитан: «Яратам мин сине, Миңнурый, өзелеп сөям!» — диде. Күңелен сөенечнең сихри болытлары бизәгән кыз: «Мин дә!» — дигәнен сизми дә калды. «Мин дә!» — дип ычкындырды.

Кино карадылар алар, янәшә утырдылар. Соң гына төнге юлның матурлыгына сокланып, янәшә утырып Ялангa кайттылар. Егет кызны озатып куйды, үзе Дәүләтшә әкәләргә кунарга китте...

Бүген тагын очрашырга, боз китү бәйрәмен бергәләп карарга сүз куешканнар иде. Иртә-таңнан килеп җитәргә тиеш иде егет! Бүтән чакларда һәрчак вәгъдәсендә торган, килешүләрне бер минутка да бозмаган егетнең бәйрәм көнне килеп җитмәве серле дә, аянычлы да, куркыныч та иде. Яз җиттеме, урманнар җанлана, әмма кошлар гына кайтмый урман ешлыкларына, әллә кайлардан, әллә нинди шикле кешеләр агыла тайгага. Яз җитүне Ишморза үзенә бер төрле тетрәнү белән көтә иде. Тубылда булган хәлләр аның эшен ашыктырдылар, аңа бүтәнчәрәк юнәлеш бирделәр.

Алтын Мөгез тирәсендәге авылларның берсеннән, Н. йортларындагы агентларның берсе: «Мөхетдинов дигән аучы, өлкән яшьләрдәге кеше көзен, әле кырпак та төшмәгән чакта, Күчем ханның базлары дип саналган мәйданнан балчык чүлмәк табып кайткан. Чүлмәктә тимер беләзекләр сакланган икән, алары күгәреп-череп уалып беткән, ди. Ә астарак шактый мул алтын тәңкәләр килеп чыккан. Мөхетдинов алтын тәңкәләрне Төмән базарына барып сатып та кайткалый...» Хәбәр килүгә, НКВД егетләре Н. йортларына барып та җиттеләр. Мөхетдинов яшереп тормаган, эшне төкми-чәчми сөйләп тә биргән. «Бардым, дигән. Таптым,

дигән, тәңкәләрнең бишесен сатып та җибәрдем, дигән». Калган унике алтын тәңкәне НКВДга акт белән тапшырган Мөхетдинов.

Боларында берниндиндк гаҗәпләнерлек эш тә юк югын, гаҗәбе соңрак башлана. Хәзинә табылган участокка экспедиция оештырабыз, менә кар гына китсен, дип әзерләнеп ятканда алтын тәңкәләр юкка чыга. Сейфның ишеге ачылган, кәгазьләр, документлар һәммәсе исән, алтын тәңкәләр генә юк. Тәңкәләрне нәкъ шул көнне банкка тапшырырга тиеш булганнар. Алтын тәңкә Армиягә зур ярдәм буласы иде...

Иртән тәңкәләрнең югалуын ачыклыйлар, көн уртасында НКВД йортында ат караучы, урам себерүче булып эшләүче адәм да гаип була. Эшкә килми, бер көн юк бу, ике көн, өченче көнне эзләп фатирына барсалар (ул шәһәр читендәге ялгыз карчыкта яшәп ята иде!), эзе дә юк тегенең. Караватт астында почмаклары ашалып беткән иске чемоданы гына торып калган. Чемоданны ачалар, әлбәттә, кәгазьләрне НКВДга алып кайталар. Вак-төяк таушалган хатлар, ертылып беткән адреслар, әллә кемнең үлеме турында белешмә... һәм арадан тикшерүчеләрне кызыксындырырлак бер-ике бит кәгазь дә килеп чыга. Күчем хан хәзинәсе белән кызыксынган ич бу бәндә!..

Урам себерүче, ат караучы булып ялланган бу бәндә хакында моңа кадәр дә бер-ике хәбәр НКВДга кергән иде инде. Исемсез, чатлы-ботлы эре хәрефләр белән сызгаланган бу хатларда, урам себерүченең бөтенләйбөтенләй үзен белдергән кеше түгеллеге, аның элеккеге офицер Канталыев булу ихтималын искәртелгән иде. Сугыш бара, ил һәркөн яңа солдатлар сорый. Күпләр фронтка бармас өчен мең хәйлә табалар, керосин эчәләр, тәмәке суы белән тончыгып, ашказаннарын агулап илдә калырга тырышалар, врачларга ришвәт китерәләр. Каз-үрдәк кенә түгел, затлы Иртеш балыкларын да азсыналар. Т. авылыннан военкомат хуҗаларына тоташ бер поши түшкәсе китереп биргәннәр. Ике атна гына элек ыжгырып барган поездлан өч кеше төшеп калган. Төшеп тә калганнар, югалганнар да. Колактан колакка күчеп йөргән хәбәрләргә таянсаң, аларның да шушы Тубыл тайгаларына чумуы бик ихтимал икән. Кемне эзләп табып өлгерәсең дә, кайлардан тотып ипкә китерәсең? Урам себерүче хакында килгән хәбәр бер мәлгә НКВД хәдимнәрен тирләтеп алган да, онытылган. Инде сейфтан алтын тәңкәләр югалгач, НКВДга сыенып яшәгән бәндә дә чыгып югалгач... һәммәсе җепкә тезгәндәй ачылып китте. Инде караватт астындагы иске чемодан да телгә килгәч, милициядәгеләр бот чаптылар. Шул! Үзе! Канталыев.

Шушы эшләр тирәсендә барган ыгы-зыгылар, ялгыш-хаталар, үкенечләр һәммәсе Ишморза Муллин өстенә төшкәч, ул, ашавын да онытып, йокысызлыктан кызарып шешенгән күз кабакларын үтә салкын су белән «дәвалый» да эшенә чыгып чаба, төнлә-төнлә авылларга да барып житә. Гасабилануыннан, йокысызлыктан яралары сызлый. Ләкин зарлана белми иде Ишморза, ул үзе тотынган эшне җиренә җиткерергә тырыша иде. Һәм аның кулында шактый кызыклы мәгълүматләр дә җыелып килә иде. Ул да ярсып-кызып быелның язын көтә иде. Яз аңа күп нәрсәләр китерергә тиеш иде. Беренчедән, Миңнурый белән алмашып тормыш корырга уйлый иде ул! Әгәр хатыны булса, аның тормыш шартларын җиңеләйтер иде ул. Миңнурый кебек уңган, аңлы кыз фикер, уй җәһәтеннән дә һәрчак ярдәмгә килер иде... Ялан авылына барып боз озатканда алар бүген үзләренең төп мәсьәләсен хәл итәргә, киләчәккә юллар сызып та куярга тиешләр иде.

Ишморза никадәр сак, җиде уйлап бер генә кисә торган егет булса да, ул үз дошманнарының никадәр хәйләкәр, мәкерле икәнен күз алдына да китереп бетерә алмый иде. Мәсәлән, кем уйлаган, Ялан халкы сөенеп, шатланып боз кантарларын боз диңгезенә озатып мавыкканда Чырык Абдрахманның мунчасында ике кеше качып утырыр дип, кем күз алдына китергән? Бу ике кеше язгы төннең караңгылыгыннан, авыл кешеләренең

кичләрен чыгып йөрмәвеннән файдаланып, курыкмыйча Чырыкның мунчасына кереп югалдылар. Мунча байтактан ягылмаган. Чырык күршекүләннәргә юынырга йөри, бер үзенә утын әрәм итеп тормый, су ташып та мәшәкатьләнми...

Миша Сорокин белән Канталыевның байтактан күзгә күз очрашып сөйләшкәннәре юк иде инде. Кыш — очрашулар өчен җайсыз чак! Шулай да бер очрашып алырга, кар китеп кар-урманнар ачылуга, тагын бер талпынып алырга иде аларның исәпләре. Канталыев алтын тәңкәләр турында бер дә авыз ачасы түгел иде, дәшмичә кала алмады. Хан хәзинәсе барлыгына шикләнә башлаган Сорокинны ни белән булса да өметләндерергә, кузгатырга, җим салырга кирәк иде. Алтын елтыравын күргәндә Колгасарның күзләрендә яшен уйнап алса да, тәңкәләрнең каян табылганын ишеткәч, ул чак кына Канталыевны буып ташламады.

— Син — дурак,— диде ул куе төкереген чәчеп,— син шыр тиле! Шушы тәңкәләрне урлап эшне бозып ташлагансың. Беләм, тәңкәләрне күрсәтеп син миңа хәзинәнең барлыгын расларга телисең. Әллә НКВДда туң күчәннәр генә утыра дип беләсеңме? Муллин дигән капитан килгән анда. Тешләгән җиреннән өзә, диләр. Хәзер алар да хәзинә барлыгына ышанып эзләүләрен көчәйтәчәкләр. Алтын тәңкә карагының да шушы тирәдән еракта йөрмәячәген белеп, бөтен юлларга капкын салачаклар! Син бөтен эшне боздың!

Канталыевның йөрәге ярсу, аның шушы газаплы, мәшәкатьле гомерендә беркемнең дә аны шушы кадәр сүккәне, түбәнсеткәне юк иде. Ул көчкә түзеп утырды, сикереп-сикереп торып кулларын болгады, әмма Сорокинның явыз тавышы, мунча караңгылыгында да кискен зәһәр күз карашлары, аны тыеп калды. Чалбар каешы астына кыстырылган наганына да эш барып җитмәде. Әллә нинди эшләр иде Канталыев, җанын алыр иде өтек офицерның, бүгенгә көч Сорокинда. Оешкан отряды бар, чарасыз калган дизертирлар өчен әлегә ул хуҗа, корал да аларда. Ә Күчем хәзинәсен сазлык-урманнар авызыннан бер үзең эзләп кара! Табарсың бик!

Сорокин бу очрашуга ныклы план белән килгән иде: Мөхетдиновны һич кичекмәстән эзләп табарга, бугазыннан алып алтын тәңкәләр табылган урынга алып барырга!..

Йомабикә абыстайның җылы почмагында посып ятканда аның уйлары туктауны белмиләр иде. «Хәзинә табылган сәгатьтә үк бу тирәләрдән юк булырга! Отрядтан ялгыз гына чыгып китүе авыр булыр дигәндә... иптәшкә бер Канталыевны гына ияртергә! Аны да юлда юк итәргә!»

Аның тизрәк бу тирәләрдән чыгып чабасы, ил киңлегендә югаласы килә иде. Ләкин бүгенге тартыш әле башланган гына икән... Һич көтмәгәндә Канталыев тагын бер шарт куйды. «Хәзинә табылган очракта Көнбатышка барып тормыйбыз». «Кая барасың ди инде син? Японнар ягына чыгарсыңмы?» «Нигә японнарга? — диде Канталыев тыныч кына.— Көньякка китәбез. Телисең икән Әфганстан, теләсең Һиндстан, Иран да ярап тора! Анда халык күп, шәһәрләрдә мәңгегә югалырга була. Малың гына булсын, анда яшәргә ярый!» Урыс тәрбиясен күргән Михаил Сорокинны Канталыев телгә алган илләр бер дә тартмый иде. «Борчакандала ашатып, корчангыдан шатыр-шотыр кашынып яшәргәме?» — диде ул, ни уйлаганын яшереп тә тормастан.

Башта ук ызгышырга, талашырга торган ахирләр тора-бара бөтенләй чыгырдан ычкындылар, мунча «җиһазлары» — тоткасыз чиләкләр оча башлады, корым коелды. Җил-давыл тынган арада Сорокинның кычкырып көлгәне ишетелде, Канталыев аңа шикләнеп карап куйды, чалбар каешына кысылып хуҗасын җылытып торган наганын капшады.

«Дураклар без,— диде Сорокин,— син генә түгел, мин дә дурак. Атылмаган аюның тиресен бүлешеп ятабыз!»

Бер башыңны «җүләр» дип атасалар, һәркемнең ачуы чыга, иллә мәгәр сөйләшүчеләр икәү булганда һәм очрашуның азагында икенче дә шул мәңге онытылмаслык сүз белән атыйлар икән, моның файдасы да бар, мунчада кызып килгән «сугыш» тукталды, ахириләр Чырык пешереп керткән кабыклы бәрәңгегә ташландылар...

## 19

Миннурый белән Ишморза ул көнне күрешә алмадылар. Язмыш аларны алдагы көннәрдә дә очраштырмады, икесе ике җирдә, Сак-Сок булып җан атып яшәп тордылар.

Капитан Ишморза Муллин бу көннәрдә Ташкәйне, Йомабикә бичәнең моңарчы дөньяга игелек күрсәтмәгән улын да исеннән чыгармады.

Таза, көчле, шактый елгыр егетне зонада күргәч, аның уенда бер план йомарланды. Иксез-чиксез тайга урманнарына таралып яшеренгән качкыннарны вакыт-вакыт ясалган обловалар белән генә тоту мөмкин булмаган эш иде. Һәр качкын — печән арасына төшеп югалган инә ул, эзлә, тап син аны! Бигрәк тә Сорокин кебек тәҗрибәле отряд командиры, берничә адәмнең җанын кыйган куркыныч бандит, андый җәтмәләрдән шаярып та чыгып котыла ала. «Батыр йөрәкле, куркусыз, тәвәккәл, кансыз, усал һәм явыз». НКВДда саклана торган «Дело»сында аңа шундый бәя биргәннәр. Ишморза белә, дошман хәйләкәр икән, син аннан битәр биш хәйләкәр, биш тапкыр көчлерәк һәм уяурак булырга тиешсең. Яшермик, Ишморза үзен батыр да, акыллы хәйләкәр дә дип исәпли иде.

Әйткәнебезчә, Ташкәй белән күрешүдән соң ук ул үзе уйлаганын тормышка ашырырга кереште, ул Ташкәйнең төрмәдән качыруын оештырып аны Сорокин отрядына «сеңдерергә» тели иде. Эшнең ифрат авыр, катлаулы икәнен тулысынча аңлап керешге Муллин. Барыннан да әүвәл НКВД начальнигы шактый тар маңгайлы Лапиковны ышандырырга, аны шушы эшкә «тартырга» кирәк иде. Аның катнашыннан, аның хәер-фатихасыннан башка бу, моңарчы сыналмаган четерекле эшкә алынырга да ярамый иде. Ишморзаның алдан ук шикләнүе хакка барып чыкты: Лапиков тыңлап та бетермәде, кул-аягы белән каршы төште, Ишморзаны ике сүзе белән егып салды.

— Мине трибуналга тапшырасың киләме? Үзеңнең бетүеңне әйтеп тә тормыйм. Бүтәннәргә әйтә күрмә, тавыклар егылып көләр!

Муллин Лапиковның үзен өлкәдә иң әзерлекле һәм мәшһүр начальник итеп санавын, бер-бер йомышлары төшкәндә Лапиков кул астындагы күпләрнең, начальникларының йомшак ягыннан оста гына файдалануларын да чамалап килә иде. Ул әллә кая чәчелмәде, шушы «аргамакны иярләргә» булды.

— Глеб Иванович! — диде ул үтә хәйләсез төс белән. — Беләм, ышанам, өлкәдә сездән дә тәҗрибәле, сездән дә куркусыз милиция командиры юк. Сезне өлкә белә, өлкә таный! Мин дә, сезне хөрмәтләүче кеше буларак, сезнең данга яңа төсләр бирмәкче булам. Кайчанга кадәр без урман бандитларына районга хуҗа булып яшәргә ирек бирәбез? Көпәкөндез сейфтан алтынны урлап чыктылар! Бу безгә дан өстәми, моның күләгәсе сезгә дә төшә. Монда уйлап эшләргә кирәклеген хәтеремнән чыгармыйм, әмма зур тәвәккәллек тә сорала монда, Глеб Иванович! Белүемчә, сез кыю да, тәвәккәл дә...

Иплəп кенә сүз башлаган иде Ишморза, бара торгач кыюланып та китте, тавышында ышаныч авазлары күбәйде, Лапиков бераз икеләнде. Ишморза, бандитлар тотыла калган очракта Глеб Ивановичның даны өлкә чикләреннән дә үтеп чыгып, Мәскәүгә барып җитәсен дә сүз арасына керткәч, Муллин әзерләнгән «кандидат» белән Лапиков кызыксына башлады.

Ташкәйнең җирле халык вәкиле, татар булуы аңа ошады, егетнең яшьлеге, дуамаллыгы һәм «мәхәббәт аркасында» гына төрмәгә элəгүе аны йомшартып җибәрде. Лапиков үзен ир-атларның бөркете дип саный, чын гыйшык дигәндә баш югалтырга да әзер икәнлеген үзара сөйләшкәннәрдә телгә кыстыра иде.

— Инде егетнең үзе белән сөйләшеп карарга рөхсәт итегез,— диде Муллин, Глеб Иванович Лапиковка кат-кат рәхмәт әйтеп.

— Ялан авылында аның әнкәсе яши, алай-болай булса, әнкәсен дә харап итәчәген аңлатырмын мин аңа,— диде.

Ташкәй белән сөйләшү НКВД начальнигы белән аңлашуга караганда да авыррак булды. Ике елдан артыграк зонада яшәп, тормыш тәҗрибәсе ныгыган, акны-карадан аерырга әзер торган егет, ярсу ат кебек чыгымчыларга, тәртәгә тибәргә тотынды.

— Гаепнең берсен ясадым, үкенмим, теге мөртәт җәзасын алды. Кылган гамәлемә сөенмим дә. Ул... әле дә күз алдымда тора! Мин аның шәүләсеннән ничек котылырга белмим. Минем янга килеп киткәч, монда чакыртып кайтаргач, әллә сез миңа яхшылык телисезме дип өметләнгән идем. Ә сез мине тагын да ныграк батырырга телисез икән. Юк-барны чәйнәп утырганчы сез миңа фронтка китәргә ярдәм итегез! Штрафной батальоннар бар икән. Сугыш беткәләгәнче шунда барып өлгерергә кирәк миңа. Сугышырга, исемемне акларга!

Ташкәйнең ярты сүздән аның тәкъдимен ашык-пошык кабул итмәвенә, ныклыгына, сүз сөрешенең төгәллегенә сокланып Ишморза һәм очраклы диярлек сайланган «кандидатурасының» ышанычлы, төпле булуын күреп сөенде.

Бер очраштылар алар, ике, тәүге очрашуларда Ташкәй күбрәк сөйләп, Муллин ул сөйләгәннәрне үлчәүгә салып, җаваплар әзерләбрәк утыра иде. Егет күңеленә килгәннәрне әйтеп бетерде, озак бәхәсләрдән, исбатлаулардан соң, Муллинның тәкъдимен кабул итеп «төрмәдән качкан кеше» булып качкыннар арасына вакытлыча «сеңергә» ризалыгын бирде.

— Хәвефле, хәтәр эшнең ни белән бетәчәген дә әйтеп булмый! «Бандитларны тоттырып исән калсаң, сине акларга тырышып карарбыз. Һич югында без сине фронтка озатачакбыз! Бусына шикләнмә!» — диде Муллин.

Зонадан качу версиясенең төрләрен, юл-сукмакларны, Ташкәйнең кая барырга тиешлеген, барысын да җентекләп өйрәнделәр, кат-кат кабатладылар. Ахыр чиктә Ташкәй соңгы теләге барлыгын белдерде:

— Әнкәй янына кагылып чыгыйм бер! — диде ул.— Сагындым! Аннан ары күрешеп буламы, юкмы... Әнкәй бит!..

Ишморза бу тәкъдимгә дә каршы килмәде, шулай килешенделәр: Ташкәй кичен караңгы төшкәч Яланга кайтып керде. Ул Төрмәдән качуын яшереп тормый. «Әзрәк баш-күз алгач, документлар юнәткәч фронтка китәчәкмен»,— дип белдерде. Таңнан чыгып югалды...

«Бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына!» — дип татарлар дөрес әйткән! Шулай булып чыкты да. Ташкәйнең берочтан Сәрвәрне дә күрәсе килә иде. Монысын ул Ишморзага әйтеп тә тормады. Күрәчәк ул Сәрвәрне, күрәчәк!

Ташкәйне Күбек чикләвеге дигән җиргә — шулай дип аталган урман аланлыгына чаптар атта китереп җиткерделәр.

— Моннан ары җәяүлисең,— диде озата килгән Ишморза Муллин. Сыңар күзле милиционер, мин дә сүзсез калмыйм инде дигәндәй, әйтеп куйды:

— Самай кызлар урлый гына торган төн!

Сыңар күз Ишморзаның нинди йомыш белән йөрүен дә, нигә монда урман ешлыгында юлаучыны төшереп калдыруларын да белми, әмма беләсе килә иде! Тик аның сүзенә колак салучы булмады, ул дилбегәсен беләгенә урап атны кирегә борды. Ишморза: «Бер чыккан килеш әллә

Яланга барып Миннурыйны күреп чыгаргамы?» — дип уйлап алды да, кулын гына селкеде. Ялан авылына Ташкәй юл тотканда, ул тирәдә күренеп йөрергә ярамый, һич ярамый иде.

Юл коры һәм тигез диярлек иде. Соңгы яз-җәйләрен зонада, төрмә камераларында үткәргән, тын җитмәүдән, яктылык юктан җәфа чиккән Ташкәй баравык җәяү теркелдәде дә җан-фәрманга йөгерә башлады. Урманны йөгереп үтте, кырга чыккач күкрәгенә сыймаган йөрәгенең дөп-дөп какканын тыңлап торды. Төгәл итеп Көнчыгышны эзләп тапты, сүрән шәфак утлары ярдәмендә кояш чыгар офыкны төгәл билгеләде. Юлы ачыклангач кызу-кызу атлап китте.

Ул соңгы озын үрне йөгереп төште, авылга керәм дигәндә туктап калды: «Туп-туры өйгә кайтыргамы, әллә Сәрвәр янына кагылыргамы?» — дип уйлады. «Өйгә, өйгә!» — дип каулады аны ашкынган күңеле.

Капка эчтән бикләнгән иде, ул инен терәп ачарга тырышып карады, капка бирешмәде. Ташкәй озын-озак уйлап тормады, кушаяклап сикереп ике куллап койма баганасына ябышты, өскә менеп атланды, як-ягына каранып бераз торгач ишегалдына сикереп төште.

Михаил Сорокин бүген Йомабикә абыстайларда кунып ята иде. Юк, Йомабикәнең мыймылдык тәне дә, бодай камырыннан изгән ап-ак йомшак беләкләре дә чакырып китермәгән иде аны, Михаил нык кына авырый иде. Кышын дымлы урман землянкаларында аунап ул быел чиргә тарыган иде. Бөтен тәнен чуан басты Колгасарның, утырып торыр әмәле калмады, олы йомышка кысталганда агачка ябышып чүгәләп кенә торды. Барыннан да бигрәк ютәл җәфалады урысны. Качкынның юлдашы — тынлык, кая таба атласа да ул атлардан элек аяк астын тикшерә, ялгыз яткан ботакны сындырып нәни генә тавыш чыгарса да качкынның йөрәге дертләп китә. Качкын — куркак куянның юлдашы ул. Саклыкка өйрәнгән Колгасарның хәле яман, корык-корык ютәлли, үпкәсе авызына менеп җитә, кан төкерә.

Йомабикә абыстайның күңеле бу араларда әйле-шәйле, күзенә әллә ниләр күренә, колагына ерактан яңгырап шомлы тавышлар килеп ирешә, тамагы нечкәрде — су да үтми. Колгасарны идән почмагына аркасын терәгән себеркене селкеп куды ул, кертмәскә тырышты.

— Башың беткере! — дип ачыктан ачык зарланды, карганды. — Бетерәсең башкайларымны! Хәзер көннәр җылы, кешеләр өйдә генә утырмый, көнгә чыгалар, күрше-каршыга керәләр. Берәрсе керсә? Күреп калса?.. Синең аю өнендә ята-ята да сеңгән исең ярты чакрымга сизеләдер әле, мәлгунь...

— Бер генә төнгә! — диде Колгасар һәм кесәсеннән ярты шешә самогон чыгарды. Эчте, ни бар — шуны ашады, югын таптырмады, җылы су белән аякларын юды, каен күмере белән казык-казык озын тешләрен чистартты һәм мич башына җылыга менеп ауды.

— Яктырганчы уятырсың! — дип мыгырдады.

Йомабикә абыстай бүген йокыны көтеп ала алмады, килмәде аңа бүген йокы, як-ягына мең кат зыр-зыр әйләнгәләп, уйларның төрледән төрлесен күңеленә китереп, яшьли ятлаган догаларын кабатлап онытырга тырышса да, теләге кабул булмады. Уйларының да төгәллеге, азагы юк иде бичара хатынның. Үткәннәрен уйлап юансынмы, Ырсытдин белән бергә, ир белән хатын булган булып торган чакларыннан сөенечләр эзләсенме, бүгенгеләрне күз алдына китереп сөенсенме?.. Ире гүрдә, күңеленең бердәнбер якты йолдызы Уразай-мөгаллим сугышта, улы Ташкәй төрмәдә, кеше үтерүче, кызы Мәүлия әткәсе йортын ташлап чыгып, чит бусагада яшәп ята. Авыл арасында бу хакта йөргән имешмимешләрне ишеттерәләр Йомабикәгә, нык ишеттерәләр. Әгәр сорасалар, бүгенге дәвердә ни уйлап, ни-нәрсәгә өметләнеп яшәгәнен Йомабикә анык кына әйтә дә алмас иде.

Болганчык, шөбһәле уйларны читкә куып кинәт кенә башына бер уй кисәге иңде: «Үтерергә кирәк бу мөртәтне! Юк итәргә! Ул булмаса, ичмасам, тынычрак яшәр иде ич!.. Чырык белән киңәшергә дә, аннан бер-бер агулы үлән алып Колгасарның самогонына салырга... котылырга, котылырга! Шушы баш бәласеннән котыла калса... котылса...» Намазлыкта оеп, кыйблага карап кына яшәр иде Ырсытдин бичәсе. Берәүгә дә кырын караш ташламас, ялгыш сүз ычкындырмас, Мәүлияне үз янына алып кайтыр, аның сүзеннән чыкмас... Раббем Алла, нигә шул дөрес якка борып җибәрмисең Йомабикәнең тормышын?..

Капкага кагылганнарын ишетте Йомабикә, тирә-як, урам-тыкырыклар тып-тын иде. Беренчесе: «Әллә теге явызны алырга милиция килеп җиттеме?» — дигән уй булды. Тик, капканы какмадылар, келәсен бер-ике күтәрделәр дә төшерделәр. Колгасар Сорокин өйгә керер алдыннан капка-коймаларны ныгытып тикшереп, күздән үткәргәч кенә өйгә уза иде...

Койма тирәсендә нидер чыжтырдады, ышкылып китте. Йомабикә торып утырды, каршы күршеләренең Алабае абалап өрә башлады. Бутәнчәрәк итеп, ятлар барын сизгәндәй өрә иде эт бүген. Кемнеңдер койма аша сикергәнен дә чамалады сак колаклы тол бичә. Ул ябынган корама юрганын бер якка атып бәрде, табаннарын куырып алган суык идәнгә яланаяк төшеп басты. Ул чап-чаҺ басып, саклыкны онытып, ишеккә таба атлады, колагын куеп тыңлана башлады. Тыелып кына кактылар, алай да Йомабикә оялды аша тышкы ишеккә бер генә сикерде...

Гадәттәгечә «Кем йөри анда?» дип сорамады, «теге бәндә ишектә кеше барын ишетте микән?» дип уйларга өлгерде дә келәне күтәрде.

Йомабикә белән Ташкәй бер-берсен тиз таныдылар.

— Улым, балам! — дип кычкырып җибәрде Йомабикә һәм улын кочагына алырга теләде. Ташкәй кочакка сыймады, ул нинди дулкынландыргыч вакыт булса да, ишекне бикләп керергә кирәклеген онытмады, келәне элде һәм әнисенең иңнәреннән тотып өйгә алып керде.

— Улым, улым!

Ташкәй каядыр ашыккан кебек, тиз-тиз чишенде, киемнәрен дә яшь чагындагы кебек анда-монда ыргытмады, һәрберсен тикшереп-барлап, таслап мич янындагы сәкегә тезеп салды. Ул арада Йомабикә казан астындагы күмергә чыра элдереп куыксыз лампага ут кабызды, лампаны сул кулына күтәреп, улының йөзенә карады. Ташкәй танымаслык булып үзгәргән иде. Аулак урам чирәмедәй куе сакалымы аны шулай үзгәрткән, җилкәләре җәелеп аңа шундый өлкәнлек төсе керткәнме?..

Ул арада Ташкәй күнегелгән урынга, мич арасына кереп, шалтыршолтыр килеп бит-күзен юып алды, әйләнеп чыкканда әнкәсе лампаны өстәлгә утыртып көйләп маташа иде. Өстәл уртасында кукыраеп утырган шешәне һәм шешә күләгәсенә кереп поскан сапсыз чәшкәне күреп, Ташкәй атлаган җиреннән шып туктап калды. Йомабикә моның сәбәбен аңышмады. Ул өзгәләнеп:

— Ничекләр кайтасы иттең, улым. Амнистия мазар булмагандыр бит? — дип сорады. Ташкәй сорауга каршы үз соравын бирде:

— Ашарга бирәр нәрсәң бармы? — диде.

— Улым, балам, кайтасыңны белмәдем шул. Күңелем нидер сизде мәгәр иләсләнде. Бераз көтәрсең инде, хәзер бәрәңге пешерәм!

— Кабыклы булсын бәрәңгең, — диде Ташкәй һәм өстәл янына килеп утыргач, сапсыз чәшкәне кулына алды, иснәде һәм тәрәзә төбенә илтеп куйды.

— Ничекләр чыгардылар, балам!? — дип сорады тагын бер кат Йомабикә.

— Мин әни төрмәдән качып чыктым.

Мич башыннан сак кыштырдаган тавыш килде, Йомабикә коты чыгып улына карады. Шулай, текәлгән килеш, авызы ачык килеш катып калды.

— Мәүлияне ник уятмыйсың? — диде Ташкәй мич башына ишарәләп. Йомабикә улының бу соравын ишетмәде, аның аңын, утын Ташкәйнең баягы сүзе биләгән иде.

— Ничек алай качып? Качып, үләт, эт күтенә бармакчы буласыңмы? Тагын тотып ябарлар да төрмәнең ныграгына, качалмаслыгына бикләп куярлар. Ай, улым, ай, балам! Хаталык кылгансың, гуй.

Йомабикә инде исенә килде, Ырсытдиннең төсе итеп тота торган үткер пычагы белән бәрәңгеләрне әрчемичә генә, урталайга ярып, кайнап чыгарга күбекләнгән суга төшерә торды, теле һаман бер үк сүзләрне кабатлады.

Мич башында калын итеп ирләрчә ютәлләделәр. Ташкәй сикереп торды, әнкәсе кулыннан үткер пычакны тартып алды.

— Анда... Мәүлия түгелмени? — дип сорады.

Йомабикә башын чайкады, бөтен гәүдәсе дер-дер калтырады.

— Юлаучы ул. Туңган бичара, чирле дә икән үзе. Бик ялынып сорагач, кунарга керттем үзен.

«Минем арттан күзәтергә НКВД җибәргән, мөгаен!» — дип уйлады Ташкәй һәм пычагын кулыннан ычкындырмыйча гына гөлмәчкә керде, мич башы караңгылыгына карап карлыккан усал тавыш белән:

— А ну, фраер! Топай сюда! Топай, топай! — дип кычкырды.

Юк, бу карачкының НКВД кешесе булуы мөмкин түгел, җилдә дә селкенерлек арык гәүдә, ач яңакларга сырышып ябышкан сакал учмалары, эчке кием-салымнарының өтәләнгән, таланган булулары... хәерчеме?.. Мич башыннан төшкән өрәк сүз әйтергә өлгермәде, Ташкәй бу йортның хуҗасы булуын сиздереп:

— Утыр да сөйләп бир әле: ник безнең йортның капкасын кактың да, сиңа монда ни кирәк? — дип сорады.

Татар урманнарында качып ятмаса, татар илендә яшәмәсә, Сорокин бу кискен сораулардан каушап-җебеп тә төшәр иде, әмма ул Ташкәйнең төрмәдә утыруын Йомабикә бичә авызыннан кат-кат ишеткән, хәбәрдар кеше иде. Шуның өстенә ул Ташкәйнең ап-ачык итеп, авыз тутырып, хәтта бераз мактаныбрак та: «Мин төрмәдән качып чыктым!» — дигән сүзләрен ишетеп калган иде. Аның каушавы бер минуттан үтте, ул ишек катында эленеп торган кыптыр тун кесәсеннән бер шешә самогон алып килде һәм, монда Ташкәй түгел, ул — качкыннар отрядының командиры Михаил Сорокин хуҗа икәнлеген сиздереп, Ташкәйне ризык бүлешергә чакырды. Бераздан, шешәдәге саргылт суны киметә төшкәч (әлбәттә Ташкәй эчмәде, иренен тидереп тә карамады! Бу хакта аны Ишморза Муллин кат-кат кисәткән иде: «Беркем белән дә, беркайда да аракыны кабул итмәскә! Акылны югалтмаска!» — дигән иде ул. Кайткан төнендә үк аракыга баш биреп үз ирке белән башын җәллад бүкәненә салмас инде, яшәргә ниятләп — төрмәдән чыга алган егет!)

Сорокин болай диде:

— Бу йорт түрендә генә түгел, тирә-як урманнарына да хуҗа булырмын мин!

Эченнән куанса да, Ташкәй аны-моны сиздермәде, алар, сәер кунак белән ары-бире сүз алышып, бер-берсен кытыклап-тикшереп байтак утырдылар...

Таң яралганда Йомабикә кунакларны озатып калды. Кеше аягы кузгалганчы Яланнан чыгып югалырга кирәк иде аларга.

Ташкәй бик теләсә дә, бавыры ташыса да, Сәрвәр сылу яшәгән йортка кагыла алмады, мөгаллимә кызга бер-бер авырлык китерермен, дип курыкты.

## 20

Гыйззәтбану түти Ялан авылының иң абруйлы, колхоз эшенә иң күп көч куйган, эшлекле, ашка-суга шактый оста хатыннарның берсе иде. Юк, «холкы тигез иде аның, сабыр иде!» дип әйтергә җыенмыйм! Күкерт кебек дерт иткән чаклары да бар иде аның, өй өчен, ирен, балаларын туздырып буран куптарган мәлләре дә аз булмады. Җыеннарда, авыл җыелышларында булыр-булмас ир-атларның якаларыннан сөйрәп сәхнәдән өреп төшерүче дә ул иде. Кыскасы, замана хатыннарына нинди сыйфатлар хас дигәндә, Гыйззәтбану түтидә шуларның һәммәсе дә җитәрлек вә хәттин ашкан иде.

Сугыш аның да кикриген шиңдерде, койрыгына басты, юашлануын юашланмады безнең тутабыз, әмма ләкин кояш баеган мәлләрдә тәрәзәгә багып, бер кулы белән яңагына таянып, онытылып утырган хатын элеккеге Гыйззәтбану түгел иде, түгел!

Анау елда, язгы кыр эшләрендә, алты хатынны җигеп, сука башына ябышып җир сөреп йөргән көннәр тәмамысы җиргә бөкте хатынны, чая хатынны! Эштән кайтып, юынып-аруланып алды да урынга ауды. Чәй кайнатырлык та хәле калмый Гыйззәтбану түтинең. Хәер, аның чәе дә инде, урман-болыннардан җыйган үлән, чәчкә тамырларыннан кайнаткан чәй, ни мактасаң да, сәйлүн чәйләренә җитми инде. Чәй димәктән, Яланда, авыл арасында чәй табарга була, әллә ниндиләрен сата йөзе кара Шәгъбикә, ләкин алты хатын җигеп җир сукаласаң да колхоз чәй сатып алырлык та сәрмия бирә алмый шул...

Көне-сәгате килеп җитте, быел хатыннарның сукага җигелерлек хәлләре беткән иде инде. Арыкландылар, тәннәрендә карга чукырлык та ит калмады...

Апрельгә кергәч үк Дәүләтшә әкә Гыйззәтбану тирәсендә юргалый башлады. Килеп керә дә, теленә май ягып, сүзләренә бал кушып, Гыйззәтбану түтинең йөрәген кузгата торган уйларга барып ябыша.

— Йосыфыңнан хат килгән икән, ишеттем, ишеттем! Шөкер Ходайга! Сугыш бер бетәр, бетми калмас. Хода кушып, сугыштан соңгы җиңеллекләр килсә, Сәгъдетдинең дә кайтып төшсә... И, ни бит әле, улыңның хаты Мәүлиягә дә килгән икән! Куандым, нык куандым! Мәүлия уңган бала. Берзаман шаулап-гөрләп килен төшерәселәр бар әле. Насыйп булса, башкода булып түрегездә үзем утырырмын. Хәзер ни, Себердәге татар йолаларын белүчеләр дә күп калмагандыр инде. Сәгъдетдиннән хат-хәбәр киләме?..

Сандугач булып сайраган рәис Гыйззәтбану түтине тәмам эретә, ул һич читенсенмичә балавыз сыга башлый. Тагын нидер сөйләшәләр, кемнәрнең ничек яшәүләрен тикшереп чыгалар, Дәүләтшә әкәнең сүзе һич бетми, сыерын карарга, аңа җылымса су эчерергә бик вакыт, анда да сүзе бетми бал авызлы рәиснең, хуҗабикәгә ияреп абзарга да чыга, Гыйззәтбануның терәге, ярдәмчесе, өмете булган куәс имиле кола сыерның муенын кашып иркәләп тора. Сыерга нәрсә, ул да йомшак күңелле кешегә таба сузып, телен чыгарып аның кулын ялый. Соңгы керүләрендә Дәүләтшә әкә сәеррәк сүзләр дә ычкындыра башлады:

— Язга чыгып барабыз... Бөтен җирләрне сөреп-чәчеп булмаса да, җиркәйне бөтенләй үк мәхрүм итеп булмас. Булат белән килешендек, ул һәр эшнең әмәлен белә, сыерларны сукага җикми булмас, сбруйлар хәстәрли башларга диебрәк торабыз.

Гыйззәтбану ишетә ишетүен, мәгънәсенең тирәнлегенә генә төшенеп җитә алмый. «Сыерлар җигәргә»,— ди рәис. Сүз Гыйззәтбану түтинең авылда иң сөтләч, иң уңган сыеры турында бармыйдыр ич?.. Юк, юк, рәис ярты чакрымнан эре кабыргалары күренеп торган, кәҗә хәтле дә сөт бирә алмаган хайваннар турында сөйлидер. Аларны ни, җиксәң ни дә, җикмәсәң ни!

Кашлак урыннарда җир кибеп эшкә керешәбез, дигән сүзләр тарал-ганда, Дәүләтшә әкә тагын килеп керде боларга. Рәис кадәр рәис бригадиры Сәлимәне үк ияртеп кергәч, Гыйззәтбану түти коелып инде. Керүчеләрнең төксе чырае болай да күп нәрсәне белдерә иде, инде сүзләрен дә ишеткәч, Гыйззәтбану түти шап итеп артына утырды.

Дәүләтшә белән Сәлимә Гыйззәтбану түтине кодаларга, сыерын жи-геп сабанга чыгарга үгетләргә кергәннәр икән. Имеш, сыер муенына яраклы камыт та әзер икән, сыерга әз-мәз печән, салам да ашаталар икән...

Гыйззәтбану яргаланган куллары белән күзен каплап җылап җибәрде.

— Бөтен күрше-тирә, карт-коры, чиргә дучар булганнар шул сыерның дүрт имчәгенә карап торабыз. Сөте каймаклы... Тормышымны шуның белән генә алып барам...

Озак җылады, озак карышты Гыйззәтбану түти, ахыр чиктә болай килештеләр. Ул фермадан үзе сайлап, әзрәк арт санын күтәреп тора алырлык сыерны ала, өендә тота, ашата, карый һәм сабанга чыга. Сыер алдыннан әйдәкләп йөрерлек баланы да сайлап алдылар:

— Фаягөл булышыр, бүрек белән бәреп егарлык түгел, буе-сыны бар...— диде хуҗа хатын. Килешер-килешмәс, рәис белән бригадирны озатып чыгаргач та Гыйззәтбану түти җилтерәп фермага төшеп китте һәм бармагын тешләп уйга калды: малкайлар янына якын барырлык түгел иде. Абзар-куралар ишелеп беткән, тишек тә тошык, бер генә тәрәзә дә исән калмаган, абзар эче караңгы. Ләкин бүтән чара юк иде, ул әле аягына баса алырлык чуар сыерны алып кайтып, бушап калган келәтенә кертте. Йә чире-фәләне йогар дип үз коласы янына якын да җибәрмәде. Чуар мүкләк кола сыер өлешенә керде һәм биш-алты көн ашаткач басуга да чыкты...

Басуга күндәм генә чыккан иде мүкләк, кыр башына җитеп, муенына камыт кигертә башлагач үрле-кырлы сикерде малкай. Ферма хатыннары мүкләкне арада иң юаш хайван, дип мактаганнар иде, кая ул, Фаягөлне ике тапкыр очыртып җибәрде, Гыйззәтбану сабанчыны тибеп екты. Чыбык белән сыптыргалап, дөньяның иң ягымлы сүзләрен ишеттергәч, күнде тагын, бичара сыер, ипләп кенә буразна сызып бара башлады.

Көн матур, җылы талгын җил әллә кайлардан хуш исләре ташып, тыныч заманнарны искә төшерә, җылыйсыны китерә. Бер көн чиләнделәр, ике көн интектеләр, Гыйззәтбану түти белән Фаягөл кызыкайның утырып кочаклашып җылаган чаклары булды, инде эш җайлана дигәндә, кич кырын мүкләк җиргә ятты, күзен агартып аякларын сузды һәм җан бирде.

Сугыш заманы өчен бу коточкыч хәл иде. Мәсьәләне идарәдә чишә алмагач, гомуми җыелыш та җыйнадылар. Торадан кеше килде, Шәгъбикәләр, Гобәйбәләр акырып-бакырып торгач «сыерны Гыйззәтбанудан түләтергә» дигән карар чыгардылар. Мондый чакта Дәүләтшә әкә дә сүзсез калды, Сәлимә дә танавын күлмәк изүенә яшереп утырды.

Гыйззәтбану түтинең юмартлыгыннан бик еш файдаланган, яхшылыгын телләреннән төшермәгән күрше-тирәләр җыелышка килсәләр дә суык су кабып утырдылар...

Булат та ул көнне җыелышка бармаган иде, җыелыш хәлләрен очына-очына, сөенә-сөенә аңа хатыны Шәгъбикә сөйләде. Шәгъбикәне кырыс кына тыңлаган Булат та, хатынының:

— Бер ул гына йөрмәсен әле әүлия саналып. Арттагысын алтынга манып, алдагысын көмешкә чумдырып яшәтмәсеннәр әле,— дип хөкем чыгарып куйгач, ул җәелеп утырган хатынының каршысына килеп басты.

— Көнләшәсеңме?— диде ир өзеп карап.

— Бәй, кай җиреннән көнләшим ди, гуй?.. Ул да ишетсен диюем генә...

— Менә нәрсә, катын,— диде Булат сүзләрне учы белән җыйгандай кулын болгап.— Хәрәм малны син шактый эләктергәнсең. Тукта, тукта, бүлдермә! Бүген минем сүзне бүлдерә торган түгел. Кылган яманлыкларың өчен шушы сүз белән котыла алсаң, рәхмәт әйтерсең. Сүземне уйлап кына башламадым, ишетсен колагың. Гыйззәтбану түтидән көлергә түгел, ярдәм итәргә кирәк аңа.

— Тилерденме әллә син? Ярдәм, имеш. Кемнекен ашап ятканыңны беләсеңме?— Шәгъбикәнең ике сүз белән ирен егасы, аяк астына салып таптыйсы килә, сүзен таба алмый, юк аның кулында көчле сүзләр. Йодрыгы белән иренең күкрәген төясе, мыскыллыйсы килә — курка... Әгәр Булат аның кыек эшләрен саный башласа...

Шәгъбикә тыелып та өлгермәде, Булат аңа авыр гаепләр өяргә тотынды.

— Җитәр,— диде ул артыгын кызмыйча гына.— Син кылган языкларың өчен җәһәннәмнең җиде каты аша үтәргә тиешле! Тәүбәгә китерәм мин сине, хәрәм малыңны кара кан итеп йоттырам. Хәзер барасың да Гыйззәтбану түтигә бер сыерлык акча биреп торасың. Әйдә, тынычлансын. Дөнья тынычлангач, Сәгъдетдин абзый белән Йосыф кайткач, үз вакытлары белән түләрләр. Катын! Каршы килеп маташма, ачуымны чыгарма...

Шәгъбикәнең эченә усал эт кереп яткан шул, сабырлыгын җыярга теләсә дә, барып чыкмады, йодрыкларын йомарлап иренә ташланды, ләкин Булат ныгып өлгергән иде, бер генә кычкырды.

— Тыел, явыз! Акчаңны ал, югыйсә бар мөлкәтеңне мунча мичендә яндырам. Сыпырт моннан!

Сугышка хәтле дә, хәзер дә Шәгъбикәнең иреннән мондый тавыш, мондый сүзләр чыкканын ишеткәне юк иде. Почмакка кадалып мышыкмышык җыласа да, ирен җиңә алмады. Шәгъбикәгә барырга, Гыйззәтбану түтине жәлләгән булып кыланырга, нәни генә спектакль уйнарга туры килде. Гыйззәтбану түти башта ышанмады, акча бер кулдан икенчесенә күчкәч кенә Шәгъбикәне кочаклап җылады. Шәгъбикә түзмәде:

— Булатка әйт рәхмәтеңне, миңа түгел. Әллә кемнәр, әллә ниләр күрсә дә жәлләсем юк, мине берәвесенең дә кызганганы юк!

Шәгъбикәнең авыр күз карашы белән озатып калган ире янына кайтасы килми иде. Гыйззәтбанулардан чыккач, ул урам уртасында аптырап тукталып калды. Кемгә барып кереп вакытны уздырырга? Уйланып, башын эшләтеп шактый басып торды, әмма аны аңларлык, күңеленә хуш килерлек беркемне дә эзләп таба алмады. Урамнар буйлап өй борынча йөреп чык, Шәгъбикәдән нәрсә-кара сатып алмаган, аны каһәрләп телгә кертмәгән адәм калмаган икән! Ул беренче тапкыр бу хакта шулай ап-ачык итеп, әрнеп уйлады. Әгәр ире Булат әүлия булмаса, бу дөньяда кеше арасына чыгарлыгы калмаган икән аның... Һәм Шәгъбикә иренә игътибарлырак булырга, аның көен көйләп, җаеннан гына торырга уй беркетте. Ире исән булса, яши ала икән әле ул!..

Шулай уйлады Шәгъбикә, үзен бөтән якка борып кертергә, һәр кешегә шәфкать-мәрхәмәт күрсәтеп Гыйззәтбану түтиләрне һәр тарафтан узып китәргә булды, шулай да хәзерге сәгатьтә өенә кайтасы килмәде аның. Ире җәзаның берсен генә әйткән кебек булды аңа. Булатның тел төбендә нидер калган кебек тоелды. Кайтып керүгә тагын бер авыр сүз әйтсә, нишләрсең? Әллә Гобәйбә буйдак янына кереп чыгарга инде? Аның янына керсәң шул инде, самогонын чыгарыр, лач-лач нарат сагызы чәйнәп гайбәт сөйләр, имиләрен селкетеп авызын җырыр. Икеләнеп, газапланып шактый басып торса да күңеленә бөгәрләнеп яткан усал эт барыбер үзенекен итте. Шәгъбикә кайтып барган җиреннән кире борылып Гобәйбәләргә китте.

Ахирәтләр кайнар кочаклашып, бер-берсенең битләрен ялап күрештеләр. Каян килеп тора диген, Гобәйбә кичәгенәк кенә самогон куйган икән, сасы исе өйдән чыгып та бетмәгән әле.

Тустаган төбенә чәк кенә салып берне күтәрделәр, беренчесе икенчене чакырды, ярты сәгать утырдымы икән, Шәгъбикәнең зиһене томаланды, мие түнде. Гобәйбә җырлап ук җибәрде, Шәгъбикә дә аңа кушылып маташты. Кыскасы, Булат янына кайтып кергәндә аның аяк атлаулары чалшайган, иреннәренә тиләләрчә елмаю ябышып каткан иде.

Булат бүген дәшмәде, хатыны киткән җирендә шактый озак торгач, ул эшнең кая таба киткәнен чамалады. Шәгъбикә аңа ышкылып-ышкылып, ирен юмалап ишекле-түрле шактый йөрде, Булатның кызмаслыгын чамалап урынга барып ятты.

Иртәнчәк торып юынып алгач, Булат озаклап кырынды, чистарынды һәм аңгы-миңге яткан хатынын уятты.

— Тор, юын. Сиңа сүзем бар,— диде ул җимерек кашларын тагын да түбәнгәрәк салындырып.

Нидер сизенгән, иреннән усаллык кына көткән хатын Булат каршысына, өстәлнең икенче ягына килеп утырды.

— Менә нәрсә,— диде Булат, ике баш бармагын гимнастеркасын буган киң каеш эченнән йөртеп.— Маеңа чыдый алмыйсың син, маеңа! Әә синдәй хатыннарның эч мае бозылган була. Тәүбәгә килергә вакыт сиңа, катын. Һәм мин сине тәүбәгә китереп, гөнаһларыңны йолырга уйлыйм.

— Ничек итеп? — Шәгъбикәнең иреннәре чак кыймылдады.

Булат беравык эндәшмичә утырды, тез башларына яткан кулларының калтыравы гына аның нык гасабиланганын, борчылуын сөйли иде. «Йа аллам,— дип уйлады Шәгъбикә,— синең телсез, саңгырау чакларың нинди рәхәт булган икән! Каян кайтып төштең син, иблис? Сугыш азагына хәтле шунда яткан булсаңчы!»

Менә Булатның авызы ачылды.

— Синең ниләр уйлаганыңны беләм мин,— дип башлады ул сүзен.— Шунда ятып калган булсаң, дип уйлыйсың... Телсез, чукрак чакларың рәхәт иде синең дисең син!

Түзмәде Шәгъбикә, күңелендәгенең читкә чыгуын сизмичәрәк калды:

— Иблистер син, шайтандыр! — дип кычкырды, җыларга тотынды.

— Иблис имәсмен, җен-убырлар да миңа булышып, котыртып тормый. Бер булышчым бар, ул Аллаһе Тәгаләдер. Күрәсең, Шәгъбикә, савыктым мин! Әле сугыш кызып кына бара. Дошманны тар-мар иткәнче әле-е! Бик күп көтәргә кирәк. Мөгаен, мине озакламый алып китәрләр. Карышып тормам. Китәргә икән, китәргә! Ләкин минем бу юлы тыныч күңел белән китеп, кирәгенчә сугышасым килә. Уйладым мин, аркылысын-буен үлчәдем, нык ваттым контузияле башымны! Һәм менә нинди уйга килеп туктадым. Бер юлы ике куянны атарга ниятлим: сиңа да сабак булыр, Мәүлихага да!

— Безнең арага Мәүлиха оятсызны кертмә! — дип чәрелдәде Шәгъбикә.

— Кертмим, андый ниятем дә юк, әмма аны да акылга утыртасым килә.

— Тагын ниләр уйлап чыгардың син, тилебаш! Теле кайтса да, контузиясе тиз генә үтмәс дигәннәр иде аны.

— Моны синең Гобәйбә ахирәтең әйткәндер инде!

— Әйтсә, ул кеше түгел мени?

— Чүбек чәйнәп май чыгарып булмый. Утырмыйк корыны бушка әвештереп. Кыскасы, менә шул! Мин Омскига барып, аяксыз-кулсыз ятучы Шәүкәтне алып кайтам. Үзебезгә алып кайтам... Икәүләшеп карыйбыз аны. Ничек инде мин, иманлы татар баласы, үз авылдашымның читләр күзенә карап тилмереп ятуына түзә алыйм! Минем дә шул хәлгә төшүем ихтималы бар иде бит!.. Ишет, колагыңа киртлә: әгәр мин тагын сугышка чыгып китсәм, анда да Шәүкәт бичараны ташламыйсың. Менә сиңа минем актыккы сүзем. Мине ир дип саныйсың икән, кушканнарымны үтисең. Үтәмисең икән — дүрт ягың кыйбла.

— Ә Мәүлиха? Мәүлиха? Ул бүксәсен киереп миннән көлеп йөрсен-ме? Ай-һай-һай...

Шәгъбикә тагынниләрдер әйтеп, унлаган дәлилләр табып Булатның уен җимереп ыргытырга ярсыса да теле әйләнмәде. Җыларга теләде, күз төпләрен усалланып бармак башы белән каезлады, челт иткән дым чыкмады. Ире кушкан, алда торган эшләр Шәгъбикәне бик күп бәлаләрдән коткарып килгән күз яшьләрен дә киптергән иде...

## 21

Сугыш ул кинәтлек, көтелмәгәнлек. Сугыш кешеләрдән бүтән төрле адәмнәр ясый, күп вакытларда җаннарын алыштыра. Әйтик, элек илендә чакта бармагы киселсә дә уфылдап йөргән бәндәләр, кан күргәндә сискәнеп китәргә әзер адәмнәр, ай, ай ярым сугышта катнашканнан соң канга да, үлемгә дә гадәти тормыш күренешләре итеп карарга гадәтләнәләр. Кышкы суыкларда окоп өстенә мәетләр тезеп җилдән ышыклану кирәкме сиңа, каткан гәүдәләр өстенә чәркә куеп «әбәд ашаулар», «аракы чөмерүләр» бик еш кабатлана торган хәлләргә әйләнә.

Бу зур авыл тирәсендә сугышлар шактый озак булды. Тупчылар кай араларда үз позицияләреннән кузгалырга да өлгермиләр, кичә генә авыл урамнарына бәреп кергән пехота бүген чигенгән, бөтенләй бүтән сызыкта ныгып, окоп-траншеялар казып маташа. Кулдан-кулга күчеп йөри торгач, авыл йортларының эзләре генә, капка баганалары һәм сугыш корымына буялган дәү-дәү мичләре генә калган.

Сугыш ике як солдатларын да кырды, Йосыф белән Шамил элек бер полкта булса да, үзгә батальоннарда иделәр, резервтан өстәмә көчләр килеп җитмәделәр, батальоннарны берләштерергә мәҗбүр булдылар. Яңа батальон өстәмә көчләрдән төзеләчәк, имеш. Янәшә урыннарда сугышсалар да Йосыф белән Шамил гел-гел күрешеп тора алмыйлар, бигрәк тә соңгы көннәрдәге авыр сугышлардан соң, күп югалтулар кичергән, көчсезләнгән батальоннардан әллә ни чыгып китеп булмый иде...

Менә ике көн инде ике як та «яраларын ялап» ял итә, хәл җыя. Йосыф та, Шамил дә — артиллериядә, тупчылар. Беренче көнне Шамил батареясеннән аяк атлап читкә китә алмады, машиналарда ягулык беткән иде, хәстәрен күреп, тынлыктан файдаланып ягулык ягын кайгыртырга кирәк булды. Ул элек тә урам булган, хәзерендә тѳтен, сөрем исенә баткан юлдан әкрен генә үз частена кайтып бара. Авыл шомлы тынлыкта һәм бушлыкта иде. Эт-писиләр күренмәгән авыл әкияти ят, сәер урынга әверелә икән... Сөенече бар Шамилнең, кичәгенәк алар Йосыф белән кавышып озак кына гәпләшеп утырдылар. Уртак сүзләре, уртак уйлары күп иде авылдашларның, Ялан авылы егетләренең. Илдән килгән һәр хат, һәр хәбәр алар өчен көтелгән, тансык вә кадерле иде. Йосыф очынып-очынып Мәүлиядән килгән хатларны күрсәтте. Мәүлия һәр хатын «Җанымнан артык күргән Йосыфым!» дип башлап китә дә, өзелеп сагынуын, түземлелек белән көтүен әллә нинди җылы сүзләр аша язып белдерә. Шул сүзләрне авылдаш егетенә укыгач, Йосыф офицер кенәгәсе эченә хатны кыстырып, йөрәге янында йөрткән Мәүлиянең фотосын ала да, янында иптәше барлыгын да онытып, Мәүлиянең сихри нур чәчкән зур күзләренә карап тора. Мәүлиясе: «Минем күңелем керсез, җаным, тәнем пакь», дия сыман.

Шамил планшеттагы карта астына кереп яткан ул хатларны үзенә килгәндәй бирелеп тыңлый, яратып сихри хисләргә чума. Хат азагындагы бер сорау җөмлә аның бәгырен сизелмәслек мизгелдә чеметеп үтә. Мәүлия һәр хатында: «Нигә Шамил Сәрвәргә хат язмый?» — дип сораган була.

Шамил үзгәрде, хәзер ул йомшак күңелле. Сәрвәр өчен өзелеп торган егет түгел, бигрәк тә үз тормышына ядрә булып атылып килеп кергән куштан кыз Зосядан соң... Улы бар хәзер Шамилнең, малае! Бу хәбәрне ул Йосыфтан яшермәде, яшерүен, ләкин ничек аны Сәрвәргә житкермәк кирәк? «Ничек алай булды?» — дип сорасалар, Шамил ачык кына бу катгый сорауга җавап та бирә алмас иде. Ниләр булганын ничек аңлатып бетермәк кирәк? Татлы иде шул аның Зосясы, егетне ихлас күңелдән яратты, саф, намуслы яшьлеген бүләк итте. Әле шул олы хөрмәт тә егеткә мәңге онытa алмаслык бәхет китергән иде, инде улы да тугач... «Исемен син куясың, егетне мин таптым»,— дип язган иде Зосясы. Әле исем тапканнары юк, бу хакта Йосыф белән кат-кат сөйләшсәләр дә сүзнең очына чыга алмадылар. «Үзең уйла!» дип килде Йосыф моңарчы. Ничек уйлыйсың да, ничек дөрес исем табасың? Зося ялгыз түгел, бабасы, әнисе бар. Шамилнең татар исеме куясы килә, ә ул аларга ошамаса?

Бүген Шамилнең күңеле күтәренке: хаты госпитальдә яткан әтисенә — Мөхәммәт Уразаевка барып ирешкән. Ул үзенең бабай булуын, Зося исемле сылу кызның Шамилдән бәбәй табуын ишеткән. Куанмаган да сыман, күтәрелеп тә бәрелмәгән. «И улым! Улың бәхетенә гомерең озын булсын!» — дип тәмамлаган.

Шамил сәгатенә карый-карый ашыга башлады. Йосыф белән күрешергә дип вәгъдәләшкән вакыт җитеп килә иде. Кайтып җитте, билгеләнгән урында Йосыф юк, ә очынып-очынып диярлек кайткан Шамил Уразаевны көтелмәгән яңалыклар, уйланмаган вакыйгалар сагалап торган икән.

Зурлыгы белән кечкенәрәк шәһәргә тартым бу авылны дошман юкка гына ташлап чыкмаган икән! Безнең халыкның иң йомшак урынын — аракыга хирeслеген белеп тозак корган икән явыз. Авыл белән янәшә диярлек, бераз читтә, элеккеге завод хуҗасы алма, чия, каен агачлары утыртып, завод биналарын яшеллек эчендә калдырып салдырган аракы заводы бар икән. Йортлар җимерелгән, күперләр сүтелгән, юллар калмаган — ә аракы заводына пычак та булмаган! Завод исән-сау, спирт тутырылган цистерналар да, каядыр китәргә әзерләнгән төсле, тын гына утыралар. Бүген иртән разведчиклар тап булганнар моңа. Башта шыпан-шыпан гына котелокларына тутырып үзләренә ташыганнар. Күз күргән агай-энегә сатканнар, әйбер-карага алмашканнар. Аннан офицерларга «бүләк» алып кайта башлаганнар. Башларына киткәч, бугаз киереп мактанганнар, цистерна кранына чиратка басканнар, ул гына җитмәгән ач күз совет солдатларына, мылтыклардан атып цистерналы тишкәләгәннәр! Спиртны фляҗаларга, мичкәләргә тутырып ташыганнар.

Шамил янына Йосыф кайтып кергәндә янәшәдәге өч полк та эчеп, чучка булып егылган.

Йосыфның кәефе кырылды, солдатларның ачкакланып спиртка ташланулары өчен генә түгел иде бу борчылу, Шамилнең шул исерекләрне тәртипкә китерергә маташуы ошамады аңа. Аракыга тап булган урыс солдатын ипкә китерерлек бер-бер әмәл бармы соң?..

Үз солдатларын, үз сугышчыларын танымады Йосыф. Кайсы җылый, кайсы җырлый, кемдер түш медальләрен югалтып үлән арасында мүкәләп йөри. Ике солдаты бер кәтилүк спиртны су кушыйча ач карынга сосып бетергәннәр, чүендәй караеп янып үлеп киткәннәр. Хәтта туплар янына каравылга баскан сак солдатлары да лаякыл исергәннәр. Аларга башлык булып батальон командирының урынбасары калган иде. Хәрби тәртип таләп иткәнчә, капитан күренүгә, рапорт бирергә тиеш. Йосыф урынбасары, ул күренүгә, ава-түнә аның каршысына килеп басты, рапорт әвәләргә керешт е. Имештер, «батареяда все в порядке!» Үзе шунда ук мәтәлеп барып төште. Торды да янадан рапортына ябышты.

— Отставить! — дигән боерыкка карамастан һаман рапортын башлап, тәмамлый алмыйча ярты юлда туктап, өр-яңадан тотынып Йосыфның теңкәсенә тиде. Ачуына буылган комбат үз ярдәмчесен бар көченә

этеп җибәрде. «Әле шушы юньсезләр аркасында трибуналга эләгүең дә бик ихтимал!» — дип уйлады ул. Шул мизгелдә аның башына ару гына уй килде: солдат гомере буе команда белән яшәргә күнектерелгән, шуңа гадәтләнгән. Башы-күзе тонса да, ул һаман солдат ич һәм исерекләр аунаган, җылашкан, юк тавышлары белән җырлашкан мәйдан өстендә Йосыфның нык тавышы яңгырады:

— Исерекләргә салкын су коярга!

Әз-мәз аякта басып торырлык солдатлар, өлкәнрәкләр, үзләрен «аек» дип кабул итүләренә сөенеп чиләкләрен шылтыратып коедан су ташырга тотындылар...

Косасыны китергән шушы ямьсез хәлләрне тамаша кылып торганда Йосыф янына взвод командирларыннан берәү, Идел буе татары йөгереп килде. Аның кыяфәте соң дәрәҗәдә куркынган иде. Ерактан ул кычкыра иде татар, тавышы да әллә ничек, әйтерсең лә аның артыннан өч башлы аждаһа куа килә.

— Командир, командир!

Йосыф аңа әйтеп бетерергә ирек биреп, чыраена текәлде.

— Командир, бәла!

— Нинди бәла?

— Капитанны... Шамил Уразаевны үтергәннәр.

Йосыф Саратов татарының якасын кулына урап тотты.

— Син исерекме? Әллә шаштың укмы?

Татарның күзләре оясыннан атылып чыгардай булып шарга әйләнде. Йосыф ни җилкенсә дә, татарны үзен атардай булып кабурасын капшаса да, аның колаклары дөрес ишеткән икән. Соңыннан мәгълүм булды: капитан Шамил Уразаев, исереп үзара сугыша башлаган тупчылар арасына барып кергән. Арада Зосяны күреп гашыйк булгандай кыланган, соңыннан Шамилдән үтә нык көнләшкән бер сержант бар икән, шул «ыгы-зыгы арасында кем атканы сизелмәс», дип уйлап, командирның җилкәсенә аткан. Пуля Ялан авылының гүзәл егете, Уразаевның бердәнбер сөекле улы, Зосяның сөйгәне, моңарчы Сәрвәр бәхетсезнең яшерен өмете булып килгән кешенең гомерен шул минутта ук өзгән иде.

Болары соңрак, хәрби трибунал утырышында мәгълүм булды.

Йосыф авылдашын үз куллары белән кабергә иңдерде. Нәни генә нарат-чыршылар үсеп утырган таучыкта ялгыз кабер ятып калды. Кабер өстенә Шамилнең туган, үлгән еллары язылган, кызыл йолдыз сурәте төшкән фанер такта кисәге кадакладылар. Кыска гына салют һәм беттекитте.

Һәр көн, һәр килмеш төн, йөзәр, меңәр кеше җаны белән хушлашканда кемгә кирәк вакытсыз һәлак булган татар баласы?! Әле ярый, кеше төсле итеп җирләргә янында Йосыф булды.

Документларын махсус бүлеккә тапшыргач, Йосыф Шамилнең кыр сумкасын, планшетын үзе белән алды, эчтәге язу-сызуларны, кәгазьконвертларны берәм-берәм күзеннән кичерде. Иң мөһиме Зося белән Мөхәммәт абыйсының адресларын табарга кирәк иде аңа. Һичшиксез, аларның икесенә дә хәбәр җиткерергә кирәк. Никадәр авыр булса да, белеп торсыннар. Дөнья йөзенә килеп аваз салган, ике яшь кешенең мәхәббәт җимеше булып туган балага да, ниһаять, исем табылды, ул Зосяга аны язып салыр... Шамил булыр ул егетнең исеме... Тау халыкларының бөркете, мөселман дөньясында туып урысларны дер селкеткән Шамил исемен бөтен халыклар да авыз тутырып әйтә ала. Шамил булыр ул баланың исеме! Инде моңарчы күргәннәреннән йөрәге ярылмаган Сәрвәр бу кайгы-хәсрәтне дә үткәреп җибәрер. Соңгы вакытларда хатлары бик сирәк килгән икән Сәрвәрнең... Язганнары да әллә ничек кенә, җиңел-шуклык төрелгән иде ул язуларга. Шамилнең күңеле бүтәндә икәнен сизгер Сәрвәр чамалаганмы?.. Әллә багучы күрәзә-корткаларның берәвесе аның күзен ачарга ярдәм иткәнме?.. Менә аның актыкка хаты:

**«Шамил, күп сәламнәр сиңа. Иптәш кызларым да сиңа сәламнәр җүндерүемне үтенделәр. Әле ярый, Ходага мең шөкер, без өчәү. Өчебез өч төрле. Сугыш заманы кызлары бәхетсез дә алар, бәхетле дә. Безгә үзара сыланып маташасы юк, һәммәсе күз алдында. Мәүлия белән икәү фронт хатларын укып юанабыз... Дөрес, синең хатларның юлы нигәдер өзелде. Моңарчы язмый торган идем, бүген сиңа белдерәсем килә: без Ташкәй утырган төрмә лагерена барып кайттык. Исән-сау. Фронтка барасы килә. «Шуннан башка миңа аклану юк»,— ди. Ничек уйлыйсың: сугышка чыгып батырлыклар күрсәтсә, аны акларлармы?.. Минем өчен төрмә рәшәткәләре артына утырды бит егет!»..**

Соңгы хаты кызның! Моннан ары егеттән килгән хатларны Сәрвәр укый алмас, Шамил дә аның эчкерсез хатларын көтеп тормас. Ул әнә тегендә, вак чыршы-наратлар үскән чаукалыкта, ят җирләрдә мәңгелеккә йокыга талган.

Йосыфның да тормышының чите кителде, Шамил аның бик күп яшьлек хатирәләрен үзе белән алып китте.

Әле сугыш бетмәгән, әле дошманны бөтен фронт буйлап куарга гына әзерләнәләр. Әле кырык өченче ел гына! Әле Йосыфны алда ни көткәнен бер Ходай үзе генә белә...

## 22

Ишморза Муллин тешләк кеше түгел, әмма ләкин авызында сүзен тота белә. Миңнурый белән арада әнә шул бетмәс кыенлык бар: НКВД капитаны үз эше хакында, бик якынына әйләнгән зирәк Миңнурыйга да сөйли алмый. Дөрес, иленнән сөрелгән мәэзин нәбәрәсе Миңнурыйның да — сөйгән яры белән кулга алулар, төрмәләр, этаплар хакында сөйләшеп утырасы килми. Тик шуны да онытмыйк: егет белән кыз үз хезмәтләре, яраткан шөгыльләре хакында гәп кормыйлар икән, гел-гел йолдызларга гына карап әкият сатып, аккан суга текәлеп бабаңнар хакында гына сөйләшеп тә булмый ич! Мәхәббәт — язмышлар уртаклыгы ул. Егет белән кыз никахлашкач, күрше йортларда үсеп, бер-берсен белгән кебек булсалар да, тормыш кора башлагач, сөйгән ярларының моңарчы күз алдына китерә алмаган сыйфатларын ачып гаҗәпләнеп, хәтта ки шаккатып калалар. Әлерәк кенә танышып китүчеләр исә, сайлаган ярларына күңел капкаларын ачалар да әкрен генә аларны җаннары янына үткәрәләр. Егетләрнең күңел капкасы кырык катлы булса, кызларда исә... юк, ялгышырмын дип куркам, кызларның күңел капкаларын ачып бетерә алган затлар — зирәкләр тарихта юк, булмас та.

Кызга ачылып китә алмавына Ишморза бик борчыла иде. Егетнең кайара телен тешләп, сүзен тыеп калуларын Миңнурый сизенгәләп шундук сагая, икәү очрашкан кадерле минутларында алар бер-берсен сынап, шигәеп, сүзләрне йотып, күңел коесының төбеннән чыгарырга кыймыйчарак үткәрәләр иде. Бу юлы алай булмады, Ишморза Миңнурыйны өйдән чакырып чыгарды, нигәдер өйдә сөйләшәсе килмәде аның. Ишморза ниндидер яңа сүз алып килгән кеше кыяфәтендә иде. Өй тирәсеннән ераграк киттеләр, авыл читенә атладылар, урамны да чыктылар. Миңнурый мәктәп хәлләрен, балалар башыннан кичкән вакыйгаларны сөйләштереп, арага җылылык, якынлык иңдерергә тырышты.

Башта игътибар белән тыңлагандай булган Ишморза Миңнурый сүзенең азагында аны бөтенләй ишетмәде, аның уе әллә кайларда читтә йөргән кыз да сизде.

— Син бүген минем янга килмәгәнсең, Ишморза. Гәүдәң килсә дә каныңны уйларың читкә алып китә,— диде.

Алар тау итәгендә коры урын табып янәшә утырыштылар.

— Үпкәләмә, Миңнурый, рәнҗемә дә! Чыннан да, бүген минем авыр көнем. Хезмәт урыным таләп иткәнчә бу хакта минем сүз башлавым хыянәт. Ул турыда беркемнән сыңар сүз дә чыгарга тиеш түгел. Бу эш буласын Тубылда биш-алты кеше һәм Төмәндә ике-өч кеше генә белә. Бу эшне үтәп чыгарга тиешле кешеләр дә чын дөреслекне азагына хәтле белеп бетермиләр. Аны без икәү генә беләбез. Мин беләм дә, начальнигыбыз Лапиков белә.

— Лапиков? — дип сорады Миңнурый, гәрчә НКВД начальнигының исемен ишеткәләгәне булса да.

— Мине бу җаваплы эшнең эчтәлеген нибарысы ике кеше генә белүе борчый, Миңнурый,— дип дәвам итте, торган саен җитдиләнә барган Ишморза.— Бу хакта кәгазьгә язылмаган, планнарның берсе дә приказлар булып дәфтәрләргә теркәлмәгән. Ә эш хәвефле, азагы ничек булып бетәр.— Һәм шунда, тау итәгенә утырып, Миңнурыйның зур ачылган сөйкемле күзләренә карап, ике учын да үз кулларына алып, кысып, Ишморза соңгы вакытларда ниләр кыдырып йөрүен сөйләп бирде. Ташкәйне очраткач та башына бер уй килүеннән башлап китте дә, күптән түгел генә аны бандитлар отрядына сеңдерүенә кадәр берсен калдырмыйча сөйләп, аңлатып бирде.

— Ташкәйнең үз йортында Сорокин дигән явыз белән очрашуы бу мәсьәләгә нык йогынты ясады, башкалар егетне карышусыз һәм шикләнмичә үз араларына алдылар. Озакламый сазлык утрауларының берсендә отряд тулы составта җыйналырга тиеш. Әлеге планнары тулысынча анык түгел, алай да без аларның җыелгән вакытларыннан файдаланырга һәм отрядны туздырып ташларга телибез... Шул көнне булачак кискен бәрелештә Ташкәй белән без, кара каршы торып, очрашырга мәҗбүр булачакбыз. Лапиков белән килешү буенча, мин Ташкәйнең исәнлеген, бөтенлеген кайгыртырга тиеш.

— Нәрсә шикләндерә соң сине, җаным?..

— Әйтә алмыйм. Әгәр дә мин аны тәгаен белсәм, бүген сиңа һәммәсен инәсеннән-җебенә тиклем сөйләп бирер идем. Ләкин син, бүген, өченче кеше буларак төп-төгәл бер нәрсәне белеп, ятлап калырга һәм мәңгегә онытмаска, бутамаска тиеш! Бүгенгенең сере киләчәк өчен документ булып синең хәтердә кала: сакла аны! Ташкәйне зонадан без алдырдык. Аның төрмәдән качуын без оештырдык. Ул бандитлар арасына барып сеңеп, аларны эчтән таркатырга, һәр адымнарын, планнарын тулысынча безгә хәбәр итеп торырга вәгъдә бирде. Ташкәй моңа кадәр тугры һәм ихлас хезмәт итте. Бу бик мөһим, Миңнурый! Ни булмас?.. Лапиковның тиз һәм ансат кына мин уйлаганнарны кабул итүе шикләндерә мине... Белмим, алай шикләнергә нигез дә юк шикелле. Әмма дөнья мине шикләнергә өйрәтте.

Ишморзаның ачылып киткәне дә, болай теләп, ясканып һәм ышанып сөйләшкәне дә юк иде шикелле.

— Туган ягыңны ташлап бу тирәләргә үз ирегең белән килдеңме? дип сораганнарың бар иде, Миңнурый, элегрәк әйтмәдем, аңлагач кичерерсең... Утызынчы еллар башында минем әткәйне дә төнлә килеп алып киттеләр дә, шул төннән ул эзсез югалды. Беләсең килсә, безнең язмышлар уртак диярлек, Миңнурый. Себер ягына эшкә килүем — бердән эз югалту булса, икенчедән мин әкерен генә әткәйнең эзләрен эзлим. Исән булып, бу тирәләргә китерелгән икән, аның бер-бер эзе калырга тиеш ләбаса! Тубыл НКВДсы аша үткән тоткыннарның саны юк, бихисап алар. Мин иплән кенә, мөмкинлек рөхсәт иткәнчә, шик-шөбһә уятмаслык итеп кенә, үткән елларның кәгазьләрен караштырам. Әткәмнең эзләрен табарга тиешме мин, юкмы?

Миңнурый түзә алмады, Ишморзаны кочаклады, бер-берсен көтеп зарыккан иреннәр иренгә ялганды.

* * *

«Су чокырга җыела»,— ди татар. Очсыз-кырыйсыз тайга урманнарына сеңгән дезертирлар, теге яки бу сәбәп белән җәмгыять кануннарына буйсынмыйча, үз белдекләре белән яшәргә керешкән гражданнар шактый иде ул елларда. Төгәл исәбен алырга мөмкинлек булмаса да, НКВД органнары Аромаш районында, Березовка, Голышманова тирәләрендә, Тубыл урманнарында оешкан отрядлар хакында азмы-күпме беләләр иде инде.

Үткән ел дәвамында бандитларның эзенә төшәргә, берәм-берәм тотып алырга тырышып карасалар да НКВД кешеләренең ниятләре тормышка ашмады... Качкыннарның «элемтәсе» җайга салынган һәм ул моңа кадәр бер ялгышсыз эшли булып чыкты. Бандитларның үз кануннары туып, оешып алар, сүз берләшеп шул канун-кагыйдәләргә тугры яшәргә тырышалар. Алар закон бозучыларны шундук юк итәләр иде. Иксез-чиксез, төпсез сазламыкларда, үлән-мүк белән капланган төпсез күлләрдә аерым кешене эзсез югалту бик җиңел. Бүген бар кеше — иртәгә юк! Шуңа күрә отрядтагылар үзләре өн корган тирәләрдәге авыллардан мал-туар, әйбер-кара урларга тырышмадылар, сагайдылар...

Төпсез сазлыклар уртасына кереп поскан коры утрауларны да, ат кереп күмелерлек үлән-камышлар арасыннан боргаланып үткән сукмакларны да алар яхшы үзләштерделәр, Миша Сорокинның кулында утрау сукмакларының төп-төгәл картасына хәтле бар иде.

Ташкәйнең отрядка килеп керүе тыныч кына узды диярлек. Сорокин югында отрядта баш булып күптәнге бандит, өч тапкыр лагерьдан качкан Голубев Павел кала торган иде. Бер ул гына Ташкәйнең әйткән сүзләренә ышанмады, алай да, болай да егетне капшап, саташтырып, чәлмәштереп сораулар биреп азаплады. Ташкәйнең бәхетенә күрә, ул килер алдыннан гына элек отрядка тагын өч кеше килеп кушылган иде.

Армиягә алынган яшь җилкенчәкне ул чакларда Омски тирәсендә әзерләп фронтка озаталар иде. Шунда хәрби өйрәнүләр үткән өч егет, күрше авыллар, бер-берсен әллә кайчаннан белгән яшьтәшләр, Ишимга җитәрәк мылтыкларын алып вагоннан сикереп төшеп калалар да Прокуткино, Сорокино авыллары аша Березовка урманнарына барып чыгалар. Ә анда — лафа! Авыл саен туганнары, кардәш-ырулары бар, бер кичне монда, икенчесендә тегендә, җылы мунчаларда, тол хатыннар янында яшәп язны җиткерәләр. Өченче көн Сорокин отрядына килеп кушылалар. Таза-таза өч егетне күрсәтеп, Павел Голубев Ташкәйне чокчыды:

— Төрмәдән качтым дисең... Нигә берүзең качтың? Нигә иптәш әзерләмәдең?

Җәһәннәм юлларын үтеп, коралларын калдырмыйча үзләренә килеп кушылган өч егетне мисалга алып, Голубев Ташкәйне сыгарга тырышты.

— Менә алар шиксез, чиста егетләр. Ә син кем? Синең кемлегеңне сөйләп бирүче бармы?..

Ташкәй таза, көчле егет. Тәмәке суы эчеп саргайган, бер чакта да тамагы туймаган, бу күксәү адәмне бер чиртүдә егар иде, әмма төрмә күргән, кыен ашаган Павелның отрядта сүзе үтә. Берәүгә дә ышанмаган шикчел Сорокин да аның сүзенә колак сала.

Голубевның егетне каезлаганын күреп, мыек астыннан көлемсерәгән Сорокин бер-ике сүз генә әйтте:

— Ташла, бәйләнмә егеткә! Төрмәдән качканмы, качкан.

Кыен чакларда кулланырсың дип, зирәк Ишморза егеткә бер-ике үгет-нәсихәт тә бүләк итеп куйган иде.

— Кыенга килә башласа, үзең һөҗүмгә күч, йоклап торма, кирәк икән сугыш! Көчеңне күрсәт. Синең атаң авылдан куылган, очраклы рәвештә генә исән калган кеше. Бу синең кулыңдагы корал, онытма! — дигән иде.

— Сора син егетләрдән, сора, белеш! Әтиләре кем булган да аларның, совет власте аларны ничек иркәләгән? Без гаиләбез белән куылган кеше.

Сорокинның йомшак кына яклавы, Ташкәйнең үзен саклап чытырдап торуы, теле-телгә йокмыйча әрәпләшеп торуы күпне күргән Голубевны да икеләндерә, егетнең лагерь телендә сүгенеп җибәрүе аны дәртләндерә. Ул Ташкәйнең нык җилкәсенә кагылып ала.

— Не горюй, сынок. Я из тебя сделаю человека! — дип кабатлый.

Хәзер отрядтагылар Ташкәй алдында яшеренмичә, ачыктан-ачык сөйләшәләр. Урман отрядына кергән бандитларның телләрендә күпчелек шул була: алар, әлбәттә, киләчәкләренә планнар коралар!

Ташкәй килеп катнашкан уникe кеше отрядның чиреге генә икән әле. Алар бик кирәк чакларда гына, айга бер генә җыйналалар икән. Җыйналалар, мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр дә авылларга таралалар икән. Мунча керәләр, ял итәләр, булдыра алган кадәр ипи-тоз юнәтеп вакытлы өннәренә юнәләләр, соңра сазлык-ястыкларны тибрәтеп, билдән су ерып төп урыннарына барып җитәләр.

Отрядның төп «өенендә» аларның кораллары, талап алган әйберкаралары саклана. «Өн»гә үтү сукмакларын алар күз карасыдай саклыйлар, утрауны ташлап чыкканда, чит кешеләр үткәнен белер өчен, сукмак өстенә агач ботаклары, үләннәр җәеп калдыралар. Күчем хан хәзинәсе саклана дип уйланылган урыннар бу «өн»нән еракта түгел икән. Теге алтын тәңкәләр дә шушы тирәләрдән табылган. Отрядның максаты нидән гыйбарәт икәнен хәтта Павел Голубев та белми, аны белүчеләр икәү генә. Әле шул «икәүлек» комсыз Сорокинны кытыклый. Аның һәр нәрсәгә бер үзе баш булып каласы килә, моның өчен ул Канталыевтан котылырга җыена.

Ташкәй отрядка килеп кушылганнан соң Канталыев та урман сукмакларына килеп чыкты. Бүтәннәргә баш бирмәгән, ызгыш-талаш чыкканда да ырлап ябыша ала торган Сорокин да Канталыев килгәннән соң авызын үлчәп кенә ача башлады. Кочаклашып күрешсәләр да «солых» озакка бармады, Канталыев белән Сорокин читкәрәк китәләр дә, бүтәннәргә сиздермичә генә пәрмә-пәр талашырга тотыналар иде.

Бер таңда Сорокин Ташкәйне уятты, «Әйдә әле!» — дип, аны аулакка алып китте. Сүзләр ишетелмәслек ара киткәч, ул куеныннан елтырап торган наган чыгарды.

— Мә, ал! Мин сине урман иясе иттем, шуның бәрабәренә син берәүне юк итәргә тиеш!

— Кемне? — диде Ташкәй нык борчылып.

— Үзеңнән соң килгән чатанны! Мин аны үзем дә юк итә алам, әмма минем сине сыныйсым килә.

Сорокин башта үтенде, аннан ачулана башлады, иң соңыннан егетнең бугазына үрелде. Ни тарткалашсалар да Ташкәй бирелмәде, явызның тәкъдимен кабул итмәде, үпкәләгән булып отрядтан ике көнгә китеп торды. Моның файдасы да булды, Ташкәй тиешле урынга барып, билгеләнгән кешене күреп, моңарчы үзе күреп-белгәннәрне бәйнә-бәйнә Ишморза Муллинга хәбәр итә алды.

Ул гафу үтенеп отрядка кайтып кергәндә Канталыев анда юк иде инде. Ташкәй үзе сорарга батырчылык итмәгән иде, соңгы килгән егетләрнең берсе сүз арасында гына:

— Ә теге аксакны аю ботарлаган! — дип куйды.

Канталыевны нинди аю ботарлаганын чамалый иде Ташкәй, ялгышмый иде. Менә иң авыр, иң җитди көн килеп җитте. Бүген якын тирәләргә таралган дезертирлар бергә җыелалар. Җыелу урыны — баткак-сазламаклар уртасындагы утрау...

Ташкәйдән хәбәр алынып, бандитлар отрядының туплану көне мәгълүм булгач, Түбәннән бер майор килеп төште, ул өч районнан милици-

яләрне, мәктәпләрдән военрукларны җыйды. КГБ начальниклары, прокурорлар да шушы хәвефле эшкә тартылды. Түбәннән килгән майор гомуми җитәкчелекне Глеб Иванович Лапиковка тапшыргач, тегенең борыны бөтенләй күз ирешмәс югарылыкка менеп китте...

Милиционерларны, җыелган барлык көчләрне барладылар, һәммә кешенең өс-башын алыштырып, аларны урманда буталып йөрүче сукбайлар рәвешенә керттеләр. Иртәгесен Сорокин отряды җыела дигән кичне юлга кузгалып, төн урталарында утрауны ярым алка булып камап алдылар. Күзләрдән йокы качты. Төне буе явыз черкиләр белән сугышып көтсәләр дә, сукмакларда кеше-кара күренмәде. Лапиков үзеннән ерак та түгел урнашкан Ишморза Муллинны эт итеп сүкте.

— Алдады синең егетең, төпсез коега утыртты. Исеңә ал: мондагы хәлләр Мәскәүгә дә билгеле! Анда да бездән җавап көтәләр.

Ишморза Ташкәйгә тулысы белән ышана иде, шулай да, дөнья бит, ни булмас. Нидер үзгәргәндер, җыелу сәгате алышынгандыр, Ташкәй өстәмә рәвештә хәбәр җиткерә алмагандыр...

Әле ярый камаучылар, утрауда кеше юк дип исәпләп, тавышланыпнитеп йөрмәгәннәр иде. Икенче көнне ул яктан искән җил нәни генә тотен исе һәм мыгыр-мыгыр сөйләшкән тавышларны китерде. Ничәү алар, ни уйлыйлар? Кемне көтәләр? Ни әзерлиләр? Көн үтте, төнлә дә әлләни яңалыклар сизелмәде, таң яралганда, иртәнге өчләрдә утрауда хәрәкәт көчәйде. Милицияләр утрауга үтеп керердәй сукмакларны тапкандай кыланасалар да, бандитлар алардан мең остарак булып чыкты. Алар милиция вәкилләренең борын астыннан үтеп киткәннәр, ә болары аларның коерыкларын гына күреп калганнар икән.

Тавыш-хәрәкәтләрне чамалап, бандитларның санын якынычка исәпләп тә алдылар. «Егермегә якын бандит булырга тиеш!» — диде Лапиков. Бу зур, милиция уйлаганга караганда шактый кимрәк булса да, куркыныч, көчле оешкан банда иде.

Алдан билгеләнгән юнәлешләрдән дошман базаларына мөмкин кадәр якынрак килергә тырыштылар. Камаучылар арасында иң борчылганы Ишморза Муллин иде, әлбәттә. Дошманнар арасында Ташкәй бар! Ул көннәрдә егетне, ул үгетләде. Ул «саклап алып калырмын!» дип Миңнурыйга ант итте. Якынлашкангамы, әллә стаканнар, шешәләр ешрак чыңлый башлагангамы, качкыннарның тавышы ачыграк ишетелә башлады. Үзара танышу, мактану китте: кем фермадан егерме тавык урлаган да, кем урман каравылчысының борыны төбеннән сыерын йомдырып киткән. Әле Сорокинның сүз алганы юк, әле җитди әңгәмә кузгалмады. Шау-шу отыры тынды, шул чагында Лапиковның бераз каушаган, әмма көчле тавышы тирә-якны яңгыратты: «Сез камалуда! Бирелегез!»

Инде генә мач килде дип уйлыйсың, инде генә теге аракы чүлмәкләре эчеп-кызып саклыкны онытты дип беләсең, юк, күңелле очрашу мәҗлесе кинәт тынды, бандитлар төрлесе төрле якка сибелде, мылтыклар гөрселдәде. Ишморза Муллин прокурор белән янәшә урнашкан иде, прокурор кирәк чакта биеккәрәк менер өчен бер урынга ботак-сатак өеп шул тауччык өстенә күренмәслек итеп үлән түшәгән иде. Аталар бандитлар, кемнеңдер ыңгырашканы да ишетелде. Милиция кешеләренә ату тыелган, чөнки анда бандитлар арасында Ташкәй бар, аны ничек тә исән алып чыгарга кирәк! Кая ул, сиңа атканда коралсыз килеш түзеп торасың?!

Ишморзаның һәр якта күзе бар кебек, алны да, як-якны да күрә. Теге яктан ике кеше янәшә диярлек сулга ташландылар. Берсе Ташкәй! Камалыштан чыгып ычкына алса ярый ла!.. Ничек булышырга? Ничек аңлашырга? Ишморзаның: «Монда таба кил!» — дип кычкырасы килде. Ярамый! Ташкәй куактан-куакка, түмгәктән-түмгәккә кача-сикерә чапканда аңа барыр юлны күрсәтте. Күрдеме егет, юкмы, мәгәр Ишморза теләгән якка ташланды. Ул ара да булмады, прокурор үзе әзерләгән

чүмәләгә менеп басты һәм болай таба йөгергән Ташкәйне абайлады наганын шуңа төбәде. Соң дәрәҗәдә киеренке хәлгә килгән Ишморза: «Атма! Бу безнең кеше!» — дип кычкырды...

Мондый чакта була торган буталыш хәрәкәте башланды: кайда уң да, кайда сул икәнен аерырлык түгел иде, милиционерлар бандитларның берничәсен эләктәреп, тимер беләзекләр кигертеп юеш җиргә сузып яткырдылар. Алар дошманны җиңелгән санап үзара кычкыра, мактана башладылар. Ә прокурорның наганы үзләренә таба ашыккан Ташкәйгә таба төбәлгән иде. Егет бер күренә, бер югала, аяклары батып китеп егыла, прокурорның наган көпшәсе чайкала. Ишморза бөтен көчен җыеп: «Атма!» — дип кычкырды да тынсыз калды, Ташкәй белән прокурор арасына кергәч, гөрселдәп җиргә ауды...

Бандитларны, шул җөмләдән, күпме вакытлар тоттырмыйча эзен яшереп килгән Колгасар Михаил Сорокинны да кулга алдылар. Берничә кеше качып котылды. Бандитлар арасыннан өч кеше үлгән булып чыкты, милиция кешеләреннән ике кеше җәрәхәтләнде, бер кеше — Ишморза Муллин вафат булды...

Кулга төшкәннәрне Тубыл төрмәсенә алып кайтып, төрле-төрле камераларга кертеп тутырдылар... Ташкәй дә алар арасында иде.

Прокурор: «Капитан Ишморза Муллинны әнә теге яшь бандит атып үтерде!» — дип бар гаепне Ташкәйгә сылап куярга теләсә дә, аны һичничек исбатлый алмады. Лапиковның да эшне артык зурга җибәрәсе килмәде, ул: «Кем атканын кем белгән, пулялар төрле яктан сызгырып оча иде», — дип баргач, прокурор да җиңелде, «Капитан Муллинны дошман пулясы алып китте», — дигән нәтиҗә ясадылар, ялкынлы речьләр сөйләп егетне җиргә тапшырдылар.

Бер Миңнурый гына бу сүзләргә ышанмады, монда ниндидер сер калганын аңлап, ул Лапиков янына да керде, прокурор белән дә сөйләшеп карады. Актык чиктә кызны Ташкәй белән очраштырдылар.

— Өзеп кенә әйтә алмыйм, хәл бик авыр, катлаулы иде. Миңа төбәлгән наганны күрдем, ләкин азаккача күзәтеп басып тора алмадым... Аткан тавыш яңгырады, теге кеше, прокурор аткан кебек тә булды... прокурор булган икән, ух... Бер нәрсәне өзеп әйтәм, мин дә, минем янәшәмдәге егет тә, беребез дә атмадык Муллинга.

Миңнурыйның райкомнарга барып, нидер эзләп, чокчынып йөрүен ишеткән Лапиков, ашык-пошык приказ әзерләп, Ташкәй Ырсытдин улы Йортлыбаены фронтка озаттылар, ул турыдан-туры штрафбатка барып керде.

Отрядка соңгы вакытта килеп кушылган Березовка егете, өчнең берсе, Сорокин боерыгы белән ниндидер аксак адәмне атып үтерүе хакында белдерде. Ул күрсәткән җирдән Канталыевның мәетен казып алдылар.

Өч-дүрт ел буена Төмән-Тубыл тирәләренең котын очырып торган бандитлар шайкасы шулай тар-мар ителде. Бандитларның һәркайсына унар ел биреп, Колыма-Магадан тирәләренә тараттылар. Сорокинны чыгарып аттылар. Лапиков орден алды, калганнарга зур-зур акчалата бүләкләр яуды. Прокурор да, милиция кешеләре дә Миңнурый дигән укытучы кызны күңелләренең кара почмагына бикләп куйдылар. Эзләнәказына торгач, кызыйның кем баласы булуын да, нинди юллар белән Яланга килеп төшүен дә ачыкладылар. «Әһә», — дип күз кысты Лапиков прокурорга, «Эһем!» — дип тамак кырды прокурор Лапиковка карап...

Миңнурыйның киләчәге әнә шулай җиңел генә хәл ителде.

*Ахыры бар*

# ШИГЪРИЯТ



## Марис Нәзиров

### Язганым савап булырмы?

Язгандыр ачтан үләргә
Бу зәхмәтле заманда.
Шагыйрьләрнең бәһасе юк,
Баш имәсә яманга.

Булган бит шулай элек тә:
Ханнарның, әмирләрнең
Исеме кергән тарихка,
Үз итсә шагыйрьләрне.

Тырышкан шагыйрь асрарга
Империя, халифәтләр.
Үткәннәр әллә терелә,
Бүген шул ук гадәтләр:

Сыеныр куен кирәклек
Суга каләмле кулга.
Кичәге дуслар, дошмандай,
Тарткалый уңга-сулга.

Җан кибә тулай торакта,
Кысынкы ул, караңгы.
Үрелгәч калҗа сузалар,
Тик ак дисәң караны.

Язса да ачтан үләргә,
Баш имәмдер ялганга.

---

Марис НӘЗИРОВ (1949) — *Уфада яшәүче татар шагыйре, башкорт телендә ...асылган өч китап авторы. 1992 елда татар телендә (Уфа) «Йолдызлар табын ...ора» исемле китабы дөнья күрде.*

...Язганым савап булырмы
Бу гөнаһлы заманга?!

## Сез кайларда, татар угланнары?

Чорлар аша, әрнеп, үткәннәргә,
Халкым тарихына карадым:
Җил-давыллы язмыш йомычкадай
Җилтерәткән милләт корабын.

Сез кайларда, татар угланнары,
Җан асрыйсыз кайсы илләрдә?
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
Сөйләшәсез нинди телләрдә?!

Яр ташына кораб сугыла да
Чигә кабат упкын-диңгезгә.
Фәләстиннәр кебек, бәйсез илен —
Үз дәүләтен йөри ул эзләп.

Сез кайларда, татар угланнары,
Кайсы кыйтга, кайсы җирләрдә?!
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
«Әнкәй!» — дисез нинди телләрдә?!

Дулкын куган кораб адашмасын —
Акчарлаклар булып ялварам.
«Җил-давылда маяк кабызыйк без,
Очрашырга, ерак ярлардан!»

Сез кайларда, татар угланнары?!
Калдырасыз мирас кемнәргә?!
Кан тартмаса, бәлки, җан тартадыр,
Җыр җырлыйсыз нинди телләрдә?!
«Әнкәй!» — дисез нинди телләрдә?!

## Кайту өчен асылыма

Калса тормыш давылында,
Кайта кеше авылына —
Яшел үлән куенына,
Саф суында коеныргa...

Килү өчен акылына
Кайта кеше авылына —
Туган теле — толпарына,
Изгелекле туфрагына...

Кайту өчен асылыма
Кайттым менә авылыма —
Гасырларның хәтеренә,
Бабаларның каберенә...

* * *

И бу яшәү кануннары!
Кояш көлеп нур койганда
Кар гомере киселә...
Суы кибеп саекканда
Агыйдел дә төшерәдер
Боз калканын исенә...

И бу яшәү кануннары!
Җәйләр язга ук атканда
Көзләр барлый керешен...
Саргаеплар коелганда
Яфраклар да хәтерлидер
Бөреләрнең күз яшен...

И бу яшәү кануннары!
Елап туган нарасыйны
Ак биләүдә юату!
Карт ананы кәфен көтү,
Буйга узган яз анага
Ләззәттән соң ут йоту...
И бу яшәү кануннары...

## Ирмен дигән ир-егет

Ирмен дигән ир-егет
Җитез була җил кебек.

Юлсызлыкта юл таба,
Каф тауларын актара,
Сулар ярып, ут эчеп,
Җитмеш җәһәннәм кичеп.

Ирмен дигән ир-егет
Чая була җыр кебек.
Канатына иш эзләп,
Күңелләрне тигезләп,
Айкап чыга җир йөзен,
Калдырып нурлы эзен.

Ирмен дигән ир-егет —
Җәлилләрдәй хөр егет.
Күк тезгене биләндә.
Ил язмышы иңендә.

Матурлыкта бер егет.
Батырлыкта бер егет.

Син түгелме бу егет?

* * *

*Ф. Г.*

Талантларга ирек бирсәң,
Шашар, имеш, зарарлы:
Шагыйрьләргә күптән әзер
Бездә хөкем карары:

«Ярамый — нельзя!» мөһерен
Маңгаена басарга,
Зиндан-читлек өркетмәсә,
Атарга йә асарга!..

* * *

Яшәүдән һич туймамын.
Йорт-кура инде җиткердем дип
Эшләүдән туктамамын.
Ә торырмы үземнән соң
Корган оям — кулым эше?
Яшәүдән һич туймамын.
Яшьлек ярым картайды дип
Сөюдән туктамамын.
Тик карасын гомерем буе
Сөеп миңа — сөйгән кешем!
Яшәүдән һич туймамын.
Бакчалар инде тергездем дип
Эшләүдән туктамамын.
Ә ни шытар үзем киткәч,
Ядкяр иткән орлыклардан?
Яшәүдән һич туймамын.
Алкын алмаш үстердем дип
Яшьнәүдән туктамамын.
Тик язмасын бу дөньядан
Соңрак китү — оныклардан!

## Кайчагында...

Дүрт аяклы ат та абынганны,
Гаҗәпмени бәндә абынганы?

Бер хатаның гына зыяннары
Мотлак югалттырмый абруй-данны.

Кайчагында ләкин гомер буе
Ул сөйрәлеп бара арттан, аңдып...

* * *

Туфаннарның чәчендәге аклык
Кар гынамы?
Ул бит ут һәм куз.

Шагыйрьләрен зинданнарга япкан
Ил бәхетсез, халык хокуксыз.

* * *

Кораблар адашмас өчен давылларда
Учак кабызырга тиеш кемдер ярда.

Сынатмаммы зур сынауда — алда торган?
Күпме юл күрсәтер маяк — мин яндырган?

Башкалар атласын өчен такыр эздән
Башлап көрт ерырга тиеш кемдер тездән.

Үзем сөрлекмәмме — сукмагым да тап-тар?
Юл ясармы аны арттан килгән сафлар?



# Нәҗип Мәдияров

## ЕЛЛАРЫМНЫ БИЗИ ШИГЪРИЯТ

### Чынлап та, шаярып та

Тик торганда кашларыңны
Сикертмәсәң ни була?
Каш сикертеп, йөрәгемне
Җилкетмәсәң ни була?

Без тиң түгел ич, дип, тагын
Өркетмәсәң ни була?
Үз итмәвең ярар да ди,
Чит итмәсәң ни була?...

### Вакыт

I

Башы да юк аның, ахыры да,
Ул мәңгелек чиксез дөньяда.
Галәмнәрне безнең уй сыйдыра,
Ә ул сыймый хәтта уйга да.

Ул дөньяда һәр нәрсәгә ана;
Тудырган ул Җирдә безне дә.
Тудырган ул безнең тын хисне дә,
Шау-шу белән тулы сүзне дә.

Тудырган ул безнең дошманны да,
Дусларны да,
Хөрмәт, үчне дә.
Тудырган ул кеше батырлыгын
Һәм куркаклык биргән кешегә.

---

Нәҗип МӘДИЯРОВ (1928) — *шагыйрь, уннан артык китап авторы. Чаллыда яши.*

Тудырган ул җиңү, җиңелүне,
Тигезлек һәм тигезсезлекне.
Тудырган ул хаклык, хаксызлыкны,
Гаделлекне, гаделсезлекне.

2

Вакыт — карак, хисаплашып тормый,
Барысын да урлый дөньядан.
Көрәш аша алган бәхетне дә
Һич качырып булмый аңардан.

Әнә шундый шуклыклары белән
Кешеләрне кызык итә ул;
Безнең өчен иң кадерле булган
Яшьлекне дә урлап китә ул.

*1964*

## Гомер иткән нигез

Күчергәннәр картны яңа йортка,
Чирәм баскан иске өй эзен.
Шулай да ул бик еш карап китә
Үзе гомер иткән нигезен.

Нәрсә тарта икән аны монда?
Сөенечме, әллә кайгымы?
Сугышларга киткән вакытымы?
Әллә аннан кайткан чагымы?

Киләдер ул әллә хыялланып
Очратырга егет чакларын.
Кыңгыраулы атта бар авылны
Шаулатып кыз алып кайтканын.

Күңелендә бәлки дөнья куйган
Шул җанашын сагыну көчледер.
Әрнү тулы, сулган күңеленә
Монда дәва табылыр төсledер.

И замана! Эзе генә калган
Челтәрле, зур, сары капканың.
Карап тора абзый сүзсез генә
Үзе салган нигез ташларын.

Ул бит шушы йортны гөрләтергә
Ялыкмыйча, көн-төн эшләгән.
...Күчергәннәр картны яңа йортка,
Ә йөрәге аның күчмәгән.

*1968*

## Сөенә басу

Чал табигать куйды бу якларга
Болытларның юлын йозаклап:
Быел тагын иген кырларыннан
Янгырсыз ай узды озаклап.

Килде явым (ярсу болытларга
Кучер итеп җилне-давылны),—
Йөз меңнәрнең айлар буе сусап,
Көтеп алган тансык яңгыры.

Үрләрне күр, анда уҗымнарның
Иркен сулыш алган хөр көне.
Сөенә басу дошман яуларыннан
Исән калган дәүләт шикелле.

*1973*

## Тойгы

Бара идем яшьлек сукмагыннан,
Очар коштай булып синең янга.
Канатланып кайтып китә идем,
Җылы алып шигъри хисле җанга.

Йөргәнем юк хәзер ул сукмактан,
Йөри фәкать якты уем гына.
Тоям кайчак синең миңа булган
Бик күптәнге кырыс җылыңны да.

*1977*

## Гомернең бер мизгеле

Хәсрәтләрдән, юкса, арынган чак,
Шатлыкларга барып абынган чак.
Үземнеке түгел, дусларымның
Кайгылары белән кайгырган чак.

*1978*

## Автографың

Үкенечле булыр идемени,
Күңелемә язып калдырмасаң
Утлы карашыңны?
Еллар аръягына үткәч,
Кабат-кабат
Ни өчендер искә алам шуны.

*1980*

## Яшьләр җыры

Урамнарга җыр таратып
Үтәселәр бар әле.
Күңелләрдә моң яңартып
Китәселәр бар әле.

Чит-ят җирләрдә зарыгып
Ятасылар бар әле.
Урам көйләрен сагынып
Кайтасылар бар әле.

*1988*

## Аңлый башладың кебек

Шаяртып кынадыр инде,
Тәрәзәдән су сиптең.
Шул суны сибүең белән,
Йөрәгемне ут иттең.

Су түгелдер ул сипкәнең,
Шаярту утыдыр ул.
Шаярту утына поскан
Ярату утыдыр ул.

Ниһаять инде син мине
Аңлый башладың кебек.
Озак санламаган идең,
Санлый башладың кебек.

Сөю яшене яшьнәде
Чыгып синең суыңнан.
Яшьнәде ул, ә күкрәве
Булыр әле соңыннан.

*1990*

## Сагындыра

Сагына идек бит
Бала вакытларны,
Карап сабыйлыкның
Гүзәл якларына.
Сагындыра хәзер
Инде үсеп җиткән
Балаларыбызның
Бала чаклары да.

*1991*

## Сиздермим

Утта — ялкын,
Миндә дә...

Суда — дулкын,
Миндә дә...
Янсам янам,
Батсам батам,
Сиздермим бер
Кемгә дә.

Ялкын сүнде,
Миндә дә...
Дулкын тынды,
Миндә дә...
Сүнсәм сүнәм,
Тынсам тынам,
Сиздермим бер
Кемгә дә.

*1993*

## Яшьлек аланы

Безне бермәл зурлап күтәп алды
Яшьлек дигән гомер аланы.
Кердек аңа,
Бала чаклар белән
Мәңгелеккә өзеп араны.

Ул аланда чын мәхәббәт дигән
Дәрьяларга кереп коендык.
Гыйшык уты белән дөрләп торган
Учакларга килеп җылындык.

Күпләп эчтек сөю шәрабләрен,
Айнымаслык булып гомергә.
Их, нишлик соң, насыйп түгел икән
Ул «оҗмах»та озак йөрергә.

Сугарылып яшьлек дәрте белән,
Яшәр өчен сөеп-сөелеп,
Ары киттек гомеребез буйлап,
Мәхәббәткә төптән җигелеп.

Еллар уза.
Кайчакларда, нигә
Киттем аннан диеп үкенәм.
Кирегә юл югын белә торып,
Шул аланга кабат җилкенәм.

*1993*

## Кайчагында...

Зурдан кубып, яңа җырлар эзләп
Чыгып йөрим иген кырларына.
Ияреп кайта чалбар балагына
Кайчагында фәкать сырлан гына.

*1976*

# Сафуан Мулла-Гали



## Нигә өшим?

Чит җирләрдә,
Җирсү күңелемне,
Казан, синең, йөрәк утларың
Җылыттылар, җанны дөрләттеләр —
Кире борып үлем укларын...

Ул вакытта
Җанга җылы бирде,
Казан, синең җиләс җилләрең.
Без сагынган кебек,
Сагындың син безне —
Җылы хатлар язып җибәрдең...

...Ничә еллар инде кайтканыма,
Нигә өшим? — хәл юк атларга.
Әллә, Казан,
Йөрәк утларыңны
Бетердеңме биреп ятларга? —
Юл юк — кеше булып атларга...

## Басып торам барсын онытып...

Һәр таң саен сайрый бер моңлы кош,
Кочып «Аккош күле» каенын.
Мин дә ялгыз яшим, и моңлы кош —
Ташып торган чагы кайгымның...

...Дошманың күп, диләр кәккүкләрем,
Кая китеп бетте дусларым?
Кай чакларда якын дусларың да
Эшли икән дошман кушканын...

Каеннарга сара моң-сагышым,
Урман эче моңсу — иңкүле.
Сайра, сайра, моңлы сандугачым —
«Аккош күле» бит ул моң күле...

---

Сафуан МУЛЛА-ГАЛИ (1927) — *шагыйрь, «Сәлам бирәм», «Көзге балкыш», «Биздерсәләр туган җиреңнән» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

...Иелде баш —
Тамды күздән яшем,
Алтмыш җидем үтте — ут йотып.
Бал йотмадым шул яшемә кадәр —
Басып торам барсын онытып...

## Гүрничә

Айга кара, айга кара —
Ай бездән сезгә бара.
Көн дә барып күрер идем,
Их, якын булса ара...

Бер килеп тә чыкмыйсың бит,
Саргайттың — сагындырдың:
«Себеркесез чабындырдың»,
Өзелде сабырлыгым...

Үзем барам яннарыңа,
Түзә алмыйм күрмичә.
Бергә булсак, синең миңа —
Җир өең дә гүрничә...
Түзә алмыйм күрмичә...

## Бик авыр шул...

Болгана күктә болытлар,
Тагын күпме болганыр.
Юлым ерак — баш өстемә
Коеп ява боз-яңгыр...

Болыт гел бер җирдә тормый,
Болыт үтеп китәдер,
Тик йөрәгемдәге бозны
Кем эретер икән бер?

«Эретәм», дигән «дусларым»
Эретә алмадылар —
Алдандылар
Үзләре дә —
Тик мине алдадылар...

...Болгана күктә болытлар,
Болыт иле болгавыр —
Йөрәгемдә эремәгән
Бозны йөртү бик авыр шул,
Бик авыр...

## Бәхетем, таң атмадың...

Киңлекләргә очар идем
Булса үз канатларым.

Җаным күпме талпынса да,
Бәхетем, таң атмадың —
Алсуланды офыкларың
Кояш чыгар күк булып,
Тик сине көн дә каплады
Килеп бер кара болыт...
Ник ул болытны кисмәдең,
Юк идеме канатың? —
Ничә гасыр сине көткән
Йөрәгемне канаттың...

... Канатсызның бәхете дә
Канатсыз була икән.
Мин канатсыз яши алмыйм —
Азатлык игълан итәм...
Азатлыгым канат булсын
Киңлекләргә очарга!
Шунда гына үз бәхетем
Килер мине кочарга —
Киңлекләргә очарга!

## Кичекмә!

Уллрыңа юлдаш булсын тулпар,
Кызларыңа булсын сандугач.
Моңаясың, татар,
Саргаясың,
Чит җирләрдә илне сагынгач...
Канлы яшең ташны тишә синең,
Тама-тама — тамып кич-иртә.
Өмет өзмә, татар,
Ничек тә
Кайт илеңә — юлга кичекмә!
...Изге синең кылган гамәлләрең,
Ходай сиңа бирсен сабырлык.
Әштә тиң юк сиңа,
Акылыңны —
Илгә нигез итеп салырлык...
Күгәрмәде көмеш күңелләрең,
Тугры хезмәт иттең гомергә —
Кайгы-хәсрәт булды сакчыларың,
Сагыш белән булдың гел бергә.
Гасырларны үтеп адашмадың,
Гел якты таң булды кыйблаң.
Гомер бакый тыйнак булдың, татар,
Тик бәхетләр генә ким булган...
...Көтә сине ата-баба җире,
Якташ, изге юлга кичекмә —
Алла юлдаш булсын,
Явызлыкны
Без җиңәрбез утлар кичеп тә —
Кайт илеңә, татар,
Кичекмә!

■ ■ ■

## КОТЛЫЙБЫЗ!

# Шагыйрь Нур Гайсинга — 80 яшь

Яфракларын селки-селки
Шаулый карурман.
Бер кечкенә малай бара
Урман юлыннан.
Үзе ашыга, үзе карый
Тирә-ягына...
Ике кеше килеп чыкты
Аның янына.

Шулай башланып киткән бер шигырь бар иде балачакта безнең — дәреслекләребездә, һәм без аны бик яратып, яттан сөйләп йөри идек. Шигырьдәге малай — Олег исемле, ул, әлбәттә, чын патриот һәм советча сак, аңлы пионер: үзенә очраган теге «ике кеше»нең шпион икәнен чамалап алып, аларга «көнчыгыш ягын көнбатыш дип күрсәтә» дә, штабка чаба һәм аларны тоттыра.

Беркатлы, саф сюжет... Шикле кешеләр эзләү, аларны фаш итү чоры бу. Без шуларны бернинди икеләнүсез кабул итеп үстек. Без — шул чор җимеше...

Төне буе Нур Гайсинны укып,
Уянылган соңлап барсыннан,—

дип яза шагыйрь Марсель Галиев тә үзенең балачагы турында. Менә без өйрәнгән чынлык, менә — безнең дәвер поэзиясенең кайбер хикмәтләре! Хәзер, әлбәттә, моңа ышану кыен, әмма ул чакта без укучылар гына түгел, шагыйрьләр үзләре дә бу чынлыкка — «мәңгелек, бөек совет хакыйкате»нә ихлас мөкиббән иделәр ләбаса! Ә бит әлеге шигырь авторы Нур Гайсинның (Нурулла Әхъяр улы Гайсин) үз тормышы да бер дә әкияти-шигъри булып башланмый: 1914 елның 2 ноябрендә хәзерге Башкортостанның Чакмагыш районы Әхмәт авылында туып, җиде яшьтән тулы ятим калып, авырлыклар күреп үсә ул... Укырга омтыла: башлангыч белем алгач, Уфада телеграфистлар курсында укый, Баймак, Зилаир районнарында элемтәче, телеграфист булып эшли; аннан Зөя шәһәре төзелеш институты, соңрак Казан педагогия институты рабфакларында белем ала, укытучы булып эшли... Һәм шунысы кызык: студент елларында ук аның бер-бер артлы китаплары («Ватаным өчен», «Зәңгәр күктә» һ. б.) басылып чыга башлый, утыз җиденче еллар — татар әдәбиятының асыл вәкилләре юкка чыгып, әдәбиятка яшьләр килгән, әдәбият үзе дә «яшәргән» чорлар бу! Аннары — Ватан сугышы... Фронтта взвод һәм батарея командиры булу... 1946—52 елларда Казан татар театры училищесында директор урынбасары булып эшләү... Яңадан Совет Армиясендә хезмәт — бусы инде Ерак Көнчыгышта, 1952—53 елларда... Аннары — тик язучылык хезмәте... Ватанга, партиягә хезмәт итү.

Гадәти биография, «совет чоры кешесе»нең типик гомер юлы... Бүгенге күзлектән караганда, бәлки, яшьләрне уйландырырлык, кайбер алданулар белән узган кеше, халык, ил язмышы. Бәлки, чын бәхет — иҗади гомердәдер? Чыннан да, Н. Гайсин — ике дистәгә якын китап авторы. Нигездә — балалар өчен шигырьләр, пьесалар һәм «Кызыл ыштанлы малай» кебек документаль повесть, хикәяләр. «Таза Мортаза» кебек популяр китаплар, җырлар...

1950 елдан ул — Язучылар берлеге әгъзасы.

Гыйбрәтле, озын гомер иясе Нур аганы 80 яше белән котлыйбыз. Әйе, гомер урманы, «яфракларын селки-селки», шаулый да шаулый әле. Анда бүген дә нәниләр, бүгенге көн геройлары йөри, мөгаен!

**Рәдиф ГАТАШ.**

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Факил Әмәк**

## ЧЫТЫРМАНДА КОШ ОЯСЫ

ПОВЕСТЬ

### Кереш

Гыйльметдин нык-нык басып баскычтан күтәрелде, өйалдына кергән уңайга җилкәсендә ипле генә яткан газ савытын җай гына төшереп, почмактагы плитә янына куйды. Күңел түреннән эләктереп алган ниндидер җырны өтә-сүтә көйләп, плитәнең ак керәчтәй капкачын ачып җибәрде: эчтә гамьсез генә утырган, инде җиңеләеп калган кызыл савытны колагыннан өстерәп чыгарды да аның урынына яңасын урнаштырды. Эш беткәч, канәгать елмаеп, маңгаена табан шуышкан майлы кәпәчен баш түбәсенә үк этәреп куйды.

— Көтүче абзыйлар кайтуга газың бетсә, керер урын тапмассың,— диде ул, кулларын чалбарына ышкый-ышкый.— Газсыз дөнья сансыз!

Янәшәдә генә кемдер күзәтеп торган кебек тоелды аңа. Ул шикләнгән сыман як-ягына каранды, беркем дә юк иде. Аның көткән кешесе — Гөлҗиһаны, Гөлкәе никтер күренми. Өйдә дә тавыш-тын ишетелми. Инде шул гомер... Өйдә булса, чыкмый торыр идеме?! Ихата арасында йөри микән? Алай дисәң, Гыйльметдин тракторын турларына туктатуга капка янына атылыр, ирнең иңсәсендә яткан газ савытына килеп ябышыр иде.

— Рәхмәт, Гыйльметдин, инде үзем генә кертеп куйыйм, син кереп мәшәкатьләнмә — дияр иде ул ярымпышылдап. Кайнар сулышы колак яфракларын өтеп алыр иде — Әхнәф кич кайткач, корып куяр әле,— дип өзгәләнер. Кешеләрдән оялудан бигрәк, хатыны Сәкинәнең тавыш чыгаруыннан курка ул.

Суга-мазарга киткәндер, җә. Хатын-кыз унга ярылса да, өй арасында эше бетми инде аның. Гыйльметдин Гөлҗиһанны күрә алмавына кәефе

---

Факил ӘМӘК (Сафин Факил Миңнемөхәммәт улы, 1954) — *шагыйрь һәм прозаик. «Соңгы көз» һәм «Тузганак чәчәге» дигән китаплар авторы. Чаллыда яши.*

кырыла төшеп, чыгу ягына кузгалган иде, үтә дә мөһим нәрсә исенә килеп, өйгә керәсе итте.

Гадәттәгечә, пөхтә итеп җыештырылган, авыл өйләрендә генә була торган яктылык, күңелгә тынычлык иңдерә торган тыйнак пөхтәлек бөркелеп тора иде аннан. Өй эченә җир җиләге исе тулган... Карават ягына күз салуга, Гыйльметдин әллә нишләп китте. Йөрәге өзелеп төшәрдәй кысылды, битенә эсселек бәреп чыкты. Ул тетрәнеп калган иде. Караватта, дөньяда бер гаме юк шикелле, Гөлҗиһан йоклап ята. Үзе шундый сылу, йөзе гөнаһсыз, саф — нәкъ яшь чактагы кебек... Ир ашыгып карашын түбән төшерде. Читкә борыла төшеп, тамак кырды:

— Эһем-һем... Газ савытын алыштырдым, Гөлкәй...

Түзмәде, янә хатынга күз ташлады.

Гөлҗиһанның йөзенә җиңелчә генә алсулык йөгергән сыман булды. Ул тагын да сөйкемлерәк тоелды, хатынның озын керфекләре тибрәнделәр, әмма күзен ачарга ашыкмый иде әле ул. Кара борчак төшкән ак күлмәгеннән төртеп торучы күкрәкләре ирнең күңелен иләсләндереп, башын әйләндереп җибәрде. Их, хәзер, шушы минутта башны хатынның күкрәгенә куеп онытыласы, иркәләнәсе иде... Дөньяларың ник асты-өскә килми шунда! Яратасы, яратасы, гомердә булмаганча, яратасы иде...

Гыйльметдин бер-ике адым алга атлады да, мич йөзлеген кытыршы куллары белән сыйпап, авыр гына тын алды. Башка гамь төшкән чак шул.

— Сәйфи үлгән... Әле үзем дә яңа гына ишеттем...— Ул Гөлҗиһанның кинәт куырылып китүен тойгандай булды.— Ат белән печән алып кайткан булган, мескенкәем. Дөнья куды бит инде ул. Капка төбенә кайтып җиткән, йөк өстеннән төшми дә, төшми ди... Кече малае капка ачып атын керткән. Гөлзада чыккан да, Сәйфине исерек дип белгәндер инде, йөкне арбасы ние белән аударып ташлаган, ди. Сәйфи бүрәнә кебек шапылдап килеп төшкән. Шуткы түгел, чандыр дисәң дә, ир-ат гәүдәсе ул.

Гыйльметдин сүзен бүлеп, өйалды ягына борылып карады. Бая ук күңелен тырмап торган шиге янә тышка бәреп чыкты. Кемдер өйалды идәннәрен шыгырдатмаска тырышып, ишек алдына табан йөгереп чыгып киткәндәй тоелды аңа. Ул тәрәзә аша урам як капкасына күз салды. Чыгучы-фәлән юк. Әмма аяк тавышларын аермачык ишетте лабаса! Гөлҗиһан да бик сәер хәлдә кебек. Гыйльметдиннең сүзләрен ишетте дә сыман, тик тавыш-тыны юк.

Гыйльметдин йөгерә-атлый тышка чыкты һәм бер мәлгә баскычта туктап, тирә-якка күз салды. Йөрәге ашкынып тибә башлады. Әйе, ул ялгышмаган, бәрәңге бакчасыннан ындыр артындагы әрәмәгә табан чәчен-башын туздырып бер хатын-кыз җан-фәрманга йөгерә иде. Бер кулы белән күкрәгенә нәрсәдер кысып тоткан кебек. Ул арада йөгерүче киртәләрне сикереп кенә үтте дә, әрәмә арасына кереп югалды. Куаклар-да хафасыз чыркылдашкан чыпчыклар күтәрелеп һавага күтәрелде.

Гыйльметдин ни уйларга да белми, янә тирә-ягына каранды, аптыраулы халәттә, тагын өй эченә үтте. Аны Гөлҗиһан аяк өстендә каршы алды...

Күзләре зур булып ачылган, бите буйлап яшь ага. Кулында ак ситсага уралган төргәк.

— Менә, таба алмаган бит,— диде Гөлҗиһан калтыранган тавыш белән һәм төргәкне Гыйльметдингә суздың.

Ир гаҗәпләнеп артка чигенде.

— Нәрсәне таба алмаган? Теге... хатын кем иде ул? Кемнән качып йөри ул?

Гөлҗиһан исенә килгән сыман булды, сәерсенеп Гыйльметдингә карап торды да, башын ирнең күкрәгенә куеп, сулкылдап елап җибәрде:

— Хараплар була яздык бит, Гыйльметдинкәем.

Ир, хатынның иңнәреннән кочып алды, үзе каушавыннан ни эшләргә белми, һаман бер сорауны кабатлый иде:

— Теге... хатын кем иде соң ул? Мин аны күргәнем дә бар кебек...

— Әфүзә...— дип сулкылдады Гөлҗиһан. «Шамилнең ... әнисе» димәкче булган иде, теле әйләнмәде.— Шамилне алып китәм, дип кайткан булган. Әллә нәрсә, һушым китеп ятканмын. Инде чыгып киткән иде ул, кабат кереп, шкафтан өй салырга дип җыйган акчаны урлап китмәкче булган, ләгыйнь. Үзем сизеп ятам, юк инде, бер сүз эндәшә алмыйм. Ярый әле, син килеп керәсе иттең,— дип Гөлҗиһан Гыйльметдиннең көчле кулларын читкәрәк этәреп, урындыкка барып утырды.— Акча дип белеп, Шәйхаттар абыйның язуларын әләктереп качкан...— диде ул, әрнүле тавыш белән.

Инде Гыйльметдин үзе кергәнче монда нинди хәлләр булганын аңлаган кебек иде. Әмма шулкадәрле көтелмәгән һәм ышанмаслык хәл иде бу аның өчен, нәрсә әйтергә белмичә, баскан урынында таптанып торды-торды да:

— Җир дә йотмый шуның ишеләрне,— дип, үз гомерендә беренче мәртәбә сүгенеп куйды.— Кеше хакына кул сузарга ничек оялмыйлар диген.

Бая Гыйльметдин әйткән хәбәр хатынның аңына яңа барып җитте, ахрысы. Ул акча төргәген күкрәгенә кысып тоткан килеш, урыныннан сикереп торды:

— И бичара, Сәйфетдин үлеп киткән дисең бит. Гөлзада нишли икән инде, бу кадәр кайгыга ничек түзмәк кирәк. Ичмасам, янына барып, бераз юатып кайтырга иде,— дип, яулыгын төзәтеп бәйли башлады.

## I

Кыз өй турларына ничек кайтып җиткәнен дә сизмәде. Юк, атлап түгел, очып кайтты бугай ла ул!..

... И-и, бу язның серле табигате, күңелләргә чак кына кагылып китсә дә, дөньяны ялкын, ут итә һәм йөрәкләрдә посып яткан өмет тойгыларын дөрләтеп җибәрә алырлык сихри көче! Озак-озак йокыдан айный алмаган халәтендәге табигатькә җан иңде. Ул уянды, талчыгулы, әмма хозур хәрәкәткә килде.

«Әй, Кешеләр!— диядер төсле Яз-сылу.— Беләм, беләм, караңгы күзләрдә, салкын кышларда сагынып, ашкынып мине көткәнсездер, йокымсыраган хыялларыгызны терелтәм мин сезнең, аларга канатлар куям, хыялларыгыздан да югарырак биеклекләргә әйдим. Наз, сөю, дәрт алып килдем сезгә: яшәү дигән мөкатдәс гомернең кадерен белеп калыгыз».

Тыгыз, дымлы өрфиядәй йомшак җилләр колакка ерак кыйтгалар авазын алып киләләр сыман. Тыңлап карагыз әле җилләрне, сак кына тыңлап карагыз — һичшиксез, алар да сезне каядыр чакыралар, җанда рәхәт тыелгысыз хисләр өермәсе тудыралар. Сак кына тыңлагыз, колак салыгыз — әллә нинди ымсындыргыч авазлар, көй-моңнар, шаулы кыңгырау чыңнары ишетерсез сез язгы тансык җилдә. Җир туйга хәзерләнә. Җиргә яз килә, яз! Аһ, шушы язларда мәңге калырга иде дә, хыялларга беркайчан да күзге кыраулар кагылмасын, кышкы салкыннар җаннарга уралмаса икән!..

Бүген Фәймәләрдә аулак өй. Гөлҗиһан да шунда керергә тиеш. Болай ашкынып кайтуы да шуның өчендер әле. Аулак өй үткәрүнең тәртип-мәшәкатьләрен көндез үк сөйләшеп куйдылар, өйгә кайткач, озаклап юанасы түгел. Нишлисең инде, башка җай калмагач, ичмасам, рәхәтләнеп аулак өйдә күңел ачып калырга кирәк. Почмак якларыннан үтәли җил йөргән клубка барып әчкә суык төшереп утыру булмас әле. Хәер, клубка барып та ни кырасың?— Хәзер анда кыз-кыркынның күңелен

җилкендереп торган гармун тавышын да ишетә алмыйсың бит. Күздән бирле шулай. Кичләрен урамнарында гармун тавышы ишетелмәгән авылдан да шыксызрак авыл юк икән дөньяда.

Баһау Гыйльметдине — авылның бердәнбер гармунчы егете, Чаллыга тракторчылар курсына китте дә барды. Ул да китте, күңел күгендә җемелдәп янган йолдыз да сүнде. Башка яшьләргә кышын чыгу бер газап булса, эч пошыргыч бертөрлелек белән тулган һәр кичне үткәреп җибәрү мең газапка әйләнде Гөлҗиһанга. Җитмәсә, Гыйльметдин киткәннән бирле яшьләр аңа кырын караган сыман. Болай, бу хакта авыз ачып сүз әйтүче юк-югын да, кыз моны күңеле белән тоя. Астан гына сирпелгән утлы карашларны күтәреп утырмас өчен, башны алып, әллә кайларга олагырдай булырсың.

Әйе, Гыйльметдиннең уйламаганда-көтмәгәндә курсларга китеп баруына Гөлҗиһанның әтисен — колхоз рәисе Мөлековны гаепли яшьләр. Имеш, булачак киявен прастуй көтүче итеп йөртмәс бит инде рәис хәтле рәис кеше. Бүтәннәр, күзләреннән канлы яшьләр агызып еласалар да, җибәрәчәк түгел, югыйсә. Ә Гыйльмине, әллә үзе сораган, әллә юк, ат белән Чаллыга кадәр үк озатып куйганнар, ди бит...

... Китте дә барды... Хәтта, Гөлҗиһан белән саубуллашмады да... Соң чиккә җитеп рәнҗемәсә дә, кыз Гыйльметдингә үпкәләде. Китәсен нигә әйтмәде икән ул? Әллә, Ходаем, әтисенең кыланышына гарьләндеме? Әллә... Әллә күңеле суынды микән?..

... Йөрәктә төерләнеп калган ул кичне бүгенгедәй хәтерли әле Гөлҗиһан. Шимбә киче иде ул. Фәрвәҗетдин Мөлеков бик тә дуамал кыланды шул. Яшьләр шау-гөр килеп «бичер» ясап ятканда, клубка атылып килеп керде дә, гармунының моңыннан битәр, күз алдында бөтерелгән сылу кызларның дәртле биюеннән тәмам әсәрләнеп утырган Гыйльметдиннең якасыннан суырып та алды.

Шушында гына туктап калса әйбәт буласы иде дә, Фәрвәйнең эше кәяли башласа, шулай тузынып, тиресенә сыя алмый йөри торган гадәтен беләләр. Моңа олысы-кечесе күнегеп беткән инде. Юктан башка нәрсә юк заманда колхоз кадәр колхозны сөйрәп кара әле, котырмас җирдән котырырсың, дип кенә уйлыйлар.

Әмма бу юлы Фәрвәй ярты юлда туктап калмады — Гыйльметдиннең кулыннан гармунын суырып алды да бер якка селтәп җибәрде. Гармун, һавада шыңгыраулы мәхлук аваз чыгарып, ишек янына ук барып төште.

Фәрвәй исерек иде. Алыптай гәүдә, нәсел үгезендә генә була торган мәгънәсез акаеп каткан күзләр, җил тегермәне канатлары шикелле иләмсез куллар. Бер-бер көн итегенә дә өч егетнең аягы шыплап кына кереп утырыр сыман.

Рәис өнсез калган яшьләрне томанлы карашы белән айкап алды да Файмәгә сыена төшеп, шым гына утырган Гөлҗиһан ягына атлады. Болай да куркудан иреннәре күгәреп, бөрешеп калган кызына җикерде:

— Сиңа ни калган монда?! Хәзер үк өйгә кайтып кит!

Гөлҗиһан, яшенә тыгылып, йөгерә-атлый клубтан чыгып китте. Бу хәлдә ни эшләргә белмичә аптырашып-куркып утырган яшьләр, Гөлҗиһан ачкан ишек ябылырга өлгермәсен дигәндәй, дәррәү чыгу ягына кузгалдылар. Гөрләп торган клуб бер тын эчендә бушап та калды. Бераз исенә килгән Гыйльми идәндә аунап яткан гармунын күтәреп алды, йөзенә чыккан аптыравын яшерә алмыйча, «тагын ни кыланырсың»— дигәндәй, Фәрвәйгә карап катып калды.

— Яңадан да безнең өй тирәсендә гармун шыңгырдатып йөрсәң, матри, малай, гармунын-ниең белән койма башына элеп куярмын!— дип гайрәт чәчте Фәрвәй, егетне янә котсыз карашы белән сөзеп.

Чыгып киткән чагында Гыйльметдинне тагын бер аптыратты Мөлеков. Авыр имән ишекне тибеп кенә ачып җибәрде дә һаман да урыныннан кузгалырга җөрьәт итмәгән Гыйльметдингә борылды ул.

— Иртәгә таңнан Чаллыга, тракторчылар курсына китәсең. Ишетсен колагың, соңга калырлык булма! Кирәкле кәгазьләрне җитештерәсе булыр — килешли силсәвит Кәлине дә уятып чык.

Көтмәгәндә рәистән бу хәбәрне ишетеп, Гыйльминең күз аллары томаланды. Үзе дә сизмәстән:

— Кем белән барам? — дип сорап ташлады. Аннары бу сүзләре өчен үкенгән сыман, — Ярый, Фәрвәҗетдин абый, Кәлимулла агайга кайтышлый ук кереп, әйтеп чыгам, — дип, баштагы мәгънәсез соравын ямап куярга ашыкты.

Әмма рәиснең клубка кергәндәге кызуы сүрелгән иде инде. Ни сәбәптер кәефе дә күтәрелеп китте, шуңа күрә егетнең соравына да ипле генә җавап кайтарды:

— Куян Сәйфи белән икегезне җибәрәм.

Колхоз рәисе клуб ишеген ябып та тормыйча, нидер сөйләнә-сөйләнә, караңгылык эченә кереп чумды.

... Гыйльминең дә эченә җан керде. Баштагы мәлдә котырып дулаган рәнҗеше басылгандай булды. Күпме хыялланды ул тракторчылар курсына китәргә. Инде өмет бетте дигәндә... Әле игеннәрне җыеп алгач, Куян Сәйфи белән җаен китереп Фәрвәйгә бер шешә көмешкә салдырганнар иде алар, һәм идарә исеменә тракторчылар курсына укырга җибәрүләрен сорап алдан ук язып куелган гаризаларны да тәрткәннәр иде. Димәк, Фәрвәй бу хәлне онытмаган; иртәгә Чаллыга юлга җыенырга, ди бит.

Моннан өч ел элек Бикмәч урманында агач кискәндә уң кулының бармагын өздергән иде егет. Узган ел армиягә алынырга тиеш иде — комиссия үтә алмады. Шул бер бармак аркасында инде. Табиблар: «Тәте тартырга иң кирәкле бармагы юк», — дип, аны солдат шулпасыннан мәхрүм иттеләр һәм «кәҗә» билеты биреп җибәрделәр. Егет яман хәсрәткә баткан иде ул чакта. Беренчедән, сау-сәламәт көе, яшьтәшләре армиягә киткәндә, бетәшкән авыру хәлендәгеләр рәтендә «кәҗә» билеты тотып кал инде. Икенчедән, «тәте тартырга иң кирәкле бармак» гармун уйнаганда да алыштыргысыз иде шул. Әмма Гыйльми ничек итсә-итте — шушы гарип кулы белән дә сыздырып гармун уйнарга өйрәнде.

Үзе көенеп йөрсә дә, аның армиягә бармый калуына авылдагы кызлар сөенделәр генә. Гөлҗиһан да кош тоткандай йөрде. Тычканга үлем, мәчегә көлке, ди.

Гыйльми, колхозда атлар карау белән беррәттән, клуб мөдире вазифасын да башкара иде, клубны бикләп чыкты да, шылт иткән тавыш та ишетелмәгән урамнардан җәһәт атлап өенә, әнисеннән сөенче алырга ашыкты.

«Тракторчы булсаммы! — дигән куанычлы уйлар йөгерешә аның миендә. — Тамак та туяр, өс тә бөтен булыр, «кәҗә» билеты да онытылыр! Ул чагында Гөлҗиһан белән дә аяк терәп сөйләшергә булыр.

* * *

Гыйльметдиннән узып авылның бер егете дә Гөлкәйне озатып куярга батырчылык итмәде.

Клубта биеп, күңел ачып талчыккан, әмма йөрәкләре җилкенгән, күңелләре очынган яшьләр соң гына өйләренә таралалар. Баштагы шактый ишле һәм шау-шулы төркем әкренләп сирәгәя, эри. Бер мәлне урам уртасыннан гармун чыңлатып баручы егет белән янәшә атлаучы Гөлҗиһан гына кала.

... Гомер-бакый яктырткыч-фәлән күрмәгән төнге авыл урамы... Гасырлар буе күпме серләрне үзенә сыендыргандыр ул. Яхшысын да яманын да. Тик мәхәббәт, сөюгә кагылышлы серләрне генә ул изге итеп,

мәңге хәтерендә саклый торгандыр. Күпме яшь йөрәкләрнең бер-берсенә биргән кайнар вәгъдәләренә шаһит булгандыр ул. Боларны ул үзе генә беләдер, саф хисләрне шыксыз җилләргә дә сипми, усал күзләрдән дә яшереп тотадыр ул. Әй, син, төнге авыл урамы! Менә әле дә янә меңнән бер гашыйк парның ялкынлы сөю хисләренә шаһит булгансыңдыр...

Юк, төнге авыл урамы караңгы түгел ул, һич түгел. Аны төпсез күктә чекерәеп янган йолдыз тәлгәшләре генә нурландырмый, бәлки гашыйк ярларның тылсымлы сөю ялкынына уралып та балкый ул. Әлеге балкышны мәхәббәт утында янучылар гына күрә, тоя ала шул. Күңел күзләре сукырларга төнге авыл урамы дөм караңгы, очсыз-кырыйсыз кебек... Гыйльметдин өздереп гармун уйный, аннан, хисләренә бирелеп, көй җаена җыр сузып җибәрә:

Алларым диям сине,
Гөлләрем, диям сине.
Аллы-гөлле чәчәгем, дип,
Өзелеп сөям сине.

Гөлҗиһанның йөрәге өзелеп төшкәндәй була. Мөмкин булса, оялуын басарлык көч таба алса, егетнең кулыннан гармунын бер читкә алып торыр иде дә, егетнең кочагына атылып керер иде, куенына сеңәр иде, эрер иде... Ходай тәгалә Гөлҗиһанга буй-сынны да, чибәрлекне дә җәлләмәгән. Инде миннән калмасын дигәндер, кызга өздереп бию сәләтен дә, моңлы итеп җырлау осталыгын да кызганмаган. Җырга Гөлҗиһан да кушыла. Кайдан чыга бу кадәр йомшак, матур тавыш, сүзләрен каян таба дип уйла син:

Аргы яктан бирге якка
Басма салдым киң итеп:
Әй, гомерлек яр булсын, дип,
Сине сөйдем тиң итеп.

Җырның хикмәтле көче шунда да инде — телең белән әйтә башласаң, аптырап бетәр идең, буталып, иң кирәкле сүзләреңне таба алмый гаҗиз булыр идең, шабыр тиргә төшәр идең, ә монда исә — мә, әзер калыпка салынып куелган нәкъ син әйтәсе килгән уйлар. Җырга күңел түреннән ургып чыккан бар хисләр дә сыйган шул.

Капка төпләрендә сыенышып утырган чакларда егетнең өзгәләнеп «яратам» диюләре генә дә ничә мәртәбә кабатлангандыр. Кыз исә бу ялкынлы сүзне ишетүгә, сабырсыз егетнең иреннәрен учы белән яба да куя. Гыйльметдин бер мәртәбә өйләнергә ниятләвен дә әйтеп салды инде. Тик бу хакта Гөлҗиһанның гына ишетәсе килми. Унсигезе дә тулмаган килеш кияүгә атлыгып торырга, ул үз акылында бит әле. Кешеләр әллә нәрсәләр уйлап бетерерләр. Болай да тик тормый авыл гайбәтчеләре. «Гыйльми тракторчылыкка укып кайтуга Гөлкәйгә өйләнә икән»,— дип кайчаннан бирле тел чарлыйлар. Бу хакта егетнең үз теле белән әйткәне дә юк иде әле. Гайбәтчеләр фараз итеп сөйли, бу фаразлар рас килә дә куя тормышта. Гайбәтчеләрнең күрәзәчелек сәләтләре дә бар микәнни соң, ә?..

Хәер, Гыйльметдин үзе дә озак көттермәде — ул сүзләрнең дөреслеккә бик якын булуын әйтеп бирде. Чыннан да, егет тракторчылар курсына укырга җибәрелүен сорап гариза язган булган икән. Бу мәсьәләне идарә карый дисәләр дә, асылда Мөлеков үзе хәл итә бит. (Егет ике дә уйлап тормый, сүз колхоз рәисенә килеп кагылса, «Мөлеков» дип кенә җибәрә. Гөлҗиһан моңа күнегеп беткән инде; бөтен колхоз, олысы, кечесе шулай сөйләшә). Шулай да, Гыйльметдин үз теләгенә ирешүенә шикләнми, «берәр җае чыгар әле», ди, аның өчен хәсрәтләнә башлаган кызны тынычландырып. Егетнең кайгысы башкада — ул укырга киткәнче кыз-

дан вәгъдә алмакчы була да, менә бәла — кыз һич кенә дә вәгъдәләр бирергә ашыкмый...

Егет карап торуга юаш, ипле генә кебек күренсә дә, кызып китсә, тыярмын димә икән. Гөлҗиһан бу кадәресен дә белә... Шушы Фәймә аркасында инде.

... Узган яз Фәймә аны үзләренә туган тиешле күрше авыл егете белән таныштырмакчы булган иде дә... ахыры һәр ике як өчен күңелсез тәмамланды. Фәймәне әйт инде — Гыйльметдин белән Гөлҗиһанның аралары көннән-көн якыная барганын белеп, күреп тора иде бит. Җүләр, нәрсә уйлап чыгарган — күрше авыл егетләре белән йөрү мәртәбәлерәк, имеш. Булды, ди!

Шулай бер кичне Гөлҗиһан клубта, яшьләр уены оештырып йөргәндә, аны Фәймә бер читкә алып китте. Бүген әллә нәрсә булган Фәймәгә — клубка да соңлап килеп керде, сүзләренең рәте-чираты юк, еш-еш сулыш ала үзе. Өеннән клубка кадәр кемдер бастырып куып килгәндер диярсең... Фәймәнең кулларын бутый-бутый Гөлҗиһанга нәрсәдер аңлатырга тырышканын, тегесенең исә каршы килеп, тартәсен кире борырга җыенуын, Гыйльметдин дә күреп алды. Күңеле нәрсәдер сизенде, сагаеп, астан гына бу ике ахирәтне күзәтә башлады ул. Бармаклары күнегелгән серле гадәт буенча гармун телләрендә чабыша, күрүкләр ярсып тартыла, көйдән-көйгә күчелә — әмма күзләр, уйлар гел башкада. Әнә бит — Фәймә һаман үзенекен тукый, үрсәләнеп Гөлҗиһанны каядыр барып килергә кыстыймы? Чү, Гөлкәй бирешә түгелме соң? Әйе, Фәймә култыклап, аны ишек ягына алып китте. Сак бул, Гыйльметдин, гармун кочаклап кала күрмә.

... Фәймә исә ахирәтен үгетләвен белә.

— Өч кенә минутка урамга чыгып керик әле, — дип Гөлҗиһанны ышандырырга тырышты ул. — Котың чыкты,кемнән куркасың ул кадәрле? — диде ул күзләрен сәер елтыратып. — Бер генә сүз әйтәсем бар.

— Соң, сүзең булса, монда әйт, — дип, Гөлҗиһан читкә тартылды.

— Монда булмый шул, — Фәймә, инде ахыр чиктә, әйтеп салырга мәҗбүр булды, — анда сине бер кеше көтә...

— Кеше? — Гөлҗиһан бу сүздән соң бөтенләй үзгәреп китте. — Минем бер кеше белән дә очрашасым юк...

Фәймәнең күзләре яшьләнде.

— Миңа ышанмыйсыңмыни, ә? Әйтәм бит, чыгып, сөйләшеп кенә керерсең, өметләндердем бит инде аны. Сиңа да уңайсыздыр, тик мине дә аңла инде син, кыен хәлдә калам...

Күрәселәре, ишетәселәре булгандыр инде, Фәймәнең тәкатьсезләнеп әйдәкләвенә буйсынып чыгып китте Гөлҗиһан.

... Караңгы язгы кич иде бу. Фәймә аны клубтан читтәрәк торган ярым җимерек, хуҗасыз йорт ягына алып китте. Үзе һаман сөйләнә дә сөйләнә. Колаклар тонды аның бытылдавыннан.

— Көнләшәм синнән, малайкаем! Чынлап әйтәм. Синең урында булсам, белер идем мин нишләргә?

— Нишләр идең? — дип көлде Гөлҗиһан.

— Нишләр идемме?! Егетләрнең «Гөлҗиһан» дисәң башы-күзе тона бит. Белмәгән булып кыланма инде. Бик яхшы сизәсеңдер әле. Әнә, күрше авыл егетләренең дә башын әйләндерергә житешкәнсең икән, — Фәймә кычкырып сөйли, үз-үзен белештермичә Гөлҗиһанның беләген кысып-кысып ала.

Бу сүзләрне ишеткәч, кызның күңеле вәсвәсәләнә башлады. Күрше авыл егетләренең монда ни катнашы бар. «Бер кеше» дигәне кем була? Кайда соң ул? Җитмәсә, Фәймә аны зәхмәтле өй ягына алып бармакчы була. Бөтен яшьләр бергәләп клубтан таралган чакта да Гөлҗиһан ул йорт янынннан тын алырга куркып үтеп китә торган иде. Бу өйдә Нәгыймә исемле әби яши иде. Сугыш вакытында, кышның зәмһәрир суык

көннәренең берсендә өендә катып үлгән ул. Керүче булмагандыр инде, ай буе яткан шунда...

Ул аяк терәп карыша башлады.

— Кая алып бармакчы буласың син мине, Фәймә, нәрсә уйлап таптың? Нинди көнләшү сөйлисең тагын? Үзең кемнән ким? Такылдыйсың тузга язмаганны!

Фәймә шаркылдап көлеп җибәрде.

— Йә инде, әйткән бер сүзгә бәйләнмә. Беркайда да бармыйбыз, килеп җиттек менә. Бер кеше көтеп торырга тиеш иде — дип тә өстәде ул.

Гөлҗиһан туктагач, ул да туктап калды. Алга табан ахирәте бер адым да атламаячагын аңлаган иде инде ул.

— Кыйланма, Фәймә. Әйттем ич инде, кемгәдер мин кирәк икән, клубка керсен. Нигә караңгы почмакларда яшеренеп йөри ул?..

Шулай җиңел генә Фәймәгә ияреп чыгып китүенә үкенә башлаган иде инде Гөлҗиһан. Аның бер кеше белән дә очрашасы да, сөйләшәсе дә килми, тизрәк кире клубка гына керергә кирәк. Кире борылырга бик вакыт. Чыгып киткәннәрен Гыйльметдин дә күреп калды...

— Кеше дигәч тә, мин сине әллә нинди өрәк янына алып бармыйм бит. Күрше авылдан егет килгән иде. Синең белән танышасы килә, ди...

Гөлҗиһанның ачуы тышка бәреп чыкты:

— Мин синнән егет таптырганым юк бит әле. Яучы булдың мыни? Фәймә аны юмаларга кереште.

— Һи, малайкаем, безнең авылда аның ише егет юк ул. Сугышта да катнашырга өлгергән, аннан Мәскәүдә нindидер зур эштә булган. Командир. Юкка ачуланасың син, безнең туган тиешле кеше булгач, каршы килмәдем инде. Клубка чыгарга әзерләнеп беткәч килеп керде дә: «Шундый-шундый кыз белән танышасым килә»,— ди. Сине узган атнада базарда күреп калган икән ул.

Гөлҗиһан аңлап алды. Чыннан да, алар үткән атнада Әмәкәй базарына барып кайтканнар иде, үги әнисе белән. Шунда сары, сирәк тешле бер егет Гөлҗиһанга бәйләнеп җәфалаган иде. Кылтык, һай кылтык егет иде. «Синдәй кызны кулга төшермәсәм, исемем Хираҗ булмасын!— дип әтәчләнде ул.— Икенче атнада ук капитан Хираҗ Камалиев йөрәк ишегеңне шакыр, чибәркәй, көтеп кенә тор»,— дип тә һаваланган иде. Кайсы авылдан икәнен төпченгән чагында Гөлҗиһан шаяртып: «Түбән Таллыктан»,— дип кенә котылмакчы иде дә, үги әнисе сатты шул:— Нигә яшереп торган буласың инде, Күперледән диген»,— дип ярды да салды. Тегенә шул җитә калды, базардан кайтып киткәнче тирәләрендә бөтерелде, кызның бу сагыз-егеттән саруы кайный башлаган иде хәтта. Шушы уйлар башында бөтерелгән арада, авызына тәмәке капкан егет үзе дә пәйда булды. Кыз аны тавышыннан таныды.

— Җир астында булсаң, аннан да эзләп таба идем, чибәрем,— дип ул Гөлҗиһанның каршына килеп басты.— Гвардия капитаны Хираҗ Камалиев сезне бераз урам әйләнеп кайтырга чакыра.

Күренеп тора, егет үз-үзенә шулкадәрле ышана иде ки, Гөлҗиһан аның тәкъдимен кире кагар дип уйламый да иде, ахрысы.

— Бу урамнарда күп йөрдем инде мин. Йөрисең килсә — үзең йөр. Фәймә белән икәүләп...— дип тә өстәде кыз.

Хираҗ көлгәндәй итте.

— Хә-хә-хә... Фәймә дә ярамаслык кыз түгел. Тик ул миңа сеңел тиешле кеше бит. Килешеп бетмәс.

Иңнәрендә Фәймәнең кулын тойды Гөлҗиһан.

— Шушындый егетне дә ычкындырасың...— дип пышылдады ул һәм ахирәтен җиңелчә алга этәрә төште.

Гөлҗиһан аптырашта иде. Саллырак итеп җавап бирмәкче иде, өлгермәде. Клуб ишегенең шактый каты тавышланып ябылганы ишетелде.

Гөлҗиһан гына түгел, Фәймә белән Хираҗ да сагаеп, тын калдылар. Гыйльметдиннең ачулы тавышы йөрәкне чеметтереп алды.

— Кай якка киттеләр алар?

Аяк тавышлары да ишетелде. Эре-эре атлап йөгерүче Гыйльметдин Гөлҗиһаннар турысына яшен тизлегендә якынлашты.

— Нишләп тору әле монда?! Нигә клубка кермисез?— дип сорады Гыйльметдин килеп җиткән уңайга.

Гөлҗиһанның күңеле дөрес сизенгән — Гыйльметдин аларны юллый чыккан иде. Тавышы төксе егетнең. Сулышы кабынган, ярыйсы ук ярсыган да кебек...

Гыйльметдиннең шулай тәкәллефсез генә арага килеп керүе Хираҗга ошамады.

— Син сорамасмы дип торабыз,— диде ул авызындагы тәмәкесен бер читкә өреп. Үзе Гөлҗиһаннан бер адымга чигенми, һаман аңа сырыша.

Гөлҗиһан ике ут арасында калды.

Гыйльметдин бу хәлдә үзен ничегрәк тотарга белми, икеләнебрәк калды. Ул үз алдында торган чакырылмаган кунакның күрше авылның сазаган егете «Куык» кушаматлы Хираҗ икәнен танып алган иде. Үз авылларында яучы җибәрмәгән кызы калмады бугай. Инде Күперлегә кармак салырга уйлаган икән.

Хираҗга да Гыйльметдин яхшы таныш. Якын-тирәдә гармунчылар бармак белән генә санарлык. Алар арасында иң остасы — Гыйльми. Әмма кунак егете кызлар өчен тарткалашып өйрәнгән иде инде. Үзенә кызлар тәтемәсә дә, егетләрнең канына тозны күп салды. Алай тиз генә шыр җибәрүчеләрдән түгел. Ул Гыйльмине танымаганга сабышты.

— Слушай, син кем буласың соң? Би-ик харап кыланасың! Мин сине белмим, и знать не хочу! Урамыгыз киң күренә, юлыңда бул!— Аның түше Гыйльметдиннең күкрәгенә тия язып тора иде инде. Кунакның авызыннан аракы исе килә, ул әтәчләнүен дәвам итте.

— Яхшы чакта аттыр моннан.

«Кара син моның әрсезлеген!»— дип уйлап алды Гыйльметдин. Моңа ирек бирсәң... Юк инде, ансы булмас! Җебеп төшәргә ярамый.

— Кем аттырыр бит әле, агай-эне, карт җизни!— Бусы кунакны үчекләү иде. Гыйльметдин Гөлҗиһанга эндәште.— Каян килеп чыккан кош бу? Кем чакырып китерде?

Гөлҗиһан тәмам каушап калган иде.

— Бел-мим...— Аның иреннәре калтырый, йөрәге дөп-дөп тибә, бу хәлгә үзен гаепле тойганга, күзләреннән яшь атылып чыгардай булды.

Мондый чакларда фәлсәфә сатып, сүз куертып торудан мәгънә юклыгын яхшы үзләштергән иде Хираҗ. Инициатива кемдә, җиңү — шунда! Ул, көтеп тормастан, куш йодрыклап Гыйльметдиннең күкрәгенә тондырды. Үзе читкә сикерде.

— Юлда торма дим бит, сопляк! Чакырып китерүләргә калган кеше тормый каршыңда.— Хираҗ пулеметтан аткан сыман сиптерде генә сүзләрне. Ул Гыйльметдин аяк астында тәгәрәп ятар дип уйлаган иде дә, тегесе чайкалып китсә дә, егылмады.

Гыйльметдиннең тыны кысылды, бугазына төер утырды. Үз авылында диярлек сөйгән кызыңны куеныңнан тартып алып, үзеңне тукмап китәргә маташсыннар инде. Гарьлеге ни тора! Ул, арыслан кебек, Хираҗга ыргылды һәм «кунак»ның шинелен изү турысыннан эләктереп алды. Әллә шинель бик үк яңа булмады, әллә эләктерү «чамасыз» булды — Хираҗның култык асты «шатырт» итеп аерылып чыкты.

— Йә, кем белән сөйләшәм инде мин?— дип сорады Гыйльметдин сүзләрне теше арасыннан гына чыгарып.— Кем ул... манка?

Хираҗ мондый дуамалланып ябышуларны да күрмәгән кеше түгел. Касыкларына бер төртсәң, бөгелеп төшәләр алар. Шуңа күрә шырләп

төшмәгәнен сиздерергә булды. Йодрыкны ияге белән читкәрәк этәреп ысылдады:

— Капитан интендатской службы Хираҗ Камалиев булам мин, энекәш! Фронтовик! Ә син...— Ул мыскыллы тавыш белән Фәймәдән сорашкан булды,— бу малай әллә... теге...

Фәймә ашыгып җавап бирде:

— Гыйльметдин... Юк нәрсә өчен бугазга бугаз килмәгез инде,— дип, егетләрне тынычландырырга тырышты ул. Ник дисәң, Хираҗ бик әтәчләнсә дә, кемнең өскә чыгасы билгеле түгел. Кунагың җиңсә ярый да...

Аның сүзләренә игътибар итүче булмады. Егетләр инде ярсыганнар, мыш-мыш килеп бер-берсенең буыннары ныклыгын сыныйлар. Өзешмичә туктау юк иде.

— Ә-ә...— дип сузды Хираҗ, һаман да шул мыскыллы тавыш белән.— Үзе кисәк кенә каерып Гыйльметдиннең кулын ычкындырмакчы булды.— «Кәҗә» билеты алган җегет шушы буламыни инде? Фронтовикка кул озайтып маташасыңмы, ә?!— Ул Гыйльметдиннең кулыннан ычкынып та китте, «гөрс» итеп егетнең йөзенә китереп тә сукты.

Гыйльметдин турында, аның Гөлҗиһанга булган мәхәббәте хакында да Фәймә Хираҗга сөйләп, аңлатып өлгергән булса кирәк. Сугуына караганда «кәҗә» сүзе ныграк тәэсир итте Гыйльметдингә. Гөлҗиһан, каршысына баскан Фәймәне этеп җибәрде дә, егетләрнең уртасына кереп басты.

— Туктагыз инде! Мин бит болай булыр дип уйламадым. Гафу ит, Гыйльметдин. Сугышмагыз гына...— дип ялынды кыз. Ул елый иде.

Гыйльметдинне тыяр көч юк иде инде. Җитмәсә, йөзенә сукканнан соң, авыз эчендә тозлы тәм барлыкка килде. Кан китте, авыздан. Кемне, ни өчен гафу итәргә?! Иң элек ул Гөлҗиһанны бер читкә селтәп җибәрде.

— Егет эзләп чыктык та, хәзер яклап йөрисеңме Куыгыңны? Мыскыл иткән буласыңмы?!— Шул арада Хираҗның ипи шүрлегенә дә менеп төшәргә өлгерде ул. Бу ярсу каян килгәндер — үзендә тыелгысыз көч сизде егет. Хираҗның мондый йодрыкны беренче тапкыр гына татуы булды, ахрысы, «гык» кына итте дә, арыш көлтәсе шикелле авып та төште. Язгы юлга сузылып яткан егет тын да тартмый, селкенми дә.

Моңарчы артык тавыш чыгармый, күзәтеп торуны хуп күргән Фәймә төнге һаваны дер селкетеп кычкыра башлады:

— Коткарыгыз! Кеше кыйныйлар! Сугышалар, коткарыгыз!

«Кунак» һаман җирдә ята иде әле. Фәймә Хираҗның баш очына тезләнеп, колагын егетнең авызына якын китерде. Тыны бармы, җан тәслим кылмаганмы, янәсе. Кызның тузгыган чәче йөзен кытыклапмы, чырыйлап кычкыруыннанмы, Хираҗ аңына килде. Үзенә иелгән башны Гыйльминеке дип белеп, куллары белән тегенең ике колагы турысыннан эләктереп алды да, кисәк кенә күтәрелеп башы белән «дошман»ның маңгаена тондырды. Фәймә «аһ» итәргә генә өлгерде, бөкән урыныннан бер як кырыйга тәгәрәде. Хираҗ әле һаман эшнең нәрсәдә икәнен аңлап бетермәгән иде, «дошманын» тәгәрәткән уңайга җитез генә аякларына торып басты, әмма аны янә Гыйльметдиннең тимер йодрыгы каршылады. Бу юлы Хираҗның эченә эләкте. «Кунак» егет урталай сынды, алпан-тилпән ике-өч адым читкәрәк каерды һәм, «дошман» якка подкрепление килеп җитте дип уйлап булса кирәк, җан-фәрман караңгылыкка ыргылды.

Шулай итеп, япуннарны тар-мар итүдә катнашкан фронтовик Хираҗ Камалиев өчен Күперледәге алыш уңышсыз тәмамланды.

... Ахырдан аңлашуы бик җиңел булмады Гөлҗиһанга. Гыйльметдиннең акылы үз башында, башта бик үртәлсә дә, тиз суынды тагын. Егетнең бигрәк тә Фәймәгә ачуы килгән иде.

— Күреп тордым бит, ничекләр юмалап алып чыгып китте ул сине. Юха елан икән. Син аның өчен үлеп торган буласың. Ахирәт, имеш...

Гөлҗиһан бар гаепне Фәймәгә өеп калдыруны өнәмәде. Аңа ачу сакламавын үтендә егеттән. Гөлҗиһанда да гаеп юк түгел бит. Чакыручылар күп булыр, нигә ияргә. Җүләрлек инде.

... Егетнең киткәннән бирле бер хат та язмавын Гөлҗиһан бик авыр кичерде. Бу кадәр үткәрә алмыйча интеккән, бәгырьләргә төшкән кышны ул белми иде әле. Гыйльметдинне уйлап өзгәләнмәгән чагы юк, йоклап китсә дә, төшләренә кереп йөдәтә егет. Мәхәббәт дигәннәре барсын өстен-аска китерә икән. Эшкә дисәң — эшкә кул бармый, ашарга утырса — ашауның рәте юк.

Бүген, бәлки, шушы шөбһәле-газаплы уйларга чик куелыр — Фәймә әйтә, аулак өйгә Гыйльметдинең дә кайтып житешмәс микән әле, ди. «Каян беләсең?» — дип соравына каршы уенын-чынын бергә кушып: «Телеграмма суктым, Гөлкәең бөтенләй янып, көл булып беткәнче, күрергә кайтып кал дип, яздым», — ди. Үзе көлә.

Фәймә көлүеннән туктап, Гөлҗиһанның күңел тынычлыгын алырлык сүзләр дә әйткән иде:

— Куян Сәйфинең хаты килгән. «Укулар ахырына якынлаша, шушы көннәрдә сынаулар башлана. Әзерләнү өчен бер атна вакыт бирәләр, бәлки авылга да кайтып килербез», — дип язган ди. Кайтсалар, икәүләп кайталар инде алар. Гыйльметдинең генә берәр шәһәр чибәркәенә ияләнмәсә.

Гөлҗиһанның сер бирәсе килмәде:

— Һәй, Чаллының шәһәр дип әйтерлек җире дә юк, ди бит аның.

— Барыбер, кызлары без түгел инде, — дип, үртәвен дәвам итте Фәймә. — Шәһәрнекеләр авыл егетләрен әләктерсә, җибәрми инде алар. Авыл егете эшнең рәтен белә. Шәһәр егетләре аракы эчеп, шәлперәеп беткәннәр, алардан ни малака, ни ширест. — Фәймә җитдиләнеп, Гөлҗиһанга эндәште. — Юк-бар эш табып, аулак өйгә килми калма, дим!

— Киләм, дидем ич инде... Фәймәнең хәбәреннән башы әйләнеп киткәндәй булды.

Их, Гыйльметдин кайтса! Күңелләрдә бар шик-шөбһәләр таралыр, ул гына да түгел, Фәймә белән Гөлҗиһан арасындагы салкынлыкка, киеренкелеккә чик куелыр иде. Мөнәсәбәтләр ачыкланса, алар элеккечә көләрләр, шаярырлар, серләшеп туймаслар иде. Әйе, бүген нәрсәдер булырга тиеш. Күңел юкка урыныннан кузгалмагандыр!

* * *

Менә шушы хәбәрдән ашкынып кайтты ул өенә.

Караңгы өйалдына кереп, ишек тоткасына үрелгән иде, өй эчендә быдыр-быдыр сөйләшкән ирләр тавышын ишетеп, Гөлҗиһан ирексездән тукталып калды. Кунаклар бар дисәң инде... Аларның өйләренә чит-ят кешеләр сирәк керә, болай кичкә калып килүчеләрне соңгы вакытта хәтерләми дә. Чөнки беләләр: йорт хуҗасы ордымбәрдем холыклырак адәм. Дүрт класс белемле Фәрвәй Мөлеков сугыштан соңгы авыр елларда фәкать шул усаллык чигенә җиткән дуамаллыгы, «давай»лыгы белән генә колхозны җилтерәтеп алып баручы рәисләрнең берсе иде.

... Өй эченнән яңгыраган ят тавышлар ишетеп, кыз каушап киттеме соң, ишек тоткасын таба алмый җәфаланды. Кармаланып, ишекне ачып җибәрүгә, борынга әчкелтем-төчкелтем исләр килеп бәрелде. Чит кеше берәү генә иде. Өстәл өстенә туры китереп түшәмгә элengән унлы лампаның кызгылт яктысында бригадир Әухәтне шәйләп алды Гөлҗиһан.

Әухәт — ялгызы гына гомер сөреп ятучы буйдак ир иде. Сугыш вакытында әнисе, хатыны белән бердәнбер улы да яз көнe кар астыннан

чыккан башак ашап, кан косып, тиз арада аллы-артлы гүр иясе булдылар. Әүхәтнең бу вакытта сугыш гарасатлары эчендә гизгән чагы, шушы хәбәрләрне ишеткәч, полк командирына рапорт язды, үзе теләп разведка взводына билгеләүләрен сорады. Куркусызлыгы, тәвәккәллеге белән күпне күргән тәҗрибәле аркадашларын да гаҗәпкә калдырган мәлләре аз булмады аның. Гомере булгач, сугыштан да исән-сау чыкты, әле яулар тынгач та җиде ел солдат хезмәтен үтәп кайтты ул. Аны инде бетте, сугыш вакытында ук хәбәрсез югалды, дип, якты дөньядан күптән киткән кешегә санап йөриләр иде. Гел онытып бетергәндә, гимнастеркасына өч орден тагып кайтып кермәсенме! Әүхәтнең исән-имин кайтуы авыл өчен сугыштан соң иң зур вакыйга булгандыр, мөгаен. Аннан күп еллар алда кайтып, сугыш хикмәтләрен бераз хәтердән җуя башлаган фронтовиклар Әүхәткә көнләшеп тә карадылар — якын-тирәдә өч орденлы фронтовик бер Әүхәт кенә булып чыкты. Ләкин Әүхәтнең хәле көнләшерлек түгел иде... Кайткач та, аркылы-торкылы такта белән кадакланган йорты болдырына утырып үксеп-үксеп елап, күңелен бушатып алды ул. Аннан күршеләре Бәдри абзый белән зиратка юл тоттылар. Иң якын кешеләренең каберләрен эзләп таптылар. Икенче көнне җир белән тигезләнеп бетә язган каберне (берьюлы үлгән өч мәеткә өч кабер казырга ул чагында авылда җүнле-башлы кешесе булмаганмы, барсын да бер кабергә күмеп куйганнар икән) төзәтте. Колхоз идарәсе аша сорап алган такталардан койма тотып, кабер өстенә өч каен утыртып куйды. Вафат булучылар рухына картлардан Коръән укытып, хәер таратты да, башы-аягы белән колхоз эшенә чумды. Аны сугыш елларында партиягә алганнар иде, озакка сузмыйча, бригадир итеп куйдылар.

Әүхәт, карап торуга, үз алдына бикләнеп, йөзенә хәсрәте бөркелеп чыккан басынкы табигатьле, салмак хәрәкәтле ир иде. Әмма эчеп алса — янына килгесез кыргый көчкә ия кешегә әйләнә. Үткән көзгә кадәр Фәймәгә адарынып йөрде ул. «Өйләнергә, йортка җан иңдерергә кирәк»,— дип, кызның күңелен дә кузгатып җибәрде.

Сарык фермасында бәрәннәр караучы кызлар төннәрен алмашлап каравыл өендә куналар, буаз сарыкларны саклап бәрәнләтәләр, бәтиләр әнкәләрен имгәч, җылы торакка ябып куялар иде. Төн дисәң дә, кызларга әллә ни куркыныч түгел, чөнки каравыл өендә төнен дә кеше өзелеп тормый. Ат караучылар да тыз-быз йөриләр, сыер торагын саклаучылар да кереп чыгалар. Һәркайсының үз вазифасы, үзенә йөкләгән эше бар.

Фәймәнең ялгыз калган чагын, ничек чамалыйдыр, әмма Әүхәтнең моңарчы форсатны ычкындырганы булмады. Башкалар исә Әүхәтне каравыл йортында төн уртасында күрсәләр дә, әлләни гаҗәпләнмиләр — бригадир бит, йомышы төшкәнгә йөридер, дип кенә уйлыйлар иде.

— Шушы Әүхәт башыма җитәр микән инде...— дип, бер көнне Фәймә балавыз сыгып алган иде.— Төнлә каравыл йортына килеп минем башымны катырып утырмаса нәрсә була! Кеше шикелле өйгә сорарга килсә, бармас идеммени инде. Юк, бит, эчмәгән чагында кайда икәнемне дә белми, бераз авызына керсә, килеп җитә. Яратмый ул мине. Үзе йөри.— Фәймә уфтанып куйды.— Туйдым инде болай яшәүдән, әнкәй авыру, әткәйне яралары интектерә. Җүнлерәк кияүгә чыксам, ичмасам, аларга ярдәм итеп, булышып яшәр идек.— Кыз күз яшьләрен бишмәт җиңе белән сөртте дә, битараф тавыш белән өстәде:

— Безнең эше хәерчеләргә Әүхәт кебекнең күзе төшкәнгә дә рәхмәт инде. Кеше фәрештә булмас, сорап килсә, ике дә уйлап тормыйм, чыгам да куям!

Фәймә шулай кияүгә чыгам, балалар үстерәм, җиң сызганып дөнья көтәм дип хыялланып йөргәндә, өстенә кар тавы җимерелдемени — Әүхәт аннан читләшә башлады. Кыз баштарак аптырап, ангы-мингерәк йөргән иде дә, бераз һуш җыйгач, әлеге хәлнең сәбәбен дә аңлагандай булды: Әүхәтнең күзе Гөлҗиһанга төшкән икән бит...

Аңа бу хәбәрне Куян Сәйфи җиткерде. Егетнең ниндидер документы җитешеп бетмәгәнме, аңа тиз генә авылга кайтып килергә туры килгән иде. Гыйльметдин җай туры килүгә куанып, аның артыннан Гөлҗиһанга хат җибәргән иде.

Сәйфи хатны иясенә клубта тапшырырмын дип чыкса — Гөлҗиһанның кизүдә икәнен белеп алды. Яшьләр белән хәл-әхвәл алышып, Чаллы хәлләрен биш-ун мәртәбә арттырып, мактанып сөйли торгач, төн җиткәнен дә сизми калган. Кайтыр вакытта гына Гыйльминең гозере исенә төшеп, Сәйфи каравыл йортына табан атлады. Йорт янына җиткәч, ничегрәк Гөлҗиһанны чакырып чыгарыйм да, ничегрәк хатны тапшырыйм микән, дип уйланып тора иде, йорт ишеге шаулап ачылып китте. Сәйфи әллә шүрләп, әллә кызык өченме, якындагы зур су чаны артына посты.

Аермачык күрде: ишектән чыгучы — бригадир Әүхәт иде. Артыннан озата чыгучыны да танып алды Сәйфи — анысы Гөлҗиһан. «Юкәдә икән чикләвек»,— дип куйды Сәйфи. Ул Әүхәттән чын-чынлап курка иде. Шуңа күрә каравыл йортына кереп, Гөлҗиһанга хат бирү теләге шушы мизгелдә үк сүнде. Бәладән баш-аяк, Гыйльми укуда, дип, чибәр кызның күңел кылларын тарткалаучылар булмасмыни! Әле Гөлҗиһанның Гыйльмине яратамы-юкмы икәнен кем белә. Егет үзе генә хыялланып ятамы шулай? Ә Әүхәт белән Гөлҗиһанның аралары бер дә уен-муен булырга охшамый, әнә төнлә дә бергә-бер калып серләшеп йөриләр икән. Күреп тора — каравыл йортында башка кешеләр юк ич. Хат китереп, араларына кереп йөргәнне Әүхәт сизеп алса, муеныңны артка борып куяр.

Иң яхшысы — тизрәк таю кирәк.

Куян Сәйфи күргәннәрен икенче көнне үк Фәймәгә дә җиткерде. Чаллыга әйләнеп килгәч, Гыйльмигә дә төкми-чәчми сөйләп бирде...

Гыйльми бу хәбәрне ишеткән көннәрне нинди газаплар белән үткәргәндер, әмма Фәймәнең бөтен җанын, тәнен Гөлҗиһаннан үч алу тойгысы биләп алды.

Гөлҗиһаннан кай төшем ким соң дип, төннәр буе елап, күзләре шешенеп бетә иде кызның. Күңелендә ахирәтем дип йөргән кешегә никадәр ачу, үпкә җыелмасын, ни гаҗәп Әүхәткә бер рәнҗеше дә юк иде. Бар гаеп Гөлҗиһанда! Ул егетләр алдында инсафлы гына йөргән була, ә үзе аларга астан гына күз сирпеп ала. Ир-егеткә шушы бер караш җитә дә инде. Әллә Гөлҗиһан — шуны белмиме? Белә! Белә торып кылтая, башкаларның сөйгән ярларын тартып алудан тәм таба ул. Ни әйтсәң дә, персидәтель кызы, шуңа масая!— дип уйлап ята Фәймә. Ахырда, түзмәде, Гыйльметдингә хат язып җибәрде. «Син, Гыйльми, кеше белән сугышырга беләсең дә, гармун кычкыртырга оста. Башка эләккән эш юк синдә!»— дип төгәлләгән иде хатын Фәймә.

* * *

Әйе, Гыйльметдин китеп озак та үтмәде, Әүхәт Гөлҗиһанга сырыша башлады. Бу Гөлҗиһан өчен көтелмәгән хәл булса да, Әүхәт өчен алдан уйлап йөртелгән эш иде. Гөлҗиһан белән Гыйльметдиннең бер-берсенә булган хисләрен белә иде Әүхәт. Аларның арасына болай гына барып кереп тә булмаячагын аңлый, әмма, йөрәк бер купса, тиз генә урынына утырмый икән шул. Гәүдәсе Фәймә янында, колагына кызның кайнар сулышы бөркелә — тегесе аңа нәрсәдер сөйли, чытыклана, ә Әүхәтнең уйлары Гөлҗиһанда. Ул аның белән яна, аның белән хыяллана. Төннәрен Гөлҗиһан белән саташа башлады.

Шундый тынгысыз хисләр биләп алган көннәрдә Куян Сәйфи белән Гыйльминең тракторчылар курсына укырга җибәрүен сорап гариза язуларын ишетте.

Беркөнне, кичке нәрәттән соң, Фәрвәй белән икәүләп салып утырганда колхоз рәисе үзе ычкындырды бу хәбәрне. Күренеп тора, Мөлеков егетләрне һич кенә Чаллыга җибәрергә атлыгып тормый.

Әүхәткә разведчик чагындагы үткерлеге әйләнеп кайткандай булды. Юк, бу форсатны кулдан ычкындыру ярамый иде. Гыйльметдин монда чакта Гөлҗиһан аңа тәтемәячәк!

Ул саклык белән генә егетләрне укырга җибәрергә үгетли башлады. Шул сөйләшүдә Мөлековның Гыйльмине өнәп бетермәвен дә сизде ул. Монсы да аның файдасына иде.

Әүхәт әлеге уенны тиешенчә уйнап чыкты — егетләр укырга китеп бардылар, хәзер аңа комачау тудырып йөрүче бер кеше дә юк иде авылда. Калганын әкренләп җайлаячак. Ул моңа ышана иде.

Әүхәтнең клубларга чыгып, яшьләрнең иркенләп күңел ачып, биеп йөрүләренә түзеп утырырга, аннан урамнарда озатышлы уйнап вакыт сарыф итәргә исәбе юк иде. Ул өйрәнгән юлыннан китте — Гөлҗиһанны каравыл йортында очратырга, күңел кылларын чиртеп карарга, аннан инде барлык осталыкны җыеп, һөҗүм итәргә. Кызны үзеннеке итмичә туктау булырга тиеш түгел. Киресенчә булса, Әүхәттәй ир-егет өчен гарьлек булыр иде. Уйлап карасаң — Гөлҗиһан кебек чибәр, уңган кызга авылда гына түгел, тирә-якта да тиң булырлык егет кисәге юк бит. Әүхәт кенә тиң аңа, Әүхәт, и, Мөлеков әйтмешли, баста! Шушы уйдан чигенергә ярамый. Үзе бригадир, дөньяны айкап кайткан кеше, йорт-җире бар, җитмәсә, партийный. Кем кирәк тагын Гөлҗиһан сылукайга!

Менә, хәлиткеч кич килеп җитте. Бүген Гөлҗиһан кизү чыгарга тиеш иде. Әүхәт, кыюлык өчен бер тустаган «чөгендер суы» җибәрде дә каравыл йортына табан атлады...

* * *

Гөлҗиһанның быел беренче мәртәбә кизүгә чыгуы иде. Яңа гына бәрәннәр торагыннан әйләнеп кайткан чагы. Кар йолдызлары җемелдәшкән шәлен салып, караватбашына элеп куйды да, башкалар кергәнче өйне җылытып алыйм әле дип, фонаренның утын баса төшеп, калай мичкә утын өстәргә иелде.

Әнә кемдер әйләнеп керде дә бугай инде...

Ул ишектән керүченең кем икәнен абайламаган иде. Инде теге кеше тын гына Гөлҗиһан каршына килеп чүгәләгәч, сискәнеп китте, үзе дә сизмәстән аяк өстенә басты. Керүче — бригадир Әүхәт иде. Сәер, бик сәер иде бу хәл.

Соңгы көннәрдә Фәймә елаудан бушамый, Әүхәткә әллә нәрсә булды, миннән читләшә, мин аның каршысына чыгам, ул күрмәмешкә салынып, үтеп китә, дип өзгәләнә, бичара. Әүхәтнең исә кызның күз яшьләрендә кайгысы юк икән, төн карты кебек, монда килеп чыккан менә. Ә Гөлҗиһанның җан тынычлыгы югалды. Ул ишек катындагы кыйшайган урындыкка барып утырды.

— Курыкма...— диде Әүхәт берни булмагандай. Ул пыскып янган калай мич авызы каршынарак күчте, кесәсеннән сары тузанга баткан, кайчандыр ак ситсыдан тегелгән матур чигүе дә булган тәмәке янчыгын тартып чыгарды. Бер мәлгә янчыкка текәлеп торды һәм:

— Әйе...— дип куйды.— Чибәр, уңган кыз син, Гөлкәй...

Әүхәт ашыкмыйча гына тәмәке төрде, мич ишеген ачып соскы белән утлы күмер әләктереп алды, пыш-пыш суырып тәмәкесен кабызып җибәрде. Күмерне кире мич эченә ташлап азапланганда, алга сөрлегеп, бүрек кашы белән мичне «сөзеп» тә алды. Төнге кунакның шактый кызмача икәнен сизеп, кызның баштагы шомлануы тагын да көчәйде, эчен нидер яндырып, өтеп алды. Ләкин Әүхәт кызны шикләндерерлек хәрәкәт күрсәтмәде.

— Күзгә йокы керми,— диде ул авыр сулап. Фонарьдан төшкән яктылык аның йөзен тагын да хәсрәтлерәк, моңсурак иткән шикелле тоелды.

Әүхәт калкынып аякларына басты, Гөлҗиһанга карап торды да, үзалдына гына сөйләгәндәй:

— Баһау Гыйльмиенә әрәм син,— диде.— Егет кешегә сугыш күрү мәҗбүри түгел, түлке, армиягә бармаган малайны кешегә чутлап сөйләшмим,— дип мич авызына чертләтеп төкереп алды.

Гөлҗиһан нәрсә дип әйтергә дә белмәде. Әүхәттән ишелеп салкынлык бөркелгән шикелле булды. Ирнең тыйнаксызлык күрсәтмичә генә чыгып китүе дә тынычландырмады аны. Гыйльметдиндә ни эше бар иде аның, җә?.. Урман кисүендә имгәнеп калмаса, армиягә бармас идемени ул! Үзе дә шуңа кимсенеп йөрде, «трудовойга булса да алмадылар бит»— дип сыкранды гел. Киткәннән бирле кайтып күзгә күренгәне юк. «Бик исегез китмәгән сыман йөри идегез, тилмертим әле»,— ди торгандыр инде. Куян Сәйфи, әнә, җай чыкса, кайта да җитә. Әллә хат язып, Сәйфи аша җибәрәсе инде?

Әүхәт ишекне катырак япкангамы, авыр ишек яртылаш ачылып китте, Гөлҗиһан шуны ябарга барган җиреннән, нигәдер тышкы баскычка ук чыгарга итте, салмак атлап өйдән ераклашып баручы ир артыннан бераз карап торды да, тәненә суык үрмәләвен тоеп, кире борылды. Шулчак күздән бирле йорт каршында аунаган зур чан артында кемнеңдер йөткергәне ишетелгән сыман булды. Ир-ат, ахрысы. Сабырсызланып таптанган аяк тавышы да ишетелеп китте. Кызның элекке куркуы да чигеп бетмәгән иде, шомлануы тагын көчәйде, күз-ачып йомганчы өй эченә чумды, кергән уңайга фонарьның пилтәсен калкытты.

Ул арада ат караучыларның сөйләшә-сөйләшә йортка якынлашулары ишетелде. Кыз шунда гына үзенең бик нык арыганын тойды, башны күтәреп булмый, керфекләренә йокы эленде...

... Әүхәт Гөлҗиһан кизү торган бер төнне дә калдырмады диярлек — җай табып сугылып китә иде. Эндәшми генә тәмәкесен пыскыта, һаман да ара-тирә күрсенеп ала, «Әйе», дип куя. Хәер, ул эндәшсә дә, Гөлҗиһан аңа җавап кайтармаска, аның белән сөйләшерлек бер генә сүзе юклыгын ачык сиздерергә тырыша иде.

Ә берсендә Гөлҗиһан туп-туры сорады:

— Син, Әүхәт абый, нигә әле Фәймәне болай саргайтасың?— диде ул. Көтелмәгән кыюлык, кызның маңгайга бәреп бирелгән соравы Әүхәтне бөтенләй аптырашка калдырды.

— Фәймә...— диде ул тавышының калтыравын басарга тырышып.— Ни бит, Гөлкәй, һәр кеше үзенә тиңне эзли... Миңа тиң түгел ул...

— Кызык... Нигә бу хакта башта ук уйламадың соң син, Әүхәт абый. Сез бик тә пар килгәнсез, минемчә.

— Юк-юк!— Әүхәт кабаланып кулларын буташтырып алды.— Ярату дигән нәрсә дә бар бит әле, Гөлкәй, тормышта. Мин аны ярата алмадым. Әмма дә ләкин тырышкан идем.

Гөлҗиһан бераз сүзсез торды.

— Кешене көчләп яраттырып булмый шул,— диде ул, ниһаять. Аның тавышында киная бар иде.— Син, Әүхәт абый, мин кизү торганда монда килмә инде, яме. Без бит Фәймә белән ахирәтләр. Аңлый торгансыңдыр. Турысын әйткәнгә ачуланма...

— Алайса өегезгә киләм.— Әүхәт елмаерга тырышты. Әмма аның бите кызганыч рәвештә чалшаеп кына киткәндәй булды.

— Өйгә...— дип тотлыгып калды кыз.— Өйгә бигрәк тә килмә...

... Бу сөйләшүдән соң Әүхәт кызны тиз генә кулга төшереп булмасын аңлап алды. «Тактик һәм стратегик планнар үзгәрде»,— дип уйлады ул. Иң ышанычлысы Фәрвәй Мөлеков — Гөлҗиһанның әтисе белән киңәшләшергә кирәк! Шунсыз эш барып чыкмаячак. Сак, әмма кискен хәрәкәт

итәргә! Кыз исенә дә килергә өлгермәсен. «Тәвәккәллә, разведчик!— дип җилкендерде ул үзен-үзе.— Тәвәккәллек — ярты уңыш!»

... Әтисе белән кызып-кызып нәрсәдер хакында гәп куертып утырган Әүхәтне күргәч тә, кайтып кергәндәге кайнарлык сүрелгәндәй булды. «Киләм», дигән иде бит. Тәки үз туксаны туксан, югыйсә, ап-ачык, бернинди шик калмаслык итеп әйткән иде бит инде.

— Исәнме, Әүхәт абый.— Бу сүзләрнең авызыннан ни рәвешле тәгәрәшкәннәрен кыз сизми дә калды.

Әтисе өстәл башында, ишеккә яны белән утыра иде, кызы кайтып керүенә куанып, киң итеп елмаеп җибәрде. Урындыгын яман шыгырдатып Гөлҗиһанга табан борылып утырды, күзләрендә бераз аптырау галәмәте дә бар кебек.

Әүхәт сүзен шундук Гөлҗиһанга күчерде:

— Менә, Гөлкәй үзе дә кайтып җитте...

Аның бу сүзләре җавапсыз калды. Гөлҗиһан өс киемнәрен салып чөйгә элде һәм чаршау эченә үтте. Әүхәтнең нинди йомыш белән йөрүен белә бит инде. Җаны бәргәләнә башлады. Әмма кызның күңелен тырнап торган минутларга тиз генә чик куелыр кебек түгел иде. Тәлинкәләргә аш бүлеп мәшәләнүче үги әнисе дә кызга мәгънәле итеп күз сирпеп алудан үтмәде. Гөлҗиһанның үз әнисе, сугыш вакытында яз көне Әҗәкүлдән чәчүлек орлык күтәреп алып кайтканда өзлегеп, җәй буе хасталанып үлеп киткән иде. Әтиләре сугыштан кайтканчы олы абыйсы белән Гөлҗиһан икәүләп дөнья көттеләр. Кайту белән Фәрвәй яшь хатын алды, кыз үги әниле булды. Олы абыйсы Шәйхаттар исә, әтисе Фәрвәҗетдин кебек үк буйчан, таза бәдәнле егет, узган ел армиягә китеп барды. Тын океанда, флотта хезмәт итәм, дигән хатлары килеп тора.

... Әтисе белән Әүхәт, Гөлҗиһан кайткач, өзелеп калган сүзләрен дәвам иттеләр.

— Мытыеста үзебезнең егетләр эшли башласа, зыян булыр дисеңме?— диде әтисе бәхәсләшкән кебек итеп.

Әүхәт рәис белән килеште.

— Ул егетләрне күптән җибәрергә кирәк иде. Гел читтән җыелган шалапай, колхозга килсәләр дә, һич җайларына ятып булмый. Үзебезнекеләр булса, сөйләшә белер идек...

— Һе... шул маңкалар белән сөйләшеп торырга! Приказываю, баста!— дип кызды Фәрвәй. «Шап» итеп өстәлгә сугып, сүзен дәвам итте:— Кем дип беләсең Куян Сәйфие белән Баһау Гыйльмиен!— Аннан әтисе, урынсыз кызып китүен үзе үк өнәмәгән төсле, тавышын йомшартып, Гөлҗиһанга эндәште:— Кызым, безнең янга чык әле... Ашны инәң дә житештерер. Менә Әүхәт абыең бик зур эш белән килгән...

Гөлҗиһанның болай да янган йөрәге сулкылдап тибә иде. Хәзер бу өзгәләнү тагын да көчәйде. Гыйльметдиннең исеме мыскыллап телгә алынуы күңелен бөтенләй ярсытып ук җибәргән иде.

Әтисе тагын эндәште:

— Гөлҗиһан, дим!

Кыз аптыраулы халәттә чаршау артыннан чыкты һәм акшарлы мич буена сузып ясалган утыргыч-ушага килеп утырды.

— Ушага утырма, Гөлҗиһан, алайса ни... бәхетең булмас,— дип акыл сатып алды Әүхәт.

Сөйләшкәндә «ни»ләрне төрләндереп кушарга һәвәс иде ул. Авыл халкы юктан да мәзәк табарга оста. Әүхәтнең дә бу гадәтен тиз эләктереп алдылар һәм җай чыкса, сөйләп-көлешергә дә форсат табалар иде. Имеш, Әүхәт әниле-кызлы яшәгән Әсма белән Бикәгә эшкә әйтергә тиеш икән дә, әнисенә нәрәтне җиткергән, кызын һич кенә таба алмый икән. Шулай йөргәндә аңа Мөлеков очраган. Әүхәт җитди кыяфәт белән: «Менә, Мөлеков иптәш, Әсма белән Бикәне нитеп йөрү әле. Әнисен ниттем, кызын нитеп булмый бит әле»,— дип зарлана икән.

... Әүхәтнең сүзләренә Гөлҗиһан җавап кайтаруны артык санап эндәшмәде, шулай да ушадан торып китте, өстәл янынарак, урындыкка күчеп утырды. Күзләре ирексездән, Әүхәт күзләре белән очраштылар. Әүхәтнең карашында тыелгысыз ашкыну, тәкатьсезлек чагыла иде. Буй җиткән Гөлҗиһан шушы караштан хатын-кызны тансыклаудан гаҗиз булган буйдак ирнең яшерен хисләрен бар тулылыгы белән төшенгәндәй булды. Бөтен гәүдәсе куырылып килде.

Әтисе Гөлҗиһанның тирән кичерешләр эчендә катып калуын күрмәмешкә салышты. Исе китмәгән кыяфәт белән сүз башлады.

— Гөлҗиһан, кызым... менә бу кеше — Әүхәт абыең инде. Әүхәт кенә дип сөйләшсәк тә ярый.

Кызның маңгаена тир бәреп чыкты. Үзе дә сизмәстән җавап кайтарды. Бу сөйләшүне нииндидер мәгънәсез сүз алмашуга гына кайтарып калдырырга тырыша иде ул.

— Беләм...

— Беләсең... Бригадир, грамотный кеше. Өе нык, ихата-курасы. Үзе ялгыз...

— Әткәй!..

Мөлеков кызының сабырсызланып инәлүенә игътибар бирмичә, сүзен дәвам итте:

— Колхозның киләчәге Әүхәтләр кулында. Без инде әллә ни майтара алмабыз.

Әүхәт телгә килде. Ул Мөлековның гадәтләрен яхшы белә. Сүз арасында рәискә бераз мактау сипләп җибәрсәң, Фәрвәйнең башы күккә тиячәк. Ул аны сиздермәскә тырыша, әмма салпы якка кыстырылган салам үзенекен итә, рәиснең йөзенә тәкәбберлек, һавалану галәмәтләре бәреп чыга.

— Синең кебек колхозны тартучылар ни... сирәк әле ул, иптәш Мөлеков. Кая инде безгә...

Әүхәтне бүлдереп, сүзен эре генә дәвам итте Мөлеков:

— Әйе, колхоз сезгә кала.— Ул Гөлҗиһанга эндәште.— Менә шундый хәлләр, кызым...

Гөлҗиһан сүзне артыкка җибәрми, шушы тукталыштан файдаланып калырга омтылды:

— Мин әнкәй янына керим инде, әткәй. Сез сөйләшегез.

— Туктап тор! Без сөйләшәсен сөйләштек инде. Әүхәтне миннән дә яхшырак белүче юктыр. Бушка тел чарлап, гомер уздыручы түгел. Малай-шалайлыктан яше үткән, кыскасы, ул өйләнергә ниятләп йөри.

Тел очында гына торган диярсең, Гөлҗиһан нәрсә уйларга өлгермәде, инде авыз ачылып та — ябылды:

— Кемгә?

Аяз көнне күктә яшен яшьнәп алдымыни!

— Сиңа!— диде әтисе коры гына.

Әүхәт күзләрен елтыратып, Гөлҗиһанга карады:

— Менә, Гөлкәй, шуңа килү инде минем, ачуланмасаң...

— Без инде әниең белән дә киңәштек,— диде әтисе, кызының аптырашта калуын күреп,— без каршы түгел.— Фәрвәҗетдин алдында торган тулы стаканны кулына алды, бераз карап торды да кире урынына куйды.— Аңласаң — аңла, аңламасаң — юк: башка кешегә бирәсем килми сине. Миннән хәер-фатиха!

Гөлҗиһан яшьле күзләрен читкә борды:

— Мин, әткәй, кияүгә чыгарга җыенмыйм бит әле. Мин дә кеше ләбаса... Очраган беренче кешегә тагып җибәргән кебек...

Кызның карышса башлавына хәтере калган Мөлеков җикеренә үк башлады.

— Кем ул очраган беренче кеше? Әүхәтме?! Юк, кызым. Теге гармун шыңгырдатып йөргән малайларны оныт инде. Дөнья көтүләре уен-муен

түгел ул. Әгәр дә Әүхәткә чыгарга каршы киләсең икән — минем кызым түгел син! Минә синә кияү, и баста!

Мөлеков исәңгерәп калган кызына күтәрелеп та карамыйча, стакандагы аракысын иләмсез зур авызына чөнкәйтеп җибәрд дә, тын алган уңайга хатынына кычкырды:

— Кая, ашыңны китерәсеңме?..

Гөлҗиһанның күз алдыннан үги әнисенең шәүләсе йөгереп үтте. Күзләренә яшь тыгылды, өй эче чайкала, лампаның ялкын теле зурайганнан зурая, түшәмнәрне ялмап ала сыман. Бөтен дөнья утка чорналды, тик каршыда гына караеп түмәр кебек ике шәүлә утыра. Шәүләнең берсе шопыр-шопыр аш чөмерә башлады, икенчесе, Әүхәт тавышлысы «ни»ләп алды:

— Сезгә килүнең ние... сәбәбе дигәндәй, шушы инде, Гөлҗиһан... Әйдә, Гөлҗиһан... мин яратам сине, чын... Өйнең түбәсен быел ниттем... такта белән. Сыер алып җибәрербез. Ни инде... Яшәргә була. Бүген үк язылышырбыз инде, име?.. Кәлине дә ниттем... Сельсәвиттә көтеп тора.— Әүхәт өстәл яныннан кузгалып, Гөлҗиһанның каршысына ук килеп чүгәләде.— Иртәгедән калмыйча никахны да укытырбыз. Ат җигүле минем, язылышып кайтыйк, дим...

Гөлҗиһан зур булып ачылган күзләрен Әүхәткә текәгән иде, әллә нишләп китте: аның моңарчы беркайчан да бу кадәр ялварудан шашыр дәрәҗәгә җиткән карашны күргәне юк иде әле. Әгәр Гөлҗиһан каршы килсә, мөлдерәп яшькә тулышкан җете зәңгәр күзләр идәнгә тәгәрәшеп төшеп китәрләр, чәлперәмә килеп уалырлар: дөнья убылыр, өйнең астыөскә килер кебек иде. Күзләрдән шулкадәр хәсрәт, өмет, чарасызлык бөркелә, Гөлҗиһанның бер сүзе һәм... бетте... әлеге чүгәлеп торучы ир-егет мәңге аягына күтәрелә алмас, идәнгә сеңеп юкка чыгар иде сыман.

— Соң, Әүхәт абый,— диде Гөлҗиһан,— синең өчен өзелеп төшәргә әзер кызлар бар бит. Нәрсә дип миңа каныгасың инде, ә?— Түзеп тора алмады, сулкылдап елап җибәрде.— Үзең үк әйткәнең бар бит — яратмаган кешегә ничек ризалык бирмәк кирәк...

Әүхәт, ярдәм сораган кебек, Фәрвәйгә карады.

— Ни бит... Гөлкәй... Мин дә аз уйламадым, уптым-илаһи гына бәреп керү түгел сезнең өйгә.

— Нәрсә кешенең насырын корытып утырасың,— дип гайрәт чәчте этисе.— Син дә, Әүхәт, егет бул, киенешегез дә, язылышырга киттек.— Үзе иң беренче булып чөйдәге пәлтәсен алып иңенә салды...

... Дөньяда иң көчле хис — мәхәббәт хисе, диләр. Әмма, кызгану хисе аннан да көчлерәк түгел микән? Дөрес анысы, сөю ул мәңгелек, сизмәгәндә генә дөрләп кабына да, кешене соңгы сулышына кадәр, ташламый озата бар. Шушы хис булмаса, тормыш булмас иде, диләр. Ул бернәрсәгә дә буйсынмый, яшьлек-картлыкка да карамый, милли аерымлыклар да юк аның өчен, кабына да берәүләрне бәхет дингезендә йөздерә, икенчеләрен сагыш утында көйдерә. Ә кызгану хисе еш кына аңны томалап ала. Берәүләрдә була андый хискә сәләтлелек, икенчеләрдә — юк. Әмма кызгану хисе озак яшәргә сәләтле түгел, кабына да сүнә. Әнә шушы кызгану хисе уянган чакларда кешеләр әллә никадәр яхшылыклар кылып калалар, инде дә килеп, гомер буе үкенеп сөйләрлек гамәлләр дә кылына шул әлеге хис акылдан өстен чыкса.

Гөлҗиһанны бернинди көч тә Әүхәткә кияүгә чыгарга мәҗбүр итәр кебек түгел иде. Ул үзенең ахыргача каршы тора алуына ышана да иде кебек хәтта. Әмма Әүхәтнең күз карашы аны әллә нишләтте дә куйды, аның үҗәтләнеп каршы торырга маташуын күзгә күренмәс серле көч юып алгандай итте. Үзе бар тәне-җаны белән каршы, үзе елый, үзе өздереп «Юк» дип әйтә алмый — арурак киемнәрен юллап киенергә җыена башлады. Шушы кызгану хисе уянган мәл иде кызның йөрәгендә. Мәңгелек үкенечкә салыр хис...

## II

Әүхәтнең ихата-каралтысы да, йорты да кешенекеннән ким-хур түгел. Кулы балта-пычкы эшенә ятып тора. Илләр-җирләр гизеп кайткач, дөньясына үч итеп, кайгы-хәсрәтләрен онытырга теләп гайрәт белән ихатасын, йортын торгызган, яңарткан иде ул. Гөлҗиһан төшкән атнада ук базардан коба сыер сатып алып кайтты.

— Карчык! Сыер ниттем әле... сатып алдым... Син дә чыгып кара,— диде ул ишектән керә-керешкә. Ничек тә бу эшкә куаныч чүпрәсе саласы килүе ярылып тора иде аның сүзләреннән.

Гөлҗиһанның язмышка буйсынудан башка чара юк диеп йөргән чагы иде. Ә димәде, җә димәде, өстенә киенде дә ишек алдына чыкты. Әүхәт инде сыерны абзарга кертеп бәйләп куйган, улакка хуш исле печән салып маташа иде. Малкайның ялындырып торырга исәбе юк иде. Ун чакрым тәпиләп кайту да үзенекен иткәндер, дымсу кара танавын чак кына печәнгә төртте. Аннан «пош» итеп тирән сулыш алды, авыз кырыеннан озын телен чыгарып, бер учманы бөтереп эчкә дә алып кереп китте, моңсу күзләрен озын керфекләре астына яшереп, ашыкмый гына чәйнәргә кереште. Сыерның ялындырмый-нитми печәнгә ябырылуы Әүхәтнең күңелен кузгатып җибәрде. Яшь тибеп торган күзләрендә шатлыклы очкыннар пәйда булды. Солдат бүреген баш очына табан этәреп, сөенечле карашын Гөлҗиһанга күчерде:

— Ашаган малда ни инде, әйеме, карчык. Өмет бар. Һе-һе...

Шушы мәлдә Гөлҗиһанның елап-сыктап кайткан бәгыре җылынып киткәндәй булды. Башына шаулап кан йөгергәнен сизде, әлеге сәер җылылык аркасы буйлап аяк табаннарына кадәр төште. Йөрәгендәге авыр таш эри, күңелдәге газаплы рәнҗеш югала башлаган сыман тоелды. Гөлҗиһан моны нәрсәгә юрарга да белмәде. Сөт исләре аңкытып, әллә сыерның кытырт-кытырт печән ашавы, әллә Әүхәтнең лапас түбәсенә сөялеп куелган баскычтан җәһәт кенә менеп, тиз-тиз учлап сары гәрәбәдәй солы саламын йолкый башлавын күрепме, аңарда хатын-кыз рухы уянды. Тормыш ихласлыгы кайта башлавы көн кебек ачык иде. Нәрсәгә дөньясы җимерелгән шикелле тора соң әле ул? Типсә тимер өзәрлек ир... Тормышлары җитеш, мал-туарлары үрчеп бара...

Иске бишмәткә исе киткән бичә кебек тору туйдырды, ахрысы, Гөлҗиһан җил-җил атлап өйгә кереп китте, озак та үтмәде, бер кулына җылы су салынган комган, икенче кулына чиләк, йомшак тастымал тотып килеп тә чыкты.

Әүхәт инде абзар түбәсеннән төшкән, лапас терәгенә сөялеп, тирән моңсулыкта басып тора иде. Хатынының сыер саварга җыенып чыгуын күргәч, кисәк ике-өч адым алга атлады, аннан шып туктады да ак тешләрен күрсәтеп елмаеп җибәрде. Чагыштырмача яшь гомерендә шактый авыр кайгы-хәсрәтләргә дучар булып, чын назга сусаган ир йөрәге Гөлҗиһандагы бу якты үзгәрешне сизми калмады, билгеле. Хатынының йөрәгендәге боз тавы эри башлаячагына иманы камил иде аның. Бу юлы да алдан күрүчәнлеге рас килде: сыер тирәсендә кайнашкан Гөлҗиһанга аңлатып булмаслык илаһилык иңгән иде.

— Тыныч холыклы сыер булган бу, нитеп ни... иркенләп сау,— дип такылдады Әүхәт, килешле итеп сыер савып утырган Гөлҗиһанның, әле уң ягына, әле сул ягына төшеп...

... Әүхәтнең, эчеп кайтса, бер яман гадәте бар иде: юк-бар сораулар биреп, шуларга җавап таптырып җәфалый иде ул яшь хатынын. Хәер, моңа Гөлҗиһан артык бәрелеп-сугылмады. «Бер минем ирем генә эчеп дөнья шаулатамыни соң? Әле, тфү-тфү, әйттем исә кайттым, алай кул күтәреп, сугарга ук талганы юк».

Әнә, Нәфисә белән Гарифның өйләнешүләренә кайчан, инде Нәфисәнең кара янмаган төше калмаган, ди. Бик яратышып, сөешеп чыксаң да

ярап бетми икән ул, җете кызыл тиз уңар. Нәфисәне туганнары килеп аерып алып китмәкче дә булып караганнар, тик хатын гаҗәпләнүләренә каршы, үтә тискәрелек күрсәткән: өректәй иремне теләсә кемгә калдырып китәсем юк, бүген сугышабыз, иртәгә кочаклашып йоклыйбыз, ди икән. Шулаен шулай да, суккан җиргә май үсми инде ул...

Әүхәтнең кыланмышларына түзәргә була әле. Артыграк исереп алса: «Нигә һаман шул Гыйльметдиненне уйлап йөрисең?—дип бәйләнгән була башлый. Гөлҗиһан эндәшми. Тегесенең моңа ачуы гына кабара.— Эндәшмисең, иеме?.. Эндәшмисең, чөнки мин дөрес нитәм... әйтәм»,— дип гайрәт чәчә.

Йә ир төн уртасында әллә нинди яман тавышлар белән кычкырып, өй буйлап чабулап йөри башлый. Кисәк туктый да куркынган күзләренә карап:

— Менә, син, миңа карап торасың, әйеме?.. Янә кычкырып җибәрә— Ә син нитә аласыңмы?—Ул күлмәк изүен аерып төшерә дә йодрыгы белән ишек яңагын төеп ала.—Кеше үтерә аласыңмы, дим!—Гөлҗиһанның каршысына килеп катып кала. Үзенең бөтен тәне тартыша. Кулында мылтык бар сыман, түшәмгә, түшәмнән акырын гына тәрәзәгә төшерә, урысчалап:

— Шакал, шакал! Ычкындырма!—дип кычкыра һәм «пых-пых» «ата» башлый.—Шакал кем ул беләсеңме?—ди ул тынычлана төшеп.—Менә мин җиде ел теге якта шакаллар куып йөрдем инде,—ди ул. Еламсырап өстәп куя,—миннән дә төз атучы юк иде...—Урт тешләрен шыгыр-шыгыр китерә һәм авыр сулап:—Ник кирәк иде миңа ул кешеләрнең җанын кыю? Алар бит үз илләрендә, үз җирләрендә. Төшкә керәләр, һич йокларга ирек бирмиләр...

Шуннан соң Әүхәт урынга каплана да лампа эшләпәсеннән түшәмгә төшкән шәүләгә бик озак карап нидер уйланып, исәпләп ята. Мондый чакларда Гөлҗиһан әллә куркудан, әллә Әүхәтне җәлләп, тын гына елап та ала. Ире гырлап йокыга киткәч кенә, бераз тынычлана. Кайбер төннәрне Әүхәт үлгән хатыны, баласы белән саташа башлый. Гөлҗиһанны караваттан җилтерәтеп кенә төшерә дә хатынын, малаен таптыра башлый. Ишекле-түрле улын чакырып, кычкырып йөри. Гөлҗиһанга иң авыры шушы иде дә инде. Әмма хатын тешен кысып булса да түзде, кешеләргә сөйләп, Әүхәтнең яман атын чыгарудан курыкты.

* * *

Гөлҗиһан кияүгә чыкканнан бирле, аның белән Фәймә арасына калын таш стена өеп куйдылармыни. Әүхәтнең өйләнгәнен ишеткәч, Фәймә үз-үзенә кул салыр дәрәҗәгә җитте. Шулай да хәсрәтен тышка чыгарып түкмәскә тырышты. Бигрәк тә Гөлҗиһан алдында сынатасы килмәде. Элекке ахирәтен бөтенләй күрмәмешкә салынган булды ул. Әүхәтен әйт инде: ымсындырып йөрде-йөрде дә, менә сиңа, мәчүмеч урынына куна тактасы!

Гөлҗиһан да үзен Фәймә алдында зур гаепле итеп санап йөри иде. Чынлап уйласаң, Фәймә алдында бик гаепле ул. Белә иде бит—Фәймә Әүхәткә өметләнеп йөрде. Хәзер ничек акланырга да белмәссең. «Җебегән шул мин, карыша алмадым»,—дияргәме... Шундый хафалы уйлар белән эшләп йөргәндә, аны аулакта Фәймә үзе эләктереп алды.

— Ничек соң?—диде ул бәрәннәр бүлмәсенә салам түшәп йөргән Гөлҗиһанның каршысына ук килеп.

Көтелмәгән сораудан, Фәймәнең мыскыллы карашыннан Гөлҗиһан каушап калды. Кабатлап сораудан башка чара тапмады:

— Нәрсә ничек?..

— Кияү кочагы, дим...— Фәймә шыпырт кына көлеп куйды.— Мин аңлаганны, син белмәскә инде... Теге нәрсәгә өйрәнеп буламы соң?..

— Кияүгә чык, син дә белерсең,— диде Гөлҗиһан ахирәтенең әдәпсез әрсезлегеннән кызарып.

Фәймә һөҗүмен дәвам итте.

— Кияүгә чык, дип... Безгә дигән кияүләрне бездән юхараклар эләктереп торгач ни. Шулай инде, безнең эше хәерчене кем алсын?— Фәймәнең күзләреннән зәһәр очкыннар чәчелде.— Персидәтель кызлары сайлап алып бетерсеннәр әле кияүләрнең кәттәләрен, аннан без кузгалырбыз. Безнең алай сайланырлык чама юк, кем кул сала, шуңа... Персидәтель кияве, дип, әйтүе генә ни тора бит, малай. Юк, синнән көнләшеп әйтүем түгел... Хәерченең бәхет янчыгы тумыштан тишек, ди.— Фәймә сөйләшүгә җентекләп әзерләнгән иде, Гөлҗиһанның бәгыренә кадалырлык сүзләрне тиздә генә.— Гыйльметдиннән хат алдым әле. Кияүгә чыкканыңны ишеткән... Чаллы качкан җир түгел, яман хәбәр анда да барып җиткән.— Фәймә «яман» сүзенә басым ясап әйтте.— Әүхәт каравыл өендә мине генә кымтырыклап йөри дисәм, синең белән дә сере уртак булган икән. Мин ни, томана, кияүгә чыкмый торып сафлыгыма пичталет белән килсә дә ягылдырмыйм дип ант эчеп йөрим тагын. Син остарак булгансың, чукынган кызый. Әйтәм аны, Әүхәттән зарлана башласам: «Нык тор, бирешмә!»— дип котырта идең. Үзең буш җибәрмәгәнсеңдер, ә!..

— Нәрсә сөйлисең, Фәймә!— дип Гөлҗиһан яшьле күзләрен читкә борды.— Кияүгә чыгарга исәбем дә юк иде бит. Үзең беләсең...

— Кешенең нәрсә уйлаганын белергә, мин Гаплатыйп түгел,— дип кырт кисте Фәймә. Аннан, теләсә ни эшлә дигәндәй, кулын селтәп куйды:— «Ниттемең» үзеңә булсын, насыйп булса, без дә яр табарбыз,— диде һәм тырт-тырт басып, торакның икенче башына табан атлады.

... Берничә көннән Фәймә авылдан китеп барды. Шәһәргә, ялланып (авылча әйтсәк «вербовка» белән) эшкә киткән, дип сөйләделәр.

* * *

Быел яз ашкынып, ургылып килде. Ике-өч көн эчендә, әле кыш нык тора, бирешергә исәбе юк дип йөргән җирдән, карлар эреп бетте, аяк асты боламыкка әйләнде. Димәк, Коры елга күпере дә ирәвәнләп тормас, ташкынга ияреп китәр дә барыр.

Елганың исеме «Коры» булып, колакка бик мескен табигатьле кебек яңгыраса да, һич тә челтерәп кенә агып ятучы инеш түгел ул. Җәйге кояшлы көндә тирән яр төбеннән көмештәй инешнең елтыр-елтыр уйнаклавын күрерсең. Төбендә бака кабырчыклары, күгәрчен сабыны. Аска төшеп карасаң, агымга каршы көтүләре белән вак балыкларның урләгәннәре күренеп тора. Тирәнрәк җирендә кызылканатлар, чабаклар мәш килә. Һәрхәлдә, кармак алып Коры елгага төшсәң, буш кул белән кайтмассың.

Менә шушы инеш, кыш буе гайрәт җыеп яткан чабыш аты кебек, яз җитүгә тыйгысызга әйләнә — Күперле авылын күперсез калдыра да куя! Күперлеләрнең үз хафасы — колхозның барлык фермалары да елганың икенче ягына, урман буендагы тау битенә урнашкан. Күпер китәр вакыт җиткәч, барлык терлекчеләр сул як ярга чыгып калалар.

Бу минутларны авыл халкы яхшы белә, елга төбеннән умырылып күтәрелгән калын бозлар күпер авызына килеп тыгылмыйча бераү дә кузгалмый әле. Күперне калын бозлар томалап алгач, актарылып аккан болганчык су ярты көн чамасы ике яклап сузылган тигез яланнарга җәелә. Бу яланнар ярты чакрым киңлектә булып, елга буйлап югарыга,

офыкка ук барып тоташа. Яланнардан соң сөзәк тау сырты башлана. Күперле үзе дә тау башынарак менеп кунаклаган авыл.

Иң кызыклы, зарыгып көткән мизгелләр җитә — күпер өстеннән шаулап су ага башлый. Терлекчеләрнең күпчелек өлеше теге як ярга чыккан, өлкәннәрнең күзләрендә чая чаткылар уйнап ала, йөрәкләре дәртләрәк тибә — алар яшь чакларына кайткандай булалар, яшь-җилкенчәк, балачага чыр-чу килә. Сөеклеләре белән хушлаша алмый аптыраган егетҗилән су ерып теге якка ашыга. Ургылып аккан көчле агым аларны ияртеп алып китәр кебек.

Менә су бөтен күперне иңләп ага башлый. Тагын берничә минут һәм... боз-су ташкынына түзә алмыйча, күпер торыклары шартлап сына, ава башлый. Күпергә түшәлгән такталарның ярдан аерылып кымшанганнары күренә. Тагын берничә талпыныш һәм күпер өсте торыкларыннан аерылачак, актарылып аккан ташкын йомычка урынына гына бөтереп алып китәчәк аны...

Нәкъ шул вакытта халыкны өнсез калдырып: «Һайт, юл бирегез... китегез, майтти, едрить-кудрить!» — дигән гайрәтле кычкыру яңгырап китә.

Моңарчы идарәдә утырган Мөлеков шушы мәлне каян белеп тора диген, су ташкыны күперне кузгатты инде дигәндә, таш юлдан Кара айгыр өстендә томырылып чабучы Мөлеков пәйда була. Ул татарчалы-урысчалы кычкыра-сүгенә юл буена тезелгән халык арасыннан чабып үтә, аның акаеп киерелгән күзләре генә ялтырап кала, бөтерелеп-болганып-кайнап аккан су янына җитәрәк Кара айгырның сыртына каеш чыбыркы белән шартлатып тамыза. Кара айгыр хуҗасының теләген аңлап алган кебек, уктай су ташкынына ыргыла. Белмим, айгырны нинди көч теге як ярга чыгарып өлгерәдер, шушы унбиш метр араны әллә очып чыга ул, әллә йөзеп үтә, аның арткы ак бәкәлләре ярга басарга җитешми, күпернең астыннан аһылдап ындыр табагы кадәр бозның зәңгәрсу сырты калкып чыга... Шушы минуттан башлап, ике яр арасында су кайный башлый...

... Әтисенең Кара айгыр өстендә Коры елга аша шушы ыргымын күрмәс өчен Гөлҗиһан әллә ни бирердәй була. Ел саен шулай малайларча кылана бит.

Быел да Мөлеков әлеге гадәте буенча барлык авыл халкын шаккатырды. Кемгә кирәк инде ул?.. Гөлҗиһан тын алудан калып, йөрәге шартлар чиккә җитте. Иллене тутырган кешегә дә акыл кермәсә керми икән.

Тик быелгы ыргым башка еллардагыча шома гына барып чыкмады. Кара айгыр инде хәлиткеч талпыныш ясап, коры җиргә атылмакчы булган иде, әллә күтәрелеп урыннарыннан кузгалган күпер тактасы арасына туры килде, әллә күпердә көздән калган зур тишек-тошык булганмы — ал аягы төште дә китте. Әмма инде гәүдә ыргым ясарга кыл кебек тартылган, айгыр әкияттәге Дөлдел кебек очарга талпыныш ясаган иде — ул киң түше белән яр читенә килеп сыланды. Айгырның аягы шартлап сынды, Мөлеков үзе кулларын җәеп ташу суына барып төште, моны аръякка чыккан һәм ярга якын торган ир-ат халкы күреп, әүвәл өнсез калдылар, кемдер айгырның тезген очын эләктереп калган икән, инде бахбай ташу суына ияреп ярдан читкә таеша дигәндә, тезгенгә тагын ике-өч ир килеп тотынды. Кара айгыр рәхмәт әйтергә теләгәндәй пошкырып алды, кисәк-кисәк талпынып, яр өстенә үк менеп баса алды. Аның авызыннан күбек ташый, күзләре куркынып аларган, үзе дер-дер калтырый, өч аяклап булса да, ярдан читкәрәк китәргә азаплана иде. Үзе ыңгыраша, мондый хәлгә төшергән хуҗасына ләгънәт укыган кебек. Сынган аяк тирәдә генә эленеп тора, аннан кызыл тасма ага...

Мөлековны да бәхет басты. Ярсыган ташу ат өстеннән егылып төшкән уңайга йотып кына куяр кебек иде аны, әмма Бәдри агайда озын саплы багор булган икән, ул аның тимерле башын колхоз рәисенә сузып

өлгерде, мондый хәлдә су салкынча сизми дә калды, бар гәүдәсен ниндидер шыксыз ялкын өтеп алган сыман гына иде, үзенә сузылган багорны бер кулы белән эләктереп алды, ул да булмады, аңа ике куллап ябышты, күзләрен чытырдатып йомды. Бәдри агайга да ярдәмгә килделәр, бергәләшеп Мөлековны да ярга өстерәп чыгардылар.

Кара айгырны бер торак ышыгында суеп маташалар иде...

* * *

Сул як ярда колхозның төп байлыгы — терлекләр. Шуңа күрә Фәрвәй Мөлеков бу якка чыга да инде. Идарә ягында башлык булып бригадир Әүхәт калды. Ул Гөлҗиһанны атка утыртып иртүк бу якка чыгарып куйды. Сүзсез диярлек аерылыштылар. Икесенең дә уенда коба сыер булды, ахрысы. Шушы хакта Гөлҗиһан авыз ачып сүз әйтмәкче иде, Әүхәт алданрак житеште:

— Гөлкәй, син борчылма име, сыерны мин үзем нитәрмен. Кешегә ялынганчы...

Гөлҗиһан сүзсез генә баш какты:

... Икенче көнне каравыл өенә төшке ашка җыелгач, Гөлҗиһанга күңелсез хәбәр житкерделәр: әтисе иртәдән бирле температура белән янып ята икән. Хастаханәгә барырга теләми, ди, бер чүлли аракы «бәреп еккан» да, бөркәнеп яткан. Тик температурасы һаман төшми, саташа башлаган. Ташу чорында терлекчеләр белән сул якка чыгып калучы яшь медсестра кыз чынлап хавада иде. «Урау юллардан булса да Бакалыга илтергә микән?» — дип киңәшкә килгән. Бәдри абзый арбага мичәүләп ике ат жигү хәстәре белән йөри икән инде. Үзләренең район больницасына илтү турында сүз булырга да мөмкин түгел, Гөлҗиһан кергәндә әтисе ныклап саташып ята иде. Йөзе агарып калган, маңгаенда борчак-борчак тирләр. Медсестра кыз укол кадарга җыена.

— Гөлҗиһан... Гөлҗиһан, — дип ыңгырашты Мөлеков.

— Мин монда, әткәй.

Кызының тавышын ишеткәч, Фәрвәжетдиннең аңы ачылып киткәндәй булды. Күзләрен чак кына ача төшеп:

— Кызым, чәй ясап китер әле, — диде. Үзен өйдә дип хис итә иде булса кирәк.

Гөлҗиһан калай мич өстендә пар бөркеп утырган чәйнектән чәй ясады. Авыруның чәйгә кагылырлык хәле юк иде. Гөлҗиһан әтисенең башын күтәреп торды, кемдер кашык белән аңа чәй каптырды. Фәрвәжетдиннең бөтен тәне тартыша, калтырана иде. Кызы бу хәлне күреп, куркынып калды. Юк, бу гадәти салкын тию генә түгел иде. Ничек булса да әтисен тизрәк Бакалыга озату чарасын күрү кирәк. Ул арада йорт каршына хастаны алып китү өчен хәзерләнгән жигүле атлар да килеп туктадылар. Дүрт кеше күпкә китә дип, Гөлҗиһанны арбага утыртмадылар, авыруны медсестра үзе озата, ә дилбегә тотып баруны бер егеткә тапшырдылар.

Аларның кайтуын Гөлҗиһан төн йокламый көтте. Юлаучылар икенче көнне генә кайтып життеләр. Мөлековның хәле шәптән түгел, бик нык салкын тидергән, дигәннәр табиблар. Шәфкать туташы Гөлҗиһанга:

— Мөлеков абый, бик күрәсем килә, Гөлҗиһанга әйтегез, килсен әле, — диде.

Бу хәбәр Гөлҗиһанның бар тынычлыгын алды. Күңеле нәрсәдер сизенә, әтисенең хәле шәптән түгелдер, ярдәм кирәктер дигән уй минут та тынгылык бирми иде. Әтисенең чатнама суыкларда да яланбаш көе, чәчләрен тузгытып Кара айгырга жигелгән кошовкага аяк өсте баскан килеш кар бураннары уйнатып, идарә очыннан чабып үтүе күз алдына килә.

Ничек тә әтисе янына, Бакалыга барырга карар итте ул. Икенче көнне Гөлҗиһан иртүк бәрәннәргә киптергән хуш исле юкә яфраклары таратып чыкты да, калган эшләрен Фәймә урынына килгән яшь кызга тапшырып, ферма мөдире Бәдри абзый янына китте. Эзләп тапты, мөдирдән Бакалыга, әтисенең хәлен белеп кайтырга җибәрүен сорады. Бәдри абзый үзе дә рәиснең капыл гына хастаханәгә озатылуына кыбырсып йөри иде. Күпер киткән көнне алар Мөлеков белән ярты төнгә кадәр икәүләп таш келәт почмагында «сыйланып» утырганнар иде. Мөлековның итеген салып келәт ишеге аша гына чолгауларын сыгып алуына да шаһит ул. Бәдринең:

— Иптәш Мөлеков, салкын-фәлән тия күрмәсен,— дигән кайгыртуына, тегесе көлеп:

— Бәдри, мин салкынның үзенә тиям, ә фәләнне фәлән итәм,— дип һаваланган иде. Әле аннан соң да келәтнең таш стенасына арка терәп, фонарь яктысында күпме гәп куерттылар, ничә мәртәбә махра төреп тарттылар...

— Ни арба, ни чана,— диде аптырап Бәдри.— Кем белән җибәрергә сине, үзең генә барып житә алмыйсың, язгы юлда нәрсә булмас...

— Фермадагы кешеләр болай да санаулы, аларны кузгатып йөрмәбез инде, Бәдри абзый. Үзем генә дә барып житәрмен әле. Атланып барырга ат бирсәгез...

— Атланып?— дип, сәерсенеп сорап куйды Бәдри абзый.— Кит булмаганны, хатын-кыз атка атланып чыгар юлмыни бу.

— Курыкма Бәдри абзыкай,— диде Гөлҗиһан ныклы карарга килүен белгертергә теләгәндәй тавышын өзеп-өзеп әйтте ул.— Мин бит атка атланып йөрмәгән кеше түгел!

Бәдри абзый сүзне озынга сузмаска булды.

— Җаны теләгән елан ите ашаган. Алайса тәвәккәллә, үземнең атны биреп торам. Бик юаш холыклы ат, мәхлук. Инде юлда бәла-казага гына очрый күрмә, кызым. Аннан миңа җавап бирәсе булыр. Язгы юл бит, язгы юл,— дип өзгәләнде мөдир.

Юлда капкаларга бераз ризык алып, Бакалыга барып житкәч, атка салырсың дип, Бәдри абзый биргән бер чиләк чамасы солыны ияренә ныклап бәйләп, Гөлҗиһан юлга чыкты.

Ат өстендә җайдак сыйфатында иркенләп йөргәне булмаса да, бөтенләй үк бу эштән мәхрүм түгел иде: абыйсы Шәйхаттар армиягә киткәнче атлар карады. Җәй көннәрендә, атларны утлауга алып чыккач, Гөлҗиһан абыйсына әбәт ашарга илтә иде. Һәр көн диярлек абыйсы сеңлесен ат өстендә йөрергә өйрәтә. Гөлҗиһан шул хәтле кыюланып китте, хәттә бер мәртәбә Әлкәй болыны буйлап «ду» килеп чабып киткән иде.

Атка атланып бару уена килгәч, Гөлҗиһан артык коелып төшмәде, шул вакыттагы күнекмәләре булмаса, үзе дә ялгызы ат менеп ерак юлга чыгарга йөрәксенмәс иде.

Бакалыга барып житкәнче шактый изаланырга туры килде аңа. Кар сулары күп урында юлларны тәмам эштән чыгарган, күперләр җимерек иде. Җирән кашка юлдан читкә аяк басса, «гөрс» итә дә тез тиңентен кар катыш пычракка чума. Мондый чакларда Гөлҗиһан чытырдатып атның аксыл ялына ябыша. Җирән кашка, акыллы малкай, җан-фәрманга тырыша, әйтерсең, җайдагының тәҗрибәсез булуын абайлап, җаваплылыкны үзенә алган сыман, кызга тезген белән артык эш итәргә урын калдырмый, җай гына кире каты юлга чыга, юлын дәвам итә иде.

Таш юлга чыгып, ат үз җаена гына бара башлагач, Гөлҗиһан уйлар эчендә йөзә башлады.

... Сугыштан кайтканнан бирле әтисенең балалары белән иркенләп, җайлап сөйләшкәне булмады. Әниләренең үлеменә балаларын гаепле санаган кебек...

Их, кулларыннан килсә, әниләрен газаплы сыкранулардан йолып алмаслар идемени соң? Әле әниләре авырып кайткач та Шәйхаттар авыл фельдшеры Сәйдә апага йөгергән иде. Сәйдә икенче көнне генә килде. Әниләрен юньләп тыңламый да. Аның: «Сәйдә, үзең дә күреп-белеп торасың, сугыш башланганнан бирле гел эштә, ичмасам, сырхауларым бераз үтмәс микән, зинһар, справка бир, өйдә ятып торыйм»,— дип ялынуларына тегесе колак та салмады. Чәрелдекле тавышы белән кычкырган булды: «Нәрсә сөйләгәнеңне беләсеңме син, Бану?! Сугыш вакыты икәнен оныттыңмы әллә, чак кына сырхаулаган саен эштән калып ята башласак, кая китә? Оят кирәк — фронтта ирләребез шулай кылансалар, без — монда... Әллә нәрсә булмас, бер кузгалып чыгып китсәң, язылa ул»,— дип тавыш кубарып, чыгып киткән иде. Тик әниләре аякка баса алмады шул...

Кайтып озак та үтмәде, әтиләре үги әни алып кайтты. Үги әни — фельдшер Сәйдә иде. Ул сугышның соңгы елында тол калган иде.

Әтисенең Сәйдәгә өйләнүенә Шәйхаттар теше-тырнагы белән каршы булды. Хәтта әтисе сүз башлап:

— Балалар, иртәгә мин сезгә үги инәй алып кайтам инде. Өйдә хатын-кыз булмагач, бик кыен бит ул. Сәйдә апагызны...— диюгә, Шәйхаттар дөртләп кабынып киткән иде:

— Их, әткәй, әткәй,— диде ул ачынып.— Соң, әнкәйне үтерүче шул иблис бит инде. Әгәр ул әнкәйгә тиешле дарулар бирсә, көн саен килеп эшкә кушмаса, бәлки әнкәй исән дә калган булыр иде!

Әти кеше шактый эндәшми утырды. Шуннан гына каты итеп Шәйхаттарга селтәнеп җибәрде, әмма тыелып калды, сукмады.

— Кара аны, малай актыгы! Бу хакта Сәйдә апаң килгәч авыз ачсаң, ишетсен колагың, каравыл йортына куып чыгарам мин сине,— дип, урысчалап нидер җикеренде, Гөлҗиһан аның сүгенү сүзләре икәнен генә чамалый иде.

Сәйдә йортка килеп кергәч тә, Шәйхаттар абыйсы өйдән эзен суытты. Күпчелек гомере каравыл йортында, атлар янында үтә иде. Ашау кайгысы басса гына өйдән урап китә, анда да Сәйдәгә күтәрелеп бер караш ташламас.

Шәйхаттар армиягә киткәч, үги әнисе бәйрәм ясады. Ни әйтсәң дә, Шәйхаттарның мондый салкын карашы сәбәбен белә иде ул. Әтиләре белән үги әнисенең аралары нигәдер якынаймады. Көн саен диярлек ызгыш, тавыш. Абыйсы киткәч тә бу хәл туктамады. Инде үги әнисе Гөлҗиһанга бәйләнә, тавышның сәбәбен өйдә ике хатын-кыз булуга бәйләп аңлата, әтисен тизрәк Гөлҗиһанны кияүгә бирергә этәрә иде. Инде менә бу теләге дә кабул булды үги әнинең. Тик өйгә кот керерме, юкмы?..

Кичке зәңгәр иңгәндә Җирән кашка Гөлҗиһанны Бакалы хастаханәсе каршына китереп җиткерде. Гөлҗиһан мәрәләп атын киртәгә бәйләштергәндәй итте, капчык авызын җайлап, бахбайның алдына солы куйды. Үзе авыр аякларын лыштыр-лыштыр сөйрәп, хастаханәгә табан юнәлде.

Күн белән тышланган авыр ишекне ачып алгы бүлмәгә үтүгә, борынга дару катыш тынчу ис килеп бәрелде. Ишек төбендә ябык кына бер түти бәйләм бәйләп утыра иде. Газапланып кына тупса аша атлап үткән яшь кызны күреп, үз уйларына оеп утырган түти урыныннан сикереп торды.

— И-и бала, бала... Нәрсә булды суң сиңа?..— Кизү санитарка-керәшен түтиенең беренче сүзләре шул булды.

Гөлҗиһанның озаклап аңлатырга хәле юк иде, язгы җилдә кибешеп чатнаган иреннәрен чак кына кыймылдатып:

— Зуравыл районыннан, Күперледән килдем,— диде.

— Күперледән?.. Әй, аллакайгынам... Бу араларда гел сезнең яктан хаста... Ничек килеп җиттең соң, үскәнем? Юл-мазар юктыр бит инде. Ай-һай, егерме биш чакрым җирне җәяүләп үтәргә...

— Ат белән килдем... Атланып...

— Әйтәм аны... Өс-кыяфәтеңә карарлык түгел, пычранып беткән. Озатучың кая калды соң?

— Үзем генә килдем.

Кизү санитарка Гөлҗиһанның сүзләрен әллә ишетеп бетермәде, әллә бу араны үзе генә, җитмәсә ат өстендә, үтә алуына зур шик белдерде, бәйләмен читкә алып, аңа җылы башмаклар китереп бирде.

— Үскәнем, кай төшең авыртып килдең соң?— дип сораштыруын дәвам итте кизү түти.— Иртәгә иртүк килерсең инде, бүген прием юк. Казер кизү врач кына йөри.

— Мин авырып килмәдем,— диде Гөлҗиһан акрын тавыш белән. Аның тәне туңып, калтырана башлаган иде.— Сезгә өченче көн Күперледән бер авыру китергәннәрие. Хәлен белергә дип килдем.

— Күперледән?..— Кизү түти сәерсенгән рәвештә кабатлап сорады.— Колхоз рәисе диделәрме соң... әллә шулмы? Ул көнне дә минем кизү көнем иде. Килгәндә үк ушы юк иде аның. Тәки ушына килмәде, бичара.— Аннан сүзен бүлеп, күзләрен чекрәйтеп Гөлҗиһанга текәлде.— Ә син... кеме буласың соң аның?

— Кызы.

Кизү зиһене ачылып киткән кешедәй, урыныннан кузгалды. Бая артыграк сүзләр ычкындырганга үкенеп, кабалана төште:

— Кызымыни...— дип сузды ул.— И-и, аллакайгынам, врачны чакырыйм, менә монда утырып кына тор,— дип җил-җил атлап, озын коридор буйлап китеп барды. Озак та үтмәде, кизү түтигә ияреп, ак халатлы табиб килеп җитте.

— Мөлековның кызы буласызмы?

— Әйе...— Хәзер инде Гөлҗиһанның туңуы бетеп, тәне кымырҗып яна башлаган иде.

Кизү табиб ике кулын халат кесәсенә тыгып, дәшми-нитми бер тын басып торды да, санитарка түтигә:

— Серафима Павловна, кыз әйбәтләп юынсын, тамагын туйдыр һәм...— ул Гөлҗиһаннан сорап куйды.— Сезнең төн кунар урыныгыз бармы?

— Юк шул.— Инде хәл кергәндәй булды.— Әткәйнең хәле ничек соң? Кайсы палатада ята ул?

Табиб бу сорауны ишетмәгән дә кебек, янә Серафима түтигә эндәште.

— Болай сөйләшәбез, Серафима Павловна. Сеңелкәшнең атын (санитарка табибка кызның ат өстендә язгы су ерып килүен әйтеп өлгергән икән инде) хастаханә утарына кертеп ябыгыз, ә үзе,— ул Гөлҗиһанга ым кагып,— кизү бүлмәсендә кунсын инде.— Табиб хәзер генә Гөлҗиһанның соравына җавап кайтарды,— авырулар турындагы мәгълүматларны, сеңлем, иртән генә бирәбез. Хәзер исә ял ит. Иртәгә...— табиб сүзен өзеп, башын аска ия төшеп, китеп барды.

Гөлҗиһан табибның әтисе хакында ләм-мим сүз әйтмәвенә күңеле борлыкса да, тәртип шундыйдыр инде дип, хафага калмаска тырышты.

... Иртүк Серафима түти керткән кайнар чәйне эчеп, бераз килешкилбәтен тәртипкә китерүгә аның янына кизү табиб белән тагын бер ак халатлы кеше килеп керделәр. Таныш булмаганы Гөлҗиһанның кәефе, сәламәтлеге хакында сорашып алгач:

— Сезгә... зур сабырлык күрсәтергә туры килер, сеңлем,— диде. Аның бит-маңгай тирәләре тартышып алды.— Без бик авыр хәбәр алып килдек... Әтиегез... кичә төштән соң аңына килә алмыйча... вафат булды.

Күз алдыннан стеналарның акшарлы шәүләләре йөгерешеп-бөтерелеп уздылар, теге кешеләр идән белән бергә кинәт түшәмгә чөелделәр. Ике куллап утыргыч читенә ябышты Гөлҗиһан.

— Ничек... Үлде?...— диде ул үзен белештермичә. Күзләреннән яшь атылып чыкты, иңсәләре тыелгысыз калтырый иде.— Сез... Сез... нигә әтием янына кертмәдегез?!— дип илерде ул.— Мине чакырган бит ул!

— Сабыр, сеңлем, сабыр,— диде табиб,— аны бераз акылына китерергә омтылып. Яхшылап аңлап калсын, дигәндәй, иплэп кенә сүзен дәвам итте.— Әтиегезнең безгә килеп житкәндә гомере санаулы сәгатьләр генә калган булган шул. Нык тидергән салкынны. Монда килергә чыккач та юл өзеклеге бит, көне буе арбада килүләр... Соңгарак калдылар, соңгарак...— Табибның сүзләрен Гөлжиһан юньләп ишетми дә, аңламый да иде инде, әмма тегесе һаман сөйләвендә булды.— Мөлековның абруйлы кеше икәнен беләбез. Үзебезнең район житәкчеләренә житкердек, алар телефон аша Зуравыл белән дә сөйләшкәннәр.

... Күперленең зираты Коры елганың уң ярында булып, Мөлековның гәүдәсен каравыл өенә кайтарып житкергән көнне дә әле су күәте кимемәгән, елга гөбердәп, кайнап ага иде. Ир-атлар кинәштеләр-табыштылар да, «Чапаев» исемендәге колхозны дистә ел житәкләп барган дүрт класс белемле, дуамал холыклы, Фәрвәжетдин Мөлековны сул яктагы күрше авылның зиратына илтеп жирләделәр. Аның кабере турыннан Күперле басуының бер почмагы күренеп тора иде...

Үги әни Мөлековның үлүенә артык көенмәде кебек. Йорттагы малтуарны, кирәк-яракны арзан бәягә күрше-күләнгә таратты да, иренең үлүенә кырык көн тулыр-тулмаста, үзенең туган ягына кайтып китте.

Гөлжиһанның үги әнисе янына барып, дөнья малы өчен тавышланып йөрү исенә дә килмәде. Әтисенең кинәт кенә жир куенына кереп ятуына ышана алмыйча тирән кайгыда йөрде.

## III

Август ахырларында Әүхәтне Зуравылга, райкомга чакыртып алдылар. Ул аннан икеле халәттә кайтты. Бер карасаң сөенгән, үсенгән кебек, икенче карасаң, йөзендә борчу галәмәтләре дә шәйләнә иде. Күрәсең, «тегендә» сөйләшү житди булгандыр. Ишек алдында булашып йөргән хатынына Әүхәт әлләни илтифат итмәде сыман тоелды. Гөлжиһанның:

— Кайттыңмы?— дигән соравына да бер сүз белән генә җавап кайтарды:

— Кайттым ла...

Ул өйалды баскычыннан йөгерә-атлый күтәрелеп, өйгә кереп китте, хатыны да аның артыннан иярде.

— Йә, нигә чакырганнар, райком кадәр райкомга?— дип үҗәтләнде Гөлжиһан. Әүхәт эндәшмәде, эре кыяфәт белән кесәсеннән яңа папирос кабы алды, бер почмагын ашыкмый гына ачты. Тәмәкесен бармагы белән әүшәләп йомшартты да, авызына кабып ут элде. Тирән итеп төтен суыргач, ниһаять, Әүхәт телгә килергә маташа башлады:

— Мине партия мәктәбенә нитәләр... кыстыйлар. Горькийга. Ике елга, ди.

Гөлжиһан төпченүен дәвам итте:

— Кемгә хаҗәт соң ул партия мәктәбең?

— Ни бит... Мине үсәргә кирәк, диләр. Партия оешмасы секретаре итмәкче булалар.

— Кайда?

— Үзебезгә инде. Күперлегә...

Әле хәзер генә сүзнең нәрсә хакында барганын төшенгән Гөлжиһан «һөжүмгә» күчте.

— Ике елга!..— диде ул шаккатып.— Ә мин... без... Әллә...

— Син ни инде... Авылда калып торасың,— Әүхәт янә папирос суырды.

— Ничек бер үзем калам? Шушы болын кадәр өйдәме?... «Гаиләм бар», дип әйтергә башың җиттеме соң, Ходай бәндәсе? Хатыным авырлы, дип.

— Ансын партия сорап тормый инде. Сугышка китмим бит. Үсәргә кирәк, диләр, әнә...

— Тагын ничек үсмәкче буласың! Җиде класс белемең бар, бригадир...

— Ул гына җитми, ди бит.

— Кем әйтә?

— Партия инде. Үсәргә кирәк, ди. Завуд-фабрикта, авыл хуҗалыгында эшләп чарланган кешеләрнең үсүе шарт, ди.

Әүхәт райкомда булган сөйләшүдән эләктереп кайткан акыллы сүзләрне өзми-куймый кабатлый иде.

Ялгыз башы кышлар, җәйләр үткәрәсен уйлап, инде борчуга калган иде Гөлҗиһан. Ялварулы тавыш белән үрсәләнеп сорады:

— Көмәндәге балам белән мин нәрсә эшләргә тиеш булам инде, Алла колы?

— Синең бар белгәнең Алла да Ходай,— диде Әүхәт көтмәгәндә җитди итеп.— Бәдри абзый белән Шәмсия түтигә әйтеп китәрмен, ташламаслар, күз-колак булып торырлар. Быелга утын-печән җитәрлек, киләсе елга җәйне авылда, практикта үткәрәм. Аннан бер кыш нитәсе дә, бетә дә...

Чарлап кайтарганнар моны дип уйлап алды Гөлҗиһан, Әүхәт һаман үзенекен тукый бирә.— Партия миңа нитә... ышана икән акламый булмый инде, Гөлкәй. Теләсә кемне райкомга чакырып, партшкулга димләмиләр. Хатын-кызның эше бала табу. Шул балага бәйләнеп тик ята ул. Бөтен ил белән йөкле хатыннарны саклап ятарга тиешме без?! Хәзер бездәге хатын-кызлар иң күп нитүчеләр... бала табучылар. Туже кирәк эш...

Гөлҗиһан ире белән сүз көрәштерүнең мәгънәсез икәнен аңлап, өстәл хәзерләргә тотынды. Хатыны сүздән туктагач, Әүхәттә бичә гаме китте, мич алдына чүгәләде дә тәмләп тәмәкесен суыра бирде. Ара-тирә ирен читенә эчкерсез елмаю җәелә иде аның.

* * *

Шыксыз суык февраль көннәренең берсе иде. Гөлҗиһан иртән авыр тойгылар эчендә уянды. Бөтен тәнне хәлсезлек ваткан, изгән кебек. Фермага барып җитеп эшкә керешер-керешмәс үк хатынның хәле мөшкелләнә башлады. Кулдашы яшь кыз булса да, Гөлҗиһанның хәлен аңлап:

— Ныгытып чирли башламас борын, бар, өеңә кайтып кит, син, Гөлҗиһан апа,— диде.— Корсагың авызыңа җиткән, ничек курыкмыйча эшкә дип чыгып киттең?.. Ат белән илтеп куяргамы соң, бөтенләй төсең киткән бит.

Гөлҗиһан үзе дә эшнең уеннан үтеп баруын тоя иде, эшкә килүенә дә үкенеп туя алмый иде. Тик, үзе шайтан котырткандай, һаман киреләнә бирде.

— Атсыз да бик әйбәт кайтып җитәрмен әле. Вакыт җитмәде бугай... карыным актарылган кебек, чыдап булмый, бәлки... әле үтеп тә китәр. Иртә бит әле.

— Үтәр, үтми-ни,— диде кыз көяләнеп.

Гөлҗиһан көрпә тузанына баткан халатын салып, чөйдә эленеп торган сырмасын алып киде, аһылдый-аһылдый шәленә уралды да, кышкы кояшның сүрән яктысында чана юлы буйлап авылга табан төшеп китте. Авыл башына җиткәндә ныклап чирли башлавына, тулгак тотуына тәмам ышанган иде инде ул. Эче борып-борып ала, карлы юлга ятып

ауныйсы килә. Күзеннән туктаусыз яшь коела. Үзе һаман кешеләрдән оялып, тирә-ягына караштыра, «Ничек тә өйгә кайтып егылырга, юлда андый-мондый булып адәм көлкесенә генә калмаска иде,— дип эченнән генә Ходайга ялвара ул, үзе тәкатьсезлектән башы әйләнүен сизеп, егылып китүдән сакланырга чамалый. Аякларын сак кына шудыра торгач, ниһаять, Бәдри агайлар турысына кайтып җиткәндә аңы томалана башлады, һич тә түзәр әмәле калмаган иде. Баш миенең ерак почмагында: «Беттем, үзем дә харап булам, бала да харап була»,— дигән җан өшеткеч уй чагылып үтте. Аркасыннан шыбырдап кайнар тир түгелә, тәнендә чәнчүләр биешә. Өйгә кайтып җитсә дә, биек баскычтан күтәрелер көч тапмаячак ул, шуңа күрә, ихтыярсыздан Бәдри агайларга табан каерылды, ашыгып ишекләрен дөбердәтә башлады. Бәхеткә каршы, Шәмсия түтинең комган тотып тышка чыгып барган чагына туры килде ул. Әби аптырый төшеп ишек шудырмасын тартып җибәрде һәм баскыч төбендә чүгәләп торучы, төс-кыяфәте киткән Гөлҗиһанны күреп бер мәлгә телсез калса да, үзен тиз кулга алды. Бар мәшәкатен онытып, комганын куйды да, өйдә тамак ялгап утыручы Бәдри абзыйны чакырып чыгарды:

— Әйдә, карт, җебеп торма! Чананы китер, күрәсең бит, баланың вакыты җитеп ашкан.

Бәдри абзый карчыгының Әмәкәй базарына йөри торган сары юкә баулы бәләкәй чанасын баскыч төбенә китереп куйды. Йөгереп өй алдыннан чыпта алып чыгып чана төбенә җәйде һәм Шәмси түти белән икәүләп Гөлҗиһанны чанага салып, каршы як өйгә — йөкле хатынның үз өенә алып кереп киттеләр. Юл уңаенда Шәмси карчык тәтелдәп алды.

— Болай булгач, өйләренә кайтарып өлгерәбез. Ходай насыйп итсә, Үз өеңдә, үз көең ди.

Кешедә соң... бәбәй табу дигәч тә. Әүхәтне әйт инде, тәки хатын йөкле дип тормады, укуга китеп барды. Кәмүнискә хатын кирәкми микән, ә?.. Билетын кочаклап ята микән инде?

Чананы җилдертеп Гөлҗиһаннарның баскыч төбенә үк китереп җиткерделәр.

...Шәфкать туташы килеп җиткәндә, Гөлҗиһан якты дөньяга бер малай «алып кайткан» иде инде. Алар тирәсендә Шәмси карчык бөтереләләә. Анасының куен җылысына төреп салган балага теләкләр теләп туймый иде.

— Аллага шөкер, исән-сау котылды, балакаем,— диде ул кет-кет көлеп.— Өенә дә җылы төште, су да җылытып өлгердем тәки. Сабыйның туган оңгайга дөнья яңгыратып сөрән салуын күрсәң, син,— дип шәфкать туташына чишенергә булышты.— Тавышы кайдан чыккандыр, йодрык кадәр генә бит үзе!

* * *

Әүхәттән хат алганның икенче көнендә үк Гөлҗиһан иренең теләген үтәде — балага Әхнәф исемен яздырып кайтты.

...Июнь урталары. Зарыгып көткән кояшлы көн. Быел җәй артык кинәндермәде. Әле һаман да көннәрнең җылыга туена алганы юк. Май ахырларыннан бирле кояш юньләп күзгә күренмәде. Яңгыр да җил — тәмам үзәкләргә үтте. Шуңа күрә аз гына кояш чыкса, күңелләр күтәрелеп, дөнья түгәрәкләнеп киткәндәй була. Әхнәфне имезеп, бишегенә салгач, Гөлҗиһан йөгерә-йөгерә чишмәдән су алып кайтты. Улының берни сизмичә изрәп йоклап ятуын күргәч, ананың йөрәге янә сөенеч белән тулды. Иплән кенә улының астындагы чүпрәкләрне караштырды — асты коры әле, «һай, бигрәк балык тотарга ярата»,— дип үз алдына

елмаеп куйды ул. Бишеккә сак кына кагылып, сиртмәсен аска тартты. Шуны гына көтеп торган сыман, сиртмә җанланып китте, үзе белгән көй җаена бәллүли башлады. «Үсәбез, әйеме, улым, үсәбез! Әттә кайтуына зур булып үсәбез»,— дип такмаклады әни кеше.

Гөлҗиһан, улының матур гадәтләренә сөенеп, сабыйның дым типкән маңгаеннан үбеп алды. Өстендәге япмасын әйбәтләп япкан чакта, җил капканың шыгырдап ачылганын ишетеп, тәрәзәгә күз салды. Капкадан зур чемодан күтәреп, ыспай гына киенгән бер ир заты кереп килә иде. Гөлҗиһан баштарак әлеге ир кешене чит-ятка санап, аптырабрак калса да, аның Әүхәт икәнен йөрешеннән чамалап, ишеккә ташланды. Аннан үзе үк бу сабырсыз кыланышын килештермичә, тупсаны үтәр-үтмәс туктап калды. Борылып тиз генә өй эчен караштырып алды. Өйдә тәртип иде. Чигүле тәрәз пәрдәләре өй эченә илаһи аклык, сафлык биреп торалар, һәр нәрсә үз урынында, пөхтәлек бөркелеп тора иде. Шуннан соң гына хатын өйалдына үтте, ул арада Әүхәтнең баскычтан менеп житүе ишетелде. Шул шәпкә киереп ишекне ачты, каршысына чыгып килүче хатынын күргәч, арыган кыяфәт белән елмаеп җибәрде һәм нәрсәдәндер тартынып торган кебек:

— Ниттем, карчык... менә... каникулга,— дип чемоданын бер кулыннан икенче кулына күчереп азапланды.

Гөлҗиһанга Әүхәт бөтенләй ят кеше сыман тоелды. Ул аның кайтуын көтте. Әмма бу көтү сагынып, зарыгып көтү түгел иде. Кулларына урын таба алмыйча (үзеңнең ирең белән, читтән кайтучы башкаларга кул сузып күрешкән сыман, күрешергәме, юкмы?), Әүхәтне өйгә кыстады:

— Әйдә, әйдә... Өйгә керик,— диде дә, иң әһәмиятлесен әйтеп калырга тырышкандай,— Әхнәф яңа гына йоклап китте,— дип, иренең чемоданына барып тотынды.— Бик авыр бит, ничек күтәреп кайттың шул тиклем җирдән.

— Авыр дип... Анда ни... китаплар инде,— диде ул акланган шикелле. Алар шулай, үзләре дә белештермичә Әүхәтнең йөге белән кайнашакайнаша эчкә үттеләр. Шунда ир кеше исенә килде:

— Исәнме, карчык,— дип хатынын иңнәреннән кочып алды.

Әүхәт кайтып кергәч, өй эче тулыланып китте кебек, Гөлҗиһан тәненең җиңелчә генә кызыша башлавын тойды. Ул арада Әүхәт бишек тирәсендә иде инде. Япмасын ачып, ашыгып балага үрелде.

— Кулларың салкын түгелме? — дип сорады Гөлҗиһан пышылдап. Әүхәт җавап кайтармады, нарасыен бишектән алып күкрәгенә кысты. Сабый иреннәрен кыеш-мыеш иттереп торды да, авызын бар хутына ачып, кычкырып елап җибәрде.

— Кара, кара, әттәсен ничек тавышланып каршы ала бу егет,— дип көлде Әүхәт. Шулай да Әхнәфнең «тактик» алымы бу юлы аңа уңыш китерде — малайны әнисе кулына тапшырудан башка чара калмады.

Хатынының читкә борыла төшеп, елавыннан туктый алмыйча маташкан сабыена күкрәк каптыруын Әүхәт тыелгысыз дәрт белән карап торды.

Гөлҗиһан кызара төшеп, иренә борылды:

— Сөннәткә утыртырга да вакыттыр инде, тынгысызлана.

— Сөннәткә? — дип гаҗәпләнгән шикелле кайтарып сорады Әүхәт.— Ни бит, карчык, безнең кебек партийныйларга мондый эшләр белән шөгыльләнү килешеп бетмәс. Әнә, урыслар сөннәтсез дә шәп яшиләр. Искелек калдыгы бит ул. Тагын шунсы да бар,— хатынының бу ниятеннән кайтарырга саллы дәлил табуына сөенгәндәй, Әүхәт ныклы ышаныч белән сөйли башлады.— Армиягә баргач та көләчәкләр аннан, мыскыл итәчәкләр. Үземнән беләм...

Кайтып кермәс борын ире белән бәхәскә керүне яхшысынмыйча, Гөлҗиһан тынып калды. Әхнәфне бишегенә салды һәм самавырга чишмә суы коя башлады.

...Әүхәт җәй буе юньләп өйдә тора алмады. Кайтышлый ук райкомга кереп чыккан иде, каникул чорында эшкә дә тәгаенләп куйдылар үзен. Аңа агитколлектив оештырып, авылдан-авылга, бер кыр станыннан икенчесенә йөреп, халыкка партиянең тарихи егерме икенче съезды карарларын аңлатып чыгарга күрсәтмә бирелде. Партия эшендә исә карар катгый, шикаятькә урын юк! Ил башлыгы Хрущев та, партия мәктәбе тыңлаучысы Әүхәт Гайсин дә партия уставы каршында тигез һәм моның шулай булуына Гайсин иптәш чын күңелдән ышана иде...

Шулай җәй буе чабулап йөрде, йөрде дә, Әүхәт янә Горький каласына, укуын дәвам итәргә китеп барды. Кышлык утын да әзерли алмады хәтта.

Киткән чагында Әүхәт: «Хафаланма, колхоз рәисе белән сөйләшенгән, утын китереп бирәчәкләр?» — дип кат-кат тәкърарласа да, сентябрь ахырлары җитеп килүгә карамастан, әле ишек алдына бер пүлән утын кайтып кергәне юк иде. Көннәр җылы тора иде. Иң элек Гөлҗиһан урманга барып, бер арба чамасы утын хәзерләде, икенче көнне ат-арба алып, янә урманга юл тотты.

Урманга инде сары төс иңгән. Агачлар көз бүләк иткән соңгы җылы көннәрнең рәхәтлекләрен үзләренә сеңдереп калырга тырышкандай, талгын тынлыкта оеп утыралар. Якындагы басуда МТС тракторлары дәү сабаннар белән басу актарып йөриләр. Караланып калган ерак кырлар артындагы Ык буе күлләреннән һавага торналар күтәрелә. Алар үзләре канат нygыткан күлләр, оялары җылысы сакланган, моңсу пошаманлыкка төшкән камышлыклар өстеннән кыйгачлап бер әйләнәләр дә, үзләреннән алдарак күтәрелеп, ырудашларын сабырсыз чакырып очкан төркемгә килеп кушылалар. Сары төс балкытып янган урман сагаеп торна тавышларын тыңлый. Урман почмагыннан үтеп, Чикләвеклек ешкынлыгына борылуга, урман читеннән боргаланган юл буйлап кара кучкыллы төтеннәр чыгарып, дөбер-шатыр килүче трактор күренде. Тимер албастыдан куркып-өркүеннән шикләнеп, малкайны урман авызына борып туктатып калды.

Трактор юлдагы кантар, чокыр-чакырларга исе китмәгәндәй, борынын йә өскә чөеп, йә аска капыл чөңкәеп алга үрмәли иде. Җигүле ат турысына җиткәч, тракторның үкерүе кинәт басылды, кояшта ялтырап торган чылбырның дулап әйләнеше әкренәйде, ахырда, тимер тавы юл буйлап бераз барды да туктап калды. Ишексез кабинадан Баһау Гыйльмиенең майлы кәпәч кигән башы күренде. Ул бер тын Гөлҗиһанга карап торды һәм бөтен гәүдәсе белән трактор чылбырына чыгып басты, җиңел генә җиргә сикерде. Хатынны шунда ук танып алган иде, арба янына килеп, әле кичә генә капка төбендә аерылышкан җан сөйгәненә күргәндәй, көр тавыш белән сәлам бирде:

— Хәлләр ничек, Гөлкәй? Арбаң бик хөрт икән, аратасыннан төшеп кала күрмә, мин сиңа әйтим...

Урман буенда Гыйльметдин каршы килеп чыгар дип Гөлҗиһан күз алдына да китермәгән иде, әлбәттә. Төптән юан егетнең янына килеп басуыннан шактый югалып та калды, кыенсынды да.

— Утынга килеш... — Сүз юнәлешен үзгәртәсе килепме, җебеп төшүен сиздермәскә тырышыпмы, күтәрелеп егеткә карады. — Укып та бетердеңмени инде?..

— Ә кәк же, — дип тел шомартты Гыйльметдин кәпәчен баш түбәсенә табан күтәрә төшеп. Һич тә исе китмәгән кыяфәт белән тракторына ишарә ясады: — Мы-ты-еста шушы үтилне бирделәр, вәт. Бүген «Чапаев»ка җибәрделәр, мондагы егетләр сыната башлаганнар, ярдәм сорыйлар. — Егет сүзне Гөлҗиһанга борды. — Урманга барам дисеңме? Әүхәт кайда, эчтәрәк, утын хәзерләү белән мәшгульме?

Егетнең бу сорауны бирми калмаячагына иманы камил иде Гөлҗиһанның.

— Әүхәтне укырга җибәрделәр бит. Райком ашыктырды, менә утын да әзерләргә өлгермәде. Яшь хатынның ялгызы урманга кереп баруын ишеткәч, Гыйльми сәерсенеп кашларын күтәрде.

— Үзең генә ничек утын төяп алып чыкмакчы буласың? Әйдә, мин дә булышам. Без аны хәзер...— дип җанланып китте.— Эшем ул кадәрле ашыгыч түгел, авылга кайтып кунсам, шул җитә. Идарәдән плугарь сорыйсы гына кала.

Егетнең сүзләрен ишетүгә, Гөлҗиһан кайнарланып, аңа каршы төште:

— Ни сөйлисең, Гыйльметдин! Утын дигәч тә, чикләвек чыбыгы гына инде ул. Якында гына... Бар, үз юлында бул. Кеше-кара килеп чыкса, Аллам сакласын, берне биш итеп сөйләрләр...

Әмма егет Гөлҗиһанның бу сүзләренә игътибар да итмәде кебек. Юл уртасында гөрелдәп утырган тракторын да онытты, җәһәт кенә арбага менеп кунаклады да хатын кулындагы дилбегәгә үрелде.

— Аптырама, Гөлкәй, хәзер төяп алабыз аны...— дип, ара-тирә тракторга куркулы караш ташлап торган атка чөңгереп җибәрде.

Гөлҗиһан, Гыйльметдиннең бу тәвәккәллегенә каршы нәрсә әйтергә белми, егет кулына күчкән дилбегәне кире үзенә алмак булды.

— Монда гына дим бит инде. Кит, кеше күрсә...

Ни сәбәптер аның тавышына, хатын үзе теләсә дә, таләпчәнлек, катгыйлек бәреп чыкмады. Янында Гыйльметдиннең булуына эчтән генә сөенде дә сыман хәтта. Урман-чытырман диләр, япа-ялгыз утын җыеп йөргәндә дә шикләнеп, куркып кына эшләде. Күңелгә әллә нинди уйлар килә. Әнә Надулат чокырында сугыш вакытында угрылар качып ятканнар, ди. Һаман да якын-тирә авыллардан мал-туар югалып кына тора. Халык арасында: «Качкыннар әле дә булса шунда килеп чыккалыйлар икән. Фәлән кеше урманга баргач, землянкалары янына ук барып чыккан, имеш. Төтен чыга иде, нәрсәдер пешерә торганнардыр дип әйткән, ди»,— кебегрәк сүзләр дә ишетелгәли иде. Дөресен әйткәндә, бераз пошаманда иде Гөлҗиһан. Шуңа күрә, Гыйльметдиннең арбага менеп утыруына бик үк риза булмаса да, артык карышып та маташмады. Дилбегә хатын кулына күчкән иде инде, атны куе үлән каплап бетерә язган иске урман юлына борды. Дымсу урман эченнән ике-өч минут баргач, атын зур гына чыбык өеменә туктатты.

— Шушында...

Гыйльметдин баштагы әрсезлегеннән кыенсынган шикелле, сүзсез калган иде. Шулай да сыртлап өйгән чыбыкны күргәч, сызгырып җибәрде:

— Фью-ю... Бу кадәрне ялгызың өйдеңме?..

— Үзем инде. Урманга барган саен мине тракторчы егетләр каршы алмый бит.

Гыйльметдин үз-үзенә ышанган хәлдә, атны җайлап өем янына борып куйды. Арба силәсенә бауларны тиешенчә бәйләп, эшкә тотындылар.

— Кияүгә чыгуыңны ишеткәч, Гөлкәй, атна-ун көн исәңгерәп йөрдем,— дип Гыйльметдин хатирәләргә кереп китте.— Укуны ташлап, Ижау якларына да китмәкче булдым...

Гөлҗиһан эндәшмәде. Гыйльми төпченә башлады:

— Әүхәт белән чынлап яратышып йөрдегезме, әллә?.. Каравыл өендә очрашып йөрисең икән, дип ишеткән идем... Әйттеләр...

Егетнең болай сөйләнүе Гөлҗиһанга ачу китергеч тәэсир итте.

— Кем белән кайда очрашуымда синең ни эшең бар?— диде ул кырыс тавыш белән. (Очрашкан мәлдә чыкмаган тавыш каян килеп үзгәрде, дип уйлады ул).— Әүхәт бер дигән кеше. Өйләнештек, яшибез. Укуы да тәмам булса.— Гөлҗиһан, көтмәгәндә, күңеленең иң түрендә тоенләнеп калган рәнҗешен тышка чыгарды.— Үзең булдырдың бик! Чаллыга китүеңне дә кешеләрдән генә ишеттем. Сез, егетләр, барыгыз да бер иш. Сөйләгәндә шома сиптерәсез, кызларның күңелендә нәрсәләр бар — ан-

сын уйлап та карамыйсыз. Әүхәт белән каравыл өендә очрашканмы-юкмы, белмисең, беләсең дә килми. Ә сөйлисең... Фәймәгә гайбәт хатлары язып ятканчы, кайтып күзгә күренеп китәләр аны!

Гөлҗиһанның сүзләре егетнең мин-минлеген кытыклап үттеләр, инде күтәреп алган чыбыкларын кире өемгә ташлап, сузып кына:

— Гайбәт түгел, Гөлкәй, белеп әйтәм,— диде. Әмма тавышында ышаныч юк иде инде.

— Каян беләсең?—диде Гөлҗиһан, егетнең авызыннан чыккан бу сүзләрнең тамырын беләсе килеп.

Егет тә сүзен бирәсе килмәде, әйткән сүз—аткан ук, яшереп торуда файда юк, турысын ярып салды:

— Сәйфи әйтте... Ул авылга кайтып килгәние бит. Артыннан сиңа хат җибәргәнием, тапшыр дип... Барган ул синең янга, каравыл йортына. Көндез күрергә җай чыкмады, ди. Вәт, Әүхәт белән чөкердәшеп утыралар иде, анда синең кайгың юк, ди килгәч... Озак та үтмәде, синең кияүгә чыгу хәбәре... Дөрес түгел дисеңме инде?!

— Тинтәк!—диде, Гөлҗиһан гарьләнүен яшерә алмыйча. Бу сүз кемгә төбәп әйтелгәндер, һәрхәлдә, аны Гыйльметдин үзенә кабул итте.

— Шулай, тинтәккә дә әйләнәсең инде...

Гөлҗиһан кайнарлануын дәвам итте:

— Каравыл өенә кем кермәс тә, кем чыкмас соң? Егет кеше булса, Сәйфиең нигә өйгә кереп амәнәтеңне үтәмәгән?

Гыйльметдин эндәшмәде. Акрын гына җыр сузып җибәрде:

Су буеннан сулар алып,
Су сибәм гөлләремә;
Мәңге шиңмәс гөлләр булып
Калдың күңелләремдә...

Йөк төялеп беткәнче яңадан сүзләре ябышмады. Гөлҗиһан әллә кайда калган ямьле кичләрне уйлап күңеле йомшара төшүен сизеп, Гыйльметдингә ялварулы тавыш белән эндәште:

— Калганын үзем дә төяп бетерермен, рәхмәт, син кит инде, Гыйльметдин.

— Юк инде, Гөлкәй, башланган эш—беткән эш. Сиңа үпкә дә, рәнҗү дә сакламыйм. Үземдә гаеп... кыюлык җитмәде...

Эш тәмамлангач, егет куак төбенә пинҗәген җәеп куйды да, бер кырыена утырып, кесәсеннән папирос алып кабызды.

* * *

Гөлҗиһанны идарәгә дәшеп алдылар. Хәл-әхвәл сорашкан булып маташтылар да хатын өчен бөтенләй көтелмәгән эш—дуңгызлар карарга тәкъдим иттеләр. Көн үткән саен үтәлмәгән хезмәт көннәре арта бара, инде бәрәннәрне карауны башка кешегә тапшырганнар—авылга яшь килен төшкән икән. Гыйльметдин өйләнгән...

...Бу кышны Әүхәт каникулга кайтмады. «Соңгы ел бит, укыйсы, өйрәнәсе фәннәр артты, печтеки генә вакыт юк»,—дип зарланып язган иде соңгы хатында. Укуны инә белән кое казу дип юкка гына әйтмиләрдер, шулай булмаса, типсә тимер өзәрлек ир зарланып ятмас иде!

Инде Әхнәф тәпи йөри башлады. Эштән кайтышлый ук Шәмси түтидән сабыен кереп ала Гөлҗиһан. Ул ишектән күренүгә малай: «Әннәм!»—дип әнисенә ташлана. Үзенә бер каз оясы кышкы суык ияртеп кергән хатын бер мәлгә аптырап тора. Сабыен ни кулына алырга белми, үзеннән читкә этәрсә дә, нәүмиз итәр кебек. Ярдәмгә Шәмси түти килеп җитә: «И-и, Ходаем, киемнәре боздай салкын, киез итекләренә кар сарган, хәзер очанлый башлыйсың?»—дип Әхнәфне әнисеннән көч-хәл

белән кубарып алуга ирешә ул. Малаен киендергән арада Гөлҗиһанга исе китеп сөйләнеп ала:

— Әүхәт, зимагур, кайтмыйм дигәнме?! Бу хөкүмәт нәрсә уйлый икән, ә? Яшь баласы белән инәсен ялгыз калдыр да, ирен алып кит инде... Уку дигәч тә, егет-кызлар бетмәгән, шулар укысын. Сугыш вакыты түгел. Үзең дә, кызым, куш йөрәкле икәнсең. Мин булсаммы! Сугышка чаклы Бәдри абзыеңны да укырга кыстаганнар иде, ветсанитар булып кайтырсың, начальства булырсың дигәннәр иде. Балалар ишле иде. Ишектән атлап чыкмыйсың, дидем. Чыгып китсәң — бусагам төсен күрмәссең, дидем. Әүхәтенә нәмә җитми икән? Шаклар катам — кәмүнискә хатын да, бала да кирәкми икән.

Гөлҗиһан карчыкның сүзләрен сабыр гына тыңлап тора да күтәрелепбәрелми генә җавап кайтара:

— Кем арбасына утырсаң — шуның җырын җырларсың, диләр бит. Бригадир булып та әйбәт эшләгәч, күреп алганнардыр инде (Шәмси түти сизә — хатынның Әүхәткә тел-теш тидерәсе килми).— Укысын, кеше булсын, дигәннәрдәр. Башка кешегә әйтмәделәр бит, Әүхәтне җибәрделәр. Күп калмый инде, бер кичкә — кер мичкә дигәндәй, җәйгә кайтып та җитәр.

...Гөлҗиһан саташып уянды. Исәнгәрәп, шактый вакыт кайда икәнен белештермичә ятты. Тешләре яңак итләрен авырттырып кысылган, куллары йодрыкланган — ниндидер күзгә күренмәс дошманының ярсулы һөҗүмен кайтарырга хәзерләнгән халәттә иде ул. Тирә-юньне тутырып ачыргаланып кычкырган авазы һаман да яңгырап тора сыман. Әүвәл бик кычкырмакчы булып та тавышын чыгара алмый интекте бугай ул. Аннан соң гына бугаз төбенә бөялгән төен кинәт тышка бәреп чыкты, өй эчен яшь хатынның «Аh!..» — дигән уфылдавы тетрәтте.

Ул төш күрде... Имеш, Әүхәт белән җәйге матур көндә атка утырып урман буендагы ямь-яшел аланнан печән чабарга килгәннәр. Аланның гүзәллеген сөйләп аңлатырлык кына түгел. Талгын җилдә аллы-гөлле чәчәкләр тибрәнә, чәчәкләрдән дә матур төрле-төрле күбәләкләр уйнап очалар. Җитез, нәфис канатларын җилпегәннәренә кадәр аермачык. Бал кортларының безелдәве колакларны иркәли, әллә нинди бөҗәкләр кайнаша. Чәчләргә тияр-тимәс дымсу җил исеп куя. Якында гына көмеш чишмә чылтыравы ишетелә.

Әүхәт-гаярь ир солтаны. Хәрәкәтләре салмак, ипле. Ап-ак күлмәгенең җиңнәрен сызганып җибәргән. Җәһәт кенә атны тугарып, арба силәсенә бәйләп куйды, арбада тыныч кына уйнап утырган Әхнәфен күтәреп алды, малайны «үчтеки-үчтеки» үсендерә, күккә чөя башлады. Сабый куанычына чыдый алмый, кулларын-аякларын бутый, икәүләп көлешәләр, чыр-чу киләләр. Ул да булмады, каяндыр әзер, шома киртәләр табып алды Әүхәт. Гөлҗиһан белән икәүләп матур шалаш корып куйдылар. Гөрселдәп күк күкрәде, аяк аслары чайкалып китте, тезгенен өзгән акбүз ат ялларын җилгә таратып чабып үтте. Дөнья караңгыланды, агачлар арасыннан иләмсез кыяфәтле гыйфрит килеп чыкты да, Гөлҗиһан искә-санга алганчы Әхнәфкә килеп ябышты. Ир белән хатын икесе тиң гыйфриткә ташландылар, аның шыксыз, корыган ботакларны хәтерләткән кул-чуклары арасыннан нарасыйларын йолып алырга тырышалар, имеш. Бала өчен җан-фәрман көрәшкән җирдән теге гыйфрит япь-яшь матур чибәр кызга әверелде дә куйды. Кыз берни булмагандай елмая төшеп, Әхнәфне әнисенең кулына тапшырды, Гөлҗиһан исә чырыйлап елаган баласын кайнар күкрәгенә кысты. Борылып караса... Әүхәт белән пәри кызы җитәкләшкән кулларын адым уңаена чайкый-чайкый урман эченә кереп баралар. Гөлҗиһан бар көченә кычкырмакчы була, туктатып калмакчы була, тик тавышы чыкмый, тораташ кебек катып калды, имеш...

Хатынның тынгысыз күңелен әлеге төш вәсвәсәләде. Куенында изрәп йоклап яткан Әхнәф әнисенең кисәк кычкырып җибәрүеннәнме, әллә асты юешләнгән дә, хәзер үзенә игътибар таләп итәме — мышкылдый башлады. Хатын исенә килде, әлеге хәлнең төш кенә булуына сөенеп, эченә җылы йөгерде. Шулай да күңелдә шик калды — хатын-кыз заты төшкә керсә, йә чир, йә бер-бер хәл килеп чыгуын көт,— ди иде мәрхүм әнкәсе. Уйлап баксаң, төшкә ниләр генә керми инде. Шәмси түти әйтмешли,— хәерле белән булсын...

* * *

Соңгы айларда Әүхәттән хат-хәбәр булмады. Инде җәй уртасы, һаман кайтып җитә алганы юк. Шуңа пошаманга төшеп йөрүе. Эштән кайтышлый Гөлҗиһан авыл советына кереп акчалата налогларның бер өлешен түләп чыкты, Әүхәт кайтып житсә, киңәштабыш итешерләр дә, бер-ике баш сарыкны суеп сатмыйча бу налог дигәннәреннән котылып булмас, дигән уйлар эчендә өенә ашыкты. Шәмси түти инде Әхнәфне сыйлагандыр, тәмләп чәй эчергәндер, капка төпләрендәге утыргычка утырып, «әннәнең» кайтып житүен дүрт күз белән көтеп торалардыр.

...Ерактан ук үз турларында гадәти булмаган җанлылык күреп, талпынып куйды Гөлҗиһан. Йөрәге кысылды, буыннары йомшарды. «Әүхәт кайткан... Ниһаять, кешечә, бергәләп яши башларбыз!» Күңеле нечкәреп, тамак төбенә төер килеп утырды. Арыган кыяфәттә, эш киемнәрендә Әүхәткә һич тә күренәсе килмәгән иде дә, нишлисең, менә ул кайтып җиткән.

Рәхәт моңсулык биләп алды аны, аңлата алмастай тойгылар эчендә яңа башлады ул. Адым саен «Кайткан... кайткан...» дигән уй баш миенә сулык-сулык бәреп бара...

Әмма капка төбенә җиткән саен аннан үзенә табан шомлы салкынлык бөркелгән сыман хис итте ул. Шәмси түти нидер сөйли. Бәдри абзый бөкерәя төшеп басып тора. Әхнәф күренми. Кайда икән ул?.. Тегe, капка баганасына сөялеп торган таза гәүдәле ир, чыннан да, Әүхәт бугай. Тик нигә соң ул Гөлҗиһан ягына күтәрелеп тә карамый. Урам буйлап кайтып килгән хатынын күрми калмагандыр ич инде... Шәмси түти торган саен кыза, ахрысы, Гөлҗиһан ягына төртеп күрсәтә-күрсәтә Әүхәткә нәрсәдер аңлатмакчы буламы?.. Колагына аерым сүзләр чалынып китте:

— Җирбит сез, жирбитләр! Ничек жир күтәрә диген... Гөлҗиһанның кай җире ярамаслык, җә? Теге кәнтәеннең нәмәсе артык? Ике ел буе танавы белән кәс ертты, кайтуыңа, дөнья таралмасын дип казганды. Рәхмәтең шушы булдымы?

Әүхәт эндәшми. Капка баганасына кадаклап куйган кебек кымшанмый да тора бирә. Авыл башына карап тик тора. Инде Гөлҗиһан алар янына ук килеп җитте, Әүхәтнең каршысына килеп басты. Шәмси түтинең сүзләреннән үтә дә сәерсенеп:

— Әүхәт... — диде.— Башка сүз таба алмагандай сорап куйды.— Укуыңны бетерепме?... — Йөрәге кайнарланып тибә, ашкынып җавап көтә иде ул.

Әүхәт өчен Шәмси түти җавап бирде:

— Уку кайгысы булган дисеңме анда! — диде ул тавышына зәһәр ачы чыгарып.

Бәдри агай, әлеге сөйләшүнең шаһиты буласы килмәгән кебек, әкрен генә үзләре өенә табан атлады.

Ниһаять, Әүхәт телгә килде:

— Ниттек лә, кайттык...

Гөлҗиһан Әүхәтнең сүзләрен ишетмәде. Ул ишектән чыгып килүче Фәймәне күреп, телдән калган иде. «Нишләп йөри ул монда? Нигә Әүхәт, аны ишек алдына үткәрмәскә теләгән кебек, кымшанмый да тора соң әле?..»

Әүхәтнең сүзләрен Шәмси түти элеп алды.

— Кайтканнар берәүләр... Күрмисеңмени — себеркесен ияртеп алып кайткан бит,— дип ярып салды ул. Тик Гөлҗиһан һаман һичнәрсә аңлый алмый, үзенә карата искиткеч гаделсезлек эшләнгәнен генә чамалагандай булды.

Әүхәт теш арасыннан янә сыгып чыгарды:

— Без, ни... Фәймә белән ниттек... Горькийда ирле-хатынлы яшәдек... Аңа өйләндем... Авырлы инде ул... Без ни инде, Гөл...җиһан, кискән ипи ябышмас, әйбәтләп кенә аерылышаек. Без Фәймә белән минем өйдә нитәрбез, синең үз өең бар...

Гөлҗиһанны җен алыштырган кебек булды. Зиһене котырып актарыла, уйный, шул ук вакытта Әүхәтнең нәрсә сөйләгәнен дә яхшы аңлады — аның каршысында хатынына, баласына хыянәт иткән ир кисәге басып тора иде.

Әүхәт нидер сөйләнә калды, Гөлҗиһан тынычлыгын сакларга тырышып ишек алдына үтте, кычкырып елап җибәреп, күрше-күлән алдында сынатасы килмәде. Эчке тоемлау белән сизә иде — хәзер тирә-як күршеләрнең күзе-колагы шушында... «И Дөнья, нигә мәрхәмәтсез син бәндәләреңә? — дип сыкранды хатынның күңеле.— Инде нишләргә, мондый чакта нинди гамәл кылырга тиеш ул?...» Җанын әрнеткән сорау шушы иде. Гөлҗиһан гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләрен Фәймәгә төбәде:

— Син... син ничек... белә торып?.. Безнең бит улыбыз, Әхнәф үсеп килә...

Фәймә әлегә рәсмиләштерелмәгән тол хатынның беренче һөҗүмен ни рәвешле кире кагу хакында кат-кат уйланган булса кирәк, яшьлек дустының яшь томалаган күзләре дә, ачыргаланып биргән тәүге соравы да аны әллә ни чыгырдан чыгармады. Йөзе агарып киткәндәй булды, иреннәре тартышып куйды. Әмма бирешергә исәбе юк иде. Авыры беленеп торган корсагына ике кулын кушырып, әкрен генә сүз башлады:

— Дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса, диләр бит. Безнең белән дә шул булды инде. Гаеп-кыек элеп торасы юк. Теге чакта... син миннән Әүхәтне тартып алдың, мин авызны салындырып калдым. Күпме газаплануларымны үзем генә беләм... Персидәтел кызы белән даулашырлык түгел идек шул. Югыйсә, белмәдең түгел — инде Әүхәткә кияүгә чыгарга җыенып беткәнием. Әүхәт тә минем өчен җан атып йөрде бит. Өйләренә кайткан чаклар да булды... төнлә... Юк, син белмәмешкә салышма хәзер. Бөтен авыл беләдерие. Сине күргәч, Әүхәтнең башы әйләнеп киткән инде, ир-ат җүләр бит ул. Хәзер бик үкенә дә, терсәк ерак... Әүхәтне син яратмый да идең, уеңда Баһау Гыйльмие булды. Персидәтел кызы дигәч тә... Хәерче кешене санламадың, бай кияү кирәк булган сиңа. Шул гына! Язмыштан качып булмый икән, Әүхәт белән Горькийда тагын очраштык. Бу юлы син аны миннән тартып ала алмаячаксың инде.— Фәймә, каршысында тавыш-тынсыз торган хатынны өркетергә теләгәндәй, җиргә тибеп куйды.

Сөйкемле хатынның бәгырьләрне яндырырдай рәхимсез сүзләрен тыңлап, Гөлҗиһанның сулуы киселгән сыман булды. Бу кешеләргә нәрсә булган, нигә алар шулкадәрле мәрхәмәтсез кыланалар, нигә дип ачыктан-ачык җанын хурлыйлар, талыйлар. Җитмәсә, үзләрен җиңүчеләр кебек тоталар, сүзләрендә мыскыллау ярылып ята. Ир бирмәк — җан бирмәк, диләр. Башны иеп, чыгып китәргәме, әллә өйгә кереп бикләнергә дә, берсенә дә ачмаскамы?.. Алай нәрсә ота ул... Башта бөтерелгән томанлы уйларны Шәмси түтинең еламсыраган тавышы бүлде:

— Бетеренмә, Гөлҗиһан кызым,— диде ул.— Бу адәм актыкларына өч сәгать буе бернәрсә тукыйм инде, һич аңларга исәпләре юк. Әүхәтне әйтәм, йөзе кара, укып мулла, чукып карга булмас нәмәкәй. Алладан курыкмасалар, бәндәдән оялырлар иде!

## IV

— Әнкәй, дим, әнкәй, ипи бир әле. «Йолдыз»ны Теллетау ягыннан уратып кайтам.

Дөбер-шатыр атылып, өйгә Әхнәф килеп керде. Гөлҗиһан улына яратып карап алды да, тавышына ачулану билгеләре чыгарып:

— Чабышка барам, дип, тәмам теңкәгә тидең инде. Төш вакытында әйбәтләп тамак ялгап китсәң, ни була?— диде.

Күкрәгенә терәп ипи кисте, зур гына телемгә май якты, шикәр комы сипте һәм ишек катында сабырсызланып торган малайга тоттырды.

— Чамалап йөр, улым, имгәнә күрмә! Чыгып китәсең дә әллә кайларга олагасың...Эшең барын онытма!

Малай әнкәсенең сүзләрен бик үк өнәп бетермичә, ишеккә тартылды.

— Сабантуена ат әзерләүнең тәртибе бар, ди Бәдри бабай. Ул нәрсә әйтсә — шул закон. Син уйлаганча, һич тә ат җәфалап, чабулап кына йөрмим!

Бәдри агай инде җитмешен тутырып килсә дә, һаман колхоз эшенә катнаша, колхоз, авыл советы җитәкчеләре җигә торган атларны карый иде. Авылда бу атларны «кәнүшни атлары» дип йөртәләр. Аннан, аның һәр язда башланып, сабантуй көнне генә тәмамлана торган «җәмәгать эше» дә бар иде, анысы — сабантуйга чабыш атларын хәзерләү белән җитәкчелек итү. Шуңа күрә бу эшкә дәртсенгән малай-шалай Бәдри бабайлары тирәсендә уралуны зур дәрәҗәгә санныйлар, ә булыр-булмас малайны үз тирәсенә сырыштырмый да ул. Быел колхозның иң шәп чабышкысын, иң елгыр егет дип, Әхнәфкә тапшырган иде. Малай чая да, андый-мондый хәлләрдә тиз генә югалып та калмый иде. Монысы әтисез үсү галәмәтедер инде, һәр эшне башлар алдыннан әнкәсе аның белән киңәшләшә, малай исә сынатмаска тырыша, башын эшләтеп, зурлар шикелле акыллы сүз әйтергә омтыла.

Әтисез малай тауда чана шуып, чаңгы белән җил куып артык йөри алмый — ул сәнәк күтәрә ала башлаган көннән дөнья күтәргә тотына.

Малайның чата-карман килеп аты тирәсендә бөтерелүенә Бәдри бабай сөенеп бетә алмый. Әледән-әле үсендереп тора:

— Һәй, булдырасың, Әхнәф улым. Чистый, җегет булдың бит, ә! Сабантуйда ат чабыштыру жегет солтаннарының эше инде ул. Бар халыкның күзен яндырып дулап чапкан ат өстендә үтеп кит әле син — һәй, инәңнең баш баласы, Коры елгада күтәй сөзеп йөрү түгел инде ул!— Бабай соклануын яшерми «Йолдыз»га карап ала һәм кеткелдәп янә сүз башлый.— Һе-һе, бу ат быел тәгаен беренче булачак, улым.

— Күз тидермә, бабакай...

— Тиярлек күзләр миндә калмады инде, улым. Моңа тиңдәшерлек ат Куян Сәйфиендә генә булырга мөмкин. Якын-тирәдә башка чабыш күренми. Ә Куян Сәйфиендә эләккән эш юк, ел да бер ат яндыра ул. Малкайларны җаен белеп тәрбияләсәң генә, бар җегәренә узыша ала, ирендеңме — бетте.

...Әхнәф чыгып барышлый әнисенә тагын берничә сүз ташлап өлгерде:

— Бүген Гыйльметдин абыйны күрдем. Утыныңны кистеңме әле, дип сорый. Әллә кайчан бетердем инде, дидем. «Маладчина», ди.

Әхнәфнең ярты сүзе әйтелеп тә бетмәде бугай, ул өй турысына, тезгене койма башына элеп куелган аты янына атылды.

...Гыйльметдин исемен ишеткәч, Гөлҗиһанның йөрәге кысылып куйды. Әле беркөнне эштән кайтышлый кибеткә кереп чыгарга уйлаган иде дә, ник кергәненә үкенде соңыннан. Кибет ишегеннән атлап кергәч Гыйльметдин хатыны Сәкинә белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздылар. Тегенең кулында буаз тана кадәр букча. Кемдер Сәкинәдән:

— Кибеткә бер чыгуда ярты еллык запас аласыңмы әллә? — дип шаяртып сораган иде, Сәкинә шушы сорауны гына көткән кебек, Гөлҗиһанга туп-туры карап тезеп китте.

— Гыйльметдин абыеңны тәрбиядә генә тотарга кирәк бит, малайкаем. Авыл тулы ирсез хатыннар, шуларның эшен эшләп, күңелләрен күреп, бөтенләй әлсерәп бетмәсен, дим. Шуңа тырышу. Ир миргә яраса да, тәрбияләү бер миңа кала бит.

Менә хәзер дә, улы Әхнәф Гыйльметдиннең исемен телгә алгач та, бу яну, оялуларның чын сәбәбе хәтердә яңарды.

...Укулар төгәлләнеп килә иде. Ул көнне бер төркем баланы укуда ирешкән уңышлары өчен дип, Казанга өч көнлек экскурсиягә алып киткәннәр иде. Әхнәфкә яңа күлмәк, яңа чалбар, сандалилар сатып алды әнисе. Алтынчы классны тәмамлаган улы малайлыктан чыгып килә, артык сайланырга яратмаса да, эленке-салынкы йөрүне дә өнәми иде. Әтисе Әүхәткә охшап гәүдәле, киң җилкәле булмакчы иде малай. Инде эш тә белешеп куйган, Сабантуйга кадәр үк бозаулар күтәргә керәм дип, очынып йөри. Укуны яхшы тәмамлавы, төшемле эш юнәтүе дә малайны дәртләндереп, әнисе каршында абруен күтәреп җибәрде.

...Әхнәфне озаткач, Гөлҗиһан көн буе үзенә урын таба алмый йөдәде. Кич, эштән кайткач, өйгә керәсе килми, ишек алдында вак-төяк мәшәкать табып юанды. Янында улы булмагач, күңелсез иде аңа. «И, Ходаем, тулы ялгызлыктан сакла», — дип ялварды ул. Әтисенең инде шактый искергән өе тагын да шыксыз сыман тоелды, йөрәк сыкрый, ялгызлык баса...

Ел артыннан ел үтә тора. Әүхәткә булган үпкә-рәнҗешләр инде хәзер дөрләп кабынып китмиләр, вакыт дигән бөек табиб бәгырь яраларын дәвалый, күп нәрсәгә битараф карата. Әхнәфнең ятим үсүе генә кимсетә иде аны. Фәрвәҗетдиннең ташландык өенә кайтып кергән көннәре кара хәсрәткә уралган иде. Аның өчен гомер агышының кызыгы бетте, яшь йөрәге сызланулардан мәңге арына алмас кебек иде. Күнегелә икән. Баштагы мәлләрне барсы да томанда гына кебек иде, кайгы болытлары аны үзләренә әләктереп алып, каядыр, җир читенә илтеп ташлаганнардыр да, ул шунда соңгы айларын үткәрәдер кебек иде. Яшәүнең мәгънәсен тапмый җәфаланды яшь хатын. Тик Әхнәфе «әннә» дип муенына сарыла, нидер сорый, ялвара, кызык табып уйный-көлә, йә булмаса, һич тә юктан көйсезләнә башлый — менә шундый мизгелдә ул яңадан үзенең яшәвен тоя, күңелсезлек болытларын әллә ничекләр итеп туздырып, гади хатын-кыз халәтенә кайтасы килә башлый.

Әүхәтнең хыянәте аның рухын җимерде, ул ир-ат халкын күрә алмас дәрәҗәгә җитте. Баштагы елларны аларны бер генә сүз: «хәшәрәтләр» дип кенә атады, берсен дә якын җибәрмәде. Ә аңа кызыгучы, яхшылык белән өйләнеп тормыш итәргә ният итүчеләр дә, нәфесләренә булышучылар да аз булмады һәм гаҗәп тә түгел. Ул бит егерме яшен яңа тутырган хатын. Кызларга биргесез. Үзе чибәр, сәламәтлеге ташып тора. Йөзендәге сагыш, күз карашларындагы моңсулык та аңа килешә, аны тагын да сылурак итә, ир-ат халкын үзенә тартып, ымсындырып, башларын тәмам әйләндереп бетерә иде.

Ул чакларда бигрәк тә Куян Сәйфи каныкты аңа. Гөлҗиһанга караганда берничә яшькә өлкәнрәк, авыз кырыеннан су тибеп йөрүче (хатын-кыз күрсә, бигрәк) чандыр гына ир иде. МТСлар таралып, анда эшләүчеләр үз авылларына кайткач, аны ферма мөдире итеп куйдылар. Өйләнгән, тормыш тәҗрибәсе дә бар дип, аңа зур өметләр баглаганнар иде

ул вакытта. Куян Сәйфи беренче көннәреннән үк үз кул астындагы хатын-кыз затларын «өйрәнә» башлады. Үзенең эшеннән башкага тыкшынып йөрмәүче, эч серләрен дә дөньяга чыгарып җилпергә ашыкмаучы, зарлану, булыр-булмас үтенечләр белән бимазаламаучы яшь хатынның үз кул астында эшләвенә Сәйфи һич тә битараф түгел иде. Җай чыккан саен ул аңа булышлык күрсәтергә тырыша, башкалар күрмәгәндә кулына сәнәк, көрәк тотып та эшләүдән тартынмый иде. Беркөнне исә тәвәккәлләргә булды... Шулай ярдәм иткән булып... Сылу хатын, билгеле, Сәйфинең ярдәменнән ашыгып баш тартты, озын керфекләрен тибрәндереп мөдиргә карап алды, ишетелер-ишетелмәс кенә рәхмәт әйтте һәм аның кулындагы сәнәккә үрелде.

— Рәхмәт, Сәйфетдин абый, үзем дә җитешәм ич...

Хатынның ныклап каршы килмәвенә Сәйфинең кәефе күтәрелде, күңеле иләсләнеп, сылукай тирәсендә сырпалануын дәвам итте, ягымлы сүзләр әйтеп, аның күңеленә үк үтеп керергә көчәнә иде.

— Һи, Гөлкәй, синдәй җиләк кебек хатынны дуңгыз бугы арасында йөртәмме соң! — Үзенең күзләре ялт-йолт уйнап алды, комсызланып хатынның түшләреннән капшап узды. Тиз генә янә бер мәртәбә торак эченә караш ташлап, сүзен дәвам итте.— Рәхмәтне соңыннан әйтерсең, ак эш чамалап йөрим әле үзеңә.— Сәйфинең бүлтәйгән иреннәре чапылдап алды.— Үгезләр карарга куям мин сине, нәсел үгезләрен... Чатан Хәбибәне бүген үк чыгарам...

— Тузга язмаганны сөйләмә, Сәйфетдин абый. Кеше эшенә кызыкмыйм. Җитмәсә, гарип апаны эшеннән алам, дисең. Рәнҗеше төшсә...

— Һи, сантый! — Яшь хатынның тиз генә бирешмәвенә артык исе китмәгән Сәйфи, Гөлҗиһанның янына ук килде, кулын ялт кына яшь хатынның биленә салып, үзенә тарта төште. Күзләре майланган, борын тишекләре киерелгән, соңгы ыргымга хәзерләнгән киек җанвар сыман иде ул бу минутларда. Моны ук көтмәгән Гөлҗиһан читкә тайпылды, күзләреннән дәһшәтле очкыннар чәчрәде. «Тәвәккәллек — ярты уңыш»,— дип, һич чигенергә исәбе күренмәгән Сәйфи бер мәлгә югалып калды.

— Кара аны, Сәйфетдин абый, әгәр адәм рисвае буласың килмәсә, миңа кулыңны сузма!

— Бәй,— диде Сәйфи — хәйләкәр төлке, гөнаһсыз тавыш белән.— Гөлкәй, нигә ул кадәр тавышка җибәрәсең? Мин бит сиңа яхшылык белән, ә син...

— Башыңны җүләргә салма, нәрсә теләгәнеңне яхшы беләм...

Сәйфетдиннең түземе төкәнде.

— Кыланма инде, Гөлкәй. Фәрештә түгелсең — ир астында кыш чыктың. Әүхәт тә юкка аермагандыр, кешегә рәхәт күрсәтмәсәң, үзең дә рәхәт күрмисең аны, матуркаем...— Ул янә хатынны юмаларга кереште.— Уйлап кара, Гөлкәй, мин бит Хәбибә урынына теләсә кайсы хатынны җибәрә алам. Әйткәне берсе йөгереп барачак. Сине үз итеп кенә... Нәрсә, яшь, чибәр хатынны ярату языкмыни! — Әмма Гөлҗиһанның каршылыгын болай гына сындыра алмаячагын сизеп, дорфа сөйләшүгә күчте.— Әле синең, Гөлкәй, ирләрдән качу түгел... шыбыр тиргә батып...— ул калган сүзләргә аеруча басым ясап, аты-юлы белән әйтте,— нәкъ таманга туры килә. Үз кадереңне үзең белмисең. Юк икән, юк... Дөнья шаулатып кычкырма, минем дә ул көнгә калганым юк! Әйдә, йөр инде... ата дуңгыз йомыркасына карап...

Сәйфи ачуына чыдаша алмый, Гөлҗиһанны яңа кайтарып аударган салам өеменә табан төртеп җибәрде. Аның уенча, бу базык гәүдәле хатын Сәйфинең җилкәсе тиюгә, өемгә мәтәлеп кенә китәргә тиеш иде. Әмма, көтелмәгән хәл килеп чыкты: шактый җитез гәүдәле Сәйфи сизми дә калды: Гөлҗиһан, икенче якка очасы урынга, мөдирнең саллы гына кагылып китүенә селкенмәде дә, ул гына түгел, үзе Сәйфинең халат кигән

инсәсеннән эәктереп алды һәм күз ачып йомган арада, мөдирне болгап торып салам өеменә атып бәрде. Сәйфи бурлаттай кызарды, күзләре гаҗәпләнүдән шардай ачылдылар. «Инде монсы гафу ителмәячәк!» — дигәндәй гайрәтләнеп сикереп торган Сәйфинең йөзенә оннан бушаган капчык алагаемга килеп сыланды. Ак буран күтәрелде. Тын юлына он тузаны капланган Сәйфи тончыга-йөткерә үзе яңа калкынган салам ояга кире кереп чумды... Сүгенә-яный торып басканда Гөлҗиһан торакның икенче башына китеп барган иде.

Шул көннән башлап Куян Сәйфи Гөлҗиһанга үч саклап йөри башлады.

* * *

Сер түгел, әле утызның өске ягына яңа чыккан хатын күпләрнең күзен кыздыра иде. Кат-кат кияүгә сорап тилмерүче егетләр дә булмады түгел, бу эшкә җиң сызганып Шәмси түти үзе алынып караган чаклар да булды, әмма Гөлҗиһанның, бердән, ир-ат халкына ышанычы бөтенләй диярлек беткән, яңадан мәхәббәт утларында яна алырмын дип башына да китерә алмый иде. Күңелләр каткан, кырысланган. Икенчедән, хәзер Әхнәфе әтисез үссә дә, сыенырга әнисе бар. Кыстауларга, вәгъдәләргә вәсвәсәләнеп кияүгә чыкса, бөтенләй ятим калачак бит ул. Ир-ат халкы авызы белән кошлар очыра ул, Әхнәфне дә сыйдырып алмакчылар, ә тора башлагач, нәрсә булыр, ансын бер Алла белә... Шуңа күрә кыстауларны сабыр гына кире кага торды, тик күңеле нидер өмет иткән кебек, йөрәгендә кем өчендер иң татлы хисләре саклана сыман...

Менә шулай үз гамьнәренә төренеп, чапкан печәне ике-өч мәртәбә яңгыр астына калып чыланганга кайгырып йөргән чакларда аны Гыйльметдин коткара иде. Печәнен дә алып кайта, утын ягын да кайгыртыша. Ул тәгәрмәчле тракторда эшли. Халык телендә «Белорусь» дип кенә аталган «җен арбасын» иярли. Гөлҗиһанның тилмереп техника эзләп йөрүен белгәндәй, каршысына ук килеп туктый хатынның. Кабинадан башын сузып, елмаеп эндәшә:

— Гөлкәй, утыныңны алып кайттыңмы әле?

— Тыңлаучы табылмады шул.

— Нигә үземә әйтмәдең, интегеп йөрисең шунда...

— Сәкинә тузыныр бит... Узганында да колхоз идарәсенә барып әйткән, диделәр.

— Ярый, ансын үзем җайлармын. Сәкинәнең утын, печән дип кайгырасы юк, мине саклап гомере үтә. Бар кайгысы шул гына.— Гыйльметдин шаяртуга күчә: — Үзем тыңлыйммы соң, Гөлкәй?

— Белмим инде, Гыйльметдин, белмим...

— Утыныңның кайда икәнен беләм. «Акбашың» әзер булсын, йөкчеләр дә табармын, кайтарып аударырбыз ишек алдыңа,— ди ул җитди тонга күчеп. Ул арада трактор гөрелдәп кузгалып та китә, Гөлҗиһан ни шатланырга, ни көенергә белми урам уртасында басып кала. «Сәкинә тагын дөнья җимерә инде. Миңа утынга барган өчен генә түгел, Гыйльметдин кемгә йөк алып кайтса да, хатыны кара тавыш чыгара». Үзе аркасында Гыйльметдиннең ызгыш-талашка дучар булуын теләми иде ул.

...Әхнәфләр Казанга киткән көнне исә, инде җиргә кичке караңгылык иңгәч, Гыйльметдиннең ишек шакуын Гөлҗиһан нәрсә дип бәяләргә дә белмәде. Бу араларда Гыйльметдингә йомышы төшкән иде төшүен, сүз тишәргә җай таба алмый йөри иде. Авыл советы делянкасын чистартып кайтканнар иде Әхнәф белән икәүләп. Сөенә-сөенә эшләделәр: гел болай туры килми ул! Утыны да мул чыкты. Алып кайту турында уйласаң гына, башка хәсрәт төшә.

Менә шундый шыксыз, дөнья мәшәкатьләре, җан тынычлыгын югалтырлык ялгызлык баскан караңгы кич иде бу. Ишек шакучының Гыйльметдин икәнен белеп алган хатынны сәер халәт биләп алды. Дөресен генә әйткәндә, күп еллар элек, урманда икәүдән-икәү очрашып, ингә-иң торып диярлек утын төягән көннән соң, аларның, менә шулай, бер-берсенең сулыш алуларына кадәр тоеп торырлык якынлыкта калганнары юк иде дә, ахры. Ара-тирә, кичке урамнарда гармун тавышы ишетелгәндә генә, Гөлҗиһанның үзәкләре өзелеп китә, ирексездән түр як тәрәзә янына килеп баса, пәрдәсен күтәрә төшеп, тәрәзәгә сыена, тын калып, зәгыйфь кенә ишетелгән гармун моңын тыңлый. Эссе чүлдә озын юл үтеп әлсерәгән мосафир чылтырап аккан чишмәгә тап булганнан соң, бар дөньясын онытып, көмештәй салкын суга ташланган сыман, Гөлҗиһан да йотылып, ләззәтләнеп тыңлый ул моңны. Әмма хәзерге яшьләрне белмәссең, гармун тавышлары торган саен сирәгрәк ишетелә, кич житсә, авыл урамнары төпсез тынлыкка чума. Бар да үтә икән, яшьлек тә, урамнарда алар җырлап йөргән җырлар да җуела, хисләр-кичерешләр дә суына, еллар аша хыяллар да көлке кебек күренә. Әнә шул пыяласына яшь типкән тәрәз аша саркып кергән сүнеп баручы гармун моңы гына күңелдә Гыйльметдинне терелтә, йөрәк тимер читлеген ватып чыгарга талпынган кош шикелле бәргәләнә, җанны талкып хатирәләр өермәсе кузгала. Юк, ул аның өчен җитдиләнгән, күзләренә сагыш бөркеп торган ир уртасы түгел. Һаман да яшь-яшь, иреннәренә оялчан елмаю кунаклаган Гыйльметдин генә яши иде Гөлҗиһанның йөрәк түрендә.

Ишек шакыганда Гөлҗиһан инде көндәлек мәшәкатьләреннән бушаган, бераз булса да эч пошуларыннан арынырга теләп, кәгазь, каләм алып, абыйсы Шәйхаттарга хат язарга утырган иде.

Шәйхаттар Тын океанда хезмәтен тутырганнан соң, кире авылга кайтып тормады. Туганлык җепләрен өзмәскә теләп, икс арада хатлар гына йөри. Ә үзенең ничә еллар инде туган нигезен күреп китә алганы юк. Абыйсы бишьеллык флот хезмәтендә чакта ышаныч бар иде әле — менә ул кайтыр да өйне, ихата-кара лтыларны яңартыр, өйләнеп җибәрер, авырлыклар килсә, таяныч булыр, Әхнәфе дә яраткан дәү абыйсы тирәсендә уралыр, ятимлеген сизмичәк көн үткәрер диген яшерен хыялы әкренләп сүнде, күрешүләр көтеп кенә яшәргә калды. Шәйхаттар корабтан чыгып ярга басуга, туп-туры Урта Азиягә китеп барды. Бергә хезмәт иткән иптәше Тау институтына керергә әзерләнгән, Шәйхаттар да аңа ияреп шунда киткән, эшләгән, укырга кергән. Инде институтны тәмамлаганына да байтак еллар. Әле студент чагында ук маржага өйләнеп, малай белән кыз үстереп яталар.

Шәйхаттар — геолог, айлар буе Памир тауларында эзләнүләр белән мәшгуль булып йөри. Гөлҗиһанга абыйсының нәрсә эзләве дә, ничек яшәве, тормыш итүе дә караңгы, тик маржа җиңгинең бер дә бу якларга кайтасы, иренең туган тияген, аның ялгыз гомер сөрүче сеңлесен күрергә атлыгып тормавын гына чамалады ул абыйсы хатларыннан.

Абыйсын бик сагына ул, әлбәттә, әмма ни хәл итәсең, башны ташка орып булмый, исән-сау булсыннар, кайтырлар. Кайтмыйча түзә алмас абыйсы... Кендек киселгән җир бит ул — Туган җир! Ел саен абыйсы: «Мәшәкать чыкты, тагын кайта алмадык инде»,— дип яза. Шәһәр кешесенең кул-аякларын бәйләп торырлык нинди мәшәкатьләре бардыр, дип уйлый Гөлҗиһан. Җитмәсә, Урта Азиядә кышын да кояш кыздырып тора икән, утын дип кайгырасы, печән дип ут йотасы юк... Хатында шуларның барсын да тезмәкче иде дә хат ике-өч юл язылган килеш өстәлдә калды — сак кына ишек шакуга сискәнеп, өй алдына чыкты, шөбһәле уйлар эчендә каударланып ишек келәсенә үрелгән хәлдә хәрәкәтсез калды.

Пышылдап диярлек:

— Гөлкәй, бу мин, Гыйльметдин,— дигән тавыш ишетте ул.

Хатын башында бөтерелгән уйларын тәртипкә китерү өчен вакыт отарга теләгәндәй, суза төшеп, кабат сорады:

— Кем бар анда, инде төн уртасы бит?..

— Мин бу,— дулкынланудан тыны кысыла иде булса кирәк, ике сүзне дә берьюлы әвәләде Гыйльметдин.

Гөлҗиһан тәмам аптыраган иде. Нәрсә дип ишек ачты соң әле бу төн кошына?! Хәтта, үзен аклый да алмый иде. Әгәр үз-үзен тынычландырырга теләсә, болай дип фараз кылырга мөмкин булыр иде: ишек шакучының кем икәнен башына да китермәде, әллә юлда ватылып-мазар Әхнәфләрне кире алып кайттылармы дип уйлады... имеш... Юк, әлеге эчкерсез хәйлә дә бу адымны аклый алачак түгел. Ул бит Әхнәфнең аяк тавышын ике-өч өй аша тоеп ала, аның һәр хәрәкәтен, һәр гамәлен әллә каян таный. Әхнәф булса-а!.. Ишекне сак кына кагып маташмый инде ул, сабырсызланып, кат-кат дөбердәтер иде. Аның болай беркатланып төн уртасында чит кешегә ишек ачуын акларлык бер сәбәп тә юк иде. Гыйльметдин булса да...

Гөлҗиһанга кыен да булып китте. Инде кунакны өйгә уздыргансың икән, болай эндәшмичә торып та булмый бит инде. Ләкин нәрсә дип сүз башларга?.. Гыйльметдин үзе дә сүз башлый алмый интегә, бөтенләй ят дөньяга килеп эләккән кеше кебек аптыраулы кыяфәттә, зиһенен җыя алмыйча тик тора иде. Хатын янынннан үтеп киткәндә үзендә гаҗәеп бер үзгәреш сизгәндәй булды. Иң беренчесе,— күптән көтелгән җан рәхәтлеге иңгәндәй булды. Сәер, бик сәер иде бу хәл. Икенчедән, күңел түренең иң ерак почмагында моңарчы йокымсырап яткан, инде онытылып та барган газаплы вә татлы хисләр уянды, чигәдәге кан тамырлары шаулап тибә, сулыш кайнарлыгы иреннәрне өтеп ала. Шушы мәлдә күңелне биләп алган сәер халәт томандай эреп юкка чыкты, ул куркулы хисләр чолганышында калды. Инде аңлый да иде: ул үзе гомере буе тыеп килгән һәм моны хатын-кызлар гына аңлый ала торган назга сусау дигән коточкыч хис өермәсе эләктереп алырга маташа иде. Болай озаклап басып торып та булмый, Гөлҗиһан дулкынлануын тыярга тырышып телгә килде:

— Шәйхаттар абыйга хат язып утыра идем әле...— диде ул Гыйльметдингә күтәрелеп карарга кыймый.— Утырып тор, димме?..

Гыйльметдин күрсәтелгән урындыкка утырды, Гөлҗиһанның сүз башлавына куанып, аңа кушылды.

— Да-а... Яшьтине күрмәгәнгә бишбылтыр... Инде зур кеше булгандыр ул. Укыган кеше-ни...

— Укыдым дип инде... Сагындым, бер кайтып та китмиләр, ичмасам...

Гыйльметдин үзе дә аңлап бетермәстән, сүзне икенчегә борды.

— Әхнәфләр Казанга киттеләрме?.. Мәктәп янында машинага төялгәннәрен карап тордым. Әхнәфне әйтәм, миңа кул болгап китте, шайтан малай,— диде ул кеткелдәп.

Төнге кунакта исереклек галәмәте күрмәсә дә, аның шыр аек булуына да шикләнә иде хатын. «Аракы-мазар өмет итеп кергән дисәң... Өткәсе әйтмешли, бераз «көртлек мае» капмаса, ир-ат болай йөрмәс иде»,— дип тә уйлап алды ул.

Гыйльметдин, бик мөһим нәрсә әйтергә җыенган сыман, берара тын калып торды да тирән итеп сулыш алганнан соң, сүзен дәвам итте:

— Син гаеп итмә инде, яме, Гөлкәй. Ерак басуга карабодай чәчәргә җибәргәннәр иде дә... Чәчүлек орлык китермәделәр. Караңгы төшкәнче көттем дә, тракторны чәчкече-ние белән басу башында калдырып киттем. Каравылчы бар анда,— диде ул аклангандай.— Ашлама чәчәргә килгән сәмәлүт тә шунда төшә бит... Турыгыздан үткәндә карыйм — утың яна... Менә керәсе иттем... Хатынның сабыр гына тыңлап торуын күреп, Гыйльметдин җанланып китте.— Әле утын кайтарта алмадыңмы соң, Гөлкәй?..

— Юк шул... — диде хатын сүзнең үзәгенә үткән нәрсәгә килеп терәлүенә күнелсезләнә төшеп.— Сине күреп сөйләшим микән дип тә исәпләгән идем... — Ул кабалана-кабалана төшеп самавырга килеп тотынды.— Самавыр яңартсам инде... Кинәт исенә килгән бу ниятеннән шундук кире кайтты — мондый вакытта ир-ат белән икәүдән-икәү генә чәй эчеп утыруны һич тә башына сыйдыра алмады ул. Шул ук вакытта Гыйльметдинне куып чыгара да алмый ич инде...

Бу фикер аңа тынгы бирми, әлбәттә. Әмма алай эшләргә уңайсызлана шул. Авылда бердәнбер таянычы булган кешене югалтудан курка иде ул. Күңеленә туган әлеге шөбһә белән бергә, йөрәкне яндырып торган яшерен сихри хис тә бар бит әле, аның да тынып калганы юк, Гыйльметдинне өйгә керткән чакта кабынган тойгылар һаман да сүрелмиләр, җанны ымсындырып, кытыклап тик торалар.

Гыйльметдин урыныннан күтәрелә төште.

— Чәй дип мәшәкатьләнмә, Гөлкәй... Аракы салып бирсәң инде ...— диде ул хатынның болай эшләвенә ышанып бетмичәрәк.— Әллә нигә күңел ярсып тора. Бүген көне буе шулай... Белмим, нәрсәгә җилкенә торганмындыр... — Авыр сулап куйды.— Өйгә кайтасы да килми. Туйдырды... хатынның колак итен чәйнәве... Ул да миннән ялка торгандыр инде. Ичмасам, балабыз да булмады... Синең Әхнәфең кебек ут борчасыдай бер малай үстерүләре насыйп булса икән... Гел икәү, егет белән кыз сыман кара-каршы утыруы да бавырга тия, Гөлкәй. Башына төшкән кеше үзе белә...

— Нишлисең инде, Гыйльметдин, берәүнең дә ихатасы буш тормый. Һәркемнең үз борчуы, үз хәсрәте. Адәм баласына шулай гомер кичерергә язгандыр инде... Икегез дә сау-сәламәт, тормышыгыз җитеш, шөкер итеп кенә яшәгез.

— Әй-й... — дип көрсенде Гыйльметдин һәм өстәл янына күченеп утырды. Кабалана төшеп Гөлҗиһан каяндыр чыгарып утырткан аракы шешәсен кулына алды.

— Утын кайтартырга дип кенә тота идем дә...

— Утыныңны алып кайтырмын, Гөлкәй, кеше эзләп йөрмә,— диде Гыйльметдин ярты стакан чамасы аракы эчеп куйгач. Сөт өсте ягып ипи капты, үз эченә бикләнгән кыяфәттә ашыкмый гына чәйнәргә кереште.

Дөнья мәшәкатьләренә кагылышлы тагын берничә кәлимә сүз алыштылар. Гөлҗиһан шактый озакка сузыла башлаган эчке киеренкелекнең тизрәк тәмамлануын, җанга якын бу ир кешенең чыгып китүен теләгән кебек тә, шул ук вакытта, бөтен жаны-тәне белән, әлеге кара мыеклы, киң күкрәкле ирнең үзе янында озаграк тоткарлануын да тели шикелле иде... Гыйльметдингә дә җиңел түгел, керүен керде дә бит. Гомере буе яшертен сөю утларында газапланган ир очрашуның сәгадәтле минутларын ничек озайтырга белми җәфалана иде.

— Гөлкәй, тәмәке тартып керим әле, ә?..

— И Гыйльметдин, тышка чыгып йөрмә инде, кеше күрсә... Өйалдында гына тарт тәмәкеңне...

Югыйсә, Гөлҗиһанның уенда бөтенләй башка сүзләр иде бит. «Әле тагын килеп керергә чамалыйсыңмы? — диярга тиеш иде ләбаса, ул.— Төн уртасында синең белән сайрашып утыра алмыйм инде, бигайбә. Кайтып китү ягын кара», — димәкче идең түгелме соң син, Гөлҗиһан?! Ләкин баш миеннән сызылып киткән әлеге сүзләр тышка бәреп чыкмадылар шул. Әйтерсең, күзгә күренмәс ниндидер көч аны тыеп тора, ирне чыгарып җибәрмәс өчен барлык чараларны да күрергә куша иде. Ишектән яртылаш сынып чыгып барган Гыйльметдингә карады да таракташ кебек катып калды. «И Ходаем, — дип ялварды ул,— бөтенләй чыгып кына китсә ярар иде. Ул да акылына килсен, мине дә җүләр адымнан сакла, адәм рисвае булып бетмәсәк ярар иде, Раббем...» Ул шундый икеләнүле уйлар астында өстәлне җыештыра башлады...

...Хатынның ялваруы чын күңелдән иде. Әмма кабул булмады... Өй ишеге тавыш-тынсыз гына янә ачылды. Гыйльметдин артыннан әчкелтем тәмәке төтене бәреп керде. Күңелең тарткан кешенең тәмәке төтене дә татлы икән. Гөлҗиһан яшь чакларына, Гыйльметдин белән икәүләп йөргән тансык кичләргә кайткандай булды. Ул чакта да егетнең тәмәке пыскытуы кызны иләсләндереп җибәрә иде. Башка ирләрдән тәмәке исе бөркелсә, күңел болгана, ни хикмәт, Гыйльметдиннең тәмәке тартуы күңелне алгысыта...

Гыйльметдин дулкынланудан тәмам югалып калган Гөлҗиһанга күтәрелеп карарга кыенсынып, иреннәрен чак кына кыймылдатып әйтеп куйды:

— Гөлкәй, өйалды ишеген элеп кердем мин... — Ул бар кыюлыгын җыеп хатынга күтәрелеп карады һәм йөзе алсуланып янган Гөлҗиһанның иңсәсеннән сак кына кочып үзенә табан тартты. Шашынган йөрәк тибешенә кушылып Гыйльметдиннең җаныннан ярылып чыккан сүзләре ишетелде: «Яратам, Гөлкәй, теләсә нишләт, яратам!» — дип пышылдады ул тилергән кыяфәттә һәм хатынны бар куәтенә үзенең гайрәтле күкрәгенә кысты. Гөлҗиһан үзен, бер мизгелгә, давыл котырынган дарьяда көймә эчендә калгандай хис итте. Бар дөнья әйләнә, барсы бетте, барсы җимерелә, барсының асты-өскә килә... Ирнең муенына сарылган кулларын ычкындырмакчы була, әмма ул моны теләгән саен ирнең кочагына сеңә генә бара иде.

— Гыйльметдин... җүләрләнмә... Тилермә, зинһар... — дип аһылдады ул, соңгы мәртәбә үзен кулга алырга омтылып. Әмма сулкылдап чыккан тавышы кайнар иреннәре арасында эреп юкка чыктылар. — Ут та сүнмәгән бит... Гыйльметдин...

Ир үрелеп утны сүндереп куйды...

...Әхнәфнең көтмәгәндә Гыйльметдин исемен телгә алуы, бәгырьне өтеп үтте. Утырып килгән күңеле янә талпынып куйды. Хәзер инде ул Җир йөзендә үзеннән дә гөнаһлы кеше юктыр дип исәпли. Бу гөнаһны юарга да мөмкин түгелдер... Авылдашларының күзенә дә карарга ояла ул бу көннәрдә, аларның барсы да теге гөнаһлы төнне беләләрдер, хәтта ир белән хатынның шашып-шашып бер-берсен яратышуларын да карап торганнардыр кебек. «Их, Гыйльметдин, никләр кердең, — дип үкенә ул ялгыз калган чакларда. — Кеше күзләренә ничек күреним дә, бернәрсә дә булмагандай ничек йөрим ди инде мин, ә?.. — ди ул кайнар яшьләрен алъяпкычы белән сөртеп. Сизсәләр, нинди гарьлек бит! Әнә Зуравылда бер ир ялгыз хатынның куенына кергәч, үзенең хатыны моны белеп алып, күрше хатыннары белән җыелып килгәннәр дә теге тол хатынны нәрсәләр кыландырып кына бетермәгәннәр, ди. Тәрәзәләрен кырулары бер хәл, үзен анадан-тума чишендереп, йомшак җирләрен кычыткан белән чапканнар, ди. Кызып җитүләре шул кадәр булган — бичара хатынның мичен ә хәтле сүтеп ташлаганнар икән... Шундый хәбәрләр ишетсә, Гөлҗиһанның күз аллары караңгылана, ул үз-үзен битәрләп бетерә алмый. Бу адымын ул мәңге гафу итмәячәк, юк, итмәячәк?!. Качып-посып сөешүдән дә татлы, ләззәтле хәл юктыр дигән булалар, аның ахыры газаплардан гына тора шул. Намусыңнан качып та, посып та калып булмый икән...

*Ахыры киләсе санда.*

# ПУБЛИЦИСТИКА



**Мәхмүт Әхмәтҗан**

## МӘГЪРИФӘТ НУРЫ ЧӘЧӘР...

Шәхес формалашуында тәрбиянең, белемнең хәлиткеч урын тотуы бәхәссез. Халык моны гади генә итеп: «Беләге юан — берне егар, белеме бар унны егар»,— дигән. Борынгы цивилизация туган җирләрдә — Ассирия, Вавилония, Фәләстин, Мисыр, Греция, Рим, Гарәбстан, Кытай, Һиндстанда фән, халык мәгарифе бик нык алга киткән булган. Әле бүген дә Мисырдагы пирамидалар, сфинксларга карап, бөтен дөнья хәйран кала, ничек шундый хикмәтләрне төзи алдылар икән, дип шакката. Җавап бер генә: ул илләрдә белемгә зур игътибар бирелгән. Ә бу исә турыдан-туры мәгарифкә бәйләнгән. Мәсәлән, борынгы Һиндстанда моннан меңнәрчә еллар элек үк инде һәрбер авылда мәктәпләр булган. Бай катлам балалары шәһәр мәктәпләрендә, храмнарда белем алганнар. Бүген бик белемле, акыллы булып кылансак та, ул чакта ук Кече Азия, Африка (Мисыр) мәктәпләрендә астрономия, геометрия, арифметика, философия, этика (әхлак) кебек фәннәр укытылган. Бүгенге медицина, дөресен генә әйткәндә, Көнчыгыш, Тибет медицинасының кискән тырнагына да тормый...

Инде Грециягә килгәндә, борынгы Элладаның укыту-тәрбия системасыннан бүген файдалансак та күпкә отачакбыз. Анда кеше үтерү, акча сорап ата-ананы буу кебек нәрсәләр бөтенләй булмаган! Спарта (Греция) дәүләте мәктәпләрендә физик тәрбиягә, музыкага, җырга, биюләргә аеруча зур урын бирелгән. Кызлар да тиешле күләмдә тәрбия алганнар.

Совет укыту-тәрбия системасы яшьләрне һәрьяклап алга киткән, гармоник үсешкә ирешкән шәхесләр итеп формалаштыру турында хыялланды. Әмма бу прогрессив омтылыш күбрәк коры сүзгә, файдасыз акыл сатуга, күз буяуга, процентоманиягә кайтып калды. Сүз уңаенда: һәрьяклап алга киткән шәхес тәрбияләү өлкәсендә борынгы Афина дәүләтендә зур уңышларга ирешкәннәр. Афиняннар, моннан ике-өч мең ел элек, кеше физик яктан да, әхлак ягыннан да матур, камил булырга тиеш, дигәннәр һәм шуңа ирешкәннәр дә. Кызганыч, бүген балаларның 80-85 проценты авыру булып туа (исеректән авыру тумый кем тусын). Акыл ягыннан зәгыйфьләр дә күбәя бара. Зур авылларда дибеллар мәктәбе ачарга була. Армиягә алырлык яшьләрне табу кыенлашканнан-кыенлаша, күбесе авыру, физик яктан чыныктырылмаган. Әхлак ягына килгәндә, халык деградация юлына ныклап басты. Кызганыч, кем килеп йолкыр безне?!

Афинада бала 7 яшькә кадәр гаиләдә тәрбияләнгән. Аннан соң 7 ел буена грамматика һәм кифаристлар мәктәбендә белем-тәрбия алган; укырга, язарга, исәп-хисап эшләренә өйрәнгән. Эстетик тәрбиягә зур әһәмият бирелгән. Бу бик дөрес юл, чөнки кеше шәхесен техник фәннәр түгел, гуманитар фәннәр, эстетик карашлар формалаштыра. Үкенечле ки, совет мәктәбе моны бервакытта да санга

сукмады. Эш менә нәрсәдә: һәр мәктәптә техник вузларга керерлек яхшыәзерлекле, алар белән кызыксынучы укучылар була. Шуңа күрә әдәбият-сәнгать, мәдәният, музыкага вакытны кызганмаска иде. Ә безнең уку планнарында киресенчә булды: күпчелек вакыт физика, математика, химия кебек фәннәргә генә бирелде. Шуңа барып җиттек ки, техник югары уку йортларында, училищеларда укытучылар булып психология, педагогика фәннәреннән бөтенләй хәбәрдар булмаган педагоглар эшли. Шундый хәлне сөйләгәннәр иде: Казандагы бер техник вузда (элекке КАИ) имтиханнар барганда, профессор карчыкның ачуы чыккан да, бер кызның зачеткасын тәрәзә аша ыргыткан. Менә сезгә педагог! Мәсьәлә анда гына да түгел, инженермы ул, техникмы, тәзүчеме, белгечкә кешеләр белән эшләргә, аралашырга туры киләчәк. Димәк, психология, педагогика кебек фәннәрне биш бармагың кебек белергә кирәк. Үзебез надан икәнбез, башкаларның тәҗрибәсенә күз салырга була ич. Мәсәлән, чит илләрдә капиталист үзенең предприятиесендә педагог һәм психолог профессорлар тота. Бу тикмәгә генә түгел, капиталист юкка гына акча түкмәс... Ә безгә нәрсә? Бүрек чөеп, кешедән көлү — безнең каныбызда. Җир шарының алтыдан бер өлешен биләгән урыс империясендә яшәүче без мәхлуклар, «капиталистик илләрдәге ач-ялангач, бәхетсез балаларны» кызганып яшь түктек, МОПРга акчалар җыйдык, дөньяда иң бәхетле ил — Советлар иле генә, дип җырлар җырладык: әтисен, бабасын харап иткән Павлик Морозов һәйкәленә чәчәкләр салдык. «Бөтен дөньядан технология сатып ала, кирәкмәсә дә, бөтен халкына урта белем бирә, югары белемлеләре эшсез йөри»,— дип, Япония хакында әллә никадәр гайбәтләр саттык. Ә шул ил — бөтенләй җир асты байлыклары булмаган, картадан карасаң, бармак башы зурлыгы гына булган җөмһүрият — тиз вакыт эчендә (ә бит ул икенче бөтендөнья сугышында җиңелеп, исәпсез-хисапсыз күләмдә контрибуцияләр түләде) дөньядагы иң бай, иң алга киткән илләрнең берсенә әверелде. Ни өчен? Чөнки Япония халкы төпле белем, тәрбия алды, бик тырышып эшли. Ә безгә килгәндә, бездә плебей-батрак психологиясе: күршеләрдән көнләшеп йокыбыз кача, кайгыдан эчәбез дә эчәбез, эшләү урынында урлашабыз. (Дөньяда бездәге кебек караклык бар микән?) Бездән торсамы, ул япошкаларны, ул «буржуй калдыкларын» сәгать тә яшәтмәс идек. Күршеләрнең матур яшәвен күрү авыр безгә...

Кибернетика фәнен җенебез сөймәде, янәсе ул магиягә бәйләнгән. Чынлыкта без үзебез магиягә — хөрәсән ялкаулык авыруына дучар булдык. Дөрес, сугыш кораллары ясауда махы бирмәдек. Зельдович, Харитон, Сахаров кебек яһүд кешеләре бу өлкәдә безгә зур уңышлар китерде. Шулай да бөтен байлык, чит ил экономистларының фикеренә караганда, һәр сумның 90 тиене хәрбиләрне тоту өчен китте. Заводлар, шахталар, төрле корылышлар кырык-иллешәр ел буе ремонт күрмәде. Ә үзебез 80 нче елларда коммунизм төзүне тәмамларга, бушлай ашарга, киенергә, яшәргә хыялландык. Американы ике-өч елда куып җитәбез, дип шапырынып, ике елда мал-туарны суеп бетердек. Тундра җирләренә кукуруз чәчеп, илнең гөлбакча булуын көттек. Кемдер, Россиядә революцияне очраклы хәл, дип уйлыйдыр. Классик схема буенча, революция алга киткән илләрдә җиңәргә тиеш иде. Ләкин бездә җиңде, чөнки безнең буын коммунизмда яшәргә, хаҗәтенчә байлыкка ия булырга теләде. Һичбер төрле экономик исәпләүләр алып бармау күрше-тирәне санга сукмау, кыскасы, күптәнге хыялыбыз — эшләмичә бай булу теләге харап итте безне... Акылга сыймас нәрсәләр: революциядән соң, вандаллар сыман, алпавыт утарларын яндыру, бай йортлардагы зиннәтле әйберләрне, антикварларны вату-җимерү китте. «Мы были никем, мы стали всем». Ярый шулай да ди. Ә нигә ил байлыгын юк итәргә? Үч итеп, үч итеп байларга! «Яңа, бәхетле ил» безне дә бай итәргә тырышты: академик Лысенко «күптармаклы бодай» (ветвистая пшеница) үстереп, илне бодай белән күммәкче иде. Памир тауларыннан китерелгән кечкенә буйлы үгезләр белән Холмогор сыерларын кушып, куе сөт белән илне коендырмакчы булдык. Шундый хыялый ниятләр күп булды «бәхет илендә».

Совет педагогика фәне ниндидер мифик «коммунистик җәмгыять төзүгә» яраклаштырылган методик алымнар тәкъдим итте. Дөресрәге, галимнәрне шулай уйларга һәм сөйләргә мәҗбүр иттеләр. «Совет педагогикасы»ның (әйтерсең лә педагогика формацияләргә карап билгеләнә инде...) методологик нигезе — марксизм-ленинизм тәгълиматы: шулай булгач, бөтен нәрсә, шул исәптән, педагогия теориясе, методика да коммунизмга хезмәт итәргә тиеш,— дип аңлаттылар. Әлбәттә, коммунизм теориясе халыкара характерда булгач, халык традицияләре, гореф-гадәтләр дигән «вак-төякләр»гә урын калмады. Диссертацияләр бары тик «комсомол, пионер, партия, Ленин, коммунистлар һ. б... традицияләрендә тәрби-

яләү» дигән темаларга гына багышланалар, җәмгыятебездә халыклар да, милләтләр дә юк иде. Балаларны «шпиономания» белән агулау китте. Бүгенге мәктәпләргә, тәрбиячеләргә әнә шундый авыр мирас калды. Үткәннәрнең һәммәсе дә начар иде, дигән нигилистик юлга басу шулай ук дөрес булмас иде. Ләкин «сыйнфый көрәш», «социаль заказ» дигән шаблоннар үзенең эшен эшләде.

Халык традицияләренә, революциягә кадәр булган мәктәпләрнең уңай тәҗрибәсенә таяну дөрес булыр иде. Ләкин шуны да онытмыйк: революциягә кадәр татарның дөньяви мәктәпләре, гимназия, лицей кебек уку йортлары аз санлы булган. Чөнки аларны ачарга рөхсәт итмәгәннәр. Аз санлы мәдрәсәләр генә хәзерге мәктәп моделе була алмый. Бүген модага кереп киткән гимназияләр, әлбәттә, яңа нәрсә түгел. Беренче гимназияләр Афинада барлыкка килгән, аларда философиягә, сәясәткә, әдәбиятка, гимнастикага, музыкага зур урын бирелгән. Борынгы Рим республикасында балалар элементлар (башлангыч), грамматика (урта) мәктәпләрендә белем алганнар. Югары мәктәпләрдә, мәсәлән, риторика мәктәбендә (ораторлар) булачак дәүләт җитәкчеләре, җәмәгать эшлеклеләре матур сөйләмгә, музыкага өйрәнгәннәр. Философия, хокук фәннәре, грек теле, математика кебек фәннәргә гаять күп вакыт бирелгән. Күренекле рим педагогы Марк Фабий Квинтилиан (42—118 еллар) укытучыларга мондый киңәшләр биргән: «һәр бала нәрсәгәдер сәләтле була, шул сәләтне вакытында ачарга һәм үстерергә, укучыларны яратырга, физик җәзага тартмаска кирәк. Педагог һәрьяклап белемле булырга, даими үз өстендә эшләргә тиеш». Әйтерсең лә бу сүзләр әле генә әйтелгән. Бу фикерне китерүнең мәгънәсе шул: педагогика кануннары мәңгелек, алар үзгәрми диярлек.

Бүгенге көн укытучысы Урта гасырлар, Яңарыш чоры (Ренессанс) галимнәре, XVII—XIX гасырның бөек педагоглары (алар берүк вакытта философлар, язучылар да) Я. Коменский, Дж. Локк, Ж. Руссо, И. Песталоцци, И. Гербарт, А. Дистервег, Кытай, Һиндстан, Гарәбстан педагогларының мираслары белән таныш булырга тиешләр. Боларга татар педагогларын да өстәргә кирәк.

Педагогика кануннары халык традицияләренә бәйләнгән. Моны тоталитар система гына таныырга теләмәде һәм «сыйнфый тәрбия» дигән ялган постулат белән бик нык оттырды. Һәр халыкның үз тәрбия алымнары бар. Мәсәлән, кытайлар балаларын бары тик уңай үрнәктә генә тәрбиялиләр. Япониядә дә шулай. Бездәге кебек, аларда да бала кыйнау юк. Чөнки, әнкәй мәрхүмә әйтмешли, кыйналган баланың оят битлеге ертыла. Ә вөҗдансыз кеше нәрсә эшләргә дә сәләтле. Христиан дине, киресенчә, баланы физик җәзага тарту файдалы дип саный. Янәсе, Адәм белән Хава гөнаһ кылганнар (Алланы тыңламаганнар) икән, алар кавемендәге балалар да гөнаһлы булып туалар. Ә физик җәза гөнаһларны киметергә ярдәм итә. Ислам дине исә моның киресен раслый.... Инглиз мәктәпләренең кайберләрендә укучыны физик җәзага тарту каралган. Урта гасыр монастырьларында балаларны укытканда: «малайларның колагы — аркасында» дигәннәр. Бүгенге Германиядә ата-ананың үз баласын кыйнап үтерү очраклары бар. Бөек немец педагогы И. Гербарт балаларны җәзага тарту (штраф системасы) шкаласын эшләгән. Һәр халыкның үз тәрбия методлары бар шул. Әмма, күршеләренә ияреп, татарларның да аларның гореф-гадәтләрен, мәсәлән, эчү һәм сүгенүләрен кабул итүе бик тә аяныч... Күршеләребезнең мең еллык эчү тәҗрибәсе, димәк, алкоголизм авыруына каршы күпмедер күләмдә иммунитеты бар. Ә татарда ул — юк. Аракыга тотынган әллә никадәр татар хатыннарының терелмәслек дәрәҗәдә алкоголизм авыруына дучар булулары әнә шуның белән аңлатыла. Мин яшн торган сиксән фатирлы йортта 50—55 яшьләр чамасындагы өч татар хатыны җирдә аунап яту дәрәҗәсендә эчәләр, чөнки алар — алкоголиклар. Әгәр милләтебезне саклап калырга телибез икән, үзебезнең гореф-гадәтләргә күчәргә, асылыбызга кайтырга кирәк. Бөек рус педагогы Ушинский, тәрбия милли характерда гына булырга мөмкин һәм ана телендә алып барылырга тиеш, дигән. Үзенең бу фикерен ул төрле халыклар мисалында дәлилләгән...

Күптән түгел «Останкино» телевидениесе «Нәрсә ул урыс маты?», — дигән темага сөйләшү уздырды. Анда катнашучыларның иң зур күпчелеге: «Сүгенүсез урыс була да, яши дә алмый, бу безнең милли яшәеш формабыз», — дигән нәтиҗә ясады. Минә шуннан соң баланы алар халкына куш инде син... Күзәткәнем, ишеткәнем бар: урыс кызы яраткан егетен ияртеп кайта. Бер бүлмәдә — алар, икенчесендә — ата-анасы. Егет үпкәндә, кочаклаганда, кыз чыелдый башлый. Бу аның ата-анасына да ошый, егет кызыбызны ярата икән, диләр. Шул ук шартларда татар кызы үзен бөтенләй башкача тота: тешен кысып, иренен тешләп булса да түзә, эндәшми. Гадәтебез шулайрак инде... Болар вак-төяктер, әмма халыкның характеры шуларда да күренә.

Кемне тәрбияләргә телибез? Эчкече каракнымы, ялкаунымы, әллә эш сөючә, инсафлы, кешелекле шәхеснеме? Мәсьәлә шулай гына торырга мөмкин. Бервакыт миңа лекциядән соң (Казанда мин лекция укымаган берәр предприятие, учреждение, сәүдә оешмасы калды микән?), тыңлаучылар болай дигәннәр иде: «Беркемне дә алкоголик итеп тәрбияләмиләр, ул үзе шундыйга әйләнә». «Бәлки шулайдыр, әмма әхлак нормаларын онытмаганнар эчү белән мавыкмаслар, эчү — җирәнгеч эш, әхлаксызлык билгесе»,— дип җавап биргән идем мин ул чакта. Кемнәрдер меңәр еллар буе эчкәннәр — моны белү өчен күршеләребезнең әдәбиятына мөрәҗәгать итү дә җитә. Ә безнең халыкта революциягә кадәр эчү бөтенләй булмаган. Сугыштан соң да ул сирәк күренеш иде. Әмма «яңа тарихи бердәмлек» — совет халкының бер өлешенә әйләнгәч, без күршеләрдән дә уздырып җибәрдек. Бәлки бу сүзләр кемгәдер ошамас, гел эчү турында яза, дияр. Мин моны аңлап эшлим, рефрен формасында кабатлыйм, чөнки бүген татарны харап итүче иң явыз дошман — хәмергә табыну... Әгәр без бу яшел еланны буып ташламасак, бәйсезлек, суверенитет дип «аһ» орууларыбыз буш аваз гына булып калачак. Эчү — халыкны һәлакәткә илтә. Бу — бәхәссез. Шуңа ачынып, Лермонтов болай дигән:

> Я хочу сказать великому народу:
> Ты — пустой и жалкий народ.

Күренекле рус әдибе А. Мережковский да, уфтанып, урыс пычракка чумган, карак, ялкау, исерекбаш, дигән. Күренекле галим һәм теолог Николай Бердяев: «Урысча ялкаулык, пошынмау, һәвәслек булмау, җаваплылык хисенең житенкерәмәве шундый сыйфатлардандыр»,— ди. Мин үз халкымның бу баткаклыктан чыгуын, яңадан чын татар булуын телим. «Элек тә эчкәннәр, муллалар самавырдан чөмергәннәр»,— дигән сүзләрне наданнар һәм явыз карашлы кешеләр генә сөйли. Онытмыйк: революциягә кадәр татар авылына бервакытта да аракы, гомумән, эчемлек кермәгән! 400 ел буе искиткеч колониаль изү шартларында да татарлар милләт буларак сакланганнар икән, моның төп сәбәбе шунда: аларда милли аң, милли хисләр көчле булган: бер милләт кешеләре икәнен белгәннәр һәм үзара тату яшәгәннәр. Аек булганнар. Бер дә юкка гына Максим Горький: «Татарлар иң яхшы, иң намуслы халык... кешеләр арасында әйбәтләрнең дә иң әйбәте»,— димәгән инде. Казан университеты профессоры, милләте белән немец Карл Фукс, татарлар эчми-тартмый, бик эшчән һәм гаҗәеп кунакчыл халык, дигән. Мин бүген дә шулай булуын телим. Моның өчен гаиләдә, мәктәптә, вузларда укыту-тәрбия системасын өр-яңадан карап чыгарга, тәрбия эшен халкыбызга хас юнәлештә алып барырга кирәк. Бу җиңел булмаячак. Чөнки һаман да инерцион фикер йөртүләр, Мәскәүгә карап торулар бар. Бу да гаҗәп түгел: дистә еллар буе Мәскәүгә, «бөек рус халкына» дан җырлаучылар әле дә түрәлек итәләр. Андый кадрларның тиз генә үзгәрүенә исәп тоту беркатлылык булыр иде. Шул уңайдан борынгы бер хикмәтне искә төшерик әле: Муса пәйгамбәр үзенең яһүд кавемен Мисырдан алып чыккач та, туп-туры Израильгә алып кайтмаган, 15—20 тәүлек юлны 40 елга сузган, халыкны уратып йөрткән дә йөрткән. Коллыкта яшәгәннәр үлеп беткәч кенә, аларның ирекtә туган балаларын гына туган ягына алып кайткан. Бик гыйбрәтле һәм акыллы вакыйга бу: коллык, курку психологиясен бетерү бик кыен эш. Әмма тарих безгә үзгәрү өчен 40 ел түгел, бик аз вакыт биргән. Рус шовинизмы көч җыйса, безнең кебекләрне яңадан коллык читлегенә ябып куячак...

Бу язманы эшләп утырганда, Мәскәү телевидениесе (1994 ел, 11 июнь) «Уходящая натура» дигән тапшыру күрсәтте. Аны күренекле шәхес Лев Аннинский алып барды. «Венедикт Ерофеев» дигән кинофильмның авторы белән сөйләште (фамилиясен хәтерләмим). Алар Россиянең киләчәге, реформаның нигә ике аякка да аксавы турында фикер алыштылар. Фильмнан фрагментлар күрсәтелде. Мин аларга тукталып тормыйм, кыскача эчтәлеген генә әйтәм: «Венедикт Ерофеев — коеп куйган рус кешесе. Ике вузга кереп карый, әмма аларны ташлый. Чөнки уку — күп көч куюны сорый. Ә Венедикт ата-бабаларының гадәтен куа: эшләми, бары тик эчә генә. Эчкән чагында хисләргә бирелә, бөтен дөньяны кочмакчы була. Әмма аз гына айнудымы, кәефе кырыла. Башында бер уй: хәмер табу. Шешәне эләктергәч, тиз генә бөкесен теше белән ача һәм тамчысын да калдырмый хәмерне эчеп бетерә. Елмая. Бу минутларда ул дөньяның иң бәхетлесе һәм акыллысы! Уе да бер генә: «Работа дураков любит», «Работа — не волк, в лес не убежит». Ләкин бу «идеологик концепцияләр» Ерофеевны коткармыйлар, ул фаҗигале рәвештә үлә. «Нигә реформа бармый?» — дигән сорауга, әңгәмәдәш-

ләр: «Эшләмәгәнгә, эшләргә теләмәгәнгә, тик эчү белән шөгыльләнгәнгә»,— дигән гомумиләштерелгән җавап бирәләр. Мөгаен, бу җавап дөрестер, чөнки элекке «социалистик илләр», базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, нык алга киттеләр. Тырыш кешеләргә киң юллар, зур мөмкинлекләр ачылды. Ә бит үйласаң, аларда җир асты байлыклары да бик аз. Ә Россиядәге кадәр җир асты байлыклары, иң яхшы кара туфраклы җирләр башкаларда юк! Шулай да халык ач-ялангач, чөнки эшләргә теләми, тәмле ашарга, эчәргә, киенергә тели, димәк, урлашу юлына баса дигән сүз. Кешеме соң без? Японнарның уртача гомере — 84 ел, бездә — 58, аның да бик күбесе авыру, инвалид. Япон эшчесенә елына ике атналык ял бирелә. Ул шуның яртысын файдалана да, эшенә йөгерә. Димәк, яраткан эш авырлыгыннан беркем дә вакытсыз дөнья куймый икән.

Лев Аннинскийның, русларны җид-большевиклар гына эчәргә өйрәттеләр, дигән сүзләре дөреслеккә туры килми. Урыс халкы гомер-гомергә эчкән, эшләргә яратмаган. Мисалы: крепостное право башка бер илдә дә булмаган, Россиядә генә кертелгән. Сәбәбе: крестьяннарны эшләргә мәҗбүр итү. Әмма моннан бер ни дә килеп чыкмаган... Болар — тарихи чынбарлык һәм аны үзгәртеп булмый... Бу халыкны аракыдан аерып алсаң, бәлки эшкә тотыныр иде. Моны әйтүемнең сәбәбе шул: татар халкы бервакытта да эчмәгән, шуңа күрә бик тырышып эшләгән. Шуның аркасында милләт буларак сакланып калган. Әгәр без күршеләргә иярүне туктатмасак, алар хәленә калачакбыз. Бу арттырып, күпертеп әйтү түгел. Аракыга каршы көрәшне мәктәптән үк, бала парта артында утырганда ук алып барырга, хәмергә, аракы эчүләргә нәфрәт тәрбияләргә кирәк. Минемчә, моны дин ярдәмендә генә тормышка ашырырга мөмкин... Күптән түгел татар милләтеннән булган бер профессор: «Дин куркытып тәрбияли, без моңа бара алмыйбыз»,— диде. Мин аңа сорау куям: кайсы закон куркытмый икән? Тәрбия кагыйдәләре шул ук законнар ич. Сезнең «куркытмый тәрбияләнгәннәрегез» бүген урам, йорт басалар, аларны тагын ничек тәрбияләргә уйлыйсыз? Төрмәгә утыртыпмы? Алар анда тәрбия алмый, әшәкелек курсын үтеп чыгалар... Мөселман илләрендә хәл бөтенләй башка, чөнки тәрбияләре шулай. Иракта машина урлаучыларның кулларын, аякларын кисәләр дип куркыталар безне. Белешмә: XVII гасырда Англиядә бер кисәк икмәк урлаган өчен хатыннарны да асканнар. Финляндиядә дә каракларның кулларын кисkәннәр. Мин бүген бездә дә кул-аяк кисү кертелсен димәс идем, ул чакта бөтен Рәсәй кулсыз-аяксыз калыр иде... Тел төбем шул: тәрбия нигезендә куркыту, мактау элементлары да бар.

Бу бәлки бераз темадан читләшү булып тоелыр, ләкин беренче карашка гына. Чөнки без сөйли торган мәсьәлә шулкадәр җитди ки, бераз читкә китми дә булмый. Сүз дөньядагы иң көчле идеология — дин турында бара. Ул шулкадәр куәтле, аның конкурентлары-көндәше дә юк. Чөнки дин берьюлы аңга һәм хисләргә тәэсир итә. Ә инанулар шул чакта гына формалаша. Марксизм-ленинизм да шуңа омтылып карады. Әмма ул хисләргә йогынты ясый алмады. Дөньяда оҗмах төзүне вәгъдә итсә дә, чынбарлыкта моның киресе килеп чыкты. Илнең иң затлы 60 миллионга якын кешесе ГУЛАГларда чиреде, атылды, асылды. Чын мәгънәсендә коллар хәленә төшерелгән халык «мин бәхет илендә яшим» дип җырларга мәҗбүр ителде.

Инде конкрет мәсьәләгә — татар мәктәбен бүгенге көн таләпләре югарылыгына күтәрүгә килгәндә, аның ике төп юлы бар: аларда уртаклыклар да, аерымлыклар да җитәрлек. Шуларның берсе — Татар иҗтимагый үзәге төзегән «Татар милли мәктәбе, укыту-тәрбия концепциясе». Бу концепция-программа үз вакытында матбугат битләрендә дөнья күрде, аның турында сүз күп булды. (Шуның бер чагылышы буларак, Татар милли университеты оешты). Шуңа күрә бу язмада аңа анализ ясау ихтыяҗы юктыр. Икенчесе — рәсми документ, Республикабыз Президенты кул куйган (1993 ел, 19 октябрь) «Мәгариф турында Татарстан республикасы законы». Ул 6 бүлектән, 56 маддәдән тора. Табигый, бу закон татар мәктәбе турында гына түгел. Принципта бу дөрестер дә: сүз күп милләтле республика халкы турында бара. Әмма да ләкин әлеге документта татар мәктәбенә аерым бер бүлек багышланса, закон отар гына иде. Ни өчен? Ул хакта сүз алда булачак әле.... Мәсәлән, моңа кадәр татарча укытыла торган мәктәпләр дә Россия империясенең сәясәтенә хезмәт итә торган уку йортлары булып килделәр. Татар мәктәбендә «татар-монголларның» тетмәсен теттеләр, «бөек прогрессив рус халкын» күкләргә чөйделәр. Моны укыту программалары таләп итте. Аларның ничек үтәлүләрен җирле Рәсәй сатраплары (аларның да монда әллә ни гаепләре юк. Яшәргә, ашарга кирәк ич...) — мәгариф түрәләре туктаусыз күзәтеп тордылар. «Коммунизмга якынайган саен», республикада татар балалар бакчалары, мәктәпләре саны нык кимеде, шәһәрләрдә, район

үзәкләрендә исә бөтенләй беттеләр. Рус мәктәпләре чәчәк аттылар. Менә шул шартларда татар мәктәбен рус мәктәбе белән бер рәткә кую дөрес булыр микән? Минемчә, милли мәктәпләр үссен, рус мәктәпләре дәрәҗәсенә күтәрелсен өчен, милли мәктәпләргә өстәмә шартлар тудырылырга тиеш. Аңлашыла ки, моңа шовинистларның кәефе китәчәк. Яңа мәктәп биналары, уку әсбаплары, дәреслекләр, компьютерлар, төрле яңа уку программалары белән иң беренче чиратта милли мәктәпләр тәэмин ителергә тиеш, чөнки һаманга кадәр аларның укыту-материаль базалары бик зәгыйфь, мескен хәлдәләр, шуңа күрә, түрә балалары тик рус мәктәбендә генә укыдылар.

«Мәгариф турында»гы закон татар мәктәпләренә нәрсәләр вәгъдә итә соң? 5 нче маддә «Татар милли мәгарифе» дип атала (шундый бердәнбер статья). Анда мондый сүзләр бар: «Татар милли мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеге кешелек хәзинәләренең өстенлеге нигезендә шәхеснең милли үзаңын торгызуга юнәлдерелә. Татар халкының милли мәгариф учреждениеләрендә укыту һәм тәрбия татар халкының милли мәгърифәте үсеше концепциясе нигезендә алып барыла». Бу статьяның эчтәлеге белән килешергә була, әмма ул — декларатив характерда. Укыту материаль база турында аерым маддә кирәк иде. Әмма иң аянычлысы башкада: халык мәгарифе кебек киләчәккә хезмәт итә торган оешмалар белән «партия мәктәбен үтүчеләр» житәкчелек иткәндә, әлеге закон төгәл үтәлмәячәк, объектив рәвештә алар моңа комачаулык итәчәкләр. Менә бер мисал: Казандагы 6 нчы урта мәктәптә укыту рус телендә алып барыла. Мәктәп директоры Таң Мәхмүт улы Еникеев моннан 5 ел элек үз инициативасы белән, барлык классларда да татар телен өйрәнүне кертә. Татар теле укытучыларын таба, алар өчен кабинет җиһазлана, дәресләр уңай вакытка куела. Бер татар хатынынннан башка («Баламның башын татар телегез белән катырмагыз»,— ди ул хатын), беркем дә бу яңалыкка каршы төшми. Рус балалары да тәнәфес вакытында татарча сөйләшергә тырышалар. Бу хәл кайбер агай-энене кара кайгыга сала. «Элекке заманнар кайтса — нишләрбез»,— дип курка алар. Ләкин директор туктап калмый, чөнки заманаларның үзгәреп баруын ул үз мәктәбе үрнәгендә тоя... Күп еллар буена бу мәктәп базасында педагогик класслар эшләп килде, балалар бакчалары өчен тәрбиячеләр әзерләнде. «Ә нигә шундый белгечләрне татар балалар бакчалары өчен әзерләмәскә?» — дип уйлый директор һәм уен тормышка ашырырга була, радио аша унынчы классны бетергән татар кызларын педклассска чакыра. Бу нәрсә түрәләргә бер дә ошамый, андый педклассларны ачарга Мәскәү кушмый, акча бирми, диләр. Ә директор: «Мәскәү бездә татар тәрбиячеләренә кытлык икәнен беләме соң?» — ди һәм педклассны ачып җибәрә. Әмма ул моның белән дә чикләнми, мәктәп базасында колледж оештырып, рус мәктәпләре өчен татар теле укытучылары әзерләмәкче була. Казан дәүләт педагогия институты ректоры Р. А. Йосыпов мәктәпкә педагогик кадрлар-укытучылар белән ярдәм итәргә ризалык бирә. Моңа бәлки, кеше ышанмас та, әмма мәгариф министрының урынбасарлары бу идеягә бик нык каршы төшәләр. Чиновник шуңа күрә чиновник инде ул, «не пущу»ны тормышка ашыру өчен йөз төрле сәбәп таба. Шундыйларның берсе: «Таң Мәхмүтович, нигә нервыгызны туздырып, әллә нәрсәләр эшләп йөрисез. Саклагыз үзегезне»,— дип, «акыллы киңәш» тә бирә. Киңәш киңәш тә бит, ә татар теле укытучыларын каян алырга? Вузлар, училищелар генә бу эшне тиз вакытта хәл итә алмый... Әйтүе кыен: нәрсә күбрәк икән кайбер агай-энедә: куркумы, элеккечә уйлаумы, әллә башка берәр нәрсәме? Тик шунсы хак, андыйларга иң беренче чиратта милләт, халык мәнфәгате түгел, йомшак кәнәфиләре кыйммәт. Хезмәт хакы килә, көн үтә, «тегенди-мондый хәлләр килеп чыкса, мине гаепли алмаячаклар», дип уйлый бу ташбаш. Әмма шуны да онытмыйк: Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең гаскәр башлыгына мондый язу уелган кылыч бүләк иткән: «Курку намуссызлыкка алып бара, ә дан һәрвакыт алга илтә. Куркаклык кешене үзенең язмышыннан беркайчан да коткармаячак». Юк инде, туганкайлар, «тегенди-мондый хәл килеп чыкса», беребезгә дә мәрхәмәт булмаячак. Ә чын күңелдән тырышсак, тарих аренасыннан төшеп калуга дучар ителгән халкыбызны элекке хәленә кайтарсак, бөек дәрәҗәсенә күтәрсәк, безне беркем дә, беркайчан да җиңә алмаячак. Вакыты шундый. Менә бит: директорның бик нык тырышлыгы аркасында, 6 нчы мәктәптә татар лицей класслары ачылды, алар быелгы уку елын уңышлы гына тәмамладылар.

Мәскәү телевидениесенең «Панорама» тапшыруында (быелның 13 июне) Португалия президенты Мариу Соареш чыгышын тапшырдылар. Ул: «...Моннан 20 еллар элек кенә Португалия артта калган ил иде. Бүген ул — дөньяда иң алга киткән дәүләтләрнең берсе. Төп сәбәбе: белемле, милли үзаңлы кадрлар әзерли алдык. Алар югары технология белән эшләү серләрен үзләштерделәр»,— диде.

Шундый ук уй-фикерләрне Кипр, Тайвань, Сингапур, Малайзия, Көньяк Корея президентлары авызыннан да ишетергә мөмкин. Югары квалификацияле кадрлар әзерләү — алга китүнең ышанычлы юлы. Татарстаныбыз да шуңа омтылырга, халык мәгарифен үстерүгә көчен кызганмаска тиеш. Татар балаларына үз телендә белем бирү — шулай ук иң мөһим бурычларның берсе. Кайберәүләр, бала нинди телдә укыса да, барыбер түгелмени, диләр. Болай уйлау тамырыннан ялгыш, чөнки бала тулы канлы шәхес булып формалашсын өчен конкрет мөхиттә, конкрет халык традицияләрендә тәрбия алырга тиеш. Бу — дөнья күләмендәге аксиома. Үз телennән, үз халкыннан аерылган бала дөрес тәрбия ала алмый. Бер ярдан кузгалып киткән корабның икенче ярга барып житә алмавын хәтерләтә андый балалар. Күп кенә татарларның шапшаклык юлына басуы еш кына әнә шуның белән аңлатыла. Андыйлар эчәләр, тарталар, сүгенәләр. Ә болар исә безнең халыкка ят сыйфатлар.

Күп кенә мәктәпләрнең, роно, гороноларның эше белән танышкач, шундый тәэсир кала: безнең республика шартларында мәгариф оешмалары, шул җөмләдән балалар бакчалары, урта уку йортлары белән төп халык вәкилләре җитәкчелек итәргә тиешләр. Чөнки, кагыйдә буларак, алар рус халкының да, татар халкының да мәгариф өлкәсендәге ихтыяжларын әйбәт беләләр. Ә күршеләр башкаларның хәлен белмиләр генә түгел, белергә дә теләмиләр. Бу — аларның канында. Татарстан радиосы, телевидениесе «Татарский язык — для вас» дигән тапшырулар башлангач, андыйлар радиоалгычларын, телевизорларын сүндереп куялар. Шулай булгач, алардан нәрсә көтәргә мөмкин соң? Аларда империячел караш, башка телләргә кимсетеп карау формалашкан. Бу — аларның хатасы түгел, фаҗигасе... Күршебездә татар агае маржа белән яши. Тату яшиләр кебек. Әмма маржа түтәй 40 ел буена 40 татар сүзен дә өйрәнмәгән. «Нигә алай булгач, татар белән торасың?» — дип сорыйлар безнең түтәйләр аңардан. «Сез иремнән сорагыз, нигә ул минем белән тора икән соң? Миңа татар теле кирәкми, шуңа балаларымны да татарчага өйрәнмәсеннәр дидем», — дип җавап бирә ул. Ә бит бу хатын татарларның дошманы да түгел, әмма идеологик шаблон «телем өстен, үзем өстен» дигән шаукым аны шулай итә. Моннан чыгып нинди нәтиҗәләр ясарга булыр иде? Шовинизм тиз генә бетә торган күренеш түгел: катнаш никахтан бервакытта да татар тумый...

Иң үкенечлесе шул: татар милләтеннән булган шактый ата-аналарның балаларын ана телендә укытырга теләмәве. Бу унар еллар буена үткәрелгән сәясәт, «бөек рус халкы»на, «бөек рус теле»нә мәдхия җырлау нәтиҗәсе. «Яңа тарихи бердәмлек — совет халкы туды», — дигәнне халык урыс халкы гына яшәргә хаклы дип аңлады. Һәм болай уйлау нигездә дөрес тә иде. 50 ел эчендә СССР дип аталган урыс империясендә яшәүче 194 халыкның 93 е юкка чыгу шуның дәлиле түгелмени? Хрущев партия мөнбәреннән торып: «Рус теле — коммунизм теле», — дип игълан итте. Балаларыбызны урыс мәктәбенә биреп, аларга коммунизм оҗмахында урын хәзерләдек. ВУЗларда да укыту гел рус телендә генә барды. Дәүләт учреждениеләрендә, бигрәк тә партоешмаларда русча сөйләшү бисмиллага тиң булды. Кыскасы, татар теле кухня теле дәрәҗәсенә төште. Хәтта карчыклар да, вата-кыра булса да, оныклары белән русча сөйләшергә тырыштылар. Безнең күрше Майтап апа 10—15 рус сүзен белә микән, әмма ул да этe белән тик урысча гына аңлаша... Әнә шул җирлектә «ата-ана теләге белән», «татар мәктәпләре урыс мәктәпләренә» әверелделәр дә инде. Бу «механизмны» яхшырак күз алдына китерү өчен, мәшһүр язучыбыз, шагыйребез Айдар Хәлимнең «Сагыш китабы...»н укып чыгарга кирәк. Кыскасы, кем килеп йолкыр безне...

Бүгенге көннең иң мөһим бурычларыннан берсе — халкыбызның милли үз аңын уяту, милли хисләрен баету. Моның өчен татар үз халкының бай, данлы, фаҗигале тарихын, бөек татар кавеменнән икәнен белергә тиеш. Шул чакта гына ата-ана баласын ана теле мәктәбенә бирәчәк. Коменский, кеше үз гомерендә дүрт баскыч мәктәп үтә, ди һәм аларны санап та чыга: аналар мәктәбе, башлангыч, урта, югары мәктәпләр. Аналар мәктәбе дип, баланың мәктәпкәчә чорда ана кулында тәрбия-белем алуы аталган. Бу вакытта бала мәктәпкә әзерлек «курсын» үтә. Л. Н. Толстойның (ул бөек язучы гына түгел, талантлы педагог та булган), өч яшькә кадәр белгәннәремне соңыннан тулыландырдым гына, дигән мәшһүр сүзләре бар. Әлбәттә, ана баласын үз телендә тәрбияли һәм үз телендәге мәктәпкә бирә. Рус телендә укыганнар гына олы тормыш юлына ныклап аяк басалар, дип уйлау — урынсыз. Әрмәннәр үз телләрендә генә укыйлар. Шул ук вакытта җан башына салып исәпләгәндә, элекке СССРда бик күп атаклы галимнәр, композиторлар, рәссамнәр, язучылар, архитекторлар, скульпторлар һ. б. — әр-

мәннәр иде. Хәрби өлкәдә дә шул ук хәл. Ни өчен шулай соң? Бу халыкның бай традицияләре бар, балалары шулар нигезендә белем һәм тәрбия алалар. Рус телен белү әле үзе генә бер нәрсә дә бирми, киләчәкне билгеләми. Моны элекке СССР составындагы союздаш республикаларның теләсә кайсысы үрнәгендә дә расларга була...

Бүген Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Әзербайҗан, Молдова, Украина, Беларусь кебек илләрдә укыту үз телләрендә алып барыла. Шигем юк: бу илләр тиз арада ныклап алга китәчәкләр. Моны мин цивилизацияле илләр тарихына таянып әйтәм...

Инде бүгенге Татарстанда мәгариф мәсьәләләренә килгәндә, эшләр болайрак тора. Принцип буларак, мәктәпкәчә яшьтәге балалар гаиләдә ана кулында тәрбия алырга тиешләр. Бу бөтен дөньяда шулай. Мәсәлән, гарәп хатыны өендә балаларын тәрбия кылган өчен, яхшы түләү (ире хезмәт хакының 70 процентына кадәр) ала. Совет җәмгыяте, ирләр белән хатын-кызларны тигез итәм дип, аларга ике камыт: өй һәм дәүләт эше камытларын кидерде. Бу шуңа китерде: бер яктан, бала табу бик нык кимеде, икенчедән, балалар ана җылысыннан, дөрес тәрбиядән мәхрүм ителделәр. Дәүләт җитәкчеләре моны ике төп сәбәп белән аңлаттылар: акча юк; хатын-кыз эшләүдән туктаса, илгә бик зур зыян киләчәк, имеш.

Әйдәгез, шул уңайдан үзебезнең республикадагы хәлләргә күз төшерик әле.

1994 елның уртасына Татарстанда 2510 балалар бакчасы бар иде. Аларда 220 меңгә якын бала тәрбияләнде. Шуларның 927 се — татар балалар бакчалары, аларга 36 мең бала йөрде. Кайбер рус балалар бакчаларында татар группалары оештырылып, аларда 7700 бала тәрбияләнде. Җыеп әйткәндә, татар балалар бакчаларында, аерым группаларда 56 мең, рус балалар бакчаларында 164 мең бала тәрбияләнүен әйтергә була. Республика халкының яртысы татарлардан торганын истә тотсак, бу нисбәтне, әлбәттә, мактап булмый. Әмма шулай да, элекке еллар белән чагыштырганда, үсеш бар... Моннан берничә ел элек кенә Казанда бер генә татар балалар бакчасы да, группасы да юк иде. Бүген дә мактанырлык түгел, әмма... Саннар китерик. Казанда 410 балалар бакчасы бар, шуларда 55 мең бала тәрбияләнә. Шуның 15 е — татар балалар бакчалары, аларга 1300 бала йөри. Бу хәл өчен конкрет кешеләр-сәбәпләр бар. Мәсәлән, үзе рус мәктәбен тәмамлаган милли ата-ана баласын татар балалар бакчасына бирергә ашыгып тормый, бу хакта хәтта уйламый да. Әмма татар мәктәпләренең, балалар бакчаларының дәрәҗәсен күтәргәндә, материаль базасын ныгытканда, әйбәт тәрбиячеләр белән тәэмин иткәндә, аларга ата-аналарның да карашы үзгәрер иде. Киләчәктә татар милли кадрларына ихтыяҗ үсү дә татар мәктәбенә, балалар бакчаларына мөнәсәбәтне, һичшиксез, уңайга үзгәртәчәк. Моны да уйлыйсы иде: татар мәктәпләрен тәмамлаучыларга вузларга кергәндә аерым льготалар каралса, керү имтиханнары ана телендә барса, әлбәттә, милли мәктәпләр ачу проблемасы бетәчәк. Бу юнәлештә республикабыз халык мәгарифе министрлыгы эшләргә тиеш нәрсә күп әле. Бәхеткә, халык мәгарифе министры булып Васил Габдуллович Гайфуллин, профессор, киң диапозонлы, тирән белемле, акыллы, татар мәктәбе мәсьәләләрен биш бармагы кебек белгән кеше эшли. Моңа кадәр булган кайбер министрлардан аермалы буларак, ул нәкъ үз урынында. Халкыбызның, милләтебезнең киләчәге халык мәгарифенә бәйле икәнен ул яхшы аңлый һәм үзе җитәкләгән өлкәне үстерүгә күп көч куя. Шулай да мөхтәрәм министрыбыз үзе бу эшкә килгәнче тупланган министрлык аппаратын яңадан карап-барлап чыкса, эш тагын да алга китәр иде. Мин бу сүзләрне күп кенә мәктәп директорлары, укытучылар фикереннән чыгып әйтәм...

Билгеле булганча, җитмешенче еллар уртасына Казан кебек шәһәрләрдә генә түгел, башка бик күп урыннарда да татар мәктәпләре ябылып бетте. Сәбәбе дә билгеле: «партиянең милли сәясәте уңышлары» шуңа китерде. Аның нигезендә бик гади нәрсә — рус шовинизмының чагылышы ята иде. Әлбәттә, бу коточкыч гаделсезлек кенә түгел, дөнья цивилизациясе өчен зур югалту да иде. Сүз тел бетү турында гына бармый, бөек рус педагогы Ушинский әйтүенчә, тел бетү белән шул телдә сөйләшүче халык та бетә. Әнә шуңа күрә Аурупа, Азия, Америка һ. б. кыйтгаларда иң кечкенә халыкларның да телләрен саклау өчен тырышалар. Финляндия, Норвегиядә гомуми саны 5 меңнән дә артмаган саамнар үз телләрендә укыйлар, әсәрләр язалар, сәнгатьләрен үстерәләр, фольклорларын туплыйлар. Кесәләрендә коммунист партбилеты йөрткән рус шовинистлары нәкъ шуның киресен эшләделәр. Ниһаять «бөек Рус империясе» җимерелә башлады, шактый көчсезләнде. Әмма ул юкка чыкты дигән сүз түгел. Шулай да әлеге форсаттан файдаланып, үлем дәрәҗәсенә җиткерелгән халкыбызны терелтергә, аякка басты-

рырга кирәк. Моны үтәрлек потенциаль көчләр бар бездә. Татар халкы, феникс кошы кебек, көлдән дә адәмгә әйләнергә тора. Л. Гумилев кебек бөек шәхесләр бер дә юкка гына татар халкының киләчәгенә зур өмет багламаганнар инде (кара: А. Н. Гумилевның пассионария теориясе). Татар халкының үсешен тәэмин итәрлек төп көчләрнең берсе — халык мәгарифе. Монда Америка ачып торасы юк.

Югалтуы гына җиңел, шуны табуы, аякка бастыруы гаҗәеп авыр, катлаулы процесс. Ләкин мөмкин булмаган нәрсә юк, халык: «Тырышкан — табар, ташка кадак кагар»,— дигән. Моннан 3000 еллар элек рим легионерлары тарафыннан тар-мар ителгән Израиль дәүләтенең аякка басуы — шуның бер үрнәге түгелмени? Яһүдләр бүген үз дәүләтләрен гөлбакча иттеләр, халык мәгарифен нык үстерделәр. Без дә мөстәкыйльлек турында хыялланабыз, суверенитет алдык, дибез. Ә аның эчтәлеге нидән гыйбарәт булырга тиеш соң?

Халык мәгарифен генә алсак та, нинди нәтиҗәләр ясарга буладыр: 1994 елның августына Татарстанда 2440 мәктәп бар иде. Шуларның яртысы чамасы — татар мәктәпләре. Татар мәктәпләрендә 90 мең, рус мәктәпләрендә ярты миллион чамасы бала укыды. Моннан тыш, Татарстанда 88 чуваш, 19 удмурт, 15 мари, 1 мордва мәктәбе бар. Республика мәктәпләрендә эшләүче укытучыларның гомуми саны — 50 мең тирәсе. Татарстан республикасының мәгариф министры В. Гайфуллин Бөгелмәдә (1994 елның апрелендә) уздырылган шәһәр мәгариф идарәләре һәм район мәгариф бүлеге мөдирләре киңәшмәсендә түбәндәгеләрне әйтте: республикада 59 татар гимназиясе һәм мәктәп-гимназиясе (мәктәп-гимназиянең мәгънәсе болай: гадәти урта мәктәпләрдә гимназияләр программаларына таянып укытыла торган класслар да була) ачылды. Республикада 1218 рус мәктәбе бар, шуларның 296сында татар сыйныфлары ачылган, аларда 100 меңнән артык татар баласы укый. Бу саннар — өметле күренеш, ләкин әлеге татар классларында татар телен һәм әдәбиятын ничек үзләштерәләрдер, әйтүе кыен. Тик шунысы билгеле: Казандагы татар гимназияләрендә укучы балалар тәнәфестә русча гына сөйләшәләр. Бу да гаҗәп түгел: алар моңа кадәр өйдә, балалар бакчасында, урамда гел русча гына сөйләшкәннәр ич. Әлегә татар теле аларга инглиз, француз, гарәп теле кебек үк чит тел... Моңа балалар гаепле түгел. Үкенечле шул: Финляндия, Америка, Германия, хәтта Австралиядә, бөтенләй чит мохиттә яшәгән татарлар бер дигән итеп татарча сөйләшәләр. Чөнки балалар кечкенә яшьтән үк гаилә шартларында татарча сөйләшеп үсәләр. Уйлап карыйк әле: Татарстанның башкаласында (халыкның яртысына якыны татарлар) татар балалары татарча белми! Сәбәпләре югарыда әйтелде инде...

Республикадагы рус мәктәпләрендә татар телен өйрәнүгә игътибар үсә башлады. Мәсәлән, 783 мәктәптә 243 меңнән артык укучы рус һәм татарча белмәгән татар балалары татар телен предмет буларак өйрәнә. Республикабыз парламентының чираттан тыш бер сессиясендә, депутат Ефремов (Бөгелмәдән), мәктәпләрнең киләчәге — балалар бакчасында, дип дөрес әйтте. Чыннан да, балалар бакчасында, өйдә татарча өйрәнеп килгән балалар гына татар гимназияләрендә, лицейларында уңышлы укыячаклар. Шуны истә тотып, Мәгариф министры һәр татар гимназиясенә, лицеена шул тирәдәге өч балалар бакчасын беркетте. Мәгънәсе: гимназия, лицей үзенә беркетелгән балалар бакчаларында татар группалары оештырып, берничә ел балаларны татарча укырга, язарга, сөйләшергә өйрәтергә тиеш. Ул балалар киләчәктә татар уку йортларына укырга керергә мөмкиннәр. Бик акыллы уй бу. Әмма күп кенә балалар бакчаларының мөдирләре, төрле сәбәпләр табып, бу эшкә каршы чыгалар. Татар милләтеннән булсалар, бәлки алай кыланмаслар иде дә бит... Кабатлап булса да, нәтиҗә ясарга туры килә: әгәр татар мәктәпләрен, балалар бакчаларын тиз арада аякка бастырырга телибез икән, мәктәпләр, балалар бакчалары, гомумән, барлык халык мәгарифе учреждениеләре, оешмалары белән бер үк дәрәҗәдә татар һәм рус телләрен яхшы белүчеләр җитәкчелек итәргә тиеш. Шовинизм (әйдә без аны бытовой, көнкүреш шовинизмы дип, йомшак кына итеп атыйк) озак яшәячәк әле. Казанда беренче гимназияләр ачылгач, күлмәкләренә сыймаган кайберәүләр Америка журналистларына кадәр барып җиттеләр, Казанда урысларны кысалар дип, шау күтәрделәр. Әйдәгез, тагын чынбарлыкка — саннарга, фактларга мөрәҗәгать итик әле. Казанда 162 мәктәп бар, шуларның 23 — татар мәктәпләре (гимназияләр, мәктәп-гимназияләр, лицейлар). Алар да әле яңа гына борынлап, аякка басып киләләр. Тәҗрибәләре бөтенләй юк диярлек. Урысларны менә шулай «кысалар»: Казандагы татар балаларының нибары 15 проценты гына үз телендә укый (моннан өч ел элек өч мәртәбәгә ким иде), рус балаларының һәммәсе дә рус телендә укый! Едельштейн-Жириновский кайберәүләрнең йөрәгенә нәрсә май булып ягылуын

яхшы белә һәм татар белән башкортны «сифилислы, пычрак Монголиягә» озатмакчы була...

Тагын шул ук аваз: урындагы җирле мәгариф оешмалары житәкчеләрендә, ата-аналарда милли үзаң, хисләр үсмәсә, укыту-тәрбия өлкәсендә уңышларга ирешү авыр булачак. Көн-төн: «Татар теле — дәүләт теле»,— дип, сөйләп торабыз торуын, әмма әле дә Аксубай, Базарлы Матак, Биектау, Кама Тамагы кебек район үзәкләрендә, Минзәлә, Норлат шәһәрләрендә, Урыссу эшчеләр поселогында, хәтта гел татар яши торган Ютазыда да татар мәктәбе юк. Роно житәкчеләренең җавабы — Явыз Иванны куандырырлык могҗиза булып, бу тиран терелсә, андыйларны ирененнән суырып үбәр иде: янәсе, «ата-аналар татар мәктәбе ачылуын теләмиләр». Югары Ослан, Лаеш, Спасс, Чирмешән кебек район үзәкләрендә бер генә татар класслары да ачылмаган, ә аларның һәрберсендә 250—500 татар баласы бар. Лениногорск, Чистай, Зеленодольск, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләрендә, Югары Ослан районындагы мәктәп яшендәге татар балаларының нибары 6—8 проценты гына ана телендә укый. Әгерже, Аксубай, Алабуга, Кайбыч, Октябрь, Чирмешән һ. б. татар телендә укучыларның саны кими бара. Ә бит моңа кадәр дә аларда эш әйбәт тормый иде. Моңа кем гаепле соң? Шомабаш татар үзе генә! Ул, беләсегез килсә, үз телләрендә укый торган грузин, әрмән, әзәрбайҗан, молдаван, үзбәк, казах, кыргыз, төрекмәннәрдән акыллырак та, өстен дә икән, шуңа күрә баласын русча гына укыта, янәсе. Ә дөресе шул: куркытылган, өркетелгән, кысылган, кимсетелгән, изелгән, мескенгә әйләнгән татар, совет власте елларында «сыйнфый тәрбия», «интернационал тәрбия» дигән олы кармакка капты, баласын тизрәк рус мәктәбенә олактырып, «коммунизм кырына» ашыкты. Ул әле бүген дә үзенең шул сатраплык халәтеннән чыга алмый. Ярамый болай, туганнар: белә торып үзебез һәлакәт упкынына ыргылмыйк, кеше булып калыйк, халкыбызны саклыйк.

Казанда гади татар урта белем мәктәпләре түгел, гимназия, лицейлар ачылу — дөрес юл. Бу тактика түгел, ә стратегиягә әйләнергә тиеш. Казан татарының идеологик карашлары бүген шулай, ул гади татар мәктәбенә үзенең баласын бирмәс иде. Моны хәтта фараз итеп торасы да юк. Сәбәп нәрсәдә? Фәндә юнәлгәнлек («направленность») дигән төшенчә бар. Аның мәгънәсе: кеше нәрсәгәдер инанган икән, ул аннан тиз генә котыла алмый. Бу аңның бер сыйфаты, консерватизмы. Татар дигән бәндә: «Баламны урыс мәктәбендә укытсам гына, ул бәхетле булыр, ВУЗга керү өчен дә юл ачык булыр»,— дип уйлый. Һәм шулай фикер йөртергә урын да булган: бөтен җирдә рус теле генә өстенлек иткән. Бу нәрсә аңлы рәвештә, татарны үз милләтеннән аеру, суындыру өчен эшләнгән. Үзәкнең бу сәясәтенә халкыбыз берләшү, үз телен, мәгърифәтен, мәдәниятен терелтү, аякка бастыру юлы белән җавап бирергә тиеш!

Татар гимназияләре, лицейлары ачыла башлагач, аларның перспектив якларын аңлагач, агай-эненең бер өлеше баласын шул уку йортларына бирергә кирәк, дигән нәтиҗә ясады. Яңа уку йортларына керергә теләүчеләрнең саны нык арту сәбәпле, конкурс үткәрергә, укучыларны сайлап алырга туры килде. Бу да дөрес юл, чөнки бөтенләй татарча белмәгән баланы класска кертеп утыртудан ни файда? Ләкин Югары Советыбыз ике дәүләт теле турында Закон кабул иткәч, татар гимназияләре белән кызыксыну, эйфория күзгә күренеп кими, кайберәүләр балаларын рус мәктәбенә бирү турында уйлый башладылар. Җил каян исә, «интернационализм бакчасы кошы» — татар шул якка аварга гына тора. Бу — әйбәт симптом түгел. Республикада ике дәүләт теле кертелгәнче, Казандагы күп кенә вузларда, техникумнарда татар телен өйрәнү курслары оешкан һәм алар яхшы гына эшләп тә киткәннәр иде, әмма ике дәүләт теле турындагы документның матбугатта чыгуы булды, түгәрәкләрдән җилләр исте... Хәлебез шулайрак шул, югыйсә өйрәнерлек урыннар, мисаллар да бар. Мәсәлән, урыслар күпләп яши торган Казакъстанда, Кыргызстанда казах, кыргыз телен белмәүчеләрне җаваплы эшкә алмыйлар. Кыргызстанда марҗа белән торган кыргызларга да җаваплы эш тапшырылмый. Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда да, кыскасы, элекке союздаш республикаларның барсында да дәүләт теле — үз телләре генә. Чөнки башка юл юк. Балтия илләрендәге тавышның да сәбәбе бер — руслар ул илләрдәге төп халыкның телләрен өйрәнергә теләмиләр. Безнең хәл катлаулы, әлеге илләр юлыннан китеп булмый. Әмма татар телен саклап калу өчен, гадәттән тыш чаралар да кулланырга кирәктер.

Нәрсә ул гимназия һәм башка уку йортларыннан ул кайсы ягы белән аерыла? Мондый сорауның тууы гаҗәп түгел, чөнки татарда бервакытта да гимназияләр булмаган. Совет чорында, гомумән, алар юк иде. Революциягә кадәр Россиядә, реаль һәм хатын-кызлар гимназияләре булуы билгеле. Беренче гимназияләр

борынгы Афинада (Греция) барлыкка килгән. Аларда хәлле кешеләрнең балалары урта белем алган. Патша Россиясендәге классик гимназияләр («классик» сүзе грек, латин, француз һ. б.— классик телләрне өйрәнүгә кайтып кала) тәмамлаучылар, чыннан да, күпкырлы тирән белем алганнар. Совет власте гимназияләрдән көнләште, аларны яратмады. Моның да гаҗәбе юк: дәүләт һәм партия белән «без башлангыч белемле» дип мактанучылар җитәкчелек итте. Сталин вуз бетергәннәрдән «институтка» (проститутка сүзенә ишарә) дип көлде. Инде гимназияләргә килгәндә, алар төпле белем бирү белән бергә, университетка керергә юл да ачканнар. Реаль гимназияне тәмамлаучылар гадәттә техник вузларда укыганнар, аларны шуңа әзерләгәннәр. Хатын-кызлар гимназияләрен тәмамлаучылар «институт благородных девиц» дип аталган уку йортларына укырга керә алганнар. Әлбәттә, бүгенге гимназияләр элеккеләрнең күчермәсе була алмый. Шулай да аларның тәҗрибәсен өйрәнү һич тә зыян итмәс иде. Бер җөмлә белән генә әйткәндә, гимназия ул югары типтагы урта мәктәп. Гади мәктәпләрдә моңа кадәр укытылмый торган күп кенә фәннәр (предметлар) гимназиянең уку планына кертеләләр. Мәсәлән, «Информатика», «Базар мөнәсәбәтләре нигезләре», «Экология», «Ритмика», «Этика», «Философия», өч чит тел (урта мәктәптә бер чит тел өйрәнелә), «Дин тарихы», «Риторика», «Практик психология», «Милли сәнгать», «Гражданлык һәм хокук нигезләре» (юриспруденция) кебек фәннәр — шундыйлар. Сүз уңаенда булса да, лицейлар турында берничә сүз әйтү кирәктер. Лицейларның уку планы да гади урта мәктәпләрнекеннән шактый аерыла. Лицейның гимназиядән аермасы шунда: гимназия белгечлек бирми, ә лицей ниндидер белгечлек бирә, мәсәлән, башлангыч класс укытучылары әзерли. Шуңа күрә лицейларда практикага, методикага, семинарларга зур урын бирелә. Лицейны тәмамлагач, һичбер чикләүләрсез вузга да керергә була. Элек, техникумны тәмамлагач, өч ел эшләү таләп ителә иде.

Республикабызда 47 татар, 36 рус телендә эшләүче гимназияләр, 28 лицей бар. Әйткәнебезчә, бу яңа типтагы уку йортларында эшләү тәҗрибәсе әлегә бик аз, хәтта юк дәрәҗәсендә. Һәр педагогик коллектив эзләнә, экспериментлар үткәрә, өйрәнләп булса да тәҗрибә туплый. Әмма бу гына җитми, тәҗрибәне уртаклашырга кирәк. Бу яктан Казандагы 5нче гимназия күпләргә үрнәк булып тора. Фарис Фахраз улы Харисов җитәкчелек иткән бу педколлектив олы бер фәнни лабораторияне хәтерләтә. Бу язмада ул хакта сөйләп чыгу мөмкин түгел, аның өчен махсус сүз алырга кирәк. Тик шуны гына әйтик: рус мохитендә эшләгән рус мәктәбе урынына татар гимназиясе ачу батырлык түгелмени? Директор Харисовның, берничә татар укытучысының тырышлыгы белән, моннан 4 ел элек 2 нче рус мәктәбендә 40 баланы туплаган беренче татар классы ачыла. Кайберәүләр өчен бу хәл аяз көнне яшен суккандай тоела. Ләкин әнә шулай итеп булачак гимназиягә нигез салына. Ике елдан соң 2 нче мәктәп 5 нче гимназия итеп үзгәртелә. Мәктәптәге рус класслары, күрше рус мәктәпләренә күчерелә. Бөтен нәрсә ата-аналар, җәмәгатьчелек белән килешеп эшләнә. Монда Мәскәү районы роносы мөдире З. Садыйкованың роле зур булуын әйтергә кирәк. Ул, кайбер роно мөдирләре кебек түгел: яңалыкка омтылган директорга комачауламый, киресенчә, аларга ярдәм итә. Бүген 5 нче гимназиядә 550 бала укый. Ләкин бу да чик түгел. Әле күптәнме, «Ата-аналар балаларын татарча укытырга теләмиләр»,— дип авыз тутырып сөйләүчеләр бар иде...

5 нче гимназиянең педагогик коллективы бөтен республика өчен беренче дәрәҗәдә әһәмиятле проблемалар өстендә эшли. Бу — укучыларда милли үзаң һәм иҗади фикерләү сәләтен үстерү мәсьәләсе. Милли үзаңга ия булганнар гына Татарстаныбызны халыкара аренага алып чыга алачаклар. Хәлбуки, бу гимназиянең эш тәҗрибәсе күпләргә таныш. Мәсәлән, 1993 елда Татарстан мәгариф министрлыгы, Татарстан фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр бүлеге, Татар гимназияләре директорлар советы, 5 нче гимназия базасында, «Укучыларда милли үзаң формалаштыру һәм иҗади фикерләү сәләтен үстерү» дигән темага республика фәнни-практик конференциясен үткәрделәр. 1994 елның май аенда Татарстан фәннәр академиясе, Татарстан республикасы татар гимназияләре директорлары советы инициативасы белән, 5 нче гимназия базасында, «Милли мәгариф: оештыру тәҗрибәсе, тикшеренү проблемалары һәм нәтиҗәләре» дигән темага Халыкара фәнни-практик конференция уздырдылар! Ә «Мәдәни инициатива» (Сорос фонды) Халыкара фонды 5 нче гимназия коллективына зур бүләк (гран) тапшырды. Шул хактагы грамотада бу педагогик коллективның зур, уңышлы тәҗрибә — тикшеренү үткәрүен хуплау турында әйтелә.

5 нче гимназиянең эш тәҗрибәсе байый, бу хакта монографияләр язарга булыр иде. Ә хәзергә андый мөмкинлек юк. Шуңа күрә коллектив үткәрә торган

класстан тыш эшләрнең кайберләрен санап чыгу белән чикләнергә туры килә: укучыларның хореография, театр, әдәбият, музыка секцияләре; фольклор ансамбле; волейбол, атлетика, татарча көрәш, шахмат, радиосөючеләр секцияләре. Мәктәп күләмендә чыгарыла торган стена газетасы, күчермәләр алу юлы белән — классларга таратыла. Этнография музее төзелгән, анда даими рәвештә төрле темаларга багышлап күргәзмәләр оештырыла. Укучылар дөнья мәдәнияте үрнәкләре белән дә даими рәвештә танышып баралар. Кыскасы, республикада 5 нче гимназия коллективы кебек тырышып иҗади эшләүче башка урта мәктәп юк бугай...


Казандагы 2 нче гимназия педагоглары коллективына Татарстанның атказанган укытучысы Камәрия Зиннур кызы Хәмидуллина җитәкчелек итә. Кызганыч, моңа кадәр 2 нче гимназия таркалу, ябылу алдында торган. Чөнки директор итеп эшне белмәүче, эшләргә теләмәүче кешене билгеләгән булганнар. Моннан чыгып шундый нәтиҗә ясарга булыр иде: бу җаваплы чорда, яңа типтагы мәктәпләргә директорларны «Энә күзе аркылы үткәреп» сайларга кирәк. Югыйсә булдыксызлар аркасында, гимназияләрнең абруе төшәргә, укучыларның укуны ташлап китүләре ихтимал. Бу — хакыйкать.

А. С. Макаренко, укыту-тәрбия эшендә уен элементлары булырга тиеш, чөнки ул укучыларның табигатенә туры килә, дигән иде. Моны 2 нче гимназиядә бик белеп, урынлы итеп файдаланалар. Мәсәлән, класс бүлмәләрен «хосусыйлаштыру» бүлмәләрне чиста тотарга, тәртип сакларга нык ярдәм иткән. «Хезмәт биржасы» дигән яңалык та укучылар күңеленә хуш килгән: балаларны файдалы эшләргә тартырга булышкан. Класслар үзара ярышалар, җиңүчеләргә бүләкләр бирелә. Мәсәлән, быел ике класс укучылары бушлай төрле шәһәрләргә экскурсиягә барып кайттылар. Казандагы 15 нче гимназия, Кукмара районының Зур Сәрдек мәктәп-лицей коллективларының укучыларны татар халкы традицияләрендә тәрбияләү тәҗрибәсе шулай ук һәртөрле мактауга лаек.

Һәм соңгысы. Гимназияләрнең, лицейларның киләчәге, язмышы, һичшиксез педагогларга бәйле. Шуңа күрә милли үзаңы үскән, тирән белемле, методик яктан оста булган укытучылар әзерләү — вузларның һәм педучилищеларның, колледжларның изге бурычына әйләнде. Алабуга, Чаллы, Казан педагогия институтларын ел саен йөзләрчә кеше тәмамлый. Әлбәттә, барысы да ал да гөл дип әйтеп булмый. Мәсәлән, ир укытучылар әзерләү эше һаман проблема булып кала бирә. Казан дәүләт педагогия институты (ректоры академик Р. А. Йосыпов) педагогик уку йортлары арасында флагман ролен уйный. Институтта 21 белгечлек буенча 7000 мең студент укый. Чит телләр (инглиз, төрек, кытай, гарәп, һинд телләре) өйрәнүгә зур әһәмият бирелә; үз чиратында бу чит илләр белән экономик, мәдәни һ. б. бәйләнешләр урнаштыруга булышачак. Тагын бер яңалык: берничә факультетта студентлар музыка һәм эстетика буенча тулы курслар үтәләр. Моның әһәмияте шунда: авылларда аз комплектлы мәктәпләр саны шактый. Аларны музыка-эстетика укытучылары белән тәэмин итү кыен: сәгатьләр аз булгач, музыкантлар кечкенә мәктәпләргә бармыйлар. Ә берничә белгечлек алган педагоглар, төп фәннән тыш, музыка, эстетиканы да укыта алачаклар.

Нәтиҗә. Татар халкы мөстәкыйль үсеш юлына басты. Димәк, халык хуҗалыгы өчен күпсанлы белгечләр кирәк булачак. Бу үзе турыдан-туры халык мәгарифенә бәйләнгән. Шуңа күрә Республикабыз җитәкчеләре, киң җәмәгатьчелек халык мәгарифен үстерүгә көчләрен дә, вакытларын да кызганмаслар дип ышанасы килә.

# КОМАНДОР



Авыр, богаулы елларда да без булдык, яшәдек, өмет агачыбызны корытмадык диярга ярый. Хикмәт нәрсәдә? Булды, адәм балалары үзләре теләгән якка чак кына тартылсалар да аларны төпсез упкыннар, һәр тере җанны йотарга ашкынган баткаклар сагалап торды. «Стой! Кая каерыласың? Ни эзләнәсең? Унга-сулга бер адым атласаң—конвой кисәтеп тормый, ата!» Уена иңгән тере сорау-табышмаклар җанында тилмереп җавапсыз кала, син, бичара бөҗәк, винтик, туа-туышканнан бирле вак күзәнәкле җәтмәдә тырпылдыйсың. Баш түбән иелә, бил сына, яшәү кырын үтеп чыкканчы син йомык күнелле бичарага әйләнәсең. Буең кыска, уең биктә, юлыңны исә партия сызып куйган.

Бәхетлемен, Ленин идеяләренең халыкларны бары тик һәлакәткә генә илтәчәген, телләрнең болай барса бетәчәген, большевизмның кешелек тарихына иң кара чорны алып килүен тирәнтен аңлаган, ВКП(б) белән КПССның бернинди акыл белән чикләнмәгән дуамал фәлсәфәсенә баш бирмәгән гаҗәеп кешеләрне тормыш юлымда байтак очраттым мин. Байтак фикердәшләремнең кадерле исемнәрен дөньяга да чыгардым. Бүген сүзем Марсель Хәким улы Сәлимҗанов хакында булыр.

Дөрес, һәр кешегә төрле яктан бәя бирергә була, адәм баласы — күп кырлы табигать могҗизасы. Бүтәннәр Марсельнең башка якларына игътибар итәрләр, кай яктан гына карасалар да аның тормыш юлыннан байтак гыйбрәтләр, хикмәтле мисаллар табарлар. Ул спорт остасы, кылыч селтәп Европаның, Рәсәйнең байтак бәйгеләрендә ут уйнаткан егет, ул Идел-Нократ тирәләрендә дан казанган мәшһүр балыкчы, балык дигәндә аңа тиңнәр юк! Ул галим, дөньяның бик күп тармакларына ерып кереп китеп, мәҗлестәшләрен егып салучы мөназарачы. Ул төн ката керфек какмыйча карта чөеп утыра алучы преферанс остасы. Тәмле ашарга яратучы, ризык кадерен бүтәннәр дә аңларлык итеп сөйли алучы тәмле тамак. Урыс-татар вә дөнья әдәбиятының иң гүзәл мисалларын өзлексез укып баручы, театр сәнгатенең хикмәтен, серләрен бик яшьли күңеленә үткәргән зирәк акыллы ил агасы да ул, хәзерендә тиңдәшсез зур режиссерлык дәрәҗәсенә ирешкән зат, кешелекле, таләпчән педагог, оста, кыю оештыручы, иманын явызларга тоттырмаган гаярь вә тәвәккәл татар да ул.

Сүз-бәяләремнең һәммәсе хак, дөрес, олуг юбилей уңае белән сүз алган зирәк замандашларым, шәт-иншалла, егетләрнең егете, ир-атларның асылы булган Марсель Сәлимҗанов турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирерләр әле. Алай да, Марсель байтак еллар дәвамында минем иң якын дусларымның берсе, әйтергә яраса, караңгы офыгымның кояшы булды. Төрмә-лагерьлар белән

тулып-ташыган, иреккә чыгып илгә кайткач кысылган җаным, аны күргәч, җиңел сулап куйды. Казаныма кайтып төшкән мәлләрдә мин бераз югалып та калган идем! Кая карама — кызыл авызлар, телләрдә ялган вә ялагайлык, һәркем кыеп сүз әйтердән элек партия күрсәтмәләрен ачып карый, гәҗит-журналларның баш мәкаләләренә табына иде. Төрмә-лагерьдагы рухи хөрлекләрдән соң Казан һавасы тынны кыса иде әле. Ничек килеп чыккандыр, башлангычы хәтердә калмаган, бер-ике очрашуда ук мин аны үз иттем. Хәтеремдә, әле аның да эзләнгән, ныгып килгән яшь чагы иде. Тирә-ягымдагы байтак кошлар, бигрәк тә җитәкче саналганнар, миңа бераз шикләнеп, сагаеп караганда, ул «во весь голос» үзенең кемлеген, иманын, тоткан мәсләген, илгә-көнгә мөнәсәбәтен ачып салды.

Марсель — тормышның бөтен якларын аңлаган, коммунистлар партиясенең илгә күпме бәла-каза, җәбер-җәфалар өйгәнен дәлилле белүче, илебездә кеше хокукларының кысылуын ап-ачык күрә алган, чын кешелек сыйфатларына ия булган гуманист шәхес. Мондый кискен хөкем-фикерләр җанда ялгыз гына яши алмыйлар, көч көчне эзли, хөрлек таләп итә алган бөтен күңел үз ишләрен табарга тырыша. Марсельнең миңа кадәр дә ышанычлы, төпле фикердәшләре булгандыр, без очрашканда ул әзерлекле, кыю, үз халкының чын улы иде инде. Ул минем эзләнгән, соңга калыбрак өлгергән рухымны ныгытты, үз-үземә, иҗатыма ышанычымны арттырды. Уйларыбыз бер булды, без бер үк әдипләргә, сәнгать әһелләренә табындык. Мәсәлән, Василий Макарович Шукшинның вакытсыз вафатыннан соң ул миңа: «Соңгы вакытлардагы иң авыр үлем бу!» — дип шалтыратты. Безнең арадашлык сүзләрдә генә калмады. Марсельнең мөмкинлекләре күбрәк булгандыр, ахрысы, ул миңа ул заман өчен үтә кадерле китапларны биреп торды. Александр Солженицынның «Роковый корпус»ын мин аның җылы кулыннан алдым. Бу әсәрнең беренче варианты бездә зур теләктәшлек уятып, без Олег Костоглотов язмышына бәйләп, тормыштагы гыйбрәтләрне табып, дөньяның бик күп каршылыклы мәсьәләләрен чишә торган идек. Антонов-Овсеенконың дөньяны тетрәткән мәшһүр «Портрет тирана»сын да мин аннан алып укыдым. Антуан де Сент Экзюперинең фәлсәфи уйларын, фәнни карашларын эченә алган «Цитадель» әсәрен дә без бер вакытта укыдык. Китапны миңа Марсель табып бирде.

Шул чакта ук, әле Сәлимҗановның сәнгать биеклеге расланып кына килгәндә, тоткан юлын, мәсләген, кем мәнфәгатен кайгыртканын дөрес шәйләргә була иде! Ул үз фикерләрен кыю рәвештә күпкырлы эшчәнлеге белән раслый килде. Чуар, кысынкы еллар дәвамында да бу рухы үтә көчле, иманы бөтен адәм милләтебезнең олы улы булып китте, аның баһадирына, халыкка көч бирерлек шәхескә әйләнде. Татарны төрле тарафтан камап-эләктереп, тәмам изеп бетерергә йөз тотканда, ил хуҗасы булып утырган акыллы, көчле Табеев татар әдипләрен җыеп: «Нәрсә юкка көчәнеп маташасыз инде, татарларның егерме еллык гомере калса калгандыр!» — дип милләткә инкыйраз юраганда, татар театры биек мөнбәрле университет, якты белем учагы булып кала бирде. Әгәр дөньяның дүрт тарафын аңлаган татар улы Сәлимҗанов дилбегәне үз кулына алмаса, театр Михайловлар кулына төшеп, сәхнәбезгә большевистик курчаклар мәңгелеккә менеп утырачак иде.

Театр — татарның җыелу, аң-белем алмашу урыны да ул. Безнең бердәмлекне күрсәтә торган иң мөкатдәс ике мәйданыбыз гына бар. Берсе аның Сабан туе мәйданнары, икенчесе театр сәхнәләре. Марсель Сәлимҗанов татарларны театр тирәсенә туплый алды, дибез икән, без артистларны гына түгел, тамашачыларны да истә тотабыз. Марсель — тамашачыны театрга якынайту, туплау, аның ышанычын югалтмау өчен әллә ничә тармакта эш башкарды. Шуңа барып җитте ки, моны аерып, басым ясап әйтергә кирәктер! Театрларның ишек өстендә «Уналты яшькәчә балалар кичке спектакльләргә кертелмиләр» дигән кисәтү эленеп торса, Марсель Сәлимҗанов академия театрына хуҗа булып килгән көннән башлап, ишек катына басып, әле яңа тәпи йөри башлаган татар бала-чагаларын, үсмерләрне елмаеп каршылап, башларыннан сыйпап, тамашага килүләре өчен рәхмәт әйтеп торды. Җылы баш түбәләрендә дәү бер абыйның кайнар учын тойган балалар бүгенге көннең иң актив, иң аңлы, иң әзерлекле милләтпәрвәр тамашачылары түгел дип кайсыбыз әйтә ала?

«Марсель Сәлимҗанов — егерменче гасырдагы иң абруйлы милли каһарманыбыз», — дип, бүген, юбилей уңае белән генә кабатламыйм. Татарстан җирен талаган, мал-мөлкәтне юк бәягә дөньяга таратканнары өчен Татарстанның «курчак хөкүмәте» тарафыннан макталып, Рәсәй «Алтын йолдыз»ын түшләренә кадап, макталып йөргән зур түрәләр заманында ук академия театры сәхнәсеннән халыкка бу фикеремне җиткергән идем.

Табигатьнең серле, көчле яклары бар. Ул бушлыкны яратмый, вакытын белеп кенә, иң зарур чагында милләт улларыннан берничәсен сайлый, аны күз уңыннан ычкындырмый, гел-гел аңа ярдәм итеп килә. Милләт улларыннан, милләт каһарманнарыннан башка халык бөтен булып, бер булып бер чорда да яшәмәгән. Табигатьнең кодрәте белән Марсель үскән, ир узаманы, акыл иясе булып ныгыган. Әти-әнисе, туганнары, якыннары, фикердәшләре, чордашлары аның юлын турылап көч биреп килгәннәр. Югыйсә, Марсельнең гадәти бер бушбугаз, кызыл авыз булып китәргә җай бик булган лабаса!

Ул 7 ноябрьдә туган. «Бәйрәм шау-шуы, кызыл әләмнәр, демонстрацияләр минем туу шәрәфенә уздырыла дип, байтак еллар ышанып йөрдем әле мин!» — диде Марсель берзаман. Революцион Марсель шәһәре, ул заманнарда күкләрне тетрәткән «Марсельеза» җыры... Бу уйларның гомергә дәвам итү мөмкинлеге булган ич! «Октябрьдә туганнарның Ленин була бабасы».

Бәхеткә күрә, Марсельнең бабасы бер чакта да Ленин булмады... Мөхтәрәм Хәким аганың әткәсе Йосыф — Әтнә ягы Бәрәскә авылы кешесе — җир эзләп, киңлеккә зарыгып Орск ягына чыгып китә. Елгыр, намуслы егетне Яушев байлар эшкә алалар, кибет, сату-алу эшенә өйрәтәләр. Казакъ арасында тире-яры җыя Йосыф, хуҗалары алдында абруй казана, эшендә сеңә, ныгый, өйләнеп җибәрә. Алар, җәмәгате белән (урыннары оҗмахта булсын, ярабби!) сигез бала үстерәләр. Төпчек уллары Хәким аерата елгыр, житез, һөнәргә-белемгә әвәслеге белән аерылып тора. Кибеттә йомышчы малай була, бик яшьли кул арасына керә, татар мәдрәсәсендә күркәм белем ала, бер очтан урысның «церковно-приходская школасын» да тәмамлап куя. «Урыс арасында сәүдә иткәч, телне белү зыянга булмас»,— дип исәпли Бәрәскә татары Йосыф.

Орскига драматург Мирхәйдәр Фәйзи килеп төшә һәм шәһәр тормышын кайнатып, кайнарлатып җибәрә. Сәнгатькә тартылучы яшьләр аның тирәсенә тупланып спектакль куялар. Яңа дөнья, икенче тормыш башлана! Шәһәргә татарның бөек улларыннан берсе Габдулла Кариев килеп китә, яшьләргә аның йогынтысы да гаять зур була. Хәким Сәлимҗанов бу хәлләрнең уртасында була, аралаша, мәшһүр татарлар елгыр егет күңеленә тәүге бәрәкәтле орлыкларны чәчеп китәләр.

Аллаһе тәгалә инде моннан ары егетне күзеннән ычкындырмый, аңа яр булырлык кызны да әзерләп куя.

Бәрәскә тирәләреннән Орскига Йосыфтан да элегерәк күченеп, шунда төпләнеп, ныгыган татар гаиләләре байтак була. Арадан берсе, Нигъмәтулла исемлесе, тиз арада үз тырышлыгы, бетмәс-төкәнмәс көче белән «Беренче гильдияле купец» дигән абруйлы дәрәҗәгә ирешә. Нигъмәтулла гаиләсендә дә сигез бала үсә. Китапханә салдыра Нигъмәтулла, Хәким-егет китапханәгә йөри, татарчасын укый, урысчаны да су кебек эчә. Нигъмәтулла оясында төпчек игезәкләрнең берсе, Галия исемлесе, үзенә яр булыр дип уйлап та карамый. Ниһаять, Тәңре кушуы буенча, Хәким белән сылу Галияне Казан, туган яклар тартып кайтара һәм алар татар театр техникумында очрашалар. Егерме дүртенче елда өйләнеп тә куялар. Мәшһүр Казан артында, татарның бәгырь үзәгендә тибеп чыккан чишмәләр, әллә никадәр көчеш, сикерешләр ясаганнан соң, борылып үз төбәкләренә кайталар. А-а, аларны кемнәр каршылый, кемнәр дәрес бирә, нинди якты, олы затлар аларга акыл өләшә! Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшевләр! Алар шушы пәйгамбәрләр, Хәким белән Галиянең кырын бәрәкәтле, шифалы дым белән сугарып кына калмыйлар, алардан туачак малайга да якты, игелекле юл сызалар. Ту, үс, ныгы — татар дөньясы талантларга һәрвакыт мохтаҗ!

Сәнгать тарихында күренекле урын алган В. Бебутов академия театрында А. Островскийның «Котырган акчалар» пьесасын куя. Сәхнәдә татар күгенең ахак йолдызлары: Ф. Ильская, Х. Әбҗәлилов, Г. Шамуков, Ш. Әсфәндиярова...

Театрга терәлеп торган янәшә йортта яшәүче Марсель-малай репетицияләрдән чыкмый да диярлек, кайчан карасаң да аяк арасында урала. Театрны ярата, актерларны ошата, тик бер дошманы бар, ул — режиссер! Инде кызып кына уен башлана, режиссер дигәннәре уенны туктата да, нидер сөйли, «акыл сата». Малай уенны бүлгәннәре өчен режиссерны пыр туздырып та ташлый. Аны вәжгытып залдан куып та чыгаргалыйлар.

Хәким белән Галия, татар сәхнәсенең шөһрәтле актерлары булып китсәләр дә, Марсельнең театрга тартылуын хупламыйлар. «Нигә» дигән сорауга җавап үзеннән-үзе табылып тора. Утызынчы, кырыгынчы елларда ил өстендә котырынган кара давыл күпме сәнгать әһелләренең башын кыймагандыр, санап бетергесез! Сизгер ата улын шул хәвефле хәтәр юлдан аеп алып калырга теләгәндер,

мөгаен. Улының юрист булуын теләгәндерме-юкмы Хәким ага, Марсель урта белем алгач университетның юридик факультетына укырга керә. Укый, инде тәмамлыйм, диплом алам дигән елны, Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы билгеләнә. «Король Лир»ны әзерли башлыйлар. Мәһабәт гәүдәле, көчле, кылыч селтәү остасы Марсельны да уенга чакыралар. Сугыш сәхнәләренә катнашып китә Марсель һәм сугышчы актер сыйфатында Мәскәүгә үк бара. Мәскәүдә шул елларда Марсельның яшьлек дусты Празат Исәнбәт укып ята, ГИТИСта. Декада вакытында алар көне-төне диярлек бергә булалар, тыгыз аралашалар. Празат — мәшһүр драматург Нәкый Исәнбәт улы! Празат Марсельгә бер үгет бирә: «Ташла юристлыгыңны, кер ГИТИСка укырга. Режиссер бул!» — ди.



*Әтисе — Сәлим Хәкимҗанов белән.*

Үз вакытында әйтелгән акыллы киңәш тә еш кына адәм улларының юлын һич көтелмәгән якка борып җибәрә ала. Мәскәүдә уку белән кызыктыра Празат Марсельны, меңнәрчә тере мисаллар китерә.

Декада шаулап-гөрләп бара һәм татарның ул чактагы талантлы актеры, халык-тамашачы мәхәббәтенең тәмен татыган Рифгать Бикчәнтәев: «Сәхнә лабиринтына бер килеп кергән кеше аннан бер чакта котылып чыга алмый. Син каптың инде, Марсель!» — дип дусларча юрап куя.

Кирәк бит, Рифгать Бикчәнтәевнең сүзе фәрештәләрнең «амин!» дигән чагына туры килә, Марсель дипломын да алып тормый (хәрби лагерьга барып, сугыш фәне буенча имтихан биреп йөрми!), ГИТИСка укырга керә. Театр дөньясын күргән, ата-анада яхшы тәрбия, үз тирәләрендәге затлы зыялылардан эзлекле белем алган Марсельны берсүзсез укырга алалар һәм ялгышмыйлар.

Театрлар Марсельның сәләтен тиз чамалыйлар, аннан да, моннан да эшкә чакырулар ява, Марсель ары-бире карана, төрле театрларда спектакльләр куя, әмма Бәрәскә каны аны татар мәркәзе Казанга алып кайта. Яшь тамашачылар театрында режиссер була. Гыйбрәтле спектакльләре белән Казан яшьләрен театрга тарта.

Хөр фикерле, үзсүзле, дөньяга карашы инде ныгыган, коммунистлар партиясенең төсен, исен аңлаган Марсель партиягә керү турында уйлап та карамый. Әмма, баш режиссер хезмәтенә алынгач, четерекле бер хәл туа. Җыен талантсыз, шакты-шокты актерлар, кызыл билетларына ябышып кына батмыйча яшәп ятучылар, җыелалар да бикле ишекләр артында карарлар кабул итеп дөнья, эш белән идарә итеп яталар. Ә баш режиссер, таулар күчереп эшләүче зат, коридор-

да йөри. Язучылар арасында да шул «тамаша»ны күзәтә идек ләбаса! Съезд җыела, сүзләр куера, карар кабул итәбез дигәндә, «партгруппа» дигән төркем аулакка керә дә бикләнә. Партиясез «Мескеннәр» карар көтеп әкрен генә кулуарларда йөри торалар. «Мескеннәр» дигәне кемнәр була инде, күрик: Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Атилла Расих, Шәриф Хөсәенов, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев...

Ничарадан-бичара Марсель Сәлимҗанов та «кызыл пропуск» тотып югары дәрәҗәдәге җыелышларга йөри башлый. Сүз озынга китә, югыйсә партия конференцияләрендә ул күрсәткән «гыйбрәтләрне» бик күп язып булыр иде. Кайберәүләре Марсельнең җитмеш, сиксән еллыкларына калсын...

Алтмышынчы еллар уртасында Марсель Сәлимҗанов татар академия театрына эшкә кайта һәм озакламый баш режиссер итеп билгеләнә. Ул шушы утыз еллык эш дәверендә сиксәннән артык спектакльне дөньяга чыгарды. Аңа кадәр театр сәнгатендә якты урыннар яулаган фидакярларьне һич кимсетмичә, Марсель Сәлимҗановның татар театр сәнгатен яңа бер биеклеккә күтәрүен авыз тутырып әйтергә кирәк. Заманны аңлаган, бүгенгене генә түгел, киләчәкне дә күз уңында тота алган олы шәхес кенә юлын туры билгели ала һәм ниләр генә булып үтсә дә юлыннан тайпылмый. Әйткәнемчә, татар театры — милләтне яклау, телебезне саклау җәһәтеннән иң ышанычлы көч булды. Дөрес, Марсель эшләгән чор чуар һәм катлаулы иде. Бер яктан сөремле цензура бугазга ябышып торса, икенче яктан аңа бәхет тә елмайды. Инде мәңгегә югалды дип саналган К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Г. Ибраһимовлар татар сәхнәсенә китмәскә әйләнеп кайттылар. Сәхнә корифейларының әле җир селкетеп яшәгән чаклары иде: Н. Исәнбәт, М. Әмир, Р. Ишморат кебек өлкән каләм осталары янына Х. Вахит, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, С. Шәкүровлар килеп кушылды. Аларның эзенә баса-баса Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Батулла, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ф. Садриевлар сәхнә төрләрен яулап алдылар. Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллиннар Марсель Сәлимҗановның иҗади мөмкинлекләрен ачарга төп ярдәм итүчеләр булды. Уртак иҗат нәтиҗәләре һәркайсы өчен бәрәкәтле чыганак иде.



*Менә шулай, туганнар...*

Театр — дөньяның йөрәк тибешен тикшереп торучы, һәр сәгать, һәр минут эшлекле хәрәкәттә яшәргә тиешле гаять зур көч ул. Милләт яшәешенә театр кадәр көч өстәгән бүтән бер хәрәкәт бармы икән? Театрны хәрәкәткә китерер өчен сәләт, көч, белем, үз-үзеңне аямау, халыкка тәмам бирелгәнлек, барыннан да бигрәк саф, нык иман кирәк. Әйтик, егерменче, утызынчы елларда язылган пьесаларны бүгенге көннең иркә, чак кына бозылган тамашачысы кабул итәрлек


дәрәҗәдә куя алу — аерым бер сиземләү, кодрәт, чиксез талант таләп итә. Мәшһүр «Сүнгән йолдызлар»ны Марсель өр-яңадан укыды, моңарчы ачылмаган дәрт-дәрманнарны берәм-берәм эзләп тапты һәм элегеррәк «күз яшьләренә манчып» кабул ителгән пьеса, катлаулы, фикерле, дәһшәтле трагедия булып яңгырады.

Урыс режиссер-педагогларының, Марсельның остазларының үз иҗат алымнарына тәэсире зур булуын да искә алырга кирәк. Андрей Михайлович Лобановның, Андрей Александрович Гончаровларның үзен рухи бөтенлеккә китергән бәрәкәтен Марсель гомере буе рәхмәт хисләре белән яд итә. Талант бөеклеге реаль көчкә әйләнсен өчен адәмнең тәкъдир сайлап алга чыгарган уллары кемнәрдән генә шифалы көчләрне кабул итмиләр?!

Гайрәтле, мөккәмәл иҗат көченә ия булыр өчен Марсель бөек талантлардан өйрәнә. Сатира театрында А. Островскийның «На всякого мудреца довольны простоты» пьесасын атаклы режиссер һәм гражданин А. Эфрос сәхнәләштерде. Эфрос мәшһүр драматургны үзенчә укый, көтелмәгән иҗат мөмкинлекләре таба һәм нәтиҗәдә бу «искраметный, озорный спектакль» Марсель күңелендә мәңгелеккә урын ала. Аның Островскийга мәхәббәте шул көннәрдән килмимени?!

Үткәннәргә карап, бүгенге күпсанлы иҗади мисалларга таянып, Марсель Сәлимҗановның татар театр сәнгатен дөнья югарылыгына күтәрүен билгелибез. Аның иҗади ысулларының серләрен, әйдә, белгечләр ачсын. Мин аның халыкка күрсәткән хезмәтләренең бер-икесен генә аерып алам. Марсель, кара көчләр төрле яктан һөҗүм иткәндә дә, татар театрының милли йөзен саклап кала алды. Бик күп театрлар буп-буш заллар, салкын сәхнәләр көненә калганда да безнең театрлар тамашачыларын югалтмадылар. Милләтебезне, туган телебезне саклап калуда аларның хезмәте бәя биреп бетермәслек зур. Әгәр бүген атаклы Кабан күле ягасында, киләчәккә илтүче җилкәннәрен киереп күтәргән театрның яңа бинасы балкый икән — без монда да Марсель Сәлимҗановның ихтыяр көченә бурычлы.

Зиһенле укучы хәтерлидер: Советлар илендәге мәгънәсез борылышларның берсендә, мәркәзебездә башланган байтак зурурый төзелешләрне шып туктаттылар. Шул җөмләдән Академия театры өчен яңа бина салу да тыелды. Марсель Хәким улы тәкъдиме белән ашыгыч рәвештә чаң кагылды. Мәскәүдән Г. И. Усманов кайтып төште, аның катнашында җыелыш җыелды. Кызыл авызлар шушы мәгънәсез карарны хуплап утырганда Марсель сүз ала һәм кайнарланып, кызып, ярты сәгатьлек нотык тота. Уннарча дәлилләр китерә, «совет власте елларында театрларга багышлап әле бер генә бина да салынганы юк!» Тәки ышандыра җыелган халыкны, җиңә, җыелыш: «Театр төзелешен туктатмаска!» — дигән мөһим карар кабул итә. Ул арада Чаллыярдан Рәис Кыям улы Беляев кайтып төшә, ике дус — Марсель Хәкимович белән Рәис Кыямович, төзелешне үз кулларына алалар.



*Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасы.*

Режиссер буларак, Марсельнын үз стиле, үз карашы, үзе эзләп тапкан, үзе көч биргән кагыйдәләре бар. Һәр спектакль — янадан туу ул.

Репетицияләргә керешкәндә анын кулында азагынача уйланылган, ныгыган план булмый диярлек. Анын еш кабатлый торган бер сүзе бар: «Спектакль как птица, ее надо лепить на лету». Эш башлаганда әле тышкы формалары гына шәйләнгән спектакль сәхнәдә, катнашучылар белән берлектә туа. Марсель «театр — фикердәшләр берлеге» дигән уй белән бер чакта да килешмәде. Анынча, «театр — шәкертләр берлеге, нигез, тамырлар бер булганда, максат берлегенә дә ирешелә».

Ат чабышын, татарча көрәшне ярата Марсель. Үзе дә көрәшә, әмәлләрен белә. Бервакыт, Идел буендагы бер җәйләүдә ул якын туганы, һөнәре буенча тимерче булган Булат белән бил алышты. Булатнын авырлыгы, ай-һай-һай! Центнердан артык. Алышалар болар, берзаман күрәм, Булатнын алып гәүдәсе болытларга тиярдәй булып күктә йөзә! Аннары — гөрс! Җир тетрәде...

Марсель — куркусыз. Пермьда РСФСР театрларынын репертуарын тикшерергә җыелдык. Матур гына тәмамладык, китәр юлга чыгып вокзалга төштек. Без шактый «җылынган», вокзалда хуҗа булып таза бер бәндә йөри. Теләсә кемгә бәйләнә, бер-ике кешенең муен тамырына да кундырып алды шикелле. Буйга Марсельдан озын, беләкләр,— гөбе, аяклар — бүрәнә. Бер эндәшә аңа Марсель, ике... Тынмый гына теге бәдбәхет! Андый чакта блатнойлар, хулиганнар: «Әйдә, чыгып керик әле!» — дип урамга чакыралар, янәсе, кеше күзеннән читтә арт сабак укытмакчылар. Марсельнын кыяфәт килгән, ике-өч тапкыр кисәткәч, тегенә әйтеп салмасынмы: «Әйдә әле, чыгып керик!» Тынды теге әзмәвер, коерыгын бот арасына кысты... Диван башына сеңде дә теш арасыннан гына: «Син ничә клиндер ашадың?» — дип сорады. «Төрмәдә ничә ел утырдын», — дип соравы иде. Клиндер ашамаса да, Марсель сүзе, күз карашы белән жиргә сеңдерде тегене...

Без авыр бер чорны үткәрдек, хәзер — хатирәләр заманы. Биографияләре сыек җаннар әй талпынган булалар, юк-бар тормыш юлларыннан вак-төяк чүпләп үзләрен әллә кемгә куярга маташалар. Аю тиресен бүлгәндә аюны урманнан куып чыгаручы куяннар хәзер хәтсез булды, алар, көн туса, ишәя торалар. Сүзләр белән уйнамаска кирәк, булмаганны булды, дип раслап шөһрәт казанунын кемгә кирәге бар?.. Эшең булсын, эшең! Куйган хезмәтең булсын!

Марсель Сәлимҗановка — алтмыш яшь. Кабан күле ярында мәгърур татар театры бар. Халыкка ничә еллар тугры хезмәт иткән асыл ир Марсель Сәлимҗанов бар. Ул үзенең шәкертләре белән халык рухын саклау юлында нык тора.

Марсель Сәлимҗановка «КОМАНДОР» дигән дәрәҗәле исемне мин түгел, адашы Марсель Галиев бирде. Романтик хисләр белән эретелгән, урта гасыр рыцарьларынын житәкчесеннән калган бу янгыравыклы исем миңа искиткеч ошады. Татар халкы бәхетле, анын яшәешен бизәп торучы олуг зат «КОМАНДОР» МАРСЕЛЬ ХӘКИМ улы СӘЛИМҖАНОВ бар. Аңа бүген алтмыш яшь. Алтмыш кына әле!..

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ.**

# ШАМИЛ УСМАНОВ КӨНДӘЛЕГЕ

*... Кулга көндәлек эләкте.,Алдым. Язасы килә. Киләчәккә документ җыясы килә. Көндәлек эш үтә дә китә. Ә бу бит җанлы документ булып кала. Үземә булмаса, әйдә, бер яшь язучы файдалансын.*

Шамил УСМАНОВ



...Егерменче елларда Шамил Усманов исеме татар мәдәнияте күгендә якты бер йолдыз сыман балкып алды. Ә инде утызынчы еллар ахырында бу шәхес, әле үз хыялларының яртысын да чынга ашырмаган килеш, Сталин төрмәләренең берсендә әрәм булды.

Ул кара еллар турында безнең матбугатта инде аз язылмады. Утызынчы елларның дәһшәтле атмосферасы хәзер татар укучысына да яхшы таныш. Шуңа күрә, әтием кулга алынгач ике кәрҗин кулъязмаларның элеккеге хатыны тарафыннан ни өчен юкка чыгарылуы бик аңлашыла. Чөнки һәркем үз башын сакларга теләгән. Ә бит анда бүгенге көн кешесе өчен кызыклы нинди генә әсәрләр булмагандыр?! Әтием, кайнап торган вулкан сыман, бик тә актив тормыш белән яшәде бит. Аны кулга алган чагында төзелгән әйберләр исемлегендә менә мондый юллар бар: «дәфтәрләр һәм кульязмалар — 36, блокнотлар — 14, төрле кәгазьләр салынган папкалар — 23».

Әмма һәр заманда да, куркак кешеләр белән бергә, батыр йөрәкле шәхесләр дә була. Артык шаулап йөрмәсәләр дә, андый кешеләр дөреслекнең бер мәл өскә чыгачагына ышаналар һәм киләчәк өчен үз кулларыннан килгәннең барысын да эшлиләр. Халыкның кадерле рухи хәзинәләре әнә шундый көчле рухлы шәхесләрнең иман ныклыгы аркасында сакланып кала, алдагы буыннарга барып ирешә.

Шамил Усмановның туганнары Абдрахман белән Йосыф та ул дәһшәтле дәвердә үз башлары киселүдән курыкмаганнар. Хәзер укучыга тәкъдим ителә торган менә бу көндәлекне алар саклап калганнар. Көндәлектәге язулар гарәп хәрефендә иде — аларны хәзерге язуга Абдрахман абый күчерде. Аның авыр туфрагы җиңел булсын!

Менә безнең алда коңгырт коленкор тышлы берничә дәфтәр. Аларда Шамил Усмановның 1924—1930 еллардагы кызыклы һәм гыйбрәтле тормышы шактый ачык чагылыш таба. Ә аннан соңгы көндәлекләр әлегә табылмады. Алары кайдадыр ята микән, әллә инде теге елларда юк ителгәнме? Бу сораулар әлегә җавапсыз кала.

Язучының кызы
Айсылу УСМАНОВА-САГАЙДАК

13/IV—24 Гаскәри мәктәп комиссарлары һәм командирлары өчен ачылган бер ай ярымлык курс-конференциядә конферент булып лекцияләр тыңлап киләм. 1914 елда ремесленное училище партасы артыннан торганнан бирле бу ун ел эчендә бер генә мәртәбә тәртипле рәвештә укырга керешүем. Моңа кадәр бер җирдә дә укыганым юк иде.

Хәер инде, парта артында укымаганга карап, ун елны бер дә файдасызга үткәрдем дияргә ярамый. Мәктәп партасыннан төшеп тормышка атлаганнан алып, бу көнгә кадәр укып килдем. Тормышның үз китабы миңа һәрвакыт ачык булды. Ә ул китапны укырга мин ярата идем.

«Хөсәения»нең рөшди сыйныфын бетерүгә, миңа яхшы бетерүчеләрдән саналуым аркасында, мәдрәсә стипендияләреннән теләсәм кайсын сайлап алырга юл бар иде. Гимназия, реальное, коммерческое училище, Төркия мәдрәсәләре, ахырында ремесленный училищеларга стипендияләр бар иде. Мин соңгысын алырга булдым. Әтием дә аны яклады.

Машинист, кузнец, слесарь балалары арасында мастерскойда үткәргән дүрт ел файдалы булды. Эшче тормышына якынайтты. Училищены бетереп чыккач, инде мин үземне эшче гаиләсендә итеп сизендем.

15/IV—24. Татарстанда хөкүмәт алмашынуы бара. «Уңлар» төшерелеп, «суллар» утыралар. Күптән түгел генә мин үземне «уң» санап йөри идем. Әмма дөресендә ул группа белән күптән инде идейный берлек юк. Күбесенчә урын өчен тартышкан, пролетариат идеологиясенә ят булган чиновниклар белән бер уйда булуым кыен иде, әлбәттә.

«Суллар»га килгәндә, аларның тоткан юлларының дөреслеге хәзергә әле «уңлар»ны тәнкыйть итүләре белән генә беленә. Хәзер эш башына утырып баралар. Карап карыйк. Алар да «уңлар» төсле чиновникланып китмәсләрме икән?.. Ни булса да, бу алмашыну яхшыга булыр дип уйлыйм.

16/IV—24. Бүген Казанга китәм. Курсантларны җәйге тәгтыйлга (ялга) озатасы бар. Яңа хөкүмәткә школа турында доклад бирәсе бар.

...Юлда язам. Һәрвакыт шул йомшак вагонларга утырганда үзенең көрәше белән 18 нче ел искә килеп төшә. Ул вакытның да зур өлешен мин вагонларда үткәрдем. Әмма хәзерге төсле билгеләнгән бер вакыт, тыныч, әмма эч пошыргыч тыныч обстановкада йоклау белән түгел. Ул вагонлар барысы да штаб вагонлары иделәр. Шунда төрле наступление, чигенү мәсьәләләре хәл ителә торган иде. Шул вагонларга карап мин отрядым белән Оренбург тимер юлы буенда казак күзәтеп йөрүемне, 36 нчы разъезд янында үткәргән онытылмаслык вакытларны искә төшерәм.

18 елның 18 декабрендә безнең группа белән Дутов гаскәренең «Мертвые соли» төбендә соңгы сугышы булды. 30 градустан арткан суыкта кич сәгать 5—6 дан башлап иртәнге уңнарга кадәр ачык кырда үткәргәннән соң, авылны алып, Дутовның иң яхшы полкларын ваттык. Кич белән тагын да тревога булды. Төн белән генә түгел, җан белән дә өшегән, арган көенчә мин мөселман комиссариатының купесына килеп кердем. Мәҗрухлар белән тулган вагон мин килеп керүгә җәннәт төсле күренде.

Хәзер купега кергәндә шул минутлар искә төшә.

20/IV—24. Бу Казан күңелдә нинди нык урнашып калган! 20 көн аерылып торганда сагынылган үзе. Әлбәттә, аның кәкре, ватылган урамнары, ящиккә ошаган тәбәнәк өйләре түгел. Мине тарткан нәрсә — аның «Октябрь», «Сулфы», диспутлары, кайнап торган әдәби тормышы.

1/V—24. Көн буе демонстрацияләрдә йөреп үткәрдем. Гаскәри парад булмады. Безнең ВПШ колонналары арасында... подшефный булган Мейерхольд театрының эшчеләре һәм артистлары бардылар (башларында Мейерхольд үзе). Ленин кабере янына уздык. Калинин, Буденный, башкалар тәбрикләделәр. Демонстрациягә катнашучыларның санын белү мөмкин түгел иде.

Бу бәйрәмнең беренчесен 17 нче елда мин Сызраньда каршы алдым. Вокзал мәйданында митингка җыелган ун меңләрчә солдатлар арасында трибунага чыгып «Бетсен сугыш!» лозунгсын аттым. Әле яңа фабриктан килүем иде. Күп халык арасында беренче мәртәбә сөйләргә чыгуым булганлыктан, йөрәк нык тибә иде. Чыгышым көтмәгәндә артык уңышлы булды. Халык безнең якка ауды.

Икенчесен 18 елда Казанда очраттым. Үземнең Сызрань партизаны отряды белән обмундирование алырга килгән идем.

19 нчы елның Беренче мае да Казанда үтте. Колчак Чистайны алган, Лаеш янында тора. Шәһәрдә һәр сәгать восстание көтәләр. Братская могилада булган митингка безнең 1 татар полкы икс мең кешедән артык составта җыелып барган иде. Сафлар тәзеклектә беренчелек күрсәтте. Мин брәдәрләр

зыярәтендә трибунага чыгып сөйләдем. Кич белән полк циркта вакытта бригада командиры Ибраһимов миңа срочный хат җибәреп 2 нче армиянең минем өстемнән донос ясаганнарын, Малютинның мине атарга теләгәнен белгерде. Мин игътибарга да алмадым. Кәеф күтәренке иде.

...Менә бу сигезенче бәйрәмем инде, Мәскәүгә туры килә. Кич белән Мейерхольд исемендәге театрда Красная Пресня районының җыелышы булды. Луначарский эчке һәм тышкы хәлләр турында доклад ясады. Мин ул кешене күп күргән булсам да, сөйләгәнен ишеткән юк иде. Матур сөйли икән. Җыелыштан соң «Лес» уйналды. Уен башлар алдында театр ложасына Клара Цеткин килеп керде. Халык озак алкышлады. Чәчләре агарган бер карчык. Бу кадәр каты алкышлар астында аптырап калдымы инде дисәм, ул көләч йөз белән: «Яшәсен беренче май!» дип кычкырып тагын да «Ура!» яңгыратты.

14/V—24. Бүген Казанга китәм. Курслар ябыла. Кичәдән бирле утырып Сызраньдагы революция айларын язарга керешәм. Канлы, кызу, авыр көрәш елларында минем яшьлек, кешенең гомерендә бер генә килә торган революциямдә үтеп китте. Хәзер миңа 27 нче яшь... Ләкин алда әле күп якты бар. Алдагы көрәшләр миңа киредән яшьлек, көч, шатлык вәгъдә итәләр.

Мин хәзер әдәбият мәйданында көрәшкә хәзерләнәм. Берничә язган әсәрләрем бар, татар әдәбиятында шулар белән әлегә бердәнбер диярлек ярый пролетариат язучысы булып саналып торам. Ләкин бу мине шатландырмый. Үземнең күп нәрсәгә көчем җитмәгәнне белә торып та «иң беренче» булу яхшы булганлыктан түгел, бәлки башкаларның миннән артка калганнарыннан килә... Бер исем алынган икән, аны тиешенчә күтәрә белергә кирәк.

18/V—24. Лагерьда торам, Ул Кабан артында җәелгән. 15 енда Тоцк дигән җиргә китәбез. Бу арада күп кенә эшләр бетерергә ният.

30/V—24. Кичә «Октябрь»нең (иҗади берләшмә) җыелышы булды. Сәрим Фәхри, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Кадыйр Гайнан, Мөҗаһит Мохтасар, Шәфикъ Салават, Ф. Әсгатьләр килгәннәр иде. ...Югары Кабан күле буенда җыелыш ясадык. «Октябрь»нең декларациясен кабул иттек. Кичә кич буе киләчәктәге эшләрнең планын корып яттык. Минем башта «Октябрь»ны бер әдәби генә түгел, идеологически көчле бер яшьләр төркеменә әйләндерү планы бар. Шуны әйтүгә егетләр барысы да кәефләнде.

3/VI—24. Бүген сәгать өчтә театральный техникумда «Октябрь» исеменнән әдәбият хакында доклад ясадым. «СУЛФ» яклылар бер дә каршы чыга алмадылар. Шимбә көн рабкорлар җыелышында мәркәз коммунистлар клубында доклад ясыйм.

7/VI—24. Коммунистлар клубында «Октябрь»нең әдәби диспуты кичәсе булды. Мин «Октябрь»нең платформасы» дигән мәүзугта доклад ясадым. «СУЛФ» турында ахырда гына бер-ике сүз белән чәнчеп үткән идем. Малайлар ярыла яздылар. 19 нда җомга көн җавап бирер өчен үзләрендә кичә ясыйлар.

13/VI—24. Шул шәһәрнең тузанлы, әмма җанлы урамларында кичке салкында йөрүнең особый ләззәте бар. Монда мин үземне киләчәкнең музенда йөргән төсле сизәм.

19/VI—24. 14 ндә Рабочий клубта татар студентларының озату кичәсе булды... Концерт-әдәбият бүлегендә үзем чыгып күңелдән «Тарих сере» хикәямне укыдым.

4/VII—24. Кичә Самарага килеп төштек. Монда IV Окружная партконференция була. Округ политотдел начальнигы Русанов мине телеграмм белән чакырды.

5/VII—24. Конференция эшләре повесткасында милли гаскәри бүлекләр төзү мәсьәләсе тора. Тагын да җиң сызганып эшләргә туры килә. Моннан бер татар дивизиясе турында карар алып кайтырга ышанам.

6/VII—24. Конференциядә Бубнов, Русановларның доклады буенча прениялар булды. Миңа иртәгә нәүбәт житә. Округның милли частьларга карашын тәнкыйть белән чыгарга хәзерләнәм.

7/VII—24. Хәзер генә Керенский хөкүмәте составында святой синодның оберпрокуроры булып торган князь Львовның лекцияләреннән кайттым. Николай II мәүзугында сөйләде. Карт, башында бер төркем дә чәче калмаган... Кыза, сөйләгәндә урыны-урыны белән үзен-үзе онытып кычкыра, Николайга ачулана... Тапкан бит вакыт. Хотя әле дә соң түгел.

Халык күбесенчә эшче белән чиновниклардан гыйбарәт иде. Чиновниклар арасында мәңге янармый торган монархистлар да күренә тора. Лектор Николайны сүккәндә мыгырданып утыралар.

Кызык эшләр булган ул вакытта. Распутинның теләве белән урыс гаскәре наступлениягә барган. Бер тиле мужик әмере белән унар меңләп кеше үтерелгән. Һәм шул эш моннан 8—9 ел гына элек булган бит! Ул вакытта адәмнәрнең башы булмаган мени соң?

9/VII—24. Плансыз, регламентсыз табигать кояшы астында үсеп аткан чәчкәне ничек яратсам, туктаусыз эш, көрәш, сугыш эчендә үткән 17—18 елларны шулай яратам.

Өч төн рәттән йокламыйча эсэр гласныйларын аулап үткәргәч, һәр минут эскадронлар килеп басу куркынычы астында утырганда, йомшак күмәч белән ач карынны туйдырганда иптәшләр белән шаярып утырулар; 10—15 меңлек солдат митингларында сүзгә оста меньшевик ораторларына каршы чыгып биш-ун сүз белән аларны бәреп еккач, күкләрне яңгыраткан «Урра!» алып сәгатьләр буенча сөйләү; көчле тойгы астында кызып энтузиазм белән рухланган, котырган солдатларның кулларында йөрүләр, караңгы төнләрдә кораллы дошман тулган шәһәр урамнарында карабин күтәреп, һәр секунд тирә яктан пуля очканын көтеп йөрүләр; залп белән атылган снаряд шартлавы янында аптыраган партизаннар алдына чыгып «Иптәшләр, таралмагыз, мин сезнең белән!» дип аларны алга алып китүләр; позициядән кайтып туган шикелле шатланып каршылаучы иптәшләрнең арасында рухлы сөйләүләр белән үткәргән төнләр... Саный башласаң, бетергесез күп жанны яшәрткән, рухны ашкындырган моментлар. Боларның һәрберсе аерым-аерым бер гомер торалар.

Бәлки сәламәтлегем түзеп мин алдагы көрәшләргә житәрмен, тагын да гали, тагын да жанлы вакыйгалар кичерермен. Бәлки күз алдымда жиңгән пролетариат Европасын күреп коммуна төзүгә катнашырмын... Ни булса булыр, әмма ул еллар, беренче көрәш сафлары, беренче ашкынулар тәкърарланмаслар. Аларны бер кадәр күздән югалтмас өчен бер эшкә тотынам. Каләм көче житкән кадәр ул минутлардан күзгә чагылган, күңелдә калганнарын суырып алып, яшь буынга укытыр өчен мәйданга чыгарам. Әйдә, аннары укучы яшьләр 17 нче елның коммунарларның тормышын белсеннәр.

27/VII—24. Өченче августта минем инсценировка була. Гәзитәдә хәбәр бирелде. Күп кеше кызыгып көтеп тора. Барысыннан бигрәк үзем көтәм. Бу Казанда мисалы күрелмәгән, масштабы белән Мәскәү инсценировкаларын уздырган бер нәрсә булачак. Берничә урамда, Театральная площадьта уйналып 3000 нән артык кеше катнашачак...

3/VIII—24. Кичә көн буе, төн буе, бүген кичкә кадәр аяк өстендә үтте. Хәзер арып кайттым. Инсценировканы уздырдым. Вакыт житмәү аркасында бөтен күләмен эшләп булмады. Кимчелекләре дә булды. Әмма аерым моментлар искиткеч бер жанлылык белән үттеләр. Иске урамдагы баррикада сугышлары, февраль революциясе сүнгән жанны уятырлык рухлы булдылар. Фронтка китә торган парад церемониалы, Николайның смотры көтелмәгәннән артык матур иделәр. Инде Октябрьга хәзерләнергә кирәк.

13/VIII—24. Алдагы планнар арта бара. Кышкы сезон житү белән яхшылап кына язарга утырам. Тырышып Кызыл гаскәр газеты чыгару мәсьәләсен вөжүдкә житкерергә уйлыйм. Школаны Русиядә беренчеләр дәрәжәсенә куясы бар. Кыш буенда немесча белән эсперантоны рәтләп өйрәнеп, киләсе елга Германиягә барып киләсе бар. Тагын... тагын... әллә ни кадәр. Пролетариатның алгы сафларыннан калышмыйча беррәттән бөтен куркыныч, авырлыкларга каршы бару — алда торган бер экскурсия-сәяхәткә бару төсле кызыктырып тора.

20/VIII—24. Мин әдәбиятне матурлык сөйгәнлектән сөймим. Әгәр дә әдәбият революциягә корал була алмаслык булса, мин аңарга тотынмаган да булыр идем кебек... Мин художникмы, әллә мастермы? Художникны элекке мәгънәсе белән алганда, матурлык өчен рухланып язучыга санаганда, мин — түгел. Мин аерым тойгылар, мәхәббәт, башка сыйфатлар белән генә хисапланып, аларны тикшерергә уйламыйм. Миңа инсаният, коллектив дигәннең тәкъдире кирәк. Аның кайгысы, шатлыгы, тойгылары миңа азык. Шуларны язарга уйлыйм.

22/IX—24. Начар билге! Көндәлек кулга эләкми. Вакытында язасы әйберләр дә бар иде.

Бу арада Самарага барып килдем. Пароходта «Су өстендәге утлар» белән урысча «Контрибуция»ны яздым. Шулай ук көннәрдә генә «Шәмсетдин байның сәяхәте» исемле көлке белән «Егерме тамчы» дигән бер пәрдәлек пьесаны язып ташладым. Хәзер «Беренче адым»ны яңадан эшләп, «Кызыл байрак астында»ны яңадан язып үтмәкче булам.

Латин хәрефе мәсьәләсенә житди генә тотынасы бар. Помощниклар юк. Барысы да инициативасызлар.

28/IX—24. Кичә элекке Дворянское собрание бинасында мәркәз коммунистлар клубы ачылды. Мең кеше сыйдырырлык колонный залы йөзләрчә лампа белән яктыртылган. Зур аш, бильярд бүлмәләре, гостинныйлары — болар бары да клубны чын коммуна Сараена охшата иделәр. Заседаниены клуб советы исеменнән мин ачтым.

Шул ук көн клуб янында радио һәм латин хәрефләре дуслары җәмгыятьләре төзеп эшкә керештем.

6/X—24. Беренче октябрьдан 4 сенә кадәр Казанга СССР мәгариф комиссары Луначарский килеп китте. Килгән көне белән Большой театрда үзенең әсәре булган «Канцлер и слесарь» дигән пьесасы алдында сүз алып, театр вә революция турында сөйләде... Ул чыкканда мин үземнең 19 нчы елда беренче мәртәбә «Канлы көннәрдә», «Беренче адым» куелганын искә төшердем.

19 нче елның яз башы. Колчак Казаннан ерак түгел, шәһәр лагерьга әйләнгән. Мин баш-аягым белән полк, бригада төзү эшенә чумган. Шул вакытта бер кичтә утырып язылган «Беренче адым» әүвәл Пороховойда, эшчеләр театрында, соңыннан төзәтелеп Красноармейский дворецта куелды. Пьесаның соңында килеп чыга торган җанлы картина күрсәтелү белән галерканы тутырган солдатларның кул чабулары — миңа язучы сыйфаты белән ясалган овация, белмим, кайчан һәм кайсы язучыга ясалгандыр... «Галерка котырды кул чабудан» дип артистлар куркыштылар.

...Луначарский да шундый шатлык белән шатлангандыр дип уйларга тырышам. Һәрхәлдә, идея өчен миннән ун мәртәбә күбрәк гомерен биргән карт башлык башкача уйлый алмас иде.

...Иртә белән мине вокзалга, Әзербайҗан ЦИК рәисе Агамалы Оглы янына чакырттылар. Иярләп киттем. Карт, бите ак йон белән капланып беткән. Мине латинчы булуым сәбәпле чакырткан. Планнарны сөйләп биргәч бик кәефләнде. Бакудан безнең төзеләчәк җәмгыятькә акчалата ярдәм җибәрергә булды. Үзенә шәһәрне күрсәтеп йөрдем. Киткәндә школа файдасына өч йөз сум акча биреп китте. Урынлы төште. Мин ул акчага радио куйдырам.

Кичә радио һәвәскәрләренең беренче җыелышы булып, постоянный правлениегә сайландым.

12/X—24. Школада җыелыш булып, латин хакында доклад ясадым. Беренче латинчылар ячейкасы төзелде. Шулай итеп, Татарстанда зур роль уйнаячак хәрәкәткә беренче адым ясалды.

14/X—24 г. Мин яшьтән, кечкенәдән әни авызыннан ишеткән бер җыр бар иде:

Киләсе елга бу айларда,—
Без булырбыз кайларда...

18 нче елның июлендә Оренбург гаскәре белән Актүбә янына чигенеп барганда, Тозтүбәдә (Илецкая Защита) тоз күлендә коенганда мин бер җирдә шушы сүзләрне язып калдырган идем. Шул вакытта, төрле яктан куркыныч, алда ни буласын белми торганда, киләсе елга кадәр яшәү уе әллә ни кадәр ерак, шуның белән кызык күренә иде. Көннән-көн кызып барган сугышлар эчендә киләсе ел түгел, киләсе ай да күренми иде. Шулай булса да үттеләр. Яшен тизлеге белән ялтырап үттеләр...

Киләсе елга бу айларда,—
Без булырбыз кайларда?

Моннан алты ел элек бу сүзләрне язганда ни буласын белү читен булса, хәзер дә җиңел түгел.

Кем белсен, Европа безгә нинди бүләкләр бирер дә, 6 нчы мәктәпнең тимер кебек нык, акыллы, батыр егетләре белән кайда барып чыгармын икән? Урамларында җил ыжгырып йөргән Казан, ярлы Казан киләсе елга, булмаса, биш елдан үзгәрерме? Аның асфальт йөзе күрмәгән бозлы таш урамлары, җимерек, тәбәнәк, тәртипсез төзелгән өйләре урынына революция стилендәге яңа сарайлар төзелерме?

Ул елларда без кайда булырбыз икән, шуны беләсе иде.

15/X—24. Мәктәптә алынган курсантлар өстенә тагын да курсантлар җибәреп, тутырып торалар. Яңа алганнардан бер өлешен чыгарырга кушалар. Калдыруларын сорап Мәскәүгә барам.

21/X—24. Мәскәү, Мәскәү! Синең җанлы урамнарың, тормыш кайнап торган театрларың, вокзалларың нинди матур! Әмма шулай да әкеренрәк төзеләсең... Монда ЦИК сессиясе мөнәсәбәте белән күп эшчеләр җыелган. Төркестаннан Рәхимов белән Икрамов, Башкортстаннан Мортазин белән Кушаевларны күрдем. Бездән Сабиров барган.

25/X—24. Бүген Казанга китәм. Иртүк 1 нче Советлар йортында торучы Сәетгалиевка барып, озак сөйләшеп утырдым. Сәетгалиев белән ике-өч елга якын күрешкән юк иде.

17/XI—24. Кичә Комклубта латинчылар җыелышы булды. Рабфак, техникум, университет студентлары һәм әүвәлге интеллигенциядән Тимерша Соловьев, Борһан Шәрәф, Садри Җәләл, Шәриф Байчуралар бар иде. Латинга каршылар бер фракция ясап, төрле юллар белән аяк чалырга тырыштылар. Ахырында резолюцияне тавышка куеп бетермичә мәҗлестән чыктылар. Залда күпчелек — латин дуслары — бер оешма ясарга карар биреп, җиде кешелек бюро төзеделәр. Мин дә анда кердем.

24/XI—24. Латинчылар бюросының беренче җыелышы булды. Мин бюроның рәисе булып сайландым. Хәзердән Татарстанда латинны тарату минем өскә йөкләнгән дигән сүз була. Әйдә, җилкәдә берничә вазыйфа бар инде. Хәзер бусын да күтәреп чыгармын әле.

21/I—25. 3 нче январьда Гомәр Галиев, Кутуй, мин — өчәүләп — Мәскәү пролетариат язучылар киңәшенә киттек. Алтысында эш-киңәш мәҗлесе ачылды. 220 дән артык вәкил килгән иде. Мәҗлесне Демьян Бедный ачты. Совещание 12—13 енә кадәр тартылды... Үземне ВАППка сайладылар.

Мәскәүгә барудан асыл ният мәктәп комиссарлыгыннан чыгу иде. Җиде ел революция дәверендә бер генә мәртәбә берәр мәктәп үтмәү аркасында мәктәпнең бөтен тормышын башкару авыр булды. Кул астындагы егетләр үзеңнән бер баш югары күтәрелгәч, идарә авыр була икән.

Гаскәри мәктәпләр башлыгы Якир иптәш:

— Юк, без сезне алырга уйламыйбыз, Кызыл Гаскәр әле дә булса укымаган комиссарларга тәрәлеп тора. Көзгә сезне Политическая Академиягә алырбыз,— диде.

Ләкин Литинтерн мине Мәскәүдә калдырырга сорагач, Якир УВУЗга (югары уку йортлары идарәсе) күчерергә ризалык бирде. Мин анда гаскәри мәктәпләр (14 данә) белән идарә итәчәкмен.

Мәскәү, Мәскәү! Ахырысы, мин дә синең халкың арасында кереп, кайнап торган тормышыңда бер тамчы булырмын.

11/VI—25. Бу көннән алып башымда приключенческий романның планы эшләнеп бетте. Кәгазьгә төшерә башлыйм.

18/VII—25. Күптән язган юк. Ә язарлык бер-ике үзгәреш бар. Беренче. Яза башлаган роман — дөресрәге хикәям «Памирдан радио» исеме белән «Эшче»дә басыла башлады. Дүрт номерда чыкты инде. Әле 14 номерлык язылган материал бар. Темасының якынча схемасы башымда булса да, бөтен килеш черновойга язганым юк. Зур күләмдә 150—200 битлек бер китап булыр дип уйлыйм.

Икенче. Мин киләсе елга ВПАКта «курсы усовершенствования высшего начальствующего состава Красной Армии»да укый башлыйм. Укулар 15 нче сентябрьдан башлана. Шулай итеп, мин дә курсант-академик булып китәм.

29/VII—25. Августның 8 ендә Казанда Татар-башкорт гаскәри мәктәбе 96 командир чыгара. Барырга уйлыйм. Әйдә әни, Айсылу, Абдрахман, Али торалар. Хәмзә белән Йосыф мондалар. Күптән акча җибәргән юк. Зарланалар.

4/VIII—25. Бүген мин Казанда... Азик*[1] килгән. Лили минем белән кала.

23/VIII—25. «Беренче адым»ның бер пәрдәсен үзгәртеп яздым. Аны хәзер дә куярга яраклы матур бер пьеса ясарга уйлыйм.

«Эшче» дә минем «Памирдан радио» басылып бара. 15 номерда чыкты инде... Ахырының приблизительный планы гына күңелдә бар.

Кичә курсларда беренче занятияләр бирелде.

27/IX—25. «Памирдан радио» утызлап номерга сузылды инде. Ахырын тагын 10—15 номерга сузарга уйлыйм. Эшчеләрнең зур интерес белән укыганлыклары күренә. Идарәдә бу турыда 20 ләп хат бар. Аларның шулай кызыгып укулары язасы килүне арттыра.

Кичә Шәрекъны өйрәнү институтында Мәскәүдәге татар студентларының җыелышы булды. Алтмышлап егет бар иде. Күбесе Казаннан, яңа килгән. Мин дә гаскәри укучы сыйфаты белән катнаштым.

---

[1] *Азик — беренче хатыны.

22/X—25. Бүген «Памирдан радио»ның соңгы главасын язып бетереп, иркен суладым.

30/X—25. Нимесчә укуым яхшы бара. Үзем старшая группада укыйм. Бу ел эчендә байтак өйрәнергә жыенам. Һәрхәлдә, күзгә гәзит укырлык булырмын дип ышанам.

31/X—25. Бүген иртәнге сәгать алтыда операциядән наркомвоен Фрунзе үлде.

1/XI—25. Союзлар йортында Фрунзе янында почетный караулда тордым. 3 ендә күмәчәкләр.

Фрунзены мин Самарада күргән идем. Татар бригадасының комиссары сыйфаты белән аның янына еш кына барадыр идем.

8/XI—25. Октябрьның 8 нче елы да үтте диген. Минем зрелый, самостоятельный тормышның сигезенче бите ачылды. Мин бит Октябрь белән генә тормышка чыктым...

11/XI—25. Бүген миндә Фатих Кәрими, Чыгытай, Фәхрелислам Аги утырып киттеләр. Фатих Кәрими Мәскәүдә эшләргә калырга тели.

17/XI—25. Соңгы көннәрдә укуга чумдым... Бирелеп укыган саен алдагы горизонт киңәя бара. Эх, әгәр дә бу белем миндә 2—3 ел элек булса иде! Дөрес, основной сизү, инстинкт белән аңлау башта ук булган. Әмма ни кадәр ялгышлыклар эшләнгән.

2/I—26. Бу арада мин күп җир йөреп килдем. 20 сендә Казанга, 26 сында Гурьевкага бардым. Карт эшчеләр белән күрешеп, сөйләштем. Күңелле булды. Аннан 29 ында Сембергә кереп, Асияне алып, бүген генә кайттым.

10/II—26. 13 февральдә Шәрекъны өйрәнү институтында латин-гарәп хакында диспут була. Мин рәсми содокладчик. Бу тема — латинчылык — минем хәзерләнгән, белгән темам булып, гарәпчеләргә өстен чыгуга ышанам.

Сәясәт мәйданында бер төрле. Партия дискуссиясе бетеп, тынычлык урнашты. Тормышның һәр почмагында восстановительный процесс — төзү пульсының көчле тибүе сизелә. Татарстанда группалар тынмыйлар. Кайчандыр мин араларында йөргән «уңлар» хәзер көннән-көн физиономияләрен ача барып, татар буржуазиясының яклаучыларына әйләнәләрр. Политэкономия белән сыйныфлар көрәше тарихы миңа аларны танырга күп ярдәм итте.

20/II—26. 25 ендә Бакуда беренче тюркология съезды ачыла. Төркия, Германиядән мәшһүр тюркологлар киләчәк.

Башта мин бармаска дип уйлаган идем. Каралачак латин хәрефе мәсьәләсе минем өчен мөһим булса да, укуны ташлыйсы килмәгән иде. Әмма казанларның бөтен гарәпчелек багажларын төяп Бакуга барырга җыенуларын ишеткәч, барасы килеп китте. Бакудагы съездның комиссиясе исеменнән телеграмм килгәч, барырга булдым.

24/II—26. Бакуга мин 20 нче елны шәрекъ халыклары съездына килгән идем. Ул вакыттагы Баку белән хәзерге Баку башкарак. Биш ел эчендә сихерле таяк белән үзгәртелгән.

Агамалы Оглы — латинчылыкның идеалы — шуның белән яши. Мине вокзалдан үк үзенә алдырды. Без аның белән Казанда танышкан идек. Иң яхшы номерны бирдереп, распоряжениема фаэтон бирдерде. Димәк, эшләргә условия бар. Иртәгедән җиң сызганып эшкә керәм. Латин мәсьәләсендә мин дә бит Агамалыдан ким фанатик түгел.

26/II—26. Бүген съезд ачыла. Делегатларның байтак өлешеннән җыеп латинчыларны оештырдым. Башкортстан, Төрекмән, Кара кыргыз — барысы да латинчылар. Үзбәкстан — бер өлеше. Дагстаннан, Татарстаннан, Кырымнан берәр делегат. Бүген сәгать 12 дә ЦК бүлмәсендә съезд фракциясының җыелышы булды.

2/III—26. Кичә кич белән съезд фракциясенең латин мәсьәләсе хакында тарихи утырыш булды. Татарстаннан килгән Галимҗан Ибраһимов белән Гаяз Максудов шәкертләрчә киреләнеп торуга карамастан, латинны яклап резолюция кабул ителде. Мин кичә съездда орфография мәсьәләсендә чыгып сөйләдем. Муафыйкатьле булды.

6/III—26. Съезд бүген бетә. Ул үзенең бурычын үтәде. Латин мәсьәләсе 7 каршыга 101 тавыш белән үтте.

Хуш, Баку! Иртәгә поездга утырып, синең җәнүб кояшы астыңны калдырып, салкын карлы шималга, кайнап торган эш эченә китәм. Синдә рәхәтләнеп хәл җыйдым.

10/III—26. Мәскәү. Моннан бер сәгать элек Бакудан килеп төштек. Поездда академик Бартольд, академик Ольденбург, профессор Жирков һәм башкалар килделәр. Бакуда вакытта алар белән яхшылап таныштым.

16/III—26. 12 сендә чыккан «Татарстан» Фатих Әмирханга багышланган. Аның портретын караганда мәрхүмне моннан ике ярым ел элек Мәскәүгә сельхозвыставкага китерүем искә төште. Үзенең «автомобиле» белән теплушкага утырып, ачык ишектән урманга карап күзләрен шар ачып кәефләнеп «Шәп!» диеп барганы хәтеремдә.

21/III—26. Вакыт житми. Көннең сәгатьләре төрле заседаниеләргә бүленеп, житми калалар. Мин Бакуда вакытта Мәскәүдә ВАППның конференциясе, шул ук вакытта радиодусларның съезды булган. Икәвендә дә буласы иде. Әмма Тюркология съезды аннан да важныерак булды.

«Памирдан радио» китап булып чыкты. Бу минем аерым китап рәвешендә чыккан әсәрләрнең сан буенча житенчесе.

25/III—26. Национальный ВУЗлар конференциясе бетте. Төрек гаскәри мәктәпләренең берләшеп, терминология төзү эшенә керешүләре турында резолюция кабул ителде.

Казанда имля мәсьәләсендә каткан боз кузгалырга тора. Бу көнгә кадәр Казан матбугатчылары, Галимжан Ибраһимовны йөгәнләп, Татарстан исеменнән гарәпчелек байрагын тараталар иде. Кичә «Татарстан»да Фатих Сәйфинең мәкаләсе латинчылар хәрәкәте башлануын белгерә. Күңел шатланып китте.

5/IV—26. Бүген Татсовнарком рәисе Гыйбадуллин, бернichә Татарстан эшчесе белән киңәшкәч, мин укып бетергәч Казанга кайтырга булдым. Анда эшләр күп. Миңа мәйдан бар.

15/IV—26. Укуны бетерү якынлаша. 24 ендә классный занятияләр бетә. Аннан 15 көнлек каникулдан соң Латвия границасына маневрга, аннан Ленинградка флот белән танышырга чыгабыз.

Иртәгә Арбат районында пищевиклар Союзы комсомол жыелышында «Международный һәм эчке хәлләр» темасына доклад ясыйм. Мәскәү жыелышында андый зур темага чыгуым беренче әле. Хәзерлек бар.

24/IV—26. Укулар бетте. Каникул майның унына кадәр сузылачак. Казанга барам.

27/IV—26. Кама елгасы ташу аркасында Казанга туры юл ябык. Бу елның язы бөтен илгә су басу бәласе китерде. Юлда йөзләрчә авыллар су эчендә йөзәләр. Мәскәүдә дә 50—60 урам су эчендә.

Мин Казанда бер-ике көндә эш бетереп Самарага, аннан Хукәнткә китәргә уйлыйм. Азик белән торган Лилине алып кайтырга кирәк.

3/V—26. Таныш жирләр! Көн буенча Переволоцк станциясеннән Актүбәгә кадәр һәрбер станция, разъезд, тау, сукмак, авыллары — барысы да таныш, барысын да ат өстендә, яисә җәяү, кулда мылтык тотып йөреп чыккан. Яндырылган авыллар төзелгән. Станцияләр яңадан ясалган. Бәйрәм булганлыктан безнең поездга каршы чуар киемле халык каршы чыга.

Ә минем күңел еракта. Менә Яйсан станциясе. Сул кулда ындырлар. Әнә читтәге канавада моннан сигез ел элек карабин тотып каршыда яткан офицерлар белән атыштым. Менә бу сусыз елганы кичкәндә минем авызым кипкән, кайдан булса бер тамчы су теләп бара идем. Шул вакыт цепьның алдында барган бер сыерны туктатып имдем. Эчтәге кызулык басылды. Менә уң кулда, станциядән 4—5 чакрымда биеклек бар. Шунда мин станциядән чигенгән татар ротасы белән очраштым. Гаскәриләр мине үлгән дип хисаплаганнар иде. Ә мин мадьяр ротасы белән бардым. Шул вакыт миңа бөтен красноармеецлар шундый якын иделәр!

Сигез ел элек киләчәк турында башка төрле уйлар кердер иде. Әмма болай Академия укучысы булып скорый поездда үтеп китәчәгемне күңелгә китерү кыен иде.

12/V—26. Мәскәүдән чыгып киткәнгә 17 көн тула. Хукәнттә булдым. Лили белән бергәләп кайтабыз. Юл буена үзенең чалтыравык тавышы белән кәефләндерә килде. Тазарган. Тәрбиясе ныгыган.

20/V—26. Тәрәзәдә яз шаулый. Лили жәелә. Монда уйнарга үзенә иптәшләр күп. Өй алды бакча. Иртә белән тәрәзәдән чыгып китә дә кич кереп йоклый. Иптәшләре эре кешеләр: Буденный, Ворошилов, Радек, Ярославский, Сосновский балалары. Еш кына үзен бульварга алып чыгам. Анда шатлыклы көлүе белән бөтен халыкның дикъкатен ала. Таза, җанлы, матур булып үсә.

7/VI—26. Ленинградта дүртенче көн. Үткәргән уенны тикшерү бара. Иртәгә таң белән Кронштадка китәбез. Аннан Гатчина, Красное Село, Мариенбург, Волхово белән Вязниково авыллары.

11/VI—26. Мәскәүгә кайттым. Кичәдән үк хатлар язарга утырдым. Гарәбстан консульствосына Юзик Туймәтовка озын бер хат, Бакуга, яңа төрек әлифбасы

комитетына, Казанга Фатих Сәйфигә, Татобкомга. Әле тагын язасы ба
айларда дәресләр бугазга килеп тыгылганлыктан күп язып булмаган ид

14/VI—26. Иртәгәдән соңга лекцияләр башлана.

29/VI—26. Сәгать 9 га безнең курслар аэродромда булырга тиешл
очабыз.

5/VII—26. Бүген безнең кай урынга билгеләнүебезне әйтергә тиешл
Мин Ташкентка Высшие востоковедение курсларына начальник помощ
лып билгеләнүемне көтәм. Анда күбрәк белем алырга, эшкә киңрәк
табуга ышанам. Казанга барудан күңел кайтты.

10/VII—26. Хәзер генә Кремльдән кайттым. Анда зур сарайның Геор
залында безнең курсларга, Академиянең основной курсларын һәм ша
культетын бетерүчеләргә выпуск булды. Мең кешегә якын банкет ү
Ворошилов, Рыков бар иде...

11/VII—26. Кичә кич белән Агамалы Оглы, профессор Павлович, Ту
Кадыровлар белән совещание булды. 13 ендә Совнаркомда латин хәрефе
булачак карарның резолюция проектын хәзерләдек. Аның буенча ми
Союз әлифба комитетының Президиумына керергә тиешмен.

12/VIII—26. Бүген ПУР мине Ташкентка, Востоковедение курсларын
часть башлыгы итеп билгеләргә карар бирде. Күптән теләгән теләгем
җитте.

Хезмәткә билгеләнүне көткән буш аралар язу өчен файдалы булды. «
гәзитенә «Төрек халыкларының Октябре алдында» исемле русча бер
бирдем. «Эшче»гә кичә генә «Ачылган йозак»ны язып, «Яшь эшче»гә «Е
коръән»не бирдем.

25/VIII—26. Ташкент. Дүртенче мәртәбә сиңа киләм... Килгән ур
курсларда — яхшы каршы алындым. Эш бик күп. Кичәләрдә шәһәр банке
әйләнә. Искусство бик бай. Авантюрный кинодан гыйбарәт.

2/IX—26. ...Хансәвәрев белән таныштым. Ул Среднеазиатское бюрон
проп мөдире. Аның белән латин хакында сөйләштек. Среднеазиатский м
та бер оешма төзергә уйлары бар.

Минем «Памирдан радио» белән «Шәмсетдин бай»ны үзбәкчәгә
итәләр.

6/IX—26. Бу көннәрдә минем киләчәк хезмәтемә маяк булып т
бер эш билгеләнде. Курста бу елдан башлап керә торган яңа дәрес п
милли-колониальный азатлык хәрәкәте предметын укыту минем өсте
ләтелде.

19/IX—26. Среднеазиатский бюрода киңәшмә ясап латин оешмасы т

26/IX—26. Бүген вакытлы квартирдан постоянныйга күчтем. Эшләр
тән көн тыгызланып китте. Буш сәгатьләр укытачак дәрескә хәзерлән
үтәләр.

5/X—26. Партиядә тагын дискуссия. Бу юлы оппозиция башында Т
Зиновьевлар тора.

8/XI—26. Кичә шаблонный парад. Красная Армия йортында ярым
ярым банкет эчендә Октябрьның 9 еллыгы үтеп китте.

Мин хәзер Урта Азия партия бюросының истпартында гаскәри секц
лыгы.

...Китап укырга вакыт юк. Семья тормышы да хәзерләнергә юл
Ялгызлык вакытын сагындыргалый шул. Иртәгәдән соңга үзбәк част
призыв баруын тикшерү өчен Кокандка барырга туры килә... Коканд
өйдәге тормышка (Асия белән мөнәсәбәткә) зарар китерә — Кокандта А
Бу хәл тагын да бер кат ялгызлыкны сагындыра.

3/XII—26. Бүген «Кызыл Татарстан»га беренче мәртәбә «Ташкент»
мәкаләмне җибәрдем. Аның редакторлыгына Галимҗан Нигъмәти куел
лахка караганда күп яхшы, укыган, акыллы егет.

4/XII—26. Укырга өйрәнелде. Күплек куркытмый. Менә язарга вакыт
әгәр берәр ай непосредственный эштән котылса идем!

18/I—27. ...Минем Мәскәүдән киткәндә биреп калдырган «Бирегә
кире» исемле хикәяләр җыентыгы «Нәшрият» тарафыннан басылып чык

23/II—27. Бүген утырып Шамигулов хакында хикәямне язып та
Хәзер, вакыт булганда, утырып берәр хикәячек язып барырга ният. Акка
язган дүрт хикәям бар инде: «Яңа чемодан», «Көчле мандат», «Идел бу

10/III—27. Бу көннәрдә «Кызыл Татарстан»да минем «Гает корбан
«Әптери агай»ның басылып чыкканын укыдым. Барлыгы биш хикәя б
иде. Берсен Сәлах Атнагулов үземә кире кайтарды («Командир хат

«Краском мәхәббәте» белән «Очрашу»ны Татлит Кәримов дигән бер тиле «идеологически мәгънәсез» дип бастырмаган... Бу көннәрдә каты гына авырып алдым.

14/III—27. Иртәгә госпитальгә ятам. Сынаута.

23/III—27. Кичә госпитальдән чыктым. Алты көн яттым. Анда 45 битлек зур хикәя яздым. Гурьевка тормышыннан. Иртәгә комиссия була.

29/III—27. Галимҗан авырый. Язуларына караганда, өметсез. 22 нче йә 21 нче елда Казанда, яңа гына Ташкенттан кайтып тиф белән авырып ятканда, үлем көтеп васыять язган идем. Васыятемдә «мин үлгәч Галимҗан мине «яхшы кеше иде» дип мактап язар. Минем теләк — газиттә аның икейөзле мактавына урын бирелмәсен. «Галимҗан һәм башка сул эсэрлар минем күмүгә катнашмасыннар», — дип язган идем. Галимҗанның да шундыйрак бер васыять кәгазе юк түгелдер.

8/VI—27. Бакуда пленумда бөтен төрек-татарлар өчен бер алфавит кабул ителгән. Бөек бер адым. Минем өчен бер бәйрәм булды. 10—12 сендә Закир Галиев белән Чистайга барып, укытучылар курсында доклад ясап кайттым. Латин хакында.

24/VIII—27. Кичә Нью-Йорктан Сакко белән Ванцеттиның үтерелүе хәбәре килде. Кич буе радио траурный марш уйнап үткәрде. Бу вакыйга якын киләчәктә капитал белән бәрелешнең неизбежностьлыгын күрсәтә.

Мәскәүдә урыс һәм төрек телендә чыгачак латинчылар журналы өчен «Әдернә фаҗигасы» хикәясен яздым.

31/I—28. 25 еннән 30 ына кадәр Яңалиф съезды булып үтте. Яңалиф хәрәкәте хәзер киңәйде, зурайды инде. 24 ендә Областком аны Татарстанда рәсмиләштерергә карар биргән. Мин съездның президиумында, редакция комиссиясендә утырдым. Советка сайландым. Ләкин президиумына кертмәгәннәр. Президиум сайлаганда мин юк идем. Галгәф кандидатлыкка булса да кертергә әйткән. Халик Садри каршы торган. Кертсәк — президиумга кирәк иде. Болай сайлау хурлау гына булыр, дигән. Егет!

Минем башлаган эшләрнең тәкъдирләре шулай! Башлыйм. Бераздан аның ин каршы булган кешеләре шул якка күчеп, эш башына менеп алалар. Татар бригадасында, җөмһүриятендә шул булды.

Объективный караштан чыкканда бу табигый. Чөнки мин хәзер яңалифтә актив эшләмим.

Кичә Казан радио дуслары җәмгыятендә булдым. Үткәрдем. Беренче докладым булды. Җәмгыятнең Совет һәм президиумына үттем.

Бүген сәгать алтыда Областком истпартында Татар бригадасы хакында тарихи җыелыш була.

7/VI—28. Бүген цирк ачылуында булдым. Яңа салган, 3000 кешелек, СССРда иң күп кеше сыйдыра торган икән. Бер ай ярымда ясалып бетте. Яңа циркның бетонлы идәненә басып йөргәндә үземне туып килгән индустрия шәһәренең сарае баскычыннан менгән күк сизендем. Кайчан соң 10—15 мең кеше сыярлык зур хезмәт сарайларының залларын күрермен икән? Минемчә ул вакытта мин үземне бәхетлеләрдән санар идем.

25/VII—28. Оренбург газите «Очкын»да минем «Ертылган корьән» исталеге басылган. Бу көннәрдә «Бузулук өчен көрәш» һәм башка исталекләрне җибәрәм.

28/VII—28. Асия белән театрга бардык. Ул Таҗдаровага керде. Мин театр директоры Заитовта булдым.

Миннән репертуарга ни бирәчәгемне сорады. «Беренче адым», «Бай кызы»ның эшләнгән нөсхәләрен бирергә булдым. Гата Исхакиның миңа күптән биргән «Кара көчләре» бар. Шуны төзәтеп сәхнәләштерергә сорый...

29/VII—28. Җиделәрдә җыелып Кабан күленә төштек. Кооперативный площадьта бакчада утырган халык арасында Садри Җәләл белән Хәйретдин Вәли безгә кушылдылар. Кабан күлендә зур көймәгә утырып, ясалып торган тимер юл дамбасына кадәр бардык.

Кайтып килгәндә Проломный чатында Кутуй, Ильясов, Ченәкәй, Минскийларны очраттык. Туктап берничә минут гөрләп сөйләшеп тордык. Дөресе, сөйләштеләр. Мин тыңлап кына тордым. Яшьлек җүләрлеге ераклана бара, күрәсең.

4/VIII—28. Кичә сәгать икеләрдә Идел белән Сталинградтан Максим Горький килеп төште. Пристаньда ике сәгатьтән артык көтеп каршы алдык. Пароходтан төшүе белән автога утырып шәһәргә китте.

Кич белән Большой театрда җыелыш булды. ...Җыелыштан соң задний выход белән алып чыгып өенә илтеп куйдык. Урамда тулы халык аны көтеп тора иде.

Россиягә килеп төшкәннән бирле халык тарафыннан чолганган бу кеше әсиренә охшый. Мин баласы белән танышып, Асия белән бергә аны Швейцариягә илтеп, татар концертын тыңлаттык. Бүген икедә татар язу белән утырыш була...

Сәгать икедә мәдәният йортына җыела башладылар. Мин беренче урын алып... үзем концертның программасын басарга дип югарыга м Аннан төшкәндә, Горький сәхнәгә кергән иде инде. Гадәтчә, кул чабып алдылар.

Бәхетсез кеше! Башкалар өчен тансык алкышлар аның җанын әрн булса кирәк. Кайда барса да кул чабып «ура» кычкыралар.

Заседаниедән соң концерт булды. Мин конферанс булып алып бардым. Казанское Подворьега банкетка бардык.

13/VIII—28. Бүген бөтен Русия физиклар съездына концерт оешт Съездда урыс физикларыннан башка немец, инглиз профессор, галимна иде. Концерт ошады. Асиянең җырлавы бөтенесен сихерләде. Концертт съезд рәисе академик Иоффе Асияне, мине, Кутуйны (ул концертта кон иде) ученыйлар йортына банкетка чакырды. Банкетта речьләр сөйләнд татар әдәбият эшчеләре һәм фән хезмәтчеләре исеменнән әүвәл татарча, русча сөйләдем.

11/IX—28. «Күк погоннар»ны укып чыктым. Кутуй, Минский, Хәй Вәли бар иделәр. «Гомумән яхшы, ләкин төзәтәсе бар»,— диделәр...

Кичә кызыл гаскәр Сараенда Татар-башкорт гаскәри мәктәпнең 5 нч мальный выпуск булды. Краскомлар яхшы киенгән, таза кыяфәтле. Го гаскәрнең күренеш яхшы. Ләкин бик казенный, туйдырды инде.

Әгәр ул командирлар чыгару урынына автозаводтан көнгә илле, автомашина чыгару бәйрәмендә булсам, минә кәеф килер иде.

14/IX—28. ...Казан кышкы дачага охшый. Көз белән анда студент киле Яшьләре, әле авылдан яңа килгәнләре, гаҗәпләнеп карап йөриләр. Ел музыка, җырның алга барганы күренә. Концертлар тулырак программа баралар. Язучы яшьләр арасында зур хәрәкәт. Быел әдәбият фронты күт зур дулкын булып барырга охшый. Оештырырга кирәк.

25/IX—28. ... 27 сендә ТАППның оештыру җыелышы булачак.

Радиостанцияне Наркомпочтельга тапшырырга йөрим. Ул вакытта өстемдә программа төзү эше генә булыр иде.

11/X—28. Сәгать кичке алты, җиденче. Радиостанция бүген эшләми. дә хәзер инде мин ул кадәр мәшгуль түгел. Анда дикторлыкка хәзер К алдым, секретаре Исмәгыйль Усманов, үзебезчә әйткәндә «кечкенә». Ик редачаны кызу, яхшы алып баралар.

11/X—28. Кичә «Подпоручик Данилов»ны русчага тәрҗемә итеп Исмәгыйль, Асияләргә укып карадым. Яхшы чыккан. Хәзер урыс телен, к ала барам.

19/X—28. Ялта. Мин монда 22 нче елның көзендә булган идем. шәһәр. Ничек үзгәргән. Үткән елның зилзиләсе эз дә калдырмаган, ба да төзәткәннәр.

24/X—28. Дәрәкәй һәм Ай Васыл авылларына барып килдек... К гостинацада Галимҗан Ибраһимовның хатыны туры килде. Галимҗан а белән җибәргән. Өченче көн мин Галимҗанның адресын белеп, үзенә кыск хат язып күрешергә теләгәнемне белдергән идем. Шуңа бик җылы җө белән җавап биреп үзенә чакырган.

25/X—28. Иртәнге чәйдән соң Галимҗанга киттек. Әллә кайда, тау ба тора икән... Галимҗан үзе ашап утыра. Без кергәч торып күреште. Йөзе ар ган, беткән... Чын күңелдән кызгандым. Ике сәгатькә якын сөйләшеп ут Казанны сорашты. Сагынган, күрәсең. Китәргә булгач: «Бу күрешү әле гына булсын, тагын да килегез. Без дә сезгә барырбыз»,— дип калды.

29/X—28. Бүген набережныйдан барганда каршыга килгән Шәриф К очраттык. Баласы, 20 яшьлек рабфак бетергән егет, тамак чахоткасы авырый икән. Кичә генә Казаннан шуны белешергә килгән. Баласыны байтак кыен бугай. Борчыла. Асиянең докторы, мәшһүр тамак, колак а профессор Меерсонга барырга булдылар.

Ялтада хәзер татар язучылары дүртәү булдык: Галимҗан, мин, М Максуд, Шәриф Камал. Иртәгә Галимҗан миңа килергә тиеш. Бергә рәсемгә төшәргә булдык.

Кичә бер утыруда «Югалган документ» белән «Көчле мандат»ны язы ладым... бу көннәрдә бер төркем хикәяләр язырга уйлыйм.

30/X—28. Кичә сөйләшкән буенча 12 дә хатыны белән Галимҗан килде. Шәриф Камал, Максуд, мин, Галимҗан — дүртәү бер группага карточкага төштек. Аннан Асия, Гөлсем кушылып алтау бергә төштек.

11/XI—28. Бүген татар Мәдәният йортында Габдрахман Сәгъдинең «Октябрьдән соң татар әдәбиятенең чорлары» дигән доклады булды. Яшь язучылар оешмасы әгъзалары һәм иске язучылардан Г. Шәрәф, Гали Рәхим, Борһан Шәрәф, Ф. Сәйфиләр бар иде. Мин дә сөйләдем.

15/XI—28. Казанда тормыш темпы куера төшкән. Әдәби эшләрендә бер кадәр җанлылык. Татиздат быел планына 200 табак яңалифтә шул кадәр матур әдәбият керткәннәр. «Яңалиф» 150 табаклар чамасы иске классик язучыларны баса. Шулар арасында Гаяз юк икән. Минемчә Гаязны кертмәгәндә авыз күтәреп «иске татар әдәбиятын бастым» дип сөйләүнең мәгънәсе юк.

11/XII—28. Бүген Мәдәният йортында Академцентрның яңалиф имлясы турында киңәйтелгән җыелыш булды. Агазадә белән Кимчатикны күрдем. Үзләрен Казанда күрү кызык. Мин имлядагы «е» белән «ъ» хәрефләрен кирәкле-кирәксез кыстыруга каршы чыктым. Имлячылар, Фатих Сәйфиләр тыныч кына утырган җирдән чыгуга тотындылар. Хәзерге яңалиф имлясы чынлап та костырырлык бер рәвештә татар консерватизмы белән төзелгән. Нугайбәкнең җимеше...

19/XII—28. Кичә III пленум ачылды. Чын мәгънәсе белән латинчылыкның тантанасы булды. Бөтен сөйләүчеләр аның хакында сөйләделәр.

23/XII—28. Пленум ябылды. Агамалы Оглы соңгы сүзен сөйләде... Фотографлар рәсемгә төшерделәр. Бөтен Шәрекъ җөмһүриятләрендә латинга күчәргә ике ел максимум срок бирелде.

30/XII—28. Хәзер генә мәдәният йортыннан кайттым. Анда ТАППның урыс, чуваш язучылары белән берләшкән җыелышы булды. Мин «Подпоручик Данилов»ны укыдым. Сөйләүчеләрнең күбе аны идеологически-моральный яман дип таптылар. Ләкин проф. Виноградов белән ГИЖны бетеручә Соловьев Фоад кына яклап сөйләделәр. Алар хикәяне тутырып, бөтен яктан килгән психологический рассказ ясарга киңәш иттеләр.

31/XII—28. Хәзер мин «Күк погоннарга каршы»ның соңгы редакциясен язып барам. 270 биткә җиттем инде... Галимҗан Акчуринга кермәкче идем. Авыру диләр. Ул вакытында Бохарада зур роль уйнаган кеше. Монда кызганыч положениегә калды.

1/I—29. Кичә радиостанциядән бирелгән концертны алып бардым. Сәгать 12 не суктырып, тыңлаучыларны Яңа ел белән тәбрик иттем... Сәгать бердә кайтып яттык. Дүртләрдә Зәйтүнә (Асиянең сеңеле), аннан бер-ике сәгать үткәч Йосыф, Гали, Ильяс, Карманнар кайттылар. Хәзер унбер. Егетләр иренеп кенә уяналар. Кухнядан пирогларга ит тураган тавыш ишетелә. Лили барыбыздан иртә торган. Аның нечкә тавышы бер кухняда, бер теге баш бүлмәдә ишетелә...

16/I—29. Бүген «Красная Татария»да минем «Яшь буынның телен бозмагыз» дигән мәкаләм чыкты. Яңалифнең хәзерге имлясына каршы булып, яңа бер фикер, хәрәкәт тудыруны күз алда тоттым. Югыйсә, хәзерге нугайбәкләрнең чәрек принциплары белән барсак, көлке булабыз.

20/I—29. Передачадан кайтып язарга утырдым. Февраль радиопрограммасын язам. Хәзер аны бүлеп, бер пьесага план төзим. Барып чыкса, матур нәрсә булыр иде. Фантазия — ун елдан Казан картинасы.

Лили үсә, хәзер ул язар инде. Теге бүлмәдә, пәрдә артында аның Гандәлиб (Асиянең сеңеле) белән сөйләшеп утырганы ишетелә. Хәзер генә килеп карандаш очлатып китте. Минем эшләгәнне карап тора. Папа, нәрсә язасың, ди. Үскәч белерсең, дим. Укып карый. Гарәпчә язуны авыррак укый. Минем кульязманы танымый, әлбәттә. Үсеп, әдәбият белән танышкач, үзенең папасының әдәбияттә тоткан урынын белеп шатланыр әле.

25/I—29. Көндәлек, хәзерлән! Син дә тиз яңалифләшерсең. Моннан ике ел элек аерым кешеләр авызында гына сөйләнгән яңалиф бүген тормышка кереп бара. Хәзер шәһәрнең вывескалар, гәзит битләре бу хәреф белән чуарлана башлады инде. Мин 25 нче елның Казанда беренче булган латинчылар оешмасы белән башчылык итә идем. Ул вакыт мине «җүләр», «фантазер» диләр иде. Ә хәзер бик тавышлап «без, латинчылар!» дип шапырыналар.

6/II—29. Мәскәү. Моннан бер атна элек Галимҗан Ибраһимовтан хат алдым. Кырымда булганнан бирле безнең мөнәсәбәтләр самимиләштеләр. Ул Кырымда һавалар начарланганын, үзенең авыруы көчәйгәннән зарланып яза.

10/II—29. Хәзер машинкада язам. Яңалифнең беренче җимеше. Кечкенә генә журналист машинкасы. «Кызыл байрак»ны һәм «Күк погоннар»ны язып барам.

Бүгенге план шулар. Чәйдән соң гәзитләр укыгач, радио программасына утырам. Иртәгә сәгать унда радиосовет була. Шунда февральның икенче яртысы-

на программа әзерләргә кирәк. 12 дә университетның эксперимен
фонетика кабинетында яңалифнең имлясы турында утырыш б
юлы «ь» белән «е»ларны кайда язмау мәсьәләсе. Без Сәлах
аны «ь — е» ларны куу дип йөрибез. Аннары чит телдәге
язу. Бу турыда «Красная Татария»ның 16 январьда мин «Не
языка молодого поколения» исемендә статья чыгарган идем.
откликлар-җавапларга килгән хатлардан бер статья төзеп чы
ТАПП линиясе белән бүген җыелышта планны карап беркетәбез. У
бару күелган.

14/II—29. ...Мәхмүд Мәрҗанинең 20 табаклы «Канлы тамчылар»ын
Бу әле язылачак эпопеясенең беренчесе генә. Укып туймаслык бер м
художество куәте белән язылган көч бар. Татар дөньясының беренче
булачак.

26/II—29. Иртә 8 дә тордым... Чәйсез чыгып выставком эше белән й
Аннан программа яздым. Кайтып ашап-эчкәч ТАТЦИК залында яңал
ОДРның кушылу мәҗлесендә булдым. Аннан Ахметшиннан машина ал
театрына килдем. Анда беренче полкның тантаналы утырышында Сәйд
маршы кабул итү мәрасимы бара иде. Маршны уйнаганда түзмәдем, т
чыгып сөйләдем.

28/II—29. Иртәгә радио артистлары һәм язучылар белән Норлат
китәргә кирәк. Такташ бармый. Аның өчен Бөдәйли бара.

6/III—29. ... Хәзер бер ярты сәгать эсперантоны укыйм да, аннар
утырам. Норлатка бару белән яшьләр өчен хикәя язам.

16/III—29. Бүген радиовыставка ачыла. Аның бөтен хәзерлеген мин
диярлек алып бардым.

23/III—29. Бүген минем турыда ОК секретариатында куела. Мин б
эштән чыгып, әдәби эшләр белән генә шөгыльләнергә карар бирдем.

31/III—29. Иртәгә рәсми рәвештә эшемне Фәйзуллинга тапшырам
соңгы мәртәбә станциядә эшне алып бардым.

2/IV—29. Икенче көн инде эшсез. Өстән көндәлек рәсми эш авырлык
нең рәхәте белән исереп йөрим. Китәргә хәзерлек алып барам... Эспе
бетереп барам. Җиңел әйберләрне иркен укыйм. Киләчәктә гомерем
өлешен аны тарату юлына бирергә уйлыйм.

7/IV—29. ТАПП җыелышыннан кайттым. Анда 25 ендә Мәскәүдә
ВАПП пленумына делегат булып сайландым.

11/IV—29. Мәскәү, кадерле шәһәр! Таксомотор алып, Тверской у
«Союзный»га килеп бер бүлмә таптык.

13/IV—29. Кичә кич буе кеше булып торды. Композитор Ключаре
(Мохтаров), Мәхмүт Галәү (Мәрҗани), хатыны белән Кәрим Хәкимов к
иде. Озак сөйләшеп утырдык. Бүген Усман Дивеевка барабыз.

16/IV—29. Центриздатта Ф. Кәримине күрдем... Әллә ничек шул кар
әйтеп бетергесез ихтирам сизәм. Рәхәтләнеп сөйләшәм. Ни дисәң дә, шу
гатьчелектә чәчен агарткан.

20/IV—29. Ялтада өченче көн. Обедтан соң атка утырып Галим
раһимовка барып килдек. Ул байтак тазарган. Шат каршылады. Әүвәлг
нда яхшырак условиядә тора башлаган.

Хәнәф Наум да Кырымда, Симеизда икән. Аңа открытка язып ча
Хәнәф белән мин заочно гына таныш. Шулай да аның язуларын яратам

30/IV—29. Ялта... Үзебез бер килеш «Франция» гостиницасында
Балкон тәрәзәсе аркылы туктаусыз диңгез шаулаганы ишетелә. Яз
погоннар»ны акка күчереп барам. Бу көннән бик ныклап утырам.

1/V—29. Иртүк тордым. Организацияләр җыелалар инде. Күбесе осо
Формалы, формасыз военизированный оешмалар. Пионерлары да ш
киемдә.

Күңел Берлин урамнарына барырга тели. Анда нәрсә бар икән
бит анда полиция тарафыннан тыелган компартия җыелышы
тиеш иде.

Үзем дә защитный гимнастерканы сагындым инде. Ләкин киләчәк
мин, наверное, каләм белән катнашырмын. Военный корреспондент
кирәк. Сугыш исе килә... Польшада, Италиядә, башкаларда кара к
фашист колонналары көрәшкә хәзерләнәләр бит.

3/V—29. ...«Күк погоннар»ны «Актүбә»гә алыштырам. Кыска исем.

9/V—29. ...Галимҗанда булып, өч сәгать чамасы утырып, сөйләшеп
«Күк погоннар»ны үзгәртү турында фикер сорадым. Укырга алып ка

үзгәртүне мәгъкуль күрә... Минем ул нәрсә кыскартылган формада «Кызыл Армия»дә басылып бара. Ә басар өчен нык үзгәртәм аны.

14/V—29. Галимҗанда булдым. Ул минем кульязманы укып чыккан. Аны алдагы төзәтү өчен кирәк булган бөтен киңәшләрне бирде. Бик уңышлы күрсәтүләр бар.

24/V—29. Ключарев килде. Асиянең аккомпаниаторы.

25/V—29. Кичә Ялта эсперанто комитетының секретаре белән сөйләштем. Аңардан шомарак сөйли беләм икән.

3/V—29. ... Кырымда имля конференциясе Нугайбәк-Сәйфи имлясын үзгәрткән. Вакытында мин ул имлягә каршы көрәшкән идем. Хәзер безнең имлябыз да кешенекенә ошады.

25/VI—29. Казан. Кутуй килгән иде, сөйләшеп утырдык... «Кызыл Татарстан»ның өченче номерында Г. Галиның, Ф. Сәйфи чыгарган «Тукай әсәрләре» турында бик матур тәнкыйте бар. Ул халтурщикка күптән шулай кирәк иде.

13/VII—29. Казан! Синнән киткәнгә шатлануны белсә иде!

24/VII—29. Мәскәү. Хәзер генә радиодан кайттык. Асия җырлады. «София» Асияне үз студиясенә алырга уйлый. Соңгы көннәрдә берөзлексез Асия эшләре белән йөрим. Иртәгә Посредрабиста квалификациядә була, үзенә тиешле дәрәҗә ала.

29/VII—29. Дачада, «Красково» станциясендә торабыз. Мохтаровларда — ярым кунак, квартирант... Лили рәхәтләнә. Аңарга почет. Кичә якшәмбе, шәһәрдән Шакир, Исмәгыйль Бибаев, Шәриф Саттар килделәр. Мин көн буе Саттарның кызыларменцлар китабын редактировать иттем.

30/VII—29. Иртәгә шәһәргә күчәбез. «Садовая» гостиницасында бүлмә алып куйдым.

2/VIII—29. Кичә парк культурада булдык. Бераздан демонстрация колонналары тула башлады. Кичкә кадәр шул «Ур-ра!» белән үтте. Янымдагы берәү: «Без монда иркен йөрибез, ә тегендә нишлиләр?» — диде. Чынлап та. Бәлки, менә йомшак креслода журнал укып утырганда, анда — Берлин, Париж урамнарында баррикадалар төзелә торгандыр...

3/VIII—29. ...Йосыф килгән. Лилине киендереп, өс-башына алып, икәвен утыртып Казанга җибәрдем... Асия концерт җырларының беренче категориясенә язылган. Шәп.

5/VIII—29. Бүген, Востоккино белән военизация темасына сценарий либреттосын язарга договор төзеп, 25 сум аванс алдым.

10/VIII—29. Казанга килеп төштек. Теләмичә, ирексездән килү... Кайчандыр үзенә җәлеп иткән, тарткан шәһәр шул кадәр биздергән. Ни өчен? Казанның халкы, бигрәк тә эшчеләре, укучы яшьләре, кайбер ответработниклары әүвәлгечә якын. Ләкин матбугат-әдәбият дөньясы вак, тәҗрибәсез кешеләр кулында.

10/VIII—29. Казанда сентябрь башларына кадәр калырга уйлыйбыз. Шул арада мин: 1) ике табаклы «Военгиз»га бирелергә тиеш хикәяләрне язып бетерергә, 2) Сценарий либреттосы язарга, аның өчен авылга барып киләргә уйлыйм. Шулай ук «София» чакырса Нижнийга Асиянең концертына барып киләргә туры килә. 3) «Актүбә»не дә язып бетерәсе бар. Аңарга язу материалы җыю юлы белән Мәскәүдә Бикбавовны күрдем. 19 нчы ел башында Зәкинең адъютанты булган. Миңа Зәки хакында картиналарны сөйләп бирде.

13/VIII—29. Бүген көндез «Военгиз» белән договор буенча язылырга тиешле хикәяләрнең берсен («Родовой позор») язып бирдем. Машинкада. Хәзер һәр көн берәр хикәя язып, атна эчендә бетерергә уйлыйм. Өйгә кайтып Дәрдемәнд мәҗмугасын карадым. Ф. Кәриминең шагыйрь турында баш сүзе ачык бер картина тудырды. Дәрдемәнднең сурәте күз алга килеп басты. Шагыйрь-миллионер, сыйнфый яктан ни кадәр ерак торса, иҗадияте ягымлы, симпатия тудыра.

...Кичә Япониядагы бер эсперантистка хат җибәрдем. Өч-дүрт атнадан җавап көтәм.

20/VIII—29. Дүртендә, иң соңы бишендә китәбез. Бу юлы бөтенләйгә, күченеп китәбез.

1/IX—29. Лили беренче мәртәбә сабакка барып кайтты. Школа үзендә тәэсир калдырган. Кайтып мактады. Үзен библиотечная комиссияга сайлаганнар. Зур кеше!

3/IX—29. Бүген Асиянең саубуллашу концерты. Иртәгә сәгать бер поезды белән китәбез.

4/IX—29. ...Мәскәүдә тормыш поездының алдагы йомшак вагонында баш әйләндерчек тизлек белән якты, ләкин таныш булмаган станциягә бара. ...Әйе, Мәскәү! Сине уйлап бөтен күңелем тулган. Ләкин элек мин синең урамнарың-

ны, автоларыңны гына сөя идем. Ә хәзер синең театр, вузларыңны, әдәбият мәйданыңны, ә алар аша бөтен төзелеп килгән тормышыңны сөям.

7/IX—29. Мәскәү! Ахырында сиңа килдем бит! Озакка, бөтенләйгә. Хәзер моннан кем дә алып китә алмас.

21/IX—29. Кичә «Богатырь» заводы эшчеләренең жилкооперациясенә язылдым. Бер ай эчендә кваритир бирергә булдылар. Әллә шулай ук күптән күңелдә сакланган хыял тормышка чыгармы икән? Ул — үз кулыбыз белән ясалган социализмның бер баскычына аяк басу дигән сүз!

Кичә Федерация клубында РАППның пленумы ачылды. Беренче докладны татар әдәбияты хакында Г. Гали ясады. Бүген Кырым хакында Сайдамовның доклады була... Көн буе пленумда үтте. Иртәнге утырышта Кырым әдәбияты хакында содокладтан соң мин сөйләдем. Бу чыгышым белән мин ТАПП һәм ОКның сәясәтенә каршы беренче һөҗүм башладым. Минем арттан чыгучылар барысы да диярлек шул юл белән сөйләделәр. Кичке утырышта Гомәр заключение сүзен сөйләгәндә җиңелгәне сизелде. Аның доклады буенча резолюция комиссиясенә кердем.

13/X—29. Квартир мәсьәләсе соңгы инстанциядә хәл кылынып үтә. Ул алдымда зур бер шатлык, тормышның сызыгы булып тора... Ике-өч елдан, квартир кризисы беткәч, бу тойгы бәлки аңлашмаста. Ә хәзер ул бик табигый...

Киләчәкнең кешесе! Син, индустрия иленең гражданы, бәлки безнең менә шундый вак шатлыкларыбыздан көләрсең! Түбәсе болытларга җиткән сарайларда яшәгәндә безнең кечкенә бүлмәләрдә яшәгәндәге зур шатлыгыбыз сине гаҗәпләндерер. Ләкин онытма: без шундый вак һәм эре шатлык-кайгы эчендә яшәп соңгы сәламәтлекне туздырып, сиңа тормыш төзәбез.

18/X—29. Кичә «Кызыл Татарстан»да Сафа Борһанның солтангалиевчелек турында мәкаләсен укыдым. Сафа Солтангалиевтан бигрәк Мөслимовка бәйләнгән. Ләкин ничек бәйләнгән!... Урам сүгенүе белән сүгенгән. Бу мәкалә белән ул үзенең социальный физиономиясын ачкан.

25/X—29. Иртә җиде ярымда дворец трудага, радиостанциясенә киттем... Сәгать тугызларда Ключарев оркестры килде. Унда беренче тапшыру башладык. Европаның иң зур станциясе аркылы беренче татар телендәге тапшыру иде.

11/XII—29. ...Кулга көндәлек эләкте. Алдым. Язасы килә. Киләчәккә документ җыясы килә. Көндәлек эш үтә дә китә. Ә бу бит җанлы документ булып кала. Үземә булмаса, әйдә, бер яшь язучы файдалансын.

21/XII—29. Бүген татар клубында әдәбият түгәрәген үткәрдем. Татар китапханәсендә «Кызыл яшьләр» дә Мирсәй Әмирнең Сафа Борһан һәм Г. Галигә каршы язган мәкаләсен укыдым. Кәеф килде. Ахырында ул әдәбият холуйларына да эләгә башлый. Пычрак себерке белән сөрәсе бар Сафаны. Болай да әдәбият мәйданын житәрлек пычраттылар инде.

10/I—30. Көтелмәгән сюрприз! Бүген Мәскәү эсперантистлар конференциясендә мине Область комитетына җаваплы секретарь итеп сайладылар. Ярый, эшләп карыйм. Эш күңелгә ята.

30/III—30. Хәзер генә эсперантистлар заседаниесеннән кайттым. Анда Германия төрмәсендә яткан берәүнең адресын алып, үзенә хат яздым. Бакудагы эсперантистларның секретаре Вольский дигән бер татар егете белән табыштык. Хәзер аңа хат язам.

14/IV—30. ...Бүген Маяковскийны күмәргә бардым. Ул яткан залга кереп карагач, күңел кузгалды. Кайчан булса үземә дә шулай ятарга туры килер бит. Бррр... һәрхәлдә мин аның шикелле җүләрлек ясап үлмәм.

8/VII—30. Хәзер генә язучылар федерация клубыннан кайттым. XVI съезд делегатлары белән язучыларның смычка кичәсе булды. Клубта Безыменский белән сөйләшеп, аңарга шушы көнләр рецензия өчен китапны бирергә булдым.

Өченче көн Җиһангильдин белән сөйләштем. Мин аны экзот типлы бер казахмы дип торсам, ул Кырым типлы акыллы кыяфәтле кеше булып чыкты. Үземнең эпопеяма аның экспедициясен бер глава итеп кертәм. Шуны сораштым. ...Федерация клубында Мстиславскийны күреп танышып сөйләштем. Легендарный шәхес! Аның «На крыше мира»сын 25 нче елда укып тирән тойгы алган идем. Шуның язылуын сораштым. Биографический нәрсә икән.

Кичә «Красная звезда» редакциясенә үземнең «Переподготовка» исемле очеркны илтергә барган идем. Баскычта бер гаскәрине очраттым. Таныш. Карасам, мин 25 нче елны УВУЗда эшләгәндә Якирның секретаре булган егет. Иртуда икән. Ул мине күреп ерактан ук: «Ә, Татарстанның яшь язучысына!» — дип сәламләде. «Каян син минем язучы икәнемне белдең»,— дим. «Мин Военно-

воздушная Академиядә укыйм. Күптән түгел «Прожектор»да синең хикәяңне укыдык. Иптәшләр белән бергәләп. Бик охшады. Яраттык»,— диде.

13/VII—30. Бүген Үзбәкстан Научный институты мөдире Рәмзи һәм Вәкил Турсун Хужалар белән киңәш булды... Рәмзи мине бик настойчиво бөтенләй Үзбәкстанда эшләргә чакыра. Ләкин мин Мәскәүдән китмим. Берлинда революция булып, СССРның мәркәзе анда күчкәч, барам. Ә башка жиргә барды юк.

15/VII—30. ...Колхозга киту командировкасы буенча бер пар белье, бер простыня, бер чалбар алдым. Иркен сәүдәдә алар юк. Мәскәүнең зур кибетләре бушап калганнар. Сатучылары мәэюс булып утыралар. Бу ни булган? Бу үсү кризисы. Көннән-көн зураеп, көчләнеп килгән индустриябыз бер сулыш белән аларга жан кертер әле.

2/VIII—30. Кибетләрдә, азык прилавкасы алдында чиратлар. Вак акча юк. Сдача урынына талоннар бирәләр.

5/VIII—30. Кичә, язып утырганда, Фәтхи Борнаш, хатыны Ильская белән килде. Кунарга калдылар. Фәтхи үзенең партия эше белән килгән. Бу юлы аны Казан «суллар»ы, үз счетлары белән хисаплашып, партиядән чыгарганлар. Мәркәз аны торгызса дөрес эшләгән булыр.

6/VIII—30. Кичә Шакирда булдым. Бернича иптәше белән пиво эчеп утыралар иде. Шул эчүче компаниягә караган саен үземне югарыда торган итеп сизәм.

13/IX—30. Әсгать Айдар килеп китте. Хатыны белән. Рульсыз, ләкин талантлы малай.

17/IX—30. «Востоккино»га сценарийны илтеп бирдем. Бу соңгы вакытта эшләп бетергән иң зур хезмәтем.

18/IX—30. «Красная звезда»ның алтынчы сентябрь номерында минем «Переподготовка» исеме белән язган очерк «30 дней за учебой» дип басылган. Редакциягә кергәч кенә басылганын белдем.

11/XII—30. Күптән язган юк! Тормыш кызу бара. Вакыт тыгыз тиялгән. Иртә торып китәм, кич кайтам. Бу көннәрдә интернациональная связь штабы төзәргә йөрибез. Эсперантистлар организациясен тиешле урынга куярга көч куям. Хәзер «Правда» редакциясе белән берләп эшлибез.

29/I—31. Көндәлек, ничек картаясың син! Сине кулга алмауга айдан артык вакыт бар. Ләкин ул вакыт сизелмичә үтте дия алмыйм. Зур, тормышны тетрәткән вакыйгалар булмаса да, көнләр буш йөгермәделәр.

4/VI—31. Хәзер генә дачадан кайттым. Дивеевка барам. Бүген «Актүбә» землячествосының бюро жыелышы...

**Көндәлек язулары шушында өзелә. Ләкин легендар шәхес Шамил Усманов турындагы уйлар безнең күңелләрдә, хәтердә дәвам итә. Әтиемнең: «Кызым Айсылу! Син зур үскәч, моның битләрен ачып укырсың да, әтиеңнең ничек яшәгәнен белерсең» — дигән сүзләре дә гел истә тора... Әйе, бу көндәлекне укыгач мин (һәм журнал укучылар да шулай булыр дип уйлыйм) әтием белән янадан очрашкан сыман булдым. Аның тормышын яңадан кичердем. Нинди катлаулы һәм шул ук вакытта кызыклы еллар, вакыйгалар гәүдәләнә бит ул көндәлектә.**

**Бу язмалар хәзерге әдәбият белгечләренә һәм тарихчыларга берникадәр ярдәм итсә, мин бик шат булыр идем.**

**Айсылу УСМАНОВА-САГАЙДАК.**

# УЛ ЕЛЛАРДА...

## ШАМИЛ УСМАНОВ КӨНДӘЛЕГЕ ТУРЫНДА ГАЛИМ ФИКЕРЕ

Кеше көндәлеген укыган чагында үзең дә сизмәстән серле һәм тулысынча аңлап житү өчен шактый катлаулы да булган үзгә бер дөньяга килеп эләгәсең. Әлеге серлелек һәм катлаулылык, күрәсең, шуның белән аңлатыла: көндәлек алып барган кеше үз күңелендәге иң ихлас хис-кичерешләрен язып калдырырга тырыша һәм, шуның белән бер үк вакытта, үз язуларының кайчан да булса ят укучы кулына эләгәсен белеп, аның алдында яхшырак, акыллырак та күренергә тели.

Язучы-әдип кеше өчен бу бигрәк тә шулай дип уйлыйм. Үзенең һәр язганын укучыга адресларга каләм иясе бигрәк тә күнеккән бит инде. Ә Шамил Усманов шикелле тоталитар система шартларында яшәгән язучы хакында инде әйтеп тә торасы юк. Аның эчендә инде берьюлы әллә ничә «цензор» утыра. Һәм, әлбәттә, әлеге эчке цензорлар каләм тибрәтүче кешегә бу язуларның кайчан да булса суд тикшерүчесе өчен бик шәп материал булып торачагын да даими искәртеп тора. Моны, билгеле, Шамил Усманов да белгән, аңлаган. Шул чорның бик зур сәяси вакыйгалары уртасында һәм күп кенә күренекле шәхесләре янәшәсендә кайнаган шәхес моны сизми, күрми кала аламы соң?!

Ләкин, шулай да, язучы кеше, барыбер, язучы булып кала. Тере кешенең кайнар хисләре аны барыбер үз артыннан ияртеп алып китә, саклык турында күпмегәдер оныттыра... Бу көндәлекләрне укыган чагында сез аны күп урында күрерсез, сизәрсез, мөхтәрәм укучылар.

Башта автор һәм аның язмышы турында берничә сүз әйтеп китик. Безнең еллар кешесе Шамил Усманов турында нәрсәләр белә? Әйе, ул Казан шәһәрендә шундый бер урам барлыгын белә, монысы дөрес. Ләкин бит язучының гражданнар сугышына багышланган әсәрләренең инде менә ничә дистә еллар үтсә дә яңадан басылганы юк.

Сталинның шәхес культы фаш ителгән елларда без гаепсез корбан булганнарның бик күбесен хәтеребездә яңадан торгызу өчен, аларны фәрештәләр кебек пакъ итеп күрә башладык. Аларның тормыш, гомер юлларын да гел алсу-матур буяулар белән генә бизәп чыктык. Бәлки ул чакта шулай эшләмичә дә булмагандыр. Чөнки ул гаепсез корбаннарны аклау башланган елларда әле безнең илдә һәм безнең аңыбызда ленинчыл идеяләр тантана итә иде. Теге яки бу кешене аклау өчен, аның партия тоткан төп юлга бик тә тугры икәнен раслау сорала иде. Димәк, кешене сөттән ак, судан пакъ итеп күрү һәм күрсәтү котылгысыз эш иде. Әгәр дә шулай эшләнмәсә — акланырга тиешле теге яки бу шәхеснең вак-төяк кимчелекләренә игътибар ителә башласа — гомумән аклау процессы үзе үк туктальп калырга мөмкин иде.

Мондый мисаллар бик күп. Мәсәлән, минем күз алдымда әле хәзер дә Мәхмүт ага Бөдәйленең моңсу, кайгылы карашлары тора. Әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән һәм күпмедер дәрәҗәдә сәясәткә катнашы булган бу кеше турында бүгенге укучы шулай ук бик аз белә. Ә бит ул Беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышын башыннан алып ахырына кадәр үткән кеше иде. Ленинның үзе белән дә әллә ничә мәртәбә күрешкән булган ул. Бүтәннәр сыман конференциядә делегат булып, еракта гына күрмәгән ул аны, ә Ленинның кабинетында утырган. Шулай ук РСФСРның Хәрәзмдәге илчесе дә булган иде Мәхмүт ага... Ләкин менә шушы олы шәхескә теге елларда «солтангалиевче» дигән кара ярлык шуның хәтле нык беркетелгән иде ки, соңрак аны барча хөкем органнары аклап чыкса да, рәсми яктан караганда ул тәмам акланып бетсә дә, гомер юлының ахырына кадәр, барыбер, аңа шикләнебрәк карадылар. 1918 елдан бирле большевик булган кешеләргә бирелә торган әз-мәз өстенлекләрдән дә ул мәхрүм иде. Мәрхүмнең холкында сарказм да көчле иде инде — Брежневның үзенә ул менә мондыйрак хат язган бит: эше ни хәтле генә күп булса да мине Ленин кабул итә алды дигән, ә менә Татарстан өлкә комитеты секретаре Табеев вакыт таба алмый, дигән. Аларның «якты киләчәкне» төзү мәшәкате, чыннан да, бик күп булгандыр шул. Югыйсә, Мәскәүдәге генеральный секретарь, Казандагы Табеевны мәҗбүр итә алган булыр иде.

Менә шуларны искә төшерсәң, Шамил Усмановка үзе үлгәннән соң булса да олы дан эләкте дип тынычланырга була. Аның исеме беренчеләрдән булып һәм

артык мәшәкатьсез генә акланды. Билгеле, моның да үзенә күрә объектив һәм субъектив сәбәпләре булды. Болары турында соңрак фикер йөртербез. Ә хәзер исә көндәлектәге язуларга күчик.

Көндәлекне укыган чагында иң элек шул күзгә ташлана: анда без белгән байтак кына шәхесләргә бүтәнчәрәк бәяләр бирелә. Без хәзер тудырган хыялый күзаллаулар белән Шамил Усманов көндәлегендә язылган тәэсирләр, нәтиҗәләр еш кына очракларда бер-берсенә туры килми. Усманов үзе дә бу хатирәләрдә безнең хыялдагы бакыр һәйкәлдән шактый ерак тора.

Шуна күрә, әйдәгез, иң башта менә бу сорауга җавап эзләп карыйк: гражданнар сугышы һәм тыныч төзелеш чоры сәясәтенең югары катлау вәкилләре арасында Шамил Усманов чынлыкта нindiрәк урын биләгән? Ягъни, бүгенге төшенчәне кулланып әйтсәк, аның сәяси «рейтингы» ниндирәк булган?

Әлбәттә, ул чорда бүгенге шикелле сәясәт тирәсендә йөреп тамак туйдыручы социологлар өере булмаган. Аннан соң социолог эше ул үзе дә шактый четерекле нәрсә — синең алдан күрәзәлек итүләреңнең чын нәтиҗәсе ничек буласын беркайчан да белеп булмый. Хәзерге социологлар да, әнә, Жириновский безнең җәмгыятьтә артык зур уңыш казана алмаячак дип әйтеп нинди житди ялгыш җибәрделәр ич әле! Ләкин, шулай булса да, ул чордагы кайбер мәгълүматларга таянып, Шамил Усманов шәхесе хакында шактый объектив фикер тупларга мөмкин дип уйлыйм. Ягъни, аның ул чактагы сәяси көчен билгеләргә була.

Менә бер генә факт. 1923 елның май башында аяз көнне яшен яшьнәгән шикелле вакыйга була: Сталинның иң якын ярдәмчеләреннән берсе Мирсәет Солтангалиев кулга алына. Бу хәбәр ишетелү белән ук Мәскәүгә — партиянең Үзәк Комитетына, Халык Комиссарлары Советына һәм Ленин, Сталин, Троцкий исеменә хат китә. Бу хатка кул куйган республиканың 15 иң зур сәяси эшлеклесе Солтангалиевне азат итү таләбен белдерә. Менә шушы 15 сәяси эшлекле арасында ТатЦИК әгъзасы Шамил Усманов имзасы да бар. Шул ук елның июль аенда Казанда Мирсәет Солтангалиев эше буенча җыелган «аны кулга алу дөрес» дигән фикер белдергән киңәшмәдә дә Шамил Усманов катнаша.

Болардан чыгып шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: димәк, Шамил Усманов Мәскәү өчен бик билгеле кешеләрнең берсе булган. Болай дип уйларга башка дәлилләр дә бар. Гражданнар сугышы елларында Шамил Усманов актив рәвештә Татбригада оештырып йөри. Ә әлеге Татбригадалар исә революция ялкынын Шәрекъка илтте, анда да «ялкын» кабызды. Шамил Усманов исә әлеге бригадада үзе дә сугыша.

Гражданнар сугышында катнашкан байтак кына ветераннар өчен Урта Азиягә революция ялкынын илтү бик тә мәртәбәле бер эш булып күренде. Алар моның белән озак еллар буена горурланып йөрделәр. Ләкин бүген Урта Азия җирендә төзелгән бәйсез мөселман дәүләтләрендә яшәүчеләр ни өчендер моны горурланырдай эш дип санарга ашыкмыйлар.

Яшерен фондларның берсендә сакланган Мидхәт Борындыков истәлекләре буенча тагын шул да билгеле. Берникадәр вакыт Сталинның секретаре булып эшләгән М. Борындыков белән соңрак Һеджаста илче булган Кәрим Хәкимов һәм Шамил Усманов — өчәүләп Татар республикасы төзү һәм Шәрекъ коммунистларының Икенче съездын җыйнау фикерен күтәрәләр. Ә татар белән башкорт халкын бер республикага берләштерү уенда йөргән Мирсәет Солтангалиевкә бу фикер бер дә ошамый. Башкортларның ул чактагы башлыгы Зәки Вәлиди истәлекләреннән күренгәнчә (Уфа, «Китап» нәшрияты, 1994 ел) ул чакта Шамил Усмановка, Борындыковка һәм Сәитгалиевкә Сталин үзе шундый әмер бирә: Калинин янында киңәшкән вакытта татарлар белән башкортларның бер республикага берләшү фикеренә каршы төшәргә!

Әлбәттә, бу фактны хәзер, күп еллар үткәннән соң, нәкъ шулай булгандыр диеп ышандыруы кыен. Аннары, моның ише яшерен әмерләрнең, гадәттә, кәгазьдә эзе калмый торган була. Чөнки бу, сәясәт кешеләренә хас булган, кара эшләр рәтенә керә. Әмма ләкин моннан чыгып шуны кистереп әйтеп була: Шамил Усманов ул чор сәяси тормышында күренекле фигура исәпләнгән һәм большевик юлбашчыларына шәхсән таныш булган. Ә бит шунысы кызык: Ш. Усманов үзе партия һәм дәүләт даирәләрендә югары урыннар да биләмәгән.

Ул актив катнашкан тагын берничә вакыйганы күрсәтеп үтәргә мөмкин. Әлеге фактларда Усмановның бик эмоциональ һәм импульсив холкы да чагылыш таба. (Сугышта алган контузиясе, бәлки, моңа бер сәбәп булгандыр). Кайчагында аның эш-хәрәкәтләрендә эзлеклелек тә югалып китә. Мисал өчен, Мирсәет Солтангалиев язуына караганда, Шамил Усманов 1920 елның августында күренекле сәясәтче һәм публицист Бари Батталның концлагерьдан качуына

булыша. Бари Баттал, шул елның язында Себердән кайткач, Башкортстан большевиклары тарафыннан кулга алына, аны Зәки Вәлиди азат итә. Шуннан соң Баттал Казанга килә, бирелә татар коммунистлары аны янадан кулга алдыралар, һәм «гражданнар сугышы беткәнче» дип төрмәгә утырталар... Ә качкач инде, Бари Баттал чит илгә, Финляндиягә китә, гомеренең ахырына кадәр шунда яши, тарих һәм сәясәткә багышланган дистәләрчә китаплар, мәкаләләр чыгара. Әгәр бу хәлләр чыннан да дөрес икән, моның өчен без бүген Шамил Усмановка бары тик рәхмәт кенә әйтергә тиешбез. Чөнки Бари Баттал бу илдә калган булса, 1937 елга кадәр дә яши алмаган булыр иде.

1936 елда Шамил Усмановның үзенә ачылган «эш»тә бу факт искә алынмый алынуын, ләкин мин әлеге фактны язган М. Солтангалиевкә ышанырга мөмкин дип саныйм. Чөнки ул чорда Мәскәүдәге һәм Казандагы олы сәясәтнең «сәхнә арты»н татар арасында аннан да яхшырак белүче башка беркем дә юк бит. Солтангалиевнең үз остазы Сталинның да моның кебек иш мәсьәләләрдә бик тә югары дәрәҗәдәге белгеч булуын истән чыгармыйк. Бу дөнья белән саубуллашып ятучы В. И. Ленин бер дә юкка гына Сталинның сәясәттә дә Кавказ халыкларына хас булганча ачы һәм борычлы ризыклар әзерләргә маһир булуын искәртеп китмәгәндер ич. Нишлисең, тау халыкларының кухнясы шундый инде аның! Бүген дә бик нык сизелә бит әле бу.

Шушы урында аз гына тукталып тагын бернәрсәне ассызыклап үтик: Мирсәет Солтангалиевнең ул елларда үз остазы Сталинга каршы чыгуы сәяси «камикадзе»ны хәтерләтә иде. Генсекның милли сәясәтен ачыктан-ачык тәнкыйтьләргә Фрунзеның да, Затонскийның һәм Мдиванининың да, шулай ук башка оппонентларның да, хәтта Ленинның үзенең дә кыюлыгы җитмәде бит. Шулай икән — алардан түбәнрәк баскычта торган Шамил Усманов нишли ала инде?!

Егерменче елларның уртасы Усмановның дөньяга карашына зур гына үзгәрешләр алып килә. Шуларның берсе мондый: Шамил Усманов РКП(б) Үзәк Комитетына җибәрелгән «39 кеше хатын»нан үзенең имзасын кире ала. (Бу хат соңга таба, «татарның үң капитулянтлары программасы» дип игълан ителә.) Ә Усмановның әлеге адымын аның дуслары куркаклык дип бәяли. Ләкин, минемчә, бирелә сәяси реализм дип әйтү дөресрәк булыр төсле. Чөнки әлеге хатка кул куйган 39 кеше Мәскәүдән вак-төяк мәсьәләләр буенча Үзәкнең опекасын бетерүне сорыйлар. Без бүген әлеге мәсьәләдә мондыйрак нәтиҗә ясасак дөресрәк булмас микән: ә бәлки Шамил Усманов тормышта барган үзгәрешләрне алданрак аңлагандыр, гражданнар сугышы чорында милли төбәкләргә бирелгән ирекнең Үзәк тарафыннан акрын-акрын кысыла килүен ул бәлки алданрак сизгәндер? Солтангалиев фаҗигасы да бик күп нәрсә турында искәртә бит... Бары тик, «кайчан чират җитәр?» дип кенә торырга кала иде ич.

Күңеле белән әнә шуларны сизепме, Шамил Усманов бу елларда иҗатка һаман ныграк тартыла бара. Иҗаттагы аның беренче адымнарын барысы да хуплый. Армия белән араны өзү дә (бу юнәлештә югары күтәрелү өчен аңа мөмкинлек тә калмаган була инде) Усмановка җәмагать эшчәнлеген көчәйтергә булыша. Ул яңадан-яңа идеяләр белән мавыгып йөри башлый; латин язуын кертү тарафдары булып Галимҗан Ибраһимовка актив рәвештә каршы төшә. Бу мәсьәлә турында сүз барганда 1926 елда Баку шәһәрендә булып узган төркине өйрәнүчеләрнең Беренче съезды тыйбрәтле. Анда чыгыш ясаган Ш. Усманов Г. Ибраһимовны латин язуының прогрессив ролен төшенмәүдә гаепли. Ә бит бу съездга барыр алдыннан Г. Ибраһимов партия өлкә комитетыннан шундый яшерен күрсәтмә алган була: татарга латин язуын кертү буенча бернинди дә йөкләмәләр алмаска! Шамил Усманов, әлбәттә, бу хакта белә алмый. Хәер, сәясәттәге күп эш-адымнарның әнә шундый яшерен, күзгә-күз карап кына әйтелгән күрсәтмәләр буенча эшләнүе һәр чор өчен дә гадәти күренеш шул инде ул!

Ә аннары Ш. Усманов тормышның бөтен тармакларына радио кертү фикере белән канатланып йөри башлый. Ул елларда радио «җене» хәзерге компьютерлаштыру шикелле үк, бик тә киң канат җәя. Аның белән күпләр мавыга. Шулай ук ясалма тел «эсперанто»ны җәелдерү буенча да шактый көч түгә Усманов.

Ә гомумән алганда, сез укып чыккан бу көндәлек язулар — шул чор чынбарлыгыннан алынган менә дигән документ. Ул безнең үткәнебез. Һәм хәтта әле, күпмедер дәрәҗәдә, бүгенгебез дә. Чөнки үткәннәр белән бүгенге тормыш бик тыгыз рәвештә бәйләнгән. Әнә шуңа күрә, укыйк та уйланыйк. Уйлаган уйларыбыз бик үк татлы булмаса да, моңа артык борчылмыйк. Алар янәшәсендә безнең күңелне күтәрердәй, йөрәкне дәртләндерердәй күренешләр дә бар ич әле. Әнә шулар турында да онытмыйк.

**Булат СОЛТАНБӘК.**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ ҺӘМ НӘСИМИ

XX йөз башы татар әдәбиятын Г. Тукай, Дәрдемәнд, Ш. Бабич, Н. Думави, М. Гафури, Һ. Такташ кебек күренекле шагыйрьләрдән башка күз алдына китереп булмый. Шул рәттән, давыллы романтик һәм гыйсъянчы Сәгыйть Рәмиев тә үзенчәлекле иҗаты белән аерым бер урын алып тора. Аның шигъри дөньясында рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятлары йогынтысы күзгә ташлана. Шулай да С. Рәмиев шигырьләрендәге Көнчыгыш классик поэзиясе традицияләренә тукталып китү бүгенге көндә әһәмиятлерәк булыр. Чөнки хәзерге вакытта татар әдәбияты үзенең көнчыгыш тамырларына яңадан әйләнеп кайта башлады.

Фарсы-таҗикның, гарәпнең урта гасырлар классик әдәбияты күп кенә төрки, шул исәптән татар шагыйрьләре өчен дә үзенчәлекле осталык мәктәбе булды. Көнчыгыш классикларының XX йөз башы татар шагыйрьләре һәм язучылары иҗатына булган йогынтысы турында күп кенә тикшерүчеләр әйтеп үткәннәр иде инде. Көнчыгыш Яңарыш чорының фәлсәфи, социаль, эстетик һәм этик идеяләре XX йөз башы татар әдәбиятында моңарчы булмаган искиткеч зур көч белән яңадан барлыкка килә. Моны Г. Халит, Х. Миңнегулов, Р. Ганиева хезмәтләре раслый. «Татарларның Фирдәүси, Хәйям, Низами, Гаттар, Руми, Сәгъди, Нәваи һәм башка урта гасыр шагыйрьләренең бөек әсәрләрен белүләре Идел һәм Урал буе укучыларының шактый зур интеллектуаль дәрәҗәсе, татар әдәбиятының бөтендөнья цивилизациясенең иң югары казанышларын үзләштерергә сәләтле булуын күрсәтеп тора»,— дип яза хәзерге чор галиме Хатыйп Миңнегулов.

Сәгыйть Рәмиев гарәп, фарсы телләрен, Көнчыгыш, бигрәк тә фарсы әдәбиятын — Сәгъди, Хәйям, Хафиз, Рудаки һәм башкалар әсәрләрен яхшы белгән. Шуңа күрә, һичшиксез, урта гасыр Көнчыгышының күп кенә шагыйрь һәм фикер ияләренең С. Рәмиевкә йогынтысы булган. Бу хакта шагыйрьнең иҗатын өйрәнүче К. Гыйрфанов, Г. Халит, Ш. Садретдиновлар язып үткәннәр иде инде.

Көнчыгыш классик поэзиясендә пантеизм идеясе аерым яңгыраш казанды. Алдынгы карашны чагылдыру чарасы, кайчак хәтта хөр фикерлелек һәм атеистик идеяләр хезмәтен үтәгән урта гасыр пантеизмында алла һәм җиһан — күтәренке рухлы бербөтен итеп санала. Моңа кадәр аллага гына кайтарып калдырылган бар нәрсә, алар аңлатканча, табигать җимеше дип игълан ителә. Кеше — «зат»тан, «җан иясе»ннән яңа мохит тудыручы, аны барлыкка китерүче алла дәрәҗәсенә күтәрелә.

Зирәклек һәм матурлык җәһәтеннән югары дәрәҗәдә торучы Көнчыгыш фәлсәфи поэзиясенең күренекле вәкилләренең исемнәре суфичылык белән бәйле. Бу фәлсәфи юнәлеш артына кара реакционерлар да, алдынгы фикерле кешеләр дә яшеренә торган булганнар. Нәкъ менә соңгылары мөселман илләрендә Яңарышны чагылдыручылар исәбенә керә. Суфичылык мөстәкыйль фикер йөртергә һәвәс кешеләрне үзенә һәрчак тартып торган. Суфичылык атамасын куллану — ислам чикләрендә калып, чынбарлыкта аннан читкә чыгарга мөмкинлек тә тудырган. Шуңа күрә мөселман дөньясының күп кенә эшлекләләренең суфичылык йогынтысын читләтеп үтә алмаулары бер дә гаҗәпләндерми. Бу хакта совет Көнчыгыш белгече Е. Бертельс язып үткән иде (Е. Бертельс. Очерк истории персидской литературы.— Л., 1923, 52 б.). Ибн-әл-Фәрид, Җәләлетдин Руми, Җами һәм башка күп кенә күренекле шагыйрьләр суфичылык вәкилләре булганнар.

Татар әдәбияты да суфичылык йогынтысыннан читтә кала алмый. Суфичылыкның урта гасырларда татар җәмгыятенең идеологик компоненты булуы һәм

үзенең чагылышын әдәбиятта табуы турында Рафаэль Мөхәммәтдинов та язып чыкты («Мирас», 1993 ел, № 12, 86 б.). Бу юнәлешнең янадан көчәюе XVII гасыр азагы һәм XVIII гасыр башына туры килә. Мәсәлән, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки һәм башка шагыйрьләр иҗаты суфичылык хыяллары белән сугарылган. Ләкин XIX гасыр урталарына суфичылыкның татар әдәбиятына булган йогынтысы кими төшә һәм бөтенләе белән югала дип әйтергә була.

XIII—XIV гасырларда Әзербайҗанда, суфичылык нигезендә, ул чорның барлык алдынгы карашлы кешеләрен берләштергән хуруфизм барлыкка килә. Хуруфизм бары тик ике дөньяны — Галәм белән Кешене генә таныган. Әзәрбайҗан тарихы һәм әдәбияты белгече Зумруд Кулизадә хуруфизм һәм аның вәкилләре турында түбәндәгеләрне язып үтә: «Хуруфистлар гыйбадәт илә түземлекне кабул итмиләр, алар буйсынмыйлар, буйсынырга чакырмыйлар да. Алар уйлаганча, кеше бөек һәм аның һәрбер теләге гамәлгә ашырга тиеш. Хуруфизмнан гыйсьян рухын аерып алып булмый» (З. Кулизаде. Хуруфизм и его представители в Азербайджане.— Баку, 1973, 71 б.). Хуруфизм, ул чор акыл ияләрен кызыксындырган иң зур юнәлеш буларак, күп кенә Көнчыгыш, аерым алганда, Әзәрбайҗанның талантлы шагыйрьләре иҗатына шактый зур йогынты ясаган. Хуруфизмны яклаучыларның берсе — Көнчыгышның шигъри һәм фәлсәфи фикеренең күренекле вәкиле әзәрбайҗанлы Сәид Имадеддин Нәсими иде.

Суфичылык белән хуруфизмның төп фикерләрен ачыклау безнең өчен бик мөһим, чөнки Нәсиминең дөньяга карашы шулар йогынтысында калыплашкан. Ә Нәсиминең дөньяга карашының төп нигезе исә бөтен иҗаты дәверендә пантеизм иде. Биредә Көнчыгыш классик фәлсәфи поэзиясенә һәм, барыннан да элек, хуруфизм белән пантеизмга мөрәҗәгать итү дә очраклы гына түгел. Бу традицияләр, Ш. Садретдинов билгеләп үткәнчә, 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә яңа көч белән Сәгыйть Рәмиев иҗатында яңара һәм шәхес идеаллары белән тыгыз үрелә. Нәсими иҗаты исә безнең өчен С. Рәмиевнең гыйсьянчылыгын аңлау юлында куәтле чыганак булып тора. Сәгыйть Рәмиевнең рухи һәм иҗади эзләнүләренә гыйсьянчылык, Хәйям, Хафиз, Нәсими һәм башка шагыйрьләр иҗатындагы бунтарь һәм атеистик фикерләрнең бигрәк тә авазаш булулары турында Р. Ганиева хезмәтләрендә ачык әйтелә. «Моны заман таләп итте. XX йөз башы татар дөньясында... Көнчыгыш поэзиясенең бу сыйфатларын үзләштерү әһәмиятле бурычларның берсе иде»,— дип яза ул (Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. 3 том.— К., 1986, 524 б.).

Кешене илаһилаштыру, аның матурлыгын күтәренке рухта җырлау Көнчыгыш фәлсәфи поэзиясенә хуруфизм һәм Нәсими шигырьләре барлыкка килгәнче ук хас булуына карамастан, нәкъ менә Нәсими тарихка Кеше җырчысы, аның иҗаты бөтенләе белән һәм аерым алганда, һәрбер газәле, Кешегә мәдхия булып керде. Бу хакта З. Кулизадә алда әйтеп үткән китабында яза.

Нәсими күк, С. Рәмиев тә үз чоры өчен бик укымышлы, белемле кеше булган. Ул Көнчыгыш классик поэзиясен, рус, аның аркылы Көнбатыш Европа әдәбиятларын бик әйбәт белгән. Гарәп, фарсы, рус телләрен су кебек эчкән. Мәдрәсәне бетергәч, С. Рәмиевне шунда фарсы телен укытырга калдыралар. Аның Көнчыгыш шагыйрьләренең күп кенә шигырьләрен фарсыча яттан сөйләп йөрүе турында замандашлары язып калдырган. Рәмиев рус язучыларын яратып тәрҗемә иткән. Шагыйрь исеме белән татар әдәбиятында яңа сыйфатлы, кешенең бөеклеге һәм матурлыгына дан җырлаучы, актив романтизм барлыкка килүе бәйле. Мондый романтизм татар әдәбиятына алга китү өчен бик кирәкле булган.

Нәсими өчен Кеше — «галәмнең тирәли әйләнә торган үзәге»,— дип әйтеп үткән иде әзәрбайҗан шагыйре Микаэль Рафили («Литературный Азербайджан», 1939 ел, № 11, 43 б.). Нәсиминең шигырен укып карыйк:

> Мин хәрәкәтсезлек терәге, ләкин көн артыннан көн, ел артыннан ел
> Минем тирәли кояш әйләнеш ясый, йолдызлар әйләнә.
>
> *«Үз-үземне мактау»*
> *(биредә һәм башка очракларда русчадан сүзгә-сүз тәрҗемә безнеке.— Ч. З.)*

Нәсими Кешене Галәмгә тиңли. Галәм аның сурәтендә — бөеклек, үлемсезлек, мәңгелек хәрәкәт. Галәм образы С. Рәмиев поэзиясенә дә үтеп керә, ләкин инде икенче төрлерәк, һәм бу табигый. Галәм сурәте Рәмиев өчен бер мәгънәле генә түгел. Бер яктан ул — яктылык чыганагы, шагыйрьнең җаны яши торган урын, ул аңар бәхет, камиллек, теләктәшлек эзләп ашкына:

Күрәм гали вә шатлыклы,
Галәм алла, бар ул алла...
Минем тик бер тәнем монда,
Үзем күктә, мәләк анда.

*«Күрәм гали...»*

Ләкин шул ук вакытта, чынбарлыктан дошманнарын таба алмыйча, Рәмиев янә галәм сурәтенә мөрәҗәгать итә. Хәзер инде галәм шагыйрь өчен — җир белән берлектә аңа каршы тора торган көч («Дөньяга», «Кеше»).

Кешене илаһилаштыру, башкача әйткәндә — алланы кешегә әверелдерү С. Рәмиев иҗатына да хас. Шагыйрьнең «мин — алла» дип раславы безгә Нәсиминең «алла — кеше улы, кеше ул — бөек» дигәнен хәтерләтә.

Әзәрбайҗан әдибе М. Дадаш-задә болай ди: «Нәсими алланы инкарь итми, ислам канунннарына каршы кеше күңеленә» урнаштыра» (Дадаш-заде М. Азербайджанская литература.— М., 1979. 53 б.). Аның белән килешми мөмкин түгел:

Мин, Нәсими, алла белән тоташмын,
Һәм үлемсез мин, мин — алла үзе!

*«Синең күзләреңдә»*

«Алла» дигән шигырендә Сәгыйть Рәмиев тә алланы тулаем кире какмый, киресенчә, ул аңарга гына баш ия. Ләкин, алланы зурлап, Рәмиев һич кенә дә үзендә кешене түбәнсетми. Кеше белән алланы тиңләп, кешене алла дәрәҗәсенә күтәрә:

Беләм тик: бу җаным аннан
Яратылган, мин — ул, ул — мин.

Әйтеп үтәргә кирәк, Рәмиев «мин — алла» дип, Нәсими кебек аерым бер тәгълимат таратучы булмаган. Нәсиминең поэзиясе белән фәлсәфә күп дәрәҗәдә дингә, руханиләргә ялкынлы протест ул. Рәмиев гыйсьянчылыгы исә аллага каршы көрәш түгел, ә бәлки, татар әдибе Хәсән Хәйри язганча, «индивидуалистлык бунты, шәхеснең «эчке алласын» ачуы, «мин»лекне даулау иде» (Х. Хәйри. Һади Такташ.— К., 1984. 33 б.).

Кеше Нәсими өчен дә, Рәмиев өчен дә — зур көчкә ия, ул үзеннән өстен хакимнәрне танымый:

Солтан да, шаһ та син, алла да син, син барыннан көчле.

**Нәсими.** *«Нәсихәт»*.

«Мин» димен мин, «мин» дидисәм,
Миңа бер зур көч кирә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

**С. Рәмиев** *«Мин»*.

Нәсими дә, Рәмиев тә һәркайсы, һәр кешегә түгел, ә азат, иң бөек тәртип кешесенә дан җырлыйлар. Ницше, Бальмонт, Җәбран кебек, С. Рәмиевнең замандашлары да үз иҗатлары белән нәкъ шундый кешене данлыйлар. Нәрсәдән гыйбарәт соң кешенең эчке ireклеге? Рим философы, стоицизм вәкиле Сенека сүзләренә караганда, «кешеләрдән дә, аллалардан да курыкмауда. Үзеңә үзең хуҗа булу — бәя биреп бетергесез бәхет» (С. Сатыбекова. Гуманизм Аль-Фараби.— Алма-Ата, 1975. 45 б). Нәсими белән Рәмиевнең лирик геройлары алладан да, патшадан да, кешеләрдән дә курыкмый. Алар үзләренә үзләре хуҗа, алай гына да түгел, алар — җир һәм галәм хуҗалары. Бу хакта безгә Нәсиминең Н. Гребнев русчага тәрҗемә иткән «Источник жизни», С. Рәмиевнең «Мин» дигән шигырьләре әйтеп тора.

Нәсими белән чагыштырып караганда, Рәмиевнең лирик герое хәрәкәтчәнрәк шәхес. Бу очракта ул Гомәр Хәйямгә якынрак. Рәмиев чынбарлыкка ләгънәт яудырып кына калмый, ул баш күтәрә, күгенә дә, алласына да каршы чыга:

Җир-суын да яндырыр һәм
Күкләрен ватар идем!..

*«Дөньяга»*

Булыр бер көн: ватар, көл итәрмен
Гарше көрси, сәман, тәхетеңне!..

*«Маҗид сүзе».*

Ләкин Рәмиевнең лирик героеның җимерүе — төзү хакына. Башка халыклардагы Рәмиевнең замандаш шагыйрьләре иҗатлары да яңа тормыш хакына иске тормышны инкарь итә.

Нәсиминең фәлсәфи поэзиясендә кеше идеалы — өндәүче, фикер иясе, үзенең асылына төшенгән кеше — кеше-алла. Һәм шул ук вакытта ул — үзенең чәчәк аткан җәннәтен җирдә тапкан гади бер кеше. Рәмиев тә җәннәтне күктән эзләми, ул да аны ахирәттә түгел, бу дөньяда тапкан:

Аяк баскан җирем барсы
Гөлстан бер, җинанлардан.

*«Алла.»*

Пантеистик суфичылык кешегә карата мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләгән. Пантеистлар матурлыкны һәм мәхәббәтне бөтен галәмне җанландыручы илаһи көч итеп аңлаттылар. Барлык кыйммәтнең үлчәме итеп Нәсими дә мәхәббәтне сайлады. Нәсими илаһи яктылыкны Матурлыкта күрә, ә матурлык үзенең гәүдәләнешен шагыйрьнең сөйгәнендә тапкан. Аның җирдәге матурлыгында — Алла үзе:

Җаным, синең күңелеңдә алла үзе яши.

*«Җаным, синең күңелеңдә...»*

Алла, Кыйбла, Мәккә гыйбадәтханәсе, хур кызы, Коръән сурәсе, дип дәшә Нәсими сөйгәненә — гади җир кызына:

Син — хур кызы, син — Коръән сурәсе,
Алла дип әйтергә кирәк сиңа,
Ялгыш, кеше, дип атыйлар сине.

*«Син — хур кызы».*

С. Рәмиев тә олы, саф мәхәббәткә, матурлыкка дан җырлый. Ул да гади җир кызы алдында баш ия, аңар үзенең иң нечкә хисләрен илтеп җиткерү рухы белән яши («Ул», «Син», «Җәмилә», «Кайвакытта уйлыймын мин...»). Рәмиев сурәтләвендә хатын-кыз җирдә һәм җиһанда булган барлык матурлыкны үзенә җыйган («Ул»). Сөйгәне хакына Рәмиев бөтен кануннардан баш тарта, бары тик аңар гына табына («Җәмилә»). Рәмиев өчен сөйгәне — үзенең «мин»е белән бертигез рәвештә аңа җан өргән илаһи зат:

Мине утка аткан да — син,
Мине суга салган да — син,
Утта янсам, суга батсам,
Тартып алган аллам да — син!

*«Син».*

Урта гасырларда ук Көнчыгыш шагыйрьләре хатын-кызны ир-аттан рухи яктан көчлерәк дип санаганнар. Хафиз газәлләреннән күрәбез ки: шагыйрь Сөйгәне алдында аның бөеклеге һәм чын мәгънәдә Хатын-кыз булганлыгы өчен баш ия:

Беркем алдында да баш имәгән идем,—
Ул килә башласа — йөзтүбән егылам.

*«Күңел — ул нибары савыт...»*

Рәмиевкә кайтсак, Ш. Садретдинов болай дип яза: «Ул гади татар кызы образын иҗат итеп, аны Ләйлә, Ширин, Зөләйха дәрәҗәләренә генә түгел, Алла образына хәтлек күтәрә, аңар табына, аның өчен үлә һәм яңадан туа».

Хатын-кызны дәрәҗәләү Рәмиевнең прозасына да хас. Аның пьесаларының берсе шулай атала да: «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (Шагыйрьнең хатын-кызны яклап чыгуының кыюлыгын, бу теманың ул чор өчен татар әдәбиятында яңа

булуын шуннан гына да күреп була: әлеге пьесаның бер тиражы руханилар таләбе белән яндырыла).

Рәмиев үзенең иҗаты белән кешелек дөньясының хатын-кызга никадәр бурычлы булуын күрсәтә белде. Күп кенә татар тикшерүчеләре, гади татар кызын аллага тиңләп, ана дан җырлау безнең әдәбиятта 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә генә мөмкин булды, дип килделәр. Ләкин без мондый фикер белән килешеп бетә алмыйбыз. С. Рәмиевкә һәм башка XX йөз башы шагыйрьләренә кадәр, X гасырның беренче яртысында ук Габделҗаббар Кандалый татар кызларына дан җырлаган. Аның хатын-кызга багышланган күп кенә шигырьләре, үгет-нәсихәттән азат булмаса да, алар арасында хатын-кызны яктылык нуры, хур кызлары белән чагыштырганнары да аз түгел:

Күрдекем сагьәт җиһанда китде зольмәт, килде нур,
Йә кояш сән, йаки ай сән, йаки җәннәт эчрә хур!

*«Бер тәбәссем садир улса...»*

Кандалый иҗатында фанатиклыкка каршы протест та, кеше өчен бәйсезлек теләге дә, алланың үзе белән бер дәрәҗәдә булырга омтылыш та яңгырады («Бу илләрдә торып калсам...»). Шәхеснең уянуы, үзенең кешелек дәрәҗәсен аңлавы инде ул чорга ук хас булган. А. Сибгатуллина, Габделҗаббар Кандалый тормышта да, иҗатында да гыйсьянчы булган, дигән фикерне уздыра. Кырыгынчы елларда язучы М. Гали «татар әдәбиятында С. Рәмиевкә кадәр аллага каршы мондый көчле формада бунт түгел, «каш астыннан караш» та булмаган»,— дип язып чыкты. («Совет әдәбияты», 1940 ел, № 4, 104 б.). Ләкин без аның белән килешә алмыйбыз. Көчле рәвештә баш күтәрү булмаса да, Г. Кандалый иҗатын карап үтү безгә Сәгыйть Рәмиевкә кадәр үк «каш астыннан караш» татар әдәбиятында булган дияргә тулысынча хокук бирә.

Мамед Ариф Нәсимигә багышланган мәкаләсендә яза: «Мәхәббәткә, хатын-кызның матурлыгына дан җырлап, шагыйрь укучыларны чын мәгънәсендә галәмкүләм гомуми нәтиҗәләргә юнәлтә» («Бакинский рабочий», 1973 ел, 13 март). Аның белән килешми мөмкин түгел. Нәсими безне «чын мәгънәдә гомуми нәтиҗәләргә» юнәлтә икән, С. Рәмиев исә хатын-кызга иң зур өметләрен баглап, аңар милләтне яңартучы һәм саклап калучы миссиясен йөкләп, гомуми нәтиҗәләрен дә әйтеп бирде:

Бетмә надан, туг яңадан
Мәгърифәтле анадан.

*«Таң вакыты»*

Милләтне саклап калучы хатын-кыз образы ул — милләт сулышы (мәсәлән, Ф. Әмирхан иҗаты), өстәвенә заман сулышы иде. Әйтик, рус әдәбиятында — А. Блок «Стихи о Прекрасной Даме» бәйләмендә камилләштергән, Вл. Соловьев күтәреп чыккан Вечная Женственность.

Нәсими үз дәверенең әхлакый яктан камил булмавын бик авыр кичергән. Шул сәбәптән шагыйрь иҗатында суфичылык һәм читләшкәнлек мотивлары барлыкка килә. Дөньяга нәфрәт белән карау, аның яраксызлыгын аңлау хисләре өстенлек ала. Бердәнбер котылу чарасы — дөньяны кире кагып, ташлап китүдә:

Бу фани дөньяны калдырам, чөнки тапмыймын мин хакыйкать.

*«Бу фани дөньяны калдырам...»*

Нәсиминең дөньядан читләшүен тикшерүчеләр болай дип аңлаталар: шагыйрьнең туган иле өчләтә изелү аркасында күп очракта кешеләрдә кешелеклек үтерелгән, өметләр нәтиҗәсез кала торган булган.

Дөньяда хакыйкать булмау С. Рәмиев иҗатында да тирән кичерелеш таба. Сәбәпләренең берсе — реакция булса, «Тәсәлла», «Талдым» кебек шигырьләрен Рәмиев 1916 елда жандармерия аңардан яшерен агент ясарга җыенган вакытта Уфада яза. Бу фаҗигале вакыйгалардан соң Рәмиев поэзиясендә талчыгу һәм читләшкәнлек мотивлары барлыкка килә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шагыйрь алардан арына алмый. 1917 ел борылышын да кабул итми.

«Ямь» шигырендә Рәмиев котылу чарасын, Нәсими кебек, фани дөньядан китүдә күрә. Монда без Рәмиевнең Нәсимидән кискен аермасын күрәбез. Әгәр дә Нәсиминең лирик герое зирәгрәк, тынычрак булса, Рәмиевнеке, киресенчә —

ялкынлырак, стихиячел һәм ихтыярсызрак. Ул бу дөньяны Нәсими кебек сабыр нәфрәт белән калдырмый, ә бәлки дөньясына ләгънәт ора, сугыш белән яный.

«Күңелле булмадым...» шигырендә Рәмиев туудан бирле үк үзенең юлдашлары кайгы һәм моң булулары турында яза. Галәм үзе аңар көчтән килмәслек авырлыклар йөкләгән. Шуңа күрә шагыйрь бөтен галәмгә ләгънәт ора. Рәмиевнең ләгънәтләре, Нәсими белән чагыштырып караганда, бөтен галәм масштабын ала:

Нәләт барлык миңа каршы
Туган йолдыз һәм айларга.

*«Кеше».*

Карыйм үз йолдызымны, тик табалсам,
Табам нурсыз, сүнәр төсле тора ул,
Җиһанга бер бикяр ләгънәт ора ул.

*«Күңелле булмадым...»*

Рәмиев хәтта титаник шәхесләрнең дә ялгыз баш күтәрүенең җәмгыять алдында көчсез булуын белми кала алмаган, әлбәттә. Аның лирик герое дөньяга һәм галәмгә ләгънәт әйтә, ә үзе шул ук вакытта ул нәләтләрнең, файдасыз һәм буш икәнен таный («бикяр ләгънәт...»).

Әгәр дә төшенкелек мотивлары күп очракта башлангыч Нәсимигә генә хас булып, аның иҗатында өстенлек алмаса, Рәмиев иҗатында исә моң-зар, дөньядан китү темасы, яңа таң атуына ышану, матурлык алдында баш ию һәм бәхеткә сусау белән беррәттән, соңгы «Сүзем һәм үзем» («Үзем») дигән шигыренә хәтле үтеп керә. Ләкин С. Рәмиев бөтенләе белән пессимизмга бирелә, дип әйтергә ярамый. Юк, шагыйрь идеалы — гуманистик идеал. Пессимистик мотивлар чагылдырган шигырьләр рәтендә «Мин», «Син», «Ул», «Җәмилә», «Ул йоклый», «Ул торды» дигән, яшәү дәрте бәреп торган шигырьләр барын да онытырга ярамый.

Рәмиев реакция хөкем сөргән елларда кешегә, кешенең көрәшергә сәләтле «мин»енә дан җырлады. Рәмиевнең Кешесе эзләнүләрендә нык торды, ул беркайчан да якты көннәр килүенә өметен ташламады:

Әллә әйләнер микән җил
Һәм исәр татлы вакыт?

*«Алданган».*

Кешене камилләштерү, аның рухи һәм әхлак йөзен тагын да яхшырту теләге — барлык татар язучылары һәм шагыйрьләре өчен дә уртак сыйфат. Рәмиевнең дә лирик герое, дөньяда явызлык хөкем сөрүенә карамастан, камиллеккә һәм гармониягә омтыла:

Нигә уйлыйм тәгали мин
Дәнилек җир тутырганда?

*«Талдым».*

С. Рәмиев сурәтләвенчә, камиллеккә илтә торган юл бик үзенчәлекле: ул газаплар аркылы үтә. Шуңа күрә шагыйрь үзенең күңелен матурлыкка барып җиткәнче сызларга, янырга өнди:

Сызла, сызлап, син мәхәббәт
Ялкынын гөлләр яса,
Мәңге хәсрәт һәм кара төн
Елларын көннәр яза!..

*«Сызла, күңлем».*

Нәсими, кешене бернинди чикләр белән киртәләп булмый, кеше рухы бернигә дә сыймый, дип әйтеп килде. XX йөз башында шагыйрь Сәгыйть Рәмиев та кеше иреген чикләүгә каршы чыкты:

...Юк, канәгать итми күңлем!
Тар миңа чикле иман.

*«Киң иман».*

Үзенең тәгълиматы өчен Нәсими гомерен бирде: аның тиресен тереләй туныйлар. Шагыйрьнең тормышы газаплы булды. Нәсими безнең күз алдыбызга барыннан да элек буйсынмас һәм баш имәс шәхес булып килеп баса.

XX йөз башында Сәгыйть Рәмиевнең иҗаты белән баш күтәреп чыгуы да — зур кыюлык иде. Нурсыз реакция елларында ул үзенең иҗатында Көнчыгыш классик поэзиясенең иң күркәм йолаларын яңарта алды. Нәсими артыннан башка чорда һәм башка халык арасында Рәмиев кешенең «мин»ен аллага тиңләде, кешене җир һәм күкләр хуҗасы дип игълан итте.

Рәмиев иҗатында гыйсьянчылык мотивлары яңа көч ала. Соңгы елларда шагыйрьнең эзеннән баручылар да шактый булган. Мәсәлән, Ш. Бабич, М. Гафури һәм башкалар. С. Рәмиевтән соң гыйсьянчылыкның иң күренекле вәкиле булып Һ. Такташ санала.

Көнчыгыш классик поэзиясенең иң яхшы традицияләренә таянып башка күп кенә татар шагыйрьләре дә иҗат иткән. Мәсәлән, Г. Тукай, Дәрдемәнд, Ш. Бабич һәм башкалар.

XX йөз башы татар әдәбиятында хатын-кызны, мәхәббәтне идеаллаштыру да, милли үзаң үсеше турында әйтмәгәндә, Көнчыгыш Яңарышы традицияләренең дәвамы булып тора.

Көнчыгыш әдәбиятының (бигрәк тә урта гасыр) күп кенә вәкилләре поэзиясе дөньяга фәлсәфи караш чагылдырган кебек, С. Рәмиев шигырьләре дә — дөньяга фәлсәфә күзлегеннән үзенчәлекле бер караш.

Сәгыйть Рәмиев иҗатын бигрәк тә Имадеддин Нәсими йөзендә гәүдәләндерелгән Көнчыгыш классик фәлсәфи поэзиясе фонында карау безгә Рәмиевның иҗади мөстәкыйльлеген, аның иҗатының милли һәм бөтендөнья әдәбиятының гомуми үсешендә алып торган урынын танырга мөмкинлек бирә. Нәсими һәм Рәмиев иҗатында булган охшашлык белән беррәттән, җитди аермалар да бар. Аларны тарихи процессның урынчыл аерымлыклары һәм шулар аркасында барлыкка килгән милли-тарихи үзенчәлекләрне китереп чыгара.

Көнчыгыш поэзиясенең күренекле шагыйре Нәсими иҗаты күп әдәбиятлар, бигрәк тә Урта Азия халыклары әдәбиятларының үсешенә зур йогынты ясады. Без бүген һич шикләнмичә Нәсиминең һәм аның фәлсәфи поэзиясенең тагын бер әдәбиятка — татар әдәбиятына, аерым алып әйткәндә Сәгыйть Рәмиев иҗатына уңай йогынты ясавы турында әйтә алабыз.

**Чулпан ЗАРИПОВА,**
Казан дәүләт педагогия институты аспиранткасы.

# БЕРӘГӘЙЛЕ БУЛСЫН ИДЕ

## БУЛАЧАК «ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ» (ТЭ)НӘ БЕР КАРАШ

«Татар энциклопедиясе», аны төзү принциплары, кыенлыклары, бу эшнең барышы турында фән даирәсендә сүзләр аз булмады. Энциклопедия өчен язылган мәкаләләр фән тармаклары буенча галимнәр җыелышларында тикшерелде, аларга карата күп фикерләр әйтелде. Әмма татар вакытлы матбугаты бу гаять әһәмиятле эшне тиешенчә яктыртмады, радио-телевидениебез дә бу турыда тиешле югарылыкта тапшырулар алып бармады. Энциклопедия төзүгә гыйльми җәмәгатьчелекне тагын да кинрәк тарту өчен, югыйсә, бу бик кирәк иде.

Билгеле ки, энциклопедия — белемнәрнең барлык яки аерым тармаклары буенча фәнни яки фәнни-популяр белешмәлек. Дөньяның алга киткән халыклары үз энциклопедияләрен инде күптән төзеде, без яшәгән урыс һәм совет империясе хакимияте татар халкына әлегә кадәр мондый мөмкинлекне бирмәгән иде.

Энциклопедия үзәгендә табигатькә яки җәмгыятькә мәгълүм бер караш тора. Бу караш андагы мәкаләләрдә чагыла. Энциклопедия әзерләүнең бөтен дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә — төзүчеләр никадәр объектив булырга тырышса да, үз заманының, иленең, халкының сәяси-икътисадый идеологиясеннән бик читкә тайпыла алмый. Мәсәлән, фән дөньясында иң мәшһүрләрдән булган «Британия энциклопедиясе», Италиянең «Фән, әдәбият, сәнгать энциклопедиясе», Алманиянең «Брокгауз энциклопедиясе», Франциянең Ларуссе фирмасы чыгарган күпсанлы энциклопедияләре, «Төрек энциклопедиясе», «Ислам энциклопедиясе» табигатьне, җәмгыятьне, аның күптөрле күренешләрен шактый үзенчәлекле аңлаталар.

«ТЭ»нең дә үз төп юлы булырга тиеш, әлбәттә. Мәсәлән, объективлык төп принцип булсын иде. Ул чакта энциклопедиябез милләтебезне бүгенге авыр хәленнән чыгаруда җитди этәргеч бирер иде. Франциянең Д. Дидро һәм Ш. Д. Аламбер редакциясендә чыккан «Энциклопедия яки фәннәрнең, сәнгатьнең, һөнәрләрнең аңлатмалы сүзлеге» XVIII—XIX йөзләр Франция мәгърифәтенең төп байракчысы булган ич.

«ТЭ»нең сүзлеге басылып чыкты, ул 16 мең берәмлекне үз эченә ала, димәк, энциклопедиягә кертү өчен 16 мең мәкалә язылып тикшерелгән. Галимнәр бу сүзлек басылганчы һәм басылып чыккач үткәрелгән фикер алышуларда да, аерым тәртиптә дә үз сүзләрен әйттеләр. Табигый ки, энциклопедия мәкаләләрен камилләштерү, яңа белешмәләр язу эше һаман дәвам итә, мәгълүмат базасы тулыландырыла.

«ТЭ»нең гуманитар бүлеген тикшерүдә катнашкан галимнәр андагы мәкаләләрнең эчтәлегендә мәгълүм күләмдә заман сулышы, фәннәрнең бүгенге казанышлары чагылуын билгеләп үттеләр. Байтак мәкаләләр бөек державачыл шовинистик, зарарлы большевистик карашлардан азат, бу тарихка караган белешмәләрдә дә шулай. Мәсәлән, 1552 елдан соң Казан ханлыгы халыклары алып барган азатлык сугышлары элеккечә «фетнә» дип түгел, «Казан ханлыгының бәйсезлеген торгызу өчен сугыш» дип бирелә. Мондый уңай якларны күп китерергә була. Шул ук вакытта галимнәр энциклопедия мәкаләләрендәге зур ялгышларны күрсәтеп, аны төзү принципларының кайберләре белән килешмәүләрен дә әйттеләр.

Галимнәрнең фикере энциклопедия төзүчеләргә җиткерелде, алар тәнкыйтьләгән ялгышларның кайберләрен төзәтү эше бара, кайбер мәсьәләләр буенча бәхәсләр кабынып китә. Мәкаләләрнең авторлары белән киңәшелә, ләкин кайберәүләр житешсезлекләрне танырга теләми. Югыйсә:

а) Аерым белешмәләрдә татар халкы һәм дәүләтләре тарихы фәнни яктан бәхәсле нигездә язылган булуы, аларда объективлык җитмәве ап-ачык;

б) Татар халкының үз дәүләтчелеген торгызу өчен гадел көрәшен аңламау, аның тарихи әһәмиятен күрмәү дә ярылып ята;

в) Аерым шәхесләрнең энциклопедиягә кертелүе яки кертелмәве дә аптырашка калдыра.

Фәнне галимнәр тудыра, ә ул галим — билгеле бер дәүләтнең, милләтнең, сыйныфның, иҗтимагый системаның вәкиле. Бу иҗтимагый фәннәрдә бик тә нык чагыла. Мәсәлән, татар халкының тарихын алып карыйк. Моңа кадәр аны күбесенчә урыс галимнәре үз чыганакларына таянып язды. Явыз Иван заманыннан алып урыс тарихи чыганаклары берничә мәртәбә «төзәтелеп», татарга каршы юнәлдереп иҗат ителгән. Урыс летописьләре күчерелеп, «редакцияләнеп» басыл-

ган, татарга каршы юнәлдерелгән «Царственная книга» төзелгән. Бу чыганаклар шундый итеп төзәтелгән ки, урыс кенәзлекләренең, урыс халкының артта калуына, наданлыгына, әчкечелеккә, фәхишәлеккә, барлык бүтән кыргый гадәтләргә бирелүендә Болгарстан, Алтын Урда, Казан, Кырым һәм бүтән ханлыклар татарлары гаепле икән! Татар урысның тарихи дошманы итеп күрсәтелә, ә урыс идеологиясе буенча, «дошман юк ителә» (М. Горький)!!

Урыс тарихчылары татар халкының, аның дәүләтләренең үткәнен аңлы рәвештә бозып сурәтләгән, юри саташтырган чыганакларга таянып, Русиянең империячел-шовинистик төшенчәләренә — «Өченче Рим» концепциясенә ярашлы итеп яздылар.

Октябрьгә кадәрге татар галимнәре Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхретдин, Г. Әхмәрев һәм бүтәннәр халкыбызның тарихын объективрак язарга тырыштылар, ләкин аларның чыганаклары чикле иде. Шуның өстенә, патша цензурасы дөрес язганны үткәрмәде дә. Кайвакыт татар тарихчылары да урыс чыганакларын тәнкыйтьсез кабул иттеләр. Мәсәлән, үз халкының азатлыгы өчен көрәшкән Һади Атласыйның Казан һәм Себер ханлыклары, Сөембикә турындагы хезмәтләре урыс чыганакларына артык ышанып, тәнкыйтьсез караштан язылган.

Татар галимнәренең әнә шундый хезмәтләре дә Октябрьдән соң коммунистик идеология тарафыннан тыелды. Совет чорында татар тарихы нигездә 1917 елга кадәрге рәсми урыс тарихы киләчәкләрендә (традицияләрендә) язылды. Коммунистик хакимият дөньяда беренче булып неоколониаль система урнаштырды. Совет чоры тарихы бу системаның бер колониясе булган Татарстанның уңышларын күпертеп күрсәтте — ул арада татар милләте, аның теле, мәдәни мирасы исә тәмам юкка чыгу хәленә килеп житте.

«ТЭ»н төзүчеләр татар халкы, татар дәүләтләре тарихын яктыртканда, алда искәрткәнемчә, нигездә дөрес караштa торалар, әмма аларга бу эштә кыюлык һәм эзлеклелек житми. Моңа Татарстанның «бердәм, бүленмәс Русия» кулыннан ычкына алмавы да, башка сәбәпләр дә комачаулый, әлбәттә.

«ТЭ» бөтен дөнья өчен языла, ә дөнья татарның дөрес тарихын белергә тиеш.

Татар халкының азатлыгын кайтару, дәүләтен торгызу өчен алып барыла торган милли-азатлык көрәше «ТЭ»ндә иң четерекле мәсьәлә, тик ул, кызганыч ки, тиешенчә әтрафлы һәм дөрес яктыртылмый. Татар халкының милли-азатлык көрәше төрле чорларда төрле формаларда барган. XVI гасырның икенче яртысында ул халкыбызның Ватан сугышы рәвешендә; соңрак гомум Русия крестьян сугышларында (Булавин, Разин, Пугачев житәкчелегендә) катнашуы төсендә; Батырша, Карасакал житәкләгән һәм бүтән баш күтәрүләр формасында мәйданга чыккан. Бу көрәшләр мәгърифәтне, мәдәниятне үстерү, ислам динен көчәйтү, шуның нигезендә милләтне, аның мирасын, үзаңын саклауга юнәлтелгән иде.

Милли-азатлык көрәше татарның үз ватаны чикләрендә дә, вакыты белән аннан бик еракларда да алып барылган. Гасырыбызның 20—40 елларында бу көрәш илебез читеннән еракларда — Харбинда, Хайларда, Мукденда, Варшавада, Берлинда, Корея, Япония, Төркия шәһәрләрендә дәвам иттерелгән. Бу көрәш ватаныбыздан ерак җирләрдә сугыштан соң да, бүген дә алып барыла.

Татар халкының үз дәүләтен торгызырга, шул максат өчен көрәшергә хакы бар. Энциклопедиядә аны яктыртудан курыкмаска кирәк.

Бу көрәш күпмедер дәрәҗәдә булачак энциклопедиядә урын алган, ләкин кабатлап әйтәм, мәкаләләрдә эзлеклелек, тарихи хакыйкать житми.

Халкыбызны чукындыру, ислам диненә каршы көрәш тә энциклопедиядә тиешенчә урын алмаган әле. Татарстаннан читтә яшәгән милләттәшләребез тарихы да бик зәгыйфь яктыртылган. Моны Себер татарлары тарихы мисалында да күреп була. Искер, Чинги Тора калалары, Себер ханнары, Себер татарларының 1395 елда ислам динен кабул итүе, Күчем хан һәм аның исеме риваятьләргә кергән хатыны Сүзге (Сөзге?), Себер татарларының изге каберләре — әстаналар турында, Себер татарларының шактый зур компонентлары — саз татарлары, бохаралылар һәм бүтәннәр хакында да мәгълүматлар юк.

Әстерхан татарлары, Башкортстанда яшәүче бер миллион ярым милләттәшләребез, Көньяк Уралда, Казагыстанда, Урта Азиядә, Кавказда яшәгән һәм әле дә яшәүче татарлар турында белешмәләр гафу ителмәслек дәрәҗәдә аз.

Энциклопедиядә урын алган бер ямьсез күренеш — большевизмнан котыла алмау. Большевиклар властена каршы булган «Чапан сугышы», «Сәнәкчеләр сугышы» советка каршы «фетнә» дип бирелә. Аның каравы, Татарстанда

тоталитар режим урнаштыручы «каһарманнарның» берсен дә калдырмыйча — Ходоровский, Грасис, Олькеницкий, Тихомирнов, Лацис, Шейнкман һәм алар ишләренең исемнәрен мактаулы төстә «ТЭ»нә шыплап тутырып, үзебезне мәсхәрәләү кирәкме икән? Алар турындагы мәкаләләр кичәге ВКП(б) тарихы рухында язылган, эшчәнлекләренә тәнкыйтьнең эзе дә күренми. Югыйсә бу бәндәләр — татар милли-азатлык көрәшен буучылар, хәтта большевистик бутафор Автономияле Татарстанны төзүгә дә каршы көрәшүчеләр.

Энциклопедия сүзлеген тикшерү җыелышларында галимнәрне гаҗәпкә калдырган һәм көчле нәфрәт уяткан нәрсә — «Татар энциклопедиясе»нә кертелгән номенклатура чиновниклары. Кем генә юк анда! Төрле елларда компартия, дәүләт аппаратына оялаган түрәләр, район, шәһәр масштабындагы җитәкчеләр һ. б. йөзләгән «бөек» кемсәләр.. Әле ике-өч ел гына район, шәһәр башлыгы булып эшләүчеләр дә, Министрлар кабинетында «күләгәдә» хезмәт итүчеләр дә онытылмаган. Район җитәкчелегенә куелып, бу эшне тарта алмаганлыктан, яше җиткәнче үк пенсиягә чыгарылган, шул ук вакытта Казанда фатир биреп бүләкләнгән «каһарманнар» да «ТЭ»нә кукыраеп кереп утырган. Исемнәре Алмыш, Кубрат ханнар, Сөембикә, Батырша, Мәрҗаниләр белән янәшә!

Энциклопедия төзүчеләр: «Бу безнең теләк буенча түгел, өстән әмер биреп кертелде», — диләр.

Коммунистик олигархиянең хакимлеге кайчангача барыр? Үзләренә махсус шифаханәләр кордырып, махсус санаторийлар төзетеп, дәрәҗәле шәп йортларда яшәп, персональ югары пенсияләр алып, иркәләнеп-назланып яшәүчеләргә бәлки махсус «Партократия энциклопедиясе» чыгару кулаерактыр? Хәзер заман башка, «Татар энциклопедиясе» битләренә теләсә кемне тутыру шома гына үтеп китәр дип уйлау хата. Дөньяны көлдермик, бу изге булырга тиешле китапны лиллипутлар, яманатлы бәндәләрне кертеп пычратмыйк, бүгенге һәлакәтле хәлгә шулар китерде ич инде безне!

Энциклопедиянең сәнгать бүлегендә дә хәл ителмәгән мәсьәләләр бар әле. Кайбер таләпләргә туры килми, дип, «Халык артисты» исемен алмаган, дип, сәнгатебезгә зур өлеш керткән, тамашачы күңелендә абруйлы урын алган шактый сәнгатькәрләребез хакында энциклопедиябездә белешмә бирү ниятләнмәгән. Мәсәлән, баянчы Мохтар Әхмәдиев, җырчы Динә Сиражетдинова, Габдулла Рәхимкулов, Ания Туишова, Гөлзада Сафиуллина, Габделхак Шаһиев исемнәре дә анда юк. Аларга мактаулы исемнәрне, тиеш булса да, әлеге бюрократик номенклатура үзе бирми калдырды лабаса. Аннары тагын бер парадокс — «Атказанган сәнгать эшлеклесе» исемен алучылар «ТЭ»нә кертелгән, ә «Атказанган мәдәният хезмәткәре» — юк. Беренчеләре, күбесенчә, ят милләт вәкилләре, икенчеләре, игътибарга лаексызлары — башлыча, татарлар.

XX йөз башында татар музыкаль культурасы зур үсеш ала, ләкин бу дәвернең музыкантлары, җырчылары энциклопедиягә кермәгән диярлек.

Мәгариф, педагогика бүлеге «ТЭ»нең шактый тулы эшләнгән өлеше, анда бай мәгълүмат тупланган. Ләкин ни өчендер 40 ел буена татар балаларын «Әлифба» китабы, укытучыларны уку ярдәмлекләре белән тәэмин итеп килүче ике галим укытучыбыз — Сәләй ага Вәгыйзов, Рәмзия апа Вәлитова исемнәре энциклопедиябездә очрамый. Халык мәгарифе министрлыгы хезмәткәрләре «Әлифба» авторларын белми яшәмидер ич?

Милләтебез тарихында, аның мәгърифәтен, мәдәниятен үстерүдә, ислам диненең ныгытуда һәм шул нигездә татарны саклап калуда бәя биреп бетергесез зур роль уйнаган мәдрәсәләребезнең күпчелеге «ТЭ»ндә тиешенчә яктыртылмаган. «Мәгълүмат, чыганак юк», — диләр. Бәлки шулайдыр да. Ләкин Мәрҗанинең «Мөстәфаделәхбар»ында йөздән артык мәдрәсәбез турында хәбәр бирелә ич.

«ТЭ»өстендә эш әле дәвам итә. Кимчелекләрне төзәтергә, мәгълүматны тулыландырырга әле соң түгел. Энциклопедиябезне югары дәрәҗәдәге фәнни хезмәт итү өчен җәмәгатьчелекне тулырак тарту кирәктер. Һәм... ашыкмаска, кабаланмаска, чиле-пешле белешмәләк тәкъдим итеп хурлыкка калмыйсы иде. Милли энциклопедиябезнең беренчесе булса да, төерле булмасын, берәгәйле булсын ул!

**Габделбәр ФӘЙЗРАХМАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исемендәге ТӘТИ өлкән фәнни хезмәткәре.

Азадә-Гайшә Рүрлих

# АЛТЫН УРДАНЫҢ БҮГЕНГЕ ВАРИСЛАРЫ

**1223** елда көньяк урыс далаларына бәреп кергән беренче монгол явы хакында коты алынган Киев елъязмачысы: «Аларны юньләп берәү дә белми: кемнәр алар, иманнары нинди. Татар дип аталалар, кайсылары үзләрен таурмән дип таныта, бәҗәнәкләргә дуслар, имеш»,— дип яза.

Елъязмачының каушап калуы һәм өзек-төтек хәбәр бирүе, урыслар күчмәләр явы белән беренче мәртәбә очрашкан, икән дигән ялгыш фикергә дә китерергә мөмкин. Әмма тарихи хакыйкать елъязмачы аңлатмасын кире кага, чөнки Киев Русе славяннары дала күчмәннәре белән IX йөздән үк төрле дәрәҗәдәге социаль, икътисадый, сәяси һәм хәрби багланышларга керә башлый. Көнчыгыш славяннар Урта Иделдәге һәм Кара диңгез буендагы шәһәр мәдәниятенә ия Болгар патшалыгын да үз биләмәсе иткән күчмән хазарлар белән бәйләнеш тота: кабиләләр берләшмәсен төзеп, унынчы йөздә һәм унберенче гасырның беренче яртысында Кара диңгез буе далаларында гомер сөргән күчмә бәҗәнәкләр һәм терлекче кыпчаклар белән күрше булалар. Димәк ки, төрле дәверләрдә аларның матди һәм рухи хәле, хәрби көче белән танышалар. Чөнки социаль-сәяси яктан алар белән күршелек мөнәсәбәтләренә керми яшәү һич тә мөмкин булмый.

Шулай икән, чик буендагы далаларда монголларның пәйда булуы Кара һәм Каспий диңгезләре буенда күчмәннәр явының дәвам итүе хакында гына сөйли. Шул ук вакытта күчмәннәрнең бу дулкыны бүтән халыклар белән яңача багланышлар урнаштырырга омтылуын да тоярга мөмкин була. Элекке күчмәннәр ара-тирә генә яу чапса, XIII йөз башында Кара һәм Каспий диңгезләре буе далаларына Чыңгыз оныгы Бату хан тарафыннан алып килгән монголлар монда тамыр җибәрү өчен юлга чыга. Бату хан «монголлары» чынлыкта этник яктан чуар Урал-Алтай кабиләләре берләшмәсе рәвешендә барлыкка килә, монголлар аларның хәрби үзәген, юлбашчыларын гына тәшкил итә. Алар һөҗүм итәргә һәм шушы җирләрне басып алып, аны ил-йорты, үз улусы итеп яшәргә омтыла. Башта алар Идел-Кама буендагы шәһәрләшкән мөселман Болгар ханлыгын басып ала, аннары 1236—1240 елларда шуннан көнбатыштагы җирләрне, җөмләдән, Киев кенәзлеген дә үз биләмәсе итүгә ирешә.

Бату походлары нәтиҗәсендә Идел-Урал буенда Бөек Монгол империясенең Җуҗи патшалары нәселе һәм Алтын Урда дәүләте барлыкка килә. Монголлар Кытайда — Юань, Иранда — Илхан, Урта Азиядә Чыгтай патшалары нәселләренә тормыш бирә. Алтын Урда биләмәләре Урта Иделне, Көнбатыш Себерне, Урта Азиянең Хәрәзем тирәсен, Төньяк Кавказны, Каспий һәм Кара диңгез буе далаларын һәм Кырымны эченә ала.

---

Азадә-Гайшә РҮРЛИХ (1942) — *АКШ галиме, төрле телләрдә басылган күп кенә тарихи хезмәтләр авторы. Лос-Анжелес шәһәрендә яши.*

Мәкаләне Д. Исхаков гыйльми редакцияләде, инглизчәдән урысчага А. Арысланова, урысчадан Т. Әйди тәрҗемә итте.

Алтын Урда, Темучинның Бөек Монгол империясенә хас булганча, күчмә кабиләләрне һәм утрак халыкларны сыгылмалы бердәмлеккә җыйный һәм куша алуы аркасында зур хәрби уңышларга ирешә, ике гасыр ярым буе тотрыклы сәяси тормышта яши. Шәһәр белән дала багланышлары зәгыйфьләнгәч, күчмәннәр белән утрак тормыштагылар арасында каршылыклар арткач, шәһәр халкы һаман ярлылана баргач, сәяси татулык та йомшый, үзәктән качу көчләре яңаданяңа фетнәләр күтәрү аркасында, тормышның яме китә. XIV йөзгә таба эчке ызгышларның көчәюе Алтын Урданың хәле мөшкелләнүен сиздергән беренче искәртү була. Үзбәк хан (1313—1341) идарәсе заманында сәяси һәм мәдәни яктан Алтын Урда иң югары үсешкә ирешә. Этник яктан үзара якынаю, исламны дәүләт дине итеп кабуллау нәтиҗәсендә төрле кавем-кабиләләрнең бердәйләшү хәрәкәте җанлану дәүләтне чагыштырмача югарырак баскычка күтәрә. XIV йөздә Алтын Урда социаль-икътисадый, мәдәни-сәяси яктан нык оешкан, идарәче монгол аксөякләре катламы җирле халыкка сеңеп беткән, төрки телле мөселман дәүләтенә әверелә.

XIV йөз ахырында яңадан куәтләнгән эчке көрәш XV йөз уртасында Алтын Урданың таркалуына китерә һәм аның хәрабәләре астыннан яңа дәүләтләр: Урта Иделдә 1445 елда Бату хан туганы Туга Тимер нәселеннән Олуг Мөхәммәт нигез салган Казан ханлыгы; 1430 елда шул ук Туга Тимер нәселеннән Хаҗи Гәрәй нигезләгән Кырым ханлыгы; 1452 елда Олуг Мөхәммәт улы, Мәскәү кенәзе вассалы Касыйм нигезләгән Касыйм ханлыгы; 1466 елда Алтын Урда ханы Кече Мөхәммәт оныгы Касыйм нигезләгән Әстерхан ханлыгы; 1428 елда Бату хан туганы Шәйбан оныкларыннан Әбелхәер нигезләгән Себер ханлыгы һәм күчмән Нугай Урдасы, Бөек Урда калкып чыга.

Алтын Урданың таркалуы сәяси һәм социаль-икътисадый яктан шактый чуар өлешләрне бергә кушып, беректереп торган уртак социаль төзелешне юкка чыгара, Батый хан һәм аның варислары ишкән җепләрне өзә. Алтын Урданы тәшкил иткән төрле биләмәләр бәйсез үсеш юлына баса, әмма аларның һәркайсы шик тә юк ки, монголлар дәвере идарәсенең мирасчылары була.

Идел буе болгарларына килсәк, аларның Алтын Урда составына керүе, соңгысының исә XIV йөз башыннан төрки-мөселман дәүләтенә әверелүе аркасында, алар ислам мәдәнияте нигезендә үсүен дәвам итә. Алтын Урда XIV йөздә төрле шивәләрдә сөйләшә торган кавем-кабиләләрне бергә куша һәм эретә торган учакка әйләнә — чуар масса шуның кайнар казанында кайнап, бердәм Алтын Урда халкын барлыкка китерә. Идел буе болгарлары бу кушылу хәрәкәтеннән читтә калмый. Шул синтез нәтиҗәсендә Идел буе төркиләре Казан ханлыгы халкы булып пешеп җитә.

Бәйсез сәяси берләшмә сыйфатында озак яшәмәсә дә (1445—1552), Казан ханлыгы социаль-икътисадый һәм мәдәни яктан тормыш итәргә сәләтле булуын һәм үсә-үзгәрә алуын исбатлый. 1552 елда ябырылачак урыс гаскәрләре һөҗүме каршысында аның мираска алган дәүләтчелек төзелеше үзен акламавын, мөстәкыйль яшәр өчен тиешле шартлар тудыра алмавын күрәбез. Чөнки ул эчке утрак хуҗалыкның, җәмгыятьнең киңәя барган ихтыяҗларын канәгатьләндерергә өлгерә алмый, шул ук вакытта ул көнбатыш чигендәге дәүләтнең кызу тизлектә үзәкләшә, агрессивлаша һәм бер хаким ихтыярына буйсынып хәвефле көчкә әйләнә баруын сүлпән генә күзәтеп торудан бүтән чаралар тапмый.

Казан ханлыгы Идел буе татарларының халык буларак оешуының соңгы баскычы — шунда аларның теле төрки телләрнең аерым бер тармагы рәвешендә формалашып бетә. Милли-мәдәни үсешнең шушы барышы, үзара охшашлык һәм бердәйлек мәсьәләсендә мәйданга чыккан каршылыклар кебек үк, Идел буе татарларының Алтын Урда мирасына дәгъвасын, ул мирасны әлеге дәүләт киңлекләрендә яшәгән бүтән кавем-кабиләләр белән уртаклашу мәсьәләсен галимнәр алдына да китереп куйды.

Әле XIX йөзнең икенче яртысында да Идел буе татарлары үзләрен «мөселман» дип атауны өстен күрә һәм шуңа омтыла иде. Хәер, алар этноним буларак «казанлы», «болгар», «мишәр», шулай ук «татар» исемнәрен дә кулландылар, урыслар һәм башка тирә-күрше халыклар да аларны шулай төрлечә атап килде. «Татар» атамасына өстенлек бирү исә Идел буе төркиләрен XIII йөз монгол-татарлары, ягъни Бату хан гаскәрен житәкләгән хәрби аксөякләр белән охшаштыру җирлегендә тамыр җәйде.

«Татар» исемен аклауда XIX йөз мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри һәм Шиһабетдин Мәрҗани төп рольне уйнады. Мәрҗани казанлыларны «татар» дип аталудан оялмаска өндәде. «Рус халкының аларны кимсетү, хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән кайберләре таʼтар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән

чирканып, без татар түгел, без «мөселман» дип, тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар... Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың?— дип мөрәҗәгать итә ул милләттәшләренә.— Әгәр синең «мөселман»нан башка бер исемеңне дин һәм милләтең дошманы белмәсә иде, сине, әлбәттә, «мөселман» дип дошман күрерләр иде»,— ди Мәрҗани. Ул әнә шулай халыкның тарихи язмышына бәйле исемнән кайберәүләрнең баш тартырга маташуына кискен каршы чыга, туган кавеме тарихының тиешенчә өйрәнелмәвенә үкенеч белдерә һәм замандашларын ата-бабаларына ихтирам күрсәтергә чакыра.

Милли исемне ачыклауга юнәлтелгән бәхәсләр, иртәме-соңмы, «татар» атамасының килеп чыгышын да колачларга тиеш иде. Әмма бу өлкәдә XIX йөздән алып бүгенгә кадәр галимнәр бер сүзгә килә алганы юк әле. Халыкның килеп чыгышын ачыклаудан җинелрәк тоелса да, этнонимның пәйда булуы хакында әле һаман ике фараз яши бирә.

«Татар» атамасын монголларга бәйләп караучылар бу сүз кытайча «Та-тан» яки «Да-дан»га барып тоташа, ягъни кытайлар монголларга әнә шулай кимсетеп эндәшкән, бу исем Чыңгыз хан буйсындырган бер монгол кабиләсенә ябышып калган, дип исәплиләр. В. Томсен, В. Бартольд һәм башкалар орхон язмаларында теркәлгән «татар» исеме әнә шул кабиләгә карый дип расլый.

Монгол-татарлар VI—VII йөзләрдәге ярым күчмән Төрки каганлыгының варисы булган төрки кабиләләр арасында яши. Чыңгыз хан тарафыннан 1202—1208 елларда яулап алынгач, монгол-татарлар, Көньяк Себер тигезлеге һәм Үзәк Азия төрки кабиләләре кебек, Чыңгыз оныгы Бату хан чирүенә алыналар.

Монголлар һәм монгол-татарлар Бату хан гаскәрендә азчылык тәшкил иткәнлектән, Алтын Урда халкы арасында алар тагын да кечерәк азчылык хәлендә кала һәм Урал тавының көнбатыш тарафында күпсанлы төркиләр тарафыннан төркиләштерелә. Алар тел һәм кыяфәт ягыннан, мәдәни җәһәттән әйләнә-тирәдәге күпчелеккә тәмам охшаш китә. Әл-Гомәри XIV йөздә тасвирлаганча: «Борынгы заманда бу дәүләт кыпчаклар иле булган, ләкин татарлар яу булып килгәч, кыпчаклар аларга буйсынган. Соңрак алар (татарлар) тегеләр (кыпчаклар) белән аралаша һәм туганлаша, җир аларның (татарның) табигый раса сыйфатларыннан өстен чыга һәм алар барысы да нәкъ кыпчак кебек кыяфәткә керә, әйтерсең, алар бер ырудан. Монголлар (һәм татарлар) кыпчак җирендә урнашканлыктан, алар белән никахка кергәнлектән, алар (кыпчаклар) җирендә яшәп калалар».

Монгол татарлары кабиләләре карышуын юк итмичә, Чыңгыз хан кул астында бөтен монгол кабиләләрен берләштерү мөмкин булмас иде. Бу җиңүнең хәлиткеч нәтиҗәсе рәвешендә 1206 елда Чыңгыз хан барлык яулап алынган халыкларны «татар» дип атарга әмер бирә. Әмма күпмедер вакыттан соң монголлар шул яулап алынган халыклар тарафыннан йотылу гына түгел, 1246 елда итальян сәяхәтчесе Плано Карпини билгеләп узганча, «монголлар үзләре дә, бигрәк тә ватаннарыннан аерылгач, үзләрен татар дип атый башлый. Әнә шулай татар исеме монгол исеменең адашы булып китә».

Идел буе татарларының ата-бабалары әле XVI йөздә дә бу исемне тагуга карышса, Алтын Урда халыкларының күпчелеге яңа этнонимны ыгы-зыгысыз гына кабул иткән, күрәсең.

«Татар» атамасын «төрки тамырдан» диючеләр карашы азрак танылган. Бу карашны Мәхмүт Кашгарлының «Диване лөгатет-төрек» сүзлегенә таянган галимнәр мәйданга чыгара. Бу әсәрендә (1072—1074) М. Кашгарлы, Иртеш елгасының көнбатышында төрки телләрнең татар тармагы яши, дип билгеләп уза. Әхмәт Тимер, мәсәлән, шушы хәбәр монгол яуларына кадәр күп элек татар дип аталган төрки халык яшәгәнлеген исбатлый, дип аңлата, Алтын Урда халыкларына шуның исеме бирелгән дип исәпли. Сүзлектәге хәбәргә таянып һәм үз фаразын тагын да үстереп, Ә. Тимер бу исемнең бер-берсенә бәйсез рәвештә төрле-төрле ике халыкка: монгол кабиләсенә һәм Урал тавының көнбатышында урнашкан төрки кабиләгә бирелү ихтималлыгын да белдерә.

Әмма Мәхмүт Кашгарлы искә алган татар теле VI—VII йөзләр Төрки хаканлыгы мирасчылары чолганышында яшәгән һәм шунлыктан аларның телен дә үзләштергән монгол-татар кабиләсе төркичәсе булуы хакыйкатькә якынрак сыман.

Идел буе татарларының килеп чыгышы элекке СССР һәм аннан тыштагы галимнәр арасында әле һаман бәхәсле булып кала. Шуның белән бергә, бик сәер бер хәл дә килеп туды: бу хакта фикер алышуның әле тәмамланмавына һәм

катлаулы булып торуына карамастан, кайберәүләр саклык, икеләнү күрсәтәсе урында, үз туксанын гына туксан дип күрсәтергә ашкына.

Идел буе татарларының килеп чыгышы хакында галимнәр арасында төрле фикерләр хөкем сөрсә дә, аларның XVI йөздә Болгар ханлыгының төньяк биләмәләрендә яшәве, бу җирләрнең гамәлдә Казан ханлыгы мәйданы белән туры килүе, шул заманның Көнбатыш Европа карталарында бу төбәкнең Болгарстан дип аталуы берәүдә дә шик уятмый.

Идел буе татарларының килеп чыгышын аңлатуда ике юнәлеш — кыпчак һәм болгар теорияләре яши. Башка фаразлар булган тәкъдирдә, алар шушы ике теориянең варианты яки аларның катнашмасы булып кала. Кыпчак теориясе тарафдарлары Идел буе татарларын Алтын Урда татарларының турыдан-туры дәвамы дип исбатлый. Мондый караш урыс тарихчылары С. Соловьев, Г. Перетяткович, А. Ашмарин, татар милләтчеләре һәм мөһаҗир тарихчылары М. Рәмзи, З. Вәлиди-Туган, Г. Баттал-Таймаслар тарафыннан мәйданга чыгарылды.

Болгар теориясе тарафдарлары Идел буе татарларының ата-бабалары Урта Иделгә һәм Кама тамагына Азак диңгезе буе далаларыннан күчеп килгән болгарлар дип саный. Алар Идел буе татарларының формалашуында Болгар ханлыгы мәдәнияте, аның сәяси җирлеге ята, Болгар җәмгыяте исә 1236—1237 елларда монгол-татарлар ябырылганчы ук калыплашкан, диләр. Бу карашны яклаучылар башка компонентларны инкарь итүдә, үз төшенчәләрен бердәнбер хакыйкать итеп танытуда чамадан тыш кискенлек күрсәтәләр. Әмма мондый кискенлек, гаҗәп ки, күпләрне болгар теориясеннән биздерми. Революциягә кадәр мондый карашны Н. Карамзин, И. Березин, В. Григорьев, Н. Чернов һәм М. Аитовлар якласа, совет дәверендә аңа А. Халиков, Х. Гыймади, Ә. Булатов, Н. Калинин һәм Ф. Вәлиевләр тугрылыклы булып кала.

Шушы теорияләрнең һәркайсы күп кенә фикер алышуларга җирлек бирде, алар барышында яңа концепцияләр туды. Кыпчак теориясенә җавап итеп, Г. Әхмәрев болгар-татар мирасы теориясен тәкъдим итте. Бу теория буенча, монгол явы алып килгән милли-мәдәни кыйммәтләр болгар нигезенә килеп өстәлә, нәтиҗәдә ике башлангыч кушылып, аралашып үсеп китә. Ш. Мәрҗани, болгар теориясен кабул иткән хәлдә, Идел буе татарлары мәдәниятенә кыпчак өлеше дә зур роль уйнавын билгеләп уза.

Егерменче елларда совет галимнәреннән беренче булып Н. Фирсов һәм М. Худяков татарларның килеп чыгышында кыпчаклар уйнаган рольне таный, әмма алар татар этносының болгар асылын кыпчак йогынтысын киң күләмдә үзгәртә алмавын искәртә.

1928 елда Газиз Гобәйдуллин кыпчак теориясен бүтәнчәрәк аңлата. Аныңча, болгарларның һәм төркиләшкән җирле фин-угыр кабиләләренең кушылуы, аларның Алтын Урда татарлары тарафыннан йотылуы нәтиҗәсендә, XV—XVI йөзләрдә Идел буе татарларының формалашуы тәмамлана. Шулай итеп, алар яңа тел һәм яңа исем кабул итә. Гобәйдуллин тикшергән Алтын Урда татарлары Түбән Идел буенда яшәгән, XIII йөздә монгол-татарларны йота алган кыпчаклар булуы күз алдында.

«Кыпчак теориясе»нең бераз үзгәртелгән вариантын яклауда Гобәйдуллин ялгыз түгел иде. Аның карашларын В. Смолин, Г. Рәхим, Ш. Мөхәммәдьяров һәм бүтәннәр дә уртаклаша. Бу теория әлегә тулысынча танылып бетмәсә дә, Алтын Урда мирасын кабул итүгә үз өлешен кертә.

1944 елда КПСС Үзәк комитеты татар тарихчыларының Алтын Урданы идеаллаштыруын хөкем итә һәм татар тарихын «гыйльми өйрәнү» соң дәрәҗәдә әһәмиятле һәм актуаль булуын басым ясап искәртә. Җәмәгатьчелекнең сәяси күрсәтмәгә җавабы рәвешендә, 1946 елда Фәннәр академиясенең махсус конференциясе җыйнала. Анда катнашкан галимнәр арасында археологлардан А. Смирнов, Н. Калинин һәм С. Толстов; телчеләрдән Л. Җәләй, Н. Димитриев, этнограф Н. Воробьев; антрополог Т. Трофимова, тарихчылардан М. Тихомиров, Р. Рәимов, Ә. Булатов һәм Х. Гыймадиларның чыгыш ясавы бу конференциягә нинди зур әһәмият бирелүе турында сөйли. Әмма монда яңа ачышлар ясалмый, галимнәр электән мәгълүм теорияләрне яклап, төрле төркемнәргә генә аерылалар. Х. Гыймади белән Н. Калинин, Идел буе татарларының бердәнбер ата-бабалары Идел-Кама буе болгарлары булуын белдереп, үзләрен болгар теориясе тарафдары итеп күрсәтәләр. Үзләре тикшеренгән өлкәдәге материалларга нигезләнеп, А. Смирнов, Н. Воробьев, Т. Трофимова һәм Латыйф Җәләй болгар-кыпчак теориясен яклый.

Мәскәү конференциясе узганнан соң кырык елдан артык вакыт үтте, әмма татарларның килеп чыгышын ачыклап бетерергә әле һаман бик ерак. Ул хәзер тагын да актуальрәк мәсьәләгә әйләнеп бара бугай, гыйльми бәхәсләргә яңадан-яңа тикшеренүчеләр кушыла.

Бүген «болгар мәктәбе» карашларын кайнар яклаучылар сафында Альфред Халиков, Фуат Вәлиев, Яхъя Абдуллиннар бирелеп хезмәт итә. Шулай да Казан татарлары килеп чыгышында болгарлар һәм кыпчаклар тоткан өлешне бербересенә каршы куймыйча тикшерүне яклаучылар саны житмешенче еллар уртасыннан соң арта баруын әйтми булмый. Миркасыйм Госманов Фуат Вәлиевнең болгар сәнгатен өйрәнүдәге берьяклылыгын тәнкыйтьли. Сәнгать галименең «болгарларның нәфис сәнгатенә дә, тулаем мәдәниятенә дә кыпчакларның дала сәнгате хәлиткеч дәрәҗәдә тәэсир итә алмый иде»,— дип аңлатуын М. Госманов үзенчә анализлый. Вәлиевнең Казан татарлары килеп чыгышын ачыклау максатын куюын, ләкин этногенез барышының катлаулы булуын искә алмавын билгеләп үтә. Госманов чыгарган нәтиҗә буенча, Идел буе татарлары болгарларны да, кыпчакларны да бары тик үз ата-бабасы итеп саный алмый, чөнки алар Идел-Урал буенда яшәгән бүтән халыклар барлыка килүгә дә өлеш кертә.

Госмановның басынкы тавышын Мирфатыйх Зәкиев һәм Вахит Хаковлар көчәйтте. Алар раслаганча, монгол басып алуыннан соң болгарлар һәм аларның теле юкка чыкмый, киресенчә, Алтын Урда корылгач, алар мәгълүм автономиягә ия була. Әмма яңа куәтле дәүләтнең барлыкка килүе, ханлык биләмәләре чигендә сәяси, социаль-икътисадый шартларның үзгәрүе барышында кыпчак теле рәсми дәүләт теленә әверелә һәм шул сыйфатта ул болгар теле үсеш-үзгәрешенә дә житди йогынты ясый. Тел мәсьәләсендә Зәкиев белән Хаков «кыпчак-болгар» теориясе тарафдарлары булса да, алар Идел буе татарларының антропологик яктан турыдан-туры болгар дәвамы булып калуына басым ясыйлар.

Татарларның килеп чыгышы хакындагы хезмәтнең соңгы бүлеге якын арада языласына өмет бик аз. Хәбәрдарлык һәм үзгәртеп кору рухы татарларның килеп чыгышы хакындагы бәхәсләрне гыйльми даирәләрдә генә калдырмыйча, аларны киң җәмәгатьчелек мәйданына да җәеп җибәрде. Мисалга, «Вечерняя Казань» газетендә Р. Фәхретдинов, Ә. Кәримуллин, И. Гыйләҗев, К. Фәсахов, Д. Вәлиев кебек танылган эшлеклеләр чыгыш ясады[1]. Татарларның килеп чыгышы хакында бәхәскә кергән милли галимнәрнең ахыр чиктә ике максаты бар: торгынлык елларында ак тап булып калган татар тарихы сәхифәләрен язып тутыру; татар исемен «болгар»га алыштыру омтылышына җавап бирү.

К. Фәсахов, мәсәлән, кайберәүләрне тарихи наданлыкта, шулай ук урыс тарихы материалларын бөгештереп файдалануда, шулай итеп җәмәгатьчелекне «болгар» исемен кабул итәргә өндәп саташтыруда гаепли. Фәсахов фикеренчә, «татар» исеменең яманатын кайбер тарихчылар тарата. Алар бүгенге Идел буе татарларын монгол-татарлар белән бердәйләштерә, монгол хәрби аксөякләренә тиңләштерә һәм әнә шулай монгол яулары аркасында авыр хәлгә төшкән Русиянең бәлаларен бүген татар дип аталган, чынлыкта Бату хан монголлары тарафыннан шулай ук басып алынган болгарларның дәвамы булган халыкка китереп бәйли. Татар яшьләре, милли тарихларын яхшырак белсә, үзләрен татар дип атаудан чирканмас, милли исемнәрен алыштыруга омтылмас иде, ди Фәсахов. Ул мәгариф челтәренең томаналыгын гаепләп, уку программаларында милли азчылыкларның тарихы чагылдырылмавын яисә аларның кимсетелеп, бозып сурәтләнүен аңлата.

Фәсахов карашынча, дәреслекләрдәге бушлык яки теге яки бу тарихи дәверне искечә яктыру халык тарихын бозуга гына китерергә мөмкин. Бүгенге татарларны тарихи монгол-татарлар белән тиң, бердәй күрсәтеп гәүдәләндергән жиденче класс дәреслеге шуңа бик ачык мисал. Халыкның рухи хәзинәсен, әйтик, авыз иҗатын өзек-төтек бастыру, тиешле аңлатмаларны төшереп калдыру — зарарлы эш, аңлы рәвештә хакыйкатьне яшерү. Шушы фикерен раслар өчен, галим алтмышынчы елларда бер миллион нөсхәдә басылган бер открытканы телгә ала. Открыткада урыс былинасы каһарманы — монголларны жиңгән бер баһадирның тантанасы сурәтләнә. Рәсем өстенә:

Кырда мин өч эт-татарны,
Өч жайлакны үтердем,—

[1] Аңлашыла ки, татар телендәге вакытлы матбугатта милли тарихыбыз мәсьәләләре тагын да киңрәк, әтрафлырак яктыртыла, ләкин автор алар белән танышудан мәхрүм, күрәсең. (Редакция искәрмәсе).

дигән сүзләр басып чыгарыла.

Бу юлларның кайсы әсәрдән алынуы открытка артында күрсәтелә, әмма ул шундый вак хәрефләр белән басыла ки, аны абайламаска мөмкин. Әнә шулай урыс тарихында һәм аңында татар халкы дошман образында мәңгеләштерелә. Алай гына да түгел, ди Фәсахов, урыс тарихының борынгы һәм Дүртенче Иван патша дәверен чагылдырган, 1983 елга кадәр басылып чыккан тикшеренүләр укучыларны саташтыра, алар Казан ханлыгы Алтын Урда сәясәтен дәвам иттерә торган дәүләтчелек итеп таныта. Казан Алтын Урданың мәдәнияте мирасчысы түгел, сәяси дәвамчысы дип танытыла һәм Русиянең XIII—XIV йөзләрдәге уңышсызлыклары өчен җаваплы итеп сурәтләнә. И. Гыйләҗев Идел буе татарларының үз килеп чыгышында болгарлар тоткан урын белән кызыксынуы сәбәпләрен санап чыга да: «Әгәр бүген кайбер татарлар туган телләрендә шәбһәләрен белдереп, без татар түгел, дип раслый икән, бу әле аңыбызда болгар теориясе өстенлек алуын исбатламый, бары тик беркатлы һәм берьяклы фикер йөртү, халкыбызны узган тарихи юлы белән тиешенчә таныштыра алмавыбызны гына күрсәтә», ди.

Ә. Кәримуллин хәзерге Идел буе татарларын турыдан-туры XIII йөз монгол-татарларына тоташтыруга каршы чыгып кына калмый, хәтта Казан ханлыгының Алтын Урда мирасчысы булуын яклаган бәхәсләрне дә кире кага. Ә. Кәримуллин һәм бүтән татар галимнәренең мөнәсәбәтен иске алып, шундый бер нәтиҗәгә килергә мөмкин: Алтын Урданың Идел буе татарларына йогынтысын киметеп күрсәтергә маташу, хәтта XIII—XIV йөзләрдәге мәдәни синтезны да кире кагырга омтылу урысларның Руська Алтын Урда тәэсирен бозып аңлату шикелләрәк бер адым ул.

XVI йөздә урыс дәүләте ватандашына әйләнгән татарлар 1552 елда Казанның егылуын үз тормышларының һәр ягына тәэсир итүен тирән аңлап кына калмый, бәйсез ханлыкларыннан килгән мирас таләпләрне истә тотып яшәргә дә өйрәнә. Идел буе татарларының ата-бабалары монголлар тарафыннан басып алынса да, ике гасырдан артык тәэсир итешүдә беренчеләр җиңә, чөнки алар биологик һәм мәдәни яктан өстенрәк була. Алтын Урданың тора-бара төрки-мөселман дәүләтенә әверелүе илбасарларны мәҗүси монгол тамырларыннан тәмам аера. Хәрби көч, сәяси өстенлек буйсындыручылар белән буйсынучыларны икегә аерып торган бер дивар булса, мәдәният уртаклашу, кан-кардәшлекне җәелдерү, дин уртаклыгын киңәйтү күпер кебек ике якны тоташтыра, шушы үзара керешү, катнашу мәгълүм сыйфат үзгәрешләренә китерә.

XIII йөздә монголлар урыс кенәзлекләрен буйсындыргач, яулап алучылар белән җирле халык мөнәсәбәте сәяси, социаль һәм икътисадый каршы тору рәвешен ала. Үзбәк хан Алтын Урданы милли-дини яктан арадаш чиккә, әмма мөселман дөньясы әйләнәсенә керткәч, моңа кадәр яшәгән каршылыклар урта гасырчыл христиан-мөселман дошманлыгы ташкынына әверелә. Ханның Русьтагы ортодоксаль чиркәүгә зур ирек, өстенлекләр бирүе тату-дус яшәүне тәэмин итми.

Урыслар һәм татарларның монгол әфәнделәре белән катлаулы мөнәсәбәтләрдә яшәве аларның моннан соңгы язмышына, үз-үзләрен аңлавына һәм үзара берсен-берсе ничек кабул итүенә дә житди йогынты ясый. Басып алынган халык булса да, Идел буе татарлары, гадәттә, үзләрен Алтын Урданың сәяси һәм хәрби чараларыннан аерып карамый. Моңа аларны Урда белән мәдәни уртаклык этәрә. Ә менә урыслар, Алтын Урданың кечәге вассаллары, яу булып килгәч һәм басып алгач, Идел буе татарларының яңа илбасарга мөнәсәбәте бөтенләй башка була.

Моны татар халык дастаны «Идегәй» бик әйбәт гәүдәләндерә. Ул беренче мәртәбә XIX йөз уртасында В. Радлов, 1919 елда аның икенче варианты Нигъмәт Хәким тарафыннан язып алына. 1940 елда «Совет әдәбияты» (№ 11—12) журналында бастырып чыгарганда, Нәкый Исәнбәт «Идегәй»нең нигездә Радлов һәм Хәким вариантларына таяна, әмма 1940 елда үзе җыйган материалларны да файдалана. Башкортлар дастанның үз вариантын 1941 елда нәшер итә. Ләкин 1944 елда ВКП(б) ҮК карары белән «Идегәй» тыела һәм ул яңадан җәмәгатьчелеккә 1989 елда гына әйләнеп кайта — «Казан утлары» һәм «Агыйдел» журналларында икенче тапкыр дөнья күрә.

«Идегәй»не аклауның озакка сузылуы һич тә очраклы хәл түгел иде. Чөнки дастанның борынгырак дәвер урыс тарихын яктыртуга катнашы бар, ул милли азчылыклар һәм совет дәүләте җитәкчеләре сәясәтен бәрелештерү ягыннан хәвефле иде.

Татар-башкорт халык дастанына рәсми даирәләр каһәре төшүен Идегәйнең тарихи шәхес, Алтын Урда ханы Туктамышның әмире, хәрби юлбашчысы булуы

белән генә аңлатырга мөмкин. Ул 1398—1419 елларда мәмләкәтнең дилбегәсен чынлыкта үз кулында тота. Туктамыш белән Аксак Тимер бәрелешләреннән файдаланып, Алтын Урда тәхетенә үз «курчак ханнарын» утырта.

Идегәй таркала барган Алтын Урданы яңадан бергә тупларга алынган соңгы кодрәтле көч була. Табигый ки, ул Урда хакимлеген урыс кенәзлекләренә кабат җәяргә тырыша. 1408 елда Мәскәүгә яу чаба һәм юл унаенда байтак җирләрне туздыра. Урыс тарихы күзлегеннән караганда, шуңа күрә ул — сугышчан әмир, Алтын Урда чиргәе юлбашчысы, башка тиңнәр арасыннан аерылып чыгып беренче булырга омтылган Мәскәүнең бөек кенәзенә хәвев тудыручы. Шушы җирлектәдер, күрәсең, компартия җитәкчелеге башкортларның һәм татарларның үз дастанын күтәрүен әдәпсезлек, хәтта хыянәт дип тамгалый, чөнки дастан рухы урыс җирләренең Алтын Урта карамагына керүен хуплый, дип фараз итә.

Нәкъ менә шул сәбәптән, әсәрне басмага әзерләгән татар-башкорт галимнәре Ф. Әхмәтова һәм Н. Зарипов дастан каһарманы Идегәйне тарихи шәхестән аерып карарга тырыша; дастан сугышчан хәрби юлбашчыны идеаллаштырмый, әсәр тарихи хакыйкать көзгесе түгел, ул бары тик қупләр күңелендә дөрләгән ирек идеалын гәүдәләндерә һәм халык аңында мәхәббәт казанган каһарманны данлый, дип таныта.

Дастан шундый аңлатмалар белән басылса да, кайбер искәрмәләрдә, бигрәк тә Зарипов төзегәннәрендә, «Идегәй» әсәре белән тарихи фактлар бәйләнешендә четрекле «аңлашылмаучылыклар» очрый. Бигрәк тә урыс тарихчысы бәяләвеннән чыгып караганда. Димәк, «Идегәй»нең халык күңелендә кадерләп саклануында дастанда тасвирланган заман — Алтын Урда урыс кенәзлекләренә хуҗа булган дәвер дә зур роль уйный. Шул ук вакытта без «Идегәй»нең мәдәни мираста абруйлы урын алуы урыс патшасының әле татарларга һәм башкортларга ия булмаган, Алтын Урда таркалып бетмәгән шартларда әле татарның үз-үзенә хуҗа булу өмете сүнмәгән заманны җанландыруына һәм искә төшерүенә дә бәйләнгән дип раслый алабыз. «Идегәй» дастаны һәм татар-башкортларның шушы дастанга мәхәббәте хәзерге милләтләрне формалаштыруда борынгы тамырларның һәм нык идеалларның нинди зур роль уйнавына ышанычлы мисал булып тора.

### ТАТАРСТАН ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ XXII СЕССИЯСЕНДӘ

10—13 октябрь көннәрендә Казанда уникенче чакырылыш Татарстан Югары Советының XXII сессиясе эшләде. Анда Татарстан Республикасы Дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын үзгәртеп коруга бәйле рәвештә ТР Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында Закон проектлары, Татарстан Республикасының икътисади һәм җәмгыяви прогрессы хакында Дәүләт программасы, җөмһүриятебезнең 1994 елга төгәлләштерелгән республика бюджеты проекты һ. б. мөһим мәсьәләләр каралды.

Сессия барышында тикшерелгән мәсьәләләр һәм тормышыбызның иҗтимагый-сәяси, икътисади проблемалары буенча Татарстан Президенты М. Шәймиев чыгыш ясады.

Сессия эшендә 23 ноябрьгә кадәр тәнәфес игълан ителде.

### ХӘТЕР КӨНЕ

Казан ханлыгының Иван Грозный тарафыннан яулап алынуына 442 ел тулу көне быел Татарстан күләмендә милли матәм көне буларак билгеләп үтелде. 15 октябрьдә — Хәтер көнендә — изге көрәштә шәһит киткән каһарман милләттәшләребезне, Идел-Урал халыклары вәкилләрен искә алырга, алар рухына дога кылырга җөмһүриятебез башкаласына Әзәрбайҗан, Украина, Чечня, Башкортстан, Чувашстан республикаларыннан, Түбән Новгород, Ульяновск, Төмән, Омск, Пермь, Самара, Миас шәһәрләреннән дә бик күпләр килгән иде. Хәтер көне Ирек мәйданында башланып китте. Ш. Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыяте президенты З. Зәйнуллин, җөмһүриятебезнең Аксакаллар Шурасы рәисе Р. Хәмидулла, БТИҮ рәистәше Р. Сафин, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы Р. Ягъфәров, «Суверенитет» комитеты рәисе Ә. Мәхмүдов, Идел-Урал халыклары Ассамблеясе һәм Чуваш Милли Мәҗлесе рәисе А. Хузангай, Татарстан халык депутаты М. Мөлеков, Башкортстан «Азатлык» татар яшьләре берлеге рәистәше М. Кәримев, галим Н. Хисамов, җырчылардан М. Галиев, А. Әхмәтшина һ. б.ның чыгышлары мәйдандагы халыкны хәтер-иман сагында уяу торырга, бердәм булырга, дус-тату яшәргә өндәде.

Ирек мәйданында матәм митингысы тәмамланганнан соң, халык Сөембикә манарасы янына барып, шәһитләр рухына багышлап дога кылды, Татарстан диния назарәте мөфтие Габдулла хәзрәт вәгазен тыңлады. Матәм көне Чаллыдан килгән укучы балаларның мөнәҗәт әйтүләре белән тәмамланды.

### ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ — ФРАНЦИЯДӘ

27—29 сентябрь көннәрендә Президент М. Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы делегациясе Франциядә эш визиты белән булды. Очрашулар барышында Казан аэропортын, Казансу аша салынган күперне, «Казан» кунакханәсен реконструкцияләү, Татарстанның шикәр заводларын үзгәртеп кору, республикабызга шикәр чөгендерен үстерү технологиясен бирү һ. б. мәсьәләләр буенча эшлекле сөйләшүләр булды.

Татарстан делегациясе француз җитәкчеләре һәм эшмәкәрләренең Милли Советында түгәрәк өстәл уздырды. Җөмһүриятебез Президенты Франция Республикасы Сенаты Президенты Р. Монори, Премьер-Министр Кабинеты директоры Н. Базир һәм хөкүмәтнең күп кенә министрлары белән очрашты, соңыннан француз һәм чит ил хәбәрчеләре катнашында уздырылган матбугат конференциясендә чыгыш ясады.

29 сентябрьдә М. Шәймиев җитәкчелегендәге бер төркем делегация әгъзалары Америка Кушма Штатларына киттеләр.

### АМЕРИКА ҖИРЕНДӘ ОЧРАШУЛАР

АКШта 7 октябрьгәчә дәвам иткән визиты барышында Татарстан Президенты М. Шәймиев сәяси һәм эшлекле даирәләр вәкилләре белән кызыклы, файдалы очрашулар үткәрде. 3 октябрьдә ул Гарвард университетының Кеннеди исемендәге Хөкүмәт мәктәбендә «Россия Федерациясенең киләчәге. Татарстаннан караш» дигән темага лекция белән чыгыш ясады. Тыңлаучыларда ул зур кызыксыну уятты.

5 октябрьдә АКШ Конгрессында М. Шәймиев Ассигнованиеләр комитеты, Европада иминлек һәм хезмәттәшлек комитеты рәисе — сенатор Д. Деконсини, Экспорт-импорт банкы рәисе К. Броуди һәм банкның Европа өчен җаваплы вице-президенты Т. Моран әфәнделәр белән һәр ике як өчен дә файдалы сөйләшүләр алып барды.

6 октябрьдә Татарстан вәкилләре «Дженерал Моторс» фирмасы җитәкчеләре белән очраштылар һәм Алабугада автомобиль заводы төзелешендә катнашу һәм капитал салу шартларын тикшерделәр.

Визит барышында М. Шәймиев чит ил эшләре буенча Дәүләт департаментында да булды.

## УНИВЕРСИТЕТТА — ТАНТАНА

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә 50 ел, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты ачылуга 5 ел тулуга багышлап, әлеге уку йортында 13—14 октябрь көннәрендә тантаналар булып узды. Беренче көнне университетның икенче корпусында татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү, укыту, татар телен гамәлгә ашыру мәсьәләләренә багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Икенче көнне УНИКС мәдәният-спорт комплексында юбилейга багышланган тантаналы җыелыш үткәрелде. Аны кереш сүз белән университет ректоры, академик Ю. Коноплев ачты. Татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты деканы язучы, профессор Т. Галиуллин доклад белән чыкты.

Юбилярны Татарстан Президенты һәм хөкүмәте исеменнән Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин котлады. Юбилей уңаеннан бер төркем галимнәргә мактаулы исемнәр бирелде, грамоталар тапшырылды.

Тантаналы җыелышта котлау сүзләре белән Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов, Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, республика халык мәгарифе министры В. Гайфуллин, Югары Советның даими комиссияләре рәисләре Р. Вәлиев, М. Шәрифуллин, университетның тарих факультеты деканы, академик И. Таһиров, Казан дәүләт педагогия институты ректоры, академик Р. Юсупов, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире М. Әһлиуллин, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Р. Туфитуллова, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, академик М. Зәкиев һәм башкалар чыкты.

Соңыннан бәйрәм концерты булды.

## СӘЙФИ КУДАШНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ

6—7 октябрь көннәрендә Башкортстанда республиканың халык шагыйре, төрки халыкларның олуг әдибе Сәйфи Кудашның тууына 100 ел тулу бәйрәме зурлап билгеләп үтелде. Шагыйрьне искә алу иң элек ул җирләнгән Акманай авылы зиратында (Чишмә районы) башланып китте. Аннары С. Кудашның туган авылы Келәштәге мәдәният йортында, Уфада — Башкорт дәүләт филармониясе залында юбилей кичәләре булып үтте. Башкорт дәүләт университетында халык шагыйренә багышланган фәнни конференция уздырылды. С. Кудаш яшәгән йортка мемориаль такта куелды.

Юбилейга Казакъстаннан, Татарстаннан да кунаклар килгән иде. Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники белән танылган шагыйрь — «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рәдиф Гаташ, Казан кунаклары буларак, барлык очрашуларда да катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## ӘМИРХАН ЕНИКИНЕ ОЛЫЛАУ

10 октябрьдә Уфада тагын бер зур кичә булып узды. Башкортстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Бөтенрусия мәгариф фондының республика «Мәгариф» бүлеге, Башкортстан татар телле язучылар берлеге, Благовар, Дәүләкән, Бүздәк районнары хакимиятләре Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникигә 85 яшь тулуны тантаналы төстә билгеләп үттеләр. Иң элек, Башкортстанның төрле районнарыннан килгән татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашында, олуг әдип иҗатына багышланган фәнни конференция үткәрелде. Аннары Актерлар йортында юбилей кичәсе уздырылды. Анда, Башкортстан әдипләре, татар язучылары, сәнгать осталары белән бергә, Татарстаннан шагыйрь Рәдиф Гаташ та чыгыш ясады. Юбиляр адресына күп кенә җылы сүзләр әйтелде, аңа истәлекле бүләкләр тапшырылды.

## МОСТАЙ КӘРИМГӘ — 75 ЯШЬ

Бүгенге төрки дөньяның танылган әдибе — Башкортстанның халык шагыйре, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Мостай Кәрим октябрь аенда 75 яшь тулды. Шул уңайдан Башкортстан Республикасында зур тантаналар булып узды.

Юбилярны котларга Татарстаннан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Ренат Харис һәм М. Җәлил исемендәге опера-балет академия театры җырчысы Хәйдәр Бигичев килгән иде. Алар Мостай Кәримгә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевның котлау хатын тапшырдылар һәм Уфада, юбилярның туган авылы Келәштә, Чишмә районында узган барлык тантаналарда катнаштылар.

## ШАГЫЙРЬГӘ — ХАЛЫКАРА БҮЛӘК

11—15 октябрьдә Испаниянең Севилья шәһәрендә Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча халыкара советның (Ай-Би-Би-Уай) 24 нче конгрессы булып узды. Анда татар шагыйре Роберт Миңнуллин да чакырулы иде. Конгресста Андерсенның 1994 елгы Мактаулы исемлеге игълан ителде. Ул исемлектә Р. Миңнуллинның «Дөньядагы иң зур алма» китабы да бар. Шагыйрьгә шулай ук халыкара бүләк — Андерсен исемендәге Почетлы диплом тапшырылды.

## МӘСКӘҮ ТАТАРЛАРЫ БЕРЛӘШӘ

Мәскәүдә яшәүче татарлар, үзара берләшеп, Асадуллаевлар йортын, милли-мәдәни үзәк буларак, кире үзләренә кайтарып алу буенча оештыру комитеты төзеделәр. Аның рәисе итеп, бертавыштан, армия генералы, хәрби фәннәр докторы, академик М. Гәрәев, урынбасарлары итеп галимнәрдән Ә. Борһанов һәм В. Мирзаянов сайланды.

Оештыру комитеты октябрь башында үткәргән татар җәмәгатьчелеге кичәсенә данлыклы милләттәшләребез күпләп җыелды. Кичә барышында татар рәссамнары һәм һөнәрчеләренең сәнгати әсәрләре аукционы эшләде. Сөйләшүләр һәм чыгышлар Казаннан махсус килгән Рамил Миндияр, Наилә Фатыйхова, Наил Нәгыймов кебек җырчыларның моңнары белән аралашып барды.

Әлеге кичәне Мәскәүдәге Интеллектуальләр клубының генераль директоры, язучы Нәзифә Кәримова оештырды һәм алып барды.

# ТӘҢГӘЛЛЕК...

Рәшит Госманның акварель парчаларына караганда, бу ябалдаш агачлардан, күл тирәли, мәрҗән кебек, тезелешеп утырган төнбоеклардан, баскыч-баскыч ефәк зәңгәрсу күк тавына менеп киткән шәфкатьле авыл йортларыннан гыйбарәт мөлдерәмә тулы самими дөньяның җанлы матурлыгына гаҗәпләнеп, шөкранә кыласың... Теге-яки бу җирдә капылт кына чагылып киткән шәүләләр, нурланып, тирә-якка сибелгән яктылык агышы, яфрак-агачларны кыймылдаткан җил аһәңе, бу могҗизаны тоташ бер тотрыклы күренешкә әйләндергән һава катламы һәм әсәрләрнең теге-яки бу өлешенә җай гына иңдерелгән кеше сыннары — рәссам нәкышьләгән манзараның әллә нинди мәңгелек мәгънәне аңлатуына ишарәлиләр... Иҗатчының әйтергә теләгәне: табигатьтән, аның хозур гүзәллегеннән дә кыйммәтле бөек әйбер юк... Ул — илһам чыганагы һәм бәрәкәтле тема; анда портрет һәм риваять, дастан һәм бетмәс-төкәнмәс им-том, ырым, сихернең мәҗүси матдәсе, бәхет һәм фаҗига... Яшәү — үлем. Иҗат энергиясе...

Чыннан да, рәссамның кайбер кара-коңгырт, яшел-зәңгәр төсләрнең нечкә җепселләреннән «чигелгән» пейзажларына багасың да, аның теләге шушы тасвирланган күренеш белән чикләнмәгәнен, манзараларның тирәнлеге аның күңел тирәнлегенә, уй-фикер чиксезлегенә тәңгәл килгәнне аңлыйсың...

Мәдхия тәмам!.. Әлбәттә, бу осталык артында күп көннәр, төннәр эчендә барган мәрхәмәтсез хезмәт, олугъ табигатьне шәкертләрчә өйрәнү, йөз-мең данәләрчә экспериментлар ята. Шул хезмәт һәм шәхсән фидакарьлеге Рәшит Госманны беренче дәрәҗәле акварельче һәм нәкышьче — җанлы язу остасы итеп җитлектерде дә. 1970—1990 еллар эчендә аның әсәрләре, хаклы рәвештә, иң абруйлы Бөтенсоюз, Бөтенруссия, Олы Идел зонасы, үз җөмһүриятебездә оештырылган иң әһәмиятле күргәзмәләргә куелдылар. Сынлы сәнгать музее, милли мәдәни мәркәз экспозицияләрен бизәделәр. Мәскәү, Петербург һәм башка сәнгать мәркәзләренең коллекцияләрен баеттылар һәм йөзләрчә әсәре элита вәкилләре, зыялылар, фәнни хезмәт кешеләре, хәтта президентлар, сәяси эшлеклеләр, илчеләр тарафыннан дулкынланып кабул ителделәр.

Инде чит илләргә килгәндә, аның иҗаты һәм исеме океан артында һәм Аурупа илләрендә — Франция, Алмания, Италия, Австрия, Венгриядә; көнчыгышта — Төркия, Япония, Кытайда үз илебезгә караганда да популяр дияргә була. Рәшитнең әсәрләре егермеләп илдәге музей-коллекцияләрдә саклана. Америка Кушма Штатларында гына да эшләре Сан-Франциско, Филодельфия, Сан-Диего, Питцбург шәһәрләре сәнгати тупланмалары арасында мәгълүм. Нәзәкатьле акварельләр һәммә кешедә дә соклану, сөю хисләре уята... Бу хакта Рәшиткә аның бер төркем әсәрләрен бүләк рәвешендә кабул итү бәхетенә ирешкән Америка Кушма Штатларының президенты җылы итеп махсус хатын да язып җибәрә...

Менә шулай, һава чөмерүче атлар, суда тибрәнгән ялгыз көймәләр, Идел-Чулман офыклары, меңьеллык авыллар, «галибанә» гүзәл кояш батулары, моңлы шәфакълар, карлы иртәләр, урман чатырлары... Мәңгелек моңлы, илаһи тирәлек... Көмеш-соры, көрән-алсу төсләргә өретелгән җәүһәрләр...

Рәшитнең әсәрләр панорамасын карыйсың да, аның пейзажчы офыкларының киңлегенә, игътибарының иксез-чиксезлегенә шаккатасың... Монда Америка күренешләре, аның елга-күперләре, җанлы урамнары, яшеренеп калган тын пейзаж базислары; Себер-Алтай таулык-бозлыклары, «кирегә агучы» елгалары, перевållар; Кавказ-Кырымның илаһи матурлыгы, Казакъстан тозлы такырларының кырыс экзотикасы, ата-бабаларыбызның ихласын белгән дала-авазлары, ирекле-кодрәтле дөнья. Чиксезлек... Болгар сериясе, Идел-Чулман сулары, унбиш яшеннән ятим калган малайның аяк сеңерләрен шактый кискән, тигәнәк-тузганаклы «Татарстан». Пейзажлар дастаны, әйтерсең лә, Рәшитнең одиссеясе...

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече

**Тышлыкның беренче битендә:** Рәшит Госманның «Җәй» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган әдип Әхәт Гаффар.


**М. ШАКИРҖАНОВ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




СУЛТАНБЕКОВ Б. Ф. **История Татарстана: страницы секретных архивов.**— Казань: Татар. кн. из-во, 1994.—253 с. Тираж—3000 экз.

Бүген тарих фәнендә инде күптән билгеле дип «исбатланган» вакыйгаларны яңабаштан өйрәнү, барлау, фактик материаллар белән баету күзәтелә. Бу хәл Татарстан тарихына да кагыла. Тарихчы Булат Солтанбәков әлеге китабында, архив материалларына нигезләнеп, Татарстан Республикасының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге өчен гаять мөһим фактларны яктырта. Китап урыс телендә дөнья күргән.





САИНОВА-АХМЕРОВА Д. З. **Салих Сайдашев.** *Биографические очерки.* Татар кн. из-во, 1994.—69 с. Тираж—10000 экз.

Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган бу китап татар халкының күренекле улы, олуг композитор Салих Сәйдәшевнең балачак һәм үсмер чор дөньясын яктырта. Мәҗмугада шулай ук композиторның дуслары һәм замандашлары хатирәләре, Сәйдәшев-Ахмәровларның шәхси архив материаллары, фотография дә урын алган. Китап рус телендә язылса да, гади, аңлаешлы телдә иҗат ителүе белән үзенә җәлеп итә, ул киң катлам укучыларга юллана.

Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог